А. Г. ЯХИН

Әдәбият

9



«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ

Әдәбият
А. Г. ЯХИН
9

ШӘФКАТЬЛЕЛЕК
УСАЛЛЫК
САБЫРЛЫК

А. Г. ЯХИН

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
9 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Өченче басма

Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан
тәкъдим ителгән

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2007

УДК 373:167.1:821.512.145*09
ББК 83.3(2Рос=Тат) я721
Я89

Охраняется Законом РФ «Об авторском праве и смежных правах». Воспроизведение всей книги или ее части на любых видах носителей запрещается без письменного разрешения издательства.

УКЫТУЧЫЛАР ИГЪТИБАРЫНА!

Шушы дәреслек белән эшләү өчен, А. Г. Яхинның «9 нчы сыйныфта әдәбият дәресләре: Укытучылар өчен методик кулланма» дигән китабы ирекле сатуга чыгарыла.

Яхин А. Г.

Я89 Әдәбият : Татар урта гомуми белем бирү мәкт. 9 нчы с-фы өчен д-лек / А. Г. Яхин.— Өченче басма.— Казан : Мәгариф, 2007.— 407 б.: порт. б-н.
ISBN 978-5-7761-1664-3

ISBN 978-5-7761-1664-3

© «Мәгариф» нәшрияты, 2001, үзгәрешләр белән
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2007

Кереш

Быел сез әдәбият тарихын өйрәнә башлаячаксыз. Тарих дип үткән заман агышына һәм шул заманда булган әһәмиятле вакыйгаларга әйтәләр.

Вакыт үтә. Буыннарны башка буын алмаштыра. Хуҗалары белән бергә аларның күңел дөньялары да юкка чыга. Яңа буын кешеләре күңеленнән тарихның башка вакыйгалары үтә. Бу вакыйгалар шулай ук күңелләрдә үз дөньяларын тудыралар. Ләкин алдагы буын кешеләре туплаган кичерешләр байлыгы тарихның үз вакыйгалары кебек үк югалмыйлар. Алар җырлар, дастаннар булып халык күңелендә сакланалар. Бу байлыкны әдипләребез барлап, җыеп, үзләреннән дә хисләр өстәп, кәгазьдә теркәп калдыралар. Буыннарның эчке дөньялары шулай ялгана.

Матур әдәбият кешеләргә бүтәннәрнең мәхәббәтен, өметләрен, теләкләрен, хәсрәт-шатлыкларын үз хисләре итеп кичерергә өйрәтә. Шулай итеп, матур әдәбият укучылар башкалар хисе белән яшәп алалар. Шул рәвешле, үзләренең хис байлыкларын тулыландыралар. Башкаларның хәленә керергә өйрәнәләр.

Хисләр искермиләр. Тарихның бер чорыннан икенчесенә күчеп яңара, тулылана гына баралар. Алдагы буыннарның хис дәрәҗәсен хәзерге укучы да үз хисләре, үз кичерешләре итеп кабул итә. Әдәбият тарихының төп үзенчәлеге шуннан гыйбарәт.

Хәтердә калдырыйк: матур әдәбият тарихы — тарихи вакыйгаларның кеше күңелендә үз теләкләре, ихтыяҗлары, хисләре, бәяләре рәвешендә яшәве ул. Әдәбият тарихы,— шуның белән бергә, әдәби алымнар үсеше дә.

Әдәби әсәрләрдә һәм әдәби төрләрдә даими алымнар барлыгын белдек. Язучылар үзләре яраткан алымнарны шул даими алымнар эченнән сайлап алалар, нидер өстиләр, шул рәвешле, үзләренә генә хас стиль тудыралар.

Бу алымнарны әдипләр гасырлар буе иҗат иткәннәр. Әдәбият, шулай итеп, үзенең эчтәлеген һәм алымнарын баета-баета үскән. Заманалар алмашу сәбәпле, әдәбият та эчтәлеген үзгәртергә тиеш булган. Яңа эчтәлек яңа алымнар белән генә табыла алган. Әдипләр, тормышның тирән катламнарына үтеп керү өчен, сәнгать алымнарын камилләштергәннән-камилләштерә барырга мәҗбүр булганнар, аеруча сәләтлеләре яңаларын эзләгәннәр. Бу байлык югалмаган, буыннан-буынга күчә барган һәм милли байлыкка әйләнгән. Язучылар әдәбият хәзинәсендәге җәүһәрләрне үзләренеке белән алмаштырмаганнар, аларга башкаларын өсти торганнар.

9 нчы сыйныфтан башлап сез шул байлыкны өйрәнәчәксез. Әдәбият тарихындагы җәүһәрләр аерым-аерым караганда да матурлар. Әмма аларның чын асылы барын бергә җыеп караганда гына ачыла. Алар, бер-берсенә нур чәчеп, үзләрендәге яңадан-яңа төсләрне яктырталар. Безне әнә шул нурлар — язучыларның иҗатлары һәм чорлар арасындагы бәйләнешләр кызыксындыра.

Моңа кадәр сез әсәр эчендәге, әдәби төр эчендәге һәм аерым язучы әсәрләре арасындагы бәйләнешләрне өйрәндегез.Чор эчендәге бәйләнешләр аларның барын да үзенә җыеп ала, гомумиләштерә. Шуңа күрә, әдәбиятның бөтен бер чорына анализ ясаганда, өстәмә алымнардан файдаланырга туры килә.

Быел сез татар әдәбиятының борынгыдан башлап Октябрь революциясенә кадәрге үсешен өйрәнәчәксез. Ә 10—11 нче сыйныфларда әдәбият үсешенең башка чорлары белән танышырсыз.

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫН ӨЙРӘНҮ ПРИНЦИПЛАРЫ

Әдәбият әдәби әсәрләр арткан саен байый бара, дидек. Әмма әдәбият сан-күләм ягыннан баю белән генә канәгатьләнми, эчтәлеген дә үзгәртә. Үзгәргән эчтәлек үзенә кулай алымнар таба. Әдипләр, тормышны тирәннәнрәк өйрәнгән саен, яңадан-яңа катламнар ачалар. Яңа эчтәлекне сөйләп бирү өчен, яңа жанрлар кирәк була. Тормыш үзе дә әледән-әле җитди үзгәрешләргә дучар була. Бу үзгәрешләр язучылар алдына яңа мәсьәләләр куя. Аларны чишү өчен, яңа сурәтләр, типлар барлыкка килә. Шул рәвешле, әдәбият башка халәткә күчә. Шундый яңа халәткә әдәбият үсешенең чираттагы чоры диләр. Һәр чорга әдәбият эчтәлегенең һәм алымнарының тотрыклылыгы хас. Ләкин ниндидер даими сыйфатлары булу чорның үз эчендә, язучылар иҗатында үзенчәлекләр юк дигән сүз түгел. Һәр чор үз эчендәге шундый үзенчәлекләре белән бай һәм кызыклы.

Безнең бурыч шушы үзенчәлекләр, төрлелекләр эченнән охшашлык эзләүдән гыйбарәт. Әдәбият тарихын сез бик катлаулы бөтен бер күренеш итеп өйрәнәчәксез. Ләкин моның өчен төрле чорларны буйдан-буйга кисеп чыккан һәм аларны җыеп, берләштереп торучы бик мөһим гомуми эчтәлек булырга тиеш. Андый гомуми эчтәлекне ничек табарга соң?

Әдәбият тарихын өйрәнүне без борынгы чордан башлыйбыз. Шуңа күрә әдәбиятның төп темасын борынгы заманда яшәгән кешеләрнең дөньяга карашыннан эзләп карыйк.

ТЕЛ

Матур әдәбият буш урында үсеп чыкмаган. Бик борынгы кешеләр башта мифлар, әкиятләр, мәкальләр, җырлар, әйтемнәр, табышмаклар уйлап чыгарганнар. Дастаннар иҗат иткәннәр. Әдәбиятның иң әһәмиятле алымнары телдән генә сөйләнә торган мифларда, аннары халык авыз иҗаты әсәрләрендә туган.

Бик борынгы бабайлар, мифлардан да алданрак, үзара аралашу өчен сөйләм теле иҗат иткәннәр.

Агачларга төртеп күрсәткәннәр дә «бу» дигәннәр. Кешеләргә төртеп күрсәткәннәр дә аларга да «бу» дигәннәр. Күз күргән барлык нәрсәнең «бу» булуы сөйләшүне шактый авырлаштырган. Шуңа күрә үз кешеләрен башка ыруг кешеләреннән аеру өчен, «бу» сүзен «алар» һәм «без» дип икегә бүлгәннәр. Аннан соң күз алларында булган предметларның иң кирәклеләренә исемнәр биреп чыкканнар. «Җәя», «ук», «көймә», «ут» һ. б. Ләкин бергәләп яшәү өчен, әйберләргә исем бирү генә дә җитмәгән. Хәрәкәтләрне, үзгәрешләрне ничек булса да атау ихтыяҗы туган. Борынгылар, исемнәрне фигыльләр белән бәйләп, җөмләләр төзергә өйрәнгәннәр. «Ук ата», «көймә йөзә», «ут яна» дип аңлаша башлаганнар. Шулай итеп, үсемлекләр дә, хайваннар да, кешеләр дә, күк җисемнәре дә, аларның хәрәкәтләре дә исемле булганнар. Хәзер галимнәр ул исемнәрне «тамга» (знак) дип йөртәләр.

Тора-бара дөньядагы чиксез күп нәрсәләрне тәртипкә салып гадиләштерергә кирәк булган. Арадагы бер зирәге каен белән имәннең уртак ягын күреп алган. Икесе дә яфраклы, икесе дә учакта яна, кышын яфраксыз кала. Алар бер-берсенә охшаганнар бит, ди. Шулай булгач, әйдәгез, икесен бер исем белән атыйк дип киңәш бирә. Бергәләп, каен белән имәнгә «агач» дигән исем уйлап табалар. Аннан соң бу исем астына юкәне дә, тупылны да, талны да, башка агачларны да җыеп сөйли башлыйлар. Төрле-төрле ерткыч хайваннарга «җәнлекләр» диләр. «Хайван» сүзен уйлап чыгаралар. Хәрәкәт исемнәрен дә бергә җыеп була икән: файдалы гамәлләрнең барысын бергә «эш» дип атыйлар.

Төрле әйберләргә уртак исем бирүгә хәзер гомумиләштерү, дибез. Гомумиләштерүнең фикерләү булуын искә төшерсәк, борынгы кешеләр сөйләм телен иҗат иткәндә үк фикерләргә өйрәнгәннәр дигән нәтиҗә ясыйбыз. Ләкин тора-бара сөйләм теле үзе тормышны танып белү һәм фикерләү чарасына әйләнә. Сәнгатьчә фикерләү исә фәкать сөйләм теле үсеп камилләшкәч кенә барлыкка килә.

МИФЛАР

Тел кешеләрне уйларга өйрәтә. Уйлый башлау белән, кешеләрне мең төрле сорау борчый башлый: Җир ничек барлыкка килгән? Диңгез каян агып килгән? Акчарлаклар каян очып чыкканнар? Йолдызлар ничек туган?

Борынгы бабайлар бөтен тирә-якларын урап алган билгесезлекне билгеле итәргә керешәләр.

Җир ничек барлыкка килгәнме?

Бик борынгы заманда Җир булмаган. Бөтен дөньяны су каплаган булган. Су уртасында берданбер үрдәк йөзеп йөргән. Ул диңгез төбендәге җим белән туена икән. Беркөнне чумган да, җим урынына диңгез төбеннән томшыгына кабып, җир алып чыккан. Җирне ашап булмый бит. Ташлаган. Җир менә шулай барлыкка килгән, диләр. Һәм шуңа ышаналар.

Ә Диңгез үзе ничек туган?

Бик борынгы заманда ялгыз яшәүче әби өй артына чыга икән дә, чүлмәгенә тутырып, су алып керә икән. Бу хәл шулай кабатланган. Күршеләре күзәтеп торганнар. Әби урманга киткәч, күршеләре дә шул урынга чыгалар. Анда зур әрекмән яфрагы күрәләр. Әрекмән яфрагында бака утыра икән. Күршеләре ук алалар да бакага аталар. Ук әрекмән яфрагын тишеп чыга. Ә яфрак өстендә су булган. Су шул тишектән аккан да аккан. Аккан да аккан. Диңгез менә шулай барлыкка килгән, диләр.

Йолдызлар ничек барлыкка килгән?

Мәнди исемле бик матур кыз яшәгән. Үзе бик ялкау булган. Башка кызлар җир казыйлар, урманга чыбыкка йөриләр, яшелчә үстерәләр. Ә Мәнди көне буе биләмдә йөри. Эшче кызлар өйләренә кич кенә кайтып керәләр. Мәнди исә иптәшләре ашарга пешереп өстәл янына утыргач кына кайтып керә торган булган. Кызлар арасында аеруча булдыклысы Мөсәп булган. Ул Мәндине көн дә үзе белән иртән эшкә чакырган. Әмма ялкау кыз аның сүзен тыңламаган. Биләмдә йөргән, көпә-көндез йоклаган. Беркөнне болында йоклап ятканда, аны чит ыру егетләре урлап китәләр. Мәнди төнлә алардан кача һәм күккә менә. Күктә ул бик матур йолдызга әйләнә. Хәзер аны көн дә иртәнге якта күреп була. Мөсәп тә йолдызга әйләнә. Ләкин ул йолдызны фәкать караңгы төшә башлагач кына күрергә була. Мөсәп күктә дә иртүк торып эшкә китә, өенә кичен генә әйләнеп кайта.

Шуның өчен яшь кызларга кичке йолдызга охшарга кушалар да, дип сөйлиләр.

Борынгы бабайлар үзләрен урап алган таулар, елгалар, урман турында да, Ай, Кояш, Җил турында да, гомумән, үзләрен кызыксындырган һәрнәрсә турында хикәятләр уйлап чыгарганнар. Сөйләгән уйдырма вакыйгаларының, чыннан да, хак булуына үзләре дә ышаналар, башкаларны да ышандыралар.

Истә калдырыйк. Дөньяны хыял белән аңлаткан хикәятләргә **мифлар** диләр.

Мифлар борынгыларның фәне дә, сәнгате дә, тәрбия чарасы да булган. Кешеләр үрдәкнең кечкенә генә томшыгында Җир кадәр Җирне диңгез төбеннән алып чыга алуына гаҗәпләнгәннәр. Әрекмән яфрагы өстендәге суның, кечкенә генә тишектән агып, диңгез булып җәелүенә аптыраганнар. Мәнди исемле кызның булдыксызлыгыннан егыла-егыла көлгәннәр. Аның якты йолдызга әйләнүенә сокланганнар.

Борынгы кешеләр дә, безнең кебек, тынычлыкта, бәла-казасыз яшәргә омтылганнар. Әледән-әле чыгып торган бәла-казадан котылу юлларын эзләгәннәр. Алар бәла-казаны да, уңышларын да янәшәдәге ниндидер яман һәм яхшы көчләрдән килә дип исәпләгәннәр. Шүрәле, убыр, бичура, су анасы, өйияләре, өрәк, албасты кебек шыксыз әкәмәтләр уйлап чыгарганнар. Борынгы кешеләр, тормыш вакыйгаларын аңлату белән бергә, тормышларын җиңеләйтү өчен, махсус кагыйдәләр дә уйлап тапканнар. Мәсәлән, кеше ялгызы гына кара урманга керсә, аны Шүрәле кытыклап үтерә, дигәннәр. Миф тыңлаучы, әлбәттә, шыксыз Шүрәледән курыккан һәм ялгызы гына урман эченә кермәгән — адашмаган.

Суның тирән һәм бөтерелеп торган урынына керсәң, су анасы сөйрәп ала; йон эрләп бетермәсәң, аның эченә өй иясе кереп оялый, ә икенче көнне эрләргә утырган кешегә зыян китерә дигәннәр. Тыңлаучы тирәнгә кермәгән, бүген эшлисе эшен иртәгәгә калдырмаган. Әкәмәтләр начар сүз әйткәнне, әдәпсезлекне, ялкаулыкны, хәтта идән астына пычрак су түгүне дә яратмаганнар. Кирәкмәгән эшләрне эшләүчеләргә җәза бирергә әзер торганнар.

Борынгы кешеләр үзләре уйлап чыгарган мифлардан белем дә алганнар, тәэсирләнгәннәр дә. Аларга миф иҗат итүчеләрнең иҗади фикерләве тәэсир иткән.

Әкиятләр, җырлар, мәкаль-әйтемнәр, табышмаклар төзүче сәнгать алымнары башта мифларда оеша башлый.

ХАЛЫК АВЫЗ ИҖАТЫ ӘСӘРЛӘРЕ

Халык авыз иҗаты әсәрләре кешелек яшәешенең югарырак баскычында туа. Аларның берише миф сюжетларыннан үсеп чыга. Башкалары, мифларда ук табылган сәнгать алымнарын үстереп, миф образларын файдаланып иҗат ителә.

Борынгы бабаларыбыз, кабиләләргә җыелып, бер урынга төпләнеп утыргач, кешеләрнең борчылу сәбәпләре үзгәрә. Моңа кадәр төп бурыч мифлар ярдәмендә табигать көчләрен аңлап җиңү булса, хәзер мифлар яңа төзелгән җәмгыятьне саклап калу бурычын үти башлыйлар.

Аерым кешеләрнең һәм гаиләләрнең язмышы хәзер җәмгыять иминлегенә бәйле булганга, халык үзенең иҗатын җәмгыятьне ныгытуга багышлый. Җәмгыять тотрыклы булуы белән көчле. Ул үзенең иң зур байлыгын — күп буыннар туплаган тормыш тәҗрибәсен — яңа шартларда да саклап калу өчен көрәшә. Халык авыз иҗатын баету — шул көрәшнең аеруча әһәмиятле чарасы.

Кешеләр көндәлек тормышта мөмкин кадәр азрак ялгыш ясарга тиешләр. Башкалар ясарга өлгергән ялгышны кабатламасаң, тормышта күп мәшәкатьтән котылырга мөмкин. Ләкин моның өчен башкалар ялгышын белергә кирәк. Шул тәҗрибәне халык хәтердә сакланырлык җыйнак, тәэсир итәрлек хикмәтле итеп әсәрләргә әйләндергән. Мәкальләр, әйтемнәр, мәсәлләр, табышмаклар шулай туган.

Элек-электән кешеләр, бер-берсенә табышмак әйтеп, үзләренең зиһеннәрен чарлаганнар. Уйлый белү бик күп ялгышлардан коткарган.

Хәсрәт кешене аяктан егарга мөмкин. Хәсрәтле кеше башкаларның да өнен ала. Халык, хәсрәтле кешеләргә юану өчен, җырлар тәкъдим итә. Сайлап ал, җырла. Үзең җырлый белмәсәң, башкалар җырлаганны, мөнәҗәт әйткәнне тыңла, ди.

Халык иҗатының беренче үрнәкләрен моннан тугыз йөз ел элек төрки галим Мәхмүд Кашгарый язып калдырган. Аның «Төрки телләре җыентыгы» (үзе куйган борынгы төрки телдәге исеме «Диване лөгатет-төрк») әсәрендә мондый җырлар бар:

Авлаб мәни коймаңыз,
айык айыб каймаңыз;
акар көзүм—уш тәңиз,
тәгрә йөрә куш учар.

(Мине аерып калдырмагыз,
вәгъдәдән баш тартмагыз;
яшьле күзем — ул диңгез,
тирәли кошлар оча.)

Буч-буч өтәр сәүргүк[1],
богзы үчүн мәңләнүр;
өзүм мәниң — будурсын,
оты аның чакланур.

(Буч-буч сайрый сәүргүк,
тукланырга җим ала;
минем күңелем — бытбылдык,
гыйшык утында яна.)

---

[1] *Сәүргүк* — сәмруг кош.

Күрәсез, борынгы җырларда ук хис дәрәҗәсен күрсәтү алымнары туган. Табигать күренешләре белән күңел хисләрен янәшә куеп, җырчылар, үзләре дә белмичә, метафора алымын уйлап тапканнар.

Академик В. А. Гордлевский әйтүенчә, Х гасырда ук халык мәзәкләре тупланган китап булган. Хуҗа Насретдин турындагы безгә мәгълүм булган иң борынгы мәзәкне дә В. А. Гордлевский язып калдырган:

«Әтисе үлгәч, улы: «Әтием, бәгърем, сине йоклар өчен урынҗире булмаган, келәмсез, утсыз, иписез караңгы йортка илтәләр»,— дип елый икән. Аны ишетеп, Хуҗа Насретдинның улы: «Әти, аны безнең өйгә илтәләрмени?»— дип сораган».

Бу мәзәкнең төзелеше хәзерге мәзәкләргә нык охшаган. Аны иҗат итүчеләр үткен фикер алымын бик оста кулланганнар.

Нәтиҗә ясыйк. Татар халык авыз иҗаты жанрларының берише кешеләрнең көндәлек тормышы белән турыдан-туры бәйле. Җырларның, мәкальләрнең, әйтемнәрнең, табышмакларның тулы эчтәлеге фәкать конкрет вакыйгалар белән бәйләнештә генә ачыла. Шуңа күрә халык авыз иҗаты жанрларының бу төркемен, берсе — гамәлдәге тормыш вакыйгасы, икенчесе — авыз иҗаты әсәре дип, ике өлешкә бүләбез. Бу төркем кешеләрне җәмгыятьтә урнашкан тәртипләрне хөрмәт итәргә, анда тупланган тәҗрибәне файдаланырга кирәклеген көн дә кисәтеп тора.

Дастаннар, әкиятләр, мәзәкләр халык авыз иҗаты жанрларының икенче төркемен тәшкил итәләр. Икенче төркемгә кергән жанрлар беренче төркемнең киресен эшлиләр. Вакыйгаларга һәм өлкәннәр тәҗрибәсенә ярашып яшәргә өйрәтмиләр, тормыш вакыйгаларының үзләрен үзгәртәләр.

Дастан, әкият, мәзәк эчтәлекләрендә уртак як бар: бу жанрлар бар да көчле белән көчсез конфликтында көчсез якны яклыйлар. Тормышта көчле һәрвакыт көчсезне җиңә. Әкияттә дию патшаның хатынын урлап китә, аждаһа кешенең алмасын урлый, бай ярлыны алдый, төлке әтәчне ашамакчы була... Ләкин ахырда шуның киресен күрәбез.

Халкы аз булган ил үзенең дастаннарында көчле дошманнарын берДәнбер Алып батыр белән җиңә. Моның өчен халыкка меңәр кешене бер селтәнүдә кырып сала торган мәһабәт Алып батыр образын иҗат итәргә кирәк була. Дастаннарга ярдәмгә әкиятләрнең дә бер өлеше килә. Героик әкиятләр дип

аталган әкиятләр дә патшаны һәм аның улларын җиңүче итәләр, чөнки патша — ил иминлеген саклаучы гаскәр башы.

Тылсымлы әкиятләрдә көчле як — патша, бай; көчсез як — халык. Шуңа күрә халык, әкиятләре белән булса да, үзен патшадан саклый, аны ярлы крестьянның кече улыннан җиңдерә.

Шулай итеп, халык үзенең иҗаты белән җәмгыятьне ике төрле ныгыта: кешене көндәлек тормыш эчендә тәрбияли һәм, үзе уйлап чыгарган хыялый тормыш турында сөйләп, рухи яктан үстерә.

ДИН

Дин — җәмгыятьне яшәтү, ныгыту коралларының аеруча көчлесе. Ул мифлар һәм халык авыз иҗаты жанрлары туплаган тәҗрибәләрне дә бик теләп үзләштерә. Ә андагы кайбер әсәрләрне тулысы белән файдалана. Дин кешеләргә Алла абруена таянып тәэсир иткән.

Коръәнгә мөрәҗәгать итик. Адәмне Алла балчыктан ясый. Һаваны аның кабыргасыннан оештыра. Алар оҗмахта бер кайгысыз, уйсыз, хиссез яшиләр дә яшиләр. Таш, су, ком кебек шулай яшәүләрен дәвам иттерерләр иде дә бит, көннәрнең берендә, шайтан вәсвәсәсенә бирелеп, өзәргә ярамаган алманы өзеп ашыйлар. Безгә мәгълүм булган иң беренче яман эш шулай башкарыла.

Шайтан котыртты дип торып булмый, кылган гөнаһларың өчен җавап бирергә кирәк. Ачуы килгән Алла гөнаһлы бәндәләрен оҗмахтан һәм мәңгелек яшәүдән мәхрүм итә. Җир өстенә менгерә дә, рәхәтлекнең кадерен белмәсәгез, үзегез эшләп ашагыз, ди.

Ләкин Алланың мәрхәмәте ачуыннан көчлерәк булып чыга. Таштай, комдай матдә рәвешендә генә яшәгән Адәмне ул кешегә әйләндерә. Әлеге вакыйгага кадәр яхшылык белән яманны Алла берүзе генә аера алса, хәзер Адәм белән Һава да бу аерманы яхшы беләләр. Оҗмахта әзергә хәзер булып яшәгән бәндә тамагын туйдырыр өчен эшли башлый, хезмәт шатлыгын татый. Адәм белән Һава кавышалар — хискә ия булалар. Шуннан соң да Алланың бөтен эше кешеләргә ярдәм итүдән гыйбарәт була. Башта Адәм гаиләсен үрчетүгә күп көч куя, Җирдә яшәүче кешеләрне күбәйтә. Чәчүлек орлыклар бирә, Кояшны, Айны бар итә, орлыклар үссен дип, яңгырлар яудыра, йоклап ял итсеннәр дип, төннәр булдыра.

Җирдә кешеләр күбәйгәч, Алланың мәшәкате тагын да арта. Ул кешеләрнең ни теләсәләр, шуны эшләп йөрүләрен күреп ала. Төрле бозыклыкларга, яман эшләргә юл куймау ниятеннән чыгып, кешеләргә пәйгамбәрләр җибәрә. Алар кешеләргә яшәү кагыйдәләрен өйрәтергә тиеш булалар. Үзара тату, килешеп яшәгез, диләр. «Моның өчен ни эшләргә кирәк?» — дип сорыйлар кешеләр. «Тату яшик дисәгез, Алла сүзенә ышаныгыз, Алла әйткән туры юлга чыгыгыз, яманны яхшылыктан аера белегез»,— диләр пәйгамбәрләр. Алла ул — мәрхәмәт, аның бөтен эше яхшылык дип аңлаталар. Яшәү кагыйдәләрен күңелләренә сеңдерсеннәр өчен, кулларына Коръән тоттыралар, бу изге китапны Алла үзе әйтеп яздырган, диләр.

Кешеләр пәйгамбәрләрне тыңлыйлар. Коръәнне укыйлар да яхшылыкны аңлый башлыйлар. Кара әле, яхшылык яманлыкның киресе икән, диләр. Аннары яманлыкны өйрәнергә керешәләр. Ә Коръәндә: «Саран булма, мохтаҗ кешеләргә ярдәм кулыңны суз, әти-әниеңне рәнҗетмә, үчле булма, хатасын таныган яманнарны гафу ит, борыныңны күтәреп, һавалы булып йөрмә, үзеңнән көчсезләрне кыерсытма» диелгән.

Тора-бара бу кагыйдәләр кешеләрнең үз ышанычына, табигатенә әйләнә. Андый кешеләрне ә х л а к л ы к е ш е л ә р диләр.

Дин фәлсәфәсендә дә матурлык бар. Алла тудырган тормыш Коръәндә м а т у р л ы к дип бәяләнә (32 нче сүрә, 6 нчы аять). Ләкин андагы матурлык үзкыйммәт югарылыгына менә алмый, файда ягыннан карала. 42 нче сүрәнең 1 нче аятендә Аллага рәхимнәрнең дә рәхиме, җирдә дә, күктә дә идарә итүче, һәрнәрсәне тудыручы дип бәя бирелә. Бәя биргәндә Алланың сабырлыгы да, миһербанлылыгы да, хакыйкать булуы да күз алдында тотыла. Бу сыйфатларны җыеп карасак, кешеләрнең безгә күптән таныш күркәм сыйфатларын күрербез. Тик алар яхшыга таба чиктән тыш арттырылганнар, Җирдән ашып, илаһи эчтәлек алганнар.

Иң зур теләкнең хыял белән баетылган эчтәлегенә м ә һ а б ә т (возвышенное) диләр.

Мифлар, халык авыз иҗаты һәм дин матур әдәбият үсеп чыгу өчен уңдырышлы җирлек була. Бу җирлектән әдәбият сәнгать алымнарын да, сурәтләү ысулларын да, эчтәлекне дә бик теләп үзләштергән. Әдәбиятның әзергә хәзер булып килүе табигый дә. Ул да җәмгыятьне ныгыту өчен туа бит.

Әмма матур әдәбият туу өчен, тагын бер шарт — җәмгыять үсешенең билгеле бер дәрәҗәгә ирешүе һәм язу барлыкка килү кирәк булган.

Сораулар һәм биремнәр

1. Сүз йә предметны, йә хәрәкәтне, йә нинди дә булса сыйфатны алыштыра, дидек. Сүз белән предметның яки хәрәкәтнең эчтәлеге бер үк. Материаллары турында алай димәс идек. Каен агачы белән «каен» сүзе дә бер үк эчтәлектә. Сүз материалы белән агачны чагыштырыгыз. Аларның кайсысында сыйфатлар күбрәк? Җавабыгызны исбат итегез.

2. Табигатьтәге вакыйганы аерып куйыйк: каен яфрагын коя. Борынгы кеше шул күренешкә карый да: а) каен яфрагын коя, ди; ә) каен да яфрагын коя, ди; б) каен яфрагын коя да, ди.

Табигать вакыйгасы белән шул вакыйганы алыштырып килүче җөмләләр арасында нинди аерма бар?

Җөмләләрнең үзләре арасында нинди аерма бар?

Шул ук җөмләләрне төрле интонация белән, ягъни басымны төрле сүзләргә күчереп әйтегез. Шулай итсәгез, ни үзгәрә?

Җаваплар табылгач, нинди нәтиҗә чыгарасыз: эчтәлек табигать вакыйгасында күбрәкме, әллә аны алыштырып килгән җөмләләрдәме?

3. Яфрагын койган каенга карасак, чынбарлыкка караган булабыз. «Яфрагын койган каен» дип әйтүче кеше үзенең җөмләсендә шул чынбарлыкны чагылдыра. Ләкин бу җөмләдә әлеге чынбарлыктан башка җөмләне әйткән кеше дә, атап әйткән башка кеше дә бар. Өстәвенә тиктомалдан бер җөмлә әйтелми, шуңа күрә анда алдарак сөйләшкән башка җөмлә эчтәлеге дә бар. Чагылдыручы җөмлә чынбарлыкның үзеннән эчтәлеккә баерак булып чыга.

Шуны ачыграк итеп исбат итегез: әлеге җөмләгә кеше һәм аның иптәше ничек килеп керә? Алдагы сөйләшкән сүз эчтәлеге нинди булырга мөмкин? Әйткәннәрдән чыгып, борынгы кешеләрнең беренче җөмләсендә үк әдәбиятка хас тормышны чагылдыру ялгысы бар, дип нәтиҗә ясау дөрес буламы?

4. Бишенче сыйныф дәреслегендәге кое казудан баш тарткан «Тавык» мифын исегезгә төшерегез. Бу мифта борынгы кешеләр җәмгыятен ныгыту идеясе бар. Шуны исбат итегез.

5. «Ак бүре» әкиятен исегезгә төшерегез. Бу әкияттә дә, башкаларындагы кебек, кабатланган вакыйгалар күп. Мәсәлән, башта әнисен эзләргә патшаның өлкән улы китә. Аннары уртанчы улы, аннары кечесе. Кабатланган вакыйгаларның башкаларын исегезгә төшерегез. Кабатлану — әдәби әсәр алымы да. Әкияттә әдәби әсәрләргә хас башка алымнар да бар. Шул алымнарны әйтегез.

6. Мәхмүд Кашгарый язып калдырган халык җырларының теленә игътибар итегез. Андагы сүзләр тәрҗемә иткәч кенә аңлашыла. Шулай булгач, борынгылар бер-берсен ничек аңлаганнар?

7. Борынгы җыр строфаларының икесендә дә хис дәрәҗәсе бар. Шуларны табыгыз.

8. Икесендә дә хиснең сәбәбе бар. Сәбәпләрне табыгыз.

9. Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкнең эчтәлеге әйтелмәгән. Мәзәкләр эчтәлеген тыңлаучы үзе табарга тиеш. Мәзәк эчтәлеген табыгыз. Аннары эчтәлекне үз сүзләрегез белән язып куегыз. Аны мәзәк сюжеты белән чагыштырыгыз. Сөйләм җөмләсе белән мәзәк сюжеты арасындагы аерма үткен фикер алымы була. Шул аерманы табыгыз.

БӨЕК БОЛГАР ДӘҮЛӘТЕ

Элек татарларны болгарлар дип йөрткәннәр. Болгар теле башкорт, үзбәк, казакъ, карачай, Кырым татарлары, якут, каракалпак, кыргыз телләренә бик охшаган. Бу халыклар бер-берсен яхшы аңлыйлар. Охшаш күренешләр гомумиләштерүне үзләре сорап торалар. Шуңа күрә, күпмедер аермалары булса да, охшаш телләрне бер гомуми сүз белән төрки телләр дип әйтәләр.

Төрки — көчле, нык дигән сүз. Бер телдә сөйләшүче халыклар кайчандыр Урта Азия һәм Себер кебек зур мәйданда яшәгәннәр. Төрле ыруглар әле бергә кушыла торган булганнар һәм бер башлыкка буйсынганнар, әле тагын аерылганнар. Бергә кушылганда алар, чынлап та, дәһшәтле көчкә әйләнгәннәр.

Хәзер бу халыклар, бик зур тарихи юл үтеп, аерым милләтләр, дәүләтләр булып яшиләр. Үзләренең борынгы бабалары — төркиләр иҗатын барысы өчен дә уртак мирас дип өйрәнәләр. Орхон-Енисей елгасы буйларында табылган ташлардагы руник (чөйгә охшаган хәрефләр) язмалар шундыйлардан исәпләнә. Борынгы төркиләр тарихы бу язмаларда шигъри сурәтләр белән тасвирлана, шуңа күрә матур әдәбиятның безгә мәгълүм булган беренче үрнәкләреннән санала.

Төрки халыкларның авыз иҗаты үрнәкләре моннан тугыз йөз ел элек язылган китапта теркәлеп калган. Аларны Мәхмүд Кашгарый үзенең төрки телләр сүзлегенә мисал итеп керткән. Халык хәтерендә шул заманнарда иҗат ителгән бик күп легендалар, дастаннар сакланган.

Безнең борынгы бабаларыбыз башта Кавказ буйларына килеп яшиләр. Аннары Кама белән Идел тоташкан җиргә

килеп урнашалар. Монда алар Болгар (Биләр) каласын төзиләр һәм X гасырда, төрле ыругларны берләштереп, үзәкләштерелгән куәтле дәүләткә әйләнәләр. Куәтенең, мәдәниятенең алга китүен күздә тотып, аны Бөек Болгар дәүләте дип йөртәләр.

900—1000 елларда Болгарга гарәп язучылары һәм галимнәре килә. Алар күргән-белгәннәрен китапларында язып калдыралар. Әл-Бәлхи исемле язучы, мәсәлән, Болгар дәүләтендә Болгар һәм Сивар (Сувар) исемле зур шәһәрләр бар, шәһәрләрдә мәчетләр, мәктәпләр бар, дип хәбәр итә. Ибне Фадлан пристаньнарда сәүдә кораблары туктавы, зур базар булуы, Алмыш ханның базарга чыгып йөрүе турында яза.

Болгар дәүләте, чыннан да, үз заманында бик алга киткән дәүләт була. Аның башкаласында, мәсәлән, шул елларда ук йөз мең кеше яшәгән. Ибне Рөстә хәтта авылларда да мәктәпләр булуын яза. «Болгарлар — игенчелек белән шөгыльләнүче халык; бодай, арпа, тары һәм башка шундый һәртөрле ашлык игәләр. Аларның күпчелеге ислам динен тота»,— дип, безнең өчен бик әһәмиятле хәбәр әйтеп калдыра. Бу елларда болгарлар ислам диненә күчкән булалар һәм үзләренең чөйле язуларын гарәп хәрефләренә алыштыралар. Гарәп шрифтында уку һәм күп илләр белән сәүдә итү болгарларга мәдәнияте бик нык алга киткән Көньяк илләре фәнен һәм сәнгатен өйрәнүгә юл ача. Болгарларның хәтта чит дәүләтләрендә дә билгеле тарихчылары, язучылары була. Болгарларны бик яхшы төзүчеләр, һөнәрчеләр диләр. Алар оста сугышканнар да. 1223 елда, мәсәлән, монголлар гаскәрен җимерәләр. Безнең борынгы бабайлар дөнья, яшәү, тормыш турында да уйланганнар. Бәхет юлларын эзләгәннәр һәм бу тормышта үзләренең урыннарын табарга тырышканнар. Шуңа күрә әкиятләр, дастаннар, легендалар иҗат иткәннәр. Көндәлек тормышларында, ялгышлардан саклану өчен, мәкальләр, әйтемнәр, табышмаклар уйлап чыгарганнар. Җыр җырлап юанганнар.

Болгарларга дин фәлсәфәсен кабул итү кыен булмаган, чөнки үз фәлсәфәләре белән дин фәлсәфәсе арасында бик күп охшашлык күргәннәр.

Дөнья гап-гади итеп яхшылыкка һәм яманлыкка бүленгән. Бу бүленеш тормышның төп эчтәлеге рәвешендә гасырлар буена сакланып килгән.

Яхшылык — артырга, яманлык кимергә, бетәргә тиеш булган. Бу максат җәмгыятьне сугышлардан, таркалудан, гаиләне

ызгышлардан, кешене ялгышларыннан саклап калуның төп чарасына әйләнгән.

Максатка ирешү юллары исә төрле булган. Мөселманнар оҗмахны да, җәза-тәмугны да киләчәктә генә вәгъдә итәләр. Хөкемнең шулай озакка сузылуын Алланың сабырлыгы белән аңлаталар.

Үзенең авыз иҗатында халык көттерми. Мәкалендә «Сабыр төбе — сары алтын» дип, тәҗрибәсен расласа да, әкиятләрендә яхшыларга бүләкне дә, явызларга җәзаны да шунда ук бирдертә.

Динчеләр өчен ышаныч хакыйкать белән тыгыз бәйләнешкә керә.

Хакыйкать кешедән, җирдән аерылган бер күренеш итеп күз алдына китерелә, ә ышаныч хакыйкатьнең һәркем көнделендә гамәлгә ашуы була.

Кеше өметсез яши алмый. Ул элек тә матур киләчәк, бәхет көтеп тормыш иткән. Үзенең авыр тормышын илаһи өмет белән бизәгән яки могҗиза көткән.

Матур әдәбиятның борынгы үрнәкләре иҗат ителгән заманда, шулай итеп, бер-берсен баетып һәм бер-берсеннән шактый аерылып, ике фәлсәфә яшәгән.

«Алла боерса» сүзе һәркемнең авызында булган. Гасырларны гасырлар алыштырган, ләкин бу сүзләр бер буыннан икенчесенә күчкәннәр, бүгенге көнгә дә килеп җиткәннәр. Бу сүзләрдә кешеләрнең, буыннарның, тарихи чорларның рухи халәте чагыла.

Күп очракта гадәткә кергәнгә генә әйтелә торган «Алла боерса» сүзе кешеләрнең хыянәтсез яклаучысы, киңәшчесе барлыгын исенә төшереп торган.

Сораулар һәм биремнәр

1. Татарлар һәм болгарлар турында сөйләгез.
2. Үзәкләштерелгән дәүләт, дидек. Ул нинди дәүләт?
3. Бөек Болгар дәүләте феодаль дәүләт булган. Шуннан чыгып, шул замандагы Болгар дәүләтен күз алдыгызга китерегез.
4. Без бит матур әдәбият өйрәнәбез. Шулай булгач, заман фәлсәфәсе һәм тарихи шартлар белән танышуның нигә кирәге бар?
5. «Алла боерса» сүзенең эчтәлеген аңлатыгыз.

Кол Гали

Әдәбият тарихын башлангыч чорыннан өйрәнә башлыйбыз. Бу чорны, кыскартып, «Борынгы әдәбият» дип тә, «Урта гасыр әдәбияты» дип тә йөртәләр. Кызганычка каршы, төрле яулар вакытында, янгыннарда элекке заман кулъязмаларының күбесе юкка чыккан. «Кыйссаи Йосыф» — безнең көннәргә кадәр сакланган иң күләмле әсәр.

«Кыйсса» дип элек хикәягә әйткәннәр. Күп вакыйгалы тезмә әсәр булганга хәзер аны «поэма» дип тә йөртәләр. Кайбер кулъязмаларда әсәрнең исемен «Йосыф китабы», «Йосыф вә Зөләйха» дип тә куйганнар.

«Кыйссаи Йосыф» — борынгы заманнардан бирле татар халкының иң яратып укыган әсәре. Шуңа күрә аның татар әдәбияты үсешенә йогынтысы бик зур булган.

Кыйсса авторы Кол Гали турында мәгълүматлар бик аз. Ул чама белән 1183 елда Идел буенда туган. Күп укыган, күп сәяхәт иткән. Заманында иң белемле кешеләрнең берсе булган. 1236—1240 елларда монгол яулары Болгарга һөҗүм иткәндә вафат булган дип исәпләнә.

Әсәрендә ул үзен «Гали» дип таныштыра. Бу елларда иҗат итүче авторлар үзләрен «Алла колы» дип язалар. Алла ярдәме белән язылуын әйтеп, әсәрләренең дәрәҗәсен күтәрәләр. Ул да үзен «Алла колы» дип белдерә. Шуңа күрә аның чын исеме «Гали»ме, әллә «Кол Гали»ме — тәгаен генә әйтергә дәлил юк. Әсәренең камиллеге аның талантлы шагыйрь булуына шик калдырмый.

Әсәр бик озын. Кыскартылган урыннарның эчтәлеген сөйләп кенә үтәргә туры килә.

Кыйссаның кереше бар. Ул ике өлештән тора. Беренчесендә Аллага һәм пәйгамбәрләргә мактау, олылау сүзләре әйтелә. Икенчесендә автор үзен «зәгыйфь кол» дип, ягъни «Алла колы» дип атый һәм Алладан, китабын язар өчен, көч, илһам сорый. Монда безнең өчен бик әһәмиятле строфа бар:

Мин зәгыйфьне хикмәт таба син юнәлдер,
Киңәш-хикмәт сөйләмәгә илһамландыр,
Күкрәгемдә ярдәм итү шәмен яндыр,—
Ниятемне нурың белән балкыт имди.

Куәт бир син хикмәт юлыннан барырга,
Гакыллы колларның күңелен баетырга.

«Хикмәт» дип элек иҗат эшенә әйткәннәр. Хикмәткә әйләнү өчен, җөмлә гадәти сөйләм җөмләләренә охшамаска тиеш булган. Хикмәт итеп сөйләгән вакыйга гадәти тормыш вакыйгасыннан үзгә булганда гына хикмәткә әйләнгән.

Бу юлларда кыйсса авторы поэмасының ниятен ачыклый. Ниятем — кешеләрнең күңелен баету, ди. Ничек итеп баетуын да әйтә: акыллы кешеләргә киңәш белән ярдәм итеп баетырга ниятлим, ди.

Поэма авторы әйткән бу изге ниятне борынгы әдәбиятның барлык әсәрләре өчен хас максат итеп исәпли алабыз.

Үзен Алла колы дип санаган Кол Гали кешеләргә нинди акыллы киңәшләр бирә? Күңелләрен нинди изге хисләр белән баета? Бу сорауларга әсәрне бик җентекләп укып анализ ясаганнан соң гына җавап биреп була.

I фасыл

Йосыфның төше

Ыру башлыгы Йагъкубның унике улы бар. Йосыф — шуларның иң кечесе. Ибне-Йәмин белән Йосыф — бер ана балалары. Ләкин Йагъкубның яшь хатыны Рәхилә үлгән. Йосыф белән туганы ятим калганнар. Унбер яшьтә Йосыф төш күрә:

«Нурлы кояш, тулган ай һәм унбер йолдыз
Шул төшемдә сәҗдә кылды миңа төп-төз.
Бу төшемне шулай күрдем, һичбер шиксез,—
Йә әткәем, шул төшемне юра имди».

Йагъкуб шунда юрап бирде аның төшен:
«Булыр,— диде,— бәхетле һәм котлы эшең.
Хуҗабыздан[1] ярдәм иңәр синең өчен,—
Сиңа хөрмәт һәм бөеклек килер имди.

Пәйгамбәрлек-нәбилек син алачаксың,
Һәм мәмләкәт иясе син булачаксың,
Рәхәт, шатлык, сөенечләр табачаксың,—
Бу төшеңдә бөек бәхет күрнер имди».

Йагъкуб Йосыфка монда ишеткәннәрен сер итеп сакларга куша. Ләкин боларның сүзен картның үги кызы ишетеп торган икән. Йагъкуб сүзләрен ул кардәшләренә ирештерә. Кардәшләр шунда ук карарга киләләр:

«Әйдә, барып, атабызга сөйләп карыйк,
Йосыфны без атабыздан сорап алыйк,
Алып китеп, берәр төрле чара кылыйк,—
Йә үтерик, йә еракка сатыйк имди.

Йосыфны ул хәзер бездән артык сөя,
Күрми торса аның йөзен янып көя,
Мирас бирсә, аңа бездән артык тия,—
Ике тапкыр бездән артык сөяр имди».

Кардәшләре шулай эшлиләр дә. Йосыфны үзләре белән кырга чакыралар. Табигать матурлыгын күреп, зиһене артыр, күңеле күтәрелер, диләр. Ләкин Йагъкуб төшендә, үзенең унбер бәрән көтеп йөргән чакта, бер бәрәнен бүре алып киткәнен күргән икән. Шуңа күрә яраткан улын башка уллары белән җибәрергә курка. Йосыф үзе дә сорагач, теләмичә генә риза була. Агалары Йосыфны күтәреп алып китәләр. Йагъкубның кызы Динә дә төшендә ун бүре күргән, бүреләр Йосыфны тартып алганнар икән. Кыз Йосыфлар артыннан йөгерә һәм аны кире кайтармакчы була. Ләкин теләгенә ирешә алмый. Кырга чыккач, туганнары Йосыфны үтерергә ниятләп кыйнарга керешәләр. Арадан берсе — Йәһүдә — кинәт Алланы искә төшерә:

Йәһүдә әйтте: «Бу эшегез дөрес булмас,
Карендәш үз карендәшен һич үтермәс,
Моны кылган Тәңредән һич рәхим күрмәс,
Иң яхшысы — тәүбә кылып дүнү имди.

[1] *Хуҗа* — Алла.

Тәңребездән куркыйк, яман эшне кылмыйк,
Ахирәттә гөнаһлылар булып калмыйк,
Оҗмах биреп, тәмуг утын сатып алмыйк,—
Ул тәмугта мәңге калып янмыйк имди».

Йәһүдә аларга тәэсир кылалмады,
Үгет сүзе белән киртә куялмады.
Кулларыннан Йосыфны йола алмады,—
Чарасыздан бүтән бер юл эзләр имди.

Йосыфны коега ташларга карар кылалар.

II фасыл

Йосыф коесының сыйфатлары

Агалары Йосыфны, чишендереп, коега ташлыйлар. Ләкин аңа кадәр ул Алладан ярдәм сорарга өлгерә:

Йосыф әйтте: «Йа Илаһым, бөек хуҗам,
Бичаралар өмете син, рәхимле Аллам,
Һич өметем калмады бу туганнардан,—
Бүген миңа үзең ярдәм күрсәт имди!»

Алла бу сүзләрне ишетә һәм аны пәйгамбәр итә. Ә ярдәмгә Җәбраилне җибәрә. Җәбраил Йосыфны суга җиткәнче үк тотып ала. Кое төбендәге бер ташны өскә күтәрә, һәм Йосыф шунда менеп утыра. Алла илчесе оҗмахтан азык, кием алып килә. Йосыфның боек күңеле шатлык белән тула:

Хөллә киде, ашап-эчте, шөкер кылды,
Йөзе йөз мең төрле нурлар белән тулды,
Җәбраилнең нуры шул нурга кушылды,—
Нур, сызылып, җирдән күккә ашар имди.

III фасыл

Йосыф яныннан агаларының кайтуы

Угъланнары егъларга дип сүз куйдылар,
Якынлашкач өйгә, бик нык аһ ордылар:
«Аһ, кызганыч Йосыф!» — дип егъладылар,—
«Аһ, Йосыфны алдырдык бит!» — диләр имди.

Йагъкубның моны ишеткәч гакълы шашты,
Бер кычкырып, һушсызланып авып төште,
Моны күреп, угъланнары кайгырышты:
«Аһ, үкенеч, хата кылдык!» — диләр имди.

Аталарына алар: ук аткан идек, укларыбызны алырга дип киткән идек, Йосыфны шул арада бүре ашаган, диләр. Йагъкуб улларының сүзләренә ышанмый, кайгысы бик зур булса да, үзен юатырлык сүзләр таба:

Йагъкуб әйтте: «Бу казалар Тәңредәндер,
Сабырсызлык бөекләрне түбән кылыр,
Мин кылармын инде моңа күркәм сабыр,—
Сабыр белән морад хасил булыр имди».

IV фасыл

Дәгыйр углы Маликның төш күргәне

Мисыр иленең бай сәүдәгәре Дәгыйр улы Малик төшендә җиргә кояш иңгәнен күргән. Кояш аның куенына кереп, якасыннан чыккан. Маликның төшен, кулыңа бер кол керер, ул сине баетачак, дип юрыйлар. Илле ел үткәч, Малик әлеге кое янына килеп чыга. Йосыфны коткара һәм агаларыннан бик аз гына бәягә сатып ала. Агалары Йосыфны болай хурлыйлар:

Алар әйтте: «Һичбер шиксез бу чын колдыр,
Колыбызның нәкъ өч төрле гайбе бардыр:
Качучыдыр, урлаучыдыр, ялганчыдыр,—
Шул өч төрле гайбе белән син ал имди».

Алар әйтте: «Моңа, Йосыф, риза бул син,
Кол икәнең телең белән икърар кыл син,
Түгел дисәң үтерәбез, ачык бел син!» —
Алар болай дип гыйбричә[1] әйтер имди.

Йосыф, мескен, бу янаудан куркып калды,
Куркуыннан коллыгына риза булды:
«Мин — кол»,— диде, күзләреннән яшь агылды,—
«Алла колы»,— дип, эченнән уйлар имди.

Тегеләр әйтте: «Йа Малик, моңа инан,
Сүзләрендә бу колның син тотма гөман[2],
Бау-богавын чишә күрмә аягыннан,—
Мисыргача гел богауда барсын имди».

---

[1] *Гыйбричә* — яһүд телендә.
[2] *Тотма гөман* — ышанма.

Йосыф Маликтан туганнарын бер туйганчы күреп калырга рөхсәт сорый. Тегеләрнең юньсезлеген күреп торган Малик Йосыфның киң күңеллелегенә шакката. Алар синең бармагыңа да тормыйлар бит, ди. Йосыф агалары янына бара һәм язмышыннан зарлана, ләкин сабырлыгын югалтмый:

«Бу язмышны Тәңредән дип белү кирәк,
Хакъ хөкменә коллар разый булу кирәк,
Җәзасына ризалыкны бирү кирәк,—
Казасына буйсынып баш идем имди».

Бер хәбәши[1] кол бар иде — Кылыч атлы,
Барлык коллар арасында иң гайрәтле,
Кара йөзле, үзе усал, каты куллы,—
Тапшырдылар Йосыфны шул колга имди.

Шул ук сәгать кәрван моннан күчеп китте,
Бер каберлек тирәсенә барып җитте,
Йосыфны бер кабер анда җәлеп итте,
Ул — анасы Рәхиләнең кабре имди.

Йосыф егълап әйтте: «Өмме-Рәхилә, анам,
Күз сал миңа: нинди хәлдә калды балаң,
Бел инде син, сатты мине барлык агам,—
Азат идем, коллыкка мин төштем имди».

* * *

Кылыч бакты — Йосыф күзгә күренмәде,
Тырышса да, кайдалыгын һич белмәде.
Үзе генә аны эзләп табалмады,—
Хуҗасына хәлне мәгълүм кылыр имди.

Аргамак ат менеп, шундук Кылыч китте,
Барыннан да элегрәк ул барып җитте,
Җитүе белән Йосыфны орды-сукты:
«Нигә качтың?» — дия-дия кыйнар имди.

Йосыф әйтте: «Йа Илаһым, мин ни кылыйм,
Бу михнәттән ничек итеп мин котылыйм,
Бу залимнән ничек итеп азат булыйм? —
Кодрәтең зур, мине аннан коткар имди!»

---

[1] *Хәбәши* — эфиоп.

Тәңредән нәкъ шул вакытта фәрман булды:
Кодрәт белән күккә кара болыт тулды,
Җилләр исте, карлы-бозлы яңгыр килде,—
Ул бик каты куәт белән явар имди.

Малик әйтте: «Аһ, ни кылыйк, булдык вәйран[1],
Йа Ходаем, нидән купты мондый туфан?
Арабызда бардыр җәбер күргән бер җан,—
Барчабыз да ярлыкавын[2] сорыйк имди».

Шул ук сәгать теге Кылыч килеп җитте,
Үзе кылган хатаны ул икърар итте:
«Мәгълүм булсын, ошбу гөнаһ миннән,— диде,—
Мин кыйнаган идем гыйбри[3] колны имди».

Малик әйтте шул вакытта кара колга:
«Бар, Йосыфның аягын үп, гафу сора,
Күңелен тап, җылы сүзләр сөйләп аңа,—
Безнең өчен изге дога кылсын имди!»

Кылыч шунда Йосыфның янына килде:
Егълый-егълый каршысында зари кылды,
Хата-гөнаһ эшләгәнен икърар кылды,—
Тезләнеп, Йосыф аягыннан үбәр имди.

Йосыф Кылычны гафу итә. Дога кыла. Догасы кабул була: яңгыр, кар туктый. Көн ялт итә. Бу хәлне күреп торган Малик Йосыфның кулын чишә, тупас киемен күлмәккә алыштыра, дөядән төшереп, атка атландыра. Шуннан соң да хикмәт дәвам итә:

Сөйләгән саен Йосыфның фәһме артты[4],
Була барды сүзе матур, теле татлы,
Йөзен ачса, бөтен җиһан нурга батты,—
Күргән кеше һич тә күреп туймас имди.

Кәрван шәһәрләр аша уза. Нинди шәһәргә генә кермәсеннәр, халык Йосыфның матурлыгына хәйран кала. Кодес дигән шәһәр бәге, Йосыфны Маликтан тартып алу нияте белән, артларыннан атлы гаскәр җибәрә. Ләкин матурлык хәтта уникe меңлек гаскәрне дә җиңә:

---

[1] *Вәйран булдык* — харап булдык.
[2] *Ярлыкавын* — гафу итүен.
[3] *Гыйбри* — гыйбрәт өчен.
[4] *Фәһме артты* — зиһене артты.

Кайчан гаскәр ул кәрванга якынлады,
Йосыф, туктап, аларга бер карап алды,
Йөзен күреп, бөтен гаскәр һушсыз калды,—
Һәммәсе дә аттан егълып төшәр имди.

Мондый хәлгә кәрван әһле хәйран калды,
Йосыф күңелен горурлану биләп алды,
Ул горурлык мәйданында сәйран кылды:
«Миңа охшаш беркем дә юк!» — дияр имди.

Шул ук сәгать ул Җәбраил тагын килде,
Моны аңа Халикъ[1] үзе кушкан иде:
«Әйа Йосыф, син нинди сүз әйттең,— диде,—
Горурландың, Хакъ сәнгатен[2] син күр имди!»

* * *

Өченче көн бер шәһәргә кәрван керде,
Шәһәр халкы һәммәсе дә пәри иде,
Шунда Йосыф пәриләрнең йөзен күрде:
Һәрбересе Йосыфтан да чибәр имди.

Шунда Халикъ Йосыфка вәхи күндерде[3]:
«Әйа Йосыф, кодрәтемне син күр инде,
Күркең белән бер дә горурланма,— диде,—
Хакыйкатьтә күрк[4] бирүче мин бит имди».

Кайчан Йосыф мондый хәлне ачык белде,
Горурлыклар кылуына бик үкенде,
Гаҗиз булып, Тәңресенә сәҗдә кылды[5],—
Тәүбә кылып, зари-зари егълар имди.

Аңа тагын Тәңресеннән ярдәм килде,
Тәңре аңа матурлыгын кире бирде.
Эчке-тышкы матурлыгын берләштерде:
«Әйа Йосыф, башың күтәр!» — дияр имди.

Мисырда Нил елгасына килеп җитәләр. Малик Йосыфка су коеныргa куша. Балыклар солтаны башка балыкларга пәйгамбәр тәненә

---

[1] *Халикъ* — Алла.
[2] *Хакъ сәнгатен* — Алла җәзасын.
[3] *Вәхи күндерде* — карарын әйтте.
[4] *Күрк (күркәмлек)* — матурлык.
[5] *Сәҗдә кылды* — баш иде.

карамаска әмер бирә һәм Йосыфны үзенең өстенә бастыра. Бу яхшылыгы өчен аңа Алла ике бала бүләк итә. Моңа кадәр солтан-балыкның балалары булмаган икән. Юынып чыгуга Йосыф кабат Алла рәхимлегенә дучар була: күктән төшкән бик матур хөлләне киеп ала да:

Шат һәм көләч булып Йосыф кире кайтты,
Нуры аның элеккедән мең кат артты,
Өстендәге хөллә йөзен һәм балкытты,—
Җирдән күккә нурдан терәк менәр имди.

Мисырда Йосыфны күрергә бөтен ил халкы җыела. Сәүдәгәр Малик бер күргәнгә башта берәр, аннан соң икешәр, өчәр, унар алтын ала. Матурлык дәрәҗәсен автор болай тасвирлый:

«Күргән кеше йөзен карап туймас имди».
«Күргәч, хәйран булып һуштан язар имди».
«Һәрбер төркем берәр төрле күрер имди».

Кыяфәтен күргән — малын фида кылды,
Холкын күргән кеше — җанын фида кылды,
Егерме мең кеше шунда шәһид[1] булды,
Рәсүллеген[2] күргән — иман китерер имди.

Сөрәнчеләр мондый игълан тараттылар:
«Бу угъланны сатып ала кем?» — диделәр.
«Түли алыр кем чын кыйммәтен?» — диделәр,
«Кем бәһасен җиткерсә алсын имди!»

V фасыл

Зөләйха турында хикәят

Колак салып тыңлагыз сез ошбу сүзне,
Ул Зөләйха — мәликзадә[3], Тәймус кызы,
Тулган айдай балкыр иде аның йөзе,—
Оҗмахтагы хур кызына охшар имди.

Тәймус Мәгъриб[4] җирләрендә патша иде,
Гаскәрләре йөз мең ирдән аша иде,
Күк иясе аңа бик зур байлык бирде,—
Дөньяда ул олугъ мәлик булган имди.

---

[1] *Шәһид* — корбан.
[2] *Рәсүллеген* — пәйгамбәрлеген.
[3] *Мәликзадә* — патша кызы.
[4] *Мәгъриб* — Африканың төньяк-көнбатыш өлеше.

Зөләйха беркөнне йоклап ятар иде,
Шунда Йосыф сурәтен ул төштә күрде,
Күрү белән шундук аңа гашыйк булды,—
Егълый-егълый ул уянып китәр имди.

Өченче ел сурәтне ул йәнә күрде,
Бик нык аһлап, аңарга ул сорау бирде:
«Әйтче, кем син, торган җирең кайда? — диде.—
Бар нәрсәдән мине мәхрүм кылдың имди!»

Йосыф әйтте: «Йа Зөләйха, әйтим шуны:
Мин Мисырның хөкемдары, бел син моны,
Мисырга кил, теләр булсаң әгәр мине,—
Табарсың син мине шунда имди.

Сабыр белән эшлә ләкин син бу эшне,
Сабыр белән эшләнә һәр эшнең башы,
Морадына тиз җитә сабырлы кеше,—
Мондый эштә күркәм сабыр кирәк имди».

Тәймус патша кызын бик ярата, шуңа күрә теләгенә каршы килми, Зөләйханы хатынлыкка тәкъдим итеп, Мисыр патшасына хат яза. Мисыр патшасының ризалыгын алгач, хисапсыз байлыклар төяп, кызын Мисырга озата. Ай ярымлык юл үтеп, Мисыр патшасы Кыйтфирне күргәч, Зөләйха утырган җиреннән егылып төшә: иренең Йосыф түгеллеген белгәч, акылдан шаша яза. Карауашлары (үзе белән килгән дус кызлары) Зөләйханы юаталар, сабыр итәргә киңәш бирәләр:

«Белеп булмый, бәлки, Раббем ярдәм кылыр,
Күргән төшең бәлки чынга туры килер,
Беркөн, бәлки, ул морадың хасил булыр,—
Теләгеңне үтәү аңар җиңел имди».

* * *

Аннан соңра нәкъ җиде ел тагын үтте,
Хәлләр кичте, бик күп айлар килеп китте,
Ахыры Йосыф Мисырга килеп җитте,—
Мисырда ул кол ителеп сатылыр имди.

Бер кеше дә аны сатып алалмады,
Бәһа биреп, аңа якын килалмады,
Мисыр малы аңа бәһа булалмады,—
Җиһан малы аның өчен җитмәс имди.

Көннәрнең берендә Йосыфны күрү бәхетенә Зөләйха дә ирешә. Һәм төшендә күргән егетнең шул булуын танып ала. Йосыфны Зөләйханың ире Кыйтфир күрә һәм, матурлыгына сокланып, сатып алырга карар кыла. Моңа дәүләтнең бөтен алтыны китә. Ләкин Йосыф догасы казнаны күз ачып йомганчы тагын алтынга күмә. Йосыф белән аерылганда сәүдәгәр Малик та, солтан-балык кебек, баласы юклыкка зарлана. Йосыф догасы бу юлы да кабул була: Маликның егерме дүрт варисы туа. Патша Йосыфны сараена алып кайта да, Зөләйхага күрсәтеп, болай ди:

«Йа Зөләйха, хөрмәт кыл син бу угъланга,
Һәрвакытта күрсәт лаекъ кадер аңа,
Тырыш миннән артык аны олыларга,—
Йосыф безнең үз угълыбыз булсын имди».

Зөләйха хөкемдар сүзен кабул күрде,
Йосыфны ул олылады, хөрмәт кылды,
Өч йөз алтмыш төрле кием әзерләде,—
Һәр көнне бер төрлесен кидерер имди.

Чәчләрен үз кулы белән тарый аның,
Энҗе-мәрҗән кушып үрә толымнарын,
Шундый хәлдә китте тынычлыгы җанның,—
Гыйшкы җиңде, һич сабыры калмас имди.

Берәр вакыт тамырыннан кан алдырса,
Тамырына пәке белән табиб сызса,
Шул чагында каны агып җиргә тамса,—
Җирдә Йосыф исеме язылыр имди!

VI фасыл

Даянең[1] Зөләйхадан хәлен соравы

Зөләйха беркөнне йоклап ята иде,
Бер даясе кереп, аның хәлен күрде:
«Әйа хатун[2], сиңа нәрсә булды? — диде,—
Ни сәбәптән мондый хәлгә төштең имди?»

Зөләйха даясенә җавап бирде,
Яшермәде, сөйләп бирде бөтен серне,

[1] *Дая* — икенче кеше баласына сөтен имезеп үстерүче хатын.
[2] *Хатун* — ханым, хуҗабикә.

Бу серне ул үзе бик нык саклар иде:
«Саклый күр син аны, зинһар!» — дияр имди.

Дая әйтте: «Төзүчеләр хәзер килсен,
Сиңа лаекъ сарай алар бина кылсын,
Шундый булсын: күргән кеше хәйран калсын,—
Бөтен эче бизәкләнгән булсын имди.

Эче энҗе-мәрҗән белән җиһазлансын,
Кызыл алтыннан агачлар анда булсын,
Тирә-якка ботаклары җәелеп торсын,
Җимешләре төрле-төрле булсын имди.

Куйдырып зур тәхет сарай уртасына,
Ефәкләрнең киенеп иң затлысына,
Шул тәхеткә лаекъ таҗ киеп башыңа,
Нурдай балкып, шул тәхеткә утыр имди.

Чакыртып ал Йосыфны, ул килеп керсен,
Төрле бизәк, сурәтләргә күзен салсын,
Карау белән тәхеттә ул сине күрсен,—
Күпме сабыры булса да, ул җуйсын имди».

Зөләйха Дая әйткәнчә эшли: бөтен акчасын тотып, гүзәл сарай салдыра, затлы киемнәрен киеп, тәхетенә менеп утыра һәм янына Йосыфны чакырта.

Сарай нәкышен[1] күреп, Йосыф гаҗәпләнде,
Мактап аны: «Бигрәк матур сарай,— диде,—
Ләкин,— диде,— газиз[2] нигә күренмәде? —
Хатуны белән ул да бергә булсын имди».

Җавап бирде ул Зөләйха шунда аңар:
«Бу сарайда ул газизнең ни эше бар?
Бу сарайда барлык нәкыш сиңа охшар,—
Аны махсус синең өчен төздек имди».

Йосыф әйтте: «Мине газиз сатып алды,
Минем гадәт-холкым аңа ошап калды,
Ул бит мине угыллыкка кабул кылды,—
Мин атама ничек хаин булыйм имди?»

---

[1] *Нәкыш* — сырлап яки чокып ясалган бизәк.
[2] *Газиз* — изге. Зөләйханың ире.

Зөләйха ул сүзләрне һич тыңламас,
Үгетләрен кабул итмәс, һич аңламас,
Аңа лаекъ бер генә сүз дә сөйләмәс,—
Тик үз сүзен кабат-кабат әйтер имди.

«Әйа Йосыф,— дидер,— синең сүзең татлы,
Ялыкмыйча тыңлар өчен ул рәхәтле,
Йөзең нәфис, әйтер сүзләрең хуп, мөрәүвәтле[1],—
Ишетсәм, җан рәхәтләрем артыр имди.

Яңа туган айга охшаган кашларың бар,
Энҗеләргә охшаш синең тешләрең бар,
Мишек-җофар[2] исе килгән сачләрең бар,—
Үрергә үз кулым белән лаекъ имди...

Кызыл якут кебек синең яңакларың,
Яшь алмадан нәфисрәктер иякләрең,
Бал-шикәрдән татлырактыр иреннәрең,—
Ике ирнең күңелем үртәп торыр имди.

Яңа үскән талчыбыктай бармакларың,
Энҗе-мәрҗәндәй тезелгән тырнакларың,
Кафурдан[3] да аграк синең беләкләрең,—
Кул-учларың ефәктән дә йомшак имди.

Син җанымның тынычлыгын алдың инде,
Аһ, кызганыч, кайчан җитәр каушу көне,
Берөзлексез күреп торсам иде сине,—
Күрми торсам, һич сабырым калмас имди».

Бәс, Зөләйха Йосыф кулын тотып алды,
Зөләйхага карап, Йосыф һәм елмайды,
Шул ук сәгать кисәтүле бер өн килде:
«Якын килмә уйнашка син!» — дияр имди.

Шулчак атасы Йагъкуб һәм заһир булды[4],
«Яман эштән нәфсең тый, угълым!» — диде,
Аны күреп тугъры Йосыф сабыр кылды,—
Халикыннан куркып, тыелып калыр имди.

---

[1] *Мөрәүвәтле* — йомшак.
[2] *Мишек-җофар* — татлы хуш ис чыгаручы матдәләр.
[3] *Кафур* — камфара; ап-ак.
[4] *Заһир булды* — пәйда булды, күренде.

Тәңресенә сыенды да Йосыф качты,
Кодрәт белән җиде капка Халикъ ачты,
Исән-имин Йосыф бик сөенеп чапты,—
Зөләйха да артыннан ук куар имди.

Бәс, Зөләйха Йосыфны тиз куып җитте,
Куып җитеп, итәгеннән ныклап тотты,
Арт итәге Йосыфның ертылып китте,—
Тыш капкадан ал-артлы чыгарлар имди.

Газиз шунда тора икән, моны күрде,
Зөләйханың төсе тәмам киткән иде,
Сизенеп, газиз аларга сорау бирде,—
Ни булганын белергә ул теләр имди.

Иң беренче Зөләйха йөгереп килде:
«Угълан миңа явыз тәкъдим кылды,— диде.—
Аңа нинди җәза тиеш, син әйт инде:
Төрмәме йә җәзалаумы?» — дияр имди.

«Мин гөнаһсыз, шаһитым бар»,— дип, Йосыф бишектәге балага күрсәтә. Алла кодрәте белән унҗиде көнлек бала телгә килә дә:

«Ачык күренә бу эш Йосыф күлмәгеннән:
Арт итәге ертык кеше — гаепсез имди!» — ди.

Газиз хәлнең ниндилеген ачык белде:
Кем итәге арттан ертык — ачык күрде,
Ул сабыйның таныклыгын кабул кылды:
«Зөләйха, гаеп синдә!» — дип орышыр имди.

VII фасыл

Зөләйха турында гайбәт сөйләгән хатыннар

Мисырдагы кайсыбер хатын-кызлар,
Ишетеп бу хәлне, бергә җыелдылар,
Зөләйханың хәлен сөйләп көлештеләр,
Һәрбересе бертөрле сүз сөйләр имди.

«Үз колына ул Зөләйха гашыйк булган,
Колы аңа буйсынмаган, рисвай кылган,
Эшнең нидә икәнлеген газиз белгән,—
Кол артыннан йөгергәнен күргән имди».

Кайчан бу хәл Зөләйхага ишетелде,
Бик зур мәҗлес җыярга ул карар бирде;
Мәҗлесенә аның дүрт йөз хатын килде,—
Барчасы да кереп түргә узар имди.

Ул хатыннар көрсиләргә[1] утырдылар,
Берәр пычак һәм әфлисун тоттырдылар:
«Әфлисунны турагыз!» — дип боердылар,
Нәкъ шулвакыт Йосыф килеп керер имди.

Йосыф таба борылып бер карадылар,
Гүзәллеген күреп аның таң калдылар,
Һәммәсе дә күз алалмый карап аңар,
Әфлисун дип бармакларын кисәр имди.

Зөләйха әйтте: «Инде сез күрдегезме,
Йөзем нидән сулганлыгын белдегезме,
Бер күрүдә кулыгызны кистегезме,
Акылыгыз җуйдыгызмы?» — дияр имди.

Зөләйха Йосыфтан үч ала: иренең кардәше Рәййан ярдәме белән аны төрмәгә яптыра. Кыйтфир кинәт вафат була. Йосыфка ярдәм итә алмый кала. Тәхеткә аның кардәше Рәййан утыра. Йосыф белән бергә зинданга шәрабчы белән икмәкче дә ябылган. Көннәрнең берендә алар икесе дә төш күрә. Төшләрен юрап, Йосыф шәрабчыга: «Сине азат итәчәкләр», ә икмәкчегә: «Сине үтерәчәкләр»,— ди. Шулай булып чыга да. Йосыф шәрабчыга үтенә:

Йосыф әйтте: «Әйт мәликкә[2] белгәнеңне,
Аңлатып бир аңа минем бу хәлемне,
Белдер минем һич гөнаһсыз икәнемне,—
Хуҗаң алдында телгә ал мине имди».

Ул да булмый күктән Җәбраил килеп төшә һәм Алланың шелтәсен белдерә, Халикъка сыенасы урында ярдәмне патшадан сорыйсың, ди.

Йосыф шунда ук гаебен аңлап алды,
Моны аңлап, каты хәсрәт, уйга калды,
Шәрабчыга әйткәненә тәүбә кылды,—
Сәҗдә кылып, Тәңресенә ялварыр имди.

---

[1] *Көрси* — терсәкле урындык, кресло.
[2] *Мәлик* — патша.

VIII фасыл

Кәнган гарәбе кыйссасы

Ул зинданда Йосыф озак тоткын булды,
Шул арада Кәнганнан бер гарәп килде,
Бу гарәпне Йосыф тәрәзәдән күрде,—
Ул ашыгып дөя куып барыр имди.

Кайчан гарәп бу зинданга якын килде,
Йосыф анда икәнлеген дөя белде,
Дөя аңа егълый-егълый зари кылды:
«Мин Кәнганнан килдем монда»,— дияр имди.

«Анда атаң Йагъкубны мин күреп килдем,
Аның хәле мөшкиллеген белеп килдем,
Кайгырып зар егълаганын үзем күрдем,—
Көннән-көнгә хәсрәтләре артыр имди.

Егълый-егълый ике күзе күрмәс булды,
Көчсезлектән буыннары тотмас булды,
Берниндидә эшкә көче җитмәс булды,—
Һәрдаим ул Йосыф диеп егълар имди».

Йагъкубның бу хәле мәгълүм булу белән,
Дөя егълап аңа хәбәр бирү белән,
Йагъкуб хәле нindилеген белү белән,—
Йосыф аһлап җиргә авып төшәр имди.

Шул сәгатьтә теге гарәп якын килде,
Дөясенең чүккәнлеген шунда күрде,
Таяк алып, сугарга дип нийят кылды,—
Ләкин аның аягын җир тотар имди.

Гарәп, мескен, ни кылырга белалмады,
Аягын һич җирдән тартып алалмады,
Атлап китәр өчен дәрман табалмады,—
Хәйранлыктан ни эшләргә белмәс имди.

Йосыф әйтте: «Әй гарәби, нийятең нидер,
Аягыңның тотылуы фигълеңнәндер,
Ул дөяне кыйнарга теләвеңнәндер,—
Ачуыңны күңелеңнән чыгар имди».

Гарәп аңлап үз гаебен тәүбә кылды,
Аякларын җир җибәрде, азат булды,
Шуннан соң ул Йосыфның янына килде,—
Кулын үбеп, аңа хөрмәт кылыр имди.

Йосыф аннан хәбәр-әхвәл сораштырды,
Гарәп барлык белгәннәрен сөйләп бирде,
Һәммәсен дә берәм-берәм бәйан кылды,—
Гарәп сөйләр, Йосыф еглап тыңлар имди.

Йосыф гарәпкә бик кыйммәтле беләзек бирә. Кәнганга кайткач, Йагъкубка сәлам әйт, миңа азатлык теләп дога кылсын, ди, ләкин үзенең кемлеген яшерә. Гарәп, иленә кайту белән, Йагъкубны күрә һәм аңа Йосыф әманәтен тапшыра. Йагъкуб зиндандагы егетнең улы булуын сизенә һәм аңа азатлык теләп дога кыла. Догасы шунда ук кабул була.

IX фасыл

Йосыфның зинданнан чыгуы

Хөкме белән әмер итеп Мәлик-рәхман[1],
Бер төш күргән Мисыр шаһы мәлик Рәййан,
Юраучылар мондый төшкә калган хәйран,—
Һичберсе дә аңа юрау тапмас имди.

Рәййан әйткән: «Җиде симез сыер күрдем,
Һәркайсының аркасына менеп йөрдем,
Берсеннән-берсенә шунда күчә тордым,—
Мондый төшкә гаҗәпләнеп калдым имди.

Күрдем йәнә җиде сыер — бар да арык,
Бар да хәлсез, бар да беткән арыкланып,
Ачыгудан булган алар шундый ябык,—
Симезләрен арыклары ашар имди!..

Тагын күрдем тулып җиткән җиде башак,
Йәнә корып-кибеп беткән җиде башак,
Бодайлары очып китте күккә шулчак,—
Тик өч бөртек җирдә торып калыр имди».

---

[1] *Мәлик-рәхман* — Алла.

Сарайда төшне юраучы табылмый. Шәрабчы кинәт Йосыфны искә төшерә һәм аның оста юраучы булуын Рәййанга әйтә. Шәрабчыны шунда ук Йосыф янына төш юратырга җибәрәләр. Йосыф патша төшен болай юрый:

Йосыф әйтте: «Нәкъ җиде ел иген уңа,
Төрле нигъмәт-азык белән дөнья тула,
Аннан соңра корылык һәм кытлык була,—
Нәкъ җиде ел зур авырлык булыр имди.

Аннан соңра Тәңре мәрхәмәт кылачак,
Кешеләргә шатлык-рәхәтләр киләчәк,
Төрле нигъмәт, арзанлыклар күп булачак,—
Байлык-муллык көннән-көнгә артыр имди».

«Бар, кире кайт,— диде Йосыф шунда аңа,—
Кулын кискән хатыннарны җый сарайга,
Кайту белән ныклап кереш бу чарага,—
Мәлик Рәййан эшнең аслын белсен имди».

Шәрабчы бу хәлне Рәййанга белдерде.
Мәлик Рәййан да бу эшне мәгъкуль күрде,
Кулын кискән хатыннарны ул җыйдырды,—
Зөләйха да ул мәҗлестә булыр имди.

Мәлик әйтте: «Йә, сөйләгез хәлегезне,
Ни сәбәптән кистегез бу кулыгызны?»
Зөләйха әйтте: «Гафу ит, мәлик, безне,—
Без гаепле, һич гаепсез Йосыф имди».

* * *

Мәлик гаскәр җыеп атка атландырды,
Зиндан янына ул аттан төшеп барды,
Ул Йосыфны киендереп алып килде,—
Моны күреп барчасы шатланыр имди.

Йосыф кылды күп шөкерләр ул рәхманга,
Мактап, бик күп рәхмәтләр әйтте аңарга,
Аннан килеп сәлам бирде ул Рәййанга,—
Җитмеш ике телдә үзе сөйләр имди.

Мәлик Рәййан аның нурлы йөзен күрде,
Сыйфатын күреп һәм гаҗәпләнде,
Бөтен малын һәм мөлкәтен аңа бирде:
«Бар да синең бойрыгыңда!» — дияр имди.

Йосыф нәби, таҗ киеп, тәхеткә менде,
Бу вакыт ул утыз яшәр егет иде,
Кояш кебек йөзеннән нурлар сибелде,—
Күргән кеше күреп һич тә туймас имди.

Гакълы камил, хикмәт гыйльмен яхшы белер,
Дәгъвачылар дәгъва белән аңа килер,
Бай-ярлыга дөрес, гадел хөкем кылыр,—
Берәүгә дә җәбер-җәфа кылмас имди.

Даругалык[1] эшен үз өстенә алды,
Ашлык-иген бик күп игәргә боерды,
Суктырмыйча аны кибәнгә өйдерде,—
Сугылганы амбарларга тулар имди.

Мисырда җиде ел буе иген уңды,
Төрле ризык белән бөтен дөнья тулды.
Аннан соңра җиде ел корылык булды,—
Кайгырып: «Иген икмәгез!» — дияр имди.

Күктән нәкъ җиде ел яңгыр һич яумады,
Коры җирдә үлән дә үсә алмады,
Дымлы җилләр искән көннәр дә булмады,—
Каты эссе, коры һава торыр имди.

Газиз[2] Йосыф шәһәрләргә игълан кылды,
Мисыр әһле[3] берөзлексез килеп торды,
Алтын-көмеш биреп, ашлык сатып алды,—
Кызыл алтын тәңкә бар да түләр имди.

Икенче ел бирделәр ат-качырларын,
Өченче ел — ефәкләрен, комачларын,
Дүртенче ел — терлекләрен, йорт-җирләрен,
Бишенче ел угълын-кызын бирер имди.

Үзләре дә кол булдылар алтынчы ел,
Йосыфны саткан кешеләр, моны да бел,
Һәммәсе дә ул Йосыфка булдылар кол,—
Бөтен шәһәр аның колы булды имди.

---

[1] *Даругалык* — игенчелек.
[2] *Газиз* — бу урында: хөкемдар, патша.
[3] *Әһле* — халкы.

Халикъ аңа Җәбраил аша белдерде:
«Әйа Йосыф, шөкраналар кыл син инде,
Бөтен Мисыр әһле синең колың булды,
Сине саткан — үзеңә кол булды имди!»

Шул тарлыкта нәкъ алты ел узып китте,
Амбарлардагы ашлыклар тәмам бетте,
Йосыф сәүчи шундый авыр хәлгә калды:
«Йа Илаһым, ярдәм синнән!» — дияр имди.

Җәбраил аның янына тагын килде,
Йосыфка ул Халикъ әмрен ирештерде:
«Тәңре кушты сиңа, йөзең син ач инде,—
Кодрәтемне минем бүген син күр имди».

Мәйданга ул аена бер чыгар иде,
Йөзеннән пәрдәсен ачып куяр иде,
Олугъ-кечек, бай һәм юксыл карар иде,—
Соңра бер ай ашамыйча түзәр имди.

X фасыл

Йосыф вәзире кыйссасы

Хакъның хәбәрчесе беркөн тагын килде
(Аны кодрәтле Тәңре җибәргән иде):
«Иртәгә, син, Хакъның әмре шундый,— диде,—
Сәйранга чык сарай әһле белән имди.

Хакыйкатьтә, һичбер шиксез шуны бел син:
Кем беренче очрый, шуны алып кил син,
Кем булса да, үзеңә аны вәзир кыл син,
Бу — Халикъның әмре, аны үтә имди!»

Йосыф шулай бик мәһабәт бара иде,
Бер гарибне[1] очратты ул — бакты-күрде:
Өсте-башы бик сәләмә иске иде,—
Йосыф әйтте: «Миңа бу тиң түгел имди!»

Ләкин Җәбраил шунда ук төшеп җитә. Бу мосафир — заманында синең гаепсезлегеңә шаһит булып сөйләгән бала. Алла әмерен үтә, дип кисәтә. Йосыф мосафирны үзенең вәзире итә.

---

[1] *Гариб* — мосафир, юлчы.

XI фасыл

Зөләйханы никах кылуы

Зөләйха бик зәгыйфьләнде, күзе күрмәс,
Ашау-эчү, киенүгә күңел бирмәс,
Бик картайды, ләкин аны Йосыф белмәс,—
Ә Зөләйха һич оныта алмас имди.

Шулай итеп, һәр яңа ай туган чакта,
Тази[1] кешнәп, гаскәр үтеп торган чакта,
Газиз Йосыф атта сәйран кылган чакта,
Зөләйха гел юлда егълап торыр имди.

Тагын яңа ай туган көн килеп җитте,
Йосыф ат менеп янә сәйран чыкты,
Зөләйха кычкырып шунда фөрьяд[2] итте:
«Әйа Йосыф, миңа күз сал!» — дияр имди.

Йосыф шулчак тази атның башын тартты,
Якын килде, хәл сорашып, аңар әйтте:
«Кем буласың, миңа нинди эшең төште?
Әйт теләгең, үти алсам»,— дияр имди.

---

[1] *Тази* — чаптар ат.
[2] *Фөрьяд* — ярдәм сорап ялвару.

Зөләйха үзенең Кыйтфир хатыны булуын әйтә, бөтен малын Йосыф өчен тотып бетерүе һәм мәхәббәт утыннан шушы хәлгә төшүе турында сөйли. Йосыф аны бик кызгана.

Йосыф әйтте: «Әгәр чынлап гашыйк булсаң,
Гыйшыклыкта чын тугърылык саклый алсаң,
Гыйшык зарын аңлауга дәгъва кылсаң,
Бу дәгъвага берәр дәлил кирәк имди».

Зөләйха әйтте: «Инде кил син яныма,
Рәхим итеп, бу камчыңны бир кулыма,
Гашыйк булсам, ул күрсәтер моны сиңа,—
Күрсәтмәсә, дәгъвам ялган булыр имди».

Йосыф, килеп, аңа үз камчысын сонды,
Хатын камчыга өрде дә кире бирде,
Камчыга ут кабынганын Йосыф күрде,—
Камчы янып, Йосыф кулын пешерер имди.

Шул ук сәгать янына Җәбраил килде,
Канаты белән бер сыйпап дога кылды,
Зөләйханың күзе ачылды, япь-яшь булды,—
Тулган айдай йөзе нурдан балкыр имди.

* * *

Зөләйханы Йосыф никах кылып алды,
Зур мәҗлескә бик күп кунак чакырылды,
Чакырылган олугъ бәкләр бар да килде,—
Бик күп шатлык, сөенечләр булды имди.

Аннан соңра Хакъ тәкъдире шулай булды:
Алар икәү гомер буе бергә торды,
Хода аларга унике ул бүләк кылды,—
Олысына Мөсалим диярләр имди.

XII фасыл

Йагъкуб угъланнарының Мисырга баруы

Кәнган иле зур кытлыкка дучар булды,
Йагъкуб нәби угылларына боерды:
«Мондый кытлык безгә яман тәэсир кылды,
Ашлык сорап, Мисырга барыгыз имди».

Ун карендәш бу сәфәргә риза булды,
Унысы да доя менеп сәфәр кылды,
Ибне-Йәмин генә бармый өйдә калды,—
Алар шулай Мисырга юл тотар имди.

Кайчан Йосыф Җәбраилдән хәбәр белде,
Кардәшләре килүенә бик сөенде,
Ходасына рәхмәт-алкышларын әйтте,—
Килүләрен бик муафикъ күрер имди.

Йосыф агаларын сагынган, махсус сарайга кертеп, барысын да бик әйбәт кунак итә. Аларны, зурлап, вәзир һәм улы Мөсалим сыйлый. Агалары бу хәлгә бик аптырыйлар. Бераздан Йосыф, үзе кереп, хәл-әхвәлләрен сораша. Туганнары әтисенең Йосыф кайгысыннан сукыраюы турында сөйлиләр һәм Йосыфны без дә бик ярата идек, дип алдыйлар. Йосыф үзенең йөзен ачмый, туганнарына Ибне-Йәминне алып килергә куша. Агалары, Кәнганга кайтып, энеләрен алып килергә мәҗбүр булалар. Мисырга җиткәч, Ибне-Йәмин агаларыннан адашып кала. Моны белеп, Йосыф яраткан туганы белән очрашырга ашыга һәм аңа бик кыйммәтле беләзек бүләк итә.

XIII фасыл

Йосыфның сарай салдыруы

Әмер бирде Йосыф: «Төзүчеләр килсен,
Гаҗәп биек, таза сарай бина кылсын,
Ул сарайның буе кырык аршын булсын,
Биеклеге дә шулкадәр булсын имди.

Ясасыннар анда Йагъкубның сурәтен
Һәм йәнә угъланнарның кыяфәтен,
Аларның Йосыфка ниләр күрсәткәнен,—
Һәммәсен дә ясасыннар анда имди».

Кардәшләре ул сарайга килеп керде,
Сарайдагы рәсемнәрне Рауил күрде,
Шыпырт кына һәрберенә мәгълүм кылды:
«Безнең батыйль[1] эшләребез!» — дияр имди.

---

[1] *Батыйль* — яман.

Бу ун кардәш, сурәтләрне күреп инде,
Яман гамәлләре өчен бик үкенде,
Мондый гөнаһ эшләреннән тәүбә кылды,—
Ашау-эчү кайгылары китте имди.

Ләкин Йосыф тәрҗемә итүчесеннән «Ник елыйсыз?» дип сораткач, тегеләр ялган сөйләүләрен дәвам итәләр. Рәсемнәрнең берсе энебез Йосыфка охшаган, аны бүре ашады, шуны искә алып елыйбыз, диләр. Кардәшләрне, сый-хөрмәт күрсәтү өчен, башка сарайга кертәләр. Ләкин Ибне-Йәмин ашамый-эчми, рәсемле сарайга үзен кире кайтаруларын сорый: бер сурәт Йосыфка бик охшый, шуны тагын бер кереп күрер идем, ди.Бераздан аның янына Йосыф килеп керә.

Йосыф аулак ул сарайга тагын барды,
Шунда нурлы йөзеннән пәрдәне алды,
Йөзен күреп, Ибне-Йәмин хәйран калды,—
Һушы китеп, тагын җиргә авар имди.

Бераздан соң Ибне-Йәмин аңга килеп,
Икесе дә күрештеләр куллар биреп,
Берсен берсе табыштылар, моны күреп,
Фәрештәләр таңга калып торыр имди.

Йосыф әйтте: «Кайт син хәзер ул сарайга,
Шулай итеп, барып кушыл агаңнарга,
Эшләреңдә күрсәт ярдәм син аларга»,—
Ибне-Йәмин куркыр, анда бармас имди.

Әйтте: «Сине көтмәгәндә мин югалттым,
Шуннан бирле мәхрүм булып хәсрәт чиктем,
Җитмеш еллар егълап, инде сине таптым,—
Бәгъремне парә-парә кылдың имди!»

Йосыф әйтте аңа: «Инде син кайгырма,
Кардәшләрең янына бар, аерылма,
Калырсың син минем янда, шөбһә кылма,—
Моның өчен мин бер чара кылам имди.

Синең йөккә мин бер касә яшерермен,
Шуны табып, угъры ул дип белдерермен,
Шулай итеп, үз янымда калдырырмын,—
Минем белән бер сүздә бул»,— дияр имди.

Йосыф туганнарын сыйлый, зурлый да озатканда Ибне-Йәмин йөгенә кыйммәтле савытын яшереп куя. Тегеләр шактый юл киткәч, артларыннан барып тота һәм караклыкта гаепли. Абыйлары, үзләрен аклар өчен, ялган сөйләүләрен дәвам итәләр:

Аннан соңра алар мондый җавап бирде:
«Энесе дә аның явыз угълан иде,
Ул да, әйбер урлап, бер тотылган иде,—
Бу икәүнең анасы Рәхилә имди».

Йосыф аларга болай дип җавап бирде:
«Сез кылдыгыз явызлыклар бик күп инде,
Йагъкуб нәби сездән күпме җәфа күрде,—
Эшләдегез күпме язык эшләр имди!

Хөрмәт итәм,— диде,— фәкать атагызны,
Мин калдырмас идем юкса исән сезне,
Мин үтерер идем, ярсып, һәммәгезне!» —
Кардәшләре зур куркуга төшәр имди.

Кардәшләре Йосыфка бик ялвардылар
Һәм, ниһаять, китәргә рөхсәт алдылар,
Йәһүдәдән башкалар сәфәр кылдылар,—
Ибне-Йәмин белән ул да калыр имди.

Туганнар өйләренә кайталар һәм башларыннан үткәнне аталарына сөйлиләр. Ләкин Йагъкуб яңа хәбәрне бик тыныч күңел белән тыңлап тора.

Йагъкуб әйтте: «Халикъ шулай булсын дисә,
Кол өстенә бирәр бәла-каза килсә,
Кол моңарга риза булып сабыр итсә,
Михнәттән соң рәхәтен дә бирер имди!»

Ибне-Йәминне коткаруын сорап, Йагъкуб Йосыфка хат яза һәм, шул хатны тапшыру өчен, улларын кабат Мисырга җибәрә. Туганнар, Йосыфны кол итеп сәүдәгәр Маликка сатканда, алыш-биреш кәгазе язган булганнар. Йосыф аны күп еллар буена саклап тоткан һәм хәзер туганнарга бирә, укырга куша.

Йосыф әйтте: «Бер кол угълан сез саткансыз,
Колыбызның өч гаебе бар дигәнсез,
Шул шарт белән бу язуны сез язгансыз!» —
Алар танмый: «Без язмадык!» — диләр имди.

«Сөйгән угълын сез Йагъкубтан аергансыз,
Айрылу утында бәгърен яндыргансыз,
Бүген, килеп, минем алда мактанасыз:
«Без — асыл зат, без — шәрифләр[1]!» — дисез имди.

---

[1] *Шәриф* — пәйгамбәр токымы.

Сезнең берәр кулыгызны кистерермен,
Һәммәгезне муйныгыздан астырырмын,
Барчагызны мин җәзалап үтертермен,—
Сез Йосыфка кылган җәбер өчен имди!»

Алар әйтте: «Кыл син, газиз, безне азат,
Атабыз хакына безгә кыл мәрхәмәт,
Шәфкатьле бул, күп чикте болай да газап,—
Сукырайды ике күзе егълап имди!..»

Моны ишетеп, Йосыф бик нык дулкынланды,
Дөя менеп, йөзеннән пәрдәсен ачты,
Тегеләрнең күзләреннән бәйне чиште,—
Йосыфны күреп, бар да ялварыр имди:

«Син Йосыфка шулкадәрле охшагансың!»
«Йосыф булсаң, нигә безне ят күрәсең?»
«Әллә инде, чыннан да, Йосыф буламсың?»
«Чыннан да, син Йосыф бит!» — диләр имди.

Йосыф әйтте аларга: «Инде белегез,
Мин, чыннан да, Йосыф — сезнең кардәшегез,
Бирде миңа падишаһлык Хакъ-Тәңребез,
Мин — Йосыф, ә бу — туганым[1]!» — дияр имди.

Бу сүздән соң бар да җиргә авып төште,
Танығач аны, ис-акылдан тәмам шашты,
Бу хәбәр Мисыр әһленә һәм иреште,—
Мондый хәлгә һәркем гаҗәпләнер имди.

Йосыф әйтте: «Күтәрегез башыгызны,
Багышладым бөтен бозык эшегезне,
Кайгырмагыз, гафу итәм бүген сезне,—
Кичерәмен гайбегезне»,— дияр имди.

Алар башларын күтәреп күрештеләр,
Күзләреннән яшьләр түгеп егълаштылар,
Һәммәсе дә аһлар орып иңрәштеләр,—
Моны күреп, фәрештәләр егълар имди.

---

[1] *Туганым* — сүз Ибне-Йәмин турында бара.

XIV фасыл

Йосыфның үз күлмәген Йагъкубка җибәрүе

Йосыф әйтте: «Инде болай мин эш күрәм:
Атама үз күлмәгемне һәм җибәрәм,
Ул мескенне, шулай итеп, сөендерәм,
Ә сез аннан үтенегез гафу имди».

Ул, анасы үлгәч, сабый килеш калды,
Йагъкуб сәүчи бер карауаш сатып алды,
Карауашны Йосыфка ул дая кылды,
Аның сабый угълын читкә сатып имди.

Зари кылды, күп егълады ул карауаш,
Күзләреннән җитмеш тамчы түгелде яшь:
«Раббем,— диде,— хәсрәткә тарды минем баш,
Угълымны ул миннән аерып сатты имди!»

Халикъ әйтте: «Ә мин шулай боерырмын:
Аны да сөеклесеннән аерырмын,
Аерылу утларында яндырырмын,—
Нәкъ җитмеш ел егълатырмын аны имди!»

Йосыф бер кол сатып алды — Бәшир атлы,
Бу сүзләрем тыңлау өчен гаять татлы,
Холкы күркәм, үзе гаять мәрхәмәтле,—
Һәрбер эшне игелек белән эшләр имди.

Үз күлмәген шул Бәширгә Йосыф бирде,
Бер хат язып, аның кулына тоттырды,
Ул күлмәкне алып, Бәшир сәфәр чыкты,—
Йосыфтан Йагъкубка ул юл тотар имди.

Саба җиле[1] Хакътан үтенеп зари кылды,
Рәхме[2] белән Халикъ аңа рөхсәт бирде:
Бәширдән ул ун көн әүвәлрәк килде,—
Йосыф исен Йагъкубка җиткерер имди.

Исне сизеп, Йагъкуб Хакъка шөкер кылды,
Хәсрәт китеп, күңеленә шатлык тулды.
Әйтте: «Минем Йосыфымның исе килде,—
Сәбах җиле китерде аны»,— дияр имди.

---

[1] *Саба (сәбах) җиле* — таң җиле.
[2] *Рәхме* — рәхмәте.

«Акрын исче, сәбах җиле, бик ашыкма,
Китерәсең Йосыфымның исен миңа,
Дәва булчы йөрәгемнең ярасына,—
Син искәндә күңелем шат була имди!»

Аннан соңра, ун көн үткәч, Бәшир килде,
Бер хатын бер коеда кер юа иде,
Йөгреп килеп, Бәшир аңа сорау бирде:
«Йагъкуб өе кайда икән?» — дияр имди.

Хатын әйтте: «Йагъкуб өен ник эзлисең,
Бик ашыгып кайдан килдең, ни телисең?
Ул Йагъкубка яхшы хәбәр китерәмсең? —
Шундый хәбәр китергәнең күрәм имди!

Йагъкуб нәби мине сатып алган иде,
Йосыфына дая итеп куйган иде,
Бәшир атлы кечек угълым саткан иде,—
Нәкъ җитмеш ел кайгы-хәсрәт чигәм имди».

Бәшир әйтте: «Егълама син, әйа ана,
Хәсрәт белән йөрәк итеңне талама,
Хакъ вәгъдәсе булмады дип гөнаһланма,
Синең угълың Бәшир менә мин ул имди!»

Моны ишеткәч, ул хатын тәмам шашты,
Бичаракай һушыны җуеп авып төште,
Аңга килгәч, угълы белән ул күреште,—
Икесе дә шатланудан егълар имди.

Йагъкубның өенә алар бергә керде,
Хатын шатлыктан нишләргә белми иде,
Бәшир килеп, Йагъкубка күлмәкне бирде,
Йагъкуб йөзен сөртте — күзе ачлыр имди.

Күзен ачкач, ул Бәширне Йагъкуб күрде:
«Син кем?» — диеп, шунда аңа сорау бирде.
Бәшир әйтте: «Син, анамнан аерып, мине
Саткан идең, мин шул Бәшир булам имди».

* * *

Аннан Йосыф кардәшләрен киендерде,
Бик күп алтын-көмеш, ат һәм качыр бирде,

Атасына да килергә рөхсәт итте,
«Килсен бөтен нәсле беләні» — дияр имди.

Алар кайтып, Йагъкуб белән күрештеләр,
Һәммәсе дә аның белән кавыштылар,
Хаталарын сөйли-сөйли егълаштылар,
«Кичер безнең гөнаһларны!» — дияр имди.

Йагъкуб әйтте: «Хатагызны ярлыкадым,
Бөтен гөнаһ эшегезне гафу кылдым,
Бүген тагын Халикымнан рәхәт алдым,—
Сез дә рәхәтләр күрегез!» — дияр имди.

Йагъкуб, җыенып, Мисырга, улы янына китә. Аны Йосыф олылап каршы ала, үзенең балалары һәм Зөләйха белән таныштыра. Зөләйха Йагъкубны башта зур зиннәтле сарайга урнаштырмакчы була. Пәйгамбәрләр андый бинада яшәми дип, Йагъкуб баш тарта. Кечерәк сарайга кертәләр, ләкин картка андагы ризык та ошамый:

Йагъкуб әйтте: «Йөз егерме минем яшем,
Гел гыйбадәт кылу минем бөтен эшем,
Һәрвакытта арпа икмәгедер ашым,—
Пәйгамбәрләр мондый ризык капмас имди!»

XV фасыл

Мәлик Рәййанның Йагъкуб нәбине үз сараена өндәве

Рәййан Йагъкубны кунакка чакырмакчы була. Бу ниятен Йосыфка әйтә. Йосыф, барыйк дип, әтисен үгетли.

Йосыф сүзен тыңлап, Йагъкуб риза булды,
Рәййан аның йөзендәге нурны күрде,
«Ничә яшьтә син?» — дип, аңа сорау бирде,
Йагъкуб әйтте: «Йөз егерме тулды имди».

Бер хәрәми[1] моңа каршы: «Артык!» — диде
(Бу — Йагъкубның сүзенә инанмау иде),
Йагъкуб сәүчи кул күтәреп дога кылды,—
Ияге күкрәккә салынып төшәр имди.

---

[1] *Хәрәми* — хәрәмдәге (гаремдагы) хатын-кыз.

Мәлик Рәййан шунда Йагъкубтан үтенде:
«Ул хәрәми үзе бик күп яшьтә инде,
Үз сүзеннән кайтып, сезнең дингә керде,—
Ул карчыкка кыл син изге дога имди».

Йагъкуб сәүчи кул күтәреп дога кылды,
Карчыкның ияге әүвәлгечә булды,
Ул үзенең ялгышканын ачык белде:
«Сине Исхакъ[1] дип торам мин»,— дияр имди.

Улы Йосыф янында кырык ел торганнан соң, Йагъкуб туган ягына кайтып вафат була. Аңа гүрне фәрештәләр казып куялар. Йагъкуб улларын чакыра да: «Авыр чакта татулыклар телим»,— ди. Бу аның соңгы васыяте була. Әтисенең үле хәбәрен ишеткәч, Йосыф бик кайгыра:

Йосыф, моны белгәч, бик каты егълады —
Зари-зари кылып, яшьләр түгәр иде,—

ди автор.

Көннәрнең берендә ул Мисыр халкын мөселман динен тотарга өнди башлый. Халык моңа каршы төшә. Шуннан соң Йосыф Рәййанга болай ди:

«Болай булгач, мин бүтәнчә кыла алмыйм,
Бу Мисырда инде артык кала алмыйм,
Мин кяферләр белән күрше була алмыйм,—
Кяферләрдән айры тору кирәк имди!»

Йосыф үзенең якыннары белән Мисырны ташлап китә. Алар бик матур бер урында яңа шәһәр төзиләр. Шәһәргә «Әмин», ягъни «Тынычлык» дип исем бирәләр. Көннәрнең берендә Зөләйха вафат була. Тиздән, бу кайгысын күтәрә алмыйча, Йосыф үзе дә үлә. Балалары, туганнары аны зурлап күмәләр. Ул күмелгән якта һәрвакыт иген уңа, ди автор. Кол Гали китабын болай тәмамлый:

Хакъка шөкер, ошбу китап тәмам булды,
Рәхмәт аңа, миңа ул күп ярдәм кылды,
Аңласагыз, мин — Уганның[2] зәгыйфь колы —
Көйгә салып, хикмәт, киңәш яздым имди.

---

[1] *Исхакъ* — Йагъкубның этисе.
[2] *Уганның* — Алланың.

«Йосыф кыйссасы»на кадәр язылган әдәби ядкарьләр

«Йосыф кыйссасы»н татар әдәбиятының беренче үрнәге итеп өйрәнәбез. Автор, әсәрен язганда, күп телләрдә язылган легенда сюжетыннан файдалана. Бу хакта ул:

Йосыф сәүчи кыйссасын мин сөйләп бирдем,
Гарәпчәсен, фарсычасын үрнәк иттем,—

ди.

Ләкин шуның артыннан ук:

Уку-тыңлау өчен булсын ансат, дидем,—
Укыганнар хәер-дога кылсын имди,—

дип тә өсти.

Кол Гали, Урта Азия халыкларында киң таралган сюжетларны өйрәндем, алардан файдаландым, ләкин үзгәрттем, дип белдерә. Хәтта әсәрнең сюжеты читтән кергән булса да, кыйссаның ритмик төгәллегенә, рифмаларга бай булуына карагандa, аңа кадәр дә шундый ук шигъри камиллек белән язылган әсәрләр яшәвенә шик калмый. Буш урында шундый гүзәл әсәр туа алмый. Кыйссаның янәшә килгән күп санлы сюжет сызыкларына корылуы, төп эчтәлекнең шулар арасындагы бәйләнешләргә салынуы «Йосыф кыйссасы»на кадәр дә күләмле әсәрләр тууы турында сөйли. Кызганыч ки, аларның күбесе төрле сәбәпләр аркасында югалганнар. Борынгыларның ничек уйлануларын белү өчен, шул заманнан бирле сакланып калган төрле өйрәтмәләрне, сүзлекләрне, сәхифәләрне җентекләп тикшерәләр. Алар арасында ике әдәби әсәр дә бар. Берсе — Йосыф Баласагуниның унберенче гасырда язган «Котадгу белег», ягъни «Бәхет белеме» исемле әсәре. Икенчесе — Әхмәд Йүгнәкинең уникенче гасырда иҗат иткән «Хакыйкатьләр җыентыгы» исемле әсәре.

Алар икесе дә — дидактик әсәрләр.

> Д и д а к т и к ә с ә р дип автор теләге турыдан-туры үгет-нәсыйхәт рәвешендә әйтелгән әсәрне атыйлар.

Баласагуни поэмасы җәмгыятьне югарыдан идарә итеп ныгытуга багышланган. Моның өчен кешеләрдә дүрт сыйфат булу шарт дип уйлый автор: 1) гаделлек, 2) идарә, ягъни актив эш, 3) акыл, 4) саклык, ди. Шул фикерен исбат итү өчен, Баласагуни әлеге дүрт сыйфатны дүрт кеше итә һәм сыйфат-кешеләрне үзара мөнәсәбәткә кертә — кавыштыра. Сыйфат-

кешеләрнең үзара мөнәсәбәте әсәрнең сюжетын тәшкил итә һәм ике нәтиҗәгә китерә. Беренчесе: кешеләр шул сыйфатларның берсенә генә ия булсалар да бүләкләнәләр — идарә эшенә күтәреләләр. Икенчесе: шул дүрт сыйфат бөтенесе бергә җыелганда гына җәмгыять хәвеф-хәтәрсез яши ала.

Әхмәд Йүгнәки әсәрендәге киңәшләр җәмгыятьне түбәннән, халыкның үзен тәрбияләү юлы белән ныгытуга юнәлтелгән. Башкалар белән тату яшәү өчен, кеше ундүрт сыйфатка ия булырга тиеш, ди автор. Шуларның берничәсен генә әйтик: кешеләр белемле булырга, өлкән буыннар калдырган рухи байлыкны хөрмәт итәргә, юмарт, гадел булырга, башкаларның серен саклый белергә, сүзне үлчәп сөйләргә, явызлыкка каршы көрәшергә тиешләр...

Баласагуни һәм Йүгнәки әсәрләрендәге үгет-нәсыйхәтнең эчтәлеге бүген дә актуаль. Без хәзер дә борынгы төрки әдипләр язган кагыйдәләрне хөрмәт итеп яшибез. Ләкин сәнгатьчә эшләнешләре ягыннан бу әсәрләр «Йосыф кыйссасы»ннан күпкә калышалар. Өстәвенә аларның төрки дәүләтләрнең кайсысында язылуы мәгълүм түгел.

«Йосыф кыйссасы»ның Болгар дәүләтендә иҗат ителүе исбатланган. Татар әдәбияты үсешенә ул — гаять зур йогынты ясаган әсәр.

Кыйссага анализ

1. Үзегезне сынагыз: чәчмә әсәрләргә анализ ничек ясалуын исегезгә төшерегез.

> Әдәби әсәрнең эчтәлеге өлешләре арасындагы бәйләнешләрдән табыла. Шуңа күрә анализны иң элек кыйссаны өлешләргә бүлүдән башлыйбыз.
>
> Чәчмә әсәрләрне вакыйгаларга бүлгән кебек, сюжетлы поэмалар да вакыйгаларга таркала.

Кыйссаның сюжеты күп санлы, бер-берсенә бәйләнешсез диярлек вакыйгалардан төзелгән. Алар арасында бер генә урында башланып тәмамлана торганнары да, әсәрнең буеннан-буена сузылганнары да бар. Соңгыларына сюжет сызыклары диләр.

2. Йосыфның әнисе кабере янындагы зары һәм кыйналуы турындагы вакыйганы тагын бер кат укып чыгыгыз. Аның ни өчен тәмамланган вакыйга булуын исбат итегез.

Әсәрнең вакыйгалары ничек табыла?

Башта әсәрдәге барлык вакыйгаларны табып, аларга исем биреп чыгарга һәм, охшашларын бергә кушып, аз гына санга калдырырга мөмкин. Ләкин теләсә кайсы тәмамланган бер вакыйганы өйрәнеп, аннары шуңа охшаган башка вакыйгаларны эзләү эшне шактый җиңеләйтә. Моңа кадәр без катлаулы әсәрләрне икенче юл белән өйрәндек. Хәзер дә шул юлны сайлыйк.

3. Йосыфның кыйналуы турындагы вакыйганы өйрәник. Шундый ук уңыш белән әсәрдәге теләсә кайсы башка вакыйганы да өйрәнергә мөмкин. Вакыйганы өйрәнү өчен, аны шулай ук өлешләргә бүләргә һәм аларга исем бирергә кирәк. Бүлегез һәм исемнәр биреп чыгыгыз.

Ә хәзер бергәләп бүлик.

Йосыф, елый-елый, энисенә үзенең ачы язмышы турында сөйли. Бу эпизодка бер генә сүз белән «зар» дип исем бирәбез. Кылыч исемле кол Йосыфны качтың дип кыйный. Ул гаделсезлек, гөнаһ эш эшли. Шуңа күрә эпизод йә «явызлык», йә «гаделсезлек», йә «гөнаһ эш» исеме ала. Карлы-бозлы яңгыр гөнаһ эш өчен Алланың җәзасы булганга, чираттагы эпизодка «җәза» дип исем бирәбез. Кылычның елый-елый гафу үтенүен «гафу үтенү» дип атыйбыз. Соңгы эпизодта Йосыф Кылычны гафу итә. Алла карлы-бозлы яңгырны туктата, ягъни ул да гөнаһны гафу итә.

Әсәрдәге бер вакыйганың төзелеше табылды. Ул гөнаһ эш — җәза — гафу үтенү — гафу итү өлешләреннән гыйбарәт.

4. Өйрәнгән вакыйганы биш өлешкә бүлгән идек. «Зар» өлеше югалды. Ни өчен Йосыфның энисенә зары аерым өлеш була алмый? Исбат итегез.

Анализның беренче адымын ясадык. Әсәрдәге тәмамланган бер вакыйганың үзара тыгыз бәйләнешкә кергән дүрт өлештән торуын белдек. Күп вакыйганы эченә алган кыйссага чәчмә әсәрләр үзенчәлеге хас, дидек. Шуңа күрә анализның икенче адымын чәчмә әсәрләр үзенчәлегенә таянып ясыйбыз. Чәчмә әсәрләрдәге вакыйгалар бер үк теманы төрле яктан ачалар. Алай гына да түгел, бер теманы бер үк төрле төзелешләре ярдәмендә ачалар.

Вакыйга төзелеше гади рәвешкә китерелгән (гомумиләштерелгән) эпизодлардан һәм алар арасындагы бәйләнештән гыйбарәт.

5. Өйрәнгән вакыйганың сюжетын сөйләп чыкмадык. Сюжетны гадиләштердек. Ничек гадиләштердек? Аңлатыгыз.

6. Шул ук вакыйганы ике генә өлешкә дә калдырып була. Моның өчен өлешләр арасындагы ике төрле бәйләнешне табарга кирәк. Вакыйганы ике генә өлешкә калдырыгыз.

Әсәрдәге вакыйгалар арасында уртак сыйфатлар бар. Шул уртаклыкны эзлибез.

7. VIII фасылда гарәп белән дөя катнашындагы вакыйгага да анализ ясагыз. Кылыч катнашкан вакыйганы бүлгән кебек өлешләргә бүлегез, өлешләрне җыеп, икегә генә калдырыгыз. Бу ике вакыйгада урын да башка, катнашучылар да, әмма төзелеш һәм тема кабатланачак. Шуны исбат итегез.

8. XV фасылдагы хәрәми хатын катнашындагы вакыйга төзелешенең дә алдагы ике вакыйга төзелешенә охшавын исбат итегез.

9. Кыйссада гөнаһ эш — җәза — гафу үтенү — гафу итү кебек төзелешле вакыйгалар тагын бар. Табыгыз.

Инде сюжет сызыкларын өйрәнүгә чират җитте. Кыйссада әсәрнең буеннан-буена сузылган Йосыф әтисе Йагъкуб, Йосыфның агалары һәм Зөләйха белән бәйле өч сюжет сызыгы бар. Шуларның беренчесенә тукталыйк.

Йосыфның әнисе үлгәч, Йагъкуб, баласына сөт күбрәк калсын дип, Йосыфны караучы хатынның баласын коллыкка сата. Йагъкуб — пәйгамбәр. Шуңа күрә аның бу гаделсезлеге бик зур гөнаһ эш булып бәяләнә. Ятим калган хатын:

> «Раббем,— диде,— хәсрәткә тарды минем баш,
> Угълымны ул миннән аерып сатты имди!» —

дип ялваргач, Алла Йагъкубка бик авыр җәза бирә:

> Халикъ (ягъни Алла) әйтте: «Ә мин шулай боерырмын,
> Аны да сөеклесеннән аерырмын,
> Аерылу утларында яндырырмын,—
> Нәкъ җитмеш ел егълатырмын аны имди!» —

ди.

Улын югалту хәсрәте — Йагъкубка Алла биргән җәза. Шуңа күрә икенче эпизодны «җәза» дип исемлибез.

Сюжет сызыгына кергән вакыйгалар бер-бер артлы Йагъкубның хәсрәтләнүен — җәза алуын кабатлыйлар. Кыйсса авторы Йагъкубның хәсрәт дәрәҗәсен дөягә әйттерә:

Даим синең хәсрәтеңне йота Йагъкуб,
Аңа синнән сөеклерәк беркем дә юк,
Уйладымы сине, һушсыз кала шундук,—
Һушсыз булып озак вакыт ятар имди.

Башта Йагъкуб Йосыфның үле хәбәрен ишетеп аңын югалта. Аннары, елаганда, күзләреннән яшь урынына кан ага, күзләре сукырая. Бу вакыйгалар бар да Йагъкубның хәсрәт дәрәҗәсен күрсәтәләр. Шуңа күрә без аларны, бергә җыеп, бер генә исем белән атыйбыз.

10. Калган ике сюжет сызыгына анализны үзегез ясагыз.Кыйссадагы бик күп вакыйгаларның һәм барлык сюжет сызыкларының төзелешләре уртак. Барысында да гөнаһ эшләүче җәзасын ала. Гафу үтенсә гафу ителә.

Күпчелек вакыйгалар охшаш. Ә калган вакыйгаларның төзелеше нинди?

Дүртенче фасылдагы үзгә вакыйганы өйрәник.

Нил елгасына килеп җиткәч, балыклар солтаны Йосыфка су коенырга ярдәм итә. Йосыфны үзенең өстенә бастыра. Башка балыкларга пәйгамбәр тәненә карамаска боерык бирә. Ярдәме өчен Алла балыклар солтанына ике бала бүләк итә.

11. Вакыйганың эчтәлеген ике генә сүз белән әйтегез. Шуннан соң ике өлештән торган төзелеш табачаксыз.

12. Кыйссада шундый ук төзелешле башка вакыйгаларны табыгыз.

Анализның бер өлешен башкардык. Әсәрне таркаттык һәм вакыйгаларның уртак төзелешен белдек. Ә охшаш вакыйгалар бер генә өлешкә җыелуны үзләре сорап торалар.

Хәзер охшаш вакыйгаларны җыеп гомумиләштерә алабыз: кыйсса гөнаһ эшкә — җәза һәм яхшылыкка — яхшылык өлешләреннән гыйбарәт, дибез.

Бер-берсе белән каршылыкта торган бу ике өлеш әсәрнең төзелеше була.

Әсәрнең төзелешен табу нигә кирәк?

Күрдегез, әсәр төзелеше (структурасы) кабатланган вакыйгаларны гомумиләштереп табылды. Ә кабатлау алымы — авторның укучысы белән үзара сөйләшү (диалог) теле ул.

Әсәрнең төзелеше аның темасын табарга ярдәм итте. Эчтәлек төзелеш өлешләренең үзара бәйләнешендә ачыклана.

Анализның чираттагы алымы — өлешләрне аерым-аерым өйрәнү.

Гөнаһ эш — җәза өлешен аерып өйрәник. Бу өлешкә кергән вакыйгаларның уртак эчтәлеген таптык. Инде аермаларын белик. Аерма персонажларның холкында да, язмышларында да, рухи халәтләрендә дә түгел. Аларның бу сыйфатларына автор игътибар итми. Вакыйгаларда ике аерма бар. Берсе — гөнаһ эшләүчеләрнең төрле социаль төркем вәкилләре булуында. Икенчесе — гөнаһ эшләрнең төрләрендә.

13. Йагъкуб — ыруг башлыгы, хаким. Кылыч — кол... Дәвам итегез.

14. Гөнаһ эшләрнең төрләрен санап чыгыйк. Йагъкуб башкалар исәбенә үзенә файда итә: ирекле кешене колга әйләндерә. Ананы баласыннан аера. Бер сүз белән әйткәндә, гаделсезлек эшли. Йосыфның туганнары көнчелектән явызлык эшлиләр, Зөләйха, сабырсызлыгы аркасында, намуслы кешегә яла яга... Гөнаһ эшләрнең калганнарын, шул рәвешле, санап чыгыгыз, исем бирегез.

Төзелешләре кабатланган күп санлы вакыйгаларның берсендә дә бер үк социаль төркем вәкиле кабатланмый. Вакыйгаларында шулай ук автор бер үк төрле юньсезлек турында язмый. Беренче өлешне өйрәнеп, кыйссаның бик мөһим шундый үзенчәлеген белдек.

15. Кыйсса төзелешенең икенче өлешен дә (яхшылыкка — яхшылык), шул рәвешле, өйрәнегез һәм нәтиҗә ясагыз.

Хәзер нәтиҗә ясый алабыз.

1. Алла кешеләрне тигез күрә. Кемнең кем булуына карамастан, эшләренә генә карап бәя бирә.

2. Алла гөнаһ эшләрнең, аларның нинди булуына карамастан, берсен дә җәзасыз калдырмый. Ләкин ялгышын аңлап төзәлгән кешеләрне гафу итә.

Беренче нәтиҗәнең идеясе мондый: башкалардан өстенлегең белән масайма.

Икенче нәтиҗәнең идеясен үзегез әйтегез.

Анализның бик мөһим эше тәмамланды: әсәрнең төзелеше табылды.

Кабатлау алымы.

Кабатлау — аеруча еш кулланыла торган сәнгать алымы.

Әдип, кабатлый-кабатлый, укучы игътибарын әсәрендәге иң мөһим фикеренә яки хисенә юнәлтә.

Кабатлау әсәрдәге вакыйгаларны үзара бәйли. Таркау вакыйгаларны җыеп, бөтенлек тудыра.

Кабатлау хиснең дәрәҗәсен арттыру өчен кулланыла.

Төзелештә әсәрнең үзәк темасы ята. Кыйссадагы башка эпизодлар, вакыйгалар, образлар бар да төзелеш аша үзара бәйләнешкә керәләр. Әсәрнең эчтәлеге шул бәйләнешләрдә табыла.

Шуңа күрә анализның чираттагы алымы әсәр эчендәге башка бәйләнешләрне өйрәнүгә багышлана.

Бу юлы да кабатланган урыннарга мөрәҗәгать итәбез. Әсәр төзелешендәге җәза бирү вакыйгасы турыдан-туры Алла белән бәйләнгән. Гөнаһ эшләрнең барысына да җәзаны Алла үзе бирә. Яхшылыкка — яхшылыкны да ул эшли. Җәза бирүнең максаты үч алу түгел — кешене төзәтү. Хатасын таныту, үкендерү, тәүбә иттерү, гафу үтендерү. Кабатланган вакыйгалар барысы да тәүбә иткән кешене гафу итү белән тәмамланалар.

Кыйсса персонажларының күбесе төш күрә. Төштә күргәннәр бар да тормышка аша. Төшләре аша Алла кешеләргә булачак вакыйгалар турында хәбәр итә. Шулай итеп, Алла әсәрдә ике бик мөһим эш башкара: ни буласын алдан әйтә һәм үткән вакыйгаларга бәя бирә. Бәясен беләбез: йә кешеләргә җәза бирә, йә теләгәннәрен үти.

Йосыф та әсәр төзелешендә яткан охшаш вакыйгаларның барысында да катнаша.

Йосыф әсәрдә күбрәк, пәйгамбәр буларак, Алла вәкиле вазифасын башкара. Алла исеменнән җәза бирә, кешеләрнең теләкләрен үти, төшләрен юрый. Йосыфның бик күп күркәм сыйфатлары — Алла бүләк иткән сыйфатлар. Үзенекеләре икәү: Аллага тугрылыгы һәм сабырлыгы. Автор героеның тугрылыгын һәм сабырлыгын кат-кат сыный.

16. Йосыфның сабырлыгы сыналган вакыйгаларны искә төшерегез.

Башка күркәм сыйфатларын Йосыфка Алла бүләк итә. Алла үзенә тугры һәм сабыр кешеләрне ярата, чөнки шул ике

сыйфатка ия булган кешеләр гөнаһ эш эшләмиләр. Башкаларга яшәргә комачауламыйлар. Бер-берсенә булышалар. Тату яшиләр. Ә җәмгыять иминлеге өчен иң кирәкле сыйфатлар шулар.

17. Зөләйханың гөнаһ эшләре сабырсызлыгыннан һәм Аллага ышанмавыннан килә. (Мөселман динен ул әсәр ахырында гына кабул итә.) Башка персонажларның да яман эшләре сабырсызлыктан килүен исбат итегез.

Кол Гали кыйссаның идеясен әсәр ахырында сурәтләп тә күрсәтә, гомумиләштереп тә әйтә. Йосыф төзегән оҗмах шәһәренә «Әмин», ягъни «Тынычлык» дип исем бирдерә. Йагъкуб пәйгамбәрнең соңгы васыятен искә төшерик: ул туганнарына һәм башка кешеләргә татулык тели. Бу аның соңгы сүзләре була. Йосыф та, Йагъкуб та — пәйгамбәрләр. Пәйгамбәрләр авызыннан әйтелгән татулык теләү Алла сүзе булып кабул ителә.

18. Кыйссада Зөләйха мәхәббәте турында күп языла. Мәхәббәт дәрәҗәсе күрсәтелгән урыннар турында сөйләгез.

19. Кыйссада Йосыф мәхәббәте турында автор бөтенләй язмый. Ни өчен шулай итә? Ул Зөләйханы ярата мы?

Кыйссадагы матурлык

Автор Йосыфка илаһи матурлык бирә. Аның һәр сыйфатын могҗиза дәрәҗәсенә җиткереп арттыра. Ләкин Йосыфның тышкы матурлыгы — эчке матурлыгының чагылышы гына. Аның йөзендәге нурлардан һәм күз карашыннан Аллага тугрылыгы да, зирәк акылы да, җитмеш ике тел белүе дә сизелеп тора.

Бу әсәрне татар халкы бик яхшы белгән. Кешеләр Йосыфның матурлыгына һәм зирәклегенә сокланганнар. Аның кебек тугрылыклы, сабыр, инсафлы, шәфкатьле булырга омтылганнар. Шулай итеп, Йосыфның күркәм сыйфатлары идеалга әйләнгән.

Идеал дип кешенең иң югары максатына әйтәләр. Коръән кешеләрне Йосыф кебек шәфкатьле булырга өнди, шәфкатьлелек, тугрылык, сабырлык кешене бәхетле итә, ди. Ләкин аның матурлыгын нибары Зөләйха сабырлыгын сынау чарасы итеп кенә файдалана. Кыйссада исә Йосыф матурлыгы —

үзенә бер кыйммәте булган бөтенлек. Дөрес, бу гүзәллек әле дөньяның үз гүзәллеге түгел — Алла иҗат иткән сәнгать. Бу хакта Кол Гали ачык яза. Унике мең гаскәр Йосыф матурлыгын күреп һуштан язгач, Җәбраил күктән төшә дә Йосыфка: «Син үзеңнең матурлыгың белән мактанасың»,— ди һәм:

— Әйа Йосыф, син нинди сүз әйттең,— диде,—
Горурландың, Хакъ сәнгатен син күр имди! —

дип өсти. Икенче төрле әйткәндә, Җәбраил Йосыфка: «Синең матурлыгың табигый, үз матурлыгың түгел — Алла бүләге»,— ди. Йосыфның матурлыгы, шулай итеп, җирдән аерыла, берьюлы идеал да, мәһабәт (возвышенное) тә була. Күркәм әхлакый сыйфатлары Йосыфны — идеал, илаһи матурлыгы мәһабәт итә.

Кыйссада тагын ике матурлык бар. Автор Йосыфка Зөләйха салдырган сарай матурлыгын әкиятләрдәге сарайларга, ә Зөләйханы патша кызы гүзәллегенә охшатып сурәтли. Үзкыйммәткә ия булган шундый сокландыргыч матурлыкка гүзәллек диләр.

Ләкин Кол Гали сурәтләгән гүзәллекләрнең аеруча әһәмиятлесе — мәхәббәт гүзәллеге. Персонажларының мәхәббәт дәрәҗәләрен автор аларның хәсрәтләре аша тасвирлый. Зөләйха, Йагъкуб, Ибне-Йәмин, Йосыф поэманың башыннан ахырына кадәр яшь түгәләр, һушларыннан язалар — кавыша алмаганга кайгыралар. Шулай итеп, хәсрәт — кеше кичереше — гүзәллек дәрәҗәсенә күтәрелә.

Кыйссаның стиле

Авторның яратып кулланган алымы — кабатлау. Кыйссадагы һәр сюжет сызыгы шәфкатьлелекнең җиңүе белән тәмамлана, дидек. Персонажларның хәсрәте дә әсәрнең буеннанбуена кабатлана. Кол Гали уйлаганча, кешеләрне тату яшәтүче чараларның берсе — мәхәббәт. Кабатлау алымы ярдәмендә автор укучысы белән диалогка керә һәм аңа күп санлы сюжет сызыкларындагы (вакыйгалардагы) эчтәлекне бер ноктага җыярга ярдәм итә.

Кол Гали кыйссасын, башлыча, персонажларының үзара сөйләшүенә корган. Ләкин ул персонажлары арасына әледәнәле үз интонациясе белән килеп керә. Мәсәлән, Йосыфны коллыкка сатканнан соң, агалары өйләренә кайталар һәм,

Йагъкубны күреп, берсеннән-берсе уздырып алдашырга керешәләр:

Аны күргәч, бигрәк тә нык аһ ордылар,
Күлмәкләрен ертып, чәчләр йолкыдылар,
Йосыф өчен барсы да аһ-зар кылдылар:
«Аһ, Йосыфны алдырдык шул!» — диләр имди.

Бу строфадагы юллар бер-берсен кабатлап һәм куәтләп киләләр. Теләсәк-теләмәсәк тә, кычкырып укыганда, тонны күтәрергә тиеш булабыз. Туганнарның шамакайлык (юньсезлек) дәрәҗәсенә автор, шул рәвешле, бәя бирә. Ләкин иң ахырдан, үзенең барлыгын белдереп, «имди» (инде) сүзен өстәп куя. Бу сүзе белән автор хәтта агалары кебек юньсезләргә карата да усаллыгы юклыгын сиздерә. «Имди» сүзен ул строфа саен кабатлый. Шул рәвешле, үзенең дә шәфкатьле, сабыр кеше булуын күрсәтә.

> Истә калдырыйк. Йосыф кыйссасында күтәрелгән темалар — **яхшылык, яманлык, шәфкатьлелек, сабырлык, татулык, тугрылык** һәм **матурлык**. Бу темалар кабатланып, эчтәлекләрен үзгәртеп, чордан чорга күчеп, бүгенге көнгә кадәр килеп җитәләр.

Кыйсса хикмәте

Борынгы әдипләр әсәрләрен хикмәт белән язулары турында әйтәләр. Кол Гали, мәсәлән, әсәрен ике өлешкә бүлеп куя: «киңәш»кә һәм сәнгать чарасына — «хикмәт»кә аера. Киңәш өлешен таптык. «Хикмәт» өлешен ачыклыйк.

Хикмәт дигәндә, борынгылар сәнгать чараларын күздә тотканнар.

Кыйссаның нигезендә яткан **кабатлау, арттыру** һәм **каршылык** алымнары шул вазифаны үтиләр. Әдәби әсәр укучының күңеленә тәэсир итәргә тиеш. Кол Гали сурәтләгән Йагъкуб, Йосыф, Зөләйха образларына игътибар итегез. Аларның хәсрәтләре чиктән тыш арттырылган.

Йагъкуб үзенең яман эше өчен үкенә. Улын югалту хәсрәтеннән сукырая. Йосыфны сатып җибәргән улларының юньсезлегенә кайгыра.

Йосыф һәм Зөләйха хәсрәтләренең сәбәпләрен, хәсрәт дәрәҗәләрен турыдан-туры тасвирлаган урыннарны искә төшерегез.

Кол Гали үзенең геройларын карщылык алымы белән дә кызгандыра. Кыйсса персонажлары яман эшләре өчен җәзаларын алалар. Йосыф җәза артыннан җәза алса да, ул гаепле кеше түгел. Җәза аңа этисе өчен бирелә. Димәк, ул, бер яктан, хаклы, икенче яктан, хаксыз рәвештә интегә.

ХИСАМ КЯТИБНЕҢ «ҖӨМҖӨМӘ СОЛТАН» ДАСТАНЫ

Борынгы Болгар дәүләте монгол баскыннарының беренче һөҗүменә бирешми. Чыңгыз хан гаскәрләрен тар-мар итеп ташлый. Ләкин монголлар, көчләрен җыеп, 1236 елда кабат киләләр. Бу юлы болгарлар үзләреннән күпкә көчле дошманга каршы тора алмыйлар. Болгарлар, гасырлар буена җиңүчеләргә буйсынып, күп салымнар түләп яшәргә мәҗбүр булалар. Алай да борынгы бабаларыбыз дәүләтләрен саклап кала алганнар. Тора-бара яраларын төзәткәннәр. Шәһәрләрен торгызганнар, сәүдә эшләрен җайга салганнар. Үз ханнары, князьләре белән яшәгәннәр.

1431 елда Болгарга рус князе Федор һөҗүм итә һәм кайчандыр төзеклеге, байлыгы белән чит ил сәяхәтчеләрен сокландырган Болгар шәһәре хәрабәгә әйләнә. Соңгы йөз ел эчендә телгә алып сөйләрлек әсәрләр иҗат ителми.

Йөз елдан соң да әдипләр Йосыф кыйссасы казанышларын дәвам итәләр. Язган әсәрләрендә яхшылыкка — яхшылык, яманлыкка — җәза бәйләнешләрен кабатлыйлар. XIV гасырда иҗат иткән Мәхмүд Гали Болгари, мәсәлән, күләмле әсәренең исемен «Нәһҗел-фәрадис», ягъни «Оҗмахларның ачык юлы» дип куя. Ул да Аллага ышанып, Алла әйткәнчә яшәгән кешеләргә оҗмах вәгъдә итә, аларның яхшы сыйфатлары эченнән, Кол Гали кебек, шәфкатьлелек сыйфатына өстенлек бирә. Әсәренең башламында: «Йа яраннарым, тәкъва (Аллага ышанып) берлә, тыйнаклык берлә тереклек кылыгыз... шәфкать кылыгыз»,— дип яза.

Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастаны 1376 елда языла. Әсәрендә әдип яман кешеләрен җәһәннәмгә кертеп җәза бирдерә. Кануннар алдында барлык кешеләр дә тигез, ди.

Кеми солтан, кеми кол, кеми әмир,
Кеми хуҗа, кеми бай, кеми фәкыйрь...

Барысы да, гаепләренә карап, үз җәзаларын алачаклар дип исәпли.

Дастанның баш герое Җөмҗөмә солтан бик бай, ләкин юмарт була. Бу хакта Гайсә пәйгамбәргә ул мондый сүзләр әйтә:

Янә бар ирде бер мәнем хуш гадәтем,
Ул сәбәптин чыкмыш иде изге атым.
Кем килер иде килмәмештә кайда ир —
Булса мескен йә гарип, йә фәкыйрь.
Көн дә мең килер ирде дәрвиш, ятим,
Алмаенча китмәз ирде тун[1], атым.

Көннәрнең берендә бер фәкыйрь кереп хәер сорый. Солтанның кәеф-сафа корып утырган чагы була. Җөмҗөмә үз гомерендә беренче мәртәбә яман эш эшли: хәерчене хәер бирмичә куып чыгара. Җәза көттерми. Шуннан соң солтанның башына бик зур шеш чыга. Аннары Газраил, иңеп, нидер эчертә дә гүргә кертә. Җир астында Җөмҗөмәне туп-туры җәһәннәмгә озаталар. Җәһәннәмдә, муенына кызган чылбыр асып, тимер күсәк белән кыйныйлар, уттан утка ташлыйлар, эчәсе килгәндә утлы зәһәр эчемлек эчертәләр. Җөмҗөмә, шул рәвешле, дүрт мең ел буена газап чигә. Җәһәннәмдә ул мактанчыкны, гайбәтчене, күп сөйләүчене, саранны төрлечә җәзалауларын күрә. Алай да иң зур җәза шәфкатьсезлек күрсәткән кешегә — Җөмҗөмәнең үзенә бирелә.

СӘЙФ САРАИ ИҖАТЫ

Сәйф Сараи 1391 елда фарсы теленнән төркигә Сәгъдинең «Гөлстан» исемле әсәрен тәрҗемә итә. Тәрҗемәсенә үзгәрешләр, өстәмәләр кертә һәм «Гөлстан бит-төрки» («Төркичә Гөлстан») дип исем бирә. Әсәрнең буеннан-буена сузылган сюжеты юк. Ул вак-вак хикәятләрдән төзелгән. Бу хикәятләрнең күбесендә «Йосыф кыйссасы»ндагы яхшыга — бүләк, яманга — җәза төзелеше сакланган. Күбесендә сүз шәфкатьлелек, игелеклелек турында бара. Ләкин әсәрдә фарсы әдәбиятында киң кулланыш алган үткен, гыйбрәтле сүз — хикмәт белән дә очрашабыз. «Гөлстан»да **хикмәт — акыл уены, әз генә әйтеп бетерелмәгән, ләкин уйлап табарга мөмкин булган гыйбрәтле фикер (гыйбарә).**

«Гөлстан бит-төрки»дәге хикмәтләрнең берсендә, мәсәлән, патшаның икесе озын, берсе карсак буйлы өч улы була. Көн-

[1] *Тун* — кием-салым.

нәрнең берендә патша карсак улына кызганып күз ташлагач, улы әтисенә: «И ата, озын буйлы ахмактан кыска буйлы акыл яхшырак»,— ди һәм тәгъбирен тиздән сугышта исбат итә.

Сугышта күп санлы дошманны җиңгән кыска буйлы егет «озын буйлы ахмактан кыска, ләкин акыллы кеше яхшырак», дими, «кыска буйлы акыл яхшырак», ди. Габдулла Тукайның «Күгәрчен» шигырен исегезгә төшерсәгез, мондый каршылыкка корылган хикмәт төзелешенең татар әдәбиятында берничә гасырдан соң да тулы хокуклы хикмәт булып калуын күрерсез.

Икенче бер хикәяттә патша үзенең колы белән көймәдә йөрергә чыга. Колы диңгез күрмәгән кеше икән: курка, калтырана башлый. Бу хәлне күреп, көймәдәге акыл иясе, хуҗадан рөхсәт сорап, колны суга ташлый һәм бераздан чәченнән тартып чыгара. «Монда хикмәт ни?» — дип сорый патша. «Көймәнең файдасын белгән кеше генә көймәдән курыкмый, бу эшнең хикмәте шул»,— дип җавап бирә хаким кеше.

Хикәятләрдәге хикмәтләрнең икесе дә бәхәссез хакыйкать рәвешендә әйтелә. Икесендә дә тыңлаган кешегә колак салу өчен гыйбрәт бар, икесе дә каршылыкка корылган. Шуның белән бергә, хикмәтләрнең икесе дә эчләрендәге фикерләрен әйтеп бетермиләр. Икесе дә башка вакыйгаларга да бәя булып килә алалар.

Сәйф Сараиның үзе иҗат иткән әсәрләре дә күп. Бу әсәрләр, башлыча, мәхәббәт матурлыгын сурәтләүгә багышлана. Ул, болгар әдәбиятында беренчеләрдән булып, мәхәббәт матурлыгын дастан кебек күләмле әсәрнең төп темасы итеп ала.

Нәтиҗә ясыйк. Сез танышкан әсәрләрнең барысында да шәфкатьлелек темасы үзәк тема буларак кабатлана. Барысының да сюжетларында яхшыга — бүләк, яманга — җәза бәйләнешләрен очратабыз. Әдипләрнең барысы да арттыру алымын яратып куллана. Борынгы әдәбият тормыш матурлыгын үзкыйммәт дәрәҗәсенә күтәрә.

XIV—XV ГАСЫРЛАРДА ИҖАТ ИТЕЛГӘН ӘСӘРЛӘР

ТАРИХИ ШАРТЛАР. МӘДӘНИ МОХИТ

Безнең борынгы бабайлар баскыннар изүенә риза булып яшәмиләр. Әледән-әле дошманнарына каршы көрәшкә күтәреләләр. Батырларны бастырырга монголларның иң танылган гаскәр башлыгы Субудай баһадирны җибәрәләр. Ләкин монголлар китү белән, болгарлар тагын баш күтәрәләр. Ирек сөюче, курку белмәс болгарлардан Батый хан курыккан булса кирәк, күп санлы гаскәре белән үзе килә.

Болгарлар бик эшчән дә булганнар. Дошманнары җимереп киткән саен, шәһәрләрен кабат төзегәннәр, күп итеп иген иккәннәр. Игенне күрше-күләнгә дә, башка илләргә дә сатканнар. Бу кыю, горур халыкның көчәеп китүе монгол баскыннарына бер дә ошамый. 1360 елда Булат Тимер хан Болгар шәһәрен җимереп, җитәкчеләрен, галимнәрен, язучыларын үтереп китә. Егерме елдан соң Туктамыш хан талап китә, ә тагын утыз ел үткәч, Туктамыш ханга каршы сугышканда, болгарларны Аксак Тимер яулап ала. 1431 елда сугышлардан, талашлардан хәлсезләнеп калган халыкка рус князе Федор һөҗүм итә һәм Болгар шәһәрен җимерә.

Бу елларда болгар халкы үзенең сәнгатен дә, илен дә дошманнан саклау эшенә җигә. Батырлар турында күп санлы дастаннар һәм әкиятләр иҗат итә. Халык авыз иҗатының бу әсәрләрендә баһадирлар дошман гаскәрен кырып салалар. Әкият батырлары әллә ничә башлы диюләрне җиңәләр. Баһадирлар турындагы дастаннар һәм әкиятләр аз санлы халыкның рухын көчле дошманга каршы торырлык итеп тәрбияләгәннәр.

Монгол ханнары Сарай шәһәренә танылган әдипләрне җыя торган булганнар. Сарайда болгар әдипләре дә иҗат иткәннәр. Сарайдагы власть өчен көрәшне алар үз күзләре белән күреп торганнар. Бу көрәшнең аеруча гыйбрәтлесе Туктамыш хан белән гаскәр башлыгы Идегәй арасында була. «Идегәй» дастанының авторы билгесез. Аны Сарайдагы Болгар әдипләренең берсе яза ала. Галимнәр дастанны болгар халкы иҗат иткән

дип тә исәплиләр. Алай да «Идегәй» дастанын Идегәйнең үз халкы — нугайлар иҗат иткән булырга тиеш. Дастанда вакыйгалар агышын, «Йосыф кыйссасы»ндагы шикелле, Алла билгеләми. Вакыйгалар персонажларның ихтыяр көче һәм үз теләкләре белән туалар. Әсәрнең бу үзенчәлеге дә авторы мәҗүси нугай халкы булуы турында сөйли.

Ничек кенә булмасын, бу бөек әсәр татар әдәбияты үсешенә зур өлеш кертә. Аның эчтәлеге бүгенге көн өчен дә актуаль, ә сәнгатьчә эшләнеше ягыннан ул һәрвакыт үрнәк булачак.

ИДЕГӘЙ[1]

I

Туктамыш хан белән Шаһ Тимер низагы һәм Котлыкыя бинең үлемгә хөкем ителгәне

Сәмәрканд әмире Аксак Тимер Туктамыш ханга хат яза. Хатында ханнан тирә-юньдә дан тоткан Төкле Аяк исемле ау лачынын бүләк итүен сорый. Хан белән әмир — кайчандыр дус булып, хәзер дошманлашкан кешеләр. Хатны укыгач, Туктамышның ачуы чыга. Җавап хатында ул үзе кебек үк тәкәббер әмирне мыскыл итә һәм үтенечен кире кага. Яз җиткәч, хан ауга чыгарга әзерләнә. Кош караучы Котлыкыяны (Идегәйнең әтисен) чакырта һәм Төкле Аякның балаларын кертергә куша. Лачыннарны кулына утырта, берсен тургайга, берсен үрдәккә очыртмакчы була. Ләкин кошлар ау лачыннары булып чыкмый. Туктамыш ханның ачуы эченә сыймый. Кош караучысына ул мондый сүзләр әйтә:

— Сәмәркандта утырган
Әмир Бырлас Шаһ Тимер;
Аргы утырган ул булса,
Бирге утырган мин булсам,
«Кара лачын Төкле Аяк
Тугыз йортка[2] дан булса,
Аны миңа тапшыргыл»,— дип,
Боерып торган ул булса,
Аның телен алмаган[3]
Туктамыш хан мин булсам,

[1] Әсәр кыскартып алынды. Төшеп калган өлешләренең эчтәлеге бирелде.
[2] *Йорт* — ил.
[3] *Телен алмау* — сүз тыңламау.

Ау лачыным караган
Котлыкыя син булсаң,
Салган ике йомыркасын
Оядан алган да син икән!
Кош бидаяк[1] йомыркасын
Ояга салган да син икән!
Лачынымның токымын
Шаһ Тимергә биргән дә син икән!
Аягы төксез бидаяк —
Аны да булса күтәреп,
Минем каршыма килгән дә
Син икән, әй, син икән!
Җавабың бир, Котлыка!
Туктамыш хан янә әйтер:
— И Котлыка, Котлыка!
Шаһ Тимер суккан сум алтын,
Сум алтынга сатылдың!
Бер башыңны ике иттең,
Ике ханга баш ордың,
Җавабың бир, Котлыка!
Котлыка би әйтте:
— Әй ханиям, ханиям,
Кас[2] дошманың Шаһ Тимер,
Шаһ Тимергә сатылсам,
Бер башымны ике итсәм,
Ике ханга баш орсам, —
Сездән дәүләт киткәне,
Бездән ырыс[3] киткәне.
Башыбызга килгән уртак көн —
Ул шул икән, ханым әй,
Ул шул икән, ханым әй!

Туктамыш хан Котлыкыядан «Сездән дәүләт киткәне, Бездән ырыс киткәне» сүзләренең мәгънәсен аңлатырга куша. Котлыкыя карышмый: син хан булып алгач, ил бөлде, хәзер калага сәүдәгәрләр дә йөрми башлады — синнән дәүләт китте. Илнең абруе бетүе — минем бәхетем китүе, ди.

---

[1] *Бидаяк* — карчыга.
[2] *Кас* — явыз ниятле.
[3] *Ырыс* — бәхет.

Бер башымны ике итеп,
Ике ханга баш орсам,
Ул да булса, ханиям,
Йорттан абруй киткәне,
Чабучы булсаң, баш — минә!
Түгүче булсаң, кан — минә!

Аны әйтеп Котлыкыя
Хан алдына йөгенде[1].
Туктамыш хан анда әйтте:
— Һай син, татар, һай татар,
Син дә кичә бар булдың,
Син дә бүген юк булдың!
Бүген килеп син дә бер
Үлем белән тиң булдың —
Токымыңны ораен!

Азамат[2] ир Туктамыш
Ике биен чакырды:
Чакмагыш би, Дөрмән би
Анда килеп баш орды.
Туктамыш хан анда әйтте:
— Әй Дөрмән би, Дөрмән би,
Айбалтаңны тот,— диде.—
Айпычагың так,— диде.—
Котлыкыя ялган бине
Муйнын ора чап! — диде.—
Пәридән алган хатыны,
Бишектә ятыр баласы;
Ул баланы тап! — диде.—
Бишеген ора чап! — диде.—
Син дә булсаң, Чакмагыш,
Чакма чаккан Чакмагыш,
Котлыкыя ялган бинең
Чаңырагын[3] чап,— диде.—
Чабып утка як! — диде.

Шунда торган Җантимер —
Киң кунычлы Җантимер —

---

[1] *Йөгенде* — баш иде.
[2] *Азамат* — 20—30 яшьлек ир.
[3] *Чаңырагын* — киез өйнең түбә алкасын.

Алты угыллы ир иде;
Атагы — өлкән аталык[1],
Йортта өлкән пир[2] иде.
Туктамышның кашында
Киңәше киң, килбәтле,
Сүзе үткен би иде;
Котлыкыя би белән,
Кан тамызып ак сөткә,
Ант эчешкән ир иде.

Торып килеп Җантимер,
Хан алдында йөгенде:
— Әй ханиям, ханиям,
Кол язарда[3] би кичәр,
Би язарда хан кичәр,
Аталыгым хакына
Хаталыгын кич,— диде.—
Аталыгым хакына
Хаталыгын кичмәсәң,
Бишектә яткан баласы —
Бер кашык каның кич,— диде,—
Буында типкән кан калсын,
Баладан кулың тарт,— диде,—
Канынннан аның кайт! — диде.

Туктамыштай олы хан
Аның телен алмады,
Сүзенә колак салмады.
Котлыкайны тоттырды,
Кулына кыл-җеп тактырды,
Чапкылыкка[4] мендереп,
Чүң[5] бүкәнгә чүктереп,
Айбалталы Дөрмән бидән
Анда башын чаптырды.

---

[1] *Аталык* — хан балаларын тәрбия итүче.
[2] *Пир* — изге кеше.
[3] *Язу* — ялгышу.
[4] *Чапкылык* — баш чабу урыны.
[5] *Чүң* — зур.

Җантимернең алты угыл,
Алтынчы угыл — Кобогыл,
Алып килеп ул аны
Котлыкыя өенә,
Салып куеп бишеккә,
Котлыкыя баласын
Киң кунычлы Җантимер,
Кунычында яшереп,
Үз өенә китерде.
Котлыкыя өенә
Анда Дөрмән би килде:
— Син дөньяда йөргәнче,
Хан боерыгы йөрсен, дип,
Хан боерыгы йөргәндә,
Атаңа җиткән айбалта
Инде сиңа җитсен, дип,
Кыл муеныңнан үтсен, дип,
Кобогылга кул салды.
Анда килеп Чакмагыш,
Чаңырагын сындырып,
Чакма чагып үрт салды[1].
Хан боерыгы үтмәде,
Хан боерыгы үткәндә,
Тәңредән узып китмәде —
Атага җиткән айбалта
Баласына җитмәде.
Балтасы чабып чапмады,
Кыл муеныннан үтмәде,
Ул үләсен бу үлде,
Ханның әйткән сүзе үлде.
Берәве үлде, берәү калды —
Тәңре хөкеме бу иде.
Ул баланы Җантимер,
Итегемнән алдым, дип,
Итегемнән алганда
Илсез-көнсез калдың, дип,
Атын куйды Идегәй.

---

[1] *Үрт салу* — яндыру.

II

Идегәйнең, Кобогыл исемендә үсеп, Туктамыш хан сараенда түрә булганы

Җантимернең алты угыл,
Алтынчы угыл — Кобогыл,
Кобогыл дип беленеп
Үсә куйды Идегәй.
Уникегә җиткәндә
Алпамыштай ир булды.

«Ир булган соң җир булыйм,
Иңсәм җиргә тисен, дип,
Ил игелегем күрсен, дип,
Асыраган чал бабам —
Ул игелегем күрсен»,— дип,
Тауда ятты, тай бакты,
Кырда ятты, куй бакты,
Елкы бакты — кол булды,
Кигәне ямау тун булды.
Идегәй андый ир булды:
Аты юкка — ат булды,
Чүлләгәнгә[1] — су булды,
Адашканга — юл булды,
Ялгызга — ясак[2],
Җәяүгә — таяк ул булды.
Унбишенә килгәндә,
Туксан башлы Урданың
Туксан углы бер булып
Айдалага[3] килгәндә,
Алар белән ант тотты.
«Көрәшеп барыңны мин ексам,
Мин барыңа баш,— диде.—
Көрәшеп берең мине екса,
Улыгыз[4] миңа баш»,— диде.

---

[1] *Чүлләгәнгә* — сусаганга.
[2] *Ясак* — ярдәм.
[3] *Айдала* — ачык җир. Киң дала.
[4] *Улыгыз* — шул кешегез.

Барын екты Идегәй;
Еккан береннән тун[1] алып,
Айдалага өйдерде.
Өеп салып Идегәй,
Өстенә менеп тайчанды.
— Туктамыш хан тәхетенә
Мин мендем! — дип яр салды.
Аннан әйтте Идегәй:
— Анау килгән ак атлы —
Ул Туктамыш хан булса,
Алдында баш имәгез,
Үзе сәлам бирмәсә,
Башлап сәлам бирмәгез.

Азамат ир Туктамыш
Килә җитеп килгәндә,
Ул туксан бер тик торды,
Торып бер баш имәде,
Иңкәеп сәлам бирмәде.

Туктамыштай олы хан,
Анда торып, моны әйтте:
— Ханыгыз булган минме өлкән,
Әллә юкса сезме өлкән?

Анда әйтте Идегәй:
— Башта булсаң син өлкән,
Аякта[2] чыгар без өлкән.
Әйтеп бирсәм ник өлкән —
Туксан башлы Урданың
Янымда туксан баласы,
Шушы туксан баланың
Яшен санап салсам мин,
Анда чыгар без өлкән.
Өлкәнне өлкән белмәгән,
Башлап сәлам бирмәгән
Ул да булса, ханиям,
Син икән, әй син икән!

---

[1] *Тун* — кием.
[2] *Аякта* — азакта.

Азамат ир Туктамыш
Анда уңга әйләнде,
Анда сулга әйләнде,
Әйләнеп җавап тапмады.
Айбалталы Дөрмән би,
Дөрмән улы Урман би —
Туксан бала эчендә
Каракчылык кылган би:
Өч урлады — котылды,
Дүртенчедә тотылды.
«Түрәсен моның бир»[1],— диеп,
Айдаланың туксан бала
Кулын килеп кушырды.
Урман бинең кашына
Торып килеп Идегәй,
Кулдан кылын тоттырды,
Салкын ташка тарттырды,
Туксанның берен җәллад итеп,
Анда башын чаптырды.

Идегәйнең этисен җәзалаган Дөрмән би ханга зарлана. Улы Урманны үтерүчене җәзага тартуын үтенә. Идегәйне сарайга чакыралар. «Урманның башын ник чаптың?»— дип сорый аңардан хан.

Анда әйтте Идегәй:
— Илендә йөргән каракчы
Өч ат урлап котылса,
Дүртенчедә тотылса,
Синең түрәң буенча,
Дүртенчедә чабылса,
Дөрмән улы Урман би —
Ул да шулай тотылды,
Синең хөкемең буенча
Ул да шулай чабылды,
Аның аргысын мин белмәм.
Туктамыш торып анда әйтте:
— Әй Дөрмән би, Дөрмән би,
Шушы торган Кобогыл
Туксан бала эчендә
Бәйге тотып дан алган,

[1] *Түрәсен моның бир* — хөкем ит.

Туксанына баш булган,
Түрәсен биреп фаш булган,
Ул ни кылса рас кылган,
Кобогылдай баланың
Түрәсенә чыгалмам.

Кобогылга аны әйтте:
— Әй Кобогыл, Кобогыл,
Сараемда кал,— диде.

Хан Идегәйгә асыл кием, кыйммәтле корал, яхшы ат бүләк итә. Егет сарайда кала. Бүләкләрне кабул итә. Хан тәкъдиме белән Айтулы исемле чибәр кызга өйләнә. Хан Идегәйне гаскәр башлыгы итә. Шуннан соң дәүләт «яу белән даудан котыла». Ил казнасы байый. Вакыт үтә. Ханәше (Туктамыш хатыны) Йәникә Кадыйрбирде исемле малай, берсеннән-берсе чибәр Ханәкә һәм Көнәкә исемле игезәк кыз таба. Шул ук вакытта Айтулы да малай таба. Аңа Норадын дип исем кушалар. Бу шатлыктан хан да, Идегәй дә зур мәҗлес оештыралар.

III

Туктамыш ханның, Идегәйдән шикләнеп, аны эзәрләгәне һәм кемлеген биләреннән сорашканы

Хан ханәше Йәникә ирен Идегәйгә каршы котырта. Көтүче башы белән, хан туена тиң итеп, бала туе үткәрде, хан байрагы күтәреп, җиңүләр яулады. Ул хәзер башкалар күзендә ханның үзеннән дә өстен, ди. Хан хатынының сүзләре белән килешми, ләкин киңәшенә күнә. Идегәйгә агу салып эчемлек бирәләр. Балны эчкәнче пычагы белән болгатса — дошманлыгын күрсәтер, сабы белән болгатса — дус булуын күрсәтер, дип сынамакчы булалар. Идегәй балны пычагының очы белән болгата. Ләкин хан шуннан соң да гаскәр башлыгын яклый:

— Ян йөрәкне яндырып,
Ялганлама син, ханәш,
Сум йөрәкне сулкытып,
Сумгыллама син, ханәш!
Яхшы ата Җантимер
Җандай күргән ир иде,
Яу да түгел — ил иде,
Аннан туган Кобогыл —
Ул да миңа яу булмас,
Дау бетереп яу кырган
Кобогыл миңа дау булмас.

Өрәге миннән каты булса да,
Кобогыл миңа үч булмас,
Синең дигән һич булмас!

Эш болай да барып чыкмавын күргәч, Йәникә Идегәй турында Сарай биләреннән (түрәләреннән) сорарга куша. Биләр берни дә әйтә алмыйлар. Ханның якын киңәшчесе Киң Җанбай йөз туксан биш яшьлек Субра карттан сорарга тәкъдим итә.

IV

Туктамыш ханның, Субраны җырлатып, Идегәйне сынаганы

Субра картны олылап каршылыйлар. Ул, Идегәйгә карап, болай ди:

Кашларына карасам,
Каләмнән пәйда булгандай;
Күзләренә карасам,
Күгеннән пәйда булгандай;
Каршыннан торып карасам,
Каһәрдән пәйда булгандай;
Буйларына карасам,
Нурдан пәйда булгандай!

Сынау карашыннан туган нәтиҗәсен Туктамыш ханга әйтә:

Алтыннан суккан Ак урдаң
Көмештән суккан ак ишек,
Төшсә тимер чукмары,
Ишегеңне ачар ул;
Кашыклап җыйган малыңны
Чүмечләп чәчеп бетәр ул.
Бар урдаңны алыр ул.
Тәхетеңә бау салыр ул,
Кола чәчең агартып,
Ике күзең кызартып,
Картайганда илеңнән
Сөрән салып куар ул;
Инде мин кеше танымам,
Әгәр кеше танысам,
Котлыкыя би улы
Идегәй ул — Кобогыл!..

V

Идегәйнең Туктамыш хан табыныннан Аксак Тимергә качып киткәне

Анда табын шау килде.
Хан уңыннан утырып,
Хан ханәше Йәникә
Туктамышка аны әйтте:
— Идегәй Котлыкыя улы булганда,
Башы моннан чыкмасын,
Биләр тоткан ак пычак
Би кулыннан төшмәсен!
Ирене юка сараяк[1]
Бер аякны баллап бир,
Бер аякны агулап бир!

Хан белән ханәшенең мәкерле ниятләрен сакчы Тыңгысын Идегәйгә җиткерә һәм, урамга чыгып, бәйдә торган атларның ияр бауларын кисә, Идегәй атын юлга чыгарып куя.

Аңгысын аңдып ни әйтсә,
Аны белде Идегәй.
Елкылдаган ак пычак
Биләрнең җиң очында
Чыгып кайтып тора икән,
Аны күрде Идегәй.
Агулап салган сары бал
Җанбай тотып килгәндә,
— Хан саркытын[2] эч! — диеп,
Идегәйгә биргәндә,
Агу салган сараяк
Борынына килеп тигәндә,
— Ай, борынымны кан кылдың! — дип,
Борынын басып Идегәй,
Бусагадан атлады.
Тим Чуарның янбашы
Җиргә ятып бер тиде.
Әйләнеп карап күргәндә,
Идегәй инде юк иде.

---

[1] *Сараяк* — савыт.
[2] *Саркыт* — хан авыз иткән эчемлек.

Азамат ир Туктамыш,
Гайрәтеннән бузарып[1],
Тугыз иргә аны әйтте:
— Әй тугыз ир, тугыз ир!
Җанбай белән бара күр!
Алдап-йолдап Идегәйне
Үз кашыңа ала күр!
Алдап-йолдап кашыңа ал!
Кашыңа ал да башын ал!

Идел кичеп Идегәй,
Бер тел алып китим[2], дип,
Бер байтирәк төбенә
Иярен салып төшәнде.
Идегәй анда ятканда
Җантимернең биш улы
Аңа килеп кушылды.

Анда килеп Киң Җанбай,
Идел аша һайкарып[3],
Идегәйне чакырып,
Тулгай биреп[4] аны әйтте:
— Әй Идегәй, Идегәй,
Юк гоманга син чумган,
Туктамыштай олы хан —
Аңа каршы кем торган?
Яуларың аз тотылырсың,
Чебен җанлы атаңдай,
Канлы күз яшь коярсың!
Кайт, Идегәй, кайтсана!
Көчле илгә син яу ачтың,
Батыр булып алга бастың,
Батырлыгың күрсәт, мордар,
Суны үтеп нигә качтың?

Җанбай, Идегәйне кулга төшерү өчен, әле бер, әле икенче хәйлә уйлап таба: куркыта, байлык, хакимият, хәтта хан кызларының берсен вәгъдә итә. Идегәйнең җавабы мондый:

---

[1] *Бузарып* — бүртенеп.
[2] *Тел алып китим* — ял итим.
[3] *Һайкарып* — кычкырып.
[4] *Тулгай биреп* — ялына төшеп.

— Атаң кара кеше иде,
Мал биргәннең колы иде,
Анаң кара кеше иде,
Аш биргәннең күңе[1] иде,
Син дә шундый кешесең:
Аш биргәннең колысың,
Мал биргәннең улысың!
Бу киткәннән китмәсәм,
Киң чүлләрне үтмәсәм,
Кырык түбәгә[2] кырык басып,
Яу булып килеп җитмәсәм;
Угланнарны сатуга
Бер чигәрә[3] куймасам,
Кырык көнлек юлына,
Кырык көнлек чүленә,
Кырык кое каздырып,
Кырык йорт-ям[4] салмасам,
Әйткәнемне кылмасам,
Мин үчемне алмасам,
Баба Төкләс бабам биргән
Идегәй атым корысын!

VI

Идегәйнең, юлда Кара Тиен Алып белән сугышып, Аксак Тимер кызы Акбеләкне һәм кырык колны коткарганы

Идегәйгә тагын унике сугышчы кушыла. Алар Сәмәрканд ягына карап юл тоталар. Юлда Идегәй, Кара Тиен Алыпны җиңеп, кырык кол һәм Аксак Тимернең Акбеләк исемле кызын коткара. Үләр алдыннан Алып болай ди:

— Китмә, китмә, Идегәй:
Ике туган пәри кыз,
Апасыннан мин тусам,
Сеңлесеннән син туган!
Мин дә мин дип масайма,
Син дә тудың пәридән,
Мин дә тудым пәридән —

---

[1] *Күңе* — колы.
[2] *Түбә* — өлкә.
[3] *Чигәрә* — чик.
[4] *Йорт-ям* — почта. Ат алыштыру урыны.

Агаңны атып үтердең,
Белми китмә, Идегәй!
Ана сөтен туя имсәң
Булыр идең миребан[1],
Баурың[2] каты ялралдың,
Илне[3] белми үтердең,
Белсәң, агаң мин идем,
Ялгыз калдың, Идегәй!
Туганда кара туганны
Сабынлап юсаң агармас.
Туганда кыек туганны
Тубыкка салсаң турАймас;
Туктамыштан җек күреп,
Шаһ Тимергә барсаң да,
Ул да сиңа тураймас!
Йортыңны талап кан эчеп,
Токымыңны кол итеп,
Йортың йорттан күчереп,
Илеңне[4] җирдән аерып,
Үз кулың белән кол итеп,
Мең хәйләгә юл итәр,
Ул да синдәй[5] була алмас!
Аны да белеп кит, Идегәй!

VII

Идегәйнең Акбеләк кыз белән Аксак Тимергә барганы

Аксак Тимер кунакны шатланып кабул итә. Кызын коткарган өчен рәхмәтләр әйтә. Аның кем булуын сорый. Җавабында Идегәй мондый сүзләр әйтә:

— Үз атамны сорасаң,
Котлыкыя би иде,
Туктамыш хан чапканда,
Ул атамнан аерылдым.

---

[1] *Миребан* — миһербанлы.
[2] *Баурың* — күңелең.
[3] *Илне* — бу урында: минем сиңа дошман булмавымны.
[4] *Илеңне* — халкыңны.
[5] *Синдәй* — син әйткәнчә.

Идел эче имин йорт —
Иделемнән аерылдым,
Үз илемнән аерылдым.
Инде кабул күрмәсәң,
Кайлардан кая китием?
Арбакаш[1] булып су ташып,
Әүкатемне итием[2].

Анда әйтте Шаһ Тимер:
— Синдәй ирне санламый,
Туктамыштай каба[3] хан
Үзе миңа биргәндә,
Үз янымда кал,— диде.—
Ак беләктәй кызымны
Коткарып калган син икән —
Аны да сиңа бирием,
Кабул күреп ал,— диде.

Анда торып Идегәй,
Шаһ Тимер ни бирсә, аны алды.
Идегәй анда би булды,
Шаһ Тимер аңа ил булды,
Әмма Идегәй үзе кем? —
Анысын белмәс ир булды.

VIII

Туктамыш ханның Норадынны мәсхәрәләп сөргәне

Ул араның эчендә
Үсә бирде Норадын,
Бүз угланнар[4] янында
Йөрә бирде Норадын,
Токымы Чыңгыз угланнар
Норадынны күргәндә,
Буйларын басып буй үскән
Ир буласын белгәндә,
Ачуыннан агарып,
Көнчелектән күгәреп,

---

[1] *Арбакаш* — арба йөртүче.
[2] *Әүкатемне итием* — тамагымны туйдырам.
[3] *Каба* — тупас, кара.
[4] *Угланнар* — җиткән егетләр.

Йәникә ханәш сүз салды:
— Ханыбыздан баш тартып,
Казак киткән[1] Идегәй —
Аның улы Норадын
Арабызда көн итә:
Ханәкәгә кул сала,
Хан ыруын тиң итә;
Туктамыштай зур ханнан
Бабамның канын алсам, дип,
Атамның үчен алсам, дип,
Урынына хан булсам, дип.

Азамат ир Туктамыш
Норадынны чакыртты,
Чакыртып алып янә әйтте:
— Бай баласы байга охшар,
Би баласы бигә охшар,
Балабан шоңкар[2] кошка охшар;
Идегәй, миннән баш тартып,
Шаһ Тимергә киткәндә,
Аннан калган Норадын —
Аның көне кемгә охшар?
Анда әйтте Норадын:
— Әй ханиям, ханиям!
Бай баласы байга охшар;
Би баласы бигә охшар,
Туктамыш хан барында
Җисер[3] хатын, ятим ул,
Аксак, гарип, ярлы, кол —
Аларның көне кемгә охшар?
Йортны бозды йорт биең,
Илне бозды ил биең,
Бозгынлыкта калган ил —
Аның көне кемгә охшар?
Кичәге киткән атамның
Менгәне — кеше аты икән,
Сауганы — кеше биясе,
Җиккәне — кеше дөясе.

---

[1] *Казак киткән* — качып киткән.
[2] *Балабан шоңкар* — лачынның бер төре.
[3] *Җисер* — тол.

Аның көне кемгә охшар?
Көнем сиңа төшкәндә,
Минем көнем кемгә охшар?

Норадын алай дигәндә,
Туктамыштай олы хан
Ике утырды, бер торды;
Янына алып Җанбайны,
Анда киңәш-уй корды:
— Котлыкыя би икән —
Аның башын чапканда,
Идегәйне чабып чабалмый,
Бер башыма бәла алдым;
Кобогыл дип белгәнем —
Ул Идегәй булганда,
Җитеп башын алыйм, дип,
Үз башыма яу алдым.
Идегәйнең ир углы
Инде калды Норадын,
Норадыннан куркамын.
Җанбай анда моны әйтте:
— Норадынга кул салсаң,
Идегәй сиңа яу булыр;
Норадын башын буш куйсаң,
Үз башыңа дау булыр,
Аның башын алмагын,
Йортында да тотмагын,
Атаңа миннән кит, диеп,
Исән-аман җит, диеп,
Җабага тайга мендереп,
Чүл-далага озаткыл;
Сау калса — үзеннән,
Сау калмаса, синнән калмыйдыр.
Туктамыш хан анда әйтте:
— Атың арык, үзең яшь,
Ерак йортка җиләсең,
Атаңа барып җиткәндә
Бездән сәлам диярсең!
Кузгалып китте Норадын,
Чыгып китте каладан.
Тибенгесен бер тибеп,

Саурыга камчы органда
Алып качты ябага.
Өч көн үткән арада,
Дүртенче көн булганда —
Идегәй менгән Тим Чуарның
Токымы икән бу Сарала[1]!

IX

Норадынның атасына килгәне, Идегәйнең Аксак Тимер белән берлектә Туктамыш хан өстенә йөргәне

Азамат ир Идегәй
Норадынны күргәндә:
— Норадын углым, синме? — дип
Атыла килеп алдына,
Күзләреннән үбеп улының,
Маңлаеннан искәп сөйгәндә:
Хәл сорашып белгәндә,
Норадынның ат-тунын,
Бар шайманын[2] күргәндә,
Туктамышның нияте
Ни булганын аңлады.
Норадынга өй бирде,
Айлар-көннәр үткәчтән,
Норадынны чакыртып,
— Газизем, сөйлә,— дигәндә,
Ир Норадын аны әйтте:
— Ат сөренми җир танымас,
Ир сөренми ил танымас,
Иделдәй илем барында
Шаһ Тимер иле тартмыйдыр,
Һич күңелемә ятмыйдыр,
Таңы таң булып атмыйдыр,
Суы су булып акмыйдыр,
Туктамышта кигем[3] бар,
Кик алганда кинә[4] юк,
Үч алганда үпкә юк;

---

[1] *Сарала* — нәселле ат.
[2] *Шайманын* — кыяфәтен.
[3] *Кигем* — үчем.
[4] *Кинә* — гаеп.

И газизем, и атам,
Каерылып атны тартаек,
Ана Иделгә кайтаек,
Идел багында ятаек.
Ул Туктамыш хан икән,
Ук-садак билдә булганда,
Угыбызны анда атаек,
Ата-ата ятаек!

Анда әйтте Идегәй:
— Әй Норадын, Норадын,
Сагынсам да илемне,
Санласам да санымны,
Туктамыштай бер ханны
Хан итеп белгән ул илгә
Янә бер кире кайтмыймын.

Анда әйтте Норадын:
— Әй газизем, әйт, атам,
Иделдәге иләңнән
Халкы ханнан өркә инде,
Татарың белән нугаең
Ханга каршы купты инде,
Идегәй безгә кайтсын, дип,
Башыбызда торсын, дип,
Сөт белән юган кылычын
Кан белән янә юсын, дип,
Болгариның Бодай би
Артымнан куа җитеп әйтте инде.
Анда әйтте Идегәй:
— Газизем, асыл икәнсең,
Рас сөйләрсең, морза улым.
Анда килеп Идегәй,
Шаһ Тимергә сүз салды:
— Иләңдә артык калалмам,
Рөхсәт боер, әй әмир,
Иделгә кире кайтаем,
Халкым җыеп алаем,
Туктамышның өстенә
Туп туплап ук бараем;
Угымны анда атаем,
Ата биреп ятаем.

Әмир Бырлас Шаһ Тимер
Идегәйгә аны әйтте:
— Туйгуҗа улы Туктамыш,
Әзәлдән[1] сиңа яу икән,
Әзәлдән миңа яу булды.
Кайта чапсам[2], көн килде,
Синдәй ирем барында
Ул көн миңа бер килде.
Шул Туктамыш өстенә
Кыргын[3] җыеп бараем,
Әзәлдән килгән кигемне
Туктамыштан алаем.
Кыргын юлга юнәлде.

Боларып яткан күлләрнең
Балыгын алды дулатып,
Сыланып яткан суларның
Суларын эчте болгатып.

Җаектан ашу Актүбә,
Актүбәгә менгәндә,
Идел-йортын күргәндә,
Туфрагын үбеп ярсулап,
Идегәй анда тулгады:
— И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт —
Иелеп тәзем кылган[4] йорт;
Анам килен булган йорт —
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт,
Бия сауган сөтле йорт,
Кымыз эчкән котлы йорт;
Агачы айбар[5] күренгән,
Маллары суга иелгән,

[1] *Әзәлдән* — мәңгелек.
[2] *Кайта чапсам* — ниһаять.
[3] *Кыргын* — гаскәр.
[4] *Тәзем кылу* — олылау.
[5] *Айбар* — биек.

Яфраклары калкадай,
Ботагы көмеш алкадай,
Алмасы бар йөрәктәй,
Балтырганы беләктәй,
Син түгелме туган йорт,
Ач тамагым туйган йорт.
Хан Туктамыш кулында
Син ни булдың, туган йорт?

Идегәй килде дигәндә,
Идел-йорттан кот китте.
Кәмалнең улы Киң Җанбай
Киңәшен биреп килгәндә
Туктамышка аны әйтте:
— Идегәй андый ир иде —
Үзеннән бер яшь олыга:
«Без тораек, газизем,
Сез белерсез»,— дир иде;
Үзеннән бер яшь кечегә:
«Син тора тор, газизем,
Без белербез»,— дир иде.
Идегәйнең остазы
Пир Галәттин ир иде,
Пирдән узып эш кылмас,
Пирен аңа күндерик,
Җаекка килеп ятканда
Явын кире дүндерик,
Ул тоткарлап торганда
Урда корып торыек!

Мулладан мулла иартеп,
Пир Галәттин килгәндә,
Идегәй бик сәламләп,
Кулыннан үбеп каршы алды.
Куй симезен суйдырып,
Тугыз төрле аш биреп,
Хезмәтендә кол булды.
Пир Галәттин анда әйтте:
— Илләштермәк — илчедән,
Яулаштырмак — яучыдан;
Каерылып атың тарт, балам,
Бу сәфәрдән кайт, балам;

Бу сәфәрдән кайтмасаң,
Әүвәлгедәй ил булып,
Туктамышка би булып,
Ак сарайга кайт, балам!

Анда әйтте Идегәй:
— Илләштергән — илчедән,
Яулаштырмак — яучыдан —
Яхшы әйттең остазым!
Йортым йорттан күчереп,
Котлыкыя атамны
Чүң бүкәнгә чүктереп,
Туктамыш хан чапканда,
Пирем, анда кайда идең?

Алты угыллы Җантимер —
Ул да синдәй пир иде.
Атамны җолып ул торды,
Мине җолып ул торды,
Менә ул карт пир иде.
Мин биләүдә ятканда,
Туктамыш мине чапканда,
Гөнаһсыз сабый баланың
Бишектә каны акканда,
Пирем, анда кайда идең?

Идел белән Җаектан,
Татарның тулы йортыннан,
Байтак яу куган җиремнән
Туктамыш хан мине куганда,
Пирем, анда кайда идең?
Каерылып атың тарт, пирем,
Бу сәфәрдән кайт, пирем!

Аны әйтеп Идегәй,
Остазын кире җибәрде.
Тора килеп урыныннан,
Шаһ Тимергә аны әйтте:
— Идел белән Җаектан,
Нократ белән Чулманнан,
Әзгәри суккан Болгардан,
Халыгым кубып килгәндә,
Каршы барып алаем;

Син кузгалып чапканда,
Туктамышны басканда,
Мин дә бер сугып багаем,
Багымны[1] сынап караем,
Рөхсәт биргел, әй әмир!

Аны әйтеп Идегәй,
Углын алып уңына,
Кырык ирен алып сулына,
Төнгә карый юнәлде.

X

Аксак Тимернең Туктамыш хан белән орыш башлап хур булганы

Пир Галәттин кайтканда,
Идегәйнең җавабын
Туктамышка әйткәндә,
Туктамыштай олы хан
Урдасына яр[2] салды,
Ул да атланды каладан,
Бу да атланды каладан.

Әмир Бырлас Шаһ Тимер
Туктамышның хәлен күргәндә,
Хәйләгә талып уй кылды,
Уй кылганда бу диде:
— Идегәй торып китте инде;
Иленнән кайта килгәнче
Мин дә аны көтмәен,
Эшемне күреп калыем;
Туктамыштай тукал[3] хан
Иделдән кубып килгәндә,
Җаектан кубып барыем,
Кизәнеп сугып калыем,
Йорт-казнасын алыем...
Идегәй кайтып килгәндә,
Аны уртакчы итмәен,

---

[1] *Багымны* — бәхетемне.
[2] *Яр* — фәрман.
[3] *Тукал* — мөгезсез.

Аның да Идел-йортына
Мин баш булып алаем!
Яу кыргынын торгызып,
Ул да килеп туктады.
Ике чиру[1] кара яу
Ике яктан бер килеп,
Кылдай мәйдан тартылды.

Бервакыт мәйдан тын булды.
Шаһ Тимердән бер батыр —
Уң кул бие Ир Каплан —
Туң чукмарын кулга әлеп,
Ат сикертеп уртага,
Мәйдан тотып туктады.

Туктамыш хан ягыннан
Мөйтәннән туган Кыпчак би
Чыга куйды «гөрс» итеп!
Каршыга килеп бер торды,
Карагай буе сөңгесен
Ир Капланга бер орды;
Иңсәсеннән бер тотты.
Как сөяген каерып,
Куйдай итеп маерып,
Ир Капланны өереп,
Туктамыш хан кашына
Саугатка[2] алып китерде.
Иртәдән тоткан мәйданын,
Кичкә шаен бирмәде.
Ир Капланнан күп өстен
Утыз тугыз пәлванны
Кайсын алып иңсәдән,
Кайсын алып якадан,
Бакыртып егып атыннан,
Башы белән күтәреп,
Туктамыш хан кашына
Илтә бирде саугатка.
Әмир Бырлас Шаһ Тимер:
— Мәйданны тоткан кем калды? — дип,

---

[1] *Чиру* — гаскәр.
[2] *Саугат* — әсир.

Эче янып ут булды,
Тышы катып боз булды.
— Туктамыш чапса, кем калды?
Ни шомлыкка тарыдым? —
    Аны әйтеп Шаһ Тимер,
Күмердәй кара киселде.

XI

Идегәйнең Туктамыш хан урдасы белән орышканы

Ул дигәнче бу булды:
Кара болыт якынлап,
Көн урынына төн булды.
Бөркелеп чыккан тузаннан
Җир белән күк бер булды.
Ханнар катып торганда,
Яулар посып торганда,
Анда тузан ачылып,
Илле төрле ту[1] белән
Җитеп килде Идегәй.
    Яу батыры Идегәй
Сузылмалы кылычын
Кармап алып сабыннан,
Андый итеп бер сукты —
Туксан урда бер купты!

    Анда купты бер орыш —
Идегәйнең орышы,
Дөньяларда булмаган
Ир Идегәй сугышы.
Бер селтәде — бере ауды,
Бере ауганга уны ауды,
Ун ауганның җиле бар,
Уны белән йөзе ауды,
Йөзе ауганга меңе ауды
Караны кара[2] димәде,
Бине күзгә элмәде,

---

[1] *Ту* — байрак.
[2] *Кара* — бу урында: кара халык, түбән сыйныф.

Үлем дигән казаны
Чебендәен күрмәде.
Идегәй килә дигәндә,
Аны белгән ни ир бар —
Урда бозып таралды.
Азамат ир Туктамыш,
Дәрвазасын[1] яптырып,
Шәһәренә кереп камалды.
Туктамышның дәрвазына
Туры барды Идегәй.

Килеп җитеп Идегәй,
Кул табанын бер орды.
Дәрвазасын кубарып,
Һавага атып җибәрде.

Ул да булып булмады,
Маңлайлары ялтырап,
Тулы кашы калтырап,
Саралатын[2] уйнатып
Җитеп килде Норадын.
Атадан күргән һөнәрен
Җитеп күрде[3] Норадын.

Алаңгасар Алман бине
Акыртып кисте Норадын;
Байназардай Диван бине,
Бугалак салып муйнына,
Бакыртып кисте Норадын;
Айбалталы Дөрмән бине
Дәрвазага бәйләтеп,
Дулатып кисте Норадын;
Анда килеп Киң Җанбай:
— Баш исәндә җан исән,
Ханның башы калсын,— дип,
Тезген башын кулга алып,
Атның башын каерып,
Йәникәдән аерып,

---

[1] *Дәрваза* — капка.
[2] *Саралатын* — нәселле атын.
[3] *Җитеп күрде* — эшкә күрсәтте.

Ас күчәгә юл алды.
Ас күчә дә өс күчә —
Биләр йөргән бүз күчә[1],
Яшерен бикне ачтырып,
Йөздән артык ир белән
Туктамыштай олы хан
Киң далага юнәлде.

XII

Туктамыш ханның сарайдан качып киткәндә тулгап[2] әйткәне

Хан Туктамыш гарьләнеп,
Байтагым[3] дип зарланып,
Аны әйтеп тулгады:
— Әй байтагым, байтагым,
Сине алдырдым мин тагын,
Дошман талар килгән соң,
Әл-аман бул миннән соң!
Чыңгыздан калган кара ту,
Сине яуга калдырдым,
Әл-аман бул миннән соң!
Ханәкәдәй аруны,
Көнәкәдәй сылуны,
Йәникәдәй бикәчне
Капыллыкта тиген улҗа калдырдым[4],
Әл-аман бул миннән соң!
        Кызыл мәрҗән таккан йорт,
Акбүз атка менгән йорт,
Яңгыз да каргам Кадыйрбирде,
Кадыйрбирде солтан туган йорт,
        Аны әйтеп Туктамыш,
Йөз батырын янга алып,
Киң Җанбайны уңга алып,
Янә юлга юнәлде.

---

[1] *Бүз күчә* — туры юл.
[2] *Тулгау* — сыктау.
[3] *Байтагым* — тәхетем.
[4] *Улҗа калдырдым* — ятим калдырдым.

Кача биреп киткәндә,
Илен алды Идегәй.
Шаһ Тимергә аны әйтте:
— Сары мәрмәр Алтын-Таш —
Сарайны саклап торгайсын;
Алла үземә биргәндә
Туктамышның эзеннән
Эз чыгарып алыем,
Башына кылыч чабыем;
Ил күңелен тындырып,
Ир күңелен табыем.

Аны әйтеп Идегәй,
Шаһ Тимердән аерылды.
Норадынны янга алып,
Ирәннәрен[1] уңга алып,
Болгардаен шәһәргә
Туры барды Идегәй.

Килә җитеп Идегәй,
Болгарны танып танымый,
Хәйран калып туктады:
Калага аяк басканда,
Каерылып яткан таш күрде,
Көйрәп яткан көл күрде,
Адәм заты тапмады.
Шәһре Болгар уртасы
Өсте мәрҗән, асты таш
Алтмыш колач манара —
Күз өстендә гәүһәр каш.
Анда җитеп килгәндә,
Төтеннән чатнап ярылган
Манараны күргәндә,
Ул манара төбендә
Башын учлап утырган,
Чәче челдәй агарган
Бодай бине күрде Идегәй.

Анда әйтте Бодай би:
— Сыенганым син идең,

---

[1] *Ирәннәр* — җан сакчылар.

Бу җиһанның фетнәсе —
Аксак Тимер дошманны
Сарайга алып китердең,
Йөз баһадир иреннән
Йорт җиренә бастырдың.
Алтын койган учагым
Ал кирпечен туздырып,
Көмеш койган учагым
Гөл кирпечен туздырып,
Төнгә үтте Туктамыш.
Ул да үтте дигәндә
Бу күрәсем бар икән:
Урысның бер гавере —
Ул килеп басты йортымны.

Идегәй Бодай бигә талаучылардан үч алырга сүз бирә дә Туктамыш ханны куа китә. Юлда ул Болгар шәһәрләре аша үтә. Бу шәһәрләрнең, шул исәптән Казанның да, янып көлгә әйләнүен үз күзе белән күрә. Ашыт, Казан суларын үтеп, Сабакүлгә җитә. Ханны анда да очратмагач, улы Норадынга: «Ык елгасы буйлап кит. Туктамышны шунда эзлә»,— ди.

Хан кашында йөз кеше;
Һәммәсе дә — сум кеше[1],
Зәһәрнең азы да бер, күбе дә бер,
Һәммәсен дә суя бир.

Хан кызы Ханәкәне улы өчен саклап торырга вәгъдә итә. Норадын хан артыннан чаба, Идегәй, кире борылып, Сарайга кайта. Шәһәргә кергәч, ни күрсен: Аксак Тимер каланы яндырган, казнаны талаган. Илгә башлык итеп үзе урынына Кыйгырчык исемле бине утырткан. Әмирнең урынбасары Кыйгырчык буйсынырга куша. Батырның ачуы чиктән аша:

Барын бердәй өереп,
Тукмагы белән чүкереп[2],
Һәлак кылып ташлады.

Идегәй, үзе башлык булып калгач, илдәге колларны азат итә, кол сатуны тыя. Янына акыллы кешеләр җыя.

Киңәшсез үскән бу йортны
Киңәшле йорт кылдырды,
Каланы кайта торгызды.

[1] *Сум кеше* — явыз кеше.
[2] *Чүкереп* — бәреп.

XIII

Норадынның Туктамыш ханны үтергәне

Ыкның үләнле болыннарына җиткәч, йөз кеше атланган атлар эз калдыра дип, Туктамыш җан сакчыларын бер якка җибәрә, үзе ялгызы гына Ку күленә (Үрдәк күленә) китә. Авыр, җилкәне баса дип, кирәүкәсен[1] ташлап калдыра. Аны Норадын, табып, өстенә кия.

Килә җитеп Норадын,
Ку күлене күргәндә,
Азамат ир Туктамыш
Качса кача белмәде,
Куба килеп урыныннан,
Тора килде Туктамыш.
Бер-беренә сәлам биргәндә
Анда әйтте Туктамыш:
— Атның бары толпар булмас,
Кошның бары шоңкар[2] булмас,
Син ич — минем колымсың.
Мин Чыңгызмын, беләмсең,
Хан улымын, ханыңмын,
Үзем үлми кулга тотылмам,
Үлтермәмен мин сине,
Үлтермәссең син мине!

Анда әйтте Норадын:
— Мин бер колың түгелмен,
Син дә Чыңгыз түгелсең.
Дусымның утын сүндермәм,
Дошманым утын яндырмам;
Шаһ Норадын миндермен,
Шушы йөргән Чыңгызның
Кайсы улыннан кимдермен?

Баш кисәрмен кайгысыз!
Атамны йорттан син кудың!
Мине йорттан син кудың!

---

[1] *Кирәүкә* — көбә, металл боҗралардан ясалган кием.
[2] *Шоңкар* — лачын.

Арын әйт тә бирен әйт,
Беренче кизәк кемнеке?
Яшең өлкән ир икән,
Син ат, кизәк[1] синеке!
Анда килеп Норадын,
Каршыдан торып басканда,
Азамат ир Туктамыш
Өч катар угын атканда,
Атканы карь итмәде[2],
Тугыз күзле кирәүкә
Бер күзеннән үтмәде.
«Үз коралыма юлыктым»,— дип,
Җонҗыгалы[3] чал башын
Сона бирде Туктамыш.
Ир Норадын сукканда,
Кылычы белән чапканда,
Туктамышның чал башы
Җиргә төште «Алла»лап.
Кан урынына сөт акты.
Башны җитеп артыннан,
Ак найзага кыстырып,
Аны да өскә күтәреп,
Норадын анда сорады:
— Колдан вәзир куясызмы?
Кол теленә инанасызмы?
Сөңгедә торган хан башы
Телгә килеп анда әйтте:
— И балам, балам, балам,
Колдан вәзир куйсак та,
Колның телен алсак та,
Гәүдә түбәндә калды,
Баш әле дә синнән югары.

Норадын башны җиргә атты,
Аннан аны янә алды,
Саралатын бер типте,
Кайта бирде Норадын.

---

[1] *Кизәк* — кизәнү чираты.
[2] *Карь итмәде* — зыяны тимәде.
[3] *Җонҗыгалы* — таҗлы.

XIV

Норадынның Җанбайга очрап әйтешкәне, Җанбайның Идегәй белән Норадынны бозылыштырганы

Кайтышлый Норадын Киң Җанбайны очрата. Аңа: мине мактап җырласаң исән калдырырмын, үзеңне мактасаң үтерермен, ди. Җанбай җырларга риза була. Ләкин җырында үзен дә мактамый, Норадын турында да уңай сүз әйтми. Киресенчә, ул аны мыскыл итә. Туктамыш улы Кадыйрбирденең хан булуын, ә синең җиңелүеңне телим, ди.

Җанбай алай дигәндә,
Тау иленең Мәмәткол
Атлы егет килде лә!
Җанбайга атын тибендереп,
Алмас кылыч күтәреп,
Җанбайны чалмак булды ла.
Норадын аны күргәндә
Аралап торып килде дә.
Анда Җанбай әйтте лә:
— Җиргә тамар канымны
Җиңнән тоттың, Норадын!
Җилкәмнән төшәр башымны
Җөйләп тоттың, Норадын!
Сиңа ияргән колларга
Гомер бирдең, Норадын!
Ир Норадын анда әйтте:
— Әй Киң Җанбай, Киң Җанбай,
Син үлгән белән җир тулмас,
Үлмәгән белән күбәймәссең!
Сине үтереп ни итием?
Үтерми ак китием.
Туктамыштай ханыңа
Нинди хезмәт кылгансың,
Атама да шуны кыла йөр!

Сарайга кайтып җиткәндә,
Туктамыштай хан башын,
Канҗагасыннан чыгарып,
Идегәйнең алдына
Ташлап әйтте Норадын:
— Иңкәйтеп башын алганмын,
Алдыңа китереп салганмын!

Анда әйтте Идегәй:
— Әй Норадын, Норадын,
Бу хезмәтем үтәдең,
Кабул кылдым морадың.
Сиңа булсын Ханәкә.

Урда башы Биш Уба[1]
Җанбай җитеп килгәндә,
Биш Убада елаган
Ханның кызы Ханәкә,
Җанбай аны күргәндә,
Тулгай биреп[2] аны әйтте:
— Әй Ханәкәм, Ханәкәм,
Хансарайга килгәндә,
Тар карныңны киңәйтеп,
Киез белән керсәң, әй!
Сине дә күреп Норадын,
Ай-көнле[3] дип белсә, әй!
«Бу кем кылды?» — дигәндә,
«Атаң кылды»,— дисәң, әй!
Атасы белән бозылып,
Икәве бердәй түнсә[4], әй!
Алар да китеп тәхеттән,
Синең энең яшь солтан
Кадыйрбирде хан булып,
Әүвәлгедәй дан булып,
Дәүран гомер сөрсә, әй!

Җанбай алай дигәндә,
Ханәкә торып килгәндә,
Киез бәйләп карнына,
Хансарайга иңгәндә,
Норадын аны күргәндә —
«Бу ни?» — диеп торганда,
Ханәкә солтан аны әйтте:
— Атаң белер мәгънәсен!

---

[1] *Биш Уба* — Урданың бер өлеше.
[2] *Тулгай биреп* — мактап, баш иеп.
[3] *Ай-көнле* — йөкле.
[4] *Түнсә* — бетсә.

Моны ишетеп Норадын,
Күмердәй кара киселде.
Атасын күреп тәхеттә:
— А! — дип, анда җикерде.
Кулындагы думбыра
Кулында түзми сикерде.
Анда чыгып уң күзе,
Күзсез калды Идегәй.

XV

Идегәйнең Норадынга рәнҗеп әйткәне, Норадынның бүленеп киткәне

Идегәй улына рәнҗи. Син тугач, «Таңда чыккан чулпандай, яна да яна торсана»,— дип, зур мәҗлес җыйдым. Сине йомшак парчага төрдем, ул каты дип сусар тиресенә, ул да каты дип тиен тиресенә төрдем. Балачактан ат менәргә өйрәттем; «Күкрәгең яулы үссен дип, качкан яуны кудырдым; Саргайган да көнемдә үз башыма көч иттем»,— ди. Идегәй сүзен болай тәмамлый:

Курдай[1] күзе кызарган,
Син дигәндә җан аткан
Ялгыз атаң мин идем,
Күзем орып чыгардың;
Кайда барып уңарсың?
Кайда барсаң тынарсың?
Языгы белән гөнаһысын
Кайда ла барып йоларсың?
Ир Норадын анда әйтте:
— Кардай чәче агарган,
Курдай күзе кызарган,
Мин дигәндә җан аткан
Ялгыз атам син булсаң,
Син сүзеңнән тангансың[2],
Киленеңне алгансың!
Күзең орып чыгарсам,
Тәңре өе Кәгъбәне
Бер әйләнсәм унармын.
Өч әйләнсәм тынармын;

---

[1] *Курдай* — утлы күмердәй.
[2] *Тангансың* — сүзеңнән кайткансың.

Языгы белән гөнаһысын
Җиде әйләнсәм йолармын!

Китәрмен, атам, китәрмен,
Шаһ Тимергә җитәрмен,
Тимер биргән кир атны[1]
Тирләткәнче менәрмен;
Тимер биргән тимер тун —
Сүтелгәнче киярмен!
Тимер биргән сылуны
Алдыма алып сөярмен!

Анда торып Норадын,
Атына менеп атланды.
Айтулы ару анасы
Норадынга аны әйтте:
— Әй Норадын, Норадын!
Каз төшермәс күлләргә
Каз төшереп уйнаттың;
Каздай башын агарткан
Атаңны нигә уйлаттың?
Ку[2] кундырмас күлләргә
Ку кундырып уйнаттың;
Кудай башын агарткан
Анаңны нигә уйлаттың?

Кара суга кан койсаң,
Суны кайдан эчәрсең?
Халык белән даулашып,
Яхшыны кайдан табарсың?

Җавап бирде Норадын:
— Әй инәкәм, инәкәм,
Кара суга кан койсам,
Балдан ширбәт эчәрмен,
Халык белән даулашсам,
Йорт яхшысын табармын.

Янә әйтте анасы:
— Әй Норадын, Норадын,

---

[1] *Кир ат* — сугыш аты.
[2] *Ку* — аккош.

Идел дигән су килер,
Аны ничек кисәрсең?
Итәгендә ил булыр,
Аны ничек үтәрсең?

Җавап бирде Норадын:
— Әй инәкәм, инәкәм,
Ике ташны култыклап,
Идел кичкән улыңмын;
Иделдән яуга төшеп,
Исән чыккан улыңмын;
Идел дигән су булса,
Ике чумсам кичәрмен;
Итәгендә ил булса,
Ике орсам үтәрмен!
Аны әйтеп Норадын
Чыгып китте баш тартып.

XVI

Норадынның, кайтып, атасын куганы, Идегәйнең казак чыгып киткәне

Идегәй улын сагынып җырлый:

— Читтә солтан булудан
Илдә олтан булу артык;
Күктә чулпан булудан
Суда чуртан булу артык,
Әй Норадын, улым әй,
Сагындырдың мине артык!

Үзе янына кайтырга күндерү өчен, ул Норадынга илчеләр җибәрә. Норадынны бик озак үгетләгәннән соң гына кайтырга күндерәләр. Идегәй улын шатланып каршы ала. Аңа мактау сүзләре әйткәннән соң, дәрәҗәле итәргә вәгъдә бирә. Әтисе сүзләрен Норадын үзенчә аңлый.

Идегәй алай әйткәндә,
Дәрәҗәгә чиккәндә,
Ир азамат Норадын
Хан булам дип уйлады,
Атасы хан итмәде,
Үзе дә хан булмады.

Норадын моны күргәндә,
Каһәреннән кыйналды.
Идегәйгә анда әйтте:
— Әйткәнеңнең барысын
Кылганың хак, и ата!
Әйткәнемнең берсен дә
Кылганың юк, и ата!
Йә син үзең хан булгын,
Йә син мине хан кылгыл!
Йә син мине үтергел,
Йә мин сине үтерим!
Йә күземә күренмә,
Казак чыгып кит! — диде.
Норадын алай дигәндә,
Азамат ир Идегәй
Җиде кат күктәй күкрәде,
Авазы калкып, яңгырап,
Норадынга аны әйтте:
— Киреләнсәм, йокың бозармын,
Көрәшсәм, сине егармын,
Йөгерсәм, сине узармын,
Каргышым кара таштан үтәдер,
Аһым җирне-күкне тотадыр,
Күтәрә алмассың, Норадын!

Анда Идегәй аһ орды,
Норадын артка егылды,
Авызы-борыны кыйшайды.
Анда әйтте Киң Җанбай:
— Норадын бердәнбер балаңдыр,
Каргыш итмә, Идегәй,
Алкыш иткел[1] углыңа!
Анда углын аяды,
Алкыш бирде Идегәй.
Тора килеп Норадын,
Идегәйгә янә әйтте:
— Кисәкчә чыккан болытмын,
Яумаенча таркалмам,
Анадан кара туганмын
Сабынлап юсаң агармам!

---

[1] *Алкыш иткел* — гафу ит.

Болыттан кыеш чыкканмын,
Алдыңа алсаң, төз булмам!
Йә син үзең хан булгын!
Йә син мине хан иткел!
Йә күземә күренмә.
Казак чыгып кит! — диде.

Анда торып Идегәй,
Норадынга аны әйтте:
— Ялгыз баланың кылыгы[1]
Яудан яман,— дисә, бу булгай.
Җанбайдаен җанбазның[2]
Языгын алып муеныңа,
Җанын исән калдырдың,
Яныңа яучы алдырдың,
Ул да җитәр беркөн җаныңа!
Карчыгадай морза углым;
Каулаганың мин булсам,
Мин качаем, син каула,
Һәрбер көндә дошманың
Миндәй качсын, морза углым!
Һөнәрсез сине күрә алмас,
Илдән илгә җилеп үтсәң дә,
Бу дөньялар сиңа да калмас!
Аны әйтеп Идегәй,
Иделдән чыгып юнәлде.

XVII

Норадынның Кадыйрбирде кулына тотсак булганы

Хан булып алган Норадын, яз җиткәч,ауга чыгарга ниятли. Үрдәк төшмәгәнме, карап кайт дип, Киң Җанбайны күлгә җибәрә. Аны юлда Туктамыш улы Ходайбирде кешеләре тотып ала. Ходайбирде Җанбайны атасына хыянәт итүдә, дошманы Норадынга хезмәт итүдә гаепли. Җанбай Норадынны тотып китерергә вәгъдә итә. Шул хакка җанны саклагыз, үтермәгез дип ялвара. Котылып Сарайга кайткач, Норадынга ауга чыгарга була, кошлар күлгә төшкән дип хәбәр итә.

---

[1] *Кылыгы* — юньсезлеге.
[2] *Җанбаз* — җан белән уйнаучы.

Җанбай алай дигәндә,
Норадын белән икәүләп,
Чирүлегә килгәндә,
Күз ачып күз күргәндә,
Җанбай анда юк булды,
Идегәй улы Норадынның
Әйләнәсе яу булды.
Күз ачып күз йомганчы
Корык ташлап артыннан,
Норадын авып атыннан,
Аягы-кулы бау булды;
Төшкән җирен караса,
Бер караңгы баз булды;
Базына таш ябылды.

Ходайбирде хәзер Идегәйне тоту эшенә керешә. Иң якын кешеләрнең тугыз улына Идегәйне табарга куша. Тугыз илче Идегәйне таба һәм: «Улың тотылды, безнең белән Сарайга кайтсаң, Норадын исән калыр, кайтмасаң үтерелер»,— ди. Идегәй бу тозакка эләкми, илчеләрнең җидесен үзе янында калдыра, икесенә: «Норадынны үтерсәгез, җиде улыгызны үтерәчәкмен»,— дип әйттерә. Кадыйрбирде Идегәй шартына күнәргә мәҗбүр була.

Кадыйрбирде анда әйтте:
— Кулга төшкән дошманны
Кайтадан буш күндерсәк,[1]
Безгә лаек эш булмас.
Бер хәйләсен кылыйк,— дип,
Норадынны баздан алдырды.
Аягын анда салдырып,
Ялангачка калдырып,
Тимер чөй каккан кара идән —
Кара идәнгә бастырды.

Норадын анда кергәндә,
Ни булганын аңлады,
Буй-буй такта, буй такта,
Тимер чөй каккан буй такта,
Пычаклап суккан урындык;
Ир Норадын курыкмады.

---

[1] *Кайтадан буш күндерсәк* — исән калдырсак.

Басып атлап узганда,
Йөзен бер дә чытмады,
Пычаклап суккан урынга
Тайчанмастан утырды.

Анда утырып Киң Жанбай,
Норадынга аны әйтте:
— Кисмә-кисмә сары алтын,
Мөһер суккан саф алтын,
Энҗе-гәүһәр, якутны,
Аны ниттең, Норадын?

Җавап бирде Норадын:
— Кисмә-кисмә сары алтын,
Мөһер суккан саф алтын,
Энҗе-гәүһәр, якутны
Халкыма мин барын
Кисеп улҗа[1] кылганмын!
Кәмал углы Киң Җанбай,
Кире сүзгә эт Җанбай!
Аш биргәннең улысың,
Мал биргәннең колысың!
Кадыйрбирде яшь солтан,
Кузагачтан биекмен,
Болытка тисәм бөгелмәм,
Кайнашып беткән ботакмын,
Өермә сукса иелмәм;
Тулай байтак иясе
Туктамыш атлы атаңны
Кисә кырыккан арысланмын!
Йөрәгемә пычак тыксаң да
Әйтермен, һич курыкмамын;
Коралсызларны кыйнау,
Йоклаганны үтерү —
Көчсез кеше эше ул,
Юньсез кеше эше ул!

Норадын алай дигәндә,
Пычаклап суккан урындык
Ботын ярып кергәндә,

---

[1] *Улҗа* — сугышта кулга төшкән мал, трофей.

Аягыннан кан саркып,
Йөзлегенә иңгәндә,
Кымшанмастан утырып,
Турыдан җавап биргәндә,
Кадыйрбирде яшь солтан
Норадынга таң калды:
— Андый батыр ир булдың,
Атаңа миннән сау юнәл.—
Аны әйтеп яшь солтан,
Норадынның кулын чиштерде,
Эчерге[1], ияр салдыртмый,
Менәренә ат бирде,
Җайдак атка мендерде,
Иделгә туры китерде.
Тирләп килгән атыннан
Ярасына үтеп кара тир,
Ягыр[2] булып Норадын,
Торалмаслык булсын, дип,
Атны кызу җилдерде.

Иделгә килгән Идегәй
Идел аша кычкырды:
— Каны[3] углым Норадын?
Аны миңа җибәрсен,
Бу җидәүне җибәрим!
Кадыйрбирде бу яктан
Норадынны, салга артлап[4],
Идел үтә җибәрде.
Ике яктан ике сал
Икәве бергә килгәндә,
Арыдан торып Идегәй,
Норадынга тулгап, аны әйтте:
— Салны салга бәйләче!
Сал эчендә җидәүне
Яхшы уңгарчы[5], морза углым!

---

[1] *Эчерге* — ат ияре астына куела торган киез.
[2] *Ягыр* — агу.
[3] *Каны* — кая.
[4] *Артлап* — утыртып.
[5] *Уңгарчы* — кирәген бир.

Идегәй алай дигәндә,
Саллар салга килгәндә,
Норадын, салны сөздереп,
Салны салга бәйләде,
Салда утырган җиде угыл —
Җидәвен дә үтереп,
Ана Иделгә колатты[1]
Иделне кичеп Норадын,
Идегәйгә килгәндә,
Гозер-гафу үтенеп,
Кулыннан үбеп йөгенде
Ярасына үтеп кара тир,
Ягыр булып Норадын,
Ул сәгатьтә егылды.

XVIII

Кадыйрбирде солтанның, урда торгызып, Идегәй өстенә барганы, Идегәйнең орышта үлгәне

Кадыйрбирде яшь солтан
Анда утырып яр салды:
— Дәүран сөргән[2] көнемдә
Идегәй исән икәндә,
Идел-йорт миңа ил булмас,
Күргән көнем көн булмас,
Йә Идегәй, йә дә мин!
Атланыек, ятмыек!

Аны әйтеп яшь солтан,
Аттан атын җыйдырды,
Ирдән ирен җыйдырды.
Идегәй аны сизгәндә,
Тора биреп корганып[3],
Яндашларын янга алып,
Ул да купты урыныннан.
Гайрәте судай ташадыр,
Ачуы чиктән ашадыр.

---

[1] *Колатты* — ташлады.
[2] *Дәүран сөрү* — гомер итү.
[3] *Корганып тору* — сакланып тору.

Атына камчы салган соң,
Яуны килеп басадыр,
Кайда садак[1] тартадыр,
Кайда мылтык атадыр;
Кайда кылыч селтәләп,
Кайда сөңге белән батадыр.
Ул читеннән керәдер,
Бу читеннән чыгадыр,
Куйга кергән бер бүре,
Бүре куйны кырадыр.
Сансыз татар, кара яу
Якадан якага алышып,
Берсенә берсе капланып,
Теш-тырнагын актарып,
Бугазга-бугаз чәйнәшеп,
Ни булганын белмәде.
Кайсы башын актарды,
Кайсы җирдә тапталды,
Кич булганда шул булды:
Һәр ике як аз калды.

Кадыйрбирде солтанга
Җанбай анда моны әйтте:
— Алтмыштагы Идегәй
Хәлдән хәле киткәндә,
Ике чиру бер килеп,
Кан заяга киткәндә,
Бермә-бергә бер чыгып,
Бер чүкерсәң, ни булыр?

Җанбай алай дигәндә,
Кадыйрбирде яшь солтан,
Гайрәте килеп, анда әйтте:
— Бүре булып барыем,
Бурбаеннан алыем,
Арыслан булып барыем.
Анда әйтте Идегәй:
— Кабагыннан кар явып,
Керпегенә боз туңып,

[1] *Садак* — җәя.

Эзләп килгән Кадыйр белән
Ярышырга көчем бар.

Алты батман чукмарын
Идегәй тулгап алганчы,
Чөйдәле балта кулга алып,
Кадыйрбирде бер сукты —
Идегәйнең калканы
Анда шыңлап ярылды.
Идегәй анда чукмарын
Янә бер тулгап алганда,
Аван куллы[1] Кадыйрбирде
Янә килеп бер сукты —
Көбәсе сынып[2], кан чыкты.
Янә бер сугыйм дигәндә,
Анда инде Идегәй
Алты батман чукмарын
Өч тулгады, бер сукты,
Андый итеп бер сукты,
Ат саурысы[3] «чырк» итте.
Кадыйрбирде бер чүкте,
Түбәсеннән кан чыкты,
Кан чыкканда җан чыкты!
Ул атыннан ауганда,
Биләр шаша калганда,
Атын сөреп Идегәй
Кача бирде арадан!

Барын морза аны әйтте:
— Әй Туктамыш биләре!
Хан тагына[4] кем менәр?
Идегәйне кем җитсә,
Җитеп башын кем алса —
Хан тагына ул менәр!

Унике түрә, алты би
Эзеннән-эзен чыгарып,
Куа килеп артыннан,
Күлгә җитеп туктады,

---

[1] *Аван куллы* — сугыш эшенә өйрәнгән кул.
[2] *Көбәсе сынып* — тимердән эшләнгән сугыш киеме тишелеп.
[3] *Ат саурысы* — ат биле.
[4] *Тагына* — тәхетенә.

Камышлыкка якынлап,
Барын анда тулгады:
— Идегәй өлкән ир иде!

Үзеннән бер яшь кечегә:
«Син тора тор, газизем,
Мин атыем»,— дир иде.
Үзеннән бер яшь олыга:
«Мин торыем, газизем,
Син атсаңчы»,— дир иде...

Барын аны әйткәндә,
Калка биреп камыштан,
Идегәй торып аны әйтте:
— Сездәен сөлтекләрдән[1]
Курка торган Идегәй юк!
Көтә торың, чыгармын,
Күк күкрәтеп, кылычым
Яшен уйнатып сугармын!

Аны әйтеп урыныннан
Куба килде Идегәй,
Шам кылычын кулга алып
Чыга килде Идегәй.
Сул кулыннан кан агып,
Уң кулыннан җан алып,
Калган хәлен бар итеп
Ора килде Идегәй.

Унике түрә, алты би —
Идегәй анда камалды.
Алар атта, ул җәяү,
Унике сөңге, алты ук
Идегәйгә кадалды.
Анда булды бер сугыш,
Камыш башын кан алды.

Анда әйтте Идегәй:
— Үлем белән куркытмаң,
Курка торган уем юк!
Үлем туры килә икән,
Котыла торган буем юк.

---

[1] *Сөлтек* — карачкы.

Илем өчен илсенеп,
Җирем өчен җилсенеп,
Халыгым өчен яхшы уем.
Күкрәк тулып җилсенеп,
Көрәшкәнне халыгым
Аңладымы — белалмам!
Аңламаса халыгым,
Аңлатмастан үләлмам!

Барын бердәй аралап,
Аттан атын яралап,
Анда батыр Идегәй
Унике ирне үтерде.
Кан ярасы ачылып,
Идегәй хәле беткәндә,
Барын морза бер җитеп,
Идегәйне бер чапты.
Башы тәненнән аерылып,
Тәгәри биреп аны әйтте:
— Барын, сиңа ни кылдым?
Берең ике булмасын![1]
Йортың-караң калмасын!

---

[1] *Берең ике булмасын!* — Балаларың булмасын!

Ханнан ханны мин ектым,
Хан булып син дә калмассың!
Казан, Кырым, Аждаркан,
Кунымны[1] сорап купканда,
Ни булганын анда күрерсең!

Идегәй башы, аны әйтеп,
Көнгә таба әйләнде,
Әйләнгәндә янә әйтте:
— Алдагы көн агырга[2]
Без барабыз, ул килмәс!..
Аны әйтте дә җан бирде.

* * *

Идел-йортны дау алды,
Яу өстенә яу килде,
Идегәй әйткән көн килде.
Чыңгызның куйган хан тагы
Кан тагына әйләнде:
Хан сарае камалды.
Казан, Кырым, Аждаркан
Башлы-күзле ил булды,
Алтын Урда таралды.

«Идегәй» дастанының чыганагы

Дастан дип батырлар турында халык иҗат иткән әсәрләргә әйтәләр. «Идегәй» дастанын Казан ханлыгының күршесе, телләре татар теленә бик якын булган нугай халкы иҗат иткән дигән фикерләр бар. Нугай халкы төрки телдә сөйләшүче халыкларга күпләп-күпләп кушыла. Үзләре белән нугай батырын мактаган җырларын да алып киләләр. Төрки телдә сөйләшүче халыклар дастанны үзләренең тормыш шартларына җайлаштырып үзгәртәләр һәм шуңа күрә бик хаклы рәвештә үз әсәрләре дип исәплиләр. Безнең борынгы бабаларыбыз да шулай иткәннәр. Әсәрне татар шигыре калыбына салып, персонажларга үзләренчә бәя биреп җырлаганнар. Бу

---

[1] *Кун* — үч.
[2] *Агыр* — хөрмәт.

әсәрне белмәгән, яратмаган татар булмаган. Шул сәбәпле дастанның татар әдәбиятына йогынтысы бик зур дия алабыз.

«Идегәй» дастанында монголлар төзегән империянең җимерелгән вакыты сурәтләнә. Сарай ханы Туктамышның, чыннан да, Идегәй исемле полководецы булган. Күренекле тарихчы Н. М. Карамзин аның 1407 елда баш күтәргән рус князьләрен җиңүе турында яза. Идегәйгә акыллы, гаять дәрәҗәдә хәйләкәр, барлык илләргә дан казанган гаскәр башлыгы дип бәя бирә. Әсәрдәге вакыйгаларның да шактые тарихи документларга нигезләнеп язылган. Идегәйнең Норадын (Нуретдин), ханның Кадыйрбирде исемле уллары, чыннан да, әсәрдәге кебек үзара конфликтка кергәннәр.

Дастанга анализ

Белемегезне сынагыз.

«Йосыф кыйссасы»на ясаган анализны хәтерегезгә төшерегез. Анализ тәртибен дәфтәрегезгә языгыз.

Сораулар һәм биремнәр

1. Әсәргә анализ ясарга керешкәнче, максатларны ачыклау сорала. Дастанга анализ ясар алдыннан, үзегезгә нинди максат куяр идегез? Ул максат үтәлгәч, чираттагы максатыгыз нинди булачак?

2. Дастанга ясыйсы анализның тулы планын языгыз. Бу эштә сезгә кыйссага ясалган анализ планы ярдәмгә килә ала.

Анализ ясарга керешкәнче, эшне җиңеләйтү өчен, болай уйлый алабыз: бер үк чорда иҗат ителгән әсәрләрнең уртак яклары күп. Шуңа күрә дастан белән кыйсса төзелешендә охшашлык булырга тиеш. Ә әсәр төзелешен табу, анализ ясаганда, иң беренче максат була ала.

Кыйсса төзелешен, ягъни күп санлы вакыйгаларның уртак эчтәлеген таптык. Уртак эчтәлекне гомумиләштерү юлы белән ачыкладык: персонажларның бик күп төрле юньсезлекләрен «гөнаһлы эш» дип бер генә төшенчә белән атадык. Бу төшенчәләрне без шулай ук «усаллык», «явызлык», «юньсезлек» төшенчәләренә дә алыштыра алыр идек.

Н ә т и җ ә я с ы й к. «Идегәй» дастаны да эчтәлекләре уртак булган вакыйгалардан төзелмәгәнме?

Вакыйгаларның уртак эчтәлекләрен табу өчен, башта берсен ныклап өйрәнү сорала. Аерып алып өйрәнү өчен, вакый-

галарның кайсын сайларга? Бу очракта Котлыкыя язмышыннан башлау дөрес булыр. Бу вакыйга безгә беренче һәм башка вакыйгалар тууына этәргеч булуы белән дә әһәмиятле. Монда Котлыкыяның яман эше һәм аңа бирелгән җәза турында әйтелә. Автор шуның белән генә чикләнсә, бу юлы да, кыйсса төзелешен тапкан кебек, вакыйга ике өлештән тора: бер ягында — яман эш, икенчесендә — җәза, алар үзара сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә торалар дигән нәтиҗә чыгарыр идек. Әмма дастанның төзелеше кыйсса төзелешеннән катлаулырак. Кыйссада яман эшләрнең яманлыгы бәхәссез булса, дастан авторы укучыларына эш куша: уйлагыз, үзегез бәя бирегез, ди.

Туктамыш хан кош караучысын үзенә хыянәт итүдә гаепли. Минем кан дошманыма сатылдың, ди.

3. Лачын йомыркаларының Туктамыш хан өчен әһәмияте турында сөйләгез. Ни өчен ул кечкенә генә ике йомырка өчен шул дәрәҗәдә ярсый?

4. Әсәрдә Туктамыш ханның хаклы булуын раслаучы дәлилләр турында сөйләгез.

5. Котлыкыя, чыннан да, ханга хыянәт итә. Бу яман эшен кош караучы үзе дә таный. Шулай булгач, хан биргән җәза хаклы җәзамы?

Хәзер Котлыкыяның хыянәтенә бәя бирик.

Котлыкыя башта хәйлә белән котылмакчы була, данлыклы лачыннар картайдылар, шуңа күрә аларның балалары да дан түгел, ди. Әмма ханның хаклы дәлилләренә каршы тора алмый, хыянәтен таный, ләкин гафу үтенми. Киресенчә, үзенең хаклы булуын исбат итәргә керешә. Аклану өчен ике сәбәп әйтә: 1. Син начар хан. Бай дәүләтне таркаттың, бөлдердең, ди. 2. Син минем Идел буендагы үз илемне яулап алдың, яндырдың, таладың, кешеләрен үтердең. Шуңа күрә мине дә бәхетсез иттең, ди.

6. Котлыкыя, Идел буендагы илемне яулап алдың дигәндә, кайсы илне күз алдында тота?

7. Үз иле башка булгач, ни өчен илен талаучы монголлар дәүләтенең таркалуы өчен кайгыра?

8. Котлыкыя ике дәлиле белән аклана алдымы? Котлыкыяга бәя бирегез.

Котлыкыя — сарайда бик кечкенә кеше. Нибары хезмәтче генә. Ләкин аның горурлыгы хан горурлыгыннан бер дә ким түгел.

9. Хан горурлыгының һәм Котлыкыя горурлыгының сәбәпләре турында сөйләгез. Сәбәпләреннән чыгып бәя бирегез: сезгә ике горурлыкның кайсы күбрәк ошый?

Автор үзе бу сорауларны бик кискен куя, ләкин аларның берсенә дә әлеге вакыйга эчендә җавап бирми. Матур әдәбият әсәрләренең эчтәлеге әсәрнең бер өлешендә генә табылмый, әсәр эчендәге барлык бәйләнешләр аша ачыклана. Бу эшне автор безгә тапшыра. Шуңа күрә югарыда куелган сорауларга һәркем үзенчә җавап бирә һәм дәлилли ала.

10. Туктамыш ханның һәм Котлыкыяның хаксызлыгын исбат итегез.

Котлыкыя, хыянәт итеп, хуҗасыннан үч ала. Үзенең гомере киселәчәген дә яхшы белә, ләкин аның үч алу хисе шул дәрәҗәдә көчле ки, лачын йомыркаларын хан дошманына биргәндә, ул фәкать ханның ачуын китерү, аны көлкегә калдыру турында гына уйлый. Котлыкыя хан белән кырыс сөйләшергә дә, ханның үлем белән янавыннан да курыкмый. Ни өчен? Бу сорауга ул үзе җавап бирә: Котлыкыя үзен Туктамыш хан җимергән һәм кол иткән нугай халкының вәкиле итеп исәпли. Ул үз халкының үчен ала. Аннары нугайлар Сарай дәүләте эчендә яши башлыйлар, һәм аларның язмышы Сарай язмышы белән бәйле була. Шуңа күрә Котлыкыя хан белән Сарай халкы вәкиле булып та сөйләшә.

11. Әсәрдән Котлыкыяның ханга биргән җавапларын тагын бер кат укып чыгыгыз. Аның халык вәкиле булып сөйләвен исбат итегез.

12. Котлыкыяның үч алу хисе гаять дәрәҗәдә көчле, дидек. Ләкин аның үче Туктамышка нинди зыян ясый соң? Котлыкыя хыянәтенең максаты нәрсәдә? Нибары ачуын китереп, көлкегә калдыру гына түгелме? Бу җавап белән риза булсагыз, әсәр текстыннан чыгып исбат итегез.

13. Туктамыш хан нибары ике кечкенә йомырка өчен кош караучысының бөтен нәселен юк итәргә боера. Бу боерыкны шулай ук бик куәтле хис тудыра. Ханның үчкә җавап хисе турында сөйләгез.

Котлыкыяны җәзалау вакыйгасы ничек төзелгән? Хәзер бу сорауга җавап бирә алабыз.

Котлыкыяга җәза бирү вакыйгасын үзләрен хаклы дип санаган, ләкин шул ук вакытта икесе дә хаксыз булган конфликтлы яклар дип гомумиләштерә алабыз.

Анализны дәвам итәбез.

Чираттагы максатыбыз — Котлыкыя вакыйгасына охшаган башка вакыйгаларны эзләп табу.

14. Икенче бүлектәге Урман бине җәзалау вакыйгасына анализ ясагыз. Бу вакыйганың Котлыкыяны җәзалау вакыйгасына охшавын исбат итегез.

15. Туктамыш ханны җәзалау вакыйгасын тулы килеш күз алдына китерегез: хан — Идегәйнең әтисен үтерүче. Субра картның юравы: Идегәй, хан синнән үчен алачак, илеңне яулап алачак, байлыгыңны талаячак, кешеләреңне әсир итәчәк, үзеңне үтерәчәк, диюе. Ханның Идегәйне үтерергә боеруы. Туктамыш ханга җәза эпизоды.

16. Туктамышның да, Идегәйнең дә хаклы да, хаксыз да булуларын исбат итегез.

17. Анализланган һәм төзелешләре табылган өч вакыйга эчтәлегенә охшаган башка вакыйгаларны табыгыз.

Дастанның төзелеше

Дастан сюжеты гомуми төзелешләре уртак булган вакыйгалардан гыйбарәт. Охшаш вакыйгаларны гомумиләштереп, әсәрнең төзелешен табабыз. Дастан бер-берсен яман эш эшләүдә гаепләүче ике як конфликтын күп мәртәбә кабатлый, шуңа күрә ике як конфликтын әсәрнең гомумиләштерелгән төзелеше дип исәплибез. Дошман яклар хисләренә буйсынып эш итәләр — сабырсызлык күрсәтәләр. Якларның икесе дә бер үк вакытта хаклы да, хаксыз да.

Дастан сюжетын сәбәп-нәтиҗә булып килгән, бер-берсенә бик тыгыз бәйләнгән вакыйгалар төзи. Алар, «Йосыф кыйссасы»ннан аермалы буларак, мөстәкыйль яшәмиләр. Бөтен бер сюжет тәшкил итәләр. Котлыкыяга җәза бирү вакыйгасы — үтерүчеләргә (Дөрмән би белән Туктамышка) җәза бирү вакыйгаларының сәбәбе. Туктамышны җәзалау Норадынга җәза бирү сәбәбенә әйләнә. Соңгысы Кадыйрбирдене җәзалауга сәбәп була. Шулай итеп, вакыйгалар бер-берсенең эченә керәләр.

Персонажларның бер-берсеннән үч ала-ала һәлак булулары ахыр чиктә илне һәлакәткә китерә.

Дастан төзелешеннән төп теманы белдек: әсәр хаклык турында дия алабыз. Дастанда һәркем үзен хаклы дип саный, персонажлар катнашкан вакыйгаларга аерым-аерым бәя бирсәк, алар эшләгән яман эшләрнең барысы да аклана кебек. Ләкин персонажларның яман эшләре — кеше үтерү. Алар, аклана-аклана, һаман явызлык кылалар. Шуңа күрә «Дастан

ни турында?» дигән сорауга: хаклык — хаксызлык турында, дип җавап бирү дөрес булыр.

Хәзер анализны дәвам итик. Хаклык — хаксызлык, сабырсызлык, горурлык темасын ачыклап килүче башка вакыйгаларны өйрәник.

18. Идегәй катнашкан вакыйгаларны күз алдына китерегез. Аңа бәя бирегез.

19. Норадын образына бәя бирегез. Норадын белән Идегәй конфликты турында сөйләгез.

20. Җантимер, Җанбай образлары хаклык — хаксызлык, горурлык темасын кайсы яктан тулыландыралар?

Дастан вакыйгаларына автор бәясе

«Йосыф кыйссасы» авторының фикере катгый: яманлык ул — яманлык, ә яхшылык — яхшылык. Алар үзара берничек тә кисешмиләр. Кол Галине беренче чиратта «Яманлыкны ничек бетерергә?» дигән сорау борчый. Һәм ул әсәрендә икеләнергә урын калдырмыйча җавап та бирә: яманлыкны сабырлык белән булдырмый калырга, шәфкатьлелек белән төзәтергә була. Мөселман дөньясында татулыкны ул шундый гади һәм аңлаешлы юл белән урнаштырырга мөмкин дип уйлый.

«Идегәй» авторы бу фәлсәфәне тулаем кабул итә. Ләкин кыйссадагы вакыйгалар Коръәннең мәгълүм идеясен раслау өчен уйлап чыгарылса, дастан нигезендә чын тарихи вакыйгалар ята. Дастанның темасын да, идеясен дә, сюжетын да чынбарлык үзе тудыра. «Идегәй» авторы: «Яманлыкның сәбәпләре нәрсәдә?» дигән сорау куя. Дастан шул сорауга җавап бирергә тиеш була. Бу сорау татар әдәбияты тарихының һәр чорында күтәреләчәк. Әдипләр һәр чорда әлеге сорауга үз җавапларын эзлиләр һәм төрлечә җавап бирәләр.

Дастан авторы зирәк акыллы, киң күңелле кеше булган дия алабыз. Яманлыкны ул өч ноктадан карап бәяли. Бер үк вакыйгага яманлык кылучы да, аның корбаны да бәя бирә. Ләкин, шуның белән бергә, әсәрдә автор бәясен дә күрәбез.

Мәсәлән, Котлыкыяның Аксак Тимергә баш июен Туктамыш хан хыянәт итү дип кабул итә. Котлыкыя үзе куәтле илне бөлдергән ханнан үч алуны гаделлек дип исәпли. Ханның Котлыкыяны үтерүен Идегәй яманлык итеп кабул итә. Дастан авторы исә яманлыкларны бергә җыеп карый һәм яманлыкның фаҗигале нәтиҗәсенә яманлык дип бәя бирә.

Идегәй дастанындагы яманлыкларның һәрберсенең сәбәбе бар. Сәбәпләрнең барысы да диярлек персонажларның үз горурлыкларын саклау, намуслары алдындагы бурычларын үтәү белән бәйле. Горурлык, намуска тугрылык — кешеләрнең иң күркәм сыйфатлары. Әсәрдәге персонажлар, горурлыкларын яклап, яманлык кылалар. Шуңа күрә яманлыкны — яхшылык, ә горурлыкны (яхшылыкны) яманлык дияргә була.

Дастан, шул рәвешле, яманлык белән яхшылыкны тиңләштереп, укучылары (тыңлаучылары) алдына: «Мондый очракта яманлыкны яхшылыктан ничек аерырга?» дигән бик җитди сорау куя. Дастанда бу сорауга җавап юк. Ләкин «Идегәй» авторы үз карашын әсәрдәге интонация аша әледән-әле күрсәтеп тора. Автор, Котлыкыяны үтерткән өчен, Туктамыш ханны өнәми. Шуның белән бергә, ул Туктамышны яман кеше дип кистереп әйтүдән дә ерак тора. Автор, ханны мескен хәлдә күреп, аны чын күңеленнән кызгана. Ханның туган иленнән аерылганда әйткән сүзләренә игътибар итик. Аның хәсрәте шундый ук хәлгә калган Идегәй сүзләрендәге хәсрәттән аерылмый диярлек. Автор үзенең шәфкатьлелеген тагын бер тапкыр күрсәтә, дошманнары өчен бер үк дәрәҗәдә борчыла. Дастанда шәфкатьлелек турында әйтелми. Ләкин без автор шәфкатен һәр вакыйгада күрәбез. Идегәйнең Кадыйрбирде гаскәренә каршы сугышын искә төшерик.

Автор героеның батырлыгына, көченә, кыюлыгына, горурлыгына соклана. Идегәйнең дошманны кыруы турында кабатлый-кабатлый язып килә дә ахырдан, кинәт бик тыныч интонациягә күчеп, фаҗигале нәтиҗә чыгарып куя:

Сансыз татар, кара яу
Якадан якага алышып,
Берсенә берсе капланып,
Теш-тырнагын актарып,
Бугазга-бугаз чәйнәшеп,
Ни булганын белмәде.

Кайсы башын актарды,
Кайсы җирдә тапталды,
Кич булганда шул булды:
Һәр ике як аз калды.

Ләкин тарихи фаҗигаләрнең үкенечле сәбәбен һәм аларга бәясен автор сүз белән әйтеп бетерми. Укучысына әсәр эчендәге бәйләнештән табарга куша. Автор әсәрендәге беренче фаҗигасен нибары лачынның ике йомыркасы белән бәйләп башлаган иде. Шул ике юк кына нәрсә аркасында туган фаҗига берсеннән-берсе үкенечлерәк һәм зуррак фаҗига тудыра.

Котлыкыя йомыркаларны Аксак Тимергә биргән өчен үтерелә. Котлыкыяны үтергән өчен, башта үтерүченең улы, аннары Туктамыш хан үтерелә, Туктамыш ханны үтергән өчен, Норадын үтерелә... Үч алулар, шул рәвешле, бер-берсенә бәйләнеп үсә-үсә, меңләгән халыкның кырылуына һәм ахыр чиктә иң зур, иң көчле дәүләтнең тәмам җимерелүенә сәбәп була. Империя таркалу кебек тарихи фаҗигане лачынның ике йомыркасы белән бәйләп, автор катлаулы сюжетын менә дигән хикмәткә корган. Бик вак нәрсәне мәһабәт вакыйганың сәбәбе иткән.

Дастандагы матурлык

Горурлык — дастан персонажларының иң күркәм һәм иң күп кабатланган сыйфаты. «Идегәй» авторы горурлыкның бик күп сәбәбен ача. Мәсәлән, Котлыкыя горурлыгы — куәтле, бай илдә яшәү. Норадын үзенең арыслан йөрәге, көче, түземлеге белән горурлана. Җантимер горурлыгының эчтәлеге — антка тугрылык. Туктамыш хан үзенең бөек Чыңгыз хан нәселеннән булуы белән горурлана.

Идегәй горурлыгында бу эчтәлекнең барысы да бар. Ул, атасы кебек, иле өчен үлә; улы Норадын кебек арыслан йөрәкле, көчле; Җантимер кебек намуслы; Туктамыш кебек үзенең абруйлы бабалары һәм атасы белән горурлана. Өстәвенә ул зирәк акыллы, игелекле кеше дә әле.

Горурлык сыйфатын төрле эчтәлекләргә бүлгәләп, автор персонажларының һәркайсын мактауга лаек кешеләр итеп күрсәтә. Ә менә Идегәйдә персонажларның барлык уңай сыйфатлары җыелган. Идегәй — авторның иң яраткан герое, башкаларга үрнәк булырга тиешле идеалы.

Дастан авторы горурлык матурлыгына коллык, ялагайлык, куркаклык сыйфатларын каршы куя. Киң Җанбай — шундый персонажларның берсе. Идегәй Җанбайга:

— Атаң кара кеше иде,
Мал биргәннең колы иде,
Анаң кара кеше иде,
Аш биргәннең күңе иде.
Син дә шундый кешесең:
Аш биргәннең колысың,
Мал биргәннең улысың! —

ди. Бу сүзләрне соңрак Җанбайга Норадын да әйтәчәк. Геройларның икесе дә Киң Җанбайга нәселең белән дә, үзең белән дә горурлана алмыйсың, диләр.

ҖИК МӘРГӘН

(Дастан)

Тугзак әби бер атаклы яу башының бикәсе иде. Ул чакта Агыйдел буе батырларының көчләрен сыный торган мәйдан Җаек[1] буе берлә Чулман[2] аръягы иде. Тугзак әбинең бие дә, яу чаба торган атаклы батырларын җыеп, Агыйдел белән Чулман буена ерак яуга киткән иде. Яу башы шул китүеннән кайтмады. Тугзак әби шул вакыттан соң, тугыз угылын канат астына җыеп, Корыч дигән тугайга күчеп килде. Бу тугайдагы агачына сыя алмый торган шомырт, карагат, миләш һәм тырыш бал кортларының яшь юкә чәчкәсеннән генә җыйган саф баллары аларны туйдыра, таштан ташка сикереп чылтыраган салкын чишмә аларны сугара иде. Агыйдел суы кебек тыныч аккан кайгысыз тормыш үз көенчә акты. Тугзак әби дә, тугыз угылының мәйдан күрергә вакытлары җиткәнен сизеп, аларны өйләндерде. Шул көннән соң яшь батырлар аталары юлыннан яуга йөри башладылар. Яшь көчләрнең һәрбер тәҗрибәсе уңадыр иде. Тугыз аргамак берлә китеп, туксан ат яу малы алып кайткан чаклары аз булмады. Ул вакытларда бөтен Агыйдел буенда телдән-телгә тугыз батыр әкиятләре сөйләнә, алар тугрысында мактау җырлары шаулый иде. Бөтен Чулман буенда тугыз батыр явыннан котлары очмаган, таң атканда җаннарыннан имин булган бер өй калмаган иде.

Заманнар үтте. Тугзак әбинең кечкенә өе дә туксан җанлы бер гаилә булды.

Менә беркөнне тугыз батыр Чулман буйларыннан хисапсыз күп яу малы берлән кайттылар. Бу олуг шатлык көненең хәтере өчен батырлар туй ясадылар.

Җәйге төн иде. Киң болын, куе кара урман, тыныч Агыйдел үлем йокысы берлә йоклыйлар; урман артыннан яңа уянган ярты айның сыек яктысы су өстендә шомлы рәвештә җемелди. Биек юкә агачының әллә кай бер җирендә шомлы ябалак сирәк-сирәк кенә кычкырып куя иде.

Тугзак әбинең йөрәге тиз шомланды. Ләкин батырлар туй хәтере өчен эчелгән колмаклы балдан берни сизмәслек рәвештә арып йоклаганнар иде. Тугзак әбинең сизгер колагына су өстендә чап-чоп иткән бер тавыш ишетелде. Шул арада ук:

---

[1] *Җаек* — Урал елгасы.

[2] *Чулман* — Кама елгасы.

— Әй Тәңрем! Тиз, балаларым, ишкәк тавышы ишетелә — яу бар, тиз торыңыз!— дип кычкырса да, батырлар йокысын ачарлык булмады.

Күп тә үтми, батырлар яткан ак тирмәне[1] көнче яу чолгап алды. Тугзак әбинең кадерле эргәсе[2] егылды. Урал буйларында мактау җырлары җырлана торган тугыз батыр хәзер урынна-рыннан югалдылар. Аларның алтын-көмешләре, ук-җәяләре — бар да дошман көймәләре өстенә төялеп йөзеп китте.

Ләкин аңкау[3] дошман кадерле эргәне тамырыннан себерә алмады. Яу килгәнне сизгән тугызынчы килен үзенең ике яшьлек баласын алып качып өлгерә алды. Ул да, тугайның бер читенә барып, үзенең батыры сагышыннан саргаеп үлде.

Кем белә, әллә тәкъдир аны хурлык белән беткән кадерле эргәнең үчен алыр өчен исән калдыргандыр. Әллә тугыз батыр фаҗигасен шатланып сөйләгәннәрнең башына сау калгандыр. Ничек кенә булса да, ул исән иде. Аңар мәрхәмәтле кыр куян-нары туклыклы үләннәр өзеп китерәләр, йомшак күңелле юаш кошлар төрле җимешләр бирәләр иде. Ул үзенең иптәш кош-лары, җанварлары арасында үсте, үзенең ни өчен болай ялгыз икәнен белмичә үсте.

Аны табигать үзе асрап үстерде.

Ул ун яшенә җиткән чакта, теләсә нинди аюларны бер кулы берлә күтәреп ыргыта иде. Кара урман «халкы» аның күләгә-сеннән куркалар иде.

Көннәр үтте. Беркөнне ул үзенең туган тирмәсенең хәра-бәсенә барып чыкты. Аның тирәсендәге юкә агачларында мең төрле җырчы кошлар, мең төрле көйгә салып, үзләренең моңлы җырларын җырлыйлар, кояшның соңгы нурлары суның өстендә сары алтын кебек җемелдиләр, чиксез кара урман куркыныч бер олылык берлә тына, кабара иде. Үксез батыр үзенең туган эргәсе өстендә, ата-аналарның сөякләре янында батырларча каты йокыга китте.

Менә төшендә аңар шәп аргамакка атланган, корыч ук берлә каты җәясен иңенә аскан бер карт батыр күренде.

Карт батыр, үксезнең янына килеп:

— Әй, Агыйдел буеның көчле кулы, атаклы батыры! Син кайда ятарга белгәнсең, балам. Сурлы[4] яуның башына туган

---

[1] *Тирмә* — киездән эшләнгән торак йорт.
[2] *Эргәсе* — нигезе.
[3] *Аңкау* — аңгыра.
[4] *Сурлы* — хур ителгән.

батыр балам, мин — синең атаң. Тор урыныңнан, менә монау юкә агачының астында сиңа атаңнан калган ук-җәя бар. Әнә анау тугайда атаңның иясен югалткан аргамагы бар. Ал син шул укны, атлан шул атка, кит көн батышына. Шунда син үзеңнең даныңны, малыңны табарсың. Тик шуны онытма: бу урын — синең туган урының, монда синең кадерле нәнәң[1], батыр аталарың, сөекле аналарың, иркә туганнарың яшәгәннәр. Алар үзләренең даннарын ата-бабадан ала килгәннәр. Шул нәселнең атагын[2] югалтма, балам, сиңа шул бөтен туганнарыңнан сәлам. Исән бул, батыр балам Җик. Синең исемең Җик булсын! Җәяң нык булсын! — диде дә күздән югалды.

Җик, уянгач, атасы кушкан ук-җәяне казып алып, тугайда йөргән аргамакны тотып менде дә көн батышына юнәлде. Ул вакытларда көн батышындагы башкортлар Казан ханына дан[3] түлиләр иде. Җик шул башкортларны кул астына җыйды да Казан ханына дан түләүдән туктатты. Ул, үзенең кул астындагы егетләр белән яу чабып, Казан ханнарын бик аз аптыратмады. Җикнең угы бушка очмый иде. Ул әгәр дә дошманның күзенә атып сукыр калдырырга теләсә, ул эш булмый калмый. Инде дошманның алдагы тешләрен сындырырга уйласа сындырмый калмый иде. Буладыр иде шундый вакытлар: ул сунарга чыгып очып барган кыр казларының бер генә каурыйсын өзеп төшерергә уйлый һәм эшли, качып барган төлкенең бер колагыннан алып, икенчесеннән чыгара иде. Аны шул тугры атучылыгы өчен Мәргән дип атадылар.

Җик Мәргәннең исеме тиз арада җырларга кушылып әйтелә башлады. Җикнең исемен ишетү күп батырларның эчен кайната, аның үзен күрү аларны куркыта.

Заман үтте, сулар акты. Бервакыт Казан ханы, иң көчле гаскәрен җыеп, Җик Мәргән өстенә сугыш ачты. Җик Мәргән дә үзенең тугры, ышанычлы иптәшләре берлән каршы чыкты. Куркынычлы сугыш башланды. Күп сугышкач, Җик үзенең иптәшләрен карыйм дип артына борылса, иптәшләренең барысы да җирдә ятканын күрде — аның батыр юлдашлары үлеп беткән иде. Шуннан соң Җик хан гаскәренә үз ирке берлән бирелде. Казанга баргач, аны хан зур таш сарайга яптырып куйды.

---

[1] *Нәнә* — әби.
[2] *Атагын* — шөһрәтен.
[3] *Дан* — дань, ясак.

Бердәнбер көнне Казан ханының сунарга бара торган күленә ялгыз аккош төшкән дип хәбәр итәләр. Сунарга һәвәсле хан тиз ара үзенең мәргәннәрен җыйдырды да шул аккошны, үтермичә генә атып алып, сарай күленә җибәрергә кушты. Хан барлык мәргәннәре берлән күл буена килде. Ләкин һичбер атучы угының яңлыш китүеннән имин түгел иде. Хан нихәтле әйтеп караса да, кулына ышанып эшкә базучы булмады. Бар да ханның каты ачуыннан курка иде.

Шулвакыт мәргәннәр арасыннан берсе чыкты да:

— Падишаһым, солтаным! Мондый нечкә эшне эшләр кеше безнең Казан илендә әле җитешмәгәндер. Монда Агыйдел буеннан килгән атаклы бер мәргән бар. Сезнең бу олуг эшегезне ул гына башкарса башкара алыр! — дип, ханга Җикне гарыз итте[1].

Хан шундук Җикне чакыртып алды да үзенең йомышын сөйләде. Җик Казан ханлыгы кул астында шундый җиңел эшкә дә батырлыгы җиткән кешеләр юклыкны күреп көлде. Аннан соң корыч уклы көмеш җаяне кулына алды да:

— Батыр хан, мин күл өстендә тик торган кошны атуны мәргәнлегемә кимчелек саныймын. Сез элек ул кошны куркытырга кушыңыз. Ул очкан вакытта кай җиренә атарга кушсагыз, башымны алдыңызга куеп, йомышымны үтим,— диде.

Хан, яшь батырның бу сүзенә рәхмәт әйтеп, аннан соң аккошның юан каурыйсыларыннан өчесен өздерергә кушты.

Аккошны куркыттылар. Куркак кош һавага күтәрелә башлады. Ул арада Җик Мәргән дә көмеш җаянең җебен чиертте. Күп тә үтми, аккошның өч каурыйсы һавадан күлгә төште. Бичара кош та, артык оча алмыйча, күлнең бер читенә төшеп йөзә башлады.

Хан Җикнең бу осталыгы, батырлыгы өчен аңар ирек багышлап, Агыйдел буена кайтарып җибәрде. Җик, Корычка кайтып, үзенең батырлыгын ерак илләргә хәтле белдергәч, аталары янына кайтып китте.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Җик Мәргән» дастаны «Идегәй» дастаныннан алдарак иҗат ителгән. Шуны исбат итегез.

2. «Идегәй»дә яу чабу, ягъни күрше кабиләләргә, башка илләргә һөҗүм итү кешеләргә фаҗига генә китерә ала. Сугыш башлаучының

---

[1] *Гарыз итте* — тәкъдим итте.

дәлиле күпме генә ышандырырлык булмасын, ул кеше барыбер явыз кеше дип бәяләнә. «Җик Мәргән» дастанында, киресенчә, күрше халыкларны талап кайту мактала. Шул каршылыкны аңлатыгыз.

3. «Җик Мәргән» дастаны, әлбәттә, күләмле әсәр булган. Андагы вакыйгалар да, бер-берсенә тыгыз бәйләнеп, уртак эчтәлекләре белән әсәр төзелешен тудырганнар. Әмма, кызганычка каршы, дастанның күп өлешен чичәннәр онытканнар. Бу бик борынгы дастан безнең көннәргә өзек-өзек вакыйгалары белән генә килеп җиткән. Алай да аңарда дастаннарга хас үзенчәлекләр сакланган.

«Җик Мәргән» дастанын вакыйгаларга бүлегез. Вакыйгаларның һәркайсына бер яки ике генә сүз белән исем бирегез. Исем аларның темасын күрсәтеп торырга тиеш.

4. Дастанда батырларның матурлыгы ничек сурәтләнгән? Аларның батырлыклары, горурлыклары нидән гыйбарәт булган?

Легендалар

Өйрәнелә торган чор яулар, сугышлар, корбаннар белән тулган. Куәтле дәүләтләр җимерелгәннәр, яңалары төзелгән. Легендалар туу өчен, шундый тарихи үзгәрешләр кирәк тә. **Легенда дип нинди дә булса тарихи вакыйга яки шәхес турында чыгарылган ярым хыялый, ярым чын хикәятләргә әйтәләр.**

«Хан кызы Алтынчәч» легендасында, мәсәлән, борынгы заман сугышларының берсе турында әйтелә.

Идел буена урнашкан бер шәһәр ханының бик чибәр кызы булган. Күп гаскәр җыеп, күрше ханы яу белән килә. Йә кызың Алтынчәчне бирәсең, йә ханлыгыңны юк итәм, ди. Алтынчәч баскак ханга барудан баш тарткан: аңа барганчы үлемем артык, дип җавап биргән. Шәһәр кешеләре дә шундый ук горур булганнар. Үлем бәрабәренә булса да, дәрәҗәләрен саклап калганнар: кызны бирмәгәннәр. Легенда, шулай итеп, дастаннар күтәреп чыккан теманы дәвам иткән. Шуның белән бергә, легенда авторлары «Йосыф кыйссасы» эчтәлеген дә үзләренчә дәвам итәләр.

«Янмый торган кыз» легендасында Аксак Тимер гаскәрләре Болгар шәһәренә бәреп керә. Болгар ханы үзенең якыннары белән ташпулатка кереп бикләнә. Баскыннар, янына агач өеп, пулатны яндыралар. Эчтәгеләр бар да янып үлә. Ни гаҗәп: ханның чибәр кызы берүзе исән кала. Дошманнар бу хәлне күреп аптырыйлар. Легенда авторы серне болай ача: «Хан кызын болгарлар акыллылыгы һәм яхшылыгы өчен изге дип атаганнар. Тәңре кызны шуның өчен саклап калган»,— ди.

Бу елларда мәхәббәт темасына багышланган легендалар һәм дастаннар да күп иҗат ителгәннәр. Гыйбрәтле кыска хикәятләр кешеләрне намуслы, шәфкатьле булырга өйрәткәннәр.

Татар әдәбияты үсүеннән тукталмаган, «Кыйссаи Йосыф» казанышларын файдаланып, яңа темалар, проблемалар, әдәби чаралар таба-таба, һаман тирәнәйгән, камилләшкән.

Йомгак

Татар әдәбияты берьюлы ике җирлектә күтәрелә.

Гомумтөрки әдәбиятының бай мирасыннан татулык идеясен һәм мәхәббәт матурлыгын үзләштерә. Татулыкка ирешү чараларын **шәфкатьлелек, сабырлык, Аллага ышану** сыйфатларында күрә һәм кешеләрдә бу сыйфатларны тәрбияләүне үзенең изге бурычы итеп кабул итә.

Татар халык авыз иҗатыннан әдәбият туган илгә хезмәт итү бурычы идеясен һәм горурлык матурлыгын үзләштерә.

Әдәбият та нәкъ кеше кебек үсә. Башта бала кебек шат күңелле, шаян, хәйләкәр була. Дөньяны бер селтәнүдә яманнарга һәм яхшыларга бүлеп ташлый. Сабырлык, шәфкатьлелек һәм Аллага ышаныч ярдәмендә ул бик тиз арада бөтен мөселман дөньясын бәхеткә күммәкче була.

Үсә төшкәч, әдәбиятта зирәклек, сабырлык сыйфатлары арта. Ул үзе бүлеп ташлаган дөньяга әледән-әле карап тора. Карый да уйга кала. Ә көннәрнең берендә яманлык белән яхшылык арасында хаклык ятуын күреп ала. Хаклыкның яманлыкны — яхшылык, ә яхшылыкны яманлык итә алуын белеп шакката: тормыш ул уйлаганга караганда катлаулырак та, кызыклырак та, гыйбрәтлерәк тә икән! Әдәбият үзенә үзе сорау бирми булдыра алмый. Өстенлекне кайсына бирергә соң: горурлыккамы, шәфкатьлелеккәме? Хаклык кайда: горурлыктамы, әллә, горурлыкны корбан итеп, яманлыкны булдырмаудамы? Әдәбиятта проблема шулай туа. Хәзер әдәбият сокланырга, яратырга, кешеләр хәсрәтен уртаклашырга өйрәнә. Күзе үткенләнә, зирәклеге арта. Яманлык — яхшылык темасын яңадан өйрәнә, яманлыктан котылуның төрле юлларын эзли.

Шул чакта Казан ханлыгын Явыз Иван гаскәрләре яулап ала. Бу фаҗига 1552 елда була. Бу елда язучылар, чичәннәр кырыла, китапханәләр яндырыла, әдәбият үсештән туктый.

УРТА ГАСЫР ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ
(XVII—XVIII гасырлар)

Явыз Иван баскыннарына каршы татарлар батырларча сугышалар. Кремль стенасы өченче мәртәбә шартлатыла. Дошман гаскәрләре шәһәргә үтеп керәләр. Кремльне саклаучылар исә бер адым да артка чигенмиләр, сугышалар да сугышалар. Тарихчы Н. М. Карамзин, күңеле белән русларны яклаca да, мондый сүзләр язып калдырган:

«Руслар: «Алла безнең белән!» — дип, штурмга ташландылар... Үлем һәм һәлакәт сәгатендә дә татарлар батырлык һәм рухи ныклык күрсәттеләр... Алар хәзер калканнары артына качмадылар, ачык күкрәк белән сугыштылар... Безнекеләрне югарыдан бүрәнә ыргытып изделәр, өсләренә кайнар сумала сиптеләр».

Безнең борынгы бабаларыбыз дастаннарында батырлыкны, горурлыкны юкка гына зурламаганнар, алар үзләре дә горур, батыр кешеләр булганнар.

Милли горурлык хисе, буыннан-буынга күчеп, Габдулла Тукайга кадәр килеп җиткән. «Шүрәле» әсәрендә автор тезелеп киткән агачларга карый да:

Кылт итеп искә төшәдер намнары[1], дәүләтләре
Карт бабайларның, моны күрсәң, бөтен саулэтләре[2],—

димичә булдыра алмый.

Ләкин көчләр тигез булмый. Н. М. Карамзинның: «Казан Рәсәйнең хосусый милкенә әверелде»,— дигән көне килеп җитә. Татар ханлыгы дәүләт булып яшәүдән туктый. Аның халкы эшкәртелгән уңдырышлы җирләреннән, су буйларыннан куыла. Мәчетләр саны кимегәннән-кими, чиркәүләр артканнанарта. Татарларны көчләп чукындыра башлыйлар.

---

[1] *Намнары* — исемнәре, шөһрәтләре.
[2] *Саулэтләре* — батырлыклары.

Милли рухны саклап калу коллыкка төшкән халык өчен төп максатка әйләнә. Әдәбиятта да кискен үзгәреш була: хәзер аның идеаллары алышына.

Татар әдәбияты халыкны сабырлыкка чакыра. Тормыш авырлыгына түзәргә, кимсетелү-рәнҗетелүләргә чыдарга өнди.

Яманлыкка кул селтәп, үз эчеңә йомылып тынычланырга да мөмкин иде. Халыкның бер өлеше шулай итте дә. Дөньясына кул селтәде дә, кулына таяк алып, ил гизәргә чыгып китте. Андый кешеләргә «дәрвиш» диләр. Илдә дәрвишләр күбәйде. Алар ни бирсәләр шуны ашап, кая туктасалар шунда йоклап, фәкать Алла турында гына уйлап йөрделәр. Бу тормышта күбрәк интеккән саен, Аллага якыная төшәсең, күңелдә бер генә мәхәббәт — Аллага мәхәббәт кенә калырга тиеш. Шунда кеше Алла белән кушылырга тиеш була. Шул чакта гына ул бәхетле, чөнки аңа гомере буена эзләгән хакыйкать ачыла. Бу фәлсәфә XVI—XVII гасырларда татарлар арасында киң тарала. Үз эченә йомылып, дөнья мәшәкатеннән баш тарткан кешеләр фәлсәфәсенә суфичылык фәлсәфәсе диләр.

Бу фәлсәфә әдәбиятка да килеп кергән.

Тормыш яманлыгыннан хыял, хәтер дөньясына качып та котылып була. Халыкның берише шулай итә дә. Бу гасырда Чыңгыз ханны, Батыйны, Аксак Тимерне,— гомумән, Алтын Урда ханнарын һәм батырларын мактаган дастаннар күп иҗат ителә. Татар халык иҗаты жанры булган дастан кешеләргә үткән заман турында сөйләп тора. Татарларның гүзәл тарихын исләренә төшерә. Күңелләрендә милли горурлык тәрбияли. Ата-бабалар батырлыгы белән горурлану кешеләргә ныклык, сабырлык, күңел тынычлыгы бирә.

Тормыш яманлыгыннан эшләп тә котылырга мөмкин. Рухи азыктан тыш, кешеләргә ашарга икмәк, кияргә кием дә кирәк. Илне эш кешесе генә яшәтә ала. Шуның өчен әдәбиятка эш яратучы, гаилә тотучы гади кеше килеп керә.

Мәүла Колый

Мәүла Колыйның тормыш юлы билгесез. Әсәрләренә караганда, ул XVII гасыр урталарында Болгар авылларында һәм шәһәрләрендә иҗат иткән булырга тиеш.

Мәүла Колый — татар әдәбиятының ике чорын бәйләп торучы шагыйрь. Борынгы чор әдипләре кебек, ул да язган әсәрләрен хикмәтләр дип атый. Гөнаһ эшләүчеләрне җәза белән куркыта, яхшы кешеләргә оҗмах вәгъдә итә. Ул да җәмгыятьне ныгытуда иң ышанычлы ярдәмче Алла дип исәпли. Әмма шул ук вакытта Мәүла Колый, борынгы әдипләр кебек, үзенең кемлеген әйтү белән генә чикләнми, үзен шигырьләренең үзәгенә куя. Борчулары, шатлыклары, өметләре турында яза. Мәүла Колый сабырлык, мәхәббәт, Алла һәм хезмәт кешесе турында да яза. Әмма барыбер тасвирлаган вакыйгасына үзен дә катнаштыра. Яхшылык турында язса, яхшылыкка яхшылык дию белән генә чикләнми, үзенең шатлыгын да белдерә. Яманлык турында язса, борчылуын сиздерә.

Мәүла Колый, шулай итеп, татар әдәбиятына лирик герой образын кертте. Эчтәлеге хис булган лирик шигырь тудырды.

Шагыйрь иҗатындагы яңа эчтәлек, яңа герой, яңа жанр татар әдәбиятының яңа чорга атлавын хәбәр итте.

Хикмәте Хәким...

(6 нчы хикмәт)

5. Мәвеҗ кылса[1] бу күңелнең бәхре[2] кайнап,
Сабырлык көймәсенә беник, икра[3];
Су сарый чайкалмакы ул көймәнең,
Сабыр ташын иңрәтеп салса булмас.

---

[1] *Мәвеҗ кылса* — дулкынланса.
[2] *Бәхре* — диңгезе.
[3] *Икра* — дуслар.

6. Сабыр берлә гөлләр ачылыр, китәр кышлар,
Йомырткадин чыкар, күккә очар кошлар,
Сабыр берлә гәүһәр булыр энҗе ташлар,
Сабырсыздин кайнаю бән пешсә булмас.

7. Мәүла Колый, сабыр эшен гадәт иткел,
Дөнья эшен куйгыл, тагать иткел,
Хәрам йидың, харам эчтең, тәүбә иткел,
Гомерең үтте, нәчә кусаң йетә булмас.

Хикмәте Хәким...

(14 нче хикмәт)

1. Суфилык мивәләре[1] пешеп йетмеш,
Мән андыйн берәм-берәм татсам иде,
Ул мивәнең ләззәтидин мәст улубән[2]
Уздин[3] китеп, иссез булып ятсам иде.

9. Мәүла Колый, сән суфилык мәен эчсәң,
Хакъ[4] гыйшкында башың илә җандин кәчсәң,
Тәүбә кылып, Хакъка егълап, яшьләр сачсәң,
Тәмугдин Хакъ сәни ерак кыла ирде.

Хикмәте Хәким...

(64 нче хикмәт)

2. Игенчегә Хакъ рәхмәте баек булыр,
Дөньялык һәм ахирәтлек кулга килер;
Игенчене рәхман изем газиз[5] кылыр,
Кыямәттә урны җәннәт, сорар булсаң.

Беренче шигырендә Мәүла Колый кешеләрнең күңел тынычсызлыгын хикмәт белән (хәзер метафора дибез) әйтә: күңел диңгезе кайнап дулкынлана, ди. Сабырлык — суы саркыган дулкынга бирешми торган көймә, ди. Кешеләрне борчулы

---

[1] *Мивәләре* — җимешләре.
[2] *Мәст улубән* — исереп.
[3] *Уздин* — һуштан.
[4] *Хакъ* — Алла.
[5] *Газиз* — хөрмәтле.

чакларында шул көймәгә менәргә өнди. Кушмый, кагыйдә әйтми, гыйбрәтле вакыйга белән аңлатмый, үтенә, укучыларына «дуслар» дип, үз итеп мөрәҗәгать итә. Шуңа күрә шигырьнең бу өлешенә «сабырлыкка өндәү» дип исем бирәбез.

Әсәрнең икенче өлешендә сабырлыкның әһәмияте турында яза. Мисалга табигать күренешләрен китерә. Бу өлешкә «сабырлыкның әһәмияте» дип исем кушарга була.

Өченче өлештә автор үзен сабырсызлыгы өчен тәнкыйтьли. Тәүбә итә. Борчыла.

Бирем

Калган ике шигырь өзекләре эчтәлекләрен үзегез сөйләгез.

Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари (1754—1834)

Габдерәхим Утыз Имәни Чирмешән районының Утыз Имән авылында игенче гаиләсендә туган. Төрле авыллардагы һәм шәһәрләрдәге мәдрәсәләрдә укып белем алганнан соң, шагыйрь читкә чыгып китә. Башта Урта Азиягә юл ала. Бохара, Акча, Туфи, Сәмәрканд, Мәзаре, Шаһимәрдән шәһәрләрендә укый. Бер үк вакытта үзе дә укыта, зур гаиләсен, шул рәвешле, туйдыра. Җыеп санаганда, аның ун улы, ун кызы була. Гаиләсе белән Габдерәхим Әфганстанга китә. Бәлех, Һират, Кабул шәһәрләрендә белем ала һәм үзе дә укыта. Монда аның яраткан хатыны Хәмидә үлә. Хатынын шагыйрь бик хөрмәт иткән булса кирәк, аңа багышлап кайгылы шигырь (мәрсия) яза. Мәрсиядә мондый юллар бар:

Эссе чакта кием булган,
Суык чакта ышык булган,
Караңгыда яктылык биргән
Чырагымнан аерылдым.

Башыма күп бәла килсә,
Дус-ишләрем күңел өзсә,
Шул чакта да күңел өзмәс
Тугъры дустан аерылдым.

Шагыйрь, Хәмидәсен югалткач, туган ягына кайта. Авылларда мәдрәсәләр сала, шәкертләр укыта. Гомеренең соңгы көннәрен хәзерге Лениногорск районының Тимәш авылында үткәрә.

Утыз Имәни йөз дә ике исемдә хезмәт язган. Алар арасында тел, фәлсәфә, әхлак-хокук, икътисад, сәүдә, медицина, астрономия турындагы фәнни хезмәтләр дә бар.

ЧИТТӘ ЙӨРҮЧЕ ХИКӘЯСЕ

(*Хәзерге телдә эшкәртелгән варианты. Эшкәртүчесе* Әхмәт Исхак)

Хөрмәт һәм өмет турында

Йөри идем җиһанда шатланып мин,
Яши идем исән-сау һәм дә имин:
Күңелем кайгысыз, ризкым күп иде,
Дусларым күп, дошманнарым юк иде.
Һич үткәнем өчен аһ ормый идем,
Киләчәгем өчен кайгырмый идем...
Булып көн-төн галимнәр арасында,
Эшем юк иде дөнья гаугасында.
Олугълар күрсәтәләр иде шәфкать,
Кечкенәләр күрсәтәләр иде хөрмәт.
Рәхәт яши идек ярым белән дә,
Сөекле балакайларым белән дә.
Уем юк иде дошманым булыр дип,
Бу рәхәттән мине мәхрүм кылыр дип.

Җәбер-җәфа һәм горбәтчелек[1] турында

Чыгып бер дошман адәм шундый чакта,
Мине зинданга салдырды нахакка.
Кинәт юк булды рәхәт, татлы көннәр,
Сорашмады, килеп, хәлем якыннар...
Бу аерылу уты көйдерде башым,
Күземнән акты даим канлы яшем.
Әгәр килсә кешегә мондый кайгы,
Кояш та күренер булып караңгы.
Көчем бетте тәмам сабыр итәргә,
Керештем шәфкать иңгәнен көтәргә.

Кыенлыктан соң шатлык килүе турында

Бәладән соң рәхәт бер килми калмас,
Гөнаһлар бер гафу ителми калмас.
Мәкерлекне Йосыф та күрде күпме,
Нәкъ унике елы зинданда үтте.

[1] *Горбәтчелек* — сәяхәт.

Вакты җиткәч, кушып язмыш, котылды,
Мисыр иле аның хөкемендә булды.
Бу дөнья михнәте дә мәңге тормас,
Шулай ук рәхәте дә мәңге булмас.

Сабыр итү турында

Сабыр ит, син, бәла килсә башыңа,
Шөкер ит Тәңре биргән язмышыңа.
Күтәр син өстеңә килгән бәлане,
Чыда, беркемгә дә фаш итмә аны.
Сабыр итте бөекләр күп җәфага,
Ничаклы булса да түзде казага.
Сабыр иткән кеше табар камиллек,
Кыенлыклар китермәс аңа кимлек.
Моны яздым итеп сезгә васыять,
Дәва булсын, укыгыз берничә кат.

Биремнәр

1. Әсәрне өлешләргә бүлегез. Өлешләр арасындагы бәйләнешне табыгыз.

2. Әсәрдәге вакыйганың мәгънәсен әйтегез.

Йомгак

1. XII—XVIII гасырлар әдәбиятын «Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты» дип бер чорга кертәләр. Бу рәвешле гомумиләштерүнең җитди сәбәбе дә бар. Алты йөз ел эчендә татар әдәбияты бик акрын үсә: үзенең балалык чорын үткәрә. Ләкин бу чорның үз гүзәллеге, үз тирәнлеге бар. Балигъ булып өлгермәгән бала кебек, ул да үзен дөньяны бик тиз генә үзгәртергә мөмкин дип исәпли. «Ничек үзгәртик?» дип, укучысы белән киңәшеп тә тормый: үзе тапкан чаралар белән канәгатьләнә. Бу чор әсәрләренең идеяләре тормышның катлаулы вакыйгаларыннан тумый. Идеяләр хыял булып туалар һәм үзләре хыялый вакыйгалар тудыралар.

2. Бу чор әдәбиятының үз стиле дә бар: әсәрләре охшаш эчтәлекле вакыйгалардан төзелгән. Авторлар үз геройларыннан һәм вакыйгаларыннан мөмкин кадәр ераграк торырга тырышалар.

Киңәшләрен, идеяләрен вакыйгаларның нәтиҗәсе итеп әйтеп бирәләр. Шуңа күрә хикмәт жанрын бик яратып кулланалар.

3. Шуның белән бергә, бу чорның үз эчендә бер-берсеннән шактый аермасы булган өч бүленеш барлыгын күрдек. Еллар үтү белән, кешеләрнең яшәеше үзгәрә. Шуңа күрә әдәбиятта да идеяләр, темалар алмашына, яңа идеаллар туа. Шәфкатьлелек идеясен горурлык алыштыра. Горурлык матурлыгы сабырлыкка алмашына. Ләкин әдәбиятта алышынган темалар, идеаллар, стильләр бервакытта да югалмыйлар. Милли байлык, мирас булып, бер чордан икенчесенә күчә. Милләтнең бик зур байлыгы булып хәтердә саклана. Бу мирас милләт намусының, әдипләр намусының эчтәлегенә әйләнә. «Йосыф кыйссасы»нда тасвирланган шәфкатьлелек, мәсәлән, милли матурлык булып, хәзер дә хәтердә яшәп килә. Шул матурлыкның иң югары дәрәҗәсен гәүдәләндергән Йосыф образы, мәһабәт кеше буларак, хәтернең иң түрендә утыра.

4. Бу чор әдәбияты халык авыз иҗаты әсәрләре белән аеруча тыгыз бәйләнгән. Әдәбиятны һәм халык иҗат иткән әсәрләрне бу чор әдәбиятының ике юнәлеше итеп карыйбыз. Халык авыз иҗаты әдәбиятыбызга горур, батыр Идегәйне бирде. Идегәй Йосыф янына — мәһабәтләр урынына урнаша.

Татар әдәбияты халык авыз иҗатыннан катлаулы сюжет төзергә, үткен фикер алымына, метафорадан файдаланырга өйрәнде.

МӘГЪРИФӘТЧЕЛЕК

Татар халкы дәүләтен һәм иреген югалтканнан соң, ике йөз ел вакыт үтеп китә. Шул арада өч-дүрт буын алышына. Ләкин чичәннәр халык иҗат иткән дастаннарны, легендаларны, экиятләрне сөйләүдә дәвам итәләр. Борынгы бабайларның батырлыклары, дәүләтләрнең куәте турындагы дастаннарны, легендаларны, экиятләрне кулъязма рәвешендә тараталар. Шулай итеп, кимсетелгән, изелгән халык күңелендә ерак тарихтан килгән горурлык хисе буыннан-буынга күчә. Милли рух Батырша, Пугачев восстаниеләре булып тышка бәреп чыга: татар халкы кулына корал ала һәм изүчеләренә каршы көрәшкә күтәрелә. Тигезсез көрәштә ул тагын җиңелә, киселә, кыйнала һәм, үз эченә йомылып, Аллага сыенып яши башлый.

1812 елгы сугышта милләттәшләребез тагын бер тапкыр талпынып алалар. Аларда илне саклаучы горурлыгы уяна. Татарлар французларга каршы батырларча сугышалар. Мәшһүр шагыйрь һәм 1812 елгы сугыш герое Денис Давыдов: «Генерал Ермолов татарлардан гаскәр төзеде. Бу гаскәр көчлелектә, кыюлыкта һәм осталыкта алардан (чик буе казакларыннан) югары»,— дип яза.

Татарлар үзләре дә батырлыклары белән мактанып алудан тартынмаганнар:

Урамнарын тутырса да французлар Мәскәүнең,
Унике типтәр бетерде французның гаскәрен.

Французлар монда килгәч таныдылар үзләрен,
Уңда — башкорт, сулда — типтәр, табалмыйлар эзләрен.

Мәскәүгә дә кердек без, Наполеонны күрдек без,
Французны җиңгәндә, җир җимертеп йөрдек без,—

дип, бәет әйтеп йөргәннәр.

Еллар үтү белән, җәмгыять тә үзгәрә. Татарлар да феодализмнан капиталистик мөнәсәбәтләргә аяк атлыйлар. Капиталистик мөнәсәбәтләр татарларга милләт булып оешырга шарт-

лар тудыра. Милләттәшләребез сәүдә итеп, төрле илләргә барып чыгалар. Европа илләрендәге тормышны, андагы сәнгатьнең, фәннең алга китүен үз күзләре белән күреп кайталар. Милләт булып оешып алгач, кешечә яшәү өмете кузгала. Укымышлылар тагын бер кат җилпенеп алалар. Татар милләтен башка илләр дәрәҗәсенә якынайту юлларын эзли башлыйлар. Ә моның өчен белем, тәрбия, яңалыкка омтылу кирәк дигән нәтиҗәгә киләләр. Милләтне шундый чаралар белән үстерергә теләүчеләргә мәгърифәтчеләр диләр.

Кешеләрне әдәпле, белемле хезмәткәрләр итеп тәрбияләү өчен, китаплар, газета-журналлар бастыруны оештырырга, мәдрәсә программаларын үзгәртергә, татарларга югары белем алу өчен шартлар тудырырга кирәк була. Мәгърифәтчеләр, җиң сызганып, шул эшкә керешәләр. Ләкин моңа татарларның кинәт үсеп, күтәрелеп китүләреннән курыккан рус хөкүмәте аяк терәп каршы тора. Милләтнең үз эчендә дә яңалык белән бергә дәрәҗәләренә куркыныч килүен сизенгән надан муллалар, булдыксыз чиновниклар барлыгы беленә. Мәгърифәтчеләр белән властьларын саклап калырга тырышучы иске фикерле зыялылар арасында кискен көрәш башлана. Бу хәл әдәбиятта ике юнәлеш тудыра. Әдипләр үзләре күрергә теләгән татар тормышын һәм шул тормышны төзүче белемле персонажларын мактыйлар, ә иске тормышны тәнкыйтьлиләр.

Бу өлкәдә тәнкыйтьчеләр Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Гали Чокрый аеруча зур эш башкардылар.



Муса Акъегет
(1864—1923)

ХИСАМЕТДИН МЕНЛА[1]

I

«Н» карьясенең[2] ханәләре[3] гади ханәләр кебек агачтан вә башлары бәгъзән саламнан, бәгъзән агачтан ясалмыштыр. «Н» авылында ике мәчет бар. Бер урамлы авыл булып, урамы озын вә киңдер. Мәчеттән ерак түгел бер кечек ханә вар.

Бу ханә, үзе кечек булса да, тактадан башы, анбары вә никлы сарайлары хуҗасының иҗтиһатлы вә хезмәт сөйгән адәм идегене күрсәтерләр иде. Бу ханәдә менла хатыны тол Зөлхая вә угылы Хисаметдин менла атлы адәмнәр торырлар иде.

Ике-өч ел моннан элек менла Хисаметдин, төрек җиреннән белем алып, туган җире «Н»га кайтты. Хәзерге көндә өйнең бер почмагында сабыйларга дәрес бирер иде. Кайберәүләр Хисаметдин менланы яклыйлар иде, чөнки ике ел эчендә балаларына язарга, хат таныргa, хисап гыйлеме өйрәтте; әмма күп адәм менлаи яхшы белмәдекләреннән сөймәсләр иде, мәсәлән, авылның указный менласы карт Бикбулат, көнләшеп, аны сөйми иде: «Ничөн бу юләр наданга балаларыгызны вирәсез, тәүфыйктан чыгарыр, китерегез бәнем үз мәдрәсәмә...» Һәм шуның ише асылсыз сүзләр илә Хисаметдин менлаи

[1] Повесть кыскартып алынды. Аңлашылмаган сүзләрнең кайберләре хәзерге әдәби телгә күчерелде.

[2] *Карьясенең* — авылының.

[3] *Ханәләре* — өйләре.

хурлар иде. Күп халык карт менланың сүзенә шәригать сүзе кебек инаныр иде.

Хисаметдин менла хәрәкәт вә кәсеп сөйгән менла иде: ун дисәтинә җире бар иде. Гәрчә бер хезмәтче тотса да вә эш күп вакытта яз вакыты иген эшендә башка хезмәтчеләр ялласа да, күп вакытта үзе дә кара иген эшене эшләер иде.

Йөзенә баксаң, бу егерме биш яшьлек егеткә гаҗәпләнерсең. Йөзе гүзәл ачык. Яңа чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары коңгырт төстә улып матур йөзен тагы да арттыралар. Нурлы вә күк күзләре китап битенең юлыннан юлына йөгереп йөриләр. Башында бәрхет такыясының көмеш ае ялт-йолт ялтырар.

Хисаметдин менла үз милләтен, ягъни татарларны, күп сөйгән адәм иде... Хәтта Бикбулат менла аны көнләшеп дошман күрсә дә, ул һич дошман күзе белән аңа бакмаз иде. Чөнки яхшы белә иде ки, бу дошманлык көнчелектән кәлер.

Мәшһүр газетаны ачып укымая башлады: «Бер байгуш күрсәк, җанмыз агырып, кайгы хасил булыр йә үлем түшәгендә яткан бер кеше күрсәк, күземезә яшь, күңелемезә мәрхәмәт кәлер, бер миллион адәмә — бер милләтә мәрхәмәтебез юктыр. Бер кешегә нотык вә нәсыйхәт нәкадәр кәрәк исә, күп кешеләргә, ягъни бер милләтә бер каумә матбугат ул дәрәҗә кәрәктер». Бу җирдә үз-үзене тота алмаеп, менла агламага башлады.

II

Җомга намазыны укыдыктан соңра, Хисаметдин менла, атны чаная җигеп, бәгъзе кәрәк нәрсәләр алмак өчен, шәһәргә юлланды.

Юлында очраган тауга менгәндә, арттан ике ат кушылмыш бер арба җитеште.

— Бу кем алда? — дип сорады арбада утырмыш яшь әфәнде ат куучысыннан.

— Бу — тап шул Хисаметдин менла, Истанбулда укымыш. Безем менлаларга агыз ачмага да вирмәз.

Яшь әфәнде, куучыга арбаны чана илә тигезләргә боерып:

— Юл бик начар; сез кайсы яктан, әфәндем? — дип сорды.

Бәс шәһәргә җиткәнчегә кадәр яшьләр, сөйләшеп барып, юлны кыскарттылар. Әңгәмәдән яшь әфәнде гимназия укучысы улдыгы аңлашылды. Вә бу ике яшь юлчы әңгәмә дәвамында бер-берисене охшаттылар.

Хәтта ки, Хисаметдин менла гимназистны шәһәрдә барып күрергә сүз биреп аерылды. Дидекемез гимназист бу өлкәдәге бикләрдән Әбүзәр Дәүләтгилдиев исемле бәк иде.

Әмма Хисаметдин менла артыннан китик әле.

Ул шәһәрдә постоялый дворга, ягъни гавам мөсафирханәсенә төште, хуҗасы Габбас әфәнде Биктимер углы бер сәүдәгәр иде.

Атны сарай астында җирләштергән заманда, менланың күзенә гүзәл бер күренеш раст кәлде: йорт буенча бакчадан бер кыз үтеп бара иде.

Кыз урта буйлы, башында яхшы Казан калфагы киелмеш, өстендәге күк йон камзулы нәзек вә зифа буена яхшы ятып тора. Муенында саф көмеш монетлар багланмыш, вак-вак атлап барган вакытта, йомры таучык кебек ике күкрәгенә акчалар челдер-челдер орылыр, аягында — тамбурлы читекбашмак, саче вә күзләре, вә кашлары ялтыравык кара, йөзе нурлы, кызгылт-ак, борыны кечек вә гүзәл. Бу нәзек билле матур кыз менланың күзенә тәмамән күренде.

Бу кыз мөсафирханә хуҗасы кызы гүзәл вә күркәм Хәнифә исемле иде. Алла нигә шундый матурларны ярата икән! Кыз, сарай тарафына бакып, менланы күреп алды һәм оялып көлде вә тиз үк шәл илә капланды, әмма бу көлешендә кыпкызыл иреннәре, вак энҗе тешләре менланың күзеннән качмады.

III

«Н» авылына кайтамыз, хөрмәтле укучыларым. Бу авылның аргы очында бер яхшы йорт бар. Бу йорт, таштан ясалмыш улып, ике каттыр вә башы тимер илә ябылмыштыр. Бу ханә Гали бай Җаватовның йорты иде. Гали бай бу өлкәдә бөек һәм мәшһүр сәүдәгәр иде. Авылда Гали байдан сүзе үтемле кеше юк иде: ул нә диде, шул улды.

Гали бай гаиләсе илә чәй эчмәгә утырганда гына Бикбулат менла әфәнде керде. Бикбулат менла Гали байга кияү буладыр, менла кадыны Гали байның кардәше иде.

Гали байның Сибгатулла исемле улы бар икән. Бикбулат менла аны Хәнифәгә димли. Хуҗа кызга риза була. Аннары Бикбулат менла гайбәт сөйләргә күчә, кыска гына вакыт эчендә бик күп кешеләрне яманлап ташлый. Бер уңайдан Хисаметдингә дә эләгә. Аны Гали бай да, байлар белән ярлыларны бер күреп, үзен зурламаган өчен яратмый икән. Хисаметдинне, Гали байга чәйгә чакырып,

куштан шәкертләр ярдәмендә көлкегә калдырырга сүз куешалар. Шулай итәләр дә. Ләкин Хисаметдин бәхәстә җиңә, шәкертләрдән дә, Бикбулат менладан да укымышлырак, акыллырак һәм әдәплерәк булып чыга.

IV

Кыш узып, яз башы ачылдыгы илә, Хисаметдиннең тормыш итүе үзгәрде, алмашынды, ул хәзер шәһәрләргә күбрәк бара башлады. Шәһәргә барган саен, ул Габбас агайга төшәр иде вә йортта капка алдында, вә кайчакта урамда Хәнифә илә очрашырга тырышыр иде. Ә кайвакытларда теләгенә дә ирешкәли иде.

Бу килүендә Хисаметдин бик бәхетле булды. Гүзәл Хәнифәнең арынып-тарынып, киенеп-ясанып базарга чыгып баруын менла тәрәзәдән күрде. Вә берничә минуттан соңра, халыкларга сиздермичә генә, гүя үз эшенә киткән кеби, мөсафирханәдән чыкты да, бер-ике йорт кадәр китеп, Хәнифә туташны куып җитте. Вә узып китешли яшь егет әйләнеп караганда, кыз да энҗе тешләрен күрсәтеп көлеп алды... Ике яшь бер-беренә карашып бәхетле булдылар.

Кыз кибеттән чыккан вакыт, Хисаметдин, туры аңа каршы барып узганда, әкрен генә бу сүзләрне әйтеп алды: «Хәнифә туташ, иртәгә таң илә бакчада сарайдан егерме бишенче казык төбендә, таш астында бер гаҗәп нәрсә табарсыз, үтенәм, чыгып карагыз!» вә бу сүзләрне әйтеп бетереп узып та китте. Хисаметдин менла Әбүзәр бәккә юлланды.

Бу ике дус, гадәтенчә исәнләшеп, баштта аз гына гади нәрсәләр хакында сөйләштеләр.

«Ни өчен Европада мөселман динен өнәмиләр? Мөселманнар хатыннарын кол урынына күрәләр дип язалар?» — дип сорый менладан Әбүзәр. «Ялганчыдыр сәнең Аурупаң, шәригать хатыннар хокукын һич тә кире какмый; белем алу мәсьәләсенә килгәндә, Алла гыйлем алуны ир кешегә дә, хатын-кызга да фарыз дип өйрәтә, ди. Безнең хатыннар мескен булса, моңа без үзебез гаепле, ди. Инде мөселманнарның ялкаулыкларына, артталыгына килгәндә, моңа диннең бер катнашы да юк. Без үзебез гаепле дип, динне яклый. Диннең хәләл кәсепне яклавын исбатлап: «Кем дә булса хәләл кәсебеннән соң арып кич үткәрсә, аңа бүләк җәннәт булыр»,— дип, шәригать сүзләрен яттан әйтә. Заманында ислам империяләренең җимерелүе дә ислам өйрәткәннәрдән тайпылуда була дип аңлата. Бәхәстән соң Хисаметдин менла Хәнифәгә мондый хат яза:

«Җаным, Хәнифә ханым!

Нурлы йөзеңне әүвәл күрдегем илә тәэсирләндем, озак вакытлар хыялымда синең матур йөзең урын алып тора. Мине бәхетле итәчәк нәрсә синең мәхәббәтеңдер, газизем. Гыйшкыма каршы мәхәббәтеңне бирерсеңме? Әгәр мине ким санамыйча берәр юл җавабыңны бүләк итсәң, шул таш астына иртәгә ун сәгатьтә куймагыңны үтенеп калучы күңел вә җаннан гашыйк Хисаметдин».

Хатны конвертка салды вә Әбүзәр илә саубуллашып менла мөсафирханәгә китте. Ястү намазы җиткән вакытларда, ул, комган алып, гүя тәһарәткә чыкты вә, бакчага кереп, сарай читеннән егерме дүрт казык хисаплап, егерме бишенчесенә җитеп, хатны куйды вә өстенә таш бастырды. Ниһаять, зарыгып көткән икенче көн иртә булды. Вәгъдәләнмеш вакыт җитте.

Хисаметдин менла, беркемгә белдермичә, гүя йөреп килмәк нияте илә бакчага чыкты. Вә билгеләнгән казыкның янына килеп, тетри-тетри вә курка-курка, ташны күтәреп, хатны алды. Бүлмәсенә кайтып, хатны ачып укыды:

«Гыйззәтлү Хисаметдин хәзрәтләре!

Сез тугры кеше улдыгыздан ышанамын ки, сез гашыйк булгансыз, ләкин тышкы кыяфәтемә генә гашыйк булгансыз. Мондый мәхәббәт исә ышанычлы түгел, шуның өчен дә бер-беребезнең табигатьләрен вә әхлакларын аңлашып җитми торып, өзеп җавап бирергә көчем һәм батырлыгым җитмидер. Мәгълүмегез Хәнифә».

Бу хатны укып, менла фикерләр дөньясына батты.

Икенче мәртәбә хат алышканнан соң, көн урталары узгач, Хәнифә туташ тәрәзә төбендә тегү тегеп утыра иде. Көтмәгәндә урамнан тәрәзә ягына вак-төяк нәрсәләр сатучы бер венгр килеп чыкты, венгрның башында — зур кара эшләпә, өстендә кара сюртук иде. Бу венгр, Хәнифә туташка эндәшеп, ярты-йорты русча сөйләп, инә-төймә тәкъдим итте. Венгрның тавышы Хәнифәгә бер таныш тавыш кеби ишетелде. Күзләре дә, тавышы да Хисаметдин менланыкына охшыйлар, ләкин зур кара сакал, озын мыеклар Хисаметдин менланыкы кебек түгел иделәр. Хәнифә туташ башын тәрәзәдән чыгарып караганда, элек венгр татарча әкрен генә сөйләргә башлады: «Җаным, Хәнифә ханым, синең белән күзгә-күз күрешеп сөйләшмәкне йөрәгем телидер».

Ике яшь бер-берсенә якынлаштылар. Сатучыбыз, киндерен сүтеп, үзе инә вә төймәләрне күрсәтер, үзе әкертен генә колак-

тан-колакка мәхәббәт сүзләре чәчәр. Төрле сүз арасында Хисаметдин менла: «Газизә Хәнифә, синең ялгыз тышкы кыяфәтеңә түгел, шулай ук матур, күркәм холкыңа гашыйк булдым»,— диде.

— Каян белдең минем яхшы холкымны?— дип, назлы вә нечкә тавыш илә сорады Хәнифә.

— Сезнең хакта тугрылыклы кешеләрдән яхшы сүзләр ишеттем. Яшьлектән гыйлем вә укуны сөйгән кешенең әхлак вә фикерләренең яман булуы шөбһәледер. Кил, йөрәк бәгъремь, бир җавап, миңа мәхәббәт итәсеңме?

— Итәмен,— сүзе Хәнифәнең авызыннан гүя атылып чыкты.

Шулвакыт Хәнифәнең анасы, ишектән кереп:

— И кыз гына! Ни монда тубалчылар белән маташасың? Тиз бире кил, эш бар,— диеп, Хәнифә туташны чакырып алды.

Ялган венгр исә үз юлына китте.

V

Шул көн кич Әбүзәр арендага алган квартирасында бер җәмгыять булды. Бу җәмгыять өч кешедән гыйбарәт булып: бере Әбүзәр бәк, бере Хисаметдин менла вә бере теләнче ятим Мохтар иде. Теләнче Мохтарның өстендә кырык ямаулы сары чикмән, пычрак чабаталары паркетлы идәнне пычратмышлар вә чуарламышлар. Сорамак мөмкин ки, бу өч, бер-берсеннән аерылып торган кешеләр нидән берләшкәннәр соң? Бере бәк, гимназист, бере укымышлы менла, берсе гади теләнче. Нидән алар бер-беренә ярашканнар? Нидән дуслашканнар? Сәбәбе будыр ки, бәк илә Хисаметдин менланы дәүләт мәнфәгатен яклауда, яратуда булган уртак сыйфат якынайткан иде. Алар, татарны наданлык дөньясыннан коткарып, гыйлемнәр илә нурландыру кирәк икәненә һәр икесе бер үк дәрәҗәдә ышаналар иде. Ышану һәм фикер уртаклыгы булганнар арасында тулы дуслык барлыкка килүе билгеледер. Мохтарга килгәндә, бу зат, үзе галим булмаса да, боларның милләт өчен тырышып йөрүләрен аңлады.

Ятим Мохтар үзе турында болай сөйләде:

— Мине теләнчелектән тыйдыгыз, бик рәхмәт сезгә. Моннан соң бер кәсепкә тотынырмын, дусларым! Сездән бик гыйбрәтле сүзләр ишеттем, һай, ничек мин укымый калдым! Наданлык — бөек бәладер.

— Наданлыкка карама, яхшы күңелле кеше булсаң, син дә файдалы булырсың,— диде Хисаметдин менла.

— Нинди файда? Гыйлемем дә юк, милкем дә юк, һич улмаса милкем булса иде, мин аны исламиятебез файдасына һәрвакыт сарыф итәргә әзер торыр идем.

— Тугры сүз,— диде Әбүзәр бәк,— тормышта иң зур куәт — акчадыр. Бу куәт илә милләтебез мәгарифе юлында күп эш кылмак мөмкин булыр иде.

— Әлбәттә, акча илә мәңгелек шөһрәт казанмак мөмкин. Ләкин корсак тутырудан башка бернәрсә белмәгән акча иясеннән ни файда килсен. Мондыйлар кешеләргә файда итүне уйларына да китермиләр. Шуның өчен алар күмелгәч үк оныталалар,— дип аңлатты Хисаметдин менла.

— Юк, дуслар, минем акчам булса иде, атымны онытмаслар иде,— диде Мохтар.

— Кәсеп ит, бай булырсың,— диде Әбүзәр бәк.

— Һәрбер кеше кәсеп итеп бай булуны теләр иде, ләкин бай була алмый,— дип җавап бирде Мохтар.

— Теләкнең теләге бар, чын күңел илә теләп, тырышлык илә кәсеп итсәң, бай була алырсың. Чөнки кеше гакылы — бик куәтле нәрсәдер,— диде Әбүзәр бәк.

— Сүзең тугры, тырышып кара,— дип сүзгә кереште менла,— тырышкан табар, димеш хәзрәте рәсүл.

Бу өч дус, сөйләшә-сөйләшә, күп вакыт утырдылар. Кичәнең яртылары булгач, Мохтар мөсафирханәгә китте. Юлда баю турында уйланды һәм мондый нәтиҗәгә килде: «Үз гайрәтем илә, бәлки, баермын, моның өчен миңа йөз сум акча кирәк. Извозчикка хезмәткә керермен, әрсезлек вә кискенлек илә һәр көн берәр кәпик тапсаң да, баемый калырга мөмкин түгелдер».

VI

Габбас агага кодалар килә. Башкода Бикбулатны бик шатланып каршы алалар. Хәнифәне Сибгатуллага димлиләр. Хәнифә хәлне Хисаметдингә сөйли. Менла сөйгәнен тынычландыра:

— Җаным, безне кем аерыр? Мәхәббәтебез шулкадәр көчле ки, безне Гали бай да, ата-анаң да аера алмаячаклар,— ди.— Мин сине әүвәл әдәп өчен яхшылык илә сорармын. Әмма бирмәсәләр, Алланың миңа биргән куәтенә берәү дә каршы килә алмас,— ди.— Шәригатьчә дә кызларны кияүгә көчләп бирү мөмкин түгел... Безнең ихтыяр вә хөрриятебезне ала алмаслар. Җаным! Бу дөньяда иң кыйммәтле нәрсә — хөррият,— дип тә өсти.

— Хөрриятсез яшәүнең авырлыгын мин дә беләм,— диде Хәнифә туташ.

— Дөрес әйттең, җаным! Фикерең минем фикер белән уртак икән.

— Болай булса бер-беремездән аерылмабыз! — диде Хәнифә туташ.

VII

Әбүзәр бәк күп җирдә татарларның язмышы турында сөйләргә ярата. Ләкин аны аңламыйлар. Берәүләр, аңа каршы килеп:

— Без гыйлемсез, мәгърифәтсез дә яши алабыз... һөнәрле булу — яхшы нәрсә, әлбәттә, ләкин татар милләте бервакытта да һөнәр иясе була алмас, чөнки мең еллар үтсә дә, татар милләте зыялы була алмады,— диләр.

Әбүзәр бәк, мондый татарларга бик борчылып, болай җавап бирә: «Әфәнделәр, мең еллар үтте, татар зыяланмады дисез. Зыяланмадык аның өчен кем, эчемездә мәгълүмат алырга омтылышыбыз, теләгебез юк иде. Мең елларга карамагыз, белем алырга теләгебез уянса, еллар үтү белән без дә мәгълүматлы булырбыз, ләкин мең еллар үтте дип йоклый бирсәк, мең түгел янә миллион еллар үтсә дә, без искечә наданлык дәрьясында калырбыз вә һөнәрләр белмичә элеккечә хезмәтче вә кол булырбыз. Башка милләтләргә карагыз, әйтик, французларга яки немецларга: болар суда, көймәдә балык кебек йөзү түгел, һавада кош кебек оча торган машиналар ясый беләләр. Әмма безнең сукаламак илә вак сәүдәдән башка һөнәребез юк кебек... вә фәлән... фәлән». Бу хакта Әбүзәр бәк күпме генә сөйләсә дә, аны берәү дә аңламас иде.

Өметсезлектән Әбүзәр бәкне Зурколаков коткара. Зурколаков бакырчылык белән шөгыльләнә. Ислам, рус, гыйлем вә һөнәр китапларын укырга ярата. Ул Әбүзәр бәк әйткәннәр белән тулысынча килешә. Хисаметдин менла белән Әбүзәр бәк бакырханәгә керәләр. Хисаметдин менла Зурколаковның әнисе Гайниҗамал абыстайдан үзенә башкода булуын үтенә. Абыстай риза була. Ул менланың этисен яхшы белгән, шуңа күрә этисен мактый:

— Кабиләгез яхшы кабиләдер. Атаңыз яхшы, рәхмәтле менла иде. Һәрвакыт башында — чалма, кулында тәсбих иде.— Бу сүзгә каршы арыслан күз, ягъни Гайсә Зурколаков, болай диде:

— Юк, анай, тәсбихкә генә бакма, Хисаметдин менланың атасы чын кешелекле, яхшы адәм иде, эш тәсбихтә түгел, динле һәм яхшы күңелле иде, диген!

— Ай углым, нә сөйләрсең сән, әлбәттә, тәсбих вә чалмалы кеше изге кеше буладыр.

— Алай ук түгел, анай: кайберәүләрнең телендә — тәсбих, башларында — чалма, әмма исламиятләре шөбһәледер, чөнки тәсбихле булсалар да, гамәлләре дингә баштан аякка кадәр каршы.

Өч-дүрт көннән соңра Гайниҗамал абыстай Габбас агайга башкода булып барса да, Хәнифәне бирергә якын да килмәделәр.

Хәнифәне никадәр үгетләсәләр дә, Гали бай улы Сибгатуллага барырга риза булмады.

VIII

Август аеның якты бер көне иде.

— Бай туе, бай туе башланды! — дип, халык, умартадан чыккан корт кебек, өйләреннән тамашага чыга башладылар. Туй җәмгыяте урам буенча әйләнә, мылтыктан атудан, кыңгырау тавышыннан колаклар тона. Урамны төтен алды, бер сугыш купты дип уйларсың.

Кыскасы, туйның башы моңа кадәр күрелмәгән, ишетелмәгән бер сурәттә башланды.

Көндезге сәгать дүртләр иде. Кояш үзенең кызулыгын һәм нурларын чуар булып күренеп торган иген басуларына чәчә. Сабан басуы дип аталган кырларның күренеше бик гүзәл иде: солы, карабодай вә тары чәчелгән кырлар күзләргә кызгылт, аксыл, саргылт төстә күренәләр иде. Кырларның гүзәллеге шат туйчыларны янә шат итәр иде.

Туй җәмгыяте «Н» авылыннан биш чакрымнар киткән бервакытта, көтмәгәндә каршы яктан атлы бер егет килеп җитте. Бу егет, туй җәмгыятенең барудан тукталуына сәбәп булып, иң элек алда баручы Гали байның янына килеп сөйләште. Сибгатулла әфәнде исә, атасы илә хәбәрләшкәннән соң, үлек кебек агарып, кайгы вә фикерләр дәрьясына батты. Башкода Бикбулат мулла телсез калып, ни эшләргә, ни дияргә белмичә аптырап калды. Шунда Гали бай: «Кайтырга кирәк»,— дип, туйчыларга игълан итте.

Юлда күп уйланулардан соң Гали бай Бикбулат муллага карап болай диде:

— Гаҗәеп, мин хәзер булдым, туй хәзерлеген тәмам кылдым, ә алар кызларын югалтканнар. Бу ни галәмәт!

IX

Хәнифә туташ шимбә көнне кайгыда кичерде. Ничә мәртәбә бакчага, билгеләнгән казык янына чыгып керде. Шунда куйган хатының Хисаметдин менла тарафыннан бу юлы алынмаганын күреп, бигрәк тә борчылды.

— Килмәде, килмәде, һәлак булам, ахры,— дип, тирәнрәк уйга батты. Күп кенә уйланулардан соң Хәнифә туташ, бер карарга килеп, кулына беренче туры килгән киемен киеп, тәрәзә аркылы урамга сикерде. Бу яшь кызның өйдән качуы иде. Әмма кемгә, кая барырга?

— Ни булса булыр, Гайниҗамал абыстайга барып хәлемне белдерим, ул — яхшы хатын,— дип, ул туп-туры Зурколаков өенә юнәлде.

— Абыстай, үтенеп сорыймын, Хисаметдин менла шәһәргә килеп җиткәнче, мине яшереп тор.

— Ай кызым, әстәгъфирулла! Ата-анаңа итагать кирәк. Юк, юк, өеңә кайт! — диде Гайниҗамал абыстай. Тагын шуны өстәде: — Бу ни хәл, ярабби! Яшьләр ничек бозылдылар!.. — Бу сүзләр Хәнифә туташның елавын, яшен тагын да арттырдылар. Ул, яңадан көчлерәк ялварып:

— Әгәр син, абыстай, шәфкать итеп яшермәсәң, мин үзүземне үтерүгә кадәр барачакмын. Шәфкать ит, җанымны коткар! — диде. Шуннан соң гына Гайниҗамал абыстай кызны берничә көнгә өендә калдырырга риза булды һәм әйтте:

— Бак, кызым, өч көннән кая теләсәң, шунда бар, бу эшләр ярамас!

Хәнифә туташ, рәхмәтләр әйтеп, Гайниҗамал абыстайның бүлмәсендә урнашты.

X

Хисаметдин, Әбүзәр, Зурколаков — өч дус, бергә җыелып, милләт файдасы, милләт файдасы дип сөйләнүдән нәтиҗә юк, эшкә керешергә кирәк дигән фикергә киләләр. Моның өчен татар халкын фән китаплары укытып уятмакчы булалар. Халыктан акча җыялар, үзләренекен өстиләр. Кырымнан география, тарих һәм башка фәнни китаплар сатып алалар. Бу китапларны халык арасында тарату өчен, авылга Хисаметдинне җибәрәләр. Шуңа күрә ул Хәнифәгә ярдәмгә килә алмый. Авылдан кайту белән сөйгәненең югалуын белә һәм эзли башлый. Егет белән кыз очрашалар.

XI

Гайниҗамал абыстай, кызны ата-анасына вакытында тапшыра алмавына борчылып, Габбас агаларга китә һәм хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп бирә. Габбас аганың Хисаметдингә бик нык ачуы килә. Ул егетне төрмәгә яптыру нияте белән адвокатлар янына китә.

XII

Бер атнадан соң «Нун»да Хисаметдин менла өендә туй мәҗлесе булды. Габбас ага, Шәмсекамәр абыстай күп фикерләрдән соң, яхшы гына игътибар белән уйлап, каргыш һәм ачуларын ташлап, дәгъвалашудан файда чыкмаячагына төшенеп, ахырда Хисаметдин менланы кияүлеккә кабул иттеләр.

Бу туйда Габбас ага һәм Шәмсекамәр абыстайның якыннары белән бергә Хисаметдин менланың дусларыннан Гайниҗамал абыстай, Гайсә әфәнде һәм Әбүзәр бәк тә булдылар. Белешебез Бикбулат мулла никах укырга мәҗбүр булды.

Берәр ел гашыйклар «Нун» авылында килешеп һәм яратышып тордылар. Ике ел үткәннән соң, Хисаметдин менла, малларын сатып, Кавказга Тифлис шәһәренә күчте һәм гаиләсен дә шунда күчерде.

Югарыда яздыгымыз ятим Мохтар, хәзер Тифлистә мануфактура малы белән сәүдә итә, Тифлистә үзенә абруй казанды. Ул иске дусты Хисаметдин менланы үзе янына имамлыкка чакырды.

Элеккеге теләнче Мохтар, хәзер Мохтар әфәнде Хәмитов булып, Хисаметдин менлага үз акчасына мәдрәсә салдырды вә мәдрәсә шәкертләренә кесәсеннән акча түләп тора.

Башка белешләребез һәркайсы үз эшендә калдылар.

Сораулар һәм биремнәр

1. Повестьны вакыйгаларга бүлегез.

2. Аларның уртак темаларын табыгыз һәм аермаларын күрсәтегез.

3. Хисаметдин, Әбүзәр, Гайсә персонажларының уртак яклары һәм аермалары турында сөйләгез.

4. Авторга Мохтар персонажын кертү нигә кирәк булган? Аңлатыгыз.

5. Повесть татар әдәбиятына нинди яңалык алып килә? Аны алдагы чор әдәбияты әсәрләре белән чагыштырыгыз.

6. Сезгә әсәр ошадымы? Ни өчен ошады яки ошамады? Исбат итеп сөйләгез.

Повестьның төзелеше

Муса Акъегет татар әдәбиятына повесть жанры алып керә. Укып күрдегез: әсәрнең кимчелекләре дә шактый. Хәзер берәү дә идеясен күпертеп, ачыктан-ачык әйтеп язмый. Ләкин әдәбиятка кергән беренче повесть буларак, без авторга ташлама да ясарга тиеш булабыз. Ничек кенә булмасын, әдип кулыннан килгән хәтле жанр кагыйдәләрен сакларга тырышкан. Әсәренә өч сюжет сызыгы керткән: 1. Хисаметдин менла белән Хәнифә туташ мәхәббәте. 2. Ярлы Мохтарның баюы. 3. Бикбулат менланың көндәшенә каршы көрәшүе.

Гадәттәгечә, сюжет сызыкларын берәм-берәм өйрәнеп, уртак якларын, ягъни гомумиләштерү өчен нигезен табыйк.

Мәхәббәт белән бәйле сюжет сызыгының конфликт үзенчәлегенә игътибар итик. Егет тә, кыз да — укымышлылар. Аларга каршы көрәшүче кеше — надан. Иске карашлы мулла, уңган егеткә үч итеп, аны кызыннан аермакчы була. Егет белән кыз артык авырлыклар күрми генә җиңеп чыгалар, чөнки аларның белеме мулланың мәкерен дә, Гали байның акча көчен дә җиңә.

Хәзер шул гап-гади сюжет сызыгын: белемле кеше һәрвакыт алдына куйган максатына ирешә дип кыскартып әйтик. Белеме аркасында кыз да, егет тә бик тиз арада уртак тел табалар. Кызның әтисен дә, дошманнарын да җиңеп чыгалар. Икесе дә бәхетле булалар.

Бикбулат менланың җиңелүе белән бәйле сюжет сызыгына анализны үзегез ясагыз. Кыскартып, төзелешен табыгыз. Алдагы сюжет сызыгы белән уртак ягын әйтегез һәм нәтиҗә ясагыз.

Мохтар белән бәйле сюжет сызыгына тукталыйк. Егет белемле түгел. Ярлы, ләкин белемле кешеләр ярдәме белән максатына ирешә. Моның өчен аңа, акыллы кеше сүзен тыңлап, тырышлык күрсәтергә генә кирәк була. Мохтар — яхшы күңелле кеше. Үзенә яхшылык иткән Хисаметдин менланы онытмый. Аны үз янына чакыртып, мәдрәсә салып бирә. Кыскасы, яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтара.

Белемле булуны яхшылык дип автор бәясе белән бәяләсәк, повесть сюжет сызыкларында бер үк бәйләнешнең кабатлануын күрәбез. Сюжет сызыкларының уртак эчтәлеген гомумиләштерәбез. Повесть ике өлешкә — тырышлык аркасында алган белем һәм белем китергән уңыш өлешләренә бүленә.

Повестьның эчтәлеге

Башка персонажларны һәм эпизодларны табылган төзелешкә бәйләп өйрәник.

Автор әсәренең идеясен Хисаметдин менланың дусларыннан әйттерә. Искә төшерик. Дуслар бар да — белемлеләр, бар да яхшы күңеллеләр, алар бергә җыелу белән милләт турында сөйләшергә керешәләр. Теләкләре бер: татар милләтен торгынлык хәленнән чыгарып, Европа илләре дәрәҗәсенә күтәрү. Моның өчен ни эшләргә кирәк соң? Дусларның фикере дә уртак — милләтне алдынгы милләт итү өчен, бер генә терәк бар — мәгърифәт. Әмма мәгърифәтне алар өчесе өч төрле аңлый. Хисаметдин өчен ул — динне яхшы белү. Коръәндә тормыш куйган сорауларның барысына да дөрес җавап бар, ди ул. Әбүзәр өчен — һөнәр. Һөнәрле булу өчен, теләк һәм белем кирәк. Зурколаков беренче планга кешенең күңелен куя. Кеше динле дә, һөнәрле дә булырга мөмкин, ләкин күңеле яхшы булмаса, ул барыбер мәгърифәтле була алмый, ди. Бу бәхәскә, читтән торып булса да, Хәнифә дә катнаша. Аның карашынча, мәгърифәт дигәндә, беренче чиратта ирекне күз алдында тотарга кирәк.

Повесть авторы персонажларның бәхәсен конфликтка җиткерми. Асылда, персонажлар бер-берсенә каршы килмиләр, бәлки башкалар әйткән фикерне тулыландыралар гына. Шуңа күрә мондый нәтиҗә ясыйбыз: Муса Акъегет сурәтләгән матурлык ул — мәгърифәтле, эш сөюче кеше.

Каюм Насыйри
(1825—1902)

Габделкаюм Габденнасыйр улы Насыйров элеккеге Казан губернасы Зөя өязе (хәзерге Яшел Үзән районы) Югары Шырдан авылында туган. Әдипнең бабасы Хөсәен һәм атасы Габденнасыйр мулла заманына күрә галим кешеләр булганнар — китаплар язганнар. Укырга-язарга Каюм атасыннан өйрәнә. Аннары унбиш ел Казан мәдрәсәсендә укый. Монда ул гарәпчә һәм фарсыча иркен сөйләшергә һәм язарга өйрәнә. Үзлегеннән рус телен дә үзләштерә.

Мәдрәсәне тәмамлагач, Каюм Насыйри Духовное училищеда, аннары Духовная семинариядә татар теле укыта. Бер үк вакытта Казан университетында ирекле тыңлаучы рәвешендә лекцияләргә йөри. Шулай итеп, 15 ел вакыт үтеп тә китә. Шуннан соң әдип, татар балаларына рус телен өйрәтер өчен, махсус мәктәп ача. 1879 елдан алып Каюм Насыйри гомерен язучылык эшенә багышлый. Татарча өйрәнергә теләгән руслар өчен татар грамматикасы, русча өйрәнүче татарлар өчен рус грамматикасы, татарларга дөньяви фәннәр өйрәтү максатыннан чыгып хисап, география, табигать белеме атамаларын ачыклап хезмәтләр яза. Татар теленең аңлатмалы сүзлеген, русча-татарча, татарча-русча сүзлекләр төзи. Татар халкының тарихына караган материаллар, халык иҗаты үрнәкләрен җыеп һәм аларны фәнни эшкәртеп бастыра.

Каюм Насыйри 24 ел буена календарьлар чыгара. Аның календарьлары ел саен чыгып бара, күләмле була, шуңа күрә

без күрергә гадәтләнгән календарьлардан бигрәк журналга охшый. Монда ул үзенең бик күп фәнни һәм әдәби әсәрләрен, мәкаләләрен бастыра. Әдип, ни турында гына язса да, төрле фәннәрнең тормыш өчен файдалы булуына басым ясый.

Галим әдәби әсәрләр дә яза. Әсәрләрнең күбесен Көнчыгыш әдәбиятыннан тәрҗемә итә. Иң күләмле әсәренә «Фәвакиһел-җөләса фил-әдәбият» («Әдәбият турында мәҗлесләрнең җимеше») дип катлаулы исем бирә. Китабы дөнья күргәч, ул аны «Кырык бакча» исеме белән кыскартып та бастыра. Әдипнең «Әбүгалисина» әсәре белән сез 7 нче сыйныфта таныштыгыз.

«КЫРЫК БАКЧА»ДАН

Ахмаклык бәянында

Берәү бер китапта күрде: «Ахмак кешенең башы кечкенә вә сакалы зур булыр» димеш. Тизрәк көзгегә барып карады, күрде — үзенең башы кечкенә, сакалы зур. Уйлап торды-торды да: «Тукта, башны зурайтыр хәл юк, әмма сакалны кечерәйтергә мөмкин»,— дип, сакалын учлап тотты һәм учыннан артканына ут төртте. Сакалы яна башлады, кулы пеште. Абау дип, кулын тартып алды. Сакалы янып китте. Бу һәм ахмаклыгымнан икән дип, китеп урынына утырды...

Зиһенсезлек һәм аңгыралык

Бер кызны кияүгә бирделәр. Кияү кыз катына килде, күрде: кызның кулы камырлы, тырнак төпләре камыр гына. Кияве пакьлекне ярата торган адәм иде. Бер хәйлә табып: «Абау, эчем»,— дип угалана башлады. Кыз, хафа булып: «Соң ничек итик, моннан элгәре эчең авыртканы бар идеме, ни дару итә торган идең?»— диде. Кияве әйтте: «Эчем һәр заман авырта торган иде, эчем авыртканда, әни кулындагы камырны юып эчертсә төзәлә торган иде»,— диде. Кыз үзенең кулына карады: «Менә кулымда камыр бар икән, алай булса юып бирәем»,— дип, бер табакка су салып юды. «Мә, эч»,— дип, киявенә бирде. Кияве әйтте: «Әни өч катка чаклы юа торган иде»,— диде. Кыз, янә кулын ике кат юып, кул юган суын киявенә бирде. Кияве суны кулына алды да: «Аллаһка шөкер, инде эчем туктады, мә, бу суны түгеп ташла»,— диде. Кыз ни өчен юдырганын аңлый алмады.

Мин кем?

Беркөн бер падишаһ берничә кешесе белән йөрергә чыккан иде. Бер җирдә кешеләреннән аерылып ялгыз калды. Шунда бер карт очрады. Ул картка әйтте: «И бабай, син кайдагы?» — диде. Карт: «Мин шул шәһәрдән»,— диде. Падишаһ әйтте: «Бу шәһәрнең хакимнәре ничек?» Карт әйтте: «Хакимнәребез — бик кирәкмәгән усал, залим кешеләр»,— диде. Падишаһ әйтте: «Падишаһ хакында ни әйтәсең?» — диде. Карт әйтте: «Шәһәребездә моның кебек кабахәт залим падишаһ булганы юк иде, золымы белән көйдерде шәһәрне»,— диде. Падишаһ әйтте: «Мине таныймсың, мин кем?» — диде. Карт әйтте: «Юк, танымыйм, син кем?» — диде. Падишаһ әйтте: «Бу шәһәрнең падишаһы булырмын»,— диде. Карт әйтте: «Мин кем, син мине таныймсың?» Падишаһ әйтте: «Юк, танымыйм, барлык кешене кайдан танып бетерәсең»,— диде. Карт әйтте: «Мин фәлән углы фәлән мәҗнүн, көн саен ике мәртәбә шулай юләрләнеп саташып йөримен»,— диде. Падишаһ көлде дә китте.

Югалган яшьлек

Бер яшь егет бер карт кешене күрде, бөкрәеп, акрын гына бара. «Бабай, ни җуйдың?» — диде. Карт әйтте: «Әй балам, яшьлегемне җуйган идем, тапмый барам»,— диде.

Бай һәм хезмәтче

Берәүнең бер ялкау хезмәтчесе бар иде. Беркөн бу кеше хезмәтчене базарга җибәрде. Акча бирде, базардан фәлән нәрсә алып кил дип. Малай базарга китте, бик озак торып кайтты. Бай янә икенче йомышка базарга җибәрде, малай төнлә кайтты. Бай кыйнады. Хезмәтчесе әйтте: «Синең ике төрле йомышың бар икән, берьюлы җибәрү кирәк иде»,— дип, бай белән төн буе кычкырышты. Бервакыт бу бай авырый башлады. «Бар, табибны алып кил»,— дип, шул хезмәтчене табибка җибәрде. Хезмәтче китте, табибны алып килде. Аның белән янә бер кешене ияртеп килде. Бай әйтте: «Ник бу кешене алып килдең?» — диде. Хезмәтче әйтте: «Фәлән вакыт үзең мине кыйнадың, йомышка барганда, ике йомышны бетереп кил, дидең. Инде менә сиңа табиб, Аллаһ бирсен, шифа тап, үлсәң, менә сиңа кабер казучы, мине икенче мәртәбә йөртмә»,— диде.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Ахмаклык бәянында» хикәятендә авторның нәтиҗәсе төшереп калдырылды. Нәтиҗәсендә ул хикәятне гыйбрәт итеп укучыларына киңәш бирә. Автор нинди киңәш бирергә мөмкин?

2. «Зиһенсезлек һәм аңгыралык» хикәятендәге егеткә бәя бирегез.

3. «Мин кем?» хикәятендә Каюм Насыйри укучыларын нәрсәгә өйрәтә?

4. «Югалган яшьлек», «Бай һәм хезмәтче» хикәятләренең төзелешен табыгыз. Аларны хикмәт дияргә буламы?

5. Бу хикәятләрнең уртак сыйфатын табып буламы?

Нәтиҗә ясыйк. Каюм Насыйри гыйбрәтле хикәятләре, мәзәкләре белән акылның көчен, гайрәтен, тормыш итү өчен, файдасын күрсәтә. «Әбүгалисина» әсәрендә акылның намус белән бергә кушылырга тиешлеге турында яза. Шулай иткәндә генә ул кешеләргә ярдәм итә ала, ди.

Акъегет тә, Каюм Насыйри да — мәгърифәтчеләр, чөнки алар икесе дә татар халкын аң-белем бирү юлы белән генә башка халыклар дәрәҗәсенә күтәрергә мөмкин дип исәплиләр. Халыкка шуны аңлату эшенә бөтен көчләрен сарыф итәләр.

Халыкны агартуда бу әдипләр икесе ике юл сайлыйлар. Акъегет аңлы, укымышлы булуның нәтиҗәләре турында яза, Каюм Насыйри кешеләрне акыллы булырга өйрәтә.

Габделҗәббар Кандалый (1797—1860)

Шагыйрь элекке Самара губернасы Ставрополь өязе (хәзерге Ульяновск өлкәсе) Иске Кандал авылында мулла гаиләсендә туган. Кандалый 17 ел буена мәдрәсәдә укый. Яшьтән үк ул уку тәртипләреннән риза булмый: әле бер, әле икенче мәдрәсәгә күчеп йөри. Туры сүзле егет, күрәсең, надан муллалар турында ни уйлавын аларның йөзләренә бәреп әйткәндер, аны шуның өчен укудан да куалар. Шулай йөри торгач, ниһаять, укуын тәмамлый һәм 27 яшендә туган авылына кайтып мулла була.

Габделҗәббар үткен телле, шул ук вакытта нечкә күңелле хис кешесе дә булган. Шуңа күрә аның иҗатында усал сатира да, нечкә юмор да, эчкерсез мәхәббәт хисе дә чагылыш тапкан.

Габделҗәббар Кандалый заман кимчелекләрен тәнкыйтьли һәм мәхәббәт темасына яза. Мәхәббәт хисен әйтеп бирүдә аңа тиңдәш әдип юк дияргә була.

СӘХИПҖАМАЛГА

Сәңа, җаным, дога итдем,
Дога илә сәлам әйтдем,
Сәламнәрнең соңы, җанкәм,
Язып гозре кәлам итдем[1].

Сәхипҗамал, чибәрем лә,
И матурым, сөярем лә,
И белмәдем нидәрем лә,
Сагышыңны мөдам иттем[2].

---

[1] *Гозре кәлам итдем* — үтенеч сүзе әйттем.
[2] *Мөдам иттем* — озак вакытлар кичердем.

Болай торганча тик качып,
Күренгел бер күңел ачып,
Агыздин энҗеләр сачып,
Сөйләш дәю бәян иттем.
Гүзәлсең алтын алмади,
Җәмалең[1] күңлем алдади,
Түзәр хәлем дә калмади,—
Алай да күп чыдам иттем!
Синең дик сылу ярлар да,
Зифа буй, нечкә билләр дә,
И алтыным, табалмадым
Шәһәрдә, һич тә илләрдә.
Гүзәлсең бик,— Параудa[2] бер,
Күңелләргә ярауда бер,
Матурсың күз карауда бер,
Дәхи сөйләргә телләрдә.
Ирәм багындамы[3] үстең,
Йөрәгем бәгъренe кистең;
Саба йиле[4] кеби исдең
Ки сахраларда, чүлләрдә!
Сәне бик каты сөйгәнем,
Гыйшкың берлә көйгәнем,
Ни язганым, ни дигәнем —
Җәелеп беткән илләрдә.
Килә белмәсәң, и җанкәм,
Бәнемдик мелла гашыйкка,
Барырсың... юмаган
Надан бер кара мажикка.
Намаздин каты бизгәне,
Эшендин белмәс үзгәне,
Иман диеп тә сүзләми —
Тоташлай бара языкка.
Иман сүзен дия белмәс,
Дине сартын[5] көя белмәс;
Бикәч диеп сөя белмәс. —
Барырсың андый фасикъка[6].
Бу дөньяның эше сартын,
Ябыгып беткәне сартын,
Йокысы булмаган яртын
Бaралмыйдыр ла гашыйкка.
Эш эшләп унике аең,
Гомер буең, кышын-җәен,
Сызып бетеп йөрәк маең,
Каның да калмый кашыкка.
Кыекча башыңа чорнап,
Урырсың лабаса җырлап,
Кулың, битең камыл тырнап,
Юлыгып билчән ашлыкка.
Мажик ир булса юлдашың,
Күзеңдин китмәгәй яшең;
Гакыл җитмәй, азат башың
Үзең салдың ла коллыкка!
Гүяки бер бояр колы,
Боярның әмре аркылы
Эш эшләп кабарып кулы,
Саладыр акча оброкка.
Бу хәлдә кыш илә язда,
Ни иманда, ни намазда
Рәхәт күрәлмый бераз да,
Кылып гөнаһ шомлыкка.
Киеп оек та чабата,
Тузан-туфрак биләката
Йөрерсең лә баса, ката,
Төшеп зилләткә[7], гарьлеккә,
Бу хәл илә — гомер буйлай
Кулыңнан эшләре куймай,
Йөрерсең тамагың туймай,
Ки бәгъзе чакта ачлыкка.

---

[1] *Җәмалең* — матурлыгың.
[2] *Парау* — Сәхипҗамал авылының исеме.
[3] *Ирәм багы* — рәхәт бакчасы.
[4] *Саба йиле* — таң җиле.
[5] *Сартын* — өчен.
[6] *Фасикъ* — гөнаһлы кеше.
[7] *Зилләткә* — түбәнлеккә.

Эчеңдин чыкарыр сөрем,
Басар күзләреңи эрен,
Йөзеңнең тузанын, керен
Юалмассың бушау юкка.

Парау илендә төш күрдем,
Ки,бер кош тоттым,
ук аттым,—
Парау илендә бер матур
Өчен ойкымны югалттым.
Ничә кемсә ничәләр дә
Ашыйлар да эчәләр дә;
Ки, бән шул көн-кичәләрдә,
Аш үтмичә, елап яттым!
Гыйшыкыңдин, и былбылым,
Сезә төште ничә юлым;
Сагышың берлә бер елым
Бәңа тоела ки беӊ елдай.

Әгәр дә меллага барсаң,
Синең урының булыр түрдә,
Күреп дөньяда күп файда,—
Кыяматтә ки һәм гүрдә
Торып яхшы гүрнәчәдә,
Тәмам гомрең буенча да
Сөешмәктә, уенчада,
Пошына белмәссең бер дә.
Кичә-көндез бизәнмәктә,
Киенмәктә, төзәнмәктә,
Булып күркәм, чибәрлектә,
Торып мелла-галим ирдә.
Аягыңда — читек-башмак,
Башыңдадыр, ки, ак калпак,
Мамык яки ефәк калпак,—
Ки һич тә кунмаган кер дә...
Ничек тә хәтереӊ екъмас,
Уракка һәм алып чыкмас,
Кояш илә һава сукмас,
Пешекмәс һәм тәнеӊ тиргә.

Уен-көлкедә ялыксаң,
Торып бер төштә ябыксаң,
Атын җигәр, әгәр чыксаң,—
Йөртер сине һәр җирдә...
Чыкарма, җани, бу серне:
Безем бу меллалык
җирене,—
Ки җиде бабадин бирле
Килеп өзелмәгән бер дә.
Сөямен,— алмый калмам
ла!—
Моңа бавыр итәрмәүсән[1]?!
Бу үзсүзле мишәр, диеп,
Ки бер сүзне бишәр, диеп,
Уңга таба ишәр, диеп,
Ки сән сулга сүтәрмүсән?

Саба йиле, исәр булсаң,
Парау атлыгъ нәфис җайга,
Сәламемне тикергәйсән[2]
Сәхипҗамал абыстайга!
Дигел, Кандалда бер хәзрәт,
Сәңа гыйшкы төшеп кәсрәт[3]
Кичә-көндез кичеп хәсрәт,
Янып-көядер, ай-һай ла.
Нидән сән аңа килмисең?
Колакка сүзен алмыйсың?
И белмисең лә, белмисең,
Бигүк сөядер, ай-һай ла!
«Сәхипҗамал!» дип, аһ орып,
Елый тик ул торып-торып,
Сагышың дин — кибеп-
корып,
Бетеп китте лә, ай-вай ла!
Тутам бар, ди-ди уйнама,
Көтәр дип һич тә уйлама!
Хода чөн җанны кыйнама,
Сәхипҗамал абыстай ла!

---

[1] *Бавыр итәрмәүсән?* — Теләктәшлек итәрсеңме?
[2] *Тикергәйсән* — җиткер.
[3] *Кәсрәт* — артык, бик күп.

Гөлем бул, гөл агачым бул,
Йә былбыл-сандугачым бул,
Бу дәртемгә даруым бул,
Сәхипҗамал абыстай ла!
Сәнең илә аем-көнем,
Сәнең илә төшем-өнем,
Сәнең илә көнем-төнем
Үтәрдер, и абыстай ла!
Корытканың өчен теңкәм
Ахирәттә ки һәм, җанкәм,
Газабың булмасын бик кәм,—
Сәңа булсын тәмуг җай ла.
Димә бу сүзне, и җаный:
«Бу кадәр каргыйсың бәни,
Ки бән соң нишләрем сәни?»
Исем китте лә, ай-һай ла.
«Минем бар ихтыярым, дип,
Теләсә кемгә барым, дип,
Мажик булса да ярым»,— дип,
Ниятләмә, абыстай ла.
Берәү карышты Борнайда,
Тиз үк кайтты да тормай да,
Тәнендин яра китмәде,
Күзендин кара китмәде,
Морад-максудка җитмәде,
Ки, һичшиксез, ул ук кына.
Акып күз яшьләре чишмә,
Ике күзе булып шешмә,—
Сән аның көненә төшмә,
Ишет, аңла, тудык[1] кына.
И тудык, тумачи гына,
Юлыкма ир ачыгына[2],
Соңгы кайгы, ачы гына,
Йотарсың улубән бүрә[3].
Җибәргән вактыйда куып,
Еларсың эчеңи уып:
«Анадин нигә генә туып,
Үсеп булдым җүләр-дурә!»
Бәне бик сөйде бер мелла,
Килеп сорады һәр елда,
Карыштым аңа һәр юл да,
Булып нәфсемә мәгърурә[4].
Диер ирде: «Кеше сүзенә
Бакып хур булма, и дурә!»
Атам-анам да бик кырку,
И каршылар ла сүз кырку,
Яшем төшмәкидин курку,
Ки һич булмады мәхтурә[5],
И-и, и генә лә, и генә,
Ни булды мәңа, ни генә?
Буласы кеше би генә,—
Булып калдым ла кол гына.
Ки барсам иде бигә лә,
Эшем китәрди игә лә,
Бу надан иргә нигә лә
Барып калдым ла тол гына?
И бу мелла, и бу мелла,
Күтәреп ике кул гына,
Дога кыйлмаса ни була?—
Бәне каргады шул гына.
Калып сүзләренә таңга,
Инанмаган идем аңа,
Ни әйткән сүзләре миңа,
Килүбән булды шул гына!

* * *

И-и, и генә лә, и генә!
Ни булды миңа, ни генә?
Эшемдә юк ла көй генә,
Никадәр язамын хатлар!
Ничек табыйм ла көй генәм?
Сөйләп бир, җанеки генәм!

---

[1] *Тудык* — туганым.
[2] *Ир ачыгы* — ир яманы.
[3] *Бүрә* — шелтә.
[4] *Мәгърурә* — горурлы.
[5] *Мәхтурә* — искә, хәтергә алучы.

Матурым, җанеки генәм,
Язып җибәр дәхи хатлар!
Ничә кәррә язам пуштым,
Сәңа китермәгә куштым,
Хатым җитмәдеме, дустым,
Йә килешмәде сәгатьләр?!
Йә сурәтең ясатырга барыйм
Микән лә нәкъкашка[1]?
Йә үзеңне алыйм микән
Тотарга күз белән кашка?

Кыйтга[2]

Бу гыйшыклык чабы китте
Сарату берлә Нижнайга;
Бу гыйшыклык бәетләре
Безгә калды ла вечнайга.

Кыйтга

Бу гыйшыклык чабы китте
Сарапул берлә Самарга;
Йосыф берлә Зөләйха тик,
Атымыз калды санарга.

Кыйтга

Бу гыйшыклык чабы тулды
Мамадыш берлә Малмыжга;
«Сәхипҗамал бәңа
гашикъ»,—
Диеп бик атка калмыш ла!

Кыйтга

Бу гыйшыклык чабы китте
Хавалинга да Зөягә;
Укы гыйшык бәетләрен,
Кушып «Мөхәммәдия»гә!

* * *

Бу сүзне әнкәңә сөйлә,
Сәхипҗамал, и җанкәй лә;
Бәне шул меллага биреп,
Ярәшсәнә, и әнкәй лә!
Үзе галим, үзе мелла,
Үзе бик сөядер, валлаһ!
Ничек итим лә, ух Аллаһ!
Сөямен бик, и әнкәй лә!
Ярамам, әнкәй, суярга,
Итем тозлап куярга,
Шул ук та бәни бер ярга
Ярәшерсез, и әнкәй лә!

* * *

Кавышыйк инде бу айда,
Вакыт җиткән, и җанкәй лә!
Йә күп елга, күп айларга
Ирадәң[3] бармы сайларга?
Йә меллага, йә байларга
Барырмусән, и җанкәй лә?
Болай бездин, и җаный ла,
Бик артык тарса[4] ярый ла.
Йә бездин ким вә тарый ла,
Белә алмассың, и җанкәй лә!
Биреп сыртың билә кырының,
Күтәреп торма бик борының,
Ки белмәссең ничек урның —
Барыр җирең, и җанкәй лә.
Һаваланмакың, и Биби,
Ки һич тә файдасыз зиби[5],
Ки бән дәхи сәнең кеби
Һаваландым, и җанкәй лә.
Үземгә тапмадым тиңне,
Тик эстәп кашкалы-миңле,

---

[1] *Нәкъкаш* — рәссам.
[2] *Кыйтга* — өзек.
[3] *Ирадәң* — теләгең.
[4] *Тарса* — очраса.
[5] *Зиби* — матурлык.

Юлыктым аңлы да миңле,
Җүләр ярга, и җанкәй лә.
Отыйм дигәндә — отылдым,
Тотыйм дигәндә — тотылдым,
Соңындин көчкә котылдым —
Ки биш ел соң, и җанкәй лә!
И-и, и генә лә! И генә!
Эшем дә булды чи генә!
Сәбәп кенәсе ни генә,—
Бәян итсә, и җанкәй лә!
Бу нидән булды чи генә?
Эшем дә җитте чигенә,
Сәхибем кире чигенә,—
Исем китәрде, җанкәй лә!
Дисәгез лә: «Чигенмәсен,
Котырткан сүзгә күнмәсен,
Соңы көндә үкенмәсен!»—
Бик әйтегез, и җанкәй лә!

Поэманың үзенчәлеге

Поэма дип сюжетлы, озын, нинди дә булса җитди проблемага багышланган тезмә әсәргә әйтәләр.

«Сәхипҗамал» — озын, җитди проблемасыз тезмә әсәр. Бүгенге таләпләр белән бәя биргәндә, аның әле поэмаларга хас сюжеты юк.

Кандалый сюжетны әсәрнең традицион төзелешен кабатлау белән алыштыра.

Әдип лирик поэма татар әдәбиятының традицион төзелеше белән дә канәгатьләнә ала дип исәпли. Поэмасын укучыларга яхшы таныш булган яман эшкә — җәза, яхшы эшкә — яхшылык өлешләрен каршы куеп яза. Сәхипҗамалның муллага кияүгә чыгарга ризалык бирүен яхшы эше дип бәяли. Әгәр шул яхшылыкны эшләсә, аның матур нәтиҗәләр китерүен кайта-кайта яза. Мулладан баш тартуын, киресенчә, яман эш дип бәяли. Бу ниятнең ямьсез нәтиҗәләре турында да кат-кат яза.

1. Поэмадагы шул урыннарга тагын бер тапкыр күз салыгыз. Сәхипҗамалны һәр ике очракта ниләр көткәнен үз сүзләрегез белән сөйләгез.

Надан кешегә кияүгә чыгу китергән җәзаны автор Борнай авылындагы кыз мисалында да дәвам итә. Борнай кызы да надан мужикка кияүгә чыккан. Ул да акыллы кеше сүзенә колак салмаган. Тиздән җәзасын да алган. Михнәткә түзә алмыйча, кире әйләнеп кайтты, тәненнән яра китмәде, күзеннән яшьләре чишмә кебек акты, ди автор.

Яман эшкә — җәза төзелешен Кандалый өченче мәртәбә, бу юлы Алла җәзасы итеп кабатлый: кызны теңкәмне корытканың өчен тәмуг утында янарсың дип куркыта.

Поэма төзелешенең традицион өлешендә әллә ни яңалык күренми. Әмма еллар үтә тора, әдәбият үсеше дәвам итә.

Шагыйрьләребез, Көнчыгыш сәнгатен өйрәнү белән генә канәгатьләнмичә, бөек рус әдәбиятын да үзләштерәләр. Габделҗәббар Кандалый да поэмасына чын мәгънәсендә лирик шигырь эчтәлеген һәм төзелешен сала. Поэманың яңалыгы да, гүзәллеге дә — лирик герой хисләрен сәнгать алымнары белән сурәтләп бирүдә.

Кандалыйга кадәр бер татар язучысы да мәхәббәт хисен аның кебек дулкынланып, гасабиланып, түзеп тормаслык дәрәҗәдәге хәсрәт итеп яза алмады.

Мәхәббәт хисенең сәбәбе — яраткан кешенең күркәмлеге. Габделҗәббар Кандалый Сәхипҗамалның фәкать тышкы матурлыгы турында гына яза. Ул гади авыл кызының чибәрлеген тасвирлый. Сурәт ясый. Ярдәмгә саба җилен дә, сахра чүлләрен дә, асылташларны да чакыра. Ләкин табигать күренешләре элеккечә чагыштыру вазифасын гына үтәмиләр, алар яңа мәгънә алалар, метафора булып киләләр.

2. Лирик герой хисенең дәрәҗәсе һәм сәбәбе күрсәтелгән урыннарны табыгыз. Аларга сәнгать табышы буларак бәя бирегез.

Шагыйрь юану өчен дә яңа алымнар таба. Турыдан-туры таң җиленә дусты итеп мөрәҗәгать итә:

Саба йиле, исәр булсаң,
Парау атлыгъ нәфис җайга,
Сәламемне җиткергәйсән
Сәхипҗамал абыстайга!

Поэма традиция белән яңалыкны янәшә куеп язылган әсәр буларак кызыклы.

Биремнәр

1. Поэманы өлешләргә бүлеп, гадиләштереп күз алдына китерү бик мөһим. Тема үзгәргән саен, яңа өлешкә исем бирә барабыз да аннары, охшашларын гомумиләштереп, бергә кушабыз. Бүлүне болай башлыйбыз:

1. Сәхипҗамалның матурлык дәрәҗәсе турында.
2. Лирик геройның хисе турында.
3. Сәхипҗамалның яман эш эшләү ихтималы...

Калган өлешләрен үзегез табыгыз. Охшаш эчтәлекләрен гомумиләштерегез.

2. Вакыйгалар бәйләнешеннән поэманың темасын, идеясен табыгыз.

3. Авторның лирик героена мөнәсәбәте турында сөйләгез.

4. «Сәхипҗамалга» поэмасындагы һәм «Хисаметдин менла» әсәрендәге мулла образларын чагыштырыгыз. Бу әсәрләрнең охшаш якларын табыгыз.

5. Габделҗәббар Кандалый иҗаты белән Муса Акъегет иҗаты арасындагы уртаклыкны һәм аерманы табыгыз.

Нәтиҗә ясыйк. Габделҗәббар Кандалый да, чордаш әдипләре Мәүла Колый, Каюм Насыйри, Муса Акъегет, Гали Чокрый, Акмулла кебек, мәгърифәтче булган. Татар милләтенең үзаңын укымышлы муллалар ярдәмендә уятырга мөмкин дигән фикердә торган. Мәгърифәтчелек карашын ул да, күпчелек әдипләр кебек, наданлыкны тәнкыйтьләп раслаган.

Габделҗәббар Кандалый бу чорда иң күренекле шагыйрь булган. Кешеләрнең мәхәббәт хисен ул дөньядагы иң зур матурлык дәрәҗәсенә күтәргән. Хисләренең тирәнлеген, байлыгын сөйләп бирү өчен, берсеннән-берсе гүзәлрәк сурәтләр, ягымлы сүзләр, өр-яңа чагыштырулар таба алган.

— Әя агач, яшең күпме?
Түгелгән җимешең күкме?
Миндәгедәй сагышың күпме?—
Диеп сорыйм ки алардан.
— Ничә җимешләрең үсте?
Ничә яфракларың төште?
Ботакларың кемнәр кисте? —
Диеп сорыйм ки алардан.

«Бу бәхетләр бетәр микән?» шигырендәге өзектә кабатланып килүче сораулар, агачларга турыдан-туры эндәшү, пауза, тыныч кына хикәяләү (Диеп сорыйм ки алардан) чиратлашып килә. Бай интонация лирик герой сагышын бик куәтле итеп ача. «Ботакларың кемнәр кисте?» — дип, агачка теләктәшлек белдертеп эндәшкәндә, үз хәсрәтенең сәбәбенә дә ишарә ясый. Бик талантлы шагыйрьләр генә кеше хәсрәтендә дә матурлык күрә beləлəр. Мәхәббәт хисләрен мәгърифәтчелек идеяләре белән бәйләсә дә, Кандалый мәхәббәт матурлыгын үзкыйммәткә ия булган матурлык итә алган. Бу — аның зур казанышы.

Габделҗәббар Кандалый — үзеннән-үзе көләргә курыкмаган эчкерсез, киң күңелле әдип. Ул үзенең мәхәббәт хисләрен кешеләрдән яшерергә уйламый да. Киресенчә, кызларга язган хатларын кулъязма хәлендә башкаларга бирә. Башкалар аларны күчереп алалар да тагын кулдан-кулга өләшәләр. «Кыйтга» дип исемләнгән бүлекчәләрендә Кандалый үз әсәр-

ләренең Өфегә, Казанга, Сембергә, Саратовка, Сарапулга, Самарага, Буага һәм башка шәһәрләргә таралуы турында яза. «Бу гыйшыклык бәетләрен олуглар укый уңгайда»,— ди. Шуңа күрә бу хатларның эчтәлеге автор һәм Сәхипҗамал, автор һәм Бәдига, автор һәм Фәрхи мөнәсәбәте белән генә чикләнми. Поэма-хатларында Кандалый беренче чиратта үзенең укучысы белән диалогка керә. Укучыларын истә тотып, үзенең лирик героена да, лирик герой яраткан кызларга да бәя бирә. Автор буларак, лирик героеның мәхәббәтенә соклана һәм шул ук вакытта аңардан рәхәтләнеп көлә.

МӘКӘРҖӘ БӘЕТЕ

(Бәетнең авторы билгесез)

Сезнең өчен дәгелдер бу нәсыйхәт,
  Бәнем үзем өчендер бу нәсыйхәт,
Боның берлә үгетләймен үземне,
  Гаепкә алмаңыз бәнем сүземне.
Бу дөньяның мисалы бер Мәкәрҗә,
  Җыелыр адәм халкы анда барча;
Алырлар анда һәр урын каюсы,
  Үзенең хәленә лаек камусы[1],
Тырышып бәгъзесе сәүдә кыйладыр,
  Үзенең өлешен һәр көн аладыр,
Һәм исраф итмәс анда үзе бер пул[2],
  Җыеладыр бәс аңа анда күп пул.
Фикер итеп йөрер ул үз халене,
  Урынсыз йиргә сарыф итмәс малыны.
Качан ярминкәсе ахырга йиткәй,
  Сөенеп кайтыр ул күп маллар илә,
(Угыл-кызларына пиш кешләр[3] илә.)
  Гаме булмас аның һичбер бурычтан,
Котылыр ул барлык куркынычтан.
  Дәхи бәгъзе кешеләр анда бардыр,
Үзенә ул яман юлдашлар алыр,
  Бозык эшләрне кылыр ул һәмишә,
Яманлыкта йөрер иртә вә кичә.

---

[1] *Камусы* — һәркайсы.
[2] *Пул* — акча.
[3] *Пиш кешләр* — яраклы нәрсәләр.

Ашап-эчеп улубән мәст сәкран[1]
Орыш-сугыш вә гафләт[2] берлә һәр ан;
Ни өчен килдегене белми һич,
Танымас, бәлкем, ул көндезме йә кич?
Сату-сәүдәдә булмас һич сагышы,
Шуның чөн булмас анда һич табышы.
Качан ярминкәнең ахры йитсә.
Халаек барчасы йортына китсә,
Хисап итеп караса, кала хәйран,
Үзенең кыйлдыкына малыны вәйран[3].
Дия хәсрәт белән мин килмәсәмче,
Чү килдем мин бу эшне кыйлмасамчы.
Бу халь белән ничек кайтып китәем,
Бурычымны нихаль итеп түләем?
Тәмам хәсрәт илә кайтып киләдер,
Җәмәгате аны күреп көядер.
Җәмәгатьләренә һичбер бүләк юк,
Угыл-кызларына һәм кучтәнәч юк.
Бәс имде аңласаң ярминкә хален,
Дәхи сән аңлагыл бу дөнья хален.
Адәм угланнары монда килептер,
Тәмам дөнья алар белән тулыптыр.
Тотыптыр һәрберсе бер ватанны[4],
Үзенең халенә лаек мәкянне[5],
Вәләкин ул ватан мәңгелек ирмәс,
Аның вәгъдәсене һичберсе белмәс.
Асыл ватан түгелдер бәс бу дөнья,
Гөман итмә минеке дип бу дөнья.
Синең кеби ничәләр үтте-китте,
Ничә шаһлар, нәбиләр үтте-китте.
Бу үлемнән котылмыш кемсә юктыр,
Бәс аны татмаен һич чара юктыр.
Бәс имди фикер кыйлгыл үз халеңне,
Бу дөньяга ни өчен килгәнеңне,

---

[1] *Улубән мәст сәкран* — исереп.
[2] *Гафләт* — ваемсызлык.
[3] *Вәйран* — бетү.
[4] *Ватанны* — туган җирне.
[5] *Мәкянне* — урынны.

Гыйбадәт кыйлмага килдек Ходага,
Итагать кыйлмага килдек Ходага.
Ни боерса Ходаем, аны кыйлгыл,
Нидән тыйса сине — андин тыелгыл.
Юмартлык кыйл, саранлык кыйлмагыл һич,
Әдәплек кыйл, тәкәббер улмагыл һич.
Үлемне һаман яныңда белгел,
Аның иркенә керәсеңне дә белгел.
Халыкның изгелеген күреп ияргел,
Яманнарны күреп гыйбрәтне алгыл.
Үлем килмәс борын кыйл изгелекне,
Әгәр бер кемсәнә дөньяга килсә,
Ни өчен килдекене анда белсә,
Ходаем нә боерды — аны кыйлса,
Дәхи тыйганнардин ул тыелса.
Зарарны кыйлмаса гади халыкка,
Бирелмәсә ул яман холыкка.
Әҗәл килсә, түкәнсә гомере аның,
Якын булса үлемгә хале аның,
Сөенечкә фәрештәләр килерләр,
Сөенечне аңа ул дәм бирерләр.
Сиңа юктыр бу көндин соң яманлык,
Синең эшең һәмишәдер әманлык.
Имин син имде тәмуг михнәтеннән,
Насыйбтыр сиңа җәннәт нигъмәтеннән.

* * *

Әгәр бер кемсәнә дөньяга килсә,
Ни өчен килдегеннән гафил улса,
Дәхи ул изгелекне кыйлмаса һич,
Яманлык эшләсә ул иртә вә кич,
Качан гомере фәна улса[1], төкәнсә,
Газап фәрештәләре аңа килсә,
Фикер йөртер үзенең үлмәгене,
Караңгы, тар кабергә кермәгене.
Кабердә һәм газапта ятмагыны,
Торубән һәм кабердин дерелмәгене.

---

[1] *Гомере фәна улса* — гомере бетсә.

Дия бәс дөньяга килмәсәмче,
Чү килдем[1] бары кеше улмасамчы.
Чү кеше булдым, балигъ улмасамчы,
Чү улдым, тик яман эш кыйлмасамчы.
Бонның тик күп үкенгәй ул заманда,
Вәләкин ул үкенмәктә ни файда?
Бу дөньядин үтеп китмәкнең хале —
Сәфәрдин йортына кайтмак мисале.
Бәс аңладыңмы минем әйткәнемне?
«Бу дөнья Мәкәрҗә кебек» дигәнемне?
Бу дөньяда ни гамәлне кыйлырсың —
Кыяматтә җәзасыны күрерсең.
Әгәр изгелек итсәң дөньяда син,
Кыяматтә һәм изгелек күрерсең.
Әгәр бу дөньяда кыйлсаң яманлык,
Бәс ул көндә табарсың һәм яманлык.
Бу дөньяда әгәр син хаким улсаң,
Гаделлекне кыйла күр кадир улсаң.
Залимне хаким итмә халыкка, зинһар,
Сиңа оят китерер ул кыйлыр хар[2].
Аның белгән эше халыкка зыяндыр,
Зыяны һәм аның утдин ямандыр.
Әгәр бер кемсәнә асраса этне,
Һәмишә кыйлса аңа тәрбиятне,
Хуҗасы тәрбият кыйлса һәмишә,
Ул эт кыйлса усаллыкны пишә[3],
Чыгып торса ул эт һаман урамга,
Үтеп киткән кешеләрне таларга,
Өзеп алса кешеләрнең итәген,
Яки тешләсә аларның беләген,
Яки талап үтерсә ул кешене,
Һәмишә куймаса ул үз эшене,
Белеп торса хуҗа аның һәммәсен,
Дәфгы кыйлмаса[4] ул этнең бәласен,
Җавапны сорамаслар ул этдин,

---

[1] *Чү килдем* — килгән тәкъдирдә.
[2] *Хар* — хурлык.
[3] *Пишә* — эш, шөгыль.
[4] *Дәфгы кыйлмаса* — бетермәсә.

Җавапны һәм алмаслар ул этдин.
Хуҗасына килер аның ояты,
Җавапны хуҗасыннан сорарлар,
Хурлау вә шелтәне аңа кыйлырлар.
Ушандук тәрбия кыйлсаң залимне,
Хаким кыйлсаң халыкка бер залимне,
Син аны тыймасаң яман холыкдин,
Аның золмын китәрмәсәң халыкдин,
Сиңа булыр ояты һәм сөале,
Кыямәттә гөнаһы һәм вәбалы[1].
Залим исмен куярлар сиңа бик тиз,
Залим исмең үзеңдин соң калыр тиз.
Үлемнең вакыты килсә үкенерсең,
Үзеңнең һәм ни кыйлганыңны күрерсең.
Бәс ул вакыт үкенмәк лаек улмас
Һәм анда үкенүдән файда булмас.
Бәс имде түбәне хәзер кыйлаек,
Һәм Аллага гыйбадәтне кыйлаек.
Безнең гыйсъяныбызны[2] күрәдер ул,
Һәммә әхвәлемезне беләдер ул.
Гөнаһмыз күп булды, тулды дөнья,
Шуның чөн фетнә белән тулды дөнья.
Гөнаһ чөн бирә безгә сәзаны[3],
Гамәлләребезгә лаек җәзаны.
Аны үз фигыльләремездән күрәбез,
Үзебезнең гөнаһдин дип беләбез.
Аның чөн кешегә үпкәмез юк,
Сабырлык гайре һич дәрманымыз юк.
Шуның чөн фетнәләргә мөбтәлямез[4],
Шуның чөн залимнәргә мөбтәлямез.
Шуның чөн дөньяда безләр фәкыйрьбез,
Шуның чөн залим кулында әсирбез.
Шуның чөн без һәмишә куркынычлык,
Шуның чөн күрмибез һичбер тынычлык.
Шуның чөн золым итә безгә залимнәр,
Шуның чөн җәбер итә безгә хакимнәр.

---

[1] *Вәбал* — гөнаһ, язык.
[2] *Гыйсъяныбызны* — җинаять кылуыбызны.
[3] *Сәзаны* — тиешлесен.
[4] *Мөбтәлямез* — дучар булабыз.

* * *

Бу өязне кыйлыплар өчкә кыйсмәт[1],
  Аны бүлүдә бар, әлбәттә, хикмәт.
Куеплар аларга үзе бер әмирне,
  Җәфа кыйлыр кечене вә һәм кәбирне[2].
Атаплар аның атыны пристав,
  Төн-көн кыйла халык аннан тәәссеф[3].
Белә алмаймын аларның исмене һич,
  Мәгәр бере Фулкин Әлаксий Федорович,
Золымлыкта барыннан әкмәледер[4],
  Җинаятьтә барыннан әгъләмедер[5].
Аны куюдан максат халыкка әмандыр[6],
  Вәләкин боларның фигыле ямандыр.
Качан яз көне ирешсә халыкка,
  Җыйдырадыр иманадин йомырка.
Дәхи җәй йитсә җыйдыра тәкәләр,
  Тәкә булмаса, сарыкларны итәләр.
Аның бу эше имәс елда якьбар[7],
  Кыйла, бәлкем, аны тәкрар-тәкрар.
Халыкның атыны угырлап алалар,
  Дәхи үзенә һәм кире саталар.
Ярым хакка аны үзе аладыр,
  Аны алмаса, һич атсыз каладыр.
Аның хезмәтендә бардыр хадимнәр,
  Һәммәсе бер-беридин артык залимнәр.
Өязгә чыгарга боера аларга,
  Халык арасында фетнә табарга.
Алар үзләре һәркайсы надандыр,
  Дәхи үзләренең фигыле ямандыр.
Салым вакыты качан йитсә түләргә,
  Гавам халкы йитәләр бәс үләргә.
Җыелып киләләр һичберсе калмай,
  Һич эшне кыйлмайлар акчаны алмай.

---

[1] *Кыйлдылар кыйсмәт* — бүлделәр.
[2] *Кәбирне* — олыны.
[3] *Тәәссеф* — хәсрәт.
[4] *Әкмәледер* — иң зурысы.
[5] *Әгъләмедер* — иң яхшы белүчеседер.
[6] *Әмандыр* — тынычлык урнаштырудыр.
[7] *Имәс якьбар* — күп кабатланыр.

Хәзерләнсә халык укырга намазны,
  Хода хәзрәтенә кыйлырга ниязны[1],
Йибәрмиләр аны намаз кыйлырга,
  Вакыт чыкканчы боералар торырга.
Берәү кыйлса бу дөньядин рихләт[2],
  Аның малын бүләргә юк рөхсәт.
Аңа окружныйдан хаҗәттер приказ,
  Йөрергә анда акча йитмәй, бик аз.
Әгәр кыйлсак болар хален хикәят,
  Ардырырмын, озын булыр шикаять.
Фәһемле кемсә сүзне камил аңлар,
  Гакыллы кемсә аздин күпне аңлар.
Түрәләр үзләре кыйлса угырылык,
  Халыкта качан булгай тугрылык?
Әгәр белсә иде моны министр,
  Ясар иде бу эшкә бер реестр.
Әгәр белсә иде моны санатлар —
  Падишаһ хәзрәтендә кул-канатлар,
Качан разый булырларди бу эшкә,
  Гаҗәп хәйран калырларди бу эшкә.
Әгәр белсә иде моны үзе шаһ,
  Камил шәфкатеннән дир иде «аһ!»
Кыйлыр иде залимнәргә сәясәт,
  Белер иде бу эшне бик кабахәт.
Зәгыйфь вә мескен булса да рәгыйять[3],
  Падишаһ хәзрәтенә кыйла хезмәт.
Тәмам ихлас илә хезмәт итәләр,
  Угылларын вә малларын бирәләр.
Ки хәтта мал түгел һәм үзләрене,
  Бирәләр җаннарын вә тәннәрене.
Аларда юктыр касды җинаять[4],
  Олы әмергә шаһка һич хыянәт.
Разыйдыр алар һәрбер казага,
  Кыйлырлар сабырны һәрбер бәлагә.
Беләләр һәм бу дөнья нидекене,

---

[1] *Ниязны* — ялваруны.
[2] *Кыйлса рихләт* — үлсә.
[3] *Рәгыйять* — халык.
[4] *Касды җинаять* — җинаятькә омтылыш.

Бу дөньяга ни өчен килдекене.
Бу дөнья йорты михнәт идекене,
Дәхи мөэмингә зиндан идекене.
Анда дөреслек юклыгыны
Һәм аның һич бәһасе юклыгыны,
Аның бетүенең тиз идекене,
Сабыр һәм бик газиз шәй идекене.

1860 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Мәкәрҗә вакыйгасын өлешләргә таркатыгыз. Өлешләрнең эчтәлекләрен сөйләгез.

2. Мәкәрҗә вакыйгасы турыдан-туры бәйләнешкә кергән башка вакыйганы табыгыз. Бер үк нәрсә сөйләгән бу вакыйгаларда Мәкәрҗә вакыйгасының нигә кирәклеген аңлатыгыз.

3. Эчтәлекләре уртак булган вакыйгаларны, бергә кушып, бер вакыйгага калдыра алабыз. Эчтәлеге башка булган вакыйганы әйтегез. Алар арасында бәйләнеш табыгыз.

4. Шул рәвешле, бәет икегә бүленә. Алар арасыннан төп вакыйганы табыгыз һәм соңгысына анализ ясагыз.

5. Эт һәм аның хуҗасы турындагы вакыйганың нигә кирәклеген аңлатыгыз.

6. Әсәрдә татар халкының рус патшасына тугрылыгы турында языла. Авторга бу мәхәббәт турында язу нигә кирәк булган?

7. «Мәкәрҗә бәете»ндә мәгърифәтчелек идеясе бармы?

Идрис Багданов

ПОМАДА МӘСЬӘЛӘСЕ

Пьеса дүрт пәрдәдә, биш мәнзарәдә

КАТНАШАЛАР:

Сәлим бай — 60 яшендә, зур татар бае. Ак сакаллы, кызыл битле, юан кеше. Гайрәтләнеп кычкырып сөйләшә, утырганда терәлеп, күкрәген киереп утырадыр.

Нигъмәтулла бай — 48 яшендә, сакалы агара башлаган, авыр бәдәнле кеше.

Газизә — 48 яшендә, Нигъмәтулла хатыны, арык, сөйләшкәндә, күңеле бозылган төсле булып, ачы тавыш белән сөйләшә.

Вәлиулла — 45 яшендә, Нигъмәтулланың кардәше, кара сакаллы, бик юан түгел.

Рәхмәтулла — 40 яшендә, юан, көләргә һәм күп сөйләргә ярата торган кеше, һәркемгә хәерхаһ кеше.

Касыйм — 60 яшендә, сакалы кырган, русча киенә, тел очы белән сөйләшә.

Мифтах хаҗи — 58 яшендә, бик арык, нечкә күкрәкле кеше, сакалы агарып җитмәгән.

Галиәкбәр хәзрәт — 60 яшендә, ак сакаллы юан бер мулла, һәрбер сөйләгән сүзен бик җитди итеп сөйли.

Габделҗаббар ахун — 65 яшендә, бик карт хәзрәт, сүзен акрын һәм озын итеп сөйли.

Галиәсгар — 23 яшендә, яңа гына мулла булган яшь шәкерт.

Габбас хәлфә — 35 яшендә, үзен тәрәккыйпәрвәр[1] кеше дип исәпләп йөри торган тугры гына кеше.

Фатих мулла — 62 яшендә
Гайнетдин мулла — 54 яшендә
Сәлахетдин мулла
} һәммәсе гадәти муллалар.

Габделхалыйк — 65 яшендә
Габделкәрим — 44 яшендә
Җиһанша — 56 яшендә
Камалетдин — 46 яшендә
} һәммәсе гадәти байлар.

[1] *Тәрәккыйпәрвәр* — алдынгы кеше.

Ш а к и р — 35 яшендә, бер маклер[1], шаулап сөйли.

Х ә н ә ф и — 18 яшендә, Сәлим бай янында йөри торган малай.

Г ы й л ь м а н с у ф и — 75 яшендә, бер шәйхе фани[2], тешсез.

М а л а й — Нигъмәтулла өендә.

Ш ә к е р т л ә р — хезмәт итеп йөрүчеләр.

Х е з м ә т ч е л ә р — Сәлим бай номерында.

Г а з и з — сәүдәгәр.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Нигъмәтулла байның өе. Ике ишек бар: берсе — коридорга, икенчесе — эчке бүлмәләргә. Бер көзге, өстәл һәм урындыклар бар, өстәлнең эскәтере юк. Пәрдә күтәрелгәндә, бүлмә буш.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Н и г ъ м ә т у л л а һәм Г а з и з ә.

Н и г ъ м ә т у л л а *(коридор ишегеннән кереп, киемен салып, бүлмә ишеген ачып кычкыра).* Газизә!! Тизрәк бире кил! *(Барып урындыкка утыра.)*

Г а з и з ә *(бераз вакыт үткәч кереп).* Ни бар? Ник бик тиз кайттың?

Н и г ъ м ә т у л л а. Күп нәрсәләр бар. Сәлим бай, өйләнмәкче булып, безнең Нәгыймәне соратмакчы, ди.

Г а з и з ә. Кем әйтә, нинди Сәлим бай? *(Ире янына утыра.)*

Н и г ъ м ә т у л л а. Менә тагы, Сәлим бай бер генә бит, Петрапавел бае.

Г а з и з ә. Әстәгъфирулла, шул Сәлим бай тагы өйләнәмени?

Н и г ъ м ә т у л л а. Өйләнә шул. Йә, ни әйтәсең, яучы җибәрсә, ни дип җавап бирик?

Г а з и з ә. Тукта әле, син рәтләп сөйлә, чын сүз түгелдер ул, сиңа кем сөйләде, кайдан ишеттең?

Н и г ъ м ә т у л л а. Хәзер мине Рәхмәтулла чәйгә алып кереп сөйләде. Сәлим бай янында теге мәрхүм Шәмси угылы Касыйм йөри бит, шул кайтып телсез апасына сөйләгән, апасы асраугa сөйләгән, асрау Рәхмәтулланың кучерына бертуган сеңел була икән. Кучер инде шуны сеңлесеннән ишетеп, бүген базарга баен алып төшкәндә баена сөйләгән.

Г а з и з ә. Бар инде, кучердан ишетелгән сүзләргә ышанып йөр.

---

[1] *Маклер* — сәүдә эшендә арадашчы.

[2] *Шәйхе фани* — карашы үзгәрүче кеше.

Н и г ъ м ә т у л л а. Ул кучердан ишетелгән хәбәр һәрвакыт дөрес була. Мин тәҗрибә итә киләм. Юныс байның хатыны үзенең каенанасын кыйнаганны шул кучердан ишеткән идек бит, ялган булдымыни?!

Г а з и з ә. Аны да шул кучер сөйләгән идемени?

Н и г ъ м ә т у л л а. Шул ук кучер сөйләгән иде шул. Йә, инде ышандыңмы?

Г а з и з ә. Ышануын ышандым да, минем бу эшкә исем китә. Сәлим бай бире ашказанын төзәттерергә килгән дип үзең сөйләгән идең ич!

Н и г ъ м ә т у л л а. Ни була соң? Эш эшкә уңайсызламый бит, ашказанын да төзәттерә, өйләнә дә.

Г а з и з ә. Кара инде, үзендә һич гакыл юк икән. Тагы нигә өйләнә? Ансыз да гомер буенда сигез хатын алган. Яшьрәк булса бер хәл иде, бу көндә булмаса иртәгә үләргә тора, шунда да хатыны өстенә хатын алмакчы була, имеш. Оятсыз!

Н и г ъ м ә т у л л а. Теләсә унсигез хатын алган булсын, син әле минем баягы сүземә җавап бир: Нәгыймәне соратса ни әйтим?

Г а з и з ә. Аны нигә миннән сорап торасың, үзе сорарга килсә — үзен, кеше җибәрсә — кешесен тотып җилкәсеннән кадатырбыз. Нәгыймә әле, җиткән кыз булса да, картаеп сасып беткән Сәлимгә бирмәс идек. Нинди йөзе белән бездән аны соратмакчы була?

Н и г ъ м ә т у л л а. Тукта әле, Нәгыймә җиткән кыз түгелмени, үткән айда аңа унбиш яшь тулды бит. Син үзеңне исеңә төшер, миңа килгәндә, ничә яшеңдә идең?

Г а з и з ә *(бик ялынып)*. Зинһар, Нәгыймәне ул карт дуңгызга биреп, балаңны ут эченә салма, ул үзе карт, хатыны да бар.

Н и г ъ м ә т у л л а *(ачуланып)*. Кит шуннан, дурак! Атаң шикелле карт кешегә шулай әйтәләрмени? Нәгыймәне сөюем минем үземнең дә синекеннән ким түгел. Ләкин Сәлим байга бирмичә дә ярамый, аның өчен әгәр Сәлим бай безнең кияү булса, ул миңа хәзер... Йә, син минем сәүдә эшләремне барыбер аңламыйсың. Аңа кызыбызны бирсәк, кеше күзендә безнең кадеребез беләсеңме никадәр артыр иде? Ул вакытта Җиһанша бай да безнең каршыда мондый гына булып калыр. *(Җиһанша байны кечерәйтеп кулы берлән күрсәтә.)*

Г а з и з ә. Нәгыймә аңа бармас, елар.

Н и г ъ м ә т у л л а *(кычкырыбрак)*. Ачуымны китермә тагы, «елар!» Еламый кияүгә барса, ул мөселман кызы да булмас

иде. Теләсә акырып еласын, гомер буена еламас бит, туктар. Юатырга хәйлә үзең дә табарсың инде. Син менә болай әйт: Сәлим абзыең бик бай кеше, сине бик яхшы киендерер, бик татлы ашатыр диген, аның остазбикәсе булсаң, шкаф белән баз ачкычы үз кесәңдә йөрер дә, һәммә нәрсә үз кулыңда булгач, теләсә нихәтле конфет, теләсә нихәтле җимеш ашарсың диген. Сәлим бай дөньяда озак тормас, докторлар аңа ике елдан артык тормассың дип әйткәннәр диген. Бай хатын булгач, бик күп яшь кияүләр табылыр диген, шулай әйт, югыйсә ул бала кеше, шундый эшләрне белми торгандыр әле.

Газизә. Менә бу сүзләрең ярар. Сиңа иргә биргәндә, этиләрем минем үземне дә шул рәвешлерәк сөйләп алдаганнар иде: синең йөрәгеңә таш үскән дип сөйләделәр.

Нигъмәтулла. Ярый, алайса, мин сиңа шуларны сөйләр өчен генә кайттым. Аннан соң шунысын да әйтим: килгән кешегә Нәгыймәнең яшен унбиш дип әйтмә, уналтыда диген, югыйсә бик яшь дип куркып ниятеннән кайтыр. Аңладыңмы? Нәгыймәгә дә әйт, бу көннән башлап син үзеңне уналтыда дип исәпләп йөр диген, ник дип сораса, этиең шулай кушты диярсең. Мин сиңа әйтергә онытканмын. Шәмси углы Касыйм Сәлим байга теге Нәгыймә берлә Фәридәне икесен бергә төшергән карточканы күрсәткән. Ул ничек аның кулына төшкән?! Без аны Вәлиулла берлә бер-беребезгә мәхәббәтебездән кызларыбызның икесен бергә төшерткән идек. Андый сагынмаклык нәрсәне ничек чит кешегә бирәсең?!

Газизә. Мин ул карточканы кемгә дә биргәнем юк.

Нигъмәтулла. Менә карточкада Фәридә ялгыз гына булса, Сәлим бай, бәлки, аңа сокланган булыр иде. Ярый әле Сәлим бай, безнекенә сокланып, моны алсам, ашказаным да төзәлер иде дигән. Фәридәгә сокланган булса ни эшләр идең?

Газизә *(тиргәп)*. Яхшымы инде, үзең берлән бертуган кардәш кызыннан көнләшәсең икән.

Нигъмәтулла *(тотлыга төшеп)*. Юк, мин алардан көнләшмим, мин Вәли белән әүвәлгечә дус. Сиңа шуның өчен генә әйтәм, ягъни... йә, синең белән сөйләп болай да бик күп вакыт үтте, эшем бар, китәм. *(Урыныннан кузгала.)*

Газизә. Анда минем дә бераз эшем бар иде. *(Торып китә, үтеп барганда, үз-үзенә.)* Оялмыйча кардәшеннән көнләшә. *(Китә.)*

Коридор ишегеннән кулына кәгазьгә төргән әйбер тоткан малай керә. Бер генә адым атлый да, Нигъмәтулланы күреп, тиз генә кире чыгып китә.

Нигъмәтулла. Тукта, ул ни китерәсең, кайт бире!

Коридордан малай тавышы. Нәгыймә апа җибәргән иде. Федоров магазинынннан әйберләр. *(Малай кулында булган нәрсәләрне тотып кереп, өстәлгә куеп чишә, кәгазь эченнән бер шешә һәм картон тартмалар чыга.)*

Газизә *(ишектән керә)*. Ник бу хәтле кычкырасың? Шул тавышың белән балаларны куркакка саптырып бетердең инде!.. *(Нигъмәтулланың шешә башындагы кәгазьне чишә башлаганын күреп.)* Аны нигә чишәсең инде?

Нигъмәтулла. Тукта, монда кершәнегез инде бөтенләй кирәксез нәрсә. *(Кулына помаданы алып.)* Әмма бу ирен помадасы... *(Звонок тавышын ишетеп.)* Звонок бар, кунак бардыр.

Малай *(коридор ишегеннән кереп)*. Абзый, кунак килде.

Нигъмәтулла. Кем? Урысмы, татармы?

Малай. Урыска да охшый, татарга да охшый.

Нигъмәтулла. Керсен, керсен.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Нигъмәтулла һәм Касыйм.

Нигъмәтулла *(елмаеп)*. Түбән ишекләр бикләнмәгән булса да, звонок биреп керәсез, ишеткәч үк абразавный кеше килгәндер дидем. Мин үзем дә, әлхәмделилла, тәрәккыйпәрвәр кеше. *(Бераз торып.)* Ничек, Сәлим абзый сәламәтләнәме инде?

Касыйм. Әлхәмделилла, әле хәле яхшы.

Нигъмәтулла. Сәлим абзый бире ник хатынын китермәгән, бире соң ялгыз торып эче пошмыймы? *(Малай самавыр керткәч, урыныннан торып өстәл янына килә дә Касыймга урын күрсәтә.)* Рәхим итегез, Мөхәмммәткасыйм, әйдә, менә бире утырыгыз.

Касыйм *(күрсәткән урынга утыра-утыра)*. Аның әлеге хатыны белән мәхәббәте юк бит. Шуның өчен китермәгән, каршымда шул хатын булмаса, эчем тыныч, ди. *(Көлә.)*

Нигъмәтулла *(көлә төшеп)*. Мәхәббәтләре юкмыни? Алайса, ник икенче хатын алмый? Шәригать буенча икене алырга дөрес бит.

Касыйм. Сәлим абзый, чынлап та, икенчене алмакчы була бит.

Нигъмәтулла. Шулаймыни? Минем ишеткәнем юк иде, Мөхәммәткасыйм, бу сүзне сездән генә ишетәмен.

Касыйм. Ишетмәгәнсез шул, аны ишетергә соң миннән башка һичкем белми бит.

Нигъмәтулла *(үз-үзенә)*. Әйе, белмәсләр.

Касыйм. Әмма миннән ул һичбер серен яшерми. Беркөн номерда икәү утырганда, Сәлим абзый миңа карады да: «Мин картайдым инде, күп нәрсәгә зиһенем җитми башлады, шуның өчен син миңа гакыл бирер идең»,— ди.

Нигъмәтулла *(үз-үзенә мыскыллап)*. Әйе, синдә акыл күп инде.

Касыйм. Ярый, дидем, Сәлим абзый, мин сезгә үземнең бөтен зиһенем берлә ярдәм итәрмен. Менә, ди, ни эшлим. Мөхәммәткасыйм, өйләнер идем, ди. Бер гакыллы кеше берлә сөйләшмичә үзем генә ни эшләргә дә белмим, ди. Шулай дигәч, мин аңа акыл бирергә тотындым, яхшы адвокаттан да остарак сөйләдем. Мин аңа сезнең Нәгыймә туташны мактадым. Шунда ул миңа әйтте: «Алайса, ди, син миңа Нигъмәтулланың кызын алып бир». *(Көлә.)* Менә бүген инде ул мине сезгә яучы итеп җибәрде, аның өчен бу эшне синнән башка һичкем эшли алмас, ди. *(Көлә.)*

Нигъмәтулла. Шулай икән. *(Бераз уйлап торып.)* Дөресен әйтсәм, Мөхәммәткасыйм, кызыбызны Сәлим абзый кеби зур кеше сорагач, бирмәсәк, безгә халыктан да оят булыр.

Касыйм. Соңыннан үкенерсез. Нигъмәтулла абзый, сез минем сүземнән чыкмагыз, минем сүземне Сәлим абзый да тыңлый. Кыз баланы унбиш яшенә җиткәч үк кияүгә бирергә тиеш, менә сезнең Нәгыймә туташ унбишкә җиткән икән.

Нигъмәтулла. Алай гына түгел, Мөхәммәткасыйм, безнең кызыбызга хәзер уналты яшь тулды.

Касыйм. Уналты яшь тулдымыни? Безгә аны унбиштә генә дип әйткәннәр иде.

Нигъмәтулла. Юк, уналтыда инде.

Касыйм. Соң, безгә унбиштә генә дип әйттеләр, без Нәгыймә туташның да, кардәшегез Вәлиулла абзыйның Фәридәсенең дә яшьләрен сорадык. Нәгыймә туташ Фәридә туташтан бер елга яшь булып, хәзер унбиштә генә дип сөйләделәр.

Нигъмәтулла *(үз-үзенә)*. Бигрәк аермачык белгәннәр икән, ни әйтим инде. *(Кычкырып.)* Юк, юк, алай түгел,

безнең Нәгыймә Фәридәдән бер яшь зур, теге унбиштә, бу уналтыда.

Касыйм. Ярый, мин аңа да шулай әйтермен. Сез инде, Нигъмәтулла абзый, кирле-мырлы сөйләшмичә, җавабыгызны әйтегез. Нәгыймә туташны Сәлим абзыйга хәләл хатынлыкка бирәсезме, юкмы? Сәлим абзый әйтә, бирсәләр, ди, туе, мәһәре тугрысында үзем берлән сөйләшерләр, ди.

Нигъмәтулла. Ни эшлисең инде, Мөхәммәткасыйм, Сәлим абзыйның соравын кайтармыйк, Аллага тапшырдык, хәерле булсын. Кыз бала, читлектәге кош кеби, вакыты җиткәч оча да китә.

Касыйм. Менә, Нигъмәтулла абзый, кызыгызны Сәлим абзыйга бирдегез, бу эшне мин эшләдем бит, миннән башка кем дә эшли алмады.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шулар ук һәм Мифтах хаҗи керә.

Мифтах. Әссәламегаләйкем.

Нигъмәтулла. Вәгаләйкемәссәлам. *(Касыймга.)* Менә, Мөхәммәткасыйм, хаҗи әфәнденең эше бик читен, үзе монда безнең арабызда торса да, күңеле тегендә, теге мөбарәк җирләрдә йөри. Ничә мәртәбә Мәккәгә сәяхәт кыйла башлады. Мондагы мөселманнарны аяп кына китми калды. Син китмә, хаҗи әфәнде, чыда, ничек булса да чыда. Болай да яхшы кешеләребез юк, син дә китсәң, монда кем калыр?

Малай *(кереп)*. Нигъмәтулла абзый, сине кантурга дәшәләр, чакырган урыс килгән.

Нигъмәтулла. Сез инде, кунаклар, зинһар, гаеп итмәгез, минем түбән кантурда биш кенә минутлык эшем бар.

Мифтах. Ярый, ярый, Нигъмәтулла, бар, монда Мөхәммәткасыйм берлә гәпләшеп торырбыз. *(Нигъмәтулла киткәч.)* Син, Мөхәммәткасыйм, Сәлим абзый аһ-ваһ итеп көтеп тора торгандыр дисең, югыйсә ул синең монда икәнеңне беләме?

Касыйм. Әйе, белә, ул мине үзе бире җибәрде. Бүген мин Сәлим абзыйга яучы булдым. Башка кеше бу эшне эшли алмас.

Мифтах. Йә әле, Нигъмәтулла шулай кызын бирдемени инде?

Касыйм. Мин үзем яучы булгач, ничек бирмәсен? Мин, хаҗи әфәнде, сүзем берлә һәркемне җиңәрмен.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шулар ук һәм Нигъмәтулла.

Нигъмәтулла *(ишектән башын сузып карый).* Ничек гәпләшәләр. *(Көлә. Күздән югала.)*

Мифтах. Әлегә хәтле, Мөхәммәткасыйм, синең белән белешүемез ул кадәр үк юк иде. Ләкин мәрхүм әткәң белән без бик дус идек. Сүземә ачуың килмәсен, син Сәлим абзыйга ник алай бушка хезмәт итеп йөрисең, аның йомышларына йөрергә башка кеше дә табылыр иде. Син бит ата баласы, Мөхәммәткасыйм, Алла Тәбарәк вә Тәгаләдән каза ирешеп, әле генә дәүләтегез бетте. Юкса мәрхүм бабагызны, мәрхүм әткәгезне халык әле Сәлим абзыйны кадерләгәннән дә бик кадерлиләр иде.

Касыйм. Болай әйткәч инде, хаҗи әфәнде, сезгә үземнең серемне әйтмичә ярамый. Ләкин минем сүзләремне беркемгә дә әйтмәгез. Дөрес, нәселем буенча мин Сәлим абзыйдан югарырак булып, миңа аның йомышларына йөрергә тиеш түгел иде. Ләкин мин аның тирәсендә бушка гына йөрмим бит, аның кызы Салиха туташны үземә сорамакчы булам, шуның өчен картның бераз хәтерен табарга кирәк. Хаҗи әфәнде, әле миңа сөйләгән сүзләрне сез барып Сәлим абзыйга сөйләсәгез, ягъни аңа менә шулай минем нәселемне мактасагыз, бик яхшы булыр иде.

Мифтах. Ярый, мин аңа сине нәсел ягыннан да, башка яктан да мактармын.

Касыйм. Шул Салиха туташны алсам, хаҗи әфәнде, мин сезне дә онытмам.

Мифтах. Рәхмәт, Мөхәммәткасыйм, бик рәхмәт. Шулай мәрхүм әткәң кебек һимммәтле бул. Бу көн генә мин аны сагындым. Мин бүген мәрхүм Шәмси абзыйны шуның өчен сагындым, миңа хәзер бераз акча кирәк, шундый вакытта ул мәрхүм миңа ярдәм итә иде.

Касыйм. Күпме кирәк, хаҗи әфәнде?

Мифтах. Югыйсә бирәсеңме, Мөхәммәткасыйм? Янында күпме акчаң бар?

Касыйм. Янымда егерме биш сум, хаҗи әфәнде.

Мифтах. Миңа да шулай егерме биш сумлап кирәк иде, бирсәң, берәр айдан түләрмен.

Касыйм. Мин сиңа... мин сезгә барсын да бирер идем, хаҗи әфәнде. Ләкин, зинһар, гаеп итмәгез, ун сумы үземә кирәк.

Мифтах. Алайса, Мөхәммәткасыйм, хәзер унбиш сумын бир, ун сумын башка вакытта бирерсең.

Касыйм. Ярый, хаҗи әфәнде, ләкин миндә егерме биш сумлык кәгазь.

Мифтах. Аны менә хәзер Нигъмәтулланың кантурына төшеп алыштырырга мөмкин, бир акчаңны, бир! *(Урыныннан торып кулын суза.)*

Касыйм *(урыныннан торып)*. Юк, хаҗи әфәнде, мин үзем алыштырырмын.

Мифтах. Юк, бир, мин барып алыштырыйм.

Касыйм. Юк, юк, хаҗи әфәнде, утыра бирегез, мин үзем дә алыштырырмын. *(Китә.)*

Мифтах. Гаҗәеп! Гаҗәеп, бу нинди эш! Бу нинди эш!! Сәлим шуны яучы итеп җибәргән. Йә, шул эшкә ничек түзим?! Нигъмәтулла да яхшы кеше, жулик, жуликның да жулигы, «Кызым унсигезгә җитмичә кияүгә бирмим» дип, әле беркөн генә сөйләгән иде. Менә бара инде хәзер! Әле бер-бер сылтау табып, Сәлим байга тәрилкә тотарга барыр... жулик, жулик!

Көзге өстәлендә ислемай күреп, борып, һәммә нәрсәләрне карагач, яулыгын чыгарып, шешәдән ислемай салыйм дигәндә, аяк тавышы ишетеп, тиз генә урынына утыра.

Пәрдә төшә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Кунакханәдә Сәлим байның номеры. Арт тарафта сул якта — коридорга чыга торган ишек, уңда — язу өстәле, уң тарафта — номерның икенче бүлмәсенә ишек, алдында өстәл, сул тарафта — янә кечкенә өстәл, аның өстендә — дару шешәләре. Пәрдә күтәрелгәндә, номер буш.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим һәм Мифтах.

Мифтах *(коридор ишегеннән кереп)*. Әссәламегаләйкем! Сәлим абзый, мин сиңа бик хәтерем калып килдем, бик рәнҗедем, үзеңә кыз карарга, мине ташлап, Касыймны җибәрәсең. Син мине шул урыс төсле егеткә алыштырдың.

Сәлим. Ни эшлим соң, хаҗи әфәнде, шулай туры килде, мин...

Мифтах *(Сәлимнең сүзен тыңламыйча, кызулык илә)*. Ул Касыймны син яхшы кеше дип исәпләп йөрисеңмени? Ул бит — ялганчы, бинамаз, шайтан колы... Ул — шарамишка...

Сәлим. Шарамишка? Бу сүзне мин аңламыйм, хаҗи әфәнде, шарамишка ни була?

Мифтах. Шарамишка шарамишка була, кесәсендә бер тиен дә акчасы булмаган кешегә әйтәләр. Ул — бик тәүфыйксыз кеше. Монда ничә кешедән кыз соратты, икейөзле дип берсе дә кыз бирмәде.

Сәлим. Яхшымы, яманмы, аның миңа кирәге бар, минем берлә докторга йөри, аптекка бара. Мин, хаҗи әфәнде, дөнья кешесе, синең кеби суфи түгел. Шуның өчен кешенең җитешмәгән җирләренә дә түземлерәк. Аны гаеп итмә инде, хаҗи әфәнде, бәхил бул, ни эшлим соң, шулай туры килде. Кичә генә Нигъмәтулла кызына өйләнергә исемә төште дә бүген Касыймны җибәрдем.

Мифтах *(көлеп)*. Касыймны да күрдеңме дип сорый торгансың. Күрдем, ул хәзер килер инде, бире кайтышлый өенә кереп калды.

Сәлим. Әйтәм озаклады, өенә кергән икән. Йә, Нигъмәтулла нинди җавап биргән?

Мифтах. Нинди җавап бирсен, әйтәсең ич, синең яучыны буш кайтарып җибәргән кеше юк, бу эшкә куанычыннан авызы иләк кадәр булган.

Сәлим. Алайса, Нәгыймә минеке булды инде, ул минем сөекле бикәчем булды, ә? Хәзер инде минем унбиш яшьлек хатыным булды, ә?

Мифтах. Син, Сәлим абзый, бик куандың, ә?

Сәлим. Син, хаҗи әфәнде, ягъни синең хатының Нәгыймәне, минем сөекле Нәгыймәне беләме?

Мифтах. Ник белмәсен, белә, бик чибәр кыз. Шәһәрдә генә түгел, илдә дә аңардан чибәр кыз юк, ди.

Сәлим. Бик чибәр кыз, ә? Чибәр шул. Ата-анасы да бик сөяләр, ахры, бик яхшы киендергәннәр, мин портретын күрдем.

Мифтах. Бик сөяләр, Сәлим абзый, бик сөяләр, киендерү генә түгел, хәтта кызына кершән, ирен помадасы кеби нәрсәләрне дә Нигъмәтулла магазиннан үзе алып китерә икән.

Сәлим. Шундый вак-төякләрне дә үзе алып китерәмени?

Мифтах. Әйе, хәзер дә көзге өстәлендә шул нәрсәләр тора иде. Нигъмәтулла яңа гына алып кайткан, ахры.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шулар ук һәм Касыйм.

Касыйм *(коридор ишегеннән кереп)*. Әссәламегаләйкем!

Сәлим һәм Мифтах *(икесе бердәм)*. Вәгаләйкемәссәлам!

Мифтах *(урыныннан торып)*. Мин китим, алайса. Түбәндә мөселман швейцар түрә бит. Ул бая монда менгәндә: «Вакытыңны туры китереп төш»,— дигән иде, баласын ютәл алган, өшкерергә кирәк. *(Китә.)*

Касыйм *(яңа киемнәрдән)*. Мөбарәк булсын, Сәлим абзый, Нигъмәтулла кызын бирде. Мин бит аңа адвокаттан да остарак сөйләдем, үзегез анда булып тыңлап торсагыз, исегез китәр иде.

Сәлим *(көлеп)*. Тукта, Мөхәммәткасыйм, син миңа үзеңне генә сөйләмә, бигрәк Нигъмәтулланың сүзләрен сөйлә.

Касыйм. Чынлап та, Сәлим абзый, сезгә әйтергә онытканмын: кичә бит сез Нәгыймә туташ берлә Фәридә туташның яшьләрен сорагач, мин аны барып апамнан белештем. Нәгыймә туташны унбиштә дип ул безгә белми әйткән икән... Уналтыда, ди.

Сәлим. Кем әйтте?

Касыйм. Нигъмәтулла абзый үзе әйтте. Уналтыда, ди. Нәгыймә туташ Фәридәдән бер яшь олуг икән.

Сәлим. Алайса, Фәридә унбиштә генә, ә? Тукта, сөйләшербез, даруымны эчим... Дару беткән икән, менә хәзер эчәргә кирәк. *(Ачуланып кычкырып.)* Менә хәзер эчәргә кирәк! Дару юк!!! Дару юк!!! Бар, хәзер ясатып китер, тиз генә йөр, элегрәк искә төшмәде! *(Касыйм китә. Сәлим ялгыз калып, ачу берлә аягына тибеп.)* Тагы булмады! Тагы өметем бушка югалды. Бу нинди эш? Унбиш яшьлек кыз алып булмый. Өч елдан бирле шуны кайгыртып йөрим, уналтыда булып чыга. Җәһәннәм утына китегез! Иң түбән җәһәннәмнең уртасында булыгыз! Җиде йөз мең ел тәмуг утында яныгыз! Менә хәзер ни эшлим инде, ә?! Ни эшлим?! Әйткән сүземнән ничек кайтыйм? Ничек моның кызын алмыйча, Вәлинең Фәридәсен алыйм? Кардәш булмасалар бер хәл иде, кардәшлекләре уңайсызлый. Ничек булса да, моны алмыйча, Фәридәне алырга кирәк. Ләкин яше карт булган өчен алмаганны сиздерергә ярамый. Монда бер-бер хәйлә табарга кирәк. Нәгыймәне алмаска бер сәбәп булсын. *(Бераз уйлап тора.)* Җәмиләне аерганда, намаз укымый дигән идем. Бу эштә дә шундый бер хәйлә шәргый табыйм, шәригать берлә һәр эшне дә булдырып була диләр бит! Таптым! Таптым!

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәнәфи, Сәлим һәм Мифтах.

Сәлим. Нигъмәтулланың өстәлендә нинди нәрсәләр күрдең, хаҗи әфәнде, тагы бер мәртәбә әйт әле.

Мифтах. Нинди нәрсәләр булсын, бер шешә ислемай, бер тартма кершән, аннан соң бер кисәк ирен помадасы.

Сәлим. Ә миңа шунысы кирәк иде, нинди помада? *(Бармагын күрсәтеп.)* Теге, шундый май төсле нәрсәме? Ул хәрам ич, аны сөртү хәрам!

Мифтах. Юк, хәрам түгелдер, нишләп хәрам булсын, Сәлим абзый.

Сәлим. Юк, хәрам, безнең Габделгафур мулла аны хәрам дип әйтә, син шуны белмисең, ахры, хаҗи әфәнде! Шуның өчен мондый хәрам эш эшләп торган кызны мин ничек алыйм. Ул минем хатыным булса, өстенә караганда «бу кыз чагында помада сөртә торган булган» дип хәтеремә килер дә, кәефем бөтенләй бозылып китәр.

Мифтах. Тукта, Сәлим абзый, мин бит сиңа Нигъмәтулланың кызы помада сөртә дип сөйләмәдем. Аның көзге өстендә шул нәрсәләр тора иде дип кенә сөйләдем.

Сәлим. Алай гына әйтмәдең шул, хаҗи әфәнде. Нигъмәтулла кызына помаданы да үзе алып китерә дип сөйләдең. *(Хәнәфигә.)* Бар, Галиәкбәр хәзрәтне тиз генә чакырып китер. Шуны әйтәм, хаҗи әфәнде, Вәлигә миннән яучы булып бар. Вәлине күреп шул турыда үзем сөйләшсәм, тагын да яхшырак булыр иде...

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Мифтах һәм Рәхмәтулла.

Рәхмәтулла *(кереп)*. Әссәламегаләйкем!

Сәлим. Вәгаләйкемәссәлам. *(Урыныннан торып.)* Әйдә, Рәхмәтулла.

Мифтах *(урыныннан торып)*. Мин китим инде, эшем бар, китим, хуш. *(Китә.)*

Сәлим. Монда сезнең кызларыгыз иреннәренә помада дигән нәрсә сөртәләрмени, Рәхмәтулла? Ул хәрам ич.

Рәхмәтулла. Помада сөртүме? Ни эшләп хәрам булсын, Мөхәммәтсәлим абзый? Мин белми сөйләсәм, әйдә, менә мулладан сорыйк, Мөхәммәтсәлим абзый.



Сәлим. Тукта, менә сорарбыз, мин Галиәкбәр мулланы чакырттым инде.

Рәхмәтулла. Галиәкбәр мулланы? Галиәкбәр мулла ишеткән бер нәрсәсен хәрам дип әйтә.

Сәлим *(үз-үзенә)*. Миңа шунысы кирәк.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Рәхмәтулла һәм Галиәкбәр.

Галиәкбәр *(кереп)*. Әссәламегаләйкем!

Сәлим *(урыныннан торып)*. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, хуш киләсең, хәзрәт, әйдә, рәхим ит. *(Утырышып дога кылалар.)* Әйе, мин, хәзрәт, синнән бер мәсьәлә сорамакчы булдым. Магазиннарда шундый май шикелле нәрсә сатыла, белмим, мөселманча ничек әйтә торганнардыр, урысча помада диләр. Шуны хатын-кызлар иреннәренә сөртәләр, шул помаданы, гаеп итмә инде, хәзрәт, урысча әйтәм, аның өчен мин китапча сөйли белмим, шуны сөртү...

Галиәкбәр. Мотлак хәрам, мотлак хәрам! Әйе, хәрам, хәрам, һич ярамый, аннан бик саклану кирәк. Әле мин аңламый калдым, Мөхәммәтсәлим, аны соң хатын-кызың ни өчен сөртәләр инде?

Пәрдә төшә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галиәкбәр, соңыннан Галиәсгар.

Галиәкбәр, кечкенәрәк өстәлдә берничә китап ачып куеп, тегеннән-моннан бер кәгазьгә гыйбарәләр язып ала, бәгъзе вакыт шул ук өстәлдә өелеп торган китаплардан кирәк булганын табып алып, бәгъзе сәхифәдән укый.

Галиәсгар *(арт ишектән керә, кулына бер кәгазь тоткан)*. Әссәламегаләйкем!

Галиәкбәр. Вәгаләйкемәссәлам, әйдә, мулла Гали! Нәрсә китерәсең!

Галиәсгар. Теге дәгъва кылып йөрүчеләр, хәзрәт, тагы прокламация басып чыгарганнар.

Галиәкбәр. Ни турында язганнар? Йә, укы әле.

Галиәсгар *(утырмыйча, аяк өстендә торып укый башлый)*. «Әй мөселманнар, әй шәкертләр, мөдәррисләр[1] безне җәберләделәр, бездән сайланып җибәрелмеш вәкилләргә Фатих мулла, чыгып: «Сезнең монда эшегез юк, сез үзегез дә әле помада сөртә торгансыз»,— дип, ачу берлә ишекне шап итеп ябып бикләмеш. Аның бу сүзләренә нәфрәт игълан кылып, комиссиягә кертмәсәләр дә, помада мәсьәләсе хакында үз фикеребезне әйтми калмыйбыз. Тәки бу хосуста шәкертләрнең ни уйда булдыгын милләтебез белсен. Безнең карт муллаларыбызның салма ашап кына ятмаклары, аларның милләт өчен, гомуми файда өчен һичкайчан бармакларын селкетеп карамадыклары бу мәсьәләдә бик нык ачыкланды. Аның өчен Сибириядән килмеш бер бай муллаларыбызның күзен ачмаса, алар бу кеби мәсьәләнең ихтималын да Кыяматкә кадәр белмәсләр иде. Бу мәсьәләне милли эшләргә бәйләнеше булмаган бер сәүдәгәрнең чыгаруы һәммәбез өчен бик зур оятдыр».

Галиәкбәр. Ахырын ничек бетергәннәр?

Галиәсгар *(кәгазьгә карап)*. «Яшәсен яшь фикер! Яшәсен тәрәккый!»

Галиәкбәр. Моны безнекеләр язмагандыр. *(Китапларны рәтләп өеп куйганда сөйләшә.)* Син бүген китәсең бит, мулла Гали?

Галиәсгар. Әйе, хәзрәт, фатихада булсагыз иде.

---

[1] *Мөдәррис* — мәдрәсәдә укытучы кеше.

Галиәкбәр. Мин синең өчен даим фатихада, даим фатихада, мулла Гали. *(Бераз туктап тора.)* Сиңа инде, мулла Гали, әүвәлдә дә әйткәнем бар иде, хәзердә дә әйтәм, тәкрар кылуның[1] зарары юк. Халык синең сүзеңнән чыкмыйча, дин юлыннан барсын дисәң, аны тыңлатып үзеңне ригая кыйлдыра[2] белергә кирәк. Син хәзер, мәсәлән, мулла булдың, синнән килеп мәсьәлә сорарлар. Ул мәсьәләгә җавап биргәндә, бик сакланырга кирәк. Фәтва[3] бирмә, фәтва бирүдән саклан, фәтваның әүвәл Алла каршында җавабы зур, икенче, анысына да фәтва бирсәң, монысына да фәтва бирсәң, халык синнән курыкмый башлар. Фәтва бирмә, телеңдә күбрәк хәрам берлә тыюны йөрт, куркыт, бик куркыт, халык әле үзе дә шуңа өйрәнеп беткән, шундый мулланы хөрмәт итәләр, надан булса да галим, диләр. Менә, мәсәлән, помада мәсьәләсе. Ул чакта мин аны Сәлимгә туп-туры хәрам дип әйттем. Безнең Габделгафур мулла да шулай әйтә, ди. Аннан кайтышлый шул эшкә кереп Габделҗаббар хәзрәткә сөйләдем. Мин үзем дә помадаларны күргәләгәнем бар иде, әмма Габделҗаббар хәзрәт һич белми икән. Ул эшне сөйләп биреп аңлаттым. Өйгә кайттым, ахшамнан соң миңа Гайнетдин мулла килде. Шунда мин бу эшне аңа да сөйләдем. Габделҗаббар хәзрәт кебек ул да миңа мөсәлләм булды[4]. Тукта, ди, алайса, моны Габделхәй муллага сөйләргә кирәк. Менә шулай итеп, Алланың рәхмәте белән, һәммәбез арасында уртак фикер хасил булды, әле инде байларыбыз үзләре шуның артыннан йөриләр. Халыкка йогынты ясар өчен, менә сездән комиссия дә ясаттылар.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галиәкбәр, Сәлим һәм Касыйм керәләр.

Сәлим. Әссәламегаләйкем!
Касыйм. Әссәламегаләйкем! } *(Бер тавыштан.)*

Галиәкбәр. Вәгаләйкемәссәлам. *(Зур өстәл янында утырырга урыннар күрсәтеп.)* Менә бире, менә бире, Мөхәммәтсәлим, сез, Касыйм, шунда утырыгыз. *(Өчесе дә утырышкач.)* Ягез, бер фатиха. *(Дога кылалар.)*

Сәлим. Бик сау-сәламәт торасызмы, хәзрәт?

---

[1] *Тәкрар кылу* — кабатлау.
[2] *Ригая кыйлу* — олылау.
[3] *Фәтва* — раслау.
[4] *Мөсәлләм булды* — килеште.

Галиәкбәр. Әлхәмделилла, Мөхәммәтсәлим, үзеңнең кәеф-хәтереӊ ничек?

Сәлим. Вәлинең кызын алуым бик яхшы булды, хәзрәт, үзем дә шатландым, халык та бик шатланган. Ләкин кичә Вәлиулла берлә Нигъмәтулланың бу хәтле кычкырышулары бераз хәтеремне җибәрде. Мин Вәлиуллага да ачуландым, ичмаса, аңа туктау кирәк иде. Оят бит, бөтен мәҗлес алдында ике кардәш бер-берсенә әйтешмәгән сүзләрен калдырмадылар. Алар бит инде — бер-берснә тәмам дошман.

Касыйм. Алар гына да түгел, хәзрәт, Нигъмәтулла инде Сәлим абзыйга да дошман булды. *(Сәлимгә әйләнеп.)* Сәлим абзый, талаш арасында ул бит сезгә дә хайван дип әйтте.

Сәлим. Йә, син аны нигә тагы яңадан сөйлисең? Ишеттем бит, синнән башка да ишеттем.

Галиәкбәр. Ул сүзне тәкрар кылырга хаҗәт юк, Мөхәммәткасыйм, ансыз да мәгълүм.

ИКЕНЧЕ КАРТИНА

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галиәкбәр мулла өендә мәҗлес. Сәлим байның бер ягында Вәлиулла, икенче ягында Мифтах хаҗи, Вәлиулла янында Касыйм, Галиәкбәр мулла.

Сәлим. Менә Федоров саттыра дип ачуыбыз килә, үз мөселманнарыбыз ук саталар икән. Әлек шуларны тыярга кирәк иде.

Габбас. Анысы, әлбәттә, шулай, ләкин теге саткан вакытта үз мөселманнарыбызны да кысарга ярамый.

Сәлим. Һаман үз сүзеңне сөйлисең, хәлфә. Шәригать буенча аны сату ярамый — бетте, вәссәлам, шуннан башкасын без белмибез. Помадага астан карасаң да помада, өстән карасаң да помада!

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Фатих мулла, Гайнетдин мулла, Камалетдин бай, Сәлахетдин мулла, Габделкәрим бай, Габделхалыйк бай килеп керәләр.

Габделхалыйк *(күкрәгендә медале бар)*. Эшебез булмады, җәмагать.

Берничә тавыш. Әллә сөйләшмәде дәме? Күрдегезме соң? Кем сөйләште?

Габделхалыйк. Күрүен күрдек тә, соравыбызны кабул итмәде, мин үзем сөйләштем. Медальләрен тагып чыкты. «Господа, что вам угодно?»— ди. Дүрт йөз ел эчендә, дидем, һичбер мәртәбә патшага хыянәт иткәнебез юк. Эшебез шул дип, ваше пр... *(Утыра.)* Безнең мөселман кварталында, мөселман арасында, хәтта безнең иң зур, урысча иң главный мәчетебездән ерак түгел, Федоров дигән кешенең парфюмерный магазины бар...

Сәлим. Ничек дидең? Нинди магазин, нинди?

Габделхалыйк. Парфюмерный, аңа шулай әйтелә икән. Моннан барышлый *(кулы илә югары күрсәтеп)* вывескасын карап, махсус язып алдык. Ул магазиннан, дидем, безнең мөселман халкы гына нәрсә алалар. Чөнки анда якын-тирәдә урыс юк. Ул магазинда, дидем, төрле ислемайлардан, кершәннәрдән башка иренгә сөртә торган помада сатыла, ләкин, дидем, ваше пр... ул помаданы сөртү безнең шәригатебездә дөрес түгел, большой грих, дидем.

Галиәкбәр. Алай гына әйтмәскә кирәк иде, большой хәрам дияргә тиеш идең!

Сәлим. Әйе, мәсәлән, фәләнчә ел тәмуг утында яндырырлар дип әйтсәң, бик яхшы аңлар иде.

Касыйм. Мин барган булсам һәммәсен дә аңлаткан булыр идем.

Габделхалыйк. Шуның өчен, дидем, ваше пр... мөселман арасында помада сатылмаса бик яхшы булыр иде, дидем. «Зур гөнаһ булса, муллаларыгыз шуны халыкка яхшы гына сөйләп, ул эштән тыйсыннар»,— ди. *(Торып, күкрәгенә кулын куеп.)* Ваше превосходительство, дидем, муллаларыбыз ул турыда мәчеттә һәр көн икешәр мәртәбә вәгазь сөйлиләр, ләкин, дидем, бу заманда халыкны аның берлә генә тыеп булмый. Шуңа күрә, дим, сезнең мәрхәмәтегездән үтенәбез, зинһар, дим, ул Федоровка помада сатуны манигъ кылыгыз, мәсәлән, воспритит итегез, дим. Закон тыймаган сатуны мин, ди, тыя алмыйм, теләсәгез ни эшләгез, ди. Менә губернаторның җавабы шул, җәмәгать. Йә, хәзер ни эшлибез, җәмәгать, эшне шуның берлә бетерәбезме, юкмы?

Камалетдин. Без бу турыда бераз сөйләштек инде. Минемчә, хәзер сенатка прошение бирергә кирәк!

Габделкәрим. Һаман шул сүзең, Камалетдин, сенат бу эшне эшли алмый, әйтәм ич, мондый мәсьәләләрне государственный совет карый.

Җиһанша. Безгә сенаты да, советы да кирәкми. Монда туп-туры патшага, үзенә барырга кирәк.

Халык бердән. Петербурга! Петербурга!!

Җиһанша. Губернаторга баруын бардылар да файдасы чыкмады. Йә, шул Федоровны ни эшләтәбез соң! Мөселман арасында помада саттыра бит, ә.

Сәлахетдин. Тукта, менә Петербургка барыйк, без аңа үзебезне танытырбыз.

Мифтах. Ислам җире булса, помадасы түгел, ул йөзе караны үзен дә күптән бетергән булырлар иде. Солтан Сәлим хәзрәтләре бервакыт шул помада өчен унике кешенең башын кистергән.

Берничә кеше. Кара син, хикмәт, ислам җирендә шуның өчен бер мәртәбә баш кистерү булган икән! Ә Сәлим хәзрәтнең бер җариясе, исемен оныттым, үзенең кызы, кәферлектән аерыла алмыйча, әлеге шул помаданы сөртә торган булган.

Сәлахетдин. Ул җариянең помадасы дуңгыз, ягъни хинзир маеннан булган икән, аның мондагысы да шуның маеннандыр.

Гыйльман суфи. Аның өстендә ике арыслан сыйфаты бар, шул арыслан маеннан ясалуга дәлил түгел микән?

Галиәкбәр. Анысы барыбер инде, арыслан маеннан булса да хәрам.

Камалетдин. Аны мин дә күрдем, чынлап та, бик кабахәт нәрсә икән, өстенә карагач ук күңел болгана башлый. Белмәгән кеше дә бер күргәч үк «бу хәрам» дип әйтер.

Берничә кеше. Бик шакшы нәрсә. Бик яман нәрсә, бигрәк начар нәрсә!

Габделкәрим. Бу эш тегенди түбән халыкка да бик зур файда булыр!

Камалетдин. Анысы халкыбызның һәммәсенә дә зур файда булыр!

Галиәсгар *(Галиәкбәргә).* Хәзрәт, мәҗлес тәмам була инде, рөхсәт итсәгез, мин халыкка берничә сүз әйтеп калыр идем.

Берничә кеше. Бик рөхсәт, мәхдүм[1], сөйләгез, сөйләгез.

Галиәсгар. Җәмәгать, әүвәл әйтәчәк сүземнән элек бу мәҗлестә шәһәребезнең иң зур голәмалары[2] һәм байлары алдында мин чын күңелемнән үземнең шатлыгымны икърар кыламын. *(Кызуланып.)* Әлхәмделилла, мөселманнар ничә еллар тирән йокыда ятканнан соң, хәзер мәгърифәт берлә

---

[1] *Мәхдүм* — хөрмәтле кеше.

[2] *Голәмалары* — укымышлы кешеләр.

нурлана башладылар! Мәгърифәт вә тәрәккый нуры берлән нурлана башладылар! Моннан биш ел элек һәркем үз кайгысын гына кайгыртып, гомуми милләт эше өчен бармагын да селкетеп карамый иде. Әмма хәзер! Хәзер бер тарафтан —голәмаларыбыз, икенче тарафтан байларыбыз, һәммәсе дә бер сүздә булып, бөтен милләтебез өчен зур әһәмиятле булган мәсьәләне җыйнаулап кайгырышалар. Бу эш милләтне сөюче һәрбер мөселманның йөрәген тетрәтеп, күкрәгендә шатлык утлары кабызачак, җәмәгать! Помада мәсьәләсе әлегә хәтле фәкать дини яктан гына каралды. Ләкин мәсьәләгә гомумән караганда, кешелек, мәдәният, тәрәккый мәгърифәт, гомуми вә хосусый сәясәт нокталарыннан караганда бу эшләрнең олуг әһәмияте бардыр. Бу эшләр бөтен голәма исламга ишетелеп, һәрбер кешенең күңелен шатлык берлә тутырачак. Аның өчен голәмаларыбыз һәм байларыбыз бергә җыелып кайгыралар. Помада мәсьәләсе! Соралгач ук бу мәсьәләгә туп-туры хәрам дип җавап бирелгән. Хәзер инде байларыбыз үзләре дә шуның артыннан йөриләр. Шуның өчен, җәмәгать, бу тугрыда үземнең шатлыгымны икърар кыйламын. Аның өчен һәммәсе дә җыйнаулашып кайгыралар. Моннан дүрт-биш ел элек һәркем үз эшен генә карый иде, әмма хәзер гомуми милләт эше һәркемнең үз эше шикелле була башлады. Мөселманнар, ничә еллар тирән йокыда ятканнан соң, хәзер мәдәният яктысын күрә башладылар. Әлегә хәтле бу эшкә фәкать дини тарафтан гына каралды. Ләкин мин анысын әйтмичә, шунысын гына сөйлим: бу эш бөтен галәмгә ишетелеп, һәрбер мөэминнең кальбен[1] шатлык нурлары берлә нурландырыр. Һәм мин авылга барып та сөйләрмен. Җәмәгать, мин сезгә шунысын гына әйтмәкче идем: әлхәмделилла, инде мөселманнарның күзе ачыла башлады. Аның өчен бер тарафтан — голәмаларыбыз, икенче яктан байларыбыз һәркайсы кулыннан килгән кадәр шул эш өчен тырышалар, һәм бу эш бөтен мөселманнарны шатландырыр. Дөрес, гомумән караганда кешелек, исламият, мәдәният, мәгърифәт, тәрәккый...

Габбас. Аңладык инде, мулла Гали, ни әйткәнеңне аңладык, яхшы, бик рәхмәт! *(Галиәсгар утыра, кунаклар арасыннан: «Рәхмәт, мәхдүм, бәрәкалла, рәхмәт, афәрин» дигән сүзләр ишетелә.)*

---

[1] *Кальбен* — күңелен.

С ә л и м. Рәхмәт, рәхмәт, сез, мәхдүм, кайда укыдыгыз?

Г а л и ә к б ә р. Бу минем иң яхшы, иң сөйгән шәкертем. Хәзер имтихан биреп кайтып мулла булды.

С ә л и м. Ә-ә, бик яхшы, остазына охшаган икән.

Р ә х м ә т у л л а. Уйлап карыйм да исем китә, шул помада да *(бармагын күрсәтеп)* моның кадәрле кечкенә генә нәрсә бит! *(Көлә.)* Сабый кызның, аны-моны белмичә, иреннәренә помада сөртүеннән шундый зур эш булып китте.

С ә л а х е т д и н. Шулай шул, кечкенәдән зур чыга бит, күрәсең, мәхдүм ни әйтә: аның шунысы яхшы!

С ә л и м. Тукта әле, Рәхмәтулла, син аны сабый дисең. Ул уналты яшьлек кыз сабый буламы соң? Ул бер дә сабый түгел.

Г ы й л ь м а н с у ф и. Кемне уналтыда дисең, Мөхәммәтсәлим абзый, Нигъмәтулла кызы Нәгыйймәнеме?

С ә л и м. Шуны әйтәм шул, ул помада сөртә бит!

Г ы й л ь м а н с у ф и. Ул, Мөхәммәтсәлим абзый, уналтыда түгел, ул унбиштә генә!

С ә л и м. Хәзрәт, суфи әле аның яшен дә белми сөйли.

В ә л и у л л а *(көлә)*. Әйе, суфи аларны яшьтән үк белә. *(Сәлимгә.)* Аның сүзе дөрес, Сәлим абзый, тегенең кызы хәзер унбиштә генә!

С ә л и м. Унбиштә генә? Фәридә соң ничә яшендә?

В ә л и у л л а. Фәридәгә хәзер уналты тулды.

С ә л и м. Уналты тулды! Син үзең белми сөйлисең, Вәлиулла!

В ә л и у л л а *(көлеп)*. Атасы булып ник белмим, Сәлим абзый!

К а с ы й м. Нигъмәтулла безгә алай әйтмәде. Нәгыймә туташ уналтыда, Фәридә туташ унбиштә дигән иде!

Г а б д е л х а л ы й к. Нигъмәтулла ул үз яшен дә ун елдан бирле кырык икедә генә дип йөри! *(Сәлимнән башкалары барысы да көләләр.)*

С ә л и м. Тукта, соң бу эш ничек, бу эш ничек соң?

Г а й н е т д и н. Шикләнмә инде, Мөхәммәтсәлим, Вәлиулланың сүзе дөрес булыр, алар минем метрикага язылганнар. *(Аш ташучы шәкерт ишектән кергәндә егыла.)*

С ә л и м *(акрынрак тавыш белән)*. Аһ, ни эшләдем?! *(Һушсыз булып урындыкка чалкан ята.)*

Г а л и ә к б ә р *(урыныннан сикереп торып, шәкерткә)*. Сөбханалла! Әкрен, җаһил, ни эшләп алай керә-чыга йөрисең!

М и ф т а х *(Сәлимнең һушсызлыгын күреп, аптырап)*. Чү, сөбханалла, Сәлим абзыйга ни булды?

Берничә кеше өстәлне читкә алалар. Галиәкбәр, Вәлиулла һәм Мифтах Сәлимнең йөрәген, маңгаен тотып карыйлар, кунаклар арасыннан: «Тизрәк ясин укырга кирәк» дигән сүзләр ишетелә.

Галиәкбәр. Юк, курыкмагыз, узды инде, узды!..

Сәлим *(торып утыра)*. Алла! Мәҗлес тәмам булдымы?

Берничә кеше. Тәмам, тәмам.

Сәлим *(урыныннан торып)*. Алайса, мин кайтыйм инде, рәхмәт, хәзрәт, хуш, сау булыгыз.

Пәрдә төшә

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Икенче пәрдәдәге күренеш. Бер тарафта чыптага бәйләнгән сандык һәм чемоданнар.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Мифтах, Вәлиулла, Галиәкбәр, Габделҗаббар, Җиһанша, Камалетдин, Габделкәрим чәй эчәләр.

Габделкәрим. Хәзер инде аны төрлечә сөйлиләр: бәгъзеләре үзләре кереп помада сораганнар дип сөйли, бәгъзеләре бер кызга килеп бәйләнгәннәр дип сөйлиләр.

Җиһанша. Менә Рәхмәтулла килгәч сөйләр, ул бүген аны тикшереп, дөресне-ялганны белгәндер.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шулар ук һәм Рәхмәтулла.

Мифтах. Син бераз кичегә төштең, Рәхмәтулла.

Җиһанша. Хәзер генә без сине сагынып торадыр идек, кичә магазин актаруның ничек булганын сөйләче.

Рәхмәтулла. Ул эш менә ничек булган: магазинга бер мөселман кызы килеп кергән. Ике егет, исеме Гайнулла, итче Вафа угылы белән: «Тукта әле, бу помада алырга кермәде микән?» — дип, кызның артыннан барганнар. «Монда ник кердең, алган нәрсәңне күрсәт», — дип бәйләнгәннәр. Шунда магазиннан приказчиклар чыгып боларга: «Сез безнең покупательләргә катышмагыз», — дип кычкырып, берсе килгән дә итче Зарифның күкрәгенә этеп җибәргән. Моңар каршы торып

сугыша башлаганнар, аннан соң халык җыелып эшләре зурга киткән.

Галиәкбәр. Теге ябылган сигез кеше кемнәр, ди, аны син белдеңме?

Рәхмәтулла. Аларның икесе шул Зариф белән Гайнулла, икесе Шульцның тире складында хезмәт итәләр, ди, өчесе көнлекләп эшләп йөриләр, берсе ат белән су ташып йөрүче, ди. Приказчикларның хәлләре бик начар, ди, берсенең башын тишкәннәр, берсенең авызын-борынын ватканнар.

Галиәкбәр. Бу сигез кешегә нинди җәза булыр икән?

Камалетдин. Җиңел булмас, хәзрәт. Себергә озатмасалар, арестанский йорттан ким җәза булмас.

Габделҗаббар *(кайгырып)*. Алла хәерле кылсын инде, безнең мөселманга бу эш бик уңайсыз булды.

Галиәкбәр. Гавам халкы бик начар бит, гавам бик начар.

Рәхмәтулла. Бу эштә гавам халкы гына гаепле түгелдер, хәзрәт.

Галиәкбәр. Ник гавам халкы гына түгел, шул магазин ватучылар бит һәммәсе гавам җенесеннән.

Сәлим *(Рәхмәтуллага)*. Әйе, анда син бармагансың бит. Мин дә бармадым. Нинди кешеләр ябылганын үзең сөйлисең ич: көнлекчеләр, тиречеләр, су ташучылар — һәммәсе дә тегенди кара халык, аларга катырак җәза бирергә кирәк иде: башкаларына да гыйбрәт булсын.

Рәхмәтулла. Тукта, син алай әйтмә инде, Сәлим абзый, ул бичаралар нишләсеннәр соң, алар гаепле түгел. Алар үзләренчә дин өчен шулай эшләгәннәр бит.

Галиәкбәр. Тукта, ни әйткәнеңне белеп сөйлә, Рәхмәтулла, ник аны дин өстенә аударасың?!

Габделҗаббар. Әйе, бу эшкә син алай динне катыштырма инде.

Рәхмәтулла. Юк, мин дингә аударыр өчен әйтмим, мин...

Габделкәрим. Рәхмәтулла үзенчә бик күп белгән булып, гакыл күрсәтмәкче була, син белгәнне тавыклар да белә инде...

Рәхмәтулла. Юк, мин...

Галиәкбәр. Юк, күп белгән булып күренү өчен түгел, Рәхмәтулла каршылыгына карап шулай сөйли. Ул бит бик каршы нәрсә.

Рәхмәтулла. Юк, хәзрәт, мин каршы сөйләү өчен әйтмәдем, мин хакыйкатьне әйтер өчен.

В ә л и у л л а. Әлегә шул, хәзрәт әйтмешли, гавам халкын син айыйсың да бит, Рәхмәтулла, менә аларның бөтен мөселманга зарары тиде. Акалотучниның ни әйткәнен ишеткәнсең бит, сөйләгәннәрдер. Бу эшне кемнәр эшләгәнне мин беләм дигән, хәзер алар дазнания ясыйлар. Шул сигез кешене ябып кына эшне бетерсәләр бик яхшы, юкса, Алла сакласын, шуның өчен голәмаларыбызны әләктерерләр.

Җ и һ а н ш а. Шулай шул. *(Рәхмәтуллага.)* Син, Рәхмәтулла, гаеп магазин сатучыларында гына түгел дип сөйләп йөрсәң, политсия өчен бигрәк тә яхшы булыр, мөселманнар үзләре үк әйтә диярләр.

Р ә х м ә т у л л а. Читтә сөйләмәсәң, монда сөйләвеңнең бер дә кирәге юк, син белгәнне без үзебез дә бик яхшы беләбез.

С ә л и м. Хәзрәт, мин сезнең комиссия ясавыгызны да артык яратмаган идем, әлегә хәтле андый эшләр эшләнми иде бит.

Җ и һ а н ш а. Губернаторга да: «Халкыбыз бик чуалып тора, андый-мондый фетнә чыкмаса ярар иде»,— дип әйтергә кирәк булган икән.

К а м а л е т д и н. Юк, мин ул көнне Габделхалыйкның сөйләвен дә бик яратмадым, помада турысында муллаларыбыз көненә икешәр мәртәбә вәгазь сөйлиләр дип, губернаторга әйтү кирәкмәс иде. Хәзер инде алар халыкны голәмаларыбыз котырткан дип уйлый торганнардыр, акалотучниның: «Бу эшне кемнәр эшләткәнне мин беләм»,— дип әйтүеннән дә шулайрак аңлашыла.

Г а л и ә к б ә р. Аны дөрес әйтәсең, Камалетдин, ул сүзне губернаторга әйтергә хаҗәт юк иде.

Җ и һ а н ш а. Ул Габделхалыйкның гадәте шундый инде, бер сөйләргә тотынса, аны-моны уйламый.

В ә л и у л л а. Әйе, үзен сүзгә оста кеше дип белеп, ни әйткәнен дә исәпләми.

Г а б д е л к ә р и м. Ул көнне, губернатордан кайткач, үзеннән башка берәүгә дә сөйләргә ирек бирмичә, мәҗлес халкы алдында күкрәгенә суга-суга: «Үзем сөйләдем! Үзем сөйләдем!» — дип мактанды. Әмма хәзер бу эштән үзе дә аптырап качып киткән, Сәлахетдин дә качкан. Икесе дә юк.

Г а б д е л җ а б б а р.
Җ и һ а н ш а. } Кая киткәннәр?

Г а б д е л к ә р и м. Белмим, качарга урын тапканнардыр. Алар бит — бурычларыннан качып йөрергә дә өйрәнгән кешеләр.

В ә л и у л л а. Әйе, бу турыда күп шауларга ярамый, эшләнгән кадәрле эшләнде, шуның белән бетсен.

Г а б д е л җ а б б а р. Хәерле булсын инде, бу эш бик уңайсыз булды.

С ә л и м *(сәгатенә карап).* Поезд китәргә дә күп вакыт калмаган икән.

Р ә х м ә т у л л а. Алайса, без китик инде, Сәлим абзый.

С ә л и м. Ярый, килүегезгә рәхмәт. Гаеп итмәгез инде, кунаклар, сез мине күп сыйладыгыз, әмма мин сезне ул хәтле сыйлый алмадым, шуның өчен әле киткәндә булса да үзләренә чәй эчерим дидем, килүегезгә бик рәхмәт. *(Китеп бара торган кунаклар артыннан кычкырып.)* Бу эш өчен сезгә алай-болай авырлык килмәсен инде, ахыры хәерле булсын. *(Кунаклар арасыннан: «Шулай инде, амин, рәхмәт» дигән сүзләр ишетелә. Вәлиулладан башкалар китәләр.)*

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

С ә л и м белән В ә л и у л л а.

В ә л и у л л а. Ачуың килсә килер, Сәлим абзый, тагын бер мәртәбә әйтим инде: юкка гына китәсең бит, бу эш өчен сиңа ни дә булмас, син мулладан мәсьәлә генә сорадың ич, башкасын эшләмәдең.

С ә л и м. Юк, Вәлиулла, мин куркып китмим бит. Болай да бик озак тордым. Әллә никадәр эшем калды.

В ә л и у л л а. Калган кадәрле калган инде, Сәлим абзый, бөтенләй сәламәтләнгәнче тору кирәк иде. Әгәр сәламәтләнеп китә алмасаң, туйны соңгарак калдырырга туры килер бит, Сәлим абзый.

С ә л и м. Туйны? Мин сиңа соңыннан хат язармын дип тә уйлаган идем, Вәлиулла, хәзер үк әйтим инде. Миңа бик ышанычлы кеше сөйләде, синең кызың да помада сөртә икән.

В ә л и у л л а. Кем әйтте, юк сүз, Сәлим абзый!

С ә л и м. Юк, бик бар сүз, сөртә, ди, шул, сөртә.

В ә л и у л л а. Тукта, Сәлим абзый, син ул сөйләгән кешене әйт.

С ә л и м. Анысы сиңа кирәк түгел, ләкин ул бик ышанычлы кеше.

В ә л и у л л а. Ышанычлы кеше дип... турысын әйткәндә, бездә ышанычлы кешеләр юк. Мифтах хаҗи дияр идем, ул үзеннән башкага усаллык тели торган кеше түгел.

С ә л и м. Юк, кешесен мин әйтмим. *(Үз-үзенә.)* Аны сөйләүче булмагач, ничек әйтәсең? *(Кычкырып.)* Ләкин ул кешегә мин бик ышанам, шуның өчен гаеп итмә инде. Вәлиулла, мин хәзер вәгъдәмнән кайтам. Миннән башка да кияү табылыр, кызыңа Алла мәхәббәт бирсен.

В ә л и у л л а *(урыныннан сикереп торып).* Сәлим абзый, зинһар, ул сүзгә ышанма. Аны сиңа минем дошманым сөйләгәндер. Ул — ялган сүз. Дошман сүзенә ышанма, Алла разый булсын, зинһар, ышанма, юк сүз.

С ә л и м *(кулын селкеп-селкеп).* Юк инде, Вәлиулла, сүзеңне дә бушка әрәм итмә, алмыйм дигәч, алмыйм була!

В ә л и у л л а *(Сәлимгә гаҗәпләнеп бераз карап торгач).* Алма соң! Син алмасаң, минем кызым кияүгә бармый калырмыни? Алучы кеше табылмасмыни? *(Ачуланып.)* Мин сиңа кызымны ник бирим! Сиңа хатын нигә? Бүген-иртәгә үләргә торасың, шунда да өйләнмәкче буласың бит. Оятсыз, ак сакалың белән оялмыйча, өйләнүне кайгыртасың, гакылың булса, бераз халыктан оялыр идең!

С ә л и м. Андый сүзләр әйтеп син минем ачуымны китермәкче була торгансың? Хезмәтеңне юкка югалтма, Вәлиулла, ак сакаллы булсам да миңа унбиш... миңа помада сөртми торган кыз табылыр.

В ә л и у л л а. Помада, помада, син шул помада белән бөтен халыкны шаулаттың, хәзер инде үзең дә аптырап качасың. Бу хәтле тиз китүеңне белмиләр дип уйлыйсыңмы? Анысын сизмиләрмени? Юк, бик яхшы беләбез, куркып качасың, магазин вату хәбәрен ишеткәч үк, малаеңа нәрсәләреңне җыештыра башларга кушмас идең, бик яхшы беләбез.

С ә л и м. Ю-ук бит, Вәлиулла, мин кызыңны алмагач...

В ә л и у л л а. Һаман шул сүземне әйтеп торам бит! Алам дисәң дә бирмим, син адәммени? Җитмеш яшькә җитеп оялмыйча хатын-кыз кайгыртасың, оялмыйча кызлар сөйлисең, оялмыйча... *(Төкереп.)* Тфү, җил сакал! Җил сакал!! *(Чыгып китә.)*

С ә л и м *(ялгыз калып, бераз җилкәсен кашып торгач).* Йә, бу тик ачулансын, миңа унбиш яшьлек кыз табылыр әле. Бу помада эшен дә миннән күрәләр, ахры, мин гаеплемени? Галиәкбәр мулладан мәсьәлә генә сорадым бит. Соңыннан үзләре, бу — бик зур эш, дип шаулап йөрделәр. *(Торып коридорга чыгарга дип ишеккә бара.)*

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сәлим, Касыйм керә.

Сәлим. Ни, булдымыни?

Касыйм. Булды, Сәлим абзый, өйдә юк иде, бераз көтеп утырдым.

Сәлим. Яхшы, бик рәхмәт. Мөхәммәткасыйм, мин хәзер керәм. *(Китә.)*

Касыйм *(ялгыз калып)*. Уф, йөрәгем хәзер үк пыштыр-пыштыр итә башлады. Хаҗи әфәнде әйтә: «Сәлим абзыйны күргән саен, мин аңа сине мактыйм»,— ди. Юк бит, шулай булса да Салихасын сорый алмыйм, әйтим дигәндә генә калтырый башлыйм. *(Бераз туктап торып.)* Юк, аңар карап сорамый калырга ярамый, ничек булса да сорарга кирәк. Бер сүз әйтсәм, соңыннан телем үзеннән-үзе сөйләр иде.

Сәлим *(керә)*. Йә, рәхмәт, Мөхәммәткасыйм, бик рәхмәт, миңа бик күп файдаң тиде, бик рәхмәт.

Касыйм. Сәлим абзый, мин сезгә бер сүз әйтмәкче идем.

Сәлим. Ярый, әйт, Мөхәммәткасыйм, нинди сүз?

Касыйм. Менә, Сәлим абзый, мин... мин сезгә шундый бер сүз әйтмәкче идем...

Сәлим. Йә соң, әйт инде, нинди сүз? Мине көттермә, мин тәһарәт төзәтергә барам, китәргә дә вакыт инде. *(Касыймнан бераз җавап көтеп торгач.)* Әллә миңа иткән хезмәтең өчен акча сорамакчы буласың? Аны сорарга курыкма, Мөхәммәткасыйм, теләсәң, мин аның өчен зак бирәм, күпме бирим, һәр көн өчен күпме акча алмакчы буласың?

Касыйм. Юк, Сәлим абзый, мин акча сорамыйм, мин, яшь егет булып, икенче төрле сүз әйтмәкче... *(Сүзе киселә.)*

Сәлим *(үз-үзенә)*. Әллә миңа приказчиклыкка ялланмакчы була микән, моны алырга ярыймы соң?! *(Кычкырып.)* Мөхәммәткасыйм, син ник Вәлиуллага: «Сәлим абзый, кичә магазин актару хәбәрен ишеткәч үк, Хәнәфигә юлга хәзерләнә башларга кушты»,— дип сөйләдең? Ул хәзер миңа: «Син куркып китәсең»,— ди. Мин бит аны ишеткәч үк китәм дип әйтмәдем.

Касыйм. Юк, Сәлим абзый, аны мин сөйләмәдем.

Сәлим. Юк, син сөйләгәнсең, хәтерең калмасын, Мөхәммәткасыйм, бу эштә мин синнән шикләнәм, Мифтах хаҗи сине икейөзле кеше дип сөйләгән иде.

Касыйм *(аптырап)*. Кем? Мифтах хаҗи?

Сәлим. Әйе, ул кеше өстенә юкны сөйләмәс, үзең өчен әйтәм, Мөхәммәткасыйм, син андый булма, монда бик күп җирдән кыз сораткансың, аның начар гадәте бар дип һичберсе кызын бирмәгән. Һәм чын, халык арасында икейөзле кеше буларак исемең чыккач, сиңа кем кызын бирер?

Касыйм. Мин, Сәлим абзый...

Сәлим. Шуны әйтәм шул, Мөхәммәткасыйм, андый булма, тәүфыйклы бул, Алла Тәбарәк вә Тәгалә үзеңә тәүфыйк бирсен.

Сәлим эчке бүлмәгә кереп китә. Касыйм баскан җиреннән кузгалмыйча шунда кала.

Пәрдә төшә

Әсәргә анализ

«Помада мәсьәләсе» — комедия. Шуңа күрә аның эчтәлегендә юмор-сатира әсәрләренә хас буш, нигезсез берничә конфликт булырга тиеш. Шундый буш конфликтларның әсәрдәге вакыйгаларны ачыклап килүчесен, җыеп торучысын табыйк.

Әсәрнең исеменнән үк күренгәнчә, төп конфликт помада мәсьәләсе белән бәйләнгән булырга тиеш. Гадәттә, әдипләр, үз фикерләрен белдерү өчен, нинди дә булса юл табалар. Комедиядә автор үз фикерен Рәхмәтулла белән Камалетдин диалогы эченә кертә:

— Уйлап карыйм да исем китә, шул помада да *(бармагын күрсәтеп)* моның кадәрле кечкенә генә нәрсә бит! — ди өченче пәрдәдә Рәхмәтулла.

— Үзе кечкенә генә булса да, аның мәсьәләсе зур. Укыган кешеләребезнең ни сөйләгәнен ишетәсең бит: бу мәсьәлә бөтен Россия өчен кирәк икән,— дип каршы төшә Камалетдин.

Конфликт бик кечкенә нәрсәнең бик зур нәрсә итеп кабул ителүендә, ди автор. Ләкин кечкенә белән зур каршылыгы сан каршылыгы гына әле ул. Шуңа күрә Идрис Багданов «кечкенә» сүзенә шунда ук ачыклык кертә, Рәхмәтулладан:

— Сабый кызның, аны-моны белмичә, иреннәренә помада сөртүеннән шундый зур эш булып китте,— дип әйттерә.

Ләкин помаданың хәраммы-түгелме мәсьәләсе конфликтның асылы түгел бит әле. Гадәттәгечә конфликтның ике ягын аерым-аерым өйрәник.

Помада сөртүнең хәрамлыгы, чынлыкта, Нәгыймәдән баш тартып, унбиш яшьлек Фәридәгә өйләнү өчен ялган сәбәп

кенә. Димәк, әсәр конфликтының нигезендә җитмеш яшьлек Сәлим байның унбиш яшьлек кызга өйләнү теләге ята. Бу теләкнең ахмаклык, бозыклык булуын искә алсак, помада мәсьәләсенең нигезендә дә мәгънәсезлек, бозыклык ятуын күрәбез. Ләкин комедия авторы моның белән генә дә канәгатьләнми. Помада мәсьәләсенең мәгънәсезлек дәрәҗәсен тагын бер мәртәбә арттыра. Сәлим карт Нәгыймәгә яше олырак дип өйләнми. Чынлыкта исә кыз, нәкъ карт теләгәнчә, унбиштә булып чыга.

Шулай итеп, конфликтның бер ягында помада мәсьәләсенең мәгънәсезлеге артканнан-арта бара. Җитмеш яшьлек картның, яше олырак дип, уналты яшьлек кыздан баш тартуыннан да зуррак ахмаклык табып булмас кебек. Идрис Багданов аннан да мәгънәсезрәк помада мәсьәләсен уйлап таба. Җитмәсә, җитди дип кабул ителгән бу мәсьәләнең нигезенә тагын бер мәгънәсезлек — кызның яшен арттырып күрсәтү ахмаклыгын салып куя.

Конфликтның икенче ягын өйрәник. Башта помада мәсьәләсе шәһәр укымышлылары һәм байлары арасында җитди бер мәсьәләгә әйләнә. Аннары губернатор чишәргә тиешле проблема булып күтәрелә. Помада мәсьәләсенең җитдилеген арттыра-арттыра шәһәр укымышлылары һәм байлары Россия хөкүмәтенә, ә аннан соң патшаның үзенә кадәр җитәләр. Өстәвенә бу мәсьәлә җәелә-күтәрелә торгач, шәһәрдә фетнә туута кадәр барып җитә.

Әсәр менә шулай, бер яктан, мәсьәләнең җитдилек дәрәҗәсе төшкәннән-төшә, ә икенче яктан, шул ук мәсьәләнең җитдилек дәрәҗәсе артканнан-арта барган каршылыкка корылган.

Драма әсәрләренең эчтәлеге конфликтта ачыла, шуңа күрә без дә әсәр эчтәлеген конфликт эчендә эзләргә тиеш булабыз.

Драма әсәрләренә анализ үзенчәлеген искә төшерик. Әдәбиятның бу төрендә башта төп конфликтны, аннары шуңа тыгыз бәйләнештә торган башка, ваграк конфликтларны өйрәнә идек. Шулай итик: төп конфликтның беренче өлешен тагын бер кат күз алдыннан кичерик. Монда персонажларның барысы да үләргә җыенган чирле Сәлим картның унбиш яшьлек кызга өйләнергә ниятләвен табигый хәл дип исәплиләр. Нигъмәтулла кызын шул картка бирү өчен җан атып йөри, Касыйм белән Мифтах, үзара ярыша-ярыша, кызны кодаларга килгәннәр. Бу явызлыкка берәүнең дә эче пошмый, шәһәр муллаларының да, байларының да исе китми. Шундый

никахның явызлык булуы турында соңгы пәрдәдә Вәлиулла гына әйтә. Ләкин ул да соңгы минутка кадәр кызы Фәридәне Сәлимгә бирергә йөри. Тегесе баш тарткач кына, ачудан хакыйкатьне әйтеп сала. Вәлиулла да, Нигъмәтулла да, башкалар да никахның явызлык булуын белеп торалар, әмма бар да табигый бер хәл итеп кабул итәләр. Димәк, әсәрнең беренче өлешендәге конфликт табигый булмаган никахны табигый итеп күрүдән гыйбарәт.

Ни өчен персонажлар яманлыкны яхшылык итеп күрсәтмәкче булалар соң? Нигъмәтулла, Касыйм, Мифтах һәм башкаларның да Сәлим бай алдында яхшатлы буласылары килә. Алар Сәлим байдан акча йолкырга да ниятләмиләр, дәрәҗәле кешегә ярап, үзләренең дәрәҗәләрен арттырырга тырышалар.

Беренче пәрдәдә Нигъмәтулла хатынына: «Сәлим бай бик зур кеше, беләсеңме, аңа никадәр халык тәрилкә тотып йөри». «Себер бае белән туганлашкач, кеше күзендә безнең кадеребез беләсеңме никадәр артыр»,— ди. Комедиядәге башка персонажлар да, Сәлим бай алдында тәлинкә тотып, үз кадерләрен арттырмакчы булалар.

Төп конфликт чишелешендә персонажлар кинәт эшнең зурга китүеннән куркып калалар. Фетнә җаваплылыгын үз өсләреннән төшереп, башкаларга аударырга тырышалар.

Помада сата торган кибеттәге фетнә вакыйгасы сәхнәдә күренмәсә дә, автор бу хакта персонажларыннан күп сөйләтә. Помадага каршы көрәшкә башта шәкертләр күтәрелүен Галиәсгар сөйли. Алар өндәмәләрендә: «Безнең карт муллаларыбызның салма ашап кына ятмаклары, аларның милләт өчен, гомуми файда өчен һичкайчан бармакларын селкетеп карамадыклары бу мәсьәләдә (помада мәсьәләсендә.— *А. Я.*) бик нык ачыкланды. Аның өчен Сибириядән килмеш бер бай муллаларыбызның күзен ачмаса, алар бу кеби мәсьәләнең ихтималын да Кыяматкә кадәр белмәсләр иде. Бу мәсьәләне милли эшләргә бәйләнеше булмаган бер сәүдәгәрнең чыгаруы һәммәбез өчен бик зур оятдыр»,— дип язалар. Шәкертләр помадага каршы көрәшү өчен төзелгән комиссиягә үзләрен дә кертүне таләп итәләр. Шәкертләргә кибетчеләр, итчеләр, көнлекчеләр — шәһәр яшьләре кушылалар. Кешеләрнең, сыер көтүе кебек, кая кусалар, шунда чабулары — төп конфликт чишелешендә ачылган икенче мөһим тема.

Комедиядәге бүтән конфликтлы вакыйгаларда персонажларның холыклары белән танышабыз.

Әсәрдәге персонажларның уртак сыйфатлары икейөзлелек һәм ялагайлык дигән нәтиҗәгә килдек. Ләкин бу кешеләрнең барысы да диярлек үзләренчә икейөзле һәм ялагай.

Мәсәлән, Мифтах — хаҗга барган кеше. Башкалар аны изге, дөреслекне яратучы кеше дип мактыйлар. Хаҗи үзе дә: «Хакыйкатьне әйтер өчен, җанымны фида кылырмын»,— дип мактана. Ул күңеленең Мәккәгә, изге урыннарга омтылуы турында сөйләргә ярата. Нигъмәтулла «китмә» дип ялына. «Инде ничек булса да чыда. Болай да яхшы кешеләребез юк, син дә китсәң, монда кем калыр?!»— ди. Хаҗига Сәлим бай да зур бәя бирә: «Синдә һич берни усаллык юк, синең кебек диндар кешене һичкайчан күргәнем юк»,— ди.

Шундый диндар, изге, гадел кеше, алдап, Касыймның акчасын ала. Сәлим байга мактап сөйләргә сүз бирә, Касыймның үзенә бик күп мактау сүзләре әйтә, ләкин шунда ук мактарга тиешле кешесен Сәлим байга хурлый да башлый. Сәлим бай помада сөртүне хәрам дигәч, Мифтах, кызуланып: «Юк, хәрам түгелдер, нишләп хәрам булсын»,— дип әйтеп ташлый. Ләкин Сәлим бай хәрам сүзен кабатлап әйткәч, ялгышуын белә. Эченнән генә «менә эләктерде» дип куя. Тамашачыга Сәлим бай ни әйтсә, шуны җөпләп торучы кеше булуын белдерә. Мифтах хаҗиның үзендә каршылык бар: тышкы изгелеге астында мәкер, ялган, ялагайлык ята.

Галиәкбәр үзен сүзендә нык торучы, каты кеше дип исәпли. Аның бу сыйфаты һәр ишеткәнен кире кагудан гыйбарәт. Яшь мулла Галиәсгаргә дә шундый булырга киңәш бирә: «Һәр нәрсәне кире кагырга кирәк, шулай итсәң, дөньяда хур булмыйсың, дөрес сүз әйтүгә караганда, һәр нәрсәне хәрам дип әйтү яхшырак»,— ди. Галиәсгарне ул: «Хәләлне хәрам дияргә, әлбәттә, ярамый. Ләкин әлеге шул, помада кебек, китапларда язылмаган нәрсәне теләсәң ничек әйтергә мөмкин, ул безнең кулда. Китап (сүз Коръән турында бара.— *А. Я.*) аңлата беләсең бит, китап сүзләренең мәгънәсен аңлатып аны хәрамга чыгару бик җиңел»,— дип өйрәтә.

Рәхмәтулла Сәлим байга базардагы сүз йөртүчеләрне сүгә. Әмма үзе җыен тузга язмаган хәбәрне «сиңа гына, сер итеп кенә әйтәм» дип таратып йөри.

Комедиядә Сәлим бай, Галиәсгар, Касыйм, Нигъмәтулла да — каршылыклы образлар. Аларның да үз холыклары бар. Бер-берсенә охшасалар да, аларның һәрберсе үзләренә генә хас сыйфатларга ия.

Әсәрдә персонажлар күп. Алар образ буларак төрлесе төрле дәрәҗәдә ачылалар. Алар арасында ахун да, карт муллалар да, яшь муллалар да, суфилар да, шәһәр байлары һәм зыялылары да бар. Драматург бу персонажларның барысын да икейөзле, ялагай һәм шул ук вакытта үзләрен дәрәҗәле итеп күрсәтүче кешеләр рәвешендә сурәтли. Төрле социаль төркем вәкилләрендәге уртак сыйфатларны күреп, без Идрис Багданов милләт башында торучы кешеләрнең типик сыйфатын күрсәткән дип нәтиҗә чыгара алабыз.

Комедиянең тагын бер үзенчәлегенә игътибар итик. Бу әсәрдә уңай персонажлар юк. Димәк, автор үз бәясен уңай герое аша әйттерә алмый. Ул яман кешеләргә җәзаны шулай ук уңай кешеләрдән дә, Алладан да бирдертми. Әмма традиция дәвам итә: яман кешеләр җәза алалар. Бөтенләй башкача итеп алалар. Җәзаны автор үзе бирә. Яман кешеләрне хур итә. Үзләрен җәмгыять җитәкчесе дип йөрүче, абруйга, акылга, диндарлыкка дәгъва кылучы кешеләрнең асылда буш, юньсез, надан, бозык булуларын ачып сала. Барысын да көлкегә калдыра.

Идрис Багданов татар әдәбиятының яңа чорга аяк атлавын комедия әсәре белән тагын бер тапкыр раслый.

Йомгак

XIX гасыр әдәбияты урта гасыр әдәбияты казанышларын дәвам итте: халык авыз иҗаты алымнарын өйрәнде, гомумтөрки әдәбиятындагы әхлак темасын яңа шартларда яңача ачарга омтылды. Бу чорда иҗат ителгән әсәрләрдәге вакыйгаларда автор турыдан-туры үзе катнашты яисә фикерләрен уңай герое авызыннан әйттерде. Шуңа күрә әсәрләрнең төзелеше бик гади, беркатлы һәм бер-берсенә шактый охшый. Мәүла Колый, Утыз Имәни шигырьләрен исегезгә төшерегез. Шагыйрьләр икесе дә укучыларын яхшы, әдәпле, сабыр булырга үгетлиләр. Яхшы кеше булуның төп шарты — дингә тугрылыклы булу, диләр. Акмулла, Каюм Насыйри, Кандалый да үзләренең укучыларын яхшы, әдәпле булырга өйрәтәләр. Ләкин моңа ирешү өчен, кешенең белемле булуы шарт дип исәплиләр.

Мәгърифәт — бу чорда иҗат иткән әдипләр өчен максат түгел, намуслы, игелекле, шәфкатьле булу чарасы.

Бу чорда рус мәдәнияте бик нык алга китә. Пушкин, Лермонтов, Гоголь, Островский, Достоевский кебек әдипләр бөтен

дөньяга танылалар. Татар язучылары, ашыга-ашыга, рус әдәбиятын өйрәнә башлыйлар.

Татар язучылары рус матбугаты аша чит илләрдә промышленность һәм авыл хуҗалыгының алга китүе, андагы халыкларның үз ирекләрен яулап көрәшүләре турында да белешмә алалар. Татар әдипләре үз халкының мескенлеген, ярлылыгын шул илләрдәге тормыш дәрәҗәсе белән чагыштырып карыйлар да уйга баталар. Татар халкын да шул дәрәҗәгә җиткерү хыялы белән яна башлыйлар. Моның өчен татар халкын йокысыннан уятырга, кызыксындырырга кирәк дигән нәтиҗәгә киләләр. Кешеләрне белемле, алдынгы карашлы яшьләр генә уята һәм һөнәр белән кызыксындыра алалар дип исәплиләр. Бу алдынгы карашка (прогресска) тәрәккыйпәрвәр дип исем бирәләр һәм шуңа ирешү өчен үзләренчә көрәшә башлыйлар.

Мәгърифәт татар әдәбияты өчен прогресска ирешү чарасы да иде.

Бу чор әдәбиятының и д е а л ы шуның өчен намуслы, игелекле, белемгә һәм үз хезмәте белән баерга омтылучы актив кеше булды.

Укымышлы, эшлекле, алдынгы карашлы кешеләр үсеп чыксын өчен, шартлар кирәк иде. Ләкин власть башында утырган түрәләр — иске карашлы муллалар, байлар — үзләренә уңайлы, күнегелгән тормыш тәртипләрен үзгәртергә теләмиләр. Алар үзләре урынына акыллы, эшчән кешеләр килүен яхшы аңлыйлар. Шуның өчен язучылар, дәррәү кубып, иске карашлы түрәләрне тәнкыйтьләргә керешәләр. Тора-бара бу тәнкыйть юмор-сатирага әйләнә башлый. Габделҗәббар Кандалый әсәрләрендә инде без аның халык авыз иҗаты әсәрләре белән тиңләшерлек үрнәкләрен күрә алабыз.

Юмор-сатира әсәрләренең барлыкка килүе бу чор әдәбиятының зур казанышы булды.

1800 елда беренче татар типографиясе ачыла. Тора-бара Казанда әдәби әсәрләрне меңәр данә баса башлыйлар. Шул рәвешле, татар әдәбияты җәмгыятькә тәэсир итәрлек дәһшәтле көчкә әверелә.

Беренче татар романы «Өлүф[1], яки Гүзәл кыз Хәдичә» (авторы Заһир Бигиев) һәм беренче татар пьесасы «Комедия Чистайда» (авторы билгесез) русчадан тәрҗемә ителәләр. Лә-

---

[1] *Өлүф* — меңнәр.

кин бераздан Заһир Бигиев «Гөнаһе кәбаир» («Зур гөнаһлар»), «Катилә», «Мөртәт» исемле романнар яза. Соңгылары татар тормышындагы бозыклыкларны тәнкыйтьләгән беренче татар романнары булалар.

Тиздән Габдрахман Ильясиның «Бичара кыз» һәм Фатих Халидиның «Рәдде бичара кыз»[2] пьесалары языла. Пьесалар әле сәнгать ягыннан бик йомшак булалар. Ләкин бу романнарда һәм пьесаларда персонажларның кичерешләрен тасвирлауга омтылыш сизелә. Габдрахман Ильяси һәм Фатих Халиди пьесалары драматург Галиәсгар Камалны «Бәхетсез егет» драмасын язарга рухландыралар. Соңрак Идрис Багданов «Помада мәсьәләсе» комедиясендә «Мәкәрҗә бәете»ндә күтәрелгән иҗтимагый теманы дәвам итә. Бәет авторы рус түрәләренең явызлыгын фаш итсә, Багданов татар түрәләренең наданлыгыннан, ахмаклыгыннан, ялагайлыгыннан көлә.

Әсәр эчтәлегендә иҗтимагый теманың чагылышы чор әдәбиятының тагын бер казанышы иде.

---

[1] *Рәдде бичара кыз* — бичара кызга каршы.

XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ

Татарлар рус империясе эчендә, язмышларына буйсынып, беркөйгә көн күрәләр: иген үстерәләр, эшкуарлар, империя тыюына карамастан, завод-фабрикалар төзиләр, сәүдә итәләр. Алдынгы фикерле укымышлылар китап бастыру артыннан йөриләр. Әдипләр пассивлыкта гаепләгән халык, белем алуга килгәндә, өлгерлек күрсәтә — мәдрәсәләр ача. Татар халкы белемле кешене элек-электән ихтирам иткән. Шуңа күрә безнең бабайлар барысы да диярлек укый-яза белгәннәр. Бу яктан татарлар күршеләрен дә уздырганнар.

Шулай бер җай белән яшәп ятканда, тарих үзенең холкын күрсәтә: аптырап калган кешеләр башына берсеннән-берсе хәтәррәк вакыйгалар яудырырга керешә. 1904 елда Россия Япония белән сугыша. Тагын бер елдан бөтен тормышны тетрәткән, йөрәкләрне ярсыткан революция була. Аннары, кара болыт каплагандай, караңгы реакция еллары тезелеп китә. 1914 елда бөтендөнья сугышы башлана. Ә тагын өч елдан Февраль революциясе кузгала. Патша төшерелә.

Татарлар бу вакыйгаларның барысында да катнашалар. Сугышлар халыкка хәсрәт, ачлык китерә, революцияләр кешеләр күңелендә азатлык өмете уята.

1905 елгы революция илгә азмы-күпме ирек алып килә. Халык күңелен җилкеткән вакыйгаларның берсе шул була. Татар китаплары күпләп басыла башлый, газета-журналлар саны артканнан-арта бара. Цензураның йомшаруы кешеләргә үз фикерләрен яшермичә әйтергә һәм язарга мөмкинлек ача.

Әдипләр әсәрләрендә халык мәнфәгатьләрен чагылдыралар. Ләкин шул ук вакытта халыкка үз фикерләре белән дә тәэсир итәләр. Шуңа күрә бу елларда татарлар арасында демократик карашлар көчәя.

Демократия дип ил белән халык идарә итүгә әйтәләр.

Бу елларда безнең бабайлар, рус дәүләтеннән аерылып, мөстәкыйль дәүләт төзү турында хыялланмыйлар да әле. Өметләре бер генә: Думага (парламентка) татарларны да сайлап,

илне идарә итүдә катнашу. Шулай иткәндә татарлар да, кеше рәтенә кереп, ниндидер хокук алачаклар дигән ышаныч көчле була. Чыннан да, Думага татар вәкилләрен дә сайлау үзе бер зур бәйрәмгә әйләнә. Күңелләрнең ерак бер почмагында посып яткан милли горурлык хисе кабат кабынып китә.

Демократия — шулай ук шәхси ирек, сүз иреге, гадел законнарга буйсынып яшәү дигән сүз.

Азатлык, шәхси ирек, сүз иреге татарларда милли горурлык хисенә төренә. Шулай итеп, изге максатка — матурлыкка әйләнә. Борынгы бабайларның бай мирасын — милли горурлыкларын кабат кайтару теләге шулкадәр көчле була, азатлык өчен көрәш әдипләрнең язмышына, яшәү мәгънәсенә әйләнә.

Реакция еллары халыкның матур хыялларын челпәрәмә китерә, сугыш еллары бөлгенлеккә төшерә. Бу хәл, әлбәттә, татар язучыларын бәхетсез итә. Ләкин азатлык хыялы, бер тышка бәреп чыккач, күңелләрдәге тар почмакларга кире кереп урнаша алмый. Тарих үзе бүләк итеп тә кабат тартып алган өмет яшәргә, күңелләрдә генә булса да дөрләп янарга тиеш була. Бу елларда әдипләр азатлык матурлыгыннан хыялый яңа дөнья коралар. Үзләрен шул күңел дөньясында ирекле, бәхетле кешеләр итеп тоялар, шул рәвешле булса да, укучылары күңелендәге ирек ялкынын сүндерми торалар. Бу чорда әдәбиятта туган романтизмның үзенчәлеге шуннан гыйбарәт.

Әдипләр уенча азатлык көрәшсез бирелми, моның өчен кешеләр аңлы булырга, укырга, өйрәнергә тиешләр. М ә г ъ р и ф ә т ч е л е к карашы, азатлык максатына буйсынып, яңа эчтәлек ала һәм XX йөз башы әдәбиятында да дәвам итә.

XX йөз башы, әдәбият үсешен күрү өчен, бик аз вакыт. Ләкин шул егерме ел эчендә татар әдәбияты бик зур тизлек белән үсеп китә. Бу еллар Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Г. Камал, Ш. Камал, Г. Ибраһимов, М. Фәйзи, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, И. Багданов кебек, татарларның милли горурлыгы, мактанычы булган талантлы әдипләрне бирә. Әдәбият башка бер чорында да бу кадәр талант ияләрен тудыра алмады. Тукайлар буыны әдипләре татар әдәбиятын югары дәрәҗәгә күтәрделәр.

Габдулла Тукай
(1886—1913)

Габдулла Тукай элекке Казан өязе Мәңгәр волосте Кушлавыч авылында туа. Әтисе Мөхәммәтгариф (шул авылның мулласы) улына дүрт ай ярым булганда дөнья куя. Озакламый әнисе Мәмдүдә дә үлеп китә. Габдулла ятим кала. Бала чагында башыннан үткәннәрне шагыйрь сез бишенче сыйныфта өйрәнгән «Исемдә калганнар» әсәрендә яза. Хәтерегезгә төшерегез, нәни Габдулланы Печән базарыннан Казандагы Яңа Бистә һөнәрчесе Мөхәммәтвәли белән Газизә өенә алып кайтып тәрбиялиләр. Кырлайда ул Сәгъди абзый гаиләсендә яши.

Кырлай турында Тукай аеруча бер җылылык белән яза. Монда ул эшкә өйрәнә, дөньяны танып белә башлый, мәдрәсәгә укырга керә. Аннары Габдулланы атасының сеңлесе Газизә үз янына Уральск шәһәренә алдыра. Булачак шагыйрь шәһәрдә укуын дәвам иттерә, бер үк вакытта рус сыйныфына да йөри. 1905 елгы революциядән соң искечә (кадимчә) укытыла торган мәдрәсәләргә дә яңалыклар үтеп керә башлый. Габдулла дөньяви фәннәр белән таныша, гарәпчә, фарсыча сөйләшергә өйрәнә. Укуын дәвам иткән хәлдә, рус телендә чыга торган «Уралец» газетасында өйрәнчек хәреф җыючы булып эшли. Уральскида татарча «Фикер», «Әлгасрелҗәдит» газеталары һәм «Уклар» исемле сатирик журнал чыга башлагач, Тукай эшләргә шунда күчә: хәреф җыючы, корректор (хата төзәтүче) вазифаларын башкара, бу газеталарның һәм журналның иң актив авторы була.

1907 елда шагыйрь тормышында кискен борылыш була. Бу елда Габдулла Тукай мәдрәсәне ташлый. Ул эшләгән газета

һәм журналлар башка хуҗа кулына эләккәннән соң тарка-
лалар. Шагыйрь эшсез кала. Габдулла Уральскидан Казанга кайта. Монда ул Фатих Әмирхан белән очраша. Ике зур әдип уртак телне тиз табалар. Кирәгеннән артык оялчан, һәрвакыт киңәшкә, ярдәмгә мохтаҗ Тукай өчен төпле, акыллы, сабыр холыклы, игелекле Фатих Әмирхан дус, туган, киңәшче була. Башта шагыйрь Фатих Әмирхан чыгарган «Әлислах» газетасында эшли. Бер үк вакытта «Китап» нәшриятына экспедитор булып эшкә керә.

Тагын бер елдан Габдулла Тукай белән Галиәсгар Камал «Яшен» исемле сатирик журнал чыгара башлыйлар. Ләкин усал телле, кыю фикерле журналлар реакция елларында озак яши алмыйлар. Журнал ябыла. Шагыйрь аптырап калмый, шунда ук фикердәшләре белән киңәшеп, «Ялт-Йолт» исемле башка сатирик журнал чыгара башлыйлар. Бу журналда ул гомеренең соңгы көннәренә кадәр эшли.

Габдулла Тукай үпкә авыруыннан үлә. Аңа нибары егерме җиде яшь була. Язмышы саранланган — иҗаты өчен шагыйрьгә 7—8 ел гына өлеш чыгарган. Ләкин Тукай шул берничә ел арасында да дүрт томга сыярлык әсәрләр язарга өлгергән. Шул ук елларда әле ул төрле эшләрдә, хәтта икешәр урында эшләгән. Астраханьга, Уфага, Петербургка, Троицкига барып кайтырга өлгергән.

Тукай гомере буена сәламәтлеккә туймаган. Аның даими бер торыр урыны да, гаиләсе дә, мөлкәте дә, якын туганнары да булмаган.

Шундый шартларда мондый күләмдә эш башкару өчен бик зур ихтыяр көче кирәк. Сәламәтлеге какшаса да, Тукай бик көчле кеше булган.

Шагыйрь зурлауларны, мактауны, төрле шау-шуларны, гомумән, үзенә игътибар итүне яратмаган. Замандашлары аның турында: бик оялчан, тыйнак кеше иде дип язалар. Оялчан, тыйнак, шәфкатьле Тукай үзенең сатирик шигырьләрендә һәм поэмаларында милләтне артка сөйрәүчеләрне бөтен бер социаль төркемнәре белән дә, исемнәрен әйтеп тә кыйнапмыкыйнаган. Ул, төрле юллар табып, патша хөкүмәтенең үзенә дә ачы хакыйкать әйтергә курыкмаган. Оялчан шагыйрь заманының иң батыр кешесе булган.

Болай да яшь Тукай кыяфәте белән тагын да яшьрәк булып күренгән. Ләкин шул яшь егет татар халкының таянычы, ышанычы, горурлыгы, милләтнең аксакалы булган.

Шагыйрь иҗатын ике чорга бүлеп өйрәник. Беренче шигырьләрен язганда, Габдулла Тукай бик яшь, тәҗрибәсез була әле. Дөньяга карашы да, идеаллары да яңа оешып килә, теле дә — башкаларныкы кебек, гарәп, фарсы сүзләре белән буталып беткән авыр тел. Бу әсәрләрен шагыйрь үзеннән алда иҗат итүче мәгърифәтче әдипләргә ияреп яза. Аларда аң-белем алырга чакыру да, намуслы булырга өндәү дә, милләтне тәрәккый итү дә — барысы бергә җыелып, әсәрләрнең темаларын да, идеяләрен дә тәшкил итәләр. Габдулла Тукай әле эзләнә, дөньяны аңларга тырыша, күп санлы юллар, сукмаклар арасыннан үз юлын сайлый.

Әйдәгез, башта шагыйрьнең өйрәнчек шигырьләре белән танышыйк.

ДУСТЛАРГА БЕР СҮЗ

Менә, дустлар, мин сезләргә бер сүз сөйлим,
«Йосыф-Йагъкуб китабы»ның көен көйлим;
Ушбу милләт ертыгының җөен җөйлим,—
Җебем — кара, инәм каләм булсын имди.

И кардәшләр, кул тотышып алга барыйк,
Башка милләтләрнең хәлен карап карыйк;
Мәдәният мәйданында урын алыйк,—
Егъла-тора алга таба атлыйк имди.

Гыйлем белмәс хайваннарга без охшамыйк,
Тырышмактан, тырмашмактан һич бушамыйк;
Диңгез якасында торып, без сусамыйк,—
Хөрриятнең диңгезләре ташый имди.

Чиновниклар безнең канны бик күп имде,
Имәлмәсләр, җитәр инде, җитәр инде!
Мәзлумнәргә[1] якты, нурлы көннәр килде,—
Азатлыкның кояшы тугъды имди.

Һәр милләтләр максудларын хасил итә[2],
Депутатлар ясап, Петербургка китә;
Инде нәүбәт без бичараларга җитә,—
Җыйлып-җыйлып, депутатлар сайлыйк имди.

---

[1] *Мәзлумнәргә* — җәберләнгән кешеләргә.

[2] *Максудларын хасил итә* — теләкләрен тормышка ашыра.

Бездә күзе ачык кешеләр дә бардыр,
Бу заманда гафилләргә[1] дөнья тардыр;
Бу хөррият — Манифесте государьдыр[2],—
Кадрен белеп, кирәкләрне сорыйк имди.

Бу эшләрдә зәхмәтләмик муллаларны,
Дин эшендә башчы иттек без аларны;
Яхшы булыр тапшырсак без дөньяларны
Абразауный егетләргә тәмам имди.

Барып керик хөрриятнең кочагына,
Тәрәккыйнең күкләренә очмагына;
Бу егетләр безне дөнья оҗмахына
Кулдан тотып җитәклиләр, белсәң имди!

1905 ел

Шигырьнең эчтәлеген табыйк.

Әсәрнең ике өлешен Габдулла Тукай беренче строфасында ук үзе әйткән. «Милләт ертыгының җөен җөйлим» дигән. Метафораның мәгънәсен табарга кушкан. Шулай итәбез дә. «Милләтнең ертыгы» ди шагыйрь — кимчелеген күз алдында тота. «Җөйлим» ди — кимчелеген бетерәм, ди.

Башта Габдулла Тукай күрәсе килгән милләтнең яхшы сыйфатларын санап чыгыйк. Шагыйрь татар милләтенең мәдәниятен алдынгы милләтләр мәдәнияте дәрәҗәсенә менгерә. Бу өлешкә «мәдәниятне үстерү» дип, кыскартып исем бирик. Аннары халыкны тырыша-тырыша укыта. Халыкның бу матур сыйфатына «белем алу» дип исем бирәбез.

Биремнәр

1. Милләтнең шагыйрь санап чыккан уңай якларын барлауны дәвам итегез.

2. Милләтнең «ертыгын» — ямьсез якларын барлап чыгыгыз. Ул сыйфатларга да исемнәр бирегез.

3. Тукайга кадәр иҗат иткән мәгърифәтчеләр дә мәдәният үсеше, белем алу, тырышлык турында яздылар. Габдулла Тукай алар искә алмаган теләкләр турында да яза. Шул теләкләрне әйтегез.

---

[1] *Гафилләргә* — ваемсыз, пассив кешеләргә.

[2] *Манифесте государьдыр* — патшаның ирек вәгъдә иткән 1905 елгы 17 октябрь Манифесты.

ИТТИФАКЪ[1] ХАКЫНДА

Күрең патша хәзрәтен,
Җуйды халык хәсрәтен;
Күргәч фетнә кәсрәтен[2],
Киңлек бирде, бәдәвам.

Файдаланыйк киңлектән,
Ваз кичик мин-минлектән;
Көчле-көчсез тиңлектән
Файда алыйк, бәдәвам.

Тырышыйк, и хас вә гам[3],
Һәр көн үзгәрә заман;
Җитәр, йокламыйк һаман,—
Таңнар атты, бәдәвам.

Кызганамын сезләрне,
Ник ачмыйсыз күзләрне?
Киләчәктә бәхетләр
Көтә безне, бәдәвам.

Итик, дуслар, иттифакъ,
Бетсен, кадалсын нифак[4];
Тәнебез айрым булса да,
Бер җан булыйк, бәдәвам.

Якты көннәр алдале,
Җәһел[5] безне алдалый;
Бүлик без бер алманы
Биш кисәккә, бәдәвам.

Җыйналып мәҗлес ясыйк,
Бер-беремездән качмыйк;
Наданлыкка юл ачмыйк,—
Бик күп изде, бәдәвам.

Кайчанга чаклы татар
Ушбу уйкуда[6] ятар;
Бер-берсенә ук атар,
Иттифакъсыз, бәдәвам.

Ачыйк иттифакъка юл:
Ушбудыр иң тугъры юл;
Сыңгар җиңнән ике кул
Чыгарыйк без, бәдәвам.

1905 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Бу шигырьнең «Дустларга бер сүз» шигыре белән уртак ягын һәм аермасын табыгыз.

2. Әлеге шигырьләрен иҗат иткәндә, Габдулла Тукайга 19 яшь була. Шигырьләр эчтәлегеннән чыгып, 19 яшьлек Тукайның дөньяга карашы турында әйтегез һәм аңа үзегезнең бәягезне бирегез.

---

[1] *Иттифакъ* — берләшү.
[2] *Кәсрәтен* — күплеген.
[3] *Хас вә гам* — барыгыз бергә.
[4] *Нифак* — икейөзлелек.
[5] *Җәһел* — наданлык.
[6] *Уйкуда* — йокыда.

3. XIX гасыр мәгърифәтчеләре (әйтик, К. Насыйри) белән чагыштырганда Г. Тукайның дөньяга карашында нинди уртаклык һәм аерма бар?

4. Соңрак Габдулла Тукай бу елларда язган шигырьләрен «разый булмаган шигырьләрем» дип бәяли. Бу ике шигырь белән Тукай ни өчен риза булмаска мөмкин?

ПАР АТ

Җиктереп пар ат, Казанга туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер, суккалап та тарткалап.

Кич иде. Шатлык белән нурлар чәчеп ай ялтырый;
Искән әкрен җил белән яфрак, агачлар калтырый.

Һәр тараф тын. Уй миңа тик әллә ни җырлый, укый;
Нәрсәдәндер күз эленгән һәм тәмам баскан йокы.

Берзаман ачсам күзем, бертөрле яп-ят кыр күрәм;
Аһ, бу нинди айрылу? Гомремдә бер тапкыр күрәм.

Сау бул инде, хуш, бәхил бул, и минем торган җирем,
Мин болай, шулай итәм дип, төрле уй корган җирем.

Хуш, гомер иткән шәһәр! инде еракта калдыгыз;
Аһ! таныш йортлар, тәмам күздән дә сез югалдыгыз.

Эч поша, яна йөрәк, хәсрәт эчендә, уйда мин;
Ичмасам, иптәш тә юк ич, тик икәү без: уй да мин.

Аһ, гөнаһым шомлыгы, бу кучеры бик тын тагын,
Җырламыйдыр бер матурның балдагын йә калфагын!

Әллә нәрсәм юк кеби; бер нәрсә юк, бер нәрсә ким;
Бар да бар, тик юк туганнар, мин ятим монда, ятим.

Монда бар да ят миңа: бу Миңгали, Бикмулла кем?
Бикмөхәммәт, Биктимер — берсен дә белмим, әллә кем!

Сездән аерылып, туганнар! — җайсыз, уңайсыз тору;
Бу тору, әйтергә мөмкиндер, кояш-айсыз тору.

Шундый уйлар берлә таштай катты китте башларым;
Чишмә төсле, ихтыярсыз акты китте яшьләрем.

Бер тавыш килде колакка, яңгырады берзаман:
«Тор, шәкерт! Җиттек Казанга, алдымызда бит Казан!»

Бу тавыш бик ачты күңлем, шатлыгымнан җан яна;
«Әйдә чап, кучер, Казанга! Атларың ку: на! на-на!»

Әйтә иртәнге намазга бик матур, моңлы азан;
И Казан! Дәртле Казан! Моңлы Казан! Нурлы Казан!

Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары;
Мондадыр дәртле күңелнең хурлары, оҗмахлары.

Монда хикмәт, мәгърифәт һәм монда гыйрфан[1], монда нур;
Монда минем нечкә билем, җәннәтем һәм монда хур...

1907 ел

Шигырьнең эчтәлеген табыйк.

Әсәрнең бер өлеше — лирик геройның кичерешләре, ә икенче өлеше теләкләре турында. Өлешләрне өйрәнүгә күчик.

Беренче өлештә лирик герой хисе әледән-әле үзгәреп тора. Башта лирик герой шатлана. Сәбәбе — Казанга китү. Аннары борчыла, сәбәбе — бала чагы үткән илдән аерылу.

Биремнәр

1. Хиснең үзгәрүенә «шатлык» һәм «борчылу» дип исемнәр бирәбез. Ләкин лирик герой хисе үзгәрүендә дәвам итә. Башка үзгәрешләрне үзегез табыгыз. Аларга исемнәр бирегез.

2. Лирик геройның теләкләрен санап чыгыгыз.

3. Башкарган эшегезне кыскача болай язарга була:

I. Лирик герой хисе:
а) шатлыгы;
ә) борчылуы һ. б. (дәвам итегез).

II. Лирик герой теләкләре:
а) борынгы бабайлар яшәгән башкалада яшәү (дәвам итегез).

Эчтәлекне мөмкин кадәр кыска итеп язу эш планы була. Планыгызны тутырыгыз. Шуның нигезендә инша языгыз. Планда өзек-өзек булып күренгән бүлекләр иншада үзара бәйләнешкә керергә тиешләр. Шигырьдә лирик герой хисенең дәрәҗәсе дә, юану да бар. Иншагызда аларын да күрсәтегез. Шигырь атлар турында түгел. Алай да Тукай әсәрен «Пар ат» дип атаган. Ни өчен шулай иткән? Пар атның мәгънәсен ачыкларга тырышыгыз.

---

[1] *Гыйрфан* — мәдәният.

СӨТКӘ ТӨШКӘН ТЫЧКАН

Ничектер, белмимен, беркөн идән асты кошы — тычкан
Егылган да келәттә бер табак сөткә килеп төшкән.

Йөзеп карый табакта арлы-бирле — һич чыгып булмый!
Сыек сөт бит — бата, һич тә табактан ычкынып булмый.

Йөри тычкан, йөзәдер, тик торып булмый, йөрәк түзми;
Йөзәдер аркылы, буйга,— котылмактан өмид өзми.

Тырышмак бушка китми бит, береаздан соң була уңгай:
Бу тычкан шулкадәр йөзгән, куерган сөт тә — булган май.

Хәзер бит батмый,— тычкан, кирелеп, майга аяк баскан;
Сикергән дә табактан ул, чыгып, үз урнына качкан.

*

И карендәш! син, кирәксә, суга бат йә сөткә бат!
Ит сабыр, күрсәт чыдамлык һәм дә ит гайрәт, сөбат[1]!

1907 ел

Бирем

Әсәрнең жанрын белегез һәм хикмәт алымы белән язылуын исбат итегез.

ТУГАН ҖИРЕМӘ

Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин,
И Казан арты! сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми[2];
Тарта торгач куймады, кайтарды ахыр җисмеми[3].

Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине,
Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине,—

Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби;
Уйласам, ул көннәрем тик кичтә күргән төш кеби.

Бәрсә дә дулкыннарың, һич алмады, гаркъ итмәде[4];
Алды дүрт ягымны ялкын, якмады, харкъ итмәде[5].

---

[1] *Сөбат* — ныклык.
[2] *Хиссеми* — тойгымны.
[3] *Җисмеми* — гәүдәмне (үземне).
[4] *Гаркъ итмәде* — батырмады.
[5] *Харкъ итмәде* — яндырмады.

Бу сәбәптән аңладым мин, и туган җирем, синең
Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының!

Җөмләтән[1] изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,
Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың;

Һәр фосулы әрбәгъәң[2]: язың, көзең, җәй, кыш көнең;
Барча, барча ак оек, киндер, чабата, ыштырың!

Һәр көтүчең, этләрең, үгез, сыер, сарыкларың;
Барчасы яхшы: бүре, җен, шүрәле, сарикъларың.

1907 ел

Биремнәр

1. Әсәрне ике каршы якка аерыгыз. Алар арасындагы бәйләнешне табыгыз.

2. Лирик геройның мәхәббәт дәрәҗәсен күрсәткән алымны әйтегез.

КӨЗ

Күрәмсез, дустларым, көз килде тышта;
Озак тормас, килер ак тунлы кыш та.

Китә башлады бездән инде кошлар;
Алар бездән ерак җирләрдә кышлар.

Мисале зәгъфыран[3] саргайды урман,
Игенчеләр игеннәрне дә урган.

Такыр калды татар башы кеби кыр;
Азык эзли — оча тургай да пыр-пыр.

Чыгып баш калкыта сахрада уҗым,
Яшел хәтфә шикелле итә җем-җем.

Кояш та яктысын киметте шактый;
Тәәссеф[4]! басты золмәт, китте якты.

Колакны шаулата инде суык җил,
Тулып эчкә өрә, мисле[5] куык, җил.

---

[1] *Җөмләтән* — барчасы.
[2] *Фосулы әрбәгъә* — елның дүрт вакыты.
[3] *Мисале зәгъфыран* — зәгъфран кебек.
[4] *Тәәссеф* — үкенеч.
[5] *Мисле* — әйтерсең лә.

Ничәйтсәң дә, күңелсез көз, күңелсез;
Чәчәксез көз, үләнсез һәм дә гөлсез.

Мәзарстанга[1] охшап калды кырлар;
Чирәмсездер тигез җирләр, чокырлар.

Үлеп торсам иде мин алты айдай,
Эреп бер йокласам мин сары майдай.

Шулай йоклап, бәһар[2] җиткәндә торсам,
Торып тагы яшел җирдә утырсам,—

Бәхетле шул заман, мин бик бәхетле,
Булырмын шаһ, бәхетле һәм тәхетле.

* * *

Качан соң, и фәкыйрь милләт, бәһарың!
Качан китәр кичең, килер нәһарың[3]?

Килер мәллә кабергә мин сөрелгәч,
Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч?

1906 ел

Шигырьне өлешләргә Тукай үзе аерып куйган. Көз күренешенең ямьсезлеген язып килгән-килгән дә йолдыз белән милләтнең фәкыйрьлеге турындагы строфаларын аерып куйган. Көз күренешенең милләткә метафора булып килүен абайлау кыен түгел.

Гадәттә, табигать күренеше тасвирланган шигырьләр лирик шигырь булалар. Ләкин Тукай, көздән соң кыш килер, кошлар китәр, игенчеләр игеннәрен урдылар, кояш яктысын киметте, ди. Һәркемгә мәгълүм нәрсәләр турында яза. Тукайның көз турында һәркемгә мәгълүм нәрсәләрне юри язуын сатира алымына тартым дип әйтә алабыз. Мондый стиль аңлашыла: Габдулла Тукайның максаты көзге табигатькә соклану да, җәй үтүгә үкенү дә түгел. Шагыйрь көз турында яза, ләкин күз алдында милләтнең аяныч хәлен тота.

Сорау һәм бирем

1. Көз күренешенә Габдулла Тукай нинди мәгънә сала?

2. «Булырмын шаһ, бәхетле һәм тәхетле» юлындагы «тәхетле» сүзенең мәгънәсен аңлатыгыз.

---

[1] *Мәзарстанга* — каберлеккә.

[2] *Бәһар* — яз.

[3] *Нәһарың* — көндезең.

ГОСУДАРСТВЕННАЯ ДУМАГА

(«Ай бәгърем, Нәгыймә» көенә)

Ник бик тиз беттең син, Дума,
Ник җир-ирек алмадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума[1]?

Ник бик яшьләй картайдың соң,
Ник мәңгегә калмадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник безне кызганмадың соң,
Коллыктан коткармадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Залим башлыкларны тотып,
Ник йөрәген ярмадың? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник куылдың син үзең соң,
Ник кумадың үзләрен? —
Аң син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ник баш бөктең залимнәргә,
Ник тыңладың сүзләрен? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Ач-ялангач мужикларга
Кайда ирек, кайда җир? —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Бирәм, дидең, вәгъдә бирдең.
Күрсәт җирең? Кайда? Бир! —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

Депутатларны кудылар,
Черки төсле, көш тә көш! —
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Иткән гайрәтең бума?

Самый важный генерал да
Түлке күрсәтте күкеш,—
Ах җанашым, Дума, Дума,
Кыйлган гайрәтең бума?

Әйдә, дустлар, бер тибрәник,
Акны Тәңре яклар бит,—
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Барлык гайрәтең бума?

Караны бер көн каралтып,
Акны бер көн аклар бит,—
Ах син, Дума, Дума, Дума,
Эшләгән эшең бума?

1906 ел

Сорау һәм биремнәр

1. Габдулла Тукайның Думага әйткән дәгъваларын, уртак эчтәлекләренә карап, ике төркемгә җыегыз һәм төркемнәрнең икесенә дә исем бирегез.

2. Шагыйрь «Государственная Думага» әсәрен фәлән көйгә җырлана дип яза. Бу әсәрен ул, чыннан да, җырлар өчен язганмы?

3. Шигырьне «Дустларга бер сүз» әсәре белән чагыштырып карагыз. Эчтәлекләрендә аерма табыгыз.

---

[1] *Бума* — «бумы» сүзе «Дума» сүзе белән рифмалаштыру өчен кулланылган.

КАЗАН ВӘ КАЗАН АРТЫ

И Казан шәһре, торасың тауда зур шәмдәл кеби,
Мәсҗедең, чиркәүләрең, һәр часларың[1] шәмнәр кеби.

Син, үзеңне чорнаган һәрбер өязгә нур чәчеп,
Бик мәһабәтле торасың, барчага юл күрсәтеп.

Нур ала синнән бөтен як: Чистополь, Спас, Тәтеш
Һәм Чабаксарга, Мамадышларга Чар[2], Малмыж катыш.

Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара:
Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.

«Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампының һичбер нуры»,—
Шул мәкаль монда дөрес шул, ах, аны җен оргыры!

1912 ел

Биремнәр

1. Әсәргә анализ ясагыз. Эчтәлеген кыска итеп сөйләп бирегез.

2. Бу шигырьнең эчтәлеге белән аеруча нык бәйләнешле башка бер шигырьне әйтегез. Җавабыгызны нигезләгез.

ӨЗЕЛГӘН ӨМИД

Күз карашымда хәзер үзгәрде әшьялар[3] төсе;
Сизлә: үтте яшь вакытлар, җитте гомрем яртысы.

Күз тегеп баксам әгәр дә тормышымның күгенә,
Яшь һилал[4] урынында — анда тулган айның яктысы.

Нинди дәрт берлән каләм сызсам да кәгазь өстенә,
Очмый әүвәлге җүләр, саф, яшь мәхәббәт чаткысы.

И мөкаддәс[5] моңлы сазым! уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз, ахрысы!

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы.

Күпме моңлансам кунып милли агачлар өстенә,
Барсы корган — бер генә юк җанлысы, яфраклысы.

---

[1] *Часларың* — часовняларың, кечкенә чиркәү.
[2] *Чар* — Йошкар-Ола.
[3] *Әшьялар* — әйберләр.
[4] *Һилал* — яңа туган ай.
[5] *Мөкаддәс* — изге, кадерле.

Булмадың, алтын ярым — салкын ярым, син дә минем
Бер тәбәссем[1] берлә дә тормыш юлым яктырткычы!

Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә[2] син,
Һәр ишектән сөрде угълыңны мәхәббәт сакчысы.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы,—
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

1910 ел

Шигырьнең эчтәлеген табыйк.

«Өзелгән өмид»,— әлбәттә, лирик шигырь. Әдип иҗатының икенче чорында иҗат ителгән һәм авторның рухи халәтен аеруча тирән ачкан әсәр. Шигырьнең эчтәлеге — хис. Автор кичерешләренең сәбәпләрен әсәренең исеменә чыгарган: өзелгән өмет, дигән. Өмет сүзе бу очракта күплек мәгънәсендә килә. Әсәрдән лирик геройның тормышка ашмаган өметләрен барлыйбыз.

Беренче строфада шагыйрь гомеренең үтүе турында яза. Икенче строфаны укыйбыз, анда да сүз шул ук хакта. Ике строфаны гомумиләштереп исем бирәбез, әйтик, «гомер үтү» яки «олыгаю» дибез.

Өченче строфада Тукай элеккечә матур итеп яза алмавы өчен борчыла. Әсәренең бу өлешенә «язу авырлыгы» дип исем бирик.

Дүртенче строфа алдагы строфаларда әйткәннәрне гомумиләштереп, куәтләп килә: әдип гомере белән дә, иҗаты белән дә хушлаша.

Баштагы дүрт строфада әйтелгәннәрне гомумиләштереп языйк: өмет — матур итеп әсәрләр язуны дәвам итү иде. Гомер узу сәбәпле, ул өмет өзелде, ди әдип.

Сорау һәм биремнәр

1. Лирик герой өметләренең башкаларын һәм аларның тормышка ашмау сәбәпләрен үзегез табыгыз.

2. Дүртенче строфа алда әйтелгәннәрне гомумиләштерә дигән идек. Хәсрәтнең башка сәбәпләрен гомумиләштергән строфаларны табыгыз.

---

[1] *Тәбәссем* — елмаю.

[2] *Кәррә* — тапкыр.

Габдулла Тукай хәсрәтенең сәбәпләре күп һәм төрле. Сәбәп өстенә сәбәп өелеп, лирик геройның хис дәрәҗәсен күрсәтә. Ләкин шигырьдә әдип хис дәрәҗәсен турыдан-туры да яза.

3. Шигырьдә хис дәрәҗәсе күрсәтелгән урынны табыгыз.

Соңгы строфасында шагыйрь бердәнбер юану урыны булган әнисенең кабер ташы турында яза. Нибары ике генә юл белән кешенең фаҗигале язмышы турында, мөгаен, Габдулла Тукай гына яза алгандыр. Салкын кабер ташы бар күңелләрдән җылы һәм йомшак, ди, чөнки ул — лирик геройның бердәнбер сыеныр урыны. Күз яшенең иң татлысы ташка тама, чөнки шагыйрь күңелен шунда гына бушата ала, юану өчен рәхмәтен дә ул әнисенә генә әйтә ала.

4. Ташка шагыйрь күз яшенең ачысы да тама. Ни өчен?

5. Габдулла Тукайның Казанга килгәч язган шигырьләрен искә төшерегез. Өметләренең чынга ашачагына чын күңелдән ышанган Тукай белән «Өзелгән өмид» шигырен язган Тукайны чагыштырыгыз. Шагыйрьнең фаҗигале язмышы турында инша языгыз.

СӨБХАНАЛЛА, СӨБХАНАЛЛА

Сабый чакта укытканда мине хәлфә,
Рәхмәт аңар, өйрәтте бер яхшы нәрсә:
— «Сөбханалла» диеп әйтү тиеш,— диде,—
Бер мән[1] яңа гына туган айны күрсә.

Шул заманнан бирле айның туганына
Һәм дә алтын көпчәк төсле тулганына
Карап, күңлем кайчан минем хәйран кала,
Диям шунда: «Сөбханалла, сөбханалла!»

Бу әйтүем, хәер, минем гадәт кенә,
Бу бертөрле дини булган әдәп кенә;
Бер вактым бар — чын күңлемнән укыйм моны,
Хәлфәм! яусын сиңа һаман рәхмәт кенә.

Менә нәрсә: күрәм бәгъзән[2] сөйгәнемне,
Көннәр, төннәр гыйшкы берлән көйгәнемне;
Хәлфә, шунда минем телем тотлыгадыр,
Әшкә кушам тагын шул ук белгәнемне.

---

[1] *Бер мән* — бер кеше.
[2] *Бәгъзән* — кайчакта.

Тулган айга охшаш йөзе, башы аның,
Яңа туган айга охшаш кашы аның;
Күңлем аңар карап торып хэйран кала,
Укыйм чынлап: «Сөбханалла, сөбханалла!»

Әгәр күрсә шул матурны Гайнетдиннәр,
Гади генә Котбетдиннәр, Шәмсетдиннәр,
«Сөбханалла» дию кайда аларга соң!—
Укымаган алар, бернәрсә белмиләр.

Әгәр, хәлфә, мин дә шулай надан булсам,
Синнән гыйлем алалмыйча калган булсам,
Әйтер идем, шулар кеби, мин дә гыйрфансыз[1]:
«Әй-яй, бигрәк матур икән, чукынган кыз!»

1909 ел

Сорау һәм бирем

1. Шигырьдәге автор ирониясен табыгыз.
2. Габдулла Тукай бу шигырендә нәрсәне тәнкыйтьли?

ЕГЕТ ИЛӘ КЫЗ

Егет: Сөям чүмеч кеби борыныңны, җаным,
Гашыйк булдым, тәмам бетте мәҗалым[2].

Җанашым, аһ, иләк аузыңны үпсәм!
Ни кайгы, инде мин шул чакта үлсәм.

Кыз: Мәхәббәтсез! лыгырдый шунда җукны,
Үзеңдә килмәгән җир бер дә җукмы?

Егет: Ачуланмасана, Гайниҗамалым,
Сине мин кимсетеп әйтмим лә, җаным.

Синең төсле матур кызлар сирәк бит,
Хатын алсаң, иләк, чүмеч кирәк бит.

Сине алсам, чүмечле һәм иләкле
Булам ич — акча туздырмак кирәкми.

---

[1] *Гыйрфансыз* — аң-белемсез.
[2] *Мәҗалым* — тәкатем.

Сорау һәм бирем

1. Автор егет авызыннан Гайниҗамалны матур дип әйттерә. Гайниҗамал, чыннан да, матурмы?

2. Авторның каршылыклы фикерен, бәясен табыгыз.

ЙОКЫ

(Сәгыйть Рәмиевтән үзгәртелде)

Безне адәм иткән йокы,
Адәмне алга илткән йокы,
Илтеп күккә җиткән йокы,—
Йокы, йокы, йокы.

Юлымызны хак иткән йокы,
Йөземезне ак иткән йокы,
Үземезне багъ[1] иткән йокы,—
Йокы, йокы, йокы.

Раст: чын кеше эше — йокы,
Багъ вә рәхәт җимеше — йокы,
Ачкан рәхмәт ишеген йокы,—
Йокы, йокы, йокы.

Гакылга нур биргән йокы,
Мөкаддәс уй биргән йокы,
Су юкта су биргән йокы,—
Йокы, йокы, йокы.

Дәүләт, бәхет биргән йокы,
Милек, тәхет биргән йокы,
Безгә кирәк илла[2] йокы,—
Йокы, йокы, йокы.

Урысча да йокы — йокы,
Кытайча да йокы — йокы,
Кемчәгнә дә йокы — йокы,—
Йокы, йокы, йокы.

Ирләргә дә фарыз[3] йокы,
Кызларга да фарыз йокы,
Фарыз эшнең барсы йокы,—
Йокы, йокы, йокы.

Сорау һәм бирем

1. Шигырьдәге «йокы» сүзләрен «уку» сүзләренә алыштырып чыксагыз, Габдулла Тукай үзгәрткән Сәгыйть Рәмиев шигыре килеп чыгачак. Шигырьләрне чагыштырып, эчтәлекләрендәге аерма турында сөйләгез.

2. Йокы кешегә дәүләт тә, бәхет тә китерми. Ләкин Тукай бәхет тә, дәүләт тә китерә дип яза. Шулай язарга нигезе бармы?

---

[1] *Багъ* — бакча.
[2] *Илла* — фәкать, тик.
[3] *Фарыз* — тиеш.

КИТМИБЕЗ!

Кара йөзләр безне булмас эшкә тәклиф иттеләр[1]:
— Сезгә монда юк ирек, солтан җиренә кит! — диләр.

Китмибез без, безгә анда мондагыдан эш кыен:
Мондагы ун урнына ул җирдә унбиш шпион.

Мондагы төслүктер анда һәм казаклар гаскәре;
Камчылар — шул иске камчы, башкалык — тик фәсләре!

Анда бит бардыр хәзинәне талаучылар, шөкер;
Ач мужиктан соң кисәкне тарткалаучы бар, шөкер!

Без җүләрме, үзебезне утка илтеп ник терик?
Бу кызу җирдән чыгып, тагын сәкарьгә[2] ник керик?

Без күчәрбез, иң элек күчсен безем әмсарымыз[3],
Һәм дә кайтсын монда үткәргән безем әгъсарымыз[4].

Монда тудык, монда үстек, мондадыр безнең әҗәл;
Бәйләмеш бу җиргә безне Тәңребез (гыйззе вә җәл[5]).

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия!
Тиз генә кузгалмыйбыз без, и гөруһе русиһ[6]!

Ап-ачык бу бер җаваптыр, сүздә түгел, басмада:
— Если лучше вам,
Туда сами пожалте, господа!

1907 ел

Шигырьнең эчтәлеген табыйк.

Сатирик шигырьләрдә ике эчтәлек була. Сюжет эчтәлегендә автор бер нәрсә турында яза, асылда исә әсәрнең эчтәлеге шул күзгә бәрелеп торган эчтәлекнең киресе була. «Китмибез!» шигырендә Габдулла Тукай, Төркиядәге тормышны тәнкыйтьләп, Русия тормышын әйбәтрәк дип мактый. Төркиядәге

---

[1] *Тәклиф иттеләр* — көчләделәр.
[2] *Сәкарьгә* — тәмугка.
[3] *Әмсарымыз* — шәһәрләребез.
[4] *Әгъсарымыз* — гасырлар буенча үткән елларыбыз.
[5] *Гыйззе вә җәл* — кодрәтле һәм шанлы.
[6] *Русиһ* — кара йөз.

тормыш шагыйрьне бик аз кызыксындыра. Аның әйтәсе килгән сүзе ул ил турында түгел.

Бирем

Шигырьнең эчтәлеген сөйләгез.

ПЕЧӘН БАЗАРЫ, ЯХУД ЯҢА КИСЕКБАШ

I

Хак Тәгалә нәрсә кыйлса ирке бар,
Рус Микитиннең Казанда циркы бар.

Шунда бардыр бер мөселман пәһлеван —
Бик озын, бик көчле, гайрәтле җиван[1].

Шәп батыр: Зәркум кеби, Салсал кеби;
Хәйләгә оста, Сәет-Баттал кеби[2].

Бер хикәят килде телемгә арый,
Яхшылап сөйләп биреп булса ярый.

Таңга калсын тиречеләр, итчеләр,
Шәмчеләр дә, майчылар, кибетчеләр.

Берзаман бардым Печән базарына[3],—
Шунда мин таптым азык язарыма.

Иртә берлән кайнамакта бу базар,
Кайда баксаң, анда тулган сәүдәгәр.

Кайсысы сатмактадыр, кайсы ала,
Берсе алдый, шунда берсе алдана.

Һәр заманны монда хәлләр шул икән,
Һәркем үз хәле белән мәшгуль икән.

Йөгрешәләр сөртенә дә абына
Барча мөэминнәр «Көфер почмагы»на[4].

---

[1] *Җиван* — таза егет.

[2] *Зәркум кеби, Салсал кеби, Сәет-Баттал кеби* — Көнчыгыш халыкларында әкият батырлары.

[3] *Печән базары* — хәзерге Киров һәм Париж Коммунасы урамнары почмагы.

[4] *Көфер почмагы* — Казандагы Печән базарында гайбәт оясы. Монда иске фикерле сәүдәгәрләр, динчеләр җыелып, «яңалар»дан көлеп, хатын-кызларны хурлап кала торган булганнар.

Нинди эш булган соң анда, нәрсә бар?
Бер сугыш чыкканмы әллә, йә пожар?..

Мин дә чаптым шунда мөэминнәр белән.
Мәскәуски якка күз салсам күрәм:

Тәгәрәп юл уртасыннан таш килә,
Таш түгел лә — бер киселгән Баш килә.

Баш килә шундый каты, шундый кызып,
Полный ход килгән трамвайдан узып.

Һәр тараф тулган караучы — юк саны;
Баш «Көфер чаты»на җиткәч туктады.

Күрделәр бер кисек адәм башыны;
Агълаю килде дә түкте яшене.

Гәүдәсе юк бер гаҗәеп баш ирер;
Шәһит ирер[1], ике күзе яшь ирер.

Юк аягы, гәүдәсе һәм юк кулы,—
Бер кисек баштыр, һаман сөйләр теле.

Сакалы ак һәм йөзеннән нур чыкар,
Күз камашыр — һәркем йөзенә бакар.

Йөзен орды туфракка, кыйлды зари,
Зари-зари егълады шәмче Гали.

Башны күргәч, ихтыярсыз җан ачый:
Әй җаным, бу кайсы мискиннең башый?

Агълыйдыр һәркем, күзеннән яшь сыгып,
Агълый кибеттән кәләпүшләр чыгып.

Һәм аяк астында яткан тиреләр
Барча: «Ай, мискин дә, ай, мискин!» — диләр.

Шунда тау-тау торган он капчыклары,
Агълыйлар саилче[2] кыз, карчыклары.

---

[1] *Шәһит ирер* — гаепсез үтерелгән.
[2] *Саилче* — хәерче.

Агъламаска — бер мөселман башы бу,
Һәр мөселман бәндәнең җанашы бу.

Агълый Кисекбаш, моңын-зарын сөйли,
Аксакаллар: «Нәрсә булды?» — дип сорый.

Кызганычлы бер кыяфәт, яшьле күз
Берлә мискин Баш болай дип башлый сүз:

«Баштан үткәнне сөйлимен, тыңлагыз,
Мин хаҗи — бардым хаҗә туксан тугыз.

Күп тәваф иттем[1] Хиҗаз сахрасыни,
Җиддәсен һәм Мәккәсен, Сангасыни.

Мин гласныйлыкта[2] тормышдым янә
Бу шәһәрнең Думасында ун сәнә.

Һәм дә Мәскәүдән дә маллар алмышым,
Сумына туксан тиенне чәлмешем.

Итә ирдем көн дә бер Коръән хәтем[3],
Алмышым гомеремдә унбишләп хатын.

Бар иде картлыкта алган хатыным,
Бер балам — аһ, күз нурым! аһ, алтыным!

Карт көнемдә бунлар иптәшләр иде,
Яхшы юлдашлар вә сердәшләр иде.

Тартып алды бунларый миннән Дию,
Сезгә важибтыр[4] миңа ярдәм кыйлу.

Анларый алды да керде коега,
Кайгы куймый күзләремне уйкуга.

Кыйлмасаңыз сез миңа ярдәм әгәр,
Сезгә миннән яүме мәхшәр[5] дәгъва бар!»

---

[1] *Тәваф иттем* — әйләнеп йөрдем.
[2] *Гласныйлык* — шәһәр Думасы әгъзасы булу.
[3] *Коръән хәтем иту* — көн дә Коръән уку.
[4] *Важибтыр* — тиештер.
[5] *Яүме мәхшәр* — Кыямәт көнендә.

II

Шунда картлар җәмгулыб[1] киңәштеләр:
«Нишлибез соң? — Агълап эш булмас!» — диләр.

Кайсы әйтә: «Патшадан солдат сорыйк,
Ул Диюне җәдрә берлән аттырыйк».

Кайсы әйтә: «Садри Максуди[2] барыр,
Мәсьәләне, бәлки, Мәҗлескә салыр.

Без аның чөн күп тырыштык шар салып,
Ахырында Думага да сайладык».

Кайсы әйтә: «Камчылы ишан[3] барыр,
Ул Диюнең, бәлки, сихрен кайтарыр».

Уртадан бер күп белекле карт кеше
Әйтә: «Бу хакта минем фикрем шушы:

Тыңлагыз, бу — тик Карәхмәтнең эше;
Инде ул, мәгълүмеңез, көчле кеше.

Ул барып алсын Диюнең җаныны,
Кайтарыр ул бу Кисекбаш каныны».

Барча картлар: «Яхшы бу, яхшы!» — диләр.
«Вәт менә рәхмәт! Бабай тапты»,— диләр.

Бу бабай фикрен туры итсен Хода!
Итте бер мөэмин кеше шунда нида[4]:

«Миңлебай! бар, тиз Карәхмәтне чакыр!» —
Чапты китте Миңлебай чатыр-чатыр.

Үтмәгәндер күз ачып йомган заман,
Килде дә җитте Карәхмәт — каһреман.

Эстәде Башны күтәреп бакмага:
Гайрәтен вә куәтен күрсәтмәгә.

---

[1] *Җәмгулыб* (җәмгы улыб) — җыелып.

[2] *Садри Максуди* — II, III, IV Дәүләт думасында депутат. Соңрак эмигрант.

[3] *Камчылы ишан* — Казанда Яңа Бистәдә яшәгән. Ул авыруларны камчы белән сугып «дәвалый» торган булган.

[4] *Итте нида* — кычкырып җибәрде.

Ничә кем зур әйләде[1] — күтәрмәде,
Зәррә мыскал[2] җиреннән тибрәтмәде.

Һич күтәралмый аны, хәйран кала;
Көчләнә, тирли батыр, хәлдән тая.

Бу Баш әйтә: «Бу Карәхмәт шаштымы?
Ул күтәрерлек җиңел бер башмы бу?

Бер түгел, меңләп Карәхмәт килсә дә,
Хәтта Зайкин, Медведев[3] бер булса да,

Һич насыйб булмас аларга кузгату,
Файдасыздыр кузгатырга күз ату.

Чикмәсен бушка газапны — булмый да,
Чөнки бар мең пот тәгассыб[4] бу мидә.

Бу мидә йөзләп гыйнад[5] амбары бар,
Бу мидә мең пот сыраның пары бар.

Бу мидә бардыр җәһаләт[6] ун вагон,
«Мин беләмлек» дәгъвасы — бер мең вагон.

«Иске — изге» фикре бардыр ун келәт,
«Һәр җәдит — кяфер» — егерме склад...»

III

Хазирун[7]: «Аһ, нинди изге баш!» — диләр,
«Тик янә урнына ябышмас»,— диләр.

Инде мөэминнәр каты кызгандылар,
Чын күңелдән Баш өчен сызландылар.

Һәм үрә торды батырның чәчләре,
Газбилә[8] аузыннан утлар чәчрәде:

---

[1] *Зур әйләде* — көч куеп карады.
[2] *Зәррә мыскал* — әз генә дә.
[3] *Зайкин, Медведев* — циркта рус көрәшчеләре.
[4] *Тәгассыб* — фанатизм, искелекне яклау.
[5] *Гыйнад* — тискәрелек.
[6] *Җәһаләт* — наданлык.
[7] *Хазирун* — шунда булучылар.
[8] *Газбилә* — ачу белән.



«Мин,— диде,— дөньяда тормыйм, ичмасам,
Шул Дию-залим башыны кисмәсәм.

Бармыймын хәтта Микитин циркына,
Шул Дию башына күңлем җилкенә.

Шунсыз инде бер дә рәхәт күрмәмен,
Һәм Пугач[1], Зайкин рәтенә кермәмен.

Йә үләм мин, йә шуның муйнын кисәм,
Хак гыйнаять әйләр ирсә[2], мин басам».

Бар халык та: «Бар, Карәхмәт, бар»,— диләр,
«Бу Кисекбаш хатынын коткар»,— диләр.

«Бармыйлармы? Мин барам, әлбәт, барам,
Бармасам, дөнья йөзе булсын хәрам!..»

Бу гаһедтән[3] соңра Башның күзләре
Яктырып китте — ачылды йөзләре.

---

[1] *Пугач* — цирк батыры.
[2] *Хак гыйнаять әйләр ирсә* — Алла ярдәм итсә.
[3] *Гаһед* — сүз бирү, ант итү.

Ул Баш әйтә: «Әй батыр, рәхмәт сиңа,
Йөкләдем мин бик авыр зәхмәт сиңа.

Барча иркеңнән вә циркыңнан җөда[1]
Булдың инде, бәс, сиңа миннән дога.

Әйдәгез, әй әһле базар, берьюлы
Фатиха: уңсын Карәхмәтнең юлы!»

Шулвакыт куллар белән тулды сәма[2],
Чын күңел берлән кыйла һәркем дога:

«И Ходаем, бир Карәхмәткә мәдәт[3],
Ушбу юлда бир аңар көч һәм сәләт!»

Берзаман куллар салындылар төшеп,—
Күрделәр: килде трамвай җитешеп.

Пәһлеван вагонга җирләшге кереп,
Алды «пересадка» берлән бер билет.

Барча мөэминнәр озатып калдылар:
«И Ходаем, рәхмәтеңне сал!» — диләр.

Кузгалып китте вагон, җилдәй бара,
Баш йомарланып китә, җирдән бара.

Башны күргәч, кузгалып гайрәтләре,
Өрде барча итчеләрнең этләре.

Йөгерәләр аллы-артлы бер кәтү
Кәкре койрыклар! — Кая Башны җитү!

Ул барадыр йөгрек аттан да каты
Һәм җәядән аткан уктан да каты.

Үз хәленчә китмәдә тыр-тыр вагон,
Таш ата башка малайлар яльгабун[4].

Бер сәгать, бер көн вә өч көн киттеләр,—
Зур завод Крестовниковны үттеләр[5].

---

[1] *Җөда булу* — аерылу.
[2] *Сәма* — күк.
[3] *Мәдәт* — ярдәм.
[4] *Яльгабун* —уйнап.
[5] *Крестовниковны үттеләр* — Казандагы сабын заводын үттеләр.

Җиде көне, төне чөнки киттеләр,
Нагяһан[1] бер сахрая ирештеләр.

Шунда җиткәчтен трамвай туктады,
Баш йомарланып барадыр туктамый.

Туктагач шунда сихерле машина:
«Нишлибез?» — диде Карәхмәт Башына.

Ул Баш әйтә: «Син вагоннан төш хәзер,
Бик якынлашты кирәкле төш хәзер.

Без барыйк азрак җәяү алга табан;
Иштә[2] бу алдыңдагы күлдер — Кабан.

Бар дорыр күлнең төбендә бер кое,
Шунда керде ул теге залим Дию!»

IV

Сүз рәте килгәч, итәм әзрәк бәян[3],
Таки яшьләр күл төбе булсын гаян[4].

Анда һәртөрле гаҗәпләр бар да бар:
Кып-кызыл алтын шәһәр, җиз карьяләр[5];

Мөгезе мәрмәр боланнармы кирәк,
Алты йөз башлы еланнармы кирәк.

Су анасы,— бик явыз, йөзе кара,—
Ел да бер угъланны йә кызны ала.

Шул заман, кем, килде Мәскәү гаскәре,
Бу Казанга туп атарга башлады.

Шулвакыт ханнар, вәзирләр качтылар,
Барча малны ушбу күлгә сачтылар.

Сачтылар алтын-көмешнең һәммәсен,
Ягъни «безнең мал кешегә калмасын».

Шул заманнан бирле, кем, алтын-көмеш
Күл төбендә һич хисапсыз күп, имеш.

---

[1] *Нагяһан* — кинәттән.
[2] *Иштә* — менә.
[3] *Итәм бәян* — аңлатам, сөйлим.
[4] *Гаян* — ачык.
[5] *Карьяләр* — авыллар.

«Бер заманда, шөбһәсез, бу күл кибәр»,—
Дип гакыллы зур хәкимнәр[1] сөйлиләр.

Киптисә, бер дәфга[2] кузгалып бары —
Күл буеның мәдрәсә талибләре[3] —

Барча байлыкны җыячаклар, имеш,
Һич һөнәрсез бай булачаклар, имеш.

Ел ел артыннан һаман үтмәктәдер,
Күл буе талибләре көтмәктәдер...

V

Әйдә максудка! Алар көтсен әле,
Сүз Кисекбашка килеп җитсен әле.

Ул Карәхмәтнең билендә бавы бар;
Бауның алты мең колачлы буе бар.

Бау белән ул эшне яхшы җайлады:
Бер очын Башның теленә бәйләде.

Бер очын учлап, Кабанга чумды ул,
Туп-туры шуннан коега тотты юл.

Ул төшә, бер көн төшә, өч көн төшә;
Туктамый инмәктәдер көндез-кичә.

Бер — аягы әйләнәдер, бер — башы,
Һәр минут — һәрдәм Хозырдыр юлдашы.

Ул инә, Алла сүзен тәкрар кыйла,
Тышта агълыйдыр Кисекбаш, кайгыра.

Нәкъ төшеп киткәнгә ун тәүлек тула,—
Ахры, җиргә аяклары тәртелә.

Пәһлеван, гаять арып, эштән чыгып,
Ун минут торды катып, гакълын җыеп.

Бервакыт безнең батыр ачты күзен:
Бер сарай алдындадыр күрде үзен.

---

[1] *Хәкимнәр* — галимнәр.
[2] *Бер дәфга* — берьюлы.
[3] *Талибләре* — шәкертләре.

Шундый яхшыдыр ки, һич мондый сарай
Салмагандыр Кәчимеский Ибырай[1].

Капка башында яшел ләүхә[2] тора;
Анда иштә ушбу сүзләр укыла:

«Монда сакин бужи фирка җания,
Табигыйннәр мәзһәбе Гайнания[3]».

Тартты куптарды Карәхмәт капканы,
Соңра тиз-тиз элгәрегә атлады.

Керде дә күрде: сарайда бер хатын
Җәлеп итәрлек һәр кешенең дикъкатен:

Йөз нуры дүрт якны әнвәр әйләгән[4],
Тәңренең гыйшкы аңар кяр әйләгән[5].

Намаз укыр ул ахирәт хатыны,
Аһ итәр — күккә чыгадыр төтене.

Күз яше сәҗдә җирене болгамыш;
Ул Кисекбашның хәлале[6] бу, имеш.

Үтте аннан, китте башка бүлмәгә,
Шундый күрнеш — кызганычтыр күрмәгә:

Анда биш йөзләп мөселманнар тулы,
Багълыдыр һәрберсенең аяк-кулы.

«Алла, Алла! Саклый күр үтдин! — диләр,
Кыйл шәфәгать, йа Баһаветдин[7]!» — диләр.

Сикерәләр, җенләнәләр үзләре,
Һәм акайган, кот очарлык күзләре.

---

[1] *Кәчимеский Ибырай* — бөтен малын эчеп, туздырып бетергән Ибраһим исемле сәүдәгәр.

[2] *Ләүхә* — язулы такта.

[3] *Сакин бужи фирка җания, табигыйннәр мәзһәбе Гайнания* — үзләрен «божий фирка» дип атап йөрткән сектантлар төркеме вәкиле Гайнан Вәисев күздә тотыла. Ул Самарадан килгән бер сәүдәгәр хатынын алып кала.

[4] *Әнвәр әйләгән* — нурландырган.

[5] *Кяр әйләгән* — йоккан.

[6] *Хәлале* — хатыны.

[7] *Баһаветдин* — дини сектаны оештыручы. Гайнан Вәисевнең атасы.

Чөн болар һәп[1] пәһлеванны күрделәр;
Бер авыздан бөйлә фөрьяд кыйлдылар[2]:

«Мәрхәмәт ит, и Карәхмәт, безгә син;
Безне коткар, из Диюнең измәсен.

Һәр минут үткән саен без куркуда:
Бу Дию һәр көн бишәр адәм суя.

Күп идек без былтыр, үткән көз генә,
Инде калды барчабыз биш йөз генә».

Шунда бер бүлмә күренде — шактый киң;
Күрде батыр: шунда яткан ул ләгыйнь[3].

Бинибая[4] зур башы — гөмбәз кадәр;
Ни сәбәптәндер башында фәс тә бар.

Салынып төшкән килешсез мыегы —
Бик озындыр, мисле[5] күсе койрыгы.

Бармаклары охшар адәм гәүдәсе,—
Күп татарны имгән ирде ул гасый[6].

Билгеле инде, Карәхмәт курыкмады;
Ул аны «тор! тор!» диюбән төрткәли.

Нәгърәләр[7] берлән Диюне уйгата;
Һич уянмый уйкусыннан, ул ята.

Төрткәли торгач, ниһаять, уйгана,
Куркынычлы күзләре уттай яна.

Ул Дию уйганды: дүрт якка бакар,
Көфер сүзләр, агъзыйдин утлар сачар:

«Ник йөрисең монда рөхсәтсез кереп,
Һич оялмый тәмле уйкум боздырып?

---

[1] *Болар һәп* — болар барысы да.
[2] *Фөрьяд кыйлдылар* — ачынып еладылар.
[3] *Ләгыйнь* — ләгънәт суккан.
[4] *Бинибая* — чиксез.
[5] *Мисле* — нәкъ.
[6] *Гасый* — гөнаһлы, җинаятьче.
[7] *Нәгъръләр* — каты кычкырулар.

Белмисең, махсус колониям бар минем,
Мәхкәмәм бар, автономьям бар минем.

Куркъмадың, монда ничек кердең кыеп?
Бар икән йөргән кеше җаннан туеп!»

Язмыймын сугыш нә рәсмә[1] булганын,
Кайсысы җиңгәнен йә җиңелгәнен.

Гөрзи төшкәч, кайсы билдән батканын,
Кайсысының маңгаеннан батканын.

Кариэм[2] иткел канәгать барына,
Итмәсәң — әйдә Печән базарына.

VI

Иртә берлән кайнамакта ул базар,
Анда да монда кызадыр сәүдәләр.

Кызса да гадәттәгечә сәүдәләр,
Әллә ник бүген күңелсездер базар.

Һәр мөселман әллә нигә кайгылы,
Нәрсәгә хәмлитмәгә[3] бу кайгыны?

Юк, аларга кайгырырга юл да бар:
Нәкъ бер айдыр — юк Кисекбаштан хәбәр.

Җәмгулыб өч-дүрт кеше һәр чат саен
Гәпләшеп кайгырталар Башның хәлен:

«Ягъни ул мискингә ни булган икән?»
«Ике якның кайсысы җиңгән икән?»

Әһле ислам[4] шул рәвешчә яхзәнүн[5]...
Күренә шул хәл ерактан, ах, вагон!

Нәрсә булган? Нинди хикмәт, кем белә?—
Ташбака төсле, вагон әкрен килә.

---

[1] *Нә рәсмә* — ни рәвешле.
[2] *Кариэм* — укучым.
[3] *Хәмлитмәгә* — сылтарга.
[4] *Әһле ислам* — ислам халкы.
[5] *Яхзәнүн* — кайгыда.

Өч сәгать үтте күренгәндин бире,
Юк әле асла якынлашкан җире.

«Ник болай бу?» — дип гаҗәпләнгән базар,
Әйләмәктә пассажирлар интизар[1].

VII

Тын гына торган вакытта шул рәвеш,
Килде ямьсез, куркыныч ы бер тавыш.

Бик каты күк күкрәгән төсле була,
Җир ярылган, тетрәгән төсле була;

Бер — арысланнар акыргандай була,
Бер — көтү ишәк бакыргандай була.

Күз ачылмаслык чыгып комлы буран,
Басты золмәт[2] җир йөзене шул заман.

Һәр тараф золмәт, күренмидер кояш,
Куркуга төште кешеләр — карт вә яшь.

Һич кеше белми: ни хикмәт бу, ни бу?
Әллә чынлап та Кыямәт көнме бу?

Әллә бер «койрыклы йолдыз» төштеме?
Әллә тәңре сур өрергә[3] куштымы?

Дөньяга соңгы минутлар килдеме?
Әллә ханның мәсҗеде җимрелдеме?

Әллә тәүбә капкасы ябылдымы?
Әллә бер бай корсагы ярылдымы?

Таш пулатлар җөмлә[4] дер-дер селкенә...
Каршылык юктыр Ходайның иркенә.

Әрҗәдә читек-кәвешләр кузгала,
Һәм өеп куйган кәләпүшләр ава.

---

[1] *Интизар* — зарыгып көтү.
[2] *Золмәт* — караңгылык.
[3] *Сур өрү* — Кыямәт көнендә, үлекләрне тергезү өчен, фәрештәнең быргы кычкыртуы.
[4] *Җөмлә* — барысы.

Танымый дуст дустны, кардәш кардәшен,
Һәр кеше куркып укый «ләхәүлә»сен.

Ни бәла килде Казанның халкына?
Очрадылармы Ходайның каһренә?

VIII

Бәс, шу рәсмә куркышып торган заман
Чыкты аңсыздан[1] кояш, китте тузан.

Күрделәр: җитте килеп мәгълүм вагон,
Тагылып артында бернәрсә тагын.

Ни күрәләр: өнме, ялган төшме бу? —
Тагылып килгән теге фәсле Дию.

И дулый! мәлгунь Дию, и тартыла!
Акыра ямьсез каты — җир селкенә.

Бите-башы канланып беткән янә;
Әйләнәсендә Кисекбаш әйләнә...

Сөйрәлеп җирдән Дию килгән икән,
Һәм вагон шуннан озак торган икән.

Бу Диюдән ул буран купкан икән,
Куркытучы шул Ходай суккан икән.

Инде һәркем күңеленә шатлык тула,
Ул Кисекбаш елмаеп көлгән була.

Шул минут чыкты вагоннан пәһлеван,
Күтәреп башыны арыслан сыман.

Чөн[2] Печән базары халкы күрделәр,
Барча күрешмәк өчен йөгерделәр.

Җөмлә бердән: «Әссәлам! дә әссәлам!»
Һәм Карәхмәт: «Вәгаләйкем әссәлам!»

Һәр мөселман дәрт белән күккә оча:
Бер Кисекбаш, бер Карәхмәтне коча.

---

[1] *Аңсыздан* — кинәттән.
[2] *Чөн* — кайчан.

Чыкты вагоннан тагын бер ир бала,
Бик чибәр — күргән кеше хәйран кала.

Чыкты тагын да чапанлы бер хатын,
Җәлеп итәрлек тиречеләр дикъкатен.

Бер хаҗи шул хәл хатынга күз кыса
Һәм дә яп-яхшук оятсыз сүз куша.

Ул Кисекбаш күрде дә бу тәкъваны[1]:
«Тимә хатынга!» — диеп, бармак яный.

«Белмәдем мин!» — дип, хаҗи зари кыйла,
Күзләреннән яшьләрен җари кыйла[2].

Шул вакытта Камчылы ишан килә;
Ул Кисекбашны тотубән өшкерә.

Күрделәр: Баш яшь егет булды янә,
Кул-аягы, гәүдәсе килде янә.

Бу кәрамәтне[3] күзилә[4] күрделәр,
Тәңрегә мең-мең шөкерләр кыйлдылар.

Ул Дию күздән югалды, юк булып,
Очты Яңа Бистә якка, ут булып.

Сез беләмсез: ул Кисекбаш әл дә бар;
Көн күрә яхшы гына, ул — сәүдәгәр.

Дин юлында күп газап күргән өчен,
Армый-талмый дин өчен йөргән өчен,

Пәһлеванга бирделәр алтын сәгать,
Чылбыры юк, белмимен, нидер сәбәп...

Фагыйләтен, фагыйләтен, фагыйләт,
Ну, Печән базары халкы күңле шат!

1908 ел

---

[1] *Тәкъва* — изге кеше.
[2] *Җари кыйла* — агыза.
[3] *Кәрамәтне* — могҗизаны.
[4] *Күзилә* — күз белән.

Әсәргә анализ ясарга керешкәнче, поэманың үзенчәлеге белән танышыйк.

Исеменнән үк күренгәнчә, әсәр Габдулла Тукай яшәгән заманда һәркемгә мәгълүм булган Печән базарына багышланган. Казандагы Печән базары, Нижгород ярминкәсе кебек, товарларының күплеге һәм төрлелеге белән Россиянең бик күп төбәкләрендә дан тоткан. Монда чит илләрдән килеп тә сәүдә итә торган булганнар. Базар байлыгы — ил байлыгы. Димәк, Тукай яшәгән заманда милләт, артталыгы өчен күпме генә тәнкыйтьләнсә дә, оста һөнәрчеләре, игенчеләре белән мәшһүр булган. Печән базарына татарлар дөнья хәбәрләрен ишетү һәм үзара аралашу өчен дә килгәннәр. Монда алар, уртак фикерле ишләрен җыеп, төркемнәр, партияләр оештырганнар. Бу кешеләр арасында яңалыкка каршы торучылар, дини фанатиклар күп булган. Габдулла Тукай поэмасында Печән базарының әнә шул ямьсез почмагыннан көлгән. Дини фанатиклар партиясенең исемен «Божий фирка» дип, аз гына үзгәртеп, мөселманнар партиясен руслаштырган. Никитин циркында көн дә көрәшчеләр ярышы уздырганнар. Никитин, башка көрәшчеләр белән сөйләшеп, Карәхмәт исемле татарны һәрвакыт өстен чыгара торган булган. Татар пәһлеванының җиңүен күрү өчен, циркка бик күп халык йөргән. Поэмасында Тукай, Карәхмәтнең көчсезлеген күрсәтеп, бу ялганны да фаш иткән.

Димәк, Габдулла Тукай үзенең поэмасында конкрет урын, вакыт, билгеле төркемнәр һәм кешеләр турында язган. Шуңа күрә бу әсәрне фельетон дияргә дә мөмкин.

> Конкрет кешеләрне, ямьсез күренешләрне сатира алымнары белән фаш иткән газета-журнал мәкаләләренә **ф е л ь е т о н** диләр.

«Кисекбаш» поэмасын укып чыккач, без хәзер рәхәтләнеп көлмибез. Әсәр язылган вакытта эш башка булган. Габдулла Тукай поэмасын беренче мәртәбә хәзерге Яшь тамашачылар театры (ТЮЗ) бинасында укый. Кичәдә катнашкан Фатих Әмирхан болай яза: «...Укыганда халык, җөмлә тәмам булганын да көтә алмыйчан, самими бер көлкегә тотылып, бөтен залны тутырып кул чабалар һәм, укучыны бүлеп, әллә никадәр вакытлар туктап торырга мәҗбүр итәләр иде».

Ул заман кешеләренә поэма аеруча кызык булган, чөнки алар поэманың һәр җөмләсендә диярлек үзләре өчен билгеле күренешләрне таныганнар.

Поэмасының исемен Габдулла Тукай «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» дип куйган. «Кисекбаш» исемле әсәр XV гасырда ук иҗат ителә. Бу дастан хәтта Тукай яшәгән чорда да мәктәп дәреслекләренә кергән була. Дастанда сүз Галинең изге мөселманны рәнҗеткән Диюне җиңүе һәм изге Башның хатынын, баласын коткаруы турында бара. Габдулла Тукай бу сюжеттан аз гына да тайпылмый. Ләкин персонажларын үзгәртә, вакыйгаларны яңа шартларга күчерә. Мәсәлән, дастанда Кисекбаш — изге, диндар кеше. Тукай поэмасында ул — әхлаксыз, мактанчык бай сәүдәгәр. Дастанда Гали Башны изге булганга күтәрә алмый, ә поэмада Габдулла Тукай Башны эче тулы бозыклык булганга авыр итеп сурәтли.

Нәтиҗәдә Габдулла Тукай поэмасының эчтәлеге дастан эчтәлегенең киресе булып чыга. Искә төшерик: бер әсәргә ияреп, аның эчтәлеген киресенә әйләндерүгә пародия диләр. «Кисекбаш» дастанын бик яхшы белгән шул заман укучыларына поэма-пародия кызык булган. Алар, поэманы укыганда, ике әсәрне чагыштырып бара алганнар. Бер әсәрдәге изгелекнең икенчесендә бозыклыкка әйләнүен күреп, Тукайның мещаннарга биргән бәясен күргәннәр.

Поэмага анализ

Сатирик әсәрләрдә буш, булдыксыз кешеләрнең җитдилеккә дәгъва кылуы турында языла. Поэмадан шул каршы якларны эзлик. Буш, ягъни надан, бозык кешеләр — Печән базарындагы итчеләр, тиречеләр, кибетчеләр һәм Кисекбаш. Габдулла Тукай Кисекбашны әсәренең исемендә үк Печән базары белән тиңләштерә. Кисекбаш үзен хөрмәтле, изге кешеләрнең берсе итеп исәпли. Хаҗга туксан тугыз мәртәбә бардым, көн дә Коръәнне укып чыгам, депутат булып торам дип мактана. Шул ук вакытта унбиш хатын аеруы, ялганчы, эчкече, мактанчык, тәкәббер («Мин беләмлек» дәгъвасы — бер мең вагон») булуы, һәр яңалыкка каршы чыгуы («Һәр җәдит — кяфер» — егерме склад») турында да горурланып сөйли.

Мөселман пәрдәсе артына качып, юньсезлек эшләп йөрүчеләр әсәрдә тагын бар. Кисекбашның мактануын тыңлаган

халык авызыннан Тукай: «Аh, нинди изге Баш!» — дип әйттерә. Шулай итеп, базар әһелләре белән Кисекбашның бер чыбыктан сөрелгән кешеләр булуын белдерә.

Кисекбашның базардагы башка сәүдәгәрләрдән җитди аермасы да бар. Ул алардан баерак та, дәрәҗәлерәк тә. Ун ел буена шәһәр Думасында депутат булып торган кеше. Шуңа күрә Кисекбашка базар халкы «Помада мәсьәләсе»ндәге Сәлим байга башкалар караган кебек олылап карыйлар.

Шагыйрь базар кешеләрен кәләпүшләр, тиреләр, он капчыклары белән янәшә куя. Автор аларның барысын да Кисекбашны кызгандырып елаттыра. Шул рәвешле, базардагы мещаннар да, кәләпүшләр, он капчыклары, тиреләр кебек, җансыз, сатыла торган әйбергә әйләнәләр.

Эчтән буш булсалар да, Тукай персонажлары үзләрен Кисекбаш кебек дингә кирәкле, җәмгыятькә файдалы кешеләр дип исәплиләр. Җыйнаулашып, Баш язмышын хәл итәргә керешәләр. Хәтта, туп аттыруны сорап, патшаның үзенә мөрәҗәгать итмәкче булалар. Персонажларның үз бәяләрен арттырырга тырышулары — әсәрнең икенче өлеше.

Габдулла Тукай поэмасын язганда сатирага, юморга хас стиль сайлаган. Бер яктан, автор базар кешеләре карашында тора кебек, аларның бар эшен хуплый, куәтли. Мәсәлән, бер урында: «Башны күргәч, ихтыярсыз җан ачый»,— ди. Кайгыручылар рәтенә үзен дә кертә. Икенче яктан, гипербола алымы кулланып, персонажларының һәм вакыйгалардагы сыйфатларны чиктән тыш арттырып, аларга үзенең кире бәясен күрсәтеп бара.

Шагыйрь татар милләтенең, алга киткән милләт халыклары кебек, үз язмышын үзе хәл итәрлек, дәртле, белемле булуын тели. Күпләрнең битарафлыгына, горурлыкларын югалтуларына, юк эшне бар итеп йөрүләренә борчыла. Шуңа күрә бу поэмада авторның көлкесе аның борчылуына, хәсрәтенә төренгән, дибез.

Йомгак

Безнең максат — әдип әсәрләре арасындагы бәйләнешләрне табу һәм күп төрле эчтәлекле шигырьләрне бербөтен иҗат итеп күз алдына китерү. Моның өчен Габдулла Тукай әсәрләрен аның иҗатының өлешләре итеп карыйбыз. Гадәттәгечә, шигырьләрнең охшаш якларын эзлик һәм охшаш дип тапканнарын аерым төркемгә җыйыйк.

«Дустларга бер сүз» шигырендә әдип, татарларның таркаулыгын «милләт ертыгы», ди. Ертыкның «җөен җөйләү»не бердәмлектә, белем алуда күрә. Муллаларга, хөкем итү эшен белемле яшьләргә тапшырып, үз эшләре белән шөгыльләнергә киңәш итә. Шул юл белән барганда, милләтнең алга китүенә унтугыз яшьлек Тукай чын күңеленнән ышана.

«Иттифакъ хакында» шигырендә Тукай милләтне минминлектән котылырга, берләшергә чакыра, ягъни «Дустларга бер сүз» шигыренең эчтәлеген ачыклый. Таркаулык хәзер «мин-минлек» булып ачыклана. Әдип «берләшү» сүзен хәтта әсәренең исеменә үк чыгара. «Пар ат» шигырендә дә әдип өметләр турында яза. Казанны, өметләре тормышка ашар өчен, бөтен шарты да килгән шәһәр дип исәпли. Бу әсәрендә яшь әдип өметенә мәхәббәтен табу хыялы да өстәлә.

«Сөткә төшкән тычкан» шигырендә дә Габдулла Тукай өмете турында яза: «Әйдәгез, әлеге тычкан кебек зур сабырлык белән тырышыйк, безне берәү дә коткармаячак, без үзебезне үзебез генә коткара алабыз»,— ди.

Бу шигырьләр, бер үк әсәрнең төрле өлешләре кебек, берберсен ачыклап, дәвам итеп киләләр. Шуңа күрә аларны бер төркемгә җыеп, «өмет» дип исем бирә алабыз.

Ә менә «Көз» шигырендә әдип милләтнең тиз генә уянуына ышанмый. Элеккеге шатлыклы өметләр борчылу хисенә алышыналар. Милләт язын күрә алуына ул бик зур шик белән карый:

Килер мәллә кабергә мин сөрелгәч,
Кыямәт көндә мин үлеп терелгәч? —

ди.

«Дустларга бер сүз» шигырендә Тукай:

Инде нәүбәт без бичараларга җитә,—
Җыелып-җыелып, депутатлар сайлыйк имди,—

дип өметләнсә, «Государственная Думага» шигырендә, Дума куылгач, бу өметенең дә юкка чыгуына хәсрәтләнә. «Пар ат»та шагыйрь Казанны нурлы, дәртле, мәгърифәтле итеп күрергә өметләнсә, шәһәрдә үзе яши башлагач, бу өмете дә җимерелә. «Казан вә Казан арты» әсәрендә, бик ачынып, «үз өязең каккара» дип яза. «Өзелгән өмид»тә яшьлек өметләренең барысы да юкка чыгуы турында әйтә.

Яшьлек өметләренең җимерелүе турындагы шигырьләрне, эчтәлекләренең уртаклыгыннан чыгып, икенче төркемгә

җыябыз. Аларга, Тукайның үз сүзләрен файдаланып, «өзелгән өмет» дип исем бирә алабыз.

Ике төркемнең уртак яклары да, аермасы да бар. Аларның икесендә дә сүз шагыйрьнең милләт арталыгына борчылуы турында бара. Ләкин беренче төркемдәгеләрендә шагыйрьнең өмете-шатлыгы чагылса, икенчеләрендә, киресенчә, өметләрнең өзелүе, хәсрәте күзгә ташлана. Гомеренең соңгы елларында шагыйрь хис, хыял дөньясыннан чынбарлыкка аяк атлый. Икенче төрле әйткәндә, романтик шагыйрь реалистка әйләнә.

Ни өчен шагыйрь башта өметләренә бик нык ышана да, ике-өч ел үтүгә, дөньяга карашын шулай кискен рәвештә үзгәртә соң?

Мондый кискен үзгәреш сәбәбенең берсе — тарихи шартлар үзгәрү. 1905 елгы революция халыкка шактый зур ирек бирү белән тәмамлана. Моңа кадәр тыелган татарча газета-журналлар күпләп чыга башлый, аларга цензура бетә. Татарча китаплар басыла башлый. Халык сайлаган депутатлардан җыелган Дума эшкә керешә. Бу вакыйгалар Тукайны канатландыралар. Аңа ил, шул рәвешле, демократик юлдан китәр кебек тоела. Әмма халыкка бирелгән ирек озакка бармый. Патша хөкүмәте биргән вәгъдәләреннән баш тарта. Газета-журналлар элеккечә эзәрлекләнәләр, Дума куыла, кыю фикерле кешеләр күзәтү астына алына. Дөньяның мондыйга әйләнүе Тукайны тәмам хәсрәткә сала. Аның дөньяга карашы бик тиз үзгәрә. Казанга кайтканнан соң, милләт тормышын якыннан торып өйрәнү дә зирәк фикерле, үткен күзле Тукайны романтик хыялларыннан бик тиз арындыра.

Әсәрләрендә дөньяга караш, стиль үзгәрүе кебек җитди һәм кискен үзгәрешләр күзәтелсә һәм бу үзгәрешләр язучы иҗатын вакыт ягыннан да икегә бүлә торган булса, әдип иҗаты ике чорга бүленә, диләр. Без дә шулай итик: Габдулла Тукай иҗатын өметкә ышанган һәм өметләренә ышанычы беткән чорларга бүлик. Ә икенче төрле: романтик һәм реалистик метод белән иҗат иткән чорга бүленә, диик.

Төркемнәргә без өйрәнгән шигырьләрнең берничәсе генә керде. Башкаларын ничек гомумиләштерергә соң?

Исегезгә төшерегез: «Мулланың зары», «Сөбханалла, сөбханалла», «Йокы», «Китмибез!», «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» әсәрләрендә дә милләтнең кимчелекле яклары, ягъни, Тукай үзе язганча, «ертыгы» тәнкыйтьләнә. «Сөбханалла» дип әйтүдән артык белем бирми торган иске мәдрәсәләр

(«Сөбханалла, сөбханалла»), йокысыннан уянырга теләмәгән халык («Йокы»), «һәркемнең үзе белән мәшгуль»леген сагынучы иске карашлы мулла («Мулланың зары»), дәрәҗәле кешеләр алдында тәлинкә тотучы надан кешеләр («Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш») һәм шул замандагы законсызлык («Китмибез!») милләт ертыгының әле бер ягын, әле икенче ягын ачалар. Тик бу шигырьләрендә әдип милләтнең ертыгын беренче төркемдәге әсәрләрендәге кебек җөпләми, ертыкларга бармагы белән төртеп күрсәтә, көлә, башкаларны да көләргә мәҗбүр итә. Шуңа күрә югарыда телгә алынган шигырьләр дә — Габдулла Тукайның рухи халәтен бүтән яктан гына күрсәтүче, ләкин эчтәлекләре белән башка әсәрләренә бик тыгыз бәйләнгән шигырьләр.

Сатирик әсәрләре әдипнең рухи халәтенә һәм дөньяга карашына дөрес бәя бирергә ярдәм итәләр. Бу әсәрләр белән танышканнан соң, Габдулла Тукай, дөньядан өметен өзеп, төшенкелеккә бирелгән дия алмыйбыз. Чөнки сатирик әсәрләре шагыйрьнең җиң сызганып гаделлек, хаклык өчен көрәшүе турында сөйлиләр.

Габдулла Тукайның үткен каләменә эләккән ямьсез күренешләрне җыеп, ул ямьсезлек турында язган дия алабыз. Ямьсезлек — матурлыкның киресе. Ямьсезлеккә каршы көрәшү — матурлыкка омтылу ул. Шуңа күрә шагыйрьнең сатирик әсәрләрен дә, «Туган җиремә», «Туган авыл» әсәрләре кебек, матурлык — ямьсезлек төркеменә кертергә мөмкин. Габдулла Тукай — үткен фикерле юморист шагыйрь дә. Аның юмористик шигырьләре, үткен фикер матурлыгы буларак, шул ук төркемгә керә.

Гаяз Исхакый
(1878—1954)

Гаяз Исхакый Казан губернасы Чистай өязе Яуширмә авылында 22 февральдә туа. Аның әтисе Гыйлаҗетдин шул авылның мулласы була. Гаяз башта әтисе мәдрәсәсендә белем ала, аннары Чистай мәдрәсәсендә укый. Шуннан соң Казанга килә һәм Күл буе мәдрәсәсенә керә. Аны тәмамлагач, Казандагы Татар укытучылар мәктәбендә белем ала. Бу елларда ул, бик тырышып, чит телләрне һәм рус телен өйрәнә.

1905 елгы революциядә Гаяз Исхакый ул вакытта татарлар арасында иң куәтле партия булган социаль-революционерлар (эсерлар) партиясенең җитәкчесе буларак катнаша. Революциянең төп көче крестьяннар булырга тиеш дип уйлый һәм аларны патша хөкүмәтенә каршы көрәшкә чакыра.

Революцион эшчәнлеге өчен әдипне берничә мәртәбә кулга алалар. Тынгы белмәс әдип төрмәдә дә эшли. Төрле төрмә камераларында ул үзенең мәшһүр повестьларын, пьесаларын иҗат итә.

1908 елда Гаяз Исхакый Төркиягә качып китә. Монда ул дүрт ел буена үзенең иҗат эшен дәвам итә. Ләкин аннан кайту белән кабат төрмәгә ябыла.

1917 елны Февраль революциясен әдип шатланып каршы ала. Ниһаять, татарларга ирек алу өчен, бөтен шартлар туды дип исәпли. Хәзер аның эшчәнлеге бермә-бер арта. Ул, татарларның мөстәкыйльлеген даулап, бер-бер артлы мәкаләләр яза, мөселман съездлары оештыруда катнаша, анда докладлар белән чыгыш ясый. Ә менә Октябрь революциясен Гаяз Исхакый кабул итми. Властька большевиклар килгәч, шартлар кискен

үзгәрүен күрә һәм бу шартларда милли азатлыкка ирешү хыялыннан өметен өзә.

1919 елда әдип Россия вәкиле сыйфатында Версаль шәһәрендә үткәрелгән солых конференциясенә китә һәм шул китүдән туган иленә әйләнеп кайтмый. Гаяз Исхакый чит илдә дә иҗат эшен дәвам итә. Берсе артыннан берсе романнар, повестьлар, пьесалар, хикәяләр яза. Илдән илгә йөреп, анда яшәүче татарларны туплый. Татар телендә газеталар чыгара.

Гаяз Исхакый туктаусыз эшли. Революциягә кадәр үк аның сигез томлык әсәрләр җыентыгы басылып чыга. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов кебек күренекле татар язучылары Гаяз Исхакыйны үзләренең беренче укытучылары итеп таныйлар. Аңа татар әдәбиятына нигез салучы әдип дип бәя бирәләр.

Язучы 1954 елда Төркиядә үлә.

КӘҖҮЛ ЧИТЕК

Минем әти бүген Казаннан кайта. Улмы? Ул миңа саплы калач китерә. Аннары миңа читек китерә. Өр-яңа читек.

Аның балтыры шадраланып тора, чем-кара.

Миңа әти кәҗүл читек китерә...

Иртәгә гаеткә мин кәҗүл читек киеп барам.

Беләмсең, Миңлегали?

Минем читек балтырының очы кып-кызыл иттереп тар сахтиян[1] тоткан була, ул әнинеке кебек түгәрәкләнеп беткән булмый... тип-тигез киселгән була.

Ул әкертен генә шыгырдый. Солдаттан кайткан Фәхри малаеның итеге шыгырдаган кебек түгел, шыгыр-шыгыр шыгырдый...

Безнең әни иртәгә бәйрәм ашы пешерә. Әйдә, тизрәк чабыйк. Көтү тиз керсен иде дә, сыерларны тиз табып кайтсак иде.

Әйеме, Миңлегали?

Миңа иртәгә гаеткә киеп барырга әби чапан тегә, минем чапан җем-җем итеп тора. Әби әйтә: «Мондый чапанны бохар патшасының угылы гына киядер,— ди.— Ул саранҗы[2]»,— ди... Ул әле өр-яңа! Әби әйтә, саранҗы искерми, ди.

---

[1] *Сахтиян* — сарык һәм кәҗә тиресеннән эшләнгән күн.

[2] *Саранҗы* — саржа. Арка-буй җепләре кыйгач итеп, үрелеп тукылган тукыма.

Ул этинең ашка йөри торган чапаны иде. Аның җиңнәре миңа нәни генә була.

Ямь-яшел!..

Мулла абый миңа иртәгә чалма чалып бирә.

Мин гаеткә барам.

Минем кәвешем әле өр-яңа... Өр-яңа... Мин аны кимәгәнгә, әзрәк кибеп киткән. Әби әле аны суга салып куйды. Аннан соң әби каз мае белән майлый, ул өр-яңа була.

Өр-яңа!..

Әти миңа прәннек тә алып кайта.

Мин сиңа да бирермен...

Миңлевәли малаена бирмим... Бая туп уйнатмады.

Чү-кә!.. Әйе, әнә көтү күренә. Тиз бул. Чап! Син күпернең Шәмсиләр ягында тор, мин — югары оч ягында.

Ишетәсеңме, Миңлегали?

Әнә, әнә чылтыр-чылтыр тырантас чылтыраганы ишетелә.

Ул безнең трантас.

Мөәзиннәрнеке бит тимерле түгел...

Мулла абый этине Казаннан алып кайта.

Миңа читек алып кайта.

Йөгер. Әнә сыерлар су эчәргә төштеләр...

— Миңлегали?.. Әхмәдулла! Миңлегали, Әхмәдулла! Минем ак башлы тананы югары очка җибәрмәгез әле...

* * *

— Әхмәдулла!.. Әхмәдулла!.. Әтиең кайтты!.. Әтиең кайтты!

— Әйдә ку, Миңлегали! Ку!

— Әби, сыерны куып алып кайтма, каймагы чайпала, ди... Минем әти кайткан, миңа кәҗүл читек алып кайткан... Өр-яңа кәҗүл читек. Әнә тырантас... Әй, җаным тырантас... Кара алаша, мескен, тирләгән... Минем читек авыр микәнни?..

— Әхмәдулла, Әхмәдулла! Сыерларны алып кайттыңмы?..

— Кайттым, әби, кайттым.

Әнә Рәбига тәрәзәдә, кулына нәни генә каймалы читекләр тоткан...

— Әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый. Яңа читегем, яңа читегем... Абый, абый, яңа читегем...

— Бик исем китте... Үземә дә әти яңа читек алып кайткан... Миңа — мулла абзыйныкы кебек кәҗүл читек.

— Әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый...

* * *

Әти түр башына утырган, аның янына мулла абый. Самовар гаеткә дип ачылган[1], самовар көлә-көлә җырлый.

Әни чәй ясый, әби әллә нәрсә сөйли.

— Әйдә, угылым, әйдә, угылым, әйдә, Әхмәдулла бәбкәм!

Әни баштан сыйпый, әби аркадан кага.

— Кил, угылым, үз яныма утыр.

— Әти, миңа читек алып кайттыңмы?

— Кайттым, угылым, кайттым. Әнисе, Әхмәдулланың саплы калачын бир әле.

— Саплы калач, саплы калач, әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый! — Мин Рәбиганы кызыктырам.

— Синең саплы калачың юк...

— Минем читегем бар, минем читегем бар...

— Минем дә читегем бар, минем дә читегем бар. Әти, читегем кая?

— Кәҗә Вәли килененең угылы кызамык чыгарган икән, угылым, ул сиңа дигәнне Ураза гаетенә генә өлгертәм диде... Аннан Миңлесәхип апаларның кодаларыннан гына алдым.

Мулла абыйга:

— Кая әле, Фәхрулла, Әхмәдулла читеген бир әле. Зур булмаса ярар иде, угылым.

Абый көлемсерәде.

Мин:

— Юк, юк, булмый. Минем нәни генә читегем була. Нәни генә. Әти, кәҗүлме?

— Кәҗүл, угылым. Менә читек...

Бу читек бөтенләй башка. Аның олтаны да кып-кызыл. Битлекләре, балтыры да дулкынланып тора. Ләкин... Ул ни дип соң кәҗә Вәли килененең угылы кызамык чыгарган?

— Йә, ки, угылым. Йә, ки, зур булмасмы? Зур булса, мулла абыеңа бирерсең...

Читекнең эченә тәпиләремне тыгам. Аның төбенә аягым барып җитми. Тирә-юньнәрендә минем балтырларым-чалтырларым кысылып, кочаклап тормый.

— Тор, угылым. Тор, бисмилла. Йә, тор!

Мин торып бастым. Итекнең кунычы бот төбенә җитте. Аяк башым аның төбен барып таба алмады. Мин төбенә аяк җитми торган суга чумган кебек булып киттем.

---

[1] *Ачылган* — чистартылган.

— Зурракмыни?.. Тегүче Хисами да юк бит шуны кечерәйтергә... Анда ук әйттем, безнең Әхмәдулланың тәпиләре әле нәни генә булыр, дидем. Миңлесәхип абыстайның кодасы: «Юк, булмас, хәзрәт, мәхдүм үсәр әле. Бу елгы гаеткә зур булса, киләсенә чак булыр»,— ди.

Мин читекне әйләндереп-әйләндереп карадым... Тагы кияргә аякларымны керттем, тагы икесе дә төбенә барып җитә алмады.

— Эч, угылым, чәеңне. Әнә саплы калачыңны ал.

Мин читеккә карадым, караган саен ул миңа дошман төсле күренә килде. Мәхәббәтсез читек, дәүкәди читек...

— Рәбига, әләлики-кызыкый, әләлики-кызыкый... Минем чапаным бар!.. Минем чыбыркым бар...

— Эч, угылым, чәеңне. Иртәгә менә мулла абыең үзеңә чалма чалып бирер. Чапаныңны киярсең. Читегеңне әллә, угылым, гаеткә киеп барырга мулла абыеңа бирәмсең? Аның, мескеннең, гаеткә читеге дә иске...

Мин күземне күтәреп карадым, читек тә кызганыч, мулла абый да кызганыч. Бәхетсез читек, нәни түгел читек! Бу кәҗүл дә түгелдер әле... Түгел!

Мин читекләремне мулла абыйга суздым.

Әти, әни һәм әби һәммәсе:

— Менә рәхмәт, менә рәхмәт, мулла абыең менә сиңа чалма чалып бирер. Киләсе гаеткә кәҗә Вәли килененең угылы кызамыктан терелер дә, сиңа нәни генә, үзеңнең тәпиләрең кебек кенә читек килер.

Мин, Ураза бәйрәмендә өр-яңа кәҗүл читек киеп, гаеткә барырмын.

«Әти! Ураза гаете еракмы?» — дияргә башымны күтәрдем. Мулла абый, әти, әни бер-берсенә карашып, елмаешып торалар.

Миңа бердән, минем хәзер дә читегем юк, ураза гаетендә дә читегем булмас, аннары да булмас кебек тоелды. Тамагымны әллә нәрсә кытыклады, борынга әллә ни тулды, күзне әллә нәрсә юешләтте. Биттән, кайнарланып, әллә нәрсә агып төште...

«Минем читегем юк, минем кәҗүл читегем юк»,— дип, әллә кем минем эчемдә сыкранып кычкырына башлады.

Мин тавышланып еларга тотындым. Саплы калачны алмадым.

Чәйне эчмәдем. Акырып барып мендәргә яттым; мине әти дә яратмый, миннән мулла абый да көлә; мине әни дә, әби дә

сөйми... Читегем юк... Рәбиганың читеге бар, минем читегем юк.

Әни торды:

— Ни булды сиңа, угылым? Синең бит читегең бар, тик, кәҗә Вәли килененең баласы кызамыктан авырганга, нәни генә өлгермәгән.

Әби:

— Менә мин сине акыллы дип чапан тектем. Син зур башың белән елап утырасың.

Әти дә:

— Елама, елама! Алай булса, мулла абыеңны кызганмасаң, киеп бар.

Минем күз алдыма тагы шул мәхәббәтсез читек килде. Мин тагы кычкырып еладым.

Әби:

— Мин сиңа үзем кәҗүл читек тегәм. Менә күр дә тор, үзем тегәм. Иртәгә чапаныңны киярсең. Читегеңне киярсең.

Әби чапанымны, яшел чапанымны кигезеп карады.

— Бар да тәмам. Өр-яңа чапан, төймәсен генә тагасы бар. Иртәгә менә читек тә өлгертәм.

— Нәни читекме, әби?

— Нәни читек, угылым.

— Кәҗүл читекме, әби?

— Кәҗүл читек.

Мин саплы калач белән малайларны кызыктырырга, ындырлар артына сыерлар ашатырга чыктым. Иртәгә минем кәҗүл нәни читегем була.

Караңгы төшеп өйгә кайтканда, әби түр башында утырган да, колак артларына җеп белән эләктереп күзлеген кигән дә чынаяк аслыгында акмай белән корымны бергә изеп маташа.

Аның янында әнинең иске читеге.

Бүлмә тактасының шәүләсендә генә аның калын бармаклары әллә нәрсә өстеннән бик кызулап йөргәне, аның әллә ни ышкыганы шәйләнде.

Минем күз алдыма нәни генә читек, кәҗүл читек килеп басты. Ул минеке.

Кил, кил, кәҗүл читек. Иртәгә гает, кәҗүл читек, иртәгә гает!

*

— Тизрәк, угылым! Тәһарәт ал! Әтиең китте. Әнә мулла абыең сиңа чалма чалырга көтеп тора.

Күлмәкне алай-болай киеп, кыска җиңле казакине кия-кия түргә чыктым. Анда әби чапан тоткан. Мулла абый чалма тоткан.

Әби чапан кидерде.

— Утыр, Әхмәдулла, утыр.

Мин чәч ала торган тәбәнәк урындыкка утырдым.

Мулла абый калын тавыш белән:

— Башыңны борма! Чалмаң бозыла.

Мин, яхшы айгыр кебек, муенымны туры тоттым. Әби минем аякларга балтыр чүпрәк урады. Бисмилла әйтеп, уң аякка читек кигезде.

Менә әби икенчесен дә кигезде.

Чалма да чалынып бетте.

— Йә, тор, Әхмәдулла.

Тордым. Аяктагы читек кап-кара булып, җем-җем итеп тора.

Чапан — ямь-яшел.

Чалма — чуп-чуар.

Мулла абый: «Йә, тиз бул!» — дип кызулагач, мин, әле чапаныма, әле читегемә карап, өйалдына чыктым.

Анда минем әле өр-яңа, әби кичә генә каз мае белән майлаган кәвешем кечкенә булганга, мин әбинең яшел башмагын гына киеп киттем.

Мәчет йортына әллә никадәр халык җыелган. Мулла абый барып җитеп тамак кыргач та, бар да торып юл бирде. Ул алга, алга китте. Мин дә, малайлардан узып, аларның алдындагы сафка утырдым.

Мин — мулла малае! Минем чалмам, чапаным, читегем бар!..

Иртә намазны укыдык. Әти вәгазь сөйләргә тотынды. Минем артта малайлар кызыгып карап торалар.

Ә, шулаймы? Таз шайтан! Миңа шалкан бирмәгән идең. Ә, алаймы? Минем чапаным бар! Минем читегем бар, кәҗүл читегем бар!

Мин кулым белән читегемне тотып карадым: йоп-йомшак, майлы кебек.

Менә кояш чыкты. Мәчет йорты тирәсенә киенгән-бизәнгән кызлар, хатыннар, малайлар тулды. Барысы да миңа карый:

— Әнә Әхмәдулла! Әнә Әхмәдулла... Әнә аның чапаны ямь-яшел, әнә аның чалмасы чуп-чуар! — ди.

— Туктагыз әле. Гает намазына торыйк, аның кәҗүл читеген дә күрерсез...

Менә мөәзин абзый әллә нәрсә сөйләде. Менә зур тавыш белән әти: «Аллаһы әкбәр!» — диде.

Һәммә кеше кулын күтәрде, төшерде. Мин дә күтәреп төшердем.

Арттан теге Таз, аның артыннан тагы әллә кем берәм-берәм көләргә тотындылар.

— Әхмәдулла энисенең читеген кигән. Әхмәдулла энисенең читеген кигән!

Малайлар пырхылдады.

Әти, кычкырып, «Әлхәм» укырга тотынды.

Малайлар һаман «Энисенең читеген кигән» дигәнне кабатлаудан бушамадылар.

«Ә, Таз! Көнлисеңме? Кәҗүл читектән көнлисеңме?»

Менә рөкугъка[1] киттек.

Ни күзем белән күрим! Минем читегемнең битлеге бөтенләй кып-кызыл. Балтырының кайбер җирендә кап-кара нәрсә ялтырап торса да, кай җирләрендә кызылланып киткән, ул ала-кола.

Рөкугъта малайлар «сөбханә раббел-газыйм» урынына: «Энисе читеген кигән, энисе читеген кигән»,— диләр.

Түгел, ул болай гына кызарган. Минем чапаным да бар. Чапаным ямь-яшел.

Менә тагы тордык. Малайлар пырых-пырых көләләр:

— Әхмәдулланың чапанына корым ягылган! Кап-кара корым...

— Энисенең читеген кигән. Әтисенең чапанын корымлаткан...

Тагы рөкугъка бардык. Ни күзем белән күрим: чапанымның алгы чабулары дегеткә буялган кебек кап-кара булган.

Әти сәлам бирде.

Бөтен халык сикереп торды. Мине малайлар чормап алдылар. Һәммәсе авызын җәйгән, һәммәсе көлә: «Энисенең кызыл читеген кигән».

Мин һаваланып кына:

— Таз шайтан, айбагар карагы!..— дип киттем. Барып, башмакларны кидем.

---

[1] *Рөкугъ* — намазда иелеп тору, тезләнү.

Малайлар тагы гөж иттереп көлделәр:

— Әбисенең башмагын кигән. Әхмәдулла әбисенең башмагын кигән.

Карасам, чын да әбинең башмагы. Әнинең кызыл читеге. Аның балтыры бешердәп төшкән. Аның эченнән балтыр чүпрәгенең очлары күренеп тора.

Яшел чапанның бер җире ямь-яшел, бер җире кап-кара булып корымлы майга буялган...

Бер малай төртеп җибәрде. Икенчеләре көлеп куйдылар. Тагы берсе төртте. Минем бер башмагым аяктан чыкты, аны, кия алмаганга, кулыма алдым. Берсе чалмамның койрыгыннан тотты. Ул сүтелеп китте.

Малайлар тагы көлә. «Әнисенең читеген кигән!» — дигәнне көйләргә керештеләр. Мин кызу-кызу атларга башладым. Берсе чабуымнан тотты. Мин аның кулын тешләдем. Берсе сүтелә башлаган чалманың очын алып китте. Мин аны куа башлагач, икенче башмагым төште.

Капка төбенә җиткәндә, әбинең:

— Оятсызлар, кая, колагын кисим! — дигән тавышын ишеттем. Күземә яшь тулды.

Умарта кортыннан качкан кеше кебек капкадан атылып кердем. Урамнан гөж итеп малайларның көлүләре, «Әнисенең читеген кигән» дигән такмаклары мине озатты. Хушбуй исле сумса, пәрәмәч тәме чыккан өй каршы алды.

Әбинең:

— Бәйрәм мөбарәк булсын, угылым! — дип, аркамнан кагуына мин акырып елап җибәрдем.

1912 ел

Хикәягә анализ

Анализның төп максаты — әсәр эчтәлеген табу. Эчтәлекнең Әхмәдулла белән бәйле булуы аңлашыла, чөнки әсәрнең башыннан ахырына кадәр сүз аның турында бара. Димәк, төп эчтәлек Әхмәдулла холкына бәя бирүдән гыйбарәт булырга тиештер. Автор үзе героена бәя бирми. Ул аны бәхетсез итә. Ләкин Әхмәдулла бәхетсезлегенә кем гаепле?

Хикәянең беренче вакыйгасы Әхмәдулланың өмете, теләге турында. Герой гает көнен яңа кием белән каршыларга хыяллана. Шул хыял белән уяна, яши. Шуңа күрә бу вакыйгага «өмет» дип тә, «теләк» дип тә исем бирә алабыз.

Беренче өлешнең исемен табу әһәмиятле, чөнки исем бу өлешнең төп эчтәлеген ача. Әхмәдулланың холкын күрсәтә. Аның теләге чиктән ашмыймы? Чиргә әйләнмиме? Бу сорауга укучылар үзләре җавап бирергә тиешләр.

Әхмәдулланың яңа чапан, яңа кәвешләр киясе килүе дә теләге, өмете бит, шуңа күрә бу вакыйгаларны да беренче өлешкә кертәбез. Ә менә геройның көтү каршылавы турындагы вакыйга теләкнең дәрәҗәсен күрсәтә. Әхмәдулланың түземсезлеге турында сөйли. Шуңа күрә көтү вакыйгасы да беренче өлешкә керә.

Әхмәдулланың яңа кием кию теләге шулкадәр зур, аның хәтта өмете дә — чиксез шатлык. Әмма шатлык тиздән үзенең киресенә әйләнәчәк.

Сораулар һәм биремнәр

1. Хикәянең икенче өлешенә кергән эпизодлары турында сөйләгез.

Хәзер, өлешләрнең үзара бәйләнешеннән чыгып, Әхмәдуллага бәя бирәбез һәм әсәрнең эчтәлеген табабыз.

2. Әхмәдуллага бәя бирегез. Әхмәдулла ни өчен яңа киемнәрен шулай түземсезлек белән көтә?
Бәягез дөресме? Чагыштырыгыз.

Әхмәдулла — беркатлы, олылар әйткәнгә ышанучан, яхшы күңелле малай. Түземлеге, сабырлыгы чамалы: аз гына хәтере калдымы, шунда ук утырып елый башлый. Ләкин шул ук вакытта үзен бик тиз кулга ала. Теләген тормышка ашыру өчен, кечкенә генә булса да өметкә ябышып үзен юата. Зур читекләрне кабат-кабат киеп карый. Анысы ярамагач, әбисенең яңа читекләр тегеп бирәм диюенә дә ышана. Өметен тагын уята. Ниндидер иске читекне корымлап утыруын күргәч тә, үзен юату өчен сүзләр таба. Корымга буялган читегенең яңа булмавын белә, әмма барыбер бик горурланып, яңа итеп кабул итә. Чапаны да әтисенең иске чапаныннан тегелә. Ләкин Әхмәдулланың әбисе сүзләренә ышанасы килә. Иске булса да, саранҗы булгач, тиз тузмый торган өр-яңа чапан дип горурлана. Кәвешләре дә озак ятудан кибеп беткән. Аякларына сыймый. Алай да Әхмәдулла кәвешләре белән дә мактана. Аларны суга салып кую, әлбәттә, яраксызлыгын күрсәтә. Ләкин Әхмәдулла үзенең иске кәвешләренең суда булуына да, каз мае

белән майлануга да яхшылык дип бәя бирә. Теләсә нинди вакыйгадан да үзенә юаныч таба белүе — малайның күркәм сыйфаты. Ләкин, шуның белән бергә, ул аз гына мактанчык та. Эчендәге шатлыгын берәүдән дә яшерә алмый. Шатлыгын беренче чиратта дусты Миңлегали белән уртаклаша. Сеңлесе алдында мактана. Әбисеннән үзенең шатлыгын хуплауны көтә. Әхмәдулланың кимчелеге — горурланасы, мактанасы килү хисенә кирәгеннән артык буйсынуда.

Әхмәдулла хикәянең ахырында да беркатлы, хисен җиңә алмый торган малай булып кала. Ул үзен үртәгән малайларга үзләре кебек үк усаллык белән җавап бирә. Берсенең кулын тешли. Тазга ачу белән: «Таз шайтан, айбагар карагы!» — дип кычкыра. Ләкин Әхмәдулла үзенең беркатлылыгы һәм риясызлыгы белән беренче өлештә үк укучыларга ошаган иде. Хәзер ул кызгандыра. Шундый зур өметләрнең кинәт җимерелеп төшүе Әхмәдулланы бәхетсез итә. Гает бәйрәменнән шатлык, бәхет көткән малай хәсрәткә бата, бәхетсез була. Укучы, шулай итеп, каршылыклы хис кичерә. Бер яктан, малайның мондый хәлгә төшүенә үзе гаепле икәнлеген белә, икенче яктан, аны кызгана.

Әхмәдулла хисенә генә буйсынып яшәүдә гаепле, билгеле. Ләкин авыл малайларының гаебе тагын да зуррак. Алар арасында ярдәмсез калган иптәшләрен яклаучы бер генә шәфкатьле кеше дә табылмый. Малайлар үртәп, кешене хур итеп тәм табалар. «Бер малай төртеп җибәрде. Икенчеләре көлеп куйдылар. Тагын берсе төртте... Берсе чалманың койрыгыннан тотты. Ул сүтелеп китте». Аларның шатлыклары усаллыкка нигезләнгән.

Хикәянең исемен метафора дип исәпләгән очракта, кәҗүл читекнең әсәрдәге барлык сыйфатларын да искә төшерергә кирәк. Беренче карауга ул чиккән, йомшак, бөтен кешенең күз явын алырлык матур. Асылда исә, читек — иске, корым ягып кына яңартылган аяк киеме. Шуңа күрә без аны Әхмәдулланың үзе белән чагыштыра алабыз. Аның да купшылыгы, хыяллары ясалма бер матурлык кына, малайлар каршылыгына очрау белән, Әхмәдулланың асыл холкы күренә башлый. Кәҗүл читек метафорасы, шул рәвешле, ике өлешне бер кеше холкы итеп берләштерә.

3. Читекнең югарыда искә алынмаган якларын табыгыз. Үзегез тапкан сыйфатларга нигезләнеп, Әхмәдуллага үз бәягезне бирегез.

Атыны туарырга дип каршы чыккан угылына да Садыйк абзый:

— Исән тордыгызмы, угылым? Хезмәтче тырмага киттеме? — дип эндәште.

Картына комган күтәреп каршы чыккан Мәрфуга абыстайның: «Исән кайттыңмы, карт? Сатулар яхшы булдымы?» — диюенә дә: «Аллага шөкер»,— дип, күңелләнеп җавап бирде.

Чәй янында да Садыйк абзый бик йомшак кыланып, йомшак сүзләр сөйләп утырды.

— Карчык, мин югары очка менеп төшим әле. Шул бүрәнәләр тузылып яталар. Әхмәди угъланнары эшсез булса, мунча салдырып ташлыйм дим. Белмәссең, Сажидә дә җиткән, тәкъдире булса, биреп тә куярбыз. Кара мунча белән кияү, кода сыйламассың инде,— диде.— Түбән авылның Шәрәфи абзый белән чәйгә кердек. Шул сөйләп торды: «Иске мөәзиннең угылына тамга җыйдык, хәзер имтиханга китте. Бик яхшы бикәч кирәк иде. Минме, минем карчыкмы, җомга укыгач, чәй эчәргә генә барып килсәк, көтелмәгән кунак кайдан килде дип исеңез китмәсен дим генә»,— диде. Көлә-көлә аерылыштык. Җыйнаграк торырга кирәк, карчык. Мин, алай-болай кунак-төшем булса дип, онын-тозын алып кайттым,— диде.

Мәрфуга абыстай, эченнән сулап:

— Алла хәерле кылсын. Кеше өчен үстергән бала бер кешегә китми хәле юк инде,— диде дә.— Кызым, кызым! Сажидә, Сажидә! — дип, кызын чакырырга тотынды. Кызы кергәч, бик йомшак иттереп кенә кызын күздән кичерде. Аңар кызы, шул, унсигезгә кадәр кадерләп үстергән кызы кызганыч, аяныч кеби тоелды. Мәрфуга абыстайның күзенә яше килеп тыгылды, ләкин күңеленә мөәзингә соралуы килеп төшкәч, аның ихтыярсыз авызы елмайды. Аның күңелен шатлык тутырды. Ул, тагы йомшак кына иттереп:

— Җиңгәңнең кулы-башы катып беткәндер, аш-су янына китерерлек тә түгел, бигрәк лыгырдык. Менә өч-дүрт йомыркага гына кош теле пешермәкче булам, кулыңны юып кына камыр әвәлә әле, муллаларга кунак-төшем буласы, имеш, чәйгә-фәләнгә алып керелсә, бернәрсә юк,— диде.

Сажидә, почта юлаучы атларының кыңгыравы кадәр зур чулпысын чалтыратып, исле сабын белән кул юарга чыгып китте.

Мәрфуга абыстай тагы: «Менә, Аллаһы Тәгалә бәхетене бирсә, мөәзин хатыны булыр, ил буенда кадер-хөрмәт күреп йөрер. Аллаһы Тәгалә сәламәтлек бирсә, баласы-чагасы булыр, шәкерте мәдрәсәгә китеп укыр. Бу елда инде мулла угылы дип тормыйлар, мөәзин угылыны да мулла ясыйлар. Атасы-анасына дога кылыр. Бу мужик халкының затсызлыгыннан йөдәдем инде. Әле бит килендәшем бай хатыны булган булып һаваланган була. Беркөн муллалар мәҗлесенә бит ашка катык катып чыгарган».

* * *

Көтүләр чыкканчы, хезмәтчеләр белән урманга киткән Галәү бөтен йортны балта шакылдавы, пычкы чыжлавы белән тулган тапты. Ул үзенең былтыр көз, сөя-сөя, кискән бүрәнәләренең, тегермән ясарга дип җыеп куйган юкәләренең кайсысы киселеп ташланганыны, кайсысы балтачының рәхимсез балтасы астында елап ятканын күрде.

«Иген сугучылар» дигән сүз тагы аның исен китәрде: «Болар нишләгәннәр?! Тегермән ясарга дип хәзерләнгән бөтен бүрәнәләрне кисеп бетереп, мунча бураталар! Фәхри малайларының шул тегермәннән генә уникe җанлы җәмәгатьне тәрбия кылып торганнарыны белмиләр. Ел да борай төшеннән генә тегермәнчегә капчык-капчык он калдырганыны сизмиләр дип белерсең! Тагы шуның өстенә иген суктыралар. Нәрсәгә кирәк? Әллә ашарга-эчәргә беттеме? Берәр ай үтеп китсә, ике сука арасында бит сугар идек тә, ике ай көткән өчен, бер потка ике пот алыр идек»,— диде. Мәрфуга абыстай:

— Алай сөйләмә, угылым. Менә сине өйләндердек. Хатыныңнан уңмасаң, безгә үпкәләмә (шул сүзне әйткәндә, бүлмәдә самовар өрә торган киленнең зур чулпылары протест ясаган кеби, шалтырап куйдылар), үзеңә үпкәлә. Менә кызымыз да җиткән, белмәссең, язмыш булса... Мулла-мөәзин шул синең кара мунчаңа кереп йөрмәс инде,— диде дә Галәүнең күзенә карады.

Галәү мунча салуның, ашлык сугуның мәгънәсе нәрсә икәнен аңлаган кеби булды.

Галәү, ачулана-ачулана чәй эчкәнен дә сизми калып, ындырга китте. Анда баргач, атасының ике кибәнне дә сугарга кушканын белеп коты очты. Галәүнең тырышлыгы-тырмашлыгы белән еллар буена җыелган шул байлыкны, әллә нинди мулла-мөәзиннәргә ияргә теләп, бер-ике көндә бетерергә

теләүгә каршы аның күңелендә әллә никадәр дошманлык хисе уянды.

Беркөнне өйләдән соң, арбадан ясаган тырантас җигеп, әтисеннән калган читекне киеп, җәйге май ае булса да, камалы тунын киеп, хатынын утыртып, Түбән авылның Шәрәфи абзый килеп төшмәсенме!

Кунаклар килү — тагы андый-мондый гына түгел бит, башкода кунаклар килү — Садыйк абзый, Мәрфуга абыстайның түбәләрене күккә күтәрде. Алар ни кылганнарын оныттылар.

Бер тәкә итене ашап бетереп, яучылар: «Киңәшеп-уйлашып карыйк, базарда хәбәр бирермез»,— җавабыны алып, килгән юлларыннан киттеләр.

Галәү, яшеннең бик якын икәнен сизенеп, шулкадәр тырышлык белән җыелган малның әрәм булырга вакыты җиткәнен күреп, атасы-анасы белән тагы чынлап сөйләшергә тотынды. Ул элгәре яхшылык белән үзләренең мулла-мөәзингә катышырлыклары юклыгын, мулла-мөәзингә Саҗидәнең ярамавын сөйләде. Ләкин шул тәнкыйть сүзләре мөәзин әбисе булу уе белән шашкан Мәрфуга абыстайга да, мулла-мөәзин арасына кереп, «мулла Садыйк» исеме белән эндәшелергә гашыйк булган Садыйк абзыйга да һич тәэсир итмәде. Авылның таза, нык байларыннан санала торган Әхмәдинең угылыннан килгән яучы да, авылның яңа гына кибет ачып сату итә башлаган, бердәнбер башы белән эшкә керешкән шактый суммалы Гарифулланың башкодасы да аларны шул фикердән кайтара алмады. Базар көнне «Аллага тапшырамыз» дияргә карар бирелде.

Баш көнне, акча салырга дип, тагы теге Шәрәфи абзый килде. Тагы аш-су ясалды, мәҗлес җыелды. Акча салырга вакыт җиткәч кенә, Шәрәфи абзый, Садыйк абзыйны читкә алып:

— Әле бит мин акча салырга килдем дә, миңа акча бирмәделәр. Аны, кода, бирәр эш эшлик, мәҗлес яме өчен бирәр хәйләсен булдырыйк, беләсең, мулла-мөәзин халкы акча биреп алырга яратмый,— диде.

Садыйк абзый, «шулай, шулай» дип, карчыгы янына чыгып китте. «Галәүнең сүзләре тугъры булмасын» дигән фикер килде. Ләкин Мәрфуга абыстай аны май кеби язды:

— Алай ярыймы соң, карт. Аларның әле мәшәкатьле елы, безнең әле, әлхәмделилла! Алай да аларга шактый күп чыгыш

булыр әле. Акча бардыр бит, Шәрәфи кодага биреп тор, ул бит барыбер безгә кайтачак! — диде.

Садыйк абзый Шәрәфи кодага утыз тәңкә акча санап бирде. Мулла кияүгә ике пар күлмәк-ыштан, ике пар балтыр чүпрәк, ике пар сөлге, башкодага намазлык, каенанага намазлык, күкрәкчә-күлмәклек, кодача бикәгә күлмәктән башка мулла кияүгә дип бер тутырган тавык, бер кадак чәй, әллә никадәр сумсалар, кодагыйга дип зур-зур күмәчләр, һәйбәт бәлешләр, пешкән очалар[1] бирелде.

* * *

Туй якынлашты. Галәү сугылган игенне ике ат белән базарга ташудан туктамады. Садыйк абзый никах мәҗлесе өчен әйберләр алырга шәһәргә барырга булды. Кесәсендә акча булса да, ул, тагы ике йөккә арыш төяргә кушып, карчык белән ниләр алырганы уйлашырга чәй янына утырды.

— Нәрсәләр кирәк, карчык?

— Бүләк, бирнә дә, аласы әйбер дә юк инде. Кодагыйга бит инде кәшемир күлмәк дигән идек, кызыл кәшемир алырсыңмы, алнымы инде? Затлырак булсын. Баш кодагыйга да, кодагый белән берочтан ук булмаса да, җон булсын дидек бит, карт? Яшь кеше түгел инде кырык итәклене кими торгандыр, ундүрт-унбиш аршын булса, җитәр. Кодачага, карт, һәйбәт кенә, зур гына яулык ал. Кодача мулла-мөәзингә китмәгән әле, аңар инде күлмәге, карт, җон булмаса да ярар. Унсигез-унтугыз аршыннан артык булмасын. Тагы, карт, кодагыйның тутасы бар ди бит. Алты чирекле зур җон яулыклар була, карт, карчыклар өчен, диярсең. Шул ярар. Инде бетте бугай. Фәридә әле әйтә: «Шәһәрдә,— ди,— кияүгә сәгать, постау чикмән бирәләр»,— ди. Минемчә, шул, казакилык, тагы бу елда бит инде яшьләр чалбар да кия. Шул, казакилык, чалбарлык алсаң җитәр. Шуның белән бетте инде. Саҗидә кияү катына керергә дигән аллы җон күлмәкне, кияү арасында алыштырырга дигән бер сатин, бер яңа сарпинкә[2] кеби бар бит әле? — шуны алырга үзең дә хәтереңнән чыгармассың инде. Аңар башка бернәрсә дә кирәкми инде: яулыгы җитәрлек, читеге-кәвеше өр-яңа. Белмим инде, берәр калфак-фәлән генә алмасаң? Хәзрәткә дә

---

[1] *Пешкән очалар* — пешкән бот ите.
[2] *Сарпинкә* — шакмаклы тукыма.

шунда, кияүгә алганда кушып кына алырсың, биш-алты аршын палатна әллә нәрсә түгел! Инде бетте! Карт, тагы ашамлык-эчемлектән тәмлерәк, затлырак нәрсәләр булса, саклап тотарга гына азрак алырсың. Белмим инде, алты пар гына яхшы чынаяк, чәйнек, алты гына тәрилкә алсаң? Әнә карт мөәзин хатынында бар бит, карт? Шуның кеби булсын! Чынаяклар ал булса, тагы затлы булыр. Тәрилкәләрнең агы затлы, ди. Муллаларда бит һәрвакыт ак тәрилкәләр! Кияү муллага пәрәмәч, коймак ашарга вак тәрилкәләр дә күзеңә чалынса алырсың. Очраса, матур гына, пөхтә генә каймак савытлары була, шунда аңар кушып, чәй түбе салырга касәсене дә калдырма инде. Бетте бугай инде. Акча калса, белмим инде, миңа, кодагыйлар белән илгә-көнгә чыгарга дип, бер күлмәк кенә алмасаң.

Садыйк абзый атка утырып чыга башлагач:

— Карт, тагы күзеңә затлырак нәрсәләр чалынса, кызыңа бер-бер бүләк, кияү муллага бер-бер нәрсә алып кайтырга онытма! Саҗидәгә укалы башмак булса да ярый. Кияү муллага сәгать ал димим инде, син ала белмәссең, Әхмәтсафаларның кияүләре алышса, чылбыры җуанрак булсын! — дип кычкырып калды.

Садыйк абзый, шуларны онытмас өчен яулыгының бөтен очларыны төенләп, шәһәргә китте. Галәү, шуларга акча җиткерү өчен теге ике йөкне шыгрым итеп төяп, өстенә базарда җыелган тиреләрне куеп, атасы артыннан китте.

Туй якынлашты.

* * *

Ашлар-сыйлар — һәммәсе муллаларча үтте: ак оннан ясалган пилмәнне ике төрле вак бәлеш алыштырды, бәлешләрдән соң, муллаларча иттереп, серкәле-керәнле тураган ит (мужикларча, турамаенча чыгарган түгел), аның артыннан затлы җимеш суы, иң ахырдан ясап чыгарылган лимонлы чәй бирелде. Чәй янына баягы как-төш чыгарылды. Бирнә күрсәтелде.

Хәзрәтләр — шактый күп алган туй садакасыннан, авыл кешеләре — тәмле иттереп ашаган ашлардан, кода-кодагыйлар — яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлесенең муллаларча үтүеннән разый калдылар. Барысы да шатландылар, сөенделәр.

Бөтен йорт-җир, бөтен кешеләр кияү көтәргә тотындылар. Бөтен кешеләр ярты тавыш белән генә сөйләшә башладылар.

Менә түбә өстеннән өч атлы тимер ходның[1] тузан туздырып якынлашканы күренде. Менә кыңгырау тавышы ишетелде. Авылга керделәр. Садыйк абзый, әдрәс[2] казакиены киеп, капка төбенә чыкты; ак күлмәк, яңа чабата кигән хезмәтче капканы тотып тора башлады.

Кыңгырау якынлашты. Капка ачылды. Шалдыр итеп килеп, тырантас ишек төбенә туктады. Тырантастан иң әүвәл Галәү сикереп төште, аның артыннан Садыйк абзыйның кияү бүләгеннән тектергән казаки, чалбарын, үзенең мәдрәсәдәге иске җиләнен, авылларындагы яшь мулладан алган кара бүрекне, Мәрфуга абыстай биргән өч тәңкәгә алынган читеккәвешне киеп, шулар өстенә болар биргән сәгать чылбырларын матур иттереп салындырып, кечкенә, ябык кына кияү мулла төште.

* * *

Икенче көнне Мәрфуга абыстай иртүк торды. Аягының очына гына басып, киленне уятып, мунча ягарга кушты.

Кояш шактый күтәрелде. Мунча өлгерде. Эссесе йомшак булсын өчен, Садыйк абзый, бер-ике чүмеч кенә пар салып чабынып чыкты. Коймак кабарып җитте, сумса камыры кабарып кире кайта башлады, пәрәмәч тышлары ясалып бетеп, майлы таба да кызарга хәзерләнеп җитте. Сүрән генә иттереп, аш өенең миче ягылды. Кияүләр өендә тавыш-тын чыкмады.

Менә кияүләрнең өендә җан галәмәте сизелде. Әллә кемнең йомшак кына идән буйлап атлау тавышы колакка керде. Мәрфуга абыстай, тагы аягының очы белән генә басып чыгып, йортта маташа торган киленне кул изәп кенә чакырды. Киленнең килүе белән:

— Бар, тордылар бугай. Шәлеңне салып кына ишек төбенә бар, чибәр абыстаңа әйт! — диде.

Килен, зәңгәр шәлне салып, падишаһ янына кергән кеби генә калтырап, ишекне акыртын гына тартты. Өйдә сөйләшкән тавыш ишетелде. Менә, акыртын гына атлап, ишеккә килгәне сизелде. Ишек ярык кына ачылды. Килен кызарганрак йөздән бераз оялганрак кыяфәтле чибәр абыстайны күрде. Килен:

— Мунча хәзер, торган булсаңыз барыңыз. Тыштагы казанда ару су, эчтәге казанда юыну суы,— диде.

---

[1] *Тимер ходның* — тимер тарантасның.
[2] *Әдрәс* — ярым ефәк тукыма.

Бераз вакыт үтмәде, шәл ябынып, оялганлыктан күзене түбән таба төшереп, Саҗидә, казакидан, ыштан өстенә генә яланаякка кигән кәвештән мулла кияү мунчага таба киттеләр.

Менә киткән кеби үк иттереп кайтып килә торган кияү, бикәче күренде. Башын түбән игән Саҗидә, бите кызара төшкән кияү мулла да, кешедән качкан йомран кеби, елт итеп кереп югалды.

Коймакның өстенә тагы сары май салып, килен, тагын шәлене ябынып, бер тәрилкә сумса, бер савыт каймак күтәреп, кияүләр ишегенә китте. Ишек ачылды. Саҗидә тагы коймак, сумсаны, каймакны алды. Килен пәрәмәчләрне ала башлады. Ул аларга тагы шурпаларын салып, бер кулына кияү сыйлар өчен алынган пыяла савыттагы серкәне күтәреп китте. Тагы ишек шакылдады, ишек ачылып, пәрәмәч эчкә китте. Икенче табалар да китте, өченче табалар салынды; ул да китте. Мәрфуга абыстай кияү муллага азрак булмаса ярар иде дип шөбһәләнә башлады. Менә тагы сумса кертелде. Саҗидә:

— Монда булды инде,— диде.

Калган бер ике-өч сумсадан баядан бирле карга кеби авызыны күтәреп тора торган киленнең угылына — берсе, Садыйк абзыйга — берсе, Мәрфуга абыстайга берсе тиде. Коймак беткәнгә, аның тәмене берсе дә татый алмады. Пәрәмәчнең тәме дә исенең яхшылыгыннан гына сизелде.

Килен, чәй эчмәкче булып, самовар яңартырга өлгермәде, хезмәтче белән Галәү кызып-янып кайтып керделәр. Галәү, йортка керү белән хатынын шәл ябынган көенчә күреп:

— Әллә бүген төштеңме, шәл ябынып йөрисең? Самовар тизрәк, тизрәк самовар! — дип кычкырды.

Мәрфуга абыстайның коты очты. Ул тагын, аяк очы белән генә басып чыгып:

— Галәү! Угылым, угылым! Акрын! (Теге өйгә күрсәтеп.) Кияү мулла бар, кияү мулла! — диде.

Сусаганнан эче кипкән Галәү, бер сүз дәшмәсә дә, дошман күзе белән түр өйгә карады. Килен үзенә дигән самоварны аларга бирде. Чәйдән соң аш ашау гадәтләре булса да, кичкә кадәр кыр эшендә ашамаенча торырга мөмкин булмаса да, Мәрфуга абыстай:

— Казан буш түгел, угылым, менә шуларны ашаңыз,— дип, бер савыт катык, кичә кияүләрдән калган бәлешнең капкачыны китереп бирде.

Галәүнең угылы: «Әти, мин дә ашыйм!» — дип, бәлеш капкачының яртысын атасыннан алды. Галәү, ачу белән ашаганыны да сизмәенчә, катыкны бетерде. Тамак аз гына да туймаганга, ачуланган тавыш белән хатынына:

— Әллә бер-бер нәрсә хәзерләргә ярамас идеме? Өйдә ятып, аш та хәзерли алмыйлар! — диде. Килен:

— Чү, чү, шаулама. Үзең ашадыңмы дип сора. Кичәдән бирле авызыма бер локма чынаяк чәй эчкәнем юк,— диде.

Галәүләр тагы киттеләр. Тагы өй өрәкләр төсен алды, тагы тавыш-тын бетте.

Менә аш пеште. Килен, кулын юып, пилмән ясап алды. Кияү сыйларга алган мискидә элгәре пилмән китте, аның артыннан тавык бәлеше, аның артыннан дөге бәлеше, аның артыннан тутырма белән ит, аннан соң чия суы. Миски төбендә генә калган пилмәнне Мәрфуга абыстай Садыйк абзыйга салып бирде. Ярты төбе калган тавык бәлешенең ярты капкачыны Галәүнең угылына сындырып биреп, калганыны җыеп куйды.

Үзе:

— Килен, самоварың кайнаганмы? Мулла халкы аштан соң чәй эчүчән була,— дип, самовар куярга кушты.

Самовар бирелде. Чәй янына Мәрфуга абыстай, лимон, эфлисуннан башка, кичә пешерелгән алма бәлешен, Садыйк абзый алып кайткан конфетлардан бер савытын, бәлки, чәй белән кабып эчәргә ярап торыр дип, варенье янына коры җимешләр төяп керттерде. Аннан соң:

— Килен, каенатаң иртәдән бирле рәтләп чәй эчкәне юк, самовар куй да мунчаңны барып кара. Тиз йөр! Кияү мулланың ашыйсы килә башлар, кичке ашны салырга кирәк,— диде.

Менә көтүләр кереп, килен сыерлар савып бетермәде, кияүләр тагы мунчага киттеләр. Алар кайтуга дип, ул тагы самовар куйды. Чәйдән соң, баягы кеби үк итеп, тагы элгәре шурпа, аннан ары бәлеш, аннан ары ит, аннан ары җимеш суы, аннан ары самовар бирелде.

Икенче көнне дә вакыт шулай үтте. Өченче көнне дә, казан буш булмаганга, Галәүләргә аш булмады. Эш күпкә, килен чәй эчә алмады.

Шул көй белән тугыз көн үтеп китте. Зәгыйфь кенә, ябык кына килгән кияү кызарып-тулып китте. Галәүләр, хезмәтчеләр уникенче көнендә, эштән кайткач, кайнар аш ашый алдылар.

* * *

Өч-дүрт көн үткәч тә, Мәрфуга абыстай:

— Карт, мулла кияүне алдыруны уйлый башларга кирәк, синең хәтереңә дә кереп чыкмый. Ул бит мужик кияве түгел,— дип туглый башлады. Тагы ун көн үткәч, кияү бөтен хәзерләнгән нәрсәләрне ашап бетереп кайтып китте, тагы Галәүләрнең авызларына кайнар аш тиде.

* * *

Өченче килүдә, программа башкара төште. Кияү мулла белән Саҗидәне Мәрфуга абыстай илгә-көнгә чыгарасы килгәнгә, иң әүвәл абыстай белән хәзрәтне кияү чәенә чакырды. Икенче көнне сатучы Сираҗилар хатыны белән чакырылдылар, «үземезнең Фәхретдиннәр» дә кичке ашка өндәлделәр. Киленнең атасы затсыз булса да, Галәү күңеле калмасын дип, кодагый белән ул да дүртенче көнне ашка алдырылды. Бишенче көн, алтынчы көн дә кунаксыз калынмады. Ләкин бу мәшәкатьләр бушка чыкмады: мулла кияү белән Саҗидәне парлап ашка чакыра башладылар.

Кияүләр кунакка чыга башлау белән Галәү өчен тагы бер уңайсызлык артты: суканың иң кызу вакыты булса да, ике сабан белән сукалап, тизрәк икешәрләргә керешергә теләсә дә, кияү мулла остазбикәсе белән урам буеннан селкенеп җәяү йөри алмаганга, бер ат һәрвакыт өйдә калдырылды. Галәү, никадәр сөйләп, суканың катыга калуыны исбат итәргә теләсә дә, бер мәгънә чыкмады, ат калды, казан бушамады, җир ката килде.

Урак өстендә дә кияү сыйлау белән мәшгуль булганга, килен өйдән китә алмады. Коры-сары белән торудан туеп беткәнгә, хезмәтче, качып, кыр ягына китте. Бөтен кырда Галәү үзе калды. Өйгә кайтканда, аш булмау, шул ашсызлыкның җәй буе баруы аны көчсезләтте: ул, кыйнап ташлаган кеби булып арып, иртәгесен урыныннан калка алмый башлады.

* * *

Ләкин кияү, өйләнгәненә өч-дүрт ай үткәнне сизмәгән кеби, һаман әле хатынын өенә алырга теләми, ул һаман әле айның егерме көнен монда үткәрә иде.

Сабан ашлык сатылгач, Мәрфуга абыстай:

— Мулла кияү Саҗидәне алырга сораса, карт, нишләрмез? Ничек итеп кызымны шул иске өйгә төшерик! Ичмасам, шунда урыс арасында йөргәндә карый йөр: юнь генә, яхшы гына

беткән өй булмасмы? Бурадан салдырырга бик озакка китәр бит,— дия башлады.

Галәү тагы каршы килә, тагы мыгырдана, тагы аңар карамаенча эш башлана иде.

Менә, шулай итеп, өй дә эшләнә башлады. Сажидә, кунакка барганда, өйне яратып кайтты, ләкин кайткач та:

— Әти, шунда калдык-постыктан мунча да ясат инде. Мунчалары юк, күршегә йөрү бик уңайсыз,— дияргә өлгермәде, Мәрфуга абыстай:

— Ясатырмыз, кызым, ясатырмыз,— диде.

Өйләр беткәч тә, кияү мулла Сажидәне бөтенләй алырга булганга, Садыйк абзый тагы кызу-кызу шәһәргә йөрергә тотынды. Ул шактый йомшаган булса да, сер белдермәс өчен, Сажидәгә ак самовар, яхшы чынаяклар, яхшы тәрилкәләр, мискиләр, кашыклар, ике җиз комган, зур бакыр тас, зур һәйбәт сандык алып кайтты.

Сыер биргәч, ат бирми килешми инде! Галәү никадәр бирдермәскә теләсә дә, бу ел гына дүрткә чыккан айгырны бирергә килешелде. Биш баш эре сарык бирергә булды.

Җәй булды. Сажидәнең кызы туды. Мулла-мөәзин баласы бит, мужик баласы түгел! Бала аты кушу мәҗлесенә Мәрфуга абыстай ничек тә кодагый абыстайны алдырасы килде. Иске запас беткән булганга, Садыйк абзый, үз сарыкларыннан дүрт башыны суеп, илтеп сатып, мәҗлескә әйберләр алып кайтты.

Туй бик шәп үтте. Алдан күрше авыл боярыннан алган повозкада кияү мулла белән Сажидә китте, арттан дүрт йөктә әйберләр китте. Сыер, сарык, болар белән бергә барып керсен өчен, алдан ук җибәрелде. Туй төште.

* * *

Кияү киткәч, йорт бераз тынганрак булып калды. Хезмәтче белән Галәүгә дә аш казаны бушады. Киленнең дә өстенбашын юарга, керен чайкарга вакыты булды.

Ләкин җәй үткән саен, бу елның былтырдан аермасы барлыгы бик беленә иде. Ун-унбиш елдан бирле төбе күренмәгән он, ашлык өсәкләреннән әллә кайчан җилләр исә иде. Сыртлары кайда икәнлеге югалган атларның да кабыргалары саналып тора иде. Садыйк абзыйның да өсте майланган, Галәүнең дә оеклары ертылган, киленнең дә күлмәкләре сизерәгән иде.

Шуларны күреп, Галәү өч кеше кадәр эшли, Садыйк абзый элгәрегедән ике өлеш артык гайрәт белән сату итә иде. Ләкин

килгән файда, эшләгән эш һаман уела бара, Садыйк абзыйның он алырга дигән актык биш сумы мулла кияүнең йорт тирәсенә такта алырга җибәрелә, Галәүнең өч атна маташып череткән мунчаласы да, мулла кияүләрне сыйлар өчен, вак-төяк алырга китә иде. Чыгыш күбәйгән саен, йорт бозыла бара, фәкыйрьләнә бара; фәкыйрьләнгән саен, җитмәгән җир күбәя бара; шул җитмәгәннәрне бетерер өчен, бигрәк кешегә күрсәтмәс өчен, бурычка бата бара иде.

Көн шулай егыла-тора үткән чакта, мулла кияү, йорт-җирне бетереп, йорт котларга кунаклар җыярга булды. Сәҗидә әнисенә:

— Кунаклар өчен, әни, әти бер капчык он алсын, бер кадак чәй алсын, биш-ун кадак шикәр янына бер генә савыт варенье алсын. Дөгенең бик вагы булмасын! Берәр көн алдан, әни, үзенең генә бер-бер малай артыннан бер суйган тәкә, берне терелә тә, муллалар алган көнне суярга, берәр язым гына май белән җибәрерсең.

Йортта чыгарырлык бернәрсә булмаганга, Садыйк абзый, башын кашый-кашый, бурычка арыш сорарга китте.

Кунаклар юлга чыктылар. Кияү мулла да, Сәҗидә дә бик шатланып каршы алдылар. Ирләр дә, хатыннар да авылның ике мулласына да кунакка бардылар, авылның бөтен байларына мәҗлескә йөрделәр. Бик зур хөрмәт күреп, дүрт-биш көн үткәреп, кызларының бәхетле булуына шатланып, өйгә кайттылар.

* * *

Бу ел ашлык бәрәкәтсез булды. Сабан ашлык сугыла башлаганчы, арыш сатылып бетте.

Яз җитә башлагач, язгы налогка туры атны сатарга тугры килде. Сабан ашлык өчен рәтләп җир ала алмаганга, хезмәтче яллап тормаенча, Галәү үзе генә сукаларга тотынды. Ул шул ике ел эчендә Хозыр кулы белән чыгарылып җибәрелгән дәүләтне үзенең тырмашуы, тырмануы белән генә кайтарырга мөмкин икәнен белгәнгә; шул тегермәнне ясый алса, кыш көннәрендә мал-туарга, үзләренә ашарлык китереп булганга; эш өсте өчен бераз он җыеп калып, әллә никадәр файда итәргә мөмкин булганга, бөтен көчен шуны булдырырга таба борды. Шуның өчен ул, алган агачларын кисеп бетергәннең соңында, кайсын валга булыр, кайсын төпкә булыр дип төпләде дә, берничә агач кисеп, өйгә таба юнәлде.

Юл буенда ул күрше авылның тегермән осталарына кереп, күпмегә эшләп бирүләрен сөйләште. Тегермәнчеләр бик очсыз эшләргә вәгъдә биргәнгә, ул, хатынының бөтен тәңкә-теңкәсен куеп торып, яңа ашлыкка кадәр өлгертергә карар биреп, атасына киңәш итәр өчен, ашыга-ашыга өйгә кайтты; ләкин ни күзе белән күрсен, былтыр кискән бүрәнәләреннән җилләр искән. Галәү никадәр ата-анага хезмәт итәргә кирәген белсә дә чыдый алмады: ул, бер кешегә дә багышламаенча гына булса да кычкырып-кычкырып сүгенә башлады. Садыйк абзый, аның сүгенүен ишетмәгәнгә салынып, ак якка чыгып китте. Анасы, чыгып:

— Чү, Галәү, бәбкәм кычкырма. Мулла кияүләрнең угыллары бар, ди. Бәбәй туена ни белән бармакчы буласың? Сәләхи малае алырга теләде дә, сатып җибәрдек,— диде.

Галәү көн буе дәшмәенчә йөрде. Кичке чәйдә Мәрфуга абыстайның иртәгә базарга бара торган картына:

— Потлы капчык ак он, ун кадак кына дөге, җимеш, бәбәй күлмәге иттереп Саҗидәмә күлмәк, кияү муллага бирәр камзуллык, казакилыкмы нәрсә...— дип сөйләп бетергәнне көтте дә, ул, әллә нинди тавыш белән генә:

— Әти, мин иртәгә чыгам, фатиха бир! — диде.

Садыйк абзый катып калды. Мәрфуга абыстай:

— Ничек оялмый сөйлисең?! Атаң-анаңны калдырып чыгып китүне уйларга ничек оялмыйсың? Мулла кияү күзенә без ничек күренермез? — дип, тагы әллә ниләр әйтмәкче булды. Ләкин «мулла кияү» дигән сүз Галәүне, көзән җыерган кеби, астын өскә китерде. Ул:

— Төкерим мин синең мулла киявеңә! Фидия козгыны! — диде дә торып китте.

Галәү һаман тиресләнеп, үз әйберләрен җыештырып йөри башлаганга, үгетләр өчен, Садыйк абзый хәзрәтне алып килде. Хәзрәтнең сүзләрен Галәү һәммәсен кабул итсә дә, ахырдан:

— Мулла абзый, болар белән торыр хәл юк. Иртәдән кичкә кадәр эшлим, мулла абзый, йорт булсын дип эшлим, өстемә сорамыйм, алыштырырга күлмәгем юк, мулла абзый. Ашаучүемез дә, мулла абзый, шуның кеби, атна буйлап кайнар аш күрмибез. Мулла кияүнең ак он сумсасы белән пәрәмәч ашавына шул унъеллык хезмәтем кереп китте, мулла абзый. Минем үземнең дә балам-чагам бар, мин ак он коймагын яратмыйммыни? Азрак чаманы белергә кирәк,— диде дә туктады.

Хәзрәт шул сүзләрдән соң, тагы әллә ниләр сөйләп караса да, Галәү тарафы хак икәнен күреп:

— Садыйк ага, сезгә дә бераз җыеныбрак торырга кирәк. Әлхәмделилла, карамадыңыз түгел, Галәүнең дә сүзләре дөрест бит! — диде.

Садыйк та Галәүнең сүзеннән чыкмаска вәгъдә биргәнгә, хәзрәт тә «ил-көнгә мәсхәрә булмаңыз» дип нәсыйхәт иткәнгә, Галәү калырга булды.

Иртәгесен кияү мулладан, бер йөк арыш сорап, хат килде. Галәү никадәр буш җибәрергә теләсә дә, Мәрфуга абыстай тындырмаганга, Садыйк абзый, потын бер сумга хисаплап, бурычка алып биреп җибәрде. Көзге ашлыкны әрәм иттермәс өчен, Галәү әллә никадәр анасы белән оршышты, базарга барганда, кияү муллага кушкан нәрсәләрнең берсен дә алмый башлады, аларны алдырырга җибәрә башласалар да, тавыш күтәрергә тотынды.

Кияү муллага бу килешмәде. Ул, әллә нәрсәгә үпкәләгән булып, өч ай килми торды, өч ай Саҗидәне дә җибәрмәде. Дүртенче айда ул, озын хат язып, оннар, итләр, ашлыклар соратты. Галәү өйдә булмаганга, Мәрфуга абыстай шыгрым бер йөк төяп җибәрде. Ул тагы ачылды, тагы кунакка килде. Кыш яртысында ашлык алырга җибәргән малаена Галәү, бернәрсә бирдермәенчә:

— Биргәннәренә дога кылсын инде, дип әйттеләр диген,— дип, буш җибәрде.

Бер атна вакыт үтмәде, балалары белән Саҗидә килеп төште. Ул елап-елап мулласының хурлануын, шуның өчен Саҗидәне кыйнавын сөйләде: «Менә орлыкка бер йөк ашлык бирмәсәләр, сукага егерме биш тәңкә акча бирмәсәләр кайтма, өйгә кертмим, диде!» — дип зарланды.

Галәү:

— Мин актык орлыктан аңар күзенә кырып салырга бер бөртек тә бирмим! — дип, келәтне биклэп алды.

Мәрфуга абыстай, тагы тәңкәләрен сатып, чулпысын закладка салып, унсигез тәңкә акча бирде. Галәү кырга киткәч, орлык тутырырга дип, келәткә дә керде. Ләкин Садыйк абзый бу юлы бер капчыктан артык салдырмаганга, аңар күрсәтмәенчә, тагы бер капчыктан артык биреп булмаганга, Саҗидә ике капчык ашлык, унсигез тәңкә белән генә китте.

Кырдан кайту белән Галәү, дүрт күзе кеби саклап килә торган орлык кимегәнне күреп, тагы тавыш чыгарды. Анасы:

— Хатының урлагандыр,— диде.

Ул, чыдый алмаенча, тагы җыенырга тотынды. Бу юлы ул дуст-ишнең дименә карамаенча чыгарга булды. Иртә белән, бабаларыннан җиккән ат алып килеп, ул, әйберләрен төяп, өйгә этисе, энисе янына: «Караңыз, бернәрсә дә алмадым!» — дияргә керде. Аларның бер сүз дәшмәүләренә карап:

— Хәерле булсын, дәшәрсез әле,— дип, хатынына кычкырып, угылын арба өстенә утыртып, капканы ачты. Капка ачылу белән, шуны гына көткән кеби, начар гына арбага көчкә генә селкенә торган бия җиккән, арбасының артына иске сандык куйган, ике ягына ике баласын утырткан, елый-елый күзләре шешенеп беткән Саҗидә килеп керде. Ул каршы чыккан энисенә, күз акайтып калган агасына, җиңгәсенә каршы:

— Аерды! Хәрам хат бирде!.. — дип кычкырды.

1911 ел

Биремнәр

1. Әсәргә анализ ясагыз.
2. Садыйк абзыйга, Мәрфуга абыстайга бәя бирегез.
3. Галәүгә һәм аның хатынына (Мәрфуга килененә) бәя бирегез.
4. Мулла кияүгә бәя бирегез.

ҖӘМГЫЯТЬ

Комедия ике пәрдәдә

КЕШЕЛӘР:

Шәриф бай — мәдрәсәләр, мәктәпләр сала торган, ысул җәдит[1] сөя торган тугры гына фикерле карт бай.

Юан бай — Шәриф байның энесе, тупас бай.

Хәзрәт — гади хәзрәт.

Мөәзин — хәйләкәр мөәзин.

Муса мирза — үзен бик динле дип күрсәтергә тырышучы, һәммә кешегә ярарга теләп йөрүче банктагы бер писарь.

Салих — яңа татар егете[2]. Тугры фикерле. Риясыз.

Җамал кода — бик мөтәгассыйб[3] татар бае. Бәдәвамчы.

Бикә — гади бай хатыны.

Килен — гади хатын.

Хуҗа угълы.

Асрау.

Халык — яшьләр, картлар.

Вакыйга Оренбургта, унтугызынчы йөзнең башларында.

---

[1] *Ысул җәдит* — яңалык.

[2] *Яңа татар егете* — яңача карашлы егет.

[3] *Мөтәгассыйб* — иске карашлы.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Зур гына зал. Уртасында озын өстәл. Өстәл өстендә графинларда кызыл кваслар. Залда **халык** күп: кайсы озын өстәл буена, кайсысы читләргә утырган. Өстәлнең башында күзлекле, чуар бишмәт, чалма кигән бер **мулла**. Аның янында чапаннан, чалмадан тагы бер **мулла**. Аның янында ак бүректән бер **хәлфә**. Аның янында русча киенгән, кара мыеклы, яланбашлы бер мирза. Тагы **мөәзин**, **бәдәлче**[1], уртача **халык**, **бай балалары**.

Шәриф бай. Менә инде, җәмәгать, сезне шуның белән өшәндердек[2]. Хәзрәтләр килми...

Бер кеше. Алар бидгатьтән[3] куркалар. Әһле голәмага[4] шул, мондый убществалар арасында йөрергә ярамый инде.

Муса мирза. Ул, Садыйк абзый, алай булып бетәр микән соң? Ул инде, вәт менә мин инде бу мөселманнарны да барысын да убществага килмәгәннәр, болар җәмгыятькә *(җәмгыять дигән сүзне бик мишәрчә әйтә)* килгәннәрдер дип уйлыйм, мин үзем убществага килмәдем, җәмгыятькә килдем.

Халык *(беравыздан)*. Убщества түгел! Җәмгыять, җәмгыять! Түгел!

Салих. Ул бит җәмгыять берлә общество арасында аерма юк!

Халык *(кычкыра)*. Бар, бар!

Мөәзин. Убществаның хәрамлыгы ап-ачык!

Бер бай. Хәрам, хәрам!

Салих. Сез миңа сөйләргә бирмәдегез. Җәмгыять — җыелыш дигән сүз, общество да шулай дигән сүз!

Тавыш. Түгел, түгел! Убщества кирәкми! Җәмгыять кирәк!

Шәриф бай. Менә мин үләм. Шуның өчен фәкыйрь балаларга укырга акча калдырмакчы булам. Шул ярыймы, юкмы? Шәригатькә сыямы, юкмы?

Җамал кода. Син ысул җәдит мәктәбе ачмакчы буласың? Менә шул шул, менә шул инде, җәмәгать, очы кая килеп чыкты!

Халык. Юк, юк! Безгә ысул җәдит кирәк түгел!

---

[1] *Бәдәлче* — башкалар өчен хаҗга баручы.
[2] *Өшәндердек* — интектердек.
[3] *Бидгать* — ярамый торган эш.
[4] *Әһле голәма* — гыйлемле кешеләр.

М у с а м и р з а. Әле вәт, Шәриф абзый ысул җәдит дигәне юк, җәмәгать. Ул, менә үзеннән соң акча калдырам, ди. Укырга инде, фәкыйрьләргә укырга. Бу соң, хәзрәтләр, саваплы эш түгелме соң?

М ө ә з и н. Ул бай акча калдырырга теләсә, әлбәттә, бик яхшы эш инде. Ләкин бит, ул фәкыйрь балалар укытудан кирәгрәк эшләр бар, мәсәлән, мулла-мөәзин халкының хәле бар бит. Мәхәллә халкы, үзеңезгә мәгълүм, карый алмый.

Б е р м у л л а. Әйе, әйе, голәманың эше авыр, көн күрүе кыен инде. Аларны онытырга ярамый.

С а л и х. Менә ни өчен сез баядан бирле шәригатькә сыймый дип торасыз икән!

Т а в ы ш. Ни сөйли! Хәзрәтләргә каршы килә! Алладан оял!

Ш ә р и ф б а й *(кызып)*. Менә инде, җәмәгать, актык сүз: мин инде карт кеше. Мин инде үләргә хәзерләнәм. Менә шул, башка шәһәрләрдәге кеби җәмгыять ачсаңыз, мөэмин-мөселман бергә булып карарга булсаңыз, мин ун мең сум акча калдырам. Юк икән, ул акчаны мин бүтән шәһәргә бирәм.

Х а л ы к. Ачамыз, ачамыз!

М у с а м и р з а. Менә инде, җәмәгать, ишеттегезме инде? Шәриф абзый бик зур акча калдырырга тели. Вәт, без инде, хәзрәтләр фатиха бирсә, шул җәмгыятьне ачыйк инде. Менә, хәзрәтләр, сез шуңарга фатиха биреңез инде.

Б е р м у л л а. Аллага тапшырдык инде, җәмәгать. Шәриф абзый да мәхәллә картымыз, аның күңелене дә калдырмыйк инде. Инде алай булса, бер фатиха бирик. *(Кул күтәреп дога кылалар.)*

Б е р м у л л а. Әһле исламга файдалы булсын инде.

Х а л ы к. Амин!

Ш ә р и ф б а й. Менә инде, алай булса, Муса мирза, син инде уставны укы.

М у с а м и р з а *(кесәсеннән кәгазьне чыгарып, күзлеген киеп караштыргалап, Салихка бирә)*. Мә әле, сез укыңыз әле, Салих әфәнде!

С а л и х *(укый башлый)*. «Җәмгыятьнең, кавычкада общество, максаты...»

Х а л ы к. Убщества кирәкми, убщества кирәкми!

Ш ә р и ф б а й. Шул сүзне сыз!

С а л и х *(кулындагы карандашы белән сызып)*. «Җәмгыятьнең максаты — халкымызның мохтаҗ тарафларына ярдәм итмәктер...»

Халык *(кычкырып).* Боз! Боз! *(Салих кара берлә боза.)*

Берәү. Монда «халкымыз» дигән. Нинди халкымыз? Ник аны бөтен мөселманның димәгән?

Салих. Бөтен дөньяның мөселманына без ярдәм итә алмыйбыз, аны үземезгә максат итеп ала да алмыйбыз.

Берәү. Ник булмасын? Әлхәмделилла, без — мөселман!

Хәзрәт. Әйе, «бөтен мөселманга» дияргә кирәк.

Муса мирза. Әйе, җәмәгать, ул шулай кирәк инде, «бөтен мөселманга» дияргә кирәк. Вәт, без барымыз да шул уйда инде. Ну, вәт, бездә тагы бернәрсә бар: миссионерлар[1] дигәнебез риза булырмы? Миссионерлар — вәт алар бик дошман — минем нишләгәнне карап кына торалар. Алар, вәт, бу Муса мирза мөселманга файдалы эш эшләмәсен дип аяк чалырга гына торалар.

Хәлфә. «Мөэмин-мөселман» дияргә кирәк.

Җамал кода. «Мөэмин-мөселман» урынына «хак мөселман» дияргә кирәк. Хак мөселман булмаган кешегә ярдәм итү — гөнаһлы эш.

Салих. Ничек кешенең хак мөселманмы, түгелме икәнен беләсең? Кешенең эченә кереп карап булмый!

Җамал кода. Әһле голәма юлы берлә йөргән кеше хак мөселман була.

Халык. Дөрест, дөрест!

Муса мирза. Әйе, ул сүзне куй, ул зарарлы түгел.

Салих *(яза).* Алай булса, менә болай булды инде. *(Укый.)* «Җәмгыятьнең максаты — хак мөселманның мохтаҗ тарафларына ярдәм итмәктер».

Берәү. Менә бит инде замана бозылды, төрле бидгатьләр күбәйде. Шуның өчен менә хак мөселманнан морад әһле голәманы игътибарга алучы, борынгы кешеләр юлы белән йөрүче дигән сүзне кушыйк, дим.

Халык. Мәслихәт, мәслихәт!

Тагы бер кеше. Мин, ата-ана фатихасыны алган кеше дигән сүзне дә кушыйк, дим!

Тавыш. Кирәк, кирәк!

Бер бай. Без хезмәт иткәндә, байдан калтырап тора идек. Бу елда менә шул, приказчиклар арасында шул инсаф бетте. Байлардан рөхсәт алмаенча чыгып китә башладылар. Эшкә

---

[1] *Миссионерлар* — мөселманнарны христиан диненә димләүчеләр.

өйрәтер өчен суксаң-нитсәң, судларга бирә башладылар. Болар бит инде, җәмәгать, мөселманлык түгел.

Мулла. Әле үземезнең асрау гына кем булган соң инде, шул да абыстасының сүзенә тел кайтарып, ирек бирсәң, оршышмакчы булып тора инде.

Муса мирза. Йә инде, соң безнең бу беренче маддә[1] ничек була инде?

Салих *(укый)*. «Хак мөселманнан морад: әһле голәманы игътибарга алучы, борынгы кешеләр сүзе белән йөрүче, ата-ана фатихасын алучы, байларның рөхсәтеннән башка үзеннән эш башламаучы» димез инде.

Бер приказчик. Әле бу заманнарда байлар арасында хезмәтчеләрне гөнаһсыз җиргә рәнҗетүчеләр күбәйде. Аз гына ачуы килсә куып чыгара. Менә мондый «урынсыз җиргә хезмәтчеләрен рәнҗетмәүчеләргә» дигән сүзне кушарга кирәк.

Хәзрәт. Ул инде, мөселман кеше алай рәнҗетмәс инде. Гөнаһ икәнлегене белә бит инде. Рәнҗетә икән, әле бит Кыямәт бар. Сезгә Аллаһы Тәгалә аның өчен әҗерене бирер.

Муса мирза. Икенче маддәне укы инде.

Салих *(укый)*. «Шул максатыны тутырыр өчен, җәмгыять мәктәпләр ачарга, кичке дәресләр ясарга, зурлар вә кечкенәләр өчен кирәкле һөнәрләр өйрәтергә юл ачачак һәм дә кирәкле китаплар бастырырга тырышачактыр».

Муса мирза. Бусы ничек, җәмәгать?

Җамал кода. Ул ник анда «мәктәп» дигән? «Мәктәп» бит — урысча «ышкул» дигән сүз. Безгә ышкул кирәк түгел! Без, әлхәмделилла, мөселман!

Халык. Дөрест, дөрест! Ышкул кирәкми! Кирәкми!

Җамал кода. Ул анда «кичке дәресләр» дигән. Ул ни дигән сүз була инде?

Салих. Менә яшь вакытында укый алмаган кешеләргә, көндез вакыты булмаенча укый ала алмый торган кешеләр өчен, кичләрдә сабак укытулар инде.

Берәү. Мондый эшләр соң, хәзрәтләр, пәйгамбәремез заманында булганмы инде?

Җамал кода. Ул алай шөбһәле дә булса, аны калдырып торыйк!

Халык. Калдырыйк, калдырыйк!

---

[1] *Маддә* — статья, параграф.

Мөәзин. Ул кич берлә дәрес укылса инде... намазлар каза кылып булмый[1] инде. Ул намазны калдырырга ярый дигән сүз була инде... Бу бит, җәмәгать, намазны җиңелгә санау була. Ул бит көфер инде.

Тавыш. Дөрест, дөрест!

Җамал кода. Монда, җәмәгать, бер бик зур эш бар икән әле. «Китаплар бастырырга» дигән. Бу инде китаптан морад[2] монда «Бәдәвам» булмый инде?

Салих. Китап «Бәдәвам» гына түгел, кирәкле китапның барысы да.

Янә берәү. Җәмәгать, бу — бик зур эш! Аллаһы Тәгалә ярдәм бирсә, без шуны шулай итик инде. Ул «кирәк китаплар» урынына «Бәдәвам» гына дисәң, яхшы булыр. «Бәдәвам»нан кирәк китап юк бит!

Халык. Шулай, шулай!

Муса мирза. Өченче маддәне укы!

Салих *(укый)*. «Җәмгыятьнең члены булу өчен, елына ун сум түләү тиештер».

Бер хәлфә. Монда инде менә, хәзрәтләр, мин «члин» дигән сүзне аңламыйм. Ул инде әле безнең духовный собраниянең члиннары бар бит. Ул шулар кеби мирза була дигән сүзме инде? Алай булса инде, җәмәгать, мин риза түгел. Имтиханга барган һәркемгә мәгълүм бит: андагы мирзалар шәкертләрнең кәвешләрене яшереп йөдәтеп бетерәләр һәм дә үзләре шәригатькә сыймый торган киемнәрдә йөриләр.

Берәү. Ул «мирзалар шәкертләрнең кәвешләрен яшермәсен» дигән сүзне шунда кертсәк ярамасмы, җәмәгать?

Мөәзин. Ул «члин» дигән сүз монда собрания члине дигән сүз түгел инде. Бу урысча инде.

Мулла. Ул «члин» дигәне, мөәзин, урыс сүзе булмаска кирәк.

Хәлфә. Ул, урысларда кулланылса да, Әндәлес гарәпләреннән кергән булырга кирәк. Ул асылда «җәлин» булырга кирәк. Ләкин урыс халкында «җ» хәрефе булмаганга, аны «члин» дип әйтәләр.

Хәзрәт. Әйе, әйе! Ул урысларның һәр нәрсәсе гарәпләрдән алынган инде. Менә монда, Шәриф абзый, сүзлек китабы булса яхшы булыр иде. Бар микән? Китер әле.

---

[1] *Намазлар каза кылып булмый* — намаз үтәлми кала.
[2] *Морад* — максат.

Я ш ь б а й. Хәзрәтләр! Ул бер дә гарәп сүзе түгел, ул урыс сүзе. Шуның өчен бу сүзне «әгъза» дигән сүз берлә алмаштырып була, һәм дә китап карарга ихтыяҗ да калмый.

Б е р ә ү. Китап карауның зарары юк. Безгә һәммә эшемезне китап боерыгынча йөртергә кирәк.

Муллалар, мыкыр-мыкыр сөйләшеп, китаплар актаралар.

М у с а м и р з а. Әйе, әйе! Без шул китап Коръән өчен, вәт, инде тырышамыз. Хәзрәтләр карасыннар. *(Салих янына бер яшь кеше килә. Алар янына Муса мирза килеп.)* Көлкеме, Салих әфәнде! Вәт, менә мин шулар берлә унике ел торам. Вәт, мин шуларны җайлап килгән кеше шул. Вәт, эш булсын, милләткә файда булсын дип тырышамыз.

С а л и х. Мин болай тырышудан файда булыр дип белмим. Без — укыган кеше, эшемезне аларның наданлыкларына яраклаштырып эшләмәенчә, аларны үземез баскан баскычка кадәр күтәрергә тырышырга кирәк.

М у с а м и р з а. Мин дә, вәт, аны беләм. Ул вакытта, вәт, алар берлә дошман булырга кирәк. Алар, вәт, безгә кире күз берлә карый башларлар.

С а л и х. Карасын. Аюдан курыккан урманга бармый, ди.

М у с а м и р з а. Минем, вәт, җәмәгать бар. Минем, вәт, аларны тәрбия кыласы бар. Ник мин, мазамны китереп, аларга каршы килим. Мин аларга, шулай-шулай дип, кул куеп торган кеби күренәм. Ә эчемнән гел сезнең кебек.

Я ш ь е г е т. Ансы шулай да бит, аннан бернәрсә дә чыкмый. Ул бит бер урында таптану гына була.

С а л и х. Хезмәт итәргә теләсәң, шул, авыр йөкне өстерәргә кирәк. Иделдә ләмкә тарткан бурлаклар кеби, аны агымга каршы сөйрәргә кирәк. Агым астында ул үзе дә бара.

М у с а м и р з а. Вәт, алар надан; алар бай, вәт, куәт алар кулында; акча алар кулында. Вәт, хәзер мин шул Җамал байга каршы килсәм, ул, вәт, мәңге дошман була. Ул, вәт, хәзер минем юлга киртә сала. Мин аңарга аның яклы күренсәм, мине, вәт, ул үзе кебек күрә. Мин үземне ныгытып йиткәч, вәт, киләм дә, юк, не смей, Җамал абзый! Синеңчә түгел, дим. Бу әле җайлашу гына! Җайлашмыйча ярамый. *(Муллалар сөйләшә башлыйлар. Муса мирза китә.)*

С а л и х. Бигрәк былчырак кеше!

Х ә з р ә т. Монда булмады!

М у с а   м и р з а. Бу маддәне, Җамал абзый, кабул итикме инде? *(Халык дәшми тора.)* Бу кирәк инде. Бу тегеләрнең борынына сугар өчен ясалган инде.

Х а л ы к. Кабул итик! Кабул итик!

Халык торып йөри башлый. Салих белән яшь бай бергә торалар. Муса мирза Җамал кода янына килә. Аның янына тагы берничә кеше җыела.

М у с а   м и р з а. Менә әле тегеләр берлә сөйләштем. Аларның күңел каралган, вәт, Җамал абзый! Иман нуры качкан. Вәт, алар безгә мишать итәләр. Әле шуларны үгетләдем. Ден, вәт, бар дим. Синең денең кирәкми, ди. Вәт, ул, андый сүздән Алла сакласын!

Җ а м а л   к о д а. Алар кяфер инде, кяфер!

Х а л ы к. Кяфер, кяфер!

М у с а   м и р з а. Вәт, шулар ук миңа дошман булып йөри. Бер яктан — тегендә миссионерлары, икенче яктан — болары. Муса мирзаң чыдасын гына!

Х а л ы к. Рәхмәт инде, рәхмәт!

Шул арада бер к е ш е килеп керә.

К е ш е. Хәзрәтләр! Җеназаны алып килделәр.

М у л л а л а р *(торып)*. Җеназа укып җибәрик инде, алай булса.

Пәрдә төшә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук өй. Шул ук бүлмә. Өстәл өстендә самовар вә башка әйберләр беренче пәрдә ахырында хәзерләнгән көе торалар. Ишектән баягы х а л ы к дөбердәшеп керә.

Ш ә р и ф   б а й. Менә, хәзрәтләр, инде шул элгәреге голәмалар шул уку юлында хезмәт иткәннәрдер бит? Без дә менә, шулай итеп, укырга юл ачуымыз берлә борынгыларга охшый торганмыз бит?

Х ә з р ә т. Әйе, әйе! Ибне Хаҗиб ундүрт яшендә дәрес укыды, дигәннәр.

Б е р ә ү. Хәзрәтләр! Менә минем бер сүз сорыйсым бар иде. Китапларда, хәзрәти Мусаның таягы бар, диләр.

Хәзрәт. Әйе, әйе! Теләсә аждаһа булган, теләсә җылан булган, теләсә, яфрак ярып, хөрмә биргән.

Теге кеше. Менә шул агач нинди агач булган инде? Ул таяк, хәзрәт, бит артыш агачыдыр инде? Артыштан бит әле җен кача, диләр.

Хәлфә. Әйе, әйе, аның хуш исенә шайтан чыдый алмас, дигән.

Салих. Соң, ул алай булгач, менә бу төн ягы тарафында, Архангел, Вологда губерналарында, артыш агачы бик күп җирләрдә, шайтан бер дә булмаска кирәк инде. *(Халыкның бер төрлесе көлә.)*

Мулла *(ачуланып)*. Ахмаклар! Ул көлкемени? Китап сүзеннән көләләрмени?

Җамал кода. Менә, хәзрәт, болай шыркылдап көлү бит китапта ярамый торгандыр?

Хәзрәт. Юк, юк! Ул инде урыс эше. Һәр көлүеннән, китап, җитмеш мең шайтан яратылыр, дигән.

Мулла. Аннан соң һәр тыелган эшне эшләүдән җитмеш мең шайтан ярала, дигәннәр.

Җамал кода. Менә, хәзрәт, безнең инде бу убществамыздан да шайтан яралмас микән?

Берәү. Соң, хәзрәтләр, бу инде шайтаннарның туе буламы?

Хәзрәт. Була, була! Аларның туена очраган кеше һәлак булыр, дигән.

Берәү. Хәзрәтләр, менә бит әле, пәйгамбәремез, Мәккәдән Мәдинәгә киткәндә, тау тишегенә кергән. Шунда аның өстенә үрмәкүч оя ясады, дигәннәр. Шул үрмәкүч ата үрмәкүч булганмы, анамы?

Мулла. Ул мәсьәлә әле тәмам ап-ачык мәгълүм түгел. Голяманың монда фикер каршылыгы бар.

Җамал кода. Менә, хәзрәтләр, бу бит бик зур эш инде. Халык аңларлык иттереп инде, шул үрмәкүчнең анамы, атамы идекене бәян кылып, җомгаларда вәгазь сөйләсәңез, яхшы булыр иде.

Мөәзин. Аны инде китап иттереп, хикәя иттереп бастырырга яхшы булыр иде. Бу кирәк инде.

Хәзрәт. Әйе, әйе! Мәслихәт, мәслихәт!

Һәммәсе чәй эчәләр. Яшьләр көлеп утыралар.

Салих. Калган маддәләрне укыймме?

Муса мирза. Хәзрәтләр чәй эчә-эчә сөйләрләр. Укы!

Салих *(кәгазьне алып, халыкка карап укый).* «Җәмгыятьнең эшләрен карар өчен, ун кешедән торган бер правления сайланачактыр, һәм дә, аның расходларын тикшерер өчен, өч кешедән торган ревизионный комиссия сайланачактыр».

Халык. Бу ярый, бу ярый!

Салих. Күп тавыш алган кешеләр сайланган хисап кылынып, аз тавыш алганнары сайланмаган хисап кылыначак.

Җамал кода. Ул ни дигән сүз? Менә хәзрәтне сайламакчы булырмыз. Ул аз тавыш алса, ул сайланмасмыни? Ул мөселманлыкмыни?

Салих. Әйе, хәзрәт аз тавыш алса, сайланмаган була шул!

Җамал кода. Ул хәзрәтләр сайланмагач, ул нинди мөселман җәмгыяте була, ди, инде!

Салих. Ул хәзрәтләр сайланмаган мөселман җәмгыяте була.

Халык. Андый җәмгыять кирәкми, кирәкми! Без хәзрәтләрдән калмыйбыз!

Җамал кода. Ул бит хәзрәтләрне мыскыл итү була!

Салих. Хәзрәтләр сайланмасын дигән кеше юк, сайлансын. Әгәр халык аларны ярата икән, аларга шар салырлар, аларны сайларлар. Яратмый икән — сайламаслар.

Бер бай. Монда бернәрсә дә юк инде. Җәмгыятьнең мәгънәсе шул шул инде. Халык бер-бер кешене яратса, аны сайлый, яратмаса — юк.

Берәү. Җәмәгать! Әле монда тагы куркынычлы җире бар. Безнең җәмгыятькә миссионерлар язылырлар да үзләре теләгәнчә күп тавыш берлә эш йөретә башларлар. Менә тотарлар да мәктәпләргә урысча укытырга ясарлар.

Җамал кода. Тагы тотарлар да, күп тавыш берлә, безнең мәктәпләремезгә тәре куярга ясарлар!

Берәү. Алар безнең мәктәпләргә чучка ите кертерләр.

Халык. Юк, юк! Бу кирәкми!

Теге кеше. Руза вакытында, күп тавыш берлә, балаларны руза тоттырмаска ясарлар.

Мөәзин. Куркыныч хәлләр инде!

Халык. Юк, кирәкми! Кирәкми!

Берәү. Моның урынына «Правления әһле исламның мәслихәт күргән эшен эшләр, әһле исламның мәслихәт күргән кешесе сайланыр, әһле голәмага юл бирерләр» дияргә кирәк.

Халык. Шулай! Шулай! *(Яшь бай сөйләргә тели.)*

Салих *(яшь байга)*. Тимә, үзләре теләгәнчә кылансыннар. *(Яшь бай утыра.)*

Җамал кода. Шулай кирәк, шулай! *(Салихка.)* Син шулай яз, Салих! Җәмәгать, соң шуңарга ризамы?

Халык. Риза, риза!

Муса мирза. Син, Салих әфәнде, тагы укып кара әле!

Салих *(укый)*. «Җәмгыятьнең правлениясенә әһле исламның мәслихәт күргән кешесе сайланыр. Әһле голямага юл бирелер. Правления әһле исламның мәслихәт күргән эшләрен эшләр...»

Мулла. Менә шунда, әһле голәмадан элек, «сөннәт юлында гамәл кыла торган» дигән сүзне арттырырга кирәк.

Җамал кода. Шулай, шулай! Хәзрәтләр авырга алмасын, мулла-мөәзин арасында да төрлесе бар.

Салих. Алай булса, менә болай инде. *(Укый.)* «Җәмгыятьнең правлениясенә әһле исламның мәслихәт күргән кешесе сайланыр. Сөннәт юлында гамәл кыла торган әһле голәмага юл бирелер».

Тавыш. Яхшы, яхшы!

Муса мирза. Шуның берлән беттеме инде, Салих әфәнде?

Салих. Бетте!

Муса мирза. Салих әфәнде! Син аны инде акка яз. *(Халыкка.)* Менә инде Салих әфәнде язсын да, җәмәгать, куллар куярмыз инде.

Халык. Әйе, әйе! *(Тагы чынаяк тавышлары, чәй тагы куәтләнә. Салих читкә утырып яза.)*

Муса мирза. Менә инде, җәмәгать, Аллага шөкер, җәмгыятебез дә булды. Инде менә шунда теге каһәрләргә сер белгертмәскә кирәк. Әле берсе миңа әйтә: «Син, Муса Сапич, үзең мөселманнар өчен тырышасың; алар сине эткә дә санамыйлар, алар сине городской Думага гласный иттереп тә сайламадылар»,— ди.

Халык. Сайларга кирәк. Сайларга!

Муса мирза. Бөтен мөселманның җәмгыяте булды. Ул, вәт, тегеләрнең борынына сукты инде. Вәт, алар хәзер белгәч тә, бөтен теше-тырнагы берлә моның председателе Муса мирза булмасын иде, диярләр. Менә, вәт, әле кая эшләр бара!

Берәү. Шул кяферләргә үч итеп, Муса мирзаны сайлыйк!

Халык. Сайлыйк, сайлыйк!

Салих *(кулына бер табак кәгазь күтәреп килеп).* Язып бетердем.

Муса мирза *(кәгазьләрне алып).* Менә, яңез инде, хәзрәтләр, кул куйыйк.

Хәзрәт кул куя. Аның артыннан мулла куя. Аның артыннан тагы мулла, тагы бер карт бай, артыннан Шәриф бай, аның артыннан Җамал кодага бирәләр. Халык тик тора.

Җамал кода *(алып, күзлеген киеп укый. Шуннан кәгазьне утка каршы тотып карый. Бик озак карап торгач).* Җәмәгать! Бу нәрсә?! *(Кәгазь эчендә ут яктысында күренгән гербны күрсәтеп.)* Бу ни бу?!

Берсен берсе бәрешеп, кәгазьне карарга тотыналар.

Берсе. Кош сурәте, кош сурәте[1]!

Янә берсе. Тәресе бар, тәресе бар! Менә, менә! *(Төртеп күрсәтәләр. Салих кәгазьне алып карый.)*

Муллалар. Бу ни бу, бу ни бу?! Сез шулай безне, алдан кул куйдырып, урыс итмәкче буласызмыни?

Җамал кода. Андук, җәмәгать, моның арты бозыктыр дидем!

---

[1] *Кош сурәте* — Россия гербы.

Х а л ы к *(дулый)*. Менә ышан! Менә ышан! *(Салихлар аптырап торалар.)*

Ш ә р и ф б а й. Соң анда кош булса, ни була?

Җ а м а л к о д а. Ишеттегезме? Кош булса, ни була, ди! Сиңа тәреле булса да шулайдыр! *(Халык тавышлана.)*

М у с а м и р з а. Җәмәгать! Бу — начар эш. Бу теге каһәрләр эше булды. Вәт, мөселман дип Салих әфәндегә ышанган идем. Менә яшьләргә ышан!

Х а л ы к *(Салихка)*. Син безне урыс итәргә кул куйдырдыңмы?! *(Салих янына йодрыкларын төеп киләләр.)* Ник дәшмисең?! Безне урыс ясамакчы булдыңмыни?

Б е р ә ү *(шул арада)*. Аллага шөкер, әле кул куеп өлгермәгән идем!

Б е р с е. Бир кәгазьне, бир кәгазьне, бир кәгазьне! Ул яшерергә тели! Кул куйган кәгазьләрне яшерергә тели! Ул, яшереп, тегеләргә бирергә тели! Җәмәгать, харап буламыз!

Х а л ы к. Бирмә! Бирмә!

Салих кулыннан кәгазьне тартып алалар да: «Минем кулым бар, менә кулым!» — дип кычкырышалар. Берсе-берсе берлә тартышып, кәгазьне ертып бетерәләр.

Җ а м а л к о д а *(вак-төяк ертык кәгазьләрне алып, тагы ерткалап, Салихның битенә бәрә)*. Мә, кара йөз, убществаңны!

Х а л ы к. Сөяген көл итик!

Салихка таба барысы да киләләр. Йодрыкларын йомарлыйлар. Яшь фикерләр сәхнә буена яшеренәләр. Салих тик катып тора. Ишектән хатыннар башы күренә.

Пәрдә төшә

1911 ел

Аңлатмалар, биремнәр, сораулар

1. Сатирик әсәрләргә генә хас төзелешне исегезгә төшерегез. Идрис Багдановның «Помада мәсьәләсе» комедиясе, Габдулла Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасы, Гаяз Исхакыйның «Кияү» хикәясе төзелешләрендәге охшашлык турында сөйләгез.

2. «Җәмгыять» комедиясе дә — сатирик әсәр. Шулай булгач, аның төзелеше дә әлеге әсәрләр төзелешенә охшаган булырга тиеш. «Җәмгыять» комедиясен ике өлешкә бүлегез.

3. Мөәзин, Җамал кода, Берәү персонажларын күп катнаштырса да, Гаяз Исхакый аларны бер генә яктан күрсәтә. Бу персонажларның уртак сыйфатын әйтегез. Алар нинди кешеләр?

4. Бертөсле персонажлар арасында Муса мирза белән Җамал кода беркадәр аерылып тора. Алар башкалардан кай яклары белән аерылалар?

5. Гаяз Исхакый шул заман тормышының үзе аеруча әһәмиятле дип тапкан кимчелеген тәнкыйтьли. Мөәзин, мулла, Муса мирза, Җамал кода һәм халыкның үзара мөнәсәбәтләреннән чыгып, шул мөһим кимчелекне әйтегез.

Йомгак

Өйрәнелгән өч әсәрне Гаяз Исхакый иҗатын тәшкил иткән бөтен бер күренеш итеп күз алдына китерергә тырышыйк. Моның өчен әлеге әсәрләрнең үзара бәйләнешен табарга тиеш булабыз.

Анализ нәтиҗәләрен искә төшерик.

«Кәҗүл читек» хикәясендә Гаяз Исхакый яхшы күңелле сабыйның шатлыгы, горурлыгы, үкенече, хәсрәте турында яза. Малай, бөтен дөньясын онытып, яңа читек киеп, урамга чыгу көнен көтә. Аның бу хыялында бала күңеленә генә хас самимилек, гөнаһсыз горурлык һәм чиксез шатлык ята.

Һәммәбезнең шундый өмет шатлыгы кичергәнебез бар. Бу хис, йә сүнгән шатлык, йә тоныкланган канәгатьсезлек булып, хәтердә саклана бирә. Хикәяне укыганда, малай хисләрендә без үзебезнең хәтердә сакланган хисләрне танып алабыз. Читек көтүче ят малай безгә үз, якын булып китә. Без чын күңелдән аңа уңыш телибез һәм уңышсызлыкка очраган сабыйны чын күңелдән кызганабыз.

Ләкин, уйлабрак карасак, малайның бу татлы хисләре алай ук гөнаһсыз түгел. Аның матур хисләре башкалардан өстен булып күренергә тырышу, кемнәндер мактанып үч алу кебек ямьсез хисләр белән аралашкан икән. Әгәр героебыз тышкы матурлыкны бәхеткә ирешүнең бердәнбер чарасы дип ышанмаган булса, малайларның үзеннән көлүен дә шулкадәр авыр кичермәгән булыр иде. Төсе киткән читектән фаҗига ясамыйча, шул вакыйгага көлеп кенә карарга үзендә көч тапкан булса, котыртучы малайларның үзләрен көлкегә калдырган булыр иде. Ләкин малайның башкалардан матуррак булып күренү теләге акылыннан да, горурлыгыннан да көчлерәк булып чыга. Үзеңне кирәгеннән артык ярату ахыр чиктә фаҗигагә китерә.

«Кияү» хикәясендәге Садыйк абзый белән Мәрфуга абыстайның теләге дә — үзләрен башкалардан дәрәҗәлерәк итеп

күрү. Алар да, теләкләренә ирешү өчен, җаннарын да кызганмыйлар. Шуңа күрә кызларының аерылып кайтуы алар өчен фаҗигагә әйләнә. Үзеңне чынлыктан югарырак итеп күрсәтү теләге — үз-үзеңне кирәгеннән артык ярату ул. Садыйк абзыйның бу сыйфаты аркасында бөтен гаиләгә бәла килә.

Гаяз Исхакый «Кәҗүл читек»тәге малайны гаепләми. Малайның, ялгышын аңлап, үзен төзәтү өчен вакыты бар әле. Ә менә Садыйк абзый белән Мәрфуга абыстай инде төзәлә алмыйлар. Тәкәбберлек аларның холкына әйләнгән. Мактану яшәү рәвешләре булып киткән. Гаяз Исхакый мондый кешеләрдән көлә. Гаилә башлыгының тәкәбберлеге бөтен гаиләгә бәла китерә, ди.

Әсәрләрнең икесендә дә бер үк тема кабатлана. Үзеңне генә ярату икесендә дә башкалардан өстен булып күренү рәвешендә ачыла. Бу сыйфат ике хикәядә дә фаҗига белән тәмамлана. Хәзер әсәрләр эчтәлегендәге аермага тукталыйк.

«Кәҗүл читек»тәге малай кемнәргә дә булса охшарга тырышмый. Ул үзе — мулла малае. Ә менә Садыйк абзый белән Мәрфуга абыстай үзләреннән дәрәҗәлерәк кешеләргә охшарга тырышалар. Алар алдында тәлинкә тоталар. Башкача әйтсәк, горурлыкларын төшерү исәбенә дәрәҗәләрен күтәрмәкче булалар.

Берәүләр алдында тәкәбберләнеп, башкалар алдында ялагайлануга икейөзлелек диләр.

Үзеңне генә ярату кешене икейөзле итә, ди автор. Кызганыч, Садыйк абзый белән Мәрфуга абыстай үзләренең шул хәлгә төшүләрен абайламыйлар. Аның каравы эти-әниләренең бу сыйфатын уллары белән килене бик яхшы күрә. Шуңа күрә алар Садыйк абзый белән Мәрфуга абыстайга булган хөрмәтләрен нәфрәткә алыштыралар.

Икейөзле кешеләргә элек-электән нәфрәт белән караганнар.

«Җәмгыять» комедиясенең төп герое — Муса мирза. Ул әсәрдәге барлык вакыйгаларда да катнаша. Муса мирза — белемсез, мактанчык, булдыксыз, алдакчы бер кеше. Кулыннан берни килмәсә дә, ул әледән-әле милли дошманнарга каршы көн-төн көрәшәм дип мактана. Максатын яшерми: шәһәр Думасына депутат һәм әлеге җәмгыятьнең председателе булу турында хыяллана. Муса мирза, яңача фикерләүче Салихлар төркеменә яхшатлы булып, мөәзиннәр төркемен хурлый. Ике-өч минут та үтми, мөәзиннәр төркеменә яхшатлы булып,

Салихлар төркемен хурлый. Икейөзлелек — Муса мирза өчен дәрәҗәгә ирешүнең мөһим чарасы.

Шәриф байның нияте изге. Ул, мәдрәсәләр төзеп, мохтаҗларга ярдәм итү өчен, бик күп акча бирә. Бу эшне шәфкатьлелек җәмгыяте башкарырга тиеш була. Муса мирзаның ишләре — Җамал кода, мөәзин, мулла, җыйнаулашып, шундый изге эшкә аяк чалырга тотыналар. Башта алар Шәриф бай акчасын үз кесәләренә салмакчы булалар. Ниятләре барып чыкмагач, җәмгыятьне үз кулларына алырга телиләр. Анысы да барып чыкмагач, җәмгыять уставындагы сүзләргә бәйләнеп, бу изге эшне бөтенләй юкка чыгаралар. Шундый юньсезлекне голәмалар (укымышлылар) бик җитди кыяфәттә, үзләрен гаять дәрәҗәдә белемле, дәрәҗәле кешеләр итеп күрсәтергә тырышып эшлиләр. Аларга үзләрен чынлыктан яхшырак итеп күрсәтү властьларын саклап калу өчен кирәк.

«Җәмгыять» комедиясендәге Муса мирзаның ишләре дә, «Кәҗүл читек»тәге малай һәм «Кияү»дәге Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай кебек, үзләрен генә яраталар. Мактаналар, үзләрен башкалардан өстен итеп күрсәтергә тырышалар. Ләкин Муса мирзаның ишләре — түрәләр. Алар үзләренең башкалардан өстенлекләрен халыкка ышандыра алганнар. Халык, алар ни әйтсә, шуны үтәргә әзер. Шуның өчен бу кешеләр көлке дә, куркыныч та. Аларның мин-минлекләре бөтен бер милләтне торгынлыкта тота. Фаҗигагә китерә.

Гаяз Исхакый әсәрләренең өчесе дә кеше холкының бер сыйфатына — чынлыктагыдан яхшырак булып күренергә тырышуга багышланганнар. Әсәрләрендә язучы бу сыйфатның балага, гаиләгә, җәмгыятькә тәэсирен күзәтә. Матур кием киеп мактанырга теләгән бала үзе бәхетсез була; муллалар белән туганлашып, дәрәҗәсен күтәрергә тырышкан гаилә хуҗасы гаиләсен бәхетсез итә; үзләрен милләт тоткасы, галимнәр итеп күрсәтергә тырышучы надан мирзалар, мөәзиннәр, муллалар бөтен милләтне бәхетсез итә, ди. Гаяз Исхакый бу әсәрләренең өчесе белән дә «милләтебез ник артта?» дигән сорауга үзенчә җавап бирә.

Әсәрләрен шул рәвешле бергә җыеп караганда гына, Гаяз Исхакыйның дөньяга карашын, борчылу сәбәбен һәм теләген белә алабыз.

Дәрдемәнд

(1859—1921)

Әдипнең чын исеме — Закир Садыйк улы Рәмиев. Ул 23 ноябрьдә Башкортстанның хәзерге Эстәрлетамак районы Җиргән авылында туган. Өч елдан соң әтисе Садыйк абзый Орск шәһәре тирәсендәге Юлык дигән авылга күчә. Закир башта үз авылында, аннан соң Орск шәһәрендә укый. Истанбулга китә. Анда бер ел буе төрек телен һәм әдәбиятын өйрәнә. Закир Рәмиев үз өендә бик бай китапханә җыя һәм гомере буе укый.

Дөнья әдәбиятын һәм фәлсәфәсен ныклап өйрәнә. Ул үз заманының иң укымышлы кешеләреннән санала.

Әтиләре бай гына кеше булса да, Закир үз тормышын үзе җайга салырга карар кыла. Абыйсы Шакир белән сәүдә итә башлыйлар. Сабын, мануфактура кебек вак-төяк товарлар белән ике туган ерак җирләргә барып сату итәләр. Беркадәр акча туплагач, алтын казу эшенә керешәләр. Сатып алган җирләре алтынга бай булып чыга. Туганнар тиз арада баеп китәләр. Приискаларын арттырганнан-арттыра баралар. Уралда иң күп алтын җитештерүчеләргә әйләнәләр. Туганнар сараннардан булмыйлар. Үз акчаларына мәдрәсәләр, мәчетләр салдыралар. Типография сатып алалар һәм үзләре «Шура» журналы, «Вакыт» газетасы чыгаралар. Милли басмалар зәвыклы булсын дип, чит җирләрдә матур шрифтлар ясаталар, шома ак кәгазь алып кайталар. Рәмиевләр чыгарган «Шура» журналы белән «Вакыт» газетасы иң матур һәм яратып укыла торган басмалар булалар. Дәрдемәнднең абыйсы да заманында

алдынгы фикерле, милләтне үстерү өчен җан атып йөрүче бай булган. Туганнар гомерләре буена иң якын сердәшләр, киңәшчеләр булып калалар.

Дәрдемәнд — бик бай, талантлы оештыручы һәм финанс эшләрен яхшы белүче кеше. Шуның өстенә ул — иң талантлы шагыйрьләрнең берсе дә. Күп язмаган. Язганнарын бастырырга ашыкмаган. Бастырганда да, чын исемен яшереп, «Дәрдемәнд» дип куя торган булган. Дәрдемәнднең кем булуын ул вакытта берәү дә белмәгән.

Әмма аның әсәрләрен бик тиз күреп алалар һәм яратып укыйлар. Бик үзенчәлекле шигырьләренең мәгънәсен аңларга тырышалар. Дәрдемәнднең аз санлы кыска шигырьләре төзеклеге, матур яңгырашы, хискә, фикергә байлыгы белән хәзерге укучыны да таң калдыра.

Закир Рәмиев дан артыннан кумаган. Исемен әйтеп мактауга мохтаҗ булмаган. Ул — чын мәгънәсендә ирекле әдип. Үз хисләре белән үзе генә ләззәтләнергә теләгән кебек, кичерешләрен, берәүгә дә охшатмыйча, шигырь юлларына тезгән дә тезгән.

Октябрь революциясеннән соң шагыйрь, мөмкинлеге булса да, чит илгә чыгып китмәгән. Байлыгын тартып алсалар да үпкәләмәгән. Бу бәхетсезлеген дә, тәкъдир шулдыр дип, тыныч кына кабул иткән. Гомеренең соңгы көненә кадәр, бик аз хезмәт хакы алып, балалар укыткан. Үзе өчен генә дигәндәй, кыска шигырьләрен язуны дәвам иткән.

Куанды ил, канат какты мәләкләр[1]!
Шашып, аң-таң булып, шайтан төкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!

Большевиклар төзи торган яңа тормышка мөнәсәбәтен ул шулай белдергән. Үзенең бу тормышта ят кеше булуын ачык әйткән. Әмма зарланмаган, мескенләнмәгән. Үзен туй кунагы дип әйтмәгән. «Кияү» дигән.

Дәрдемәнд — «хәсрәт чигеп яшәүче» дигән сүз. Нигә үзен шулай атаган? Хәсрәтләнү өчен аның бер сәбәбе дә юк кебек бит. Ни теләсә, шуны алырлык байлыгы, яраткан гаиләсе, эше булган. Шагыйрь хәсрәтенең сәбәбе нәрсәдә? Җавапны шигырьләреннән эзлик.

---

[1] *Мәләкләр* — фәрештәләр.

* * *

Күңел һәр җирдә гөл эзли,
Къәдәр[1] һәр җирдә тикән[2] төзли...

Бу икеюллык тәмамланмаган шигырьгә охшаган. Дәрдемәнд аны үзе дә күп нокта белән бетерә. Кыска гына булуына да карамастан, бу шигырьдә күңел дөньясы белән чынбарлыкның каршылыкка килүе ярылып ята. Шигырьнең ике өлеше менә шуннан гыйбарәт. Матур гөл белән чәнечкеле тигәнәк бу каршылыкны тагын да көчәйтә төшәләр. Ләкин бу ике сурәт уйга калдыра. Күңел гөл эзли, тәкъдир тигәнәк чәнечкесен төзли, ди автор. Ләкин ул бит гөл белән тигәнәкне генә күз алдында тотмый.

Шигырьдә без күзалларга күнеккән чынбарлыкта ниндидер башка чынбарлык — тәкъдир, язмыш. Язмыш шулай чынбарлыкны алыштырырлык куәтле көчмени?

Шагыйрь бу сорауларны бирми. Күпнокта кую белән канәгатьләнә. Ләкин шул өч ноктасы белән ул укучысына: хөрмәтле укучым, үз күңелең һәм язмышың турында уйлан әле. Синең үз күңелең дә матурлык эзли бит. Ләкин гөл күрәм дип барган юлыңда әледән-әле тигәнәк утырган була, ди.

Кабатланып килгән «һәр җирдә» сүзләренә игътибар итик. Бу сүзләрнең дә мәгънәсе күп бит. Шуларның берсе: кеше күңеле хәтта тигәнәк чәчәген күреп тә сокланмакчы була. Һәркемнең үзе күрәсе килгән гөле бар. Ул әледән-әле чәнечкегә барып төртелә. Кеше гомере буена өмете белән чынлык каршылыгында яши.

Күп нокта әйтә: бу ике юл тормыш турындагы уйлануларымның гомуми нәтиҗәсе генә, ди. Өмет белән язмыш каршылыгын һәркем үзенчә кичерә. Мин дә үземчә кичерәм. Минем кичерешләрем башкаларныкына охшамаска да мөмкин, ләкин охшарга да мөмкин. Тормыш тудырган бу каршылык миңа ничек тәэсир итә — анысын башка шигырьләремне укып белә аласыз, ди.

* * *

Гариб моң[3] бар өнендә[4] җил-җиләснең —
Туган илләрдән искән җил димәссең.

---

[1] *Къәдәр* — язмыш, тәкъдир.
[2] *Тикән* — чәнечке, тигәнәк.
[3] *Гариб моң* — чит-ят моң.
[4] *Өнендә* — тавышында.

Бу икеюллыкта Дәрдемәнд туган иленә мәхәббәте турында берни дә әйтми. Ләкин укучы бик тиз абайлап алырга тиеш: туган як җиленең тавышын илен бик нык ярата торган кеше генә таный ала. Алай да шигырьнең төп эчтәлеге мәхәббәт түгел. Дәрдемәнд үз итеп яратып әйткән җил-җиләстә ят моң сиземләп ала. Туган илгә килеп җиткән бу ят моң аны шомландыра. Автор бу ят моңда әлегә үзе дә белеп бетерми торган ниндидер күңелсезлек килүен тоя.

Шомлану — бу шигырьнең хис дәрәҗәсе. Ә менә сәбәбе — моңа кадәр безгә очрамаган сиземләү, тою. Туган илгә ниндидер күңелсезлек килүен тою. Авторның сиземләве әлегә үзенә дә анык түгел. Ул әле аның аңы белән анықланмаган. Ләкин шагыйрь күңеле өчен сиземләү, тою да шомлану өчен сәбәп була.

«Күңел һәр җирдә гөл эзли» икеюллыгын искә төшерик. Аның эчтәлеген «Гариб моң бар» икеюллыгы эчтәлегенә салып карыйк.

«Гариб моң бар» шигырендә дә автор күңеле матурлык эзли.

Матурлык — туган илнең тыныч яшәве. Әмма ил кадәр ил дә язмышына буйсына. Шагыйрь аның чәнечкеләрен шул тавышыннан ишетә.

* * *

Исәрме җил тугай буйлап,
Җыларммы кыз моңын сөйләп,
Көләрме шатланып, көйләп,—
Агач, таш эчләре шаңрап[1],
Киләдер бер нида[2] яңрап!..

Биремнәр

1. Шигырьнең хис-эчтәлеген әйтегез.

2. Шул хиснең сәбәбен күрсәтегез.

3. Баштагы өч юлның эчтәлеген башка сүзләр белән сөйләгез. Бу юллар эчтәлеген соңгы ике юл эчтәлеге белән бәйләгез.

4. «Исәрме җил тугай буйлап...» шигырен «Гариб моң бар» шигыре белән чагыштырыгыз. Аларның уртак төзелешен һәм эчтәлеген табыгыз.

5. Бу ике шигырь эчтәлегендәге аерманы күрсәтегез.

6. «Исәрме җил тугай буйлап...» һәм «Күңел һәр җирдә гөл эзли» шигырьләре арасындагы бәйләнешне табыгыз.

---

[1] *Шаңрап* — шаңгырап.
[2] *Нида* — зар, ыңгырашу.

* * *

Ятам кай чаклары моңлап,
Һаваның тынлыгын тыңлап;
Килә өнләр, колак чыңлап
Диямен:
— «Ни бу? Нидәндер бу?»
Җавап урынында — гөрли су,
Тирәклек тирбәнә, шаулый!..

* * *

Түкте кояш нурларын алтын-сары,
Тауларның бетте эреп салкын кары.
Күтәрелде күк йөзенә сабан тургай,
Ишетелде чырлап түккән моңлы зары.

* * *

Булырмы яз, исеп җилләр,
Килерме җәй, ачып гөлләр;
Җитәрме кыш, кичеп еллар,—
Диярменсез, газиз илләр.

* * *

Болыт үтте, гөмберли күк еракларда.
Сил[1] шаулый, сулар гөрли болакларда[2],
Тавышы — колакларда...
озакларда...

* * *

Гомерләрдер... Өелмәктә сагышлар...
Дәвам итмәктәдер шиддәтле[3] кышлар...
Һавалар тын... Кыеп очкан һома[4] юк...
Азан иштелсә дә, кыйбла-нөма[5] юк!..

Сораулар һәм биремнәр

1. «Ятам кай чаклары моңлап...» әсәрен алдагы дәресләрдә өйрәнгән башка шигырьләр белән чагыштырыгыз. Бу әсәр аларга кайсы ягы белән охшаган? Нәрсәне ачыклап килә?

---

[1] *Сил* — хәтәр ташкын.
[2] *Болакларда* — инешләрдә.
[3] *Шиддәтле* — бәла-казалы.
[4] *Һома* — бәхет кошы.
[5] *Нөма* — компас.

2. Соңгы юл ни өчендер рифмалашмаган. Ни өчен?

3. «Түкте кояш нурларын алтын-сары...» шигырендә дә теләк белән язмыш каршылыгы бармы?

4. Шундый матур җәйге көндә тургай ни өчен моңлана, зарлана?

5. «Булырмы яз исеп җилләр...» шигырендә язның, җәйнең, кышның башка мәгънәләре дә бар. Әсәрдән башка мәгънәләр булган урынны табыгыз.

6. Бу шигырьне дә авторның башка әсәрләре белән чагыштырыгыз. Уртак ягын һәм аермасын табыгыз.

7. «Болыт үтте...» шигырендә автор язмыш тигәнәге турында сөйлиме?

8. Ни өчен автор бу шигырьнең соңгы сүзен аерып куйган?

9. «Гомерләрдер... Өелмәктә сагышлар...» шигыре алдагы әсәрләр эчтәлегенә нәрсә өсти?

КОРАБ

* * *

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөрәдер:
Юл бара ят ил карап...

* * *

Чыкты җилләр,
Купты тулкын —
Ил корабын җил сөрә!..
Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне җан сорап?!

Биремнәр

1. Шигырьне күңелдән ятлагыз.

2. Темасын әйтегез.

3. Автор хисе турында сөйләгез.

4. Күп нокталарның мәгънәләрен аңлатыгыз.

5. «Кораб»ны Дәрдемәнднең башка шигырьләре белән чагыштырыгыз. Уртак ягы һәм аермасы турында сөйләгез.

* * *

Җәй үтте...
Кар-яңгырлы көз урнашты,
Күк тургайның баурына боз урнашты.
Гөл кипте,
Сабагында кинә[1] калды.
Былбыл!
Сиңа бер бөртек инә калды.

Шигырьгә анализ

«Җәй үтте...» шигырендә дә шул ук тема кабатлана. Шуңа күрә аны моңа кадәр өйрәнгән әсәрләр белән чагыштырыйк.

Бу әсәрдә дә таныш образлар белән очрашабыз. Монда да җәй, салкын кыш, гөл, чәнечке бар. Монда да җәй үтеп кыш җитүе язмышның котылгысызлыгын күрсәтә дип әйтә алабыз. Ләкин моңа кадәр өйрәнгән шигырьләрдән аермалы буларак, «Җәй үтте...» әсәрендә билгесезлек тудырган шомлану юк, чөнки билгесезлек үзе юк. Тугай язмышын — кыш, гөл язмышын тугай хәл итә.

Шигырьдә язмышы болар белән бәйләнгән былбыл да бар. Былбыл язмышы — гөл инәсендә.

Язмышлар бәйләнешеннән чыгып, автор фикерен табыйк.

1. Язмыш үз корбанының бәхетсезлегенә битараф. Ул берәүдән дә үч алмый. Бернәрсәгә дә усаллык теләми. 2. Язмышлар бер-берсе белән күренмәслек, сизелмәслек җепләр белән бәйләнгәннәр. Кыш тугайны бозга катыра, тугай гөлне киптерә. Гөл былбылга куркыныч тудыра.

Бу шигырь — тулысы белән метафора. Шуңа күрә шигырь эчтәлеге образларның мәгънәсе табылгач кына ачыклана. Табигать күренешен кешеләр мөнәсәбәтенә күчерик. Көз — табигатьнең кабатланып килүче афәте. Көз бөтен табигатьне үзгәртә. Шуңа күрә аның мәгънәсе — аерым бер кеше бәхетсезлеге генә түгел җәмгыятькә килгән зур бәхетсезлек. Көз — тургайны, тургай гөлне туңдырган кебек, әйтик, революция кебек, сугыш кебек җәмгыять бәхетсезлеге дә күпләргә табигый рәвештә кагыла. Күпләрне бәхетсез итә. Һәм бу бәхетсезлектән берничек тә котылып булмый. Көздән былбыл кача ала. Көз аңа бернинди дә зыян ясамый. Ләкин былбылның нәкъ

[1] *Кинә* — үч.

менә шул өстенлеге башкаларның ачуын китерә. Бер гаепсез былбылдан үч алган кебек, кешеләр дә үзләренә охшамаган кешеләрдән үч алалар.

Дөнья агышы, кеше язмышы турында шул рәвешле гомуми итеп фикерләүгә фәлсәфи фикерләү диләр. Димәк, «Җәй үтте...» шигыренең эчтәлеге фәлсәфи фикерләүдән гыйбарәт.

Ләкин бу шигырьдә кыштан, тугайдан, гөлдән, былбылдан башка автор үзе дә бар бит әле. Автор дөньяның язмыш ирегенә буйсынып яшәвенә борчыла, чөнки ул үзенең дә былбыл хәлендә калуын күз алдына китерә. Димәк, бу шигырь эчтәлегендә авторның борчу хисе дә бар, ә ул хиснең сәбәбе (ягъни эчтәлеге) — әдипнең язмыш турындагы уйланулары, дия алабыз.

ТАЛ ЧЫБЫК

(Ислах[1] сораган шәкертләргә тартамын)

Ничөн суга сузыласың,
   Тал чыбыккай, интегеп;
Ялварасың, борыласың,
Тилмерәсең, өзеләсең,
   Аккан суга күз тегеп.

Япраккайларың кылтырый...
   Эчеп канасың[2] килә!..
Йөгерә-кача су чылтырый,
Кояш нурында җылтырый —
   Һәм кача ул, һәм көлә!

Биремнәр һәм сораулар

1. «Тал чыбык» шигырендә язмыш темасы бармы?

2. Тал чыбыкны метафора дип исәпләгез һәм бу образның сыйфатларын шәкертләргә күчерегез. Шул юл белән авторның шәкертләргә биргән бәясен табыгыз.

3. Тал чыбыкны шәкертләргә автор үзе охшаткан. Ләкин автор аңа башка мәгънә дә салмаганмы?

4. Авторның хисен әйтеп бирегез һәм хис сәбәпләре турында сөйләгез.

---

[1] *Ислах* — реформа, үзгәртү.
[2] *Эчеп канасың* — эчеп юанасың.

* * *

Кил, и башчы[1]! Агачны юнма юкка,
Кирәк булмас — угыңны як, кил, утка.
Агарды чәч,
Куарды[2] баш,
Сары юллар сызылды.
Өмидләр, кем...
Өмидләр, кем...
Дәригъ[3], бер-бер өзелде!..

* * *

Куанды ил, канат какты мәләкләр,
Шашып, аң-таң булып, шайтан төкерде!..
Җитәр, җилкенмә, йолкынма, күңел, син,
Кияү булсаң да, ул туйга түгел син!
Җиһан тормыш туен иткән чагында,
Синең урның — үлекләр аймагында[4].

БҮЗЛӘРЕМ МАНА АЛМАДЫМ

Гәрчә мин дә бар саналдым,
Ил катар[5] сан алмадым;
Илдә йөрдем, хазлар[6] алдым,
Уйласам — сан алмадым.
Янды Мәҗнүн, янды Фәрһад,—
Бер янып ат алдылар[7].
Мин, гариб, мең кат янып та,
Яндыга саналмадым.
Уйлагыз: мәгъшука меңләр[8]!..
Мин гашыйк саналмадым!
Кемгә васләт[9], кемгә өмид
Нигъмәтен бирде фәләк[10],

---

[1] *Башчы* — әйдәп баручы. Җитәкче. Башлык.
[2] *Куарды* — куырылды.
[3] *Дәригъ* — ни кызганыч.
[4] *Аймагында* — янында.
[5] *Ил катар* — ил буйлап.
[6] *Хазлар* — өлешләр.
[7] *Ат алдылар* — исем алдылар.
[8] *Мәгъшука меңләр* — меңнәрчә гашыйклар.
[9] *Васләт* — кавышу.
[10] *Фәләк* — язмыш, тәкъдир.

Мин өмиднең сул кулындан
Бер сынык нан[1] алмадым.
    Кемгә васләт, кемгә өмид!..
    Мин сынык нан алмадым!
Әйттеләр, кем, бер бәхетсез
Илгә гашыйксың, фәкыйрь.
Бер кызардым, бер бузардым[2]...
Ни таныйм — таналмадым.
    Ни таныйм?.. Таналмадым!
Сезне, милләт кызлары, аh!
И өмид йолдызлары!
Таң-сәхәрләр эзләп-эзләп,
Бер күреп каналмадым.
    И өмид йолдызлары!..
Бер күреп каналмадым!
Исте җилләр ил эченнән,
Иртә-кич салдым колак.
Җил-җиләсләрнең моңыннан
Зәүкы әлхан[3] алмадым.
Кайда бер тау, кайда мәэмүл
Чишмәи абелхәят[4]!
Тез йөгендем, яшь тамыздым,—
Дәрткә дәрман алмадым.
    ...Дәрткә дәрман алмадым!
Биэре милләт, мази зәмзәм[5]
Күзләдем еллар буе.
Җитте дәфнем[6] вакыты,
Кәфнем бүзләрен маналмадым!..
    Вәйля[7]!..
Дәри-и-и-гъ!
Бүзләрем мана алмадым!..

---

[1] *Нан* — икмәк.

[2] *Бузардым* — агардым.

[3] *Зәүкы әлхан* — көй ләззәте.

[4] *Мәэмүл чишмәи абелхәят* — булыр дип фараз ителгән мәңгелек чишмә.

[5] *Биэре милләт, мази зәмзәм* — милләт коесы, зәмзәм суы.

[6] *Җитте дәфнем* — җирләү вакытым җитте.

[7] *Вәйля* — ни үкенеч.

Сораулар һәм биремнәр

1. «Кил, и башчы! Агачны юнма юкка...» шигырендәге алдагы ике юл калганнары белән бәйләнешкә ничек керә?

2. Шигырьдә язмыш турында әйтелгән урыннарны күрсәтегез.

3. «Кил, и башчы! Агачны юнма юкка...» шигыренең Дәрдемәнд иҗат иткән башка шигырьләрдән аермасын күрсәтегез.

4. «Куанды ил, канат какты мәләкләр...» әсәрен «Кил, и башчы! Агачны юнма юкка...» шигыре белән чагыштырыгыз һәм эчтәлекләрендәге уртаклыкны күрсәтегез.

5. «Куанды ил, канат какты мәләкләр...» шигыренең соңгы юлында сүз үлем турында бара. Бу юл эчтәлегенең тагын бер мәгънәсен әйтегез.

6. Дәрдемәнднең бик күп шигырьләре кебек, «Куанды ил, канат какты мәләкләр...» шигыренең дә язылу вакыты билгесез. «Куанган ил», «җиһанның тормыш туе» дигәндә, әдип нәрсәне күз алдында тотарга мөмкин?

7. Бу әсәрдә автор хисләрен белдерүче интонацияне күрсәтегез.

8. «Бүзләрем мана алмадым» шигырендә автор күңеле эзләгән гөлне һәм язмыш чәнечкесен табыгыз.

9. «Бүзләрем мана алмадым» шигыренең эчтәлеге Дәрдемәнднең нинди шигырьләре эчтәлегенә якын?

10. «Бүзләрем мана алмадым» шигырен үзегезнең җөмләләр белән чәчмә әсәр итеп языгыз.

11. Чәчмә әсәр итеп язылгач, шигырьнең нинди урыннары төшеп калды, күрсәтегез.

12. Чәчмә вариантында шигырь эчтәлегенә зыян килдеме?

Нәтиҗә ясыйк.

Дәрдемәнднең сезгә таныш шигырьләрен ике өлешкә бүлеп була.

Бер төркем әсәрләрендә әдип үзенең даими рухи халәте белән таныштыра. Бу әсәрләрдән күренгәнчә, вакыт агышы, тарих, табигатьтәге үзгәрешләр, милләт, кеше турындагы уйланулары һәм илдәге тынычсызлыклар шагыйрьне сискәндерәләр, тынычсызландыралар, шомландыралар. Шагыйрь уйлана һәм әлеге күренешләрнең уртак сыйфатын абайлап ала. Бөтен галәм үзенең иртәгесе өчен борчылып яши дигән нәтиҗәгә килә. Тарих та, табигать тә, кешелек тә, милләт тә, аерым кеше дә алдагы көне өчен борчыла. Һәр ят нәрсә, үзгәреш аларга күңелсезлек китерер кебек тоела.

Шагыйрьнең бу сиземләве үзенә дә тынычлык бирми. Ул галәм өчен дә, табигать, кешелек, милләт, гөлләр, кечкенә генә

былбыл өчен дә борчыла. Чөнки гөлләр дә, былбыл да — табигать матурлыгы, тынычлык.

Дәрдемәнднең бер төркем шигырьләре эчтәлеген алдагы көн билгесезлеген тою һәм шуңа борчылу тәшкил итә.

«Җәй үтте...», «Тал чыбык», «Кил, и башчы! Агачны юнма юкка...», «Куанды ил, канат какты мәләкләр...», «Бүзләрем мана алмадым» шигырьләрендә шомландырып торган билгесезлекнең сере ачыла. Җил тавышларына кушылып, агачлар, ташлар тынычлыгын бозып, тугайларны, былбылларны, гөлләрне куркытып килгән билгесезлек һәр нәрсәне үзенә буйсындыра торган котылгысыз язмыш икән.

Картлык, илдәге күңел кабул итми торган үзгәрешләр, ирексезлек, көчсезлек — һәр нәрсәне үзгәртә торган язмышның (бу урында ул — вакыт) төрләре генә.

Икенче төркемдәге шигырьләрдә авторның хисе хәсрәткә әйләнә. Монда Дәрдемәнд билгесезлекне күрсәтүче күп ноктaларын хис дәрәҗәсен белдереп килүче паузаларга алыштыра. Интонация үзгәрә. Икенче төркемгә кергән әсәрләрдә хис сәбәбе сиземләү, тою түгел — күреп белү, уйлап нәтиҗә ясау рәвешендә конкретлаша.

Икенче төркем шигырьләре Дәрдемәнднең күңел төшенкелеге — пессимизмы турында сөйләмиләрме?

Сорауга җавапны әдипнең башка шигырьләреннән эзлик.

* * *

Бүген уйнап-көлүдән тыйма, зинһар.
Үләргә көн булыр — алда әҗәл бар!
Тыя күрмә — уен уйнар мәлендә,
Әҗәл эшләр эшен үз тәңгәлендә[1]!

* * *

Рәнеж хәтер[2] булганын илнең суыктан белде яз,
Кем, чәчеп нур, йөргезеп[3] җилләр шифалы, килде яз.

Кар эреп, кырлар ачылды, таудан исте хуш җиләс,
Тау вә сәхраларга яңа җан биреп сирпелде яз.

Кырны, тугайларны алды язгы сулар ташкыны,
Кем, чәчеп нурлар шифалы, йөргезеп җил, килде яз.

---

[1] *Үз тәңгәлендә* — үзе теләгәнчә.
[2] *Рәнеж хәтер* — рәнҗүле күңел.
[3] *Йөргезеп* — йөртеп.

* * *

Яз үтеп, көннәр бетеп, булды тәмам гомрем кышы,
Ела, и бичара Закир, кем, синеңчөн үлде яз.

ҮТКӘН КӨННӘР

Әй кая ул көн, ки бездә —
Шәп торулар бар иде;
Әмма дошманнарда гамьләр[1],
Эч пошулар бар иде.

Берзаман чыгар идек без
Кырга дуст-ишләр илә;
Анда уенлар, көлүләр,
Сикерүләр бар иде.

Һай, гомерләр... Үтте китте...
Кая китте ул заман!
Кайда ул шәп һае-һулар!
Гөфтегүләр[2] бар иде.

Бервакыт бунча рәхимсез
Дәгел иде кызлары;
Анда туташларда ымлар,
Күз кысулар бар иде.

Ничә еллар үтте, әмма
Күрмәдек кызлар йөзен!
Янымызда әүвәле
Кандай сылулар бар иде.

Шигырен күргәч Закирның,
Диде өлкәннәр дә: «Һай!
Яшь чагында бездә һәм
Андай йөрүләр бар иде!»

Сораулар һәм биремнәр

1. «Бүген...», «Рәнеж хәтер булганын илнең...», «Үткән көннәр»дә моңа кадәр Дәрдемәнд шигырьләрендә күренмәгән яңа эчтәлек бар. Шул яңа эчтәлек турында сөйләгез.

2. Бу әсәрләрдә язмыш һәм матурлык янәшә килә. Шуларның кайсына автор өстенлек бирә?

3. Габдулла Тукай да, Дәрдемәнд тә үткән көннәре турында язалар. Ләкин үткән көннәрен ике әдип ике төрле искә төшерәләр. Аерма нәрсәдә? Сөйләгез.

Юану шигырьләре

Дәрдемәнд язмыш чәнечкеләре турында күп яза. Аны билгесезлек тә, гомернең бик тиз үтүе дә даими рәвештә борчып тора. Әмма ул күңел төшенкелегенә бирелгән пессимист шагыйрь түгел. Әдипнең башка шигырьләре шул хакта сөйли.

Дәрдемәнд фикеренчә, күңел эзләгән гөлләр — тормыш матурлыгы: яз, җәй, яшьлек, мәхәббәт — бар да үтә. Әмма гөлләр бар һәм алар матурлар, шиңгән гөлләр урынына баш-

[1] *Гамьләр* — көнчелекләр.
[2] *Гөфтегүләр* — җыелып сөйләшү.

калары чәчәк ата, картайган буынны башка буын алыштыра, яшьләр мәхәббәтне яңарта тора. Шуларны күреп соклана белергә, яратып, шатланып калырга кирәк. Кеше күңеле һәр җирдә матурлыкка омтыла. Матурлыкка омтылу — үзе бер бәхет ул. Тормышның мәгънәсе шуннан гыйбарәт.

Дәрдемәнд шигырьләре — бөтен бер иҗат. Аларны бергә җыеп, үзара бәйләнешкә кертеп өйрәнгәндә генә аңларга була.

«Исә җилләр, күчә комлар... бетә эз... Кызганыч, моңлы күңел, без дә бетәрбез» дип яза әдип «Без» шигырендә. «Бүген уйнап көлүдән тыйма» шигырендә бала балачакта тормыштан уйнап-көлеп ямь табарга тиеш дип өсти.

Дәрдемәнд уенча, бәхетле булу өчен, һич тә тәкъдир чәнечкеләреннән куркып яшәргә ярамый. «Нәсихәт» шигырендә ул кешеләрне үз бәхетләре өчен көрәшергә чакыра:

Житәкләргә тырыш дөньяи дүнәнне[1],
Иконең берсе: йә сине җитәкләр.
Алып барыр үзеңне бер чокырга,
Барырсың — бардырыр, төртәр, этәкләр.

Үз бәхетең өчен көрәшү — ул гаделлек, игелек күрсәтү икән:

Килсә кулдан, шат кыйл һәр җанны,
Кем, ханлык булыр,
Тәхет кыйл[2] кырмысканың күңлен —
Сөләйманлык[3] булыр!

«Рәнеҗ хәтер булганын илнең...» әсәрендә шагыйрь кабат язмыш чәнечкеләре турында яза кебек: «Ела, бичара Закир, кем, синеңчөн үлде яз»,— ди. Әмма шунда ук җирнең яңаруын, яз килүен мактап яза. Бер кешенең картаюы ул әле матурлык бетте дигән сүз түгел. Матурлык дәвам итә — яз килә.

«Үткән көннәр» шигырендә әдип яшьлеген сагына. Матур, күңелле чаклары үтүгә көрсенә. Ләкин шул ук шигырендә лирик геройның тышка бәреп чыккан шатлыгын да күрәбез. Яшьлекнең күңел хәзинәсендә сакланган бер дә шиңмәс матур гөл булуын әйтә. «Кичә күр, иркәм» әсәрендә күңел хәтеренең иң ышанычлы юану булуын ачыктан-ачык белдерә:

---

[1] *Дөньяи дүнән* — дөнья дигән ат.
[2] *Тәхет кыйл* — күңелен тап.
[3] *Сөләйманлык* — изгелек.

Әмма шул көннәрне, кем, булган иде,
Гыйшык илә моңлы күңел тулган иде,
Уйнашыр, уйнар идек без мәңге шат,—
Шул заманнарны онытма — әйдә яд[1]!

Күңел үз гөлен һәр җирдә эзли һәм таба. Табигатьтә дә, милләт эченнән дә, мәхәббәттә дә, яшьлектә дә... дуслыкта да. Дуслык матурлыгына Дәрдемәнд аерым шигырь багышлый:

Ни гамь — бөлсәм? Әгәр үлсәм — ни ваем?
Эчеп, дустлык шәрабеннән исерсәм;
Булып дустлар белән берлектә даим[2],
Гомернең тиз үтәр язын кичерсәм.

Ә матурлыкны эзләгән, табып, аңа соклана белгән кешеләр язмыш кодрәтенә буйсынмыйлар. Бу фикерен Дәрдемәнд ике генә юллык шигырендә язып калдырган:

Энҗе-алмаслар югалмас
Һәм ятып калмас — үтәр,—

дигән.

Йомгак

Бериш шигырьләрендә Дәрдемәнд бөтен дөнья язмышы өчен борчыла. Рәхимсез вакыт язларны, җәйләрне салкын кышка әйләндерә. Дәүләтләрне, буыннарны җиргә күмә. Язлар, җәйләр кабат әйләнеп кайта, яңа буыннар алдагыларын алыштыра. Әмма үткән язлар, күмелгән буыннар эзсез югалалар. Бөтен дөнья язмышының фаҗигасе шуннан гыйбарәт.

Дәрдемәнд галәм кешесе булып фикерли һәм шомлана. Әдип татар милләтенең киләчәген дә язмышның гомуми кануннарына буйсындыра. Шагыйрьне татар милләтенең, идарәсен югалткан кораб кебек, җил куган билгесез якка йөзүе борчый.

Милләт язмышы белән әдип үз язмышын да бәйли. Артта калган хәерче милләтен яратуын үзенең иң зур бәхете һәм шул ук вакытта бәхетсезлеге дип исәпли. Милләтне Дәрдемәнд туган иле, туган халкы булганга ярата. Аның матур гөлгә әйләнүе өчен, гомере буе көрәшүенә куана. Яшәүнең төп мәгънәсен шунда күрә. Әмма бу көрәшнең нәтиҗәсезлеге әдипне бәхетсез итә.

---

[1] *Яд* — хәтеремдә тот.
[2] *Даим* — һәрвакыт.

Бу очракта Дәрдемәнд җирнең гади бер кешесе булып фикер йөртә һәм хәсрәтләнә.

Әдип, шул рәвешле, бөтен дөньяны язмышлар аша бербөтенгә җыеп күрә. Язмышның дәһшәтле көче — Вакыт. Вакыт тарихны да, табигатьне дә, милләтне дә, кешеләрне дә үзе теләгән якка куып йөртә һәм соңгы ярга китереп ташлый.

Чынбарлык вакыйгаларына әдип үзе төзегән шул фәлсәфи дөньясыннан көймәсен ярдан суга этеп керткән кебек йөзеп керә. Күңел эзләгән гөлне ул шунда күрә. Матурлык кешенең яшәешендә, ди. Кешеләргә яшәү, сөю, шатлану өчен вакыт бирелгән. Күңел эзләгән гөлләр шул вакыт арасындагы яшәештә. Бу арада кеше яз язмышын үз кулына алырга тиеш. Кеше тормышының мәгънәсен — матурлыгын — әдип кешеләрнең матурлыкка омтылуында, гүзәллекне таба һәм тудыра белүендә күрә.

Дәрдемәнд шигырьләренең фәлсәфәсе шуннан гыйбарәт.

Һәр җирдә сагалап торган язмыш чәнечкеләре шагыйрь күңелен өзлексез шомландырып тора. Шул сәбәпле гөлләр-язмышлар фәлсәфәсе шигырьләрдәге хиснең сәбәбенә әйләнә, дидек. Әдип тормышның гомуми агышын һәм көндәлек матурлыгын, шулай итеп, хисләре аша күрә. Шуның өчен Дәрдемәнд шигырьләрен лирик шигырьләр дибез.

Дәрдемәнд шигырьләре үзара шулкадәр тыгыз бәйләнгәннәр ки, аларның кайберен гадәтләнгәнчә өчкә бүлү дә кыен.

Шигырьләрнең беришендә сәбәп булса, башкаларында хис дәрәҗәсен һәм юануны очратабыз.

Дәрдемәнд иҗатын өйрәнү сезгә әдәбият белән чынбарлыкның катлаулы мөнәсәбәтен тоярга ярдәм итте. Хәзер бу мөнәсәбәтне ачыклап китик.

Чынбарлык дип андагы кешеләрнең яшәү шартларына әйтәләр.

Чынбарлык — кешеләр бәясеннән арынган тормыш ул.

Язучы чынбарлыкны ничек бар шулай чагылдырмый. Шулай итсә, ул сөйләп чыккан язманың темасы да, проблемасы да, идеясе дә, стиле дә булмас иде.

Әдәби әсәр чынбарлыктагы чиксез мәйданны бик нык тарайта, тәмамланмаган вакыйгаларны тәмамлый. Аларны авторның һәм әсәрендә автор сурәтләгән персонажларның бәяләре, кичерешләре белән тулыландыра.

Галиәсгар Камал

БАНКРОТ

Пьеса өч пәрдәдә

КАТНАШУЧЫЛАР:

Сираҗетдин Туктагаев — тыштан бик изге күренә торган сәүдәгәр.
Гөлҗиһан — Сираҗетдинның хатыны.
Җамалетдин Туктагаев — } Сираҗетдинның бертуган
Камалетдин Туктагаев — } кардәшләре.
Хәдичә — Сираҗетдиннарга белеш тол хатын.
Нәгыймә — им-том итеп йөри торган карчык.
«Туганым» — Гөлҗиһанның карендәш тиешле кешесе.
Гарифә — } кунаклар.
Мәликә — }
Мөхәммәтҗан 1 нче — } кибетчеләр.
Закир — }
Мөхәммәтҗан 2 нче — кибетче малай.
Гарәфи — Сираҗетдинның юлдашы.
Хәмди — }
Мәрфуга — } асраулар.
Гайниҗамал — }
Доктор һәм Мәскәү доверенныйлары.

Вакыйга Казанда.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сираҗетдин Туктагаевның йорты. Яхшы итеп җыештырылган, бай сымак бер өй. Сул якта — кантор өстәле, аның янында — бер шкаф, уң тарафта — диван, өстәл, креслолар. Стена буенда —урындыклар, көзгеләр, ике тарафта һәм түрдә — ишекләр, ике як янда — тәрәзәләр. Пәрдә ачылганда, сәхнәдә бер кеше дә юк.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Сираҗетдин ялгыз.

Сираҗетдин *(ишектән бик кызуланып кереп, як-ягына каранып).* Бик яхшы булды әле, бер кеше дә юк икән. *(Өстеннән намаз тунын салып ташлап.)* Бер дә шаулама, эшләрнең һәммәсе дә минем файдага баралар әле. *(Кесәсеннән бер газета чыгарып.)* Менә бүген дә бик шәп хәбәрләр язганнар әле. *(Укый.)* «Астраханьнан менеп килә торган «Кавказ-Меркурий» пароходының беренче классында килә торган юлчы — Тарабаров исемле бер бай — өстенә-башына бик яхшы киенгән бер кеше белән белешләнгән. Кич белән чәй эчкән вакытта теге кеше Тарабаровның стаканына йоклата торган дару салып эчерткән. Тарабаровның һушы китеп егылгач, янында алып бара торган унбиш мең сум акчасын алып, бер пристаньда төшеп калган». Шәп иткән бит, ә, Тарабаров йоклаган диген, ә? Бигрәк аңгыра нәрсә икән. Хәзерге заманда шулкадәр күп акчаны үзең белән бергә юлга алып чыгарга ярыймы соң? Кладавайга бикләп киткән булса, бер дә югалмас иде. Ну, ярый, бик шәп булды әле, бу да бик шәп. Үземезчә гәзитләр чыкмаса, мин әле ул фикерне кайдан уйлап чыгара алыр идем? *(Газетаны шкаф астына куя да, аннан бер кочак газета чыгарып.)* Менә алар монда никадәр! Боларның һәммәсендә дә шундый хәбәрләр тулып ята. Мин аларның монда талаучылары бер дә тотылмаганнарын гына сайлап җыеп куйдым. Мине талыйсылары да юк, һәм минем үз янымда акча йөртәсем дә юк. *(Газеталарны тыгып куеп.)* Сез миңа никадәр зур гакыл бирдегез. Коры көе генә, кеше өстендә алачакларым бик күп китте-фәлән дип кенә шартлап булмый. Алай итеп кенә мәскәүләргә сумына ун-унбиш тиен генә биреп булмый. Аның мудасы да беткән. Ә менә болай булганда үзләренең дә күзләре акаер. Биргәнне тизрәк алып калырга тырышырлар. *(Шкаф астыннан бер кечкенә саквояжны чыгарып һәм аңа берничә төргәк кәгазьләрне салып.)* Барыгыз әле, сез шунда ятып торыгыз. Сезнең һәрберегез

бишәр йөз сумнан — барысы 49 мең тәңкә акча, ди. Озакламый поездга төшәргә вакыт җитә. Сиңа әйтәм, сиңа әйтәм! Кая син, бире кил әле!

ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Сиражетдин, Гөлҗиһан.

Гөлҗиһан *(ишектән кереп)*. Ай Алла, син кайткансың да икән.

Сиражетдин. Мин хәзер банкыга барам, аннан акча алып кайтам, поездга төшәр вакыт җитә, син нәрсәләрне тизрәк хәзерләп куй.

Гөлҗиһан. Хәзерлә дип, мин әллә нәрсәләр хәзерләмим: юлга чәй, шикәр, ике алма бәлеше, бер табак сумса, бер тавык гөбәдиясе, ике чебеш хәзерләдем. Өч пар күлмәк, ике сөлге, бер пар эскәтер, ике пар аяк чолгавы, өч тастымал куйдым. Шулар җитәр бит?

Сиражетдин. Ярар, җитәр. *(Өстенә киенә дә кечкенә саквояжны алып чыгып китә.)*

ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан ялгыз.

Гөлҗиһан. Әле онытмаска кирәк, бер-ике табын хатыннар уздырып алырга кирәк. Инде мәҗлес уздырмаганга да әллә никадәр булды.

ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, Хәдичә.

Гөлҗиһан. Әйдүк, Хәдичә абыстай, хуш киләсең!

Хәдичә. Исәнме, Гөлҗиһан, Сиражетдин Мәскәүгә бара икән ич. Әйтеп җибәрәсе йомышларым бар иде. Мәргыйбәнең кызы Фатыйманы кияүгә бирмәкче булабыз бит. Шуңа бер пар чиккән өстәл эскәтере, дүрт намазлык, берничә пар аяк чолгаулары кирәк буласы иде. Шуларны барган юлы Сиражетдин Мәскәүдән алып кайтып бирмәс микән дип килгән идем. Шуңа дип илле тәңкә акча да алып килгән идем.

Гөлҗиһан *(акчаны алып)*. Ярар, әйтермен, алып кайтыр.

Хәдичә. Зинһар инде, тыңлый күрсен! Ярый, хуш, сау бул! *(Чыгып китә.)*

БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан ялгыз.

Гөлҗиһан. Намазлык димәктән, үземнең дә хәтеремә килми тора икән әле, үзебез өчен дә чиккән постау эскәтерләр кирәк иде. Ишек чаршаулык яхшы плүш тә әйтермен дигән идем. Беркөннәрне Мәңгәр Йосыфларның ишек чаршауларын күреп исем китте. Алтынланган төсле, җылык-җылык итеп, ялтырап тора. *(Чыгып китә.)*

АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Сиражетдин ялгыз.

Сиражетдин *(ишектән кызуланып кайтып кереп, өстен чишенеп ташлый).* Һәммәсе дә мин теләгәнчә булды. Барысына да бишәр йөз сумлык акчалар алдым. «Андый акчалар ни эшкә кирәк соң алар?» — диләр. «Акчаны үзем белән алып барам, шуның өчен кирәк»,— дигән булам. Фидыр Иваныч әйтә: «Ай-һай, Сиражетдин Гыйлаҗетдинович, хата кыласың икән. Хәзерге заманнарда акчаны үзең белән йөртү апасны бит, пирават белән генә кирәк иде»,— ди. «Ничава дим, Алла кушмаган эш булмас»,— дим. Миңа нигә куркырга? Аны кладавайдагы тимер сандыктан кем килеп урлый ала? *(Саквояжны шкафка куеп.)* Әйдәгез әле сез, акчалар, мин кайтканчы кладавайда бик һәйбәтләп, тынычлап кына ятып торыгыз әле. Эшне төзәтергә, бәлки, сез артыгы белән җитеп торырсыз. *(Чыгып китә.)*

ҖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, Нәгыймә.

Нәгыймә. Сиражетдин бит ул минем балам шикелле кеше. Рәхмәт инде аңа, мине һичбер вакытта да хәтереннән чыгармый. Узган Мәскәүгә барганда да: «Мә, әби, Хуҗа Баһаветдин рухына багышлап дога кылырсың»,— дип, илле тиен садака биреп киткән иде. Безнең шикелле ятим карчыкларны зурлаган өчен, аны Алла үзе зурласын. *(Асрау керә.)*

Асрау. Абыстай, син ул чебешләрне кайсы кәрзинкәгә салырга дип әйткән идең?

Гөлҗиһан. Һи аңгыра нәрсәләр! Хәзер бит абзаң кайтыр вакыт җиткән. Үзең карамасаң, бер эшне дә җүнләп эшләүче кеше юк. Нәгыймә абыстай, мин, чыгып, шул нәрсәләрне генә рәтләп керим әле. *(Чыгып китә.)*

СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Нәгыймә ялгыз.

Нәгыймә. Әле мин белгәндә генә Сираҗи кышкы суыкта бер кат юка бишмәт белән калтырап туңып йөри торган бер кибетче малай иде. Аз арада гына нинди баеды да китте. Тукта әле, мин тагы бу якта утырып, авызымны ачып, юл садакасыннан колак кагып калмыйм. Сираҗи китеп-нитеп бармасын. Чыгыйм әле. *(Чыгып китә.)*

ТУГЫЗЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Сираҗетдин, Гөлҗиһан, соңра Нәгыймә.

Сираҗетдин *(ишектән кереп)*. Кара әле, сиңа әйтәм. *(Гөлҗиһан керә.)* Миңа бик яхшы таза аякчулар[1] китер әле. *(Гөлҗиһан чыгып китә.)* Эшне шулай итеп бик ныгытып пешереп эшләргә кирәк. Бер дә кеше шикләнерлек булмасын. *(Шкафтан саквояжны алып.)* Менә болар инде акчалар, ди. Аларны, югалмасын өчен, бик яхшылап балтырга чорнарга кирәк. *(Гөлҗиһан керә.)*

Гөлҗиһан. Менә аякчулар китердем. Бу аякчуларың да ак ич әле.

Сираҗетдин. Менә бу кәгазьләр акча булыр. Боларда кырык тугыз мең тәңкә, аңладыңмы?

Гөлҗиһан. И Ходаем! Кая әле! *(Бер төргәкне ачып карамакчы була.)*

Сираҗетдин. Чү-чү-чү! Тия күрмә! Мин аларны бик ыспайлап юка итеп төреп куйдым. Чуалтма. *(Төргәкле кәгазьләрне ала. Халыкка карап.)* Бөтенләй эшне боза язды. *(Гөлҗиһанга.)* Менә аларны шушылай итеп, бик һәйбәтләп читек балтырына батырабыз. *(Төргәкләрне икешәр-икешәр итеп, балтырларының ике ягына куеп, аякчу белән чорный башлый.)*

Гөлҗиһан. Ул кадәр күп акчаны читек балтырына гына кую, әллә ничек, бик куркынычлы шикелле тоела.

Сираҗетдин. Тәкъдирдә язылмаган булса, бернәрсә дә булмас. *(Киеп бетерә.)* Нихәл, бик җуан булмадымы? Тыштан бик беленеп тормыймы?

Гөлҗиһан. Юк, алай зарарлы түгел, бик беленми.

Сираҗетдин. Кая инде алайса, әйберләрне чыгарсын-

---

[1] *Аякчу* — чолгау.

нар. Пуездга төшәргә вакыт. Кара әле, син минем акчаны читек балтырына батырганны бер кешегә дә сөйли күрмә.

Гөлҗиһан. Алла үзе сакласын. *(Ишекне ачып.)* Кая, абзагызның багажларын чыгарыгыз!

Сиражетдин. Йә, әйдә, Аллага тапшырдым инде, дога кылыйк. Башка йомыш-юл юкмы инде?

Гөлҗиһан. Ә, онытып кала яздым. Бая Хәдичә абыстай килгән иде. Фатыйманы кияүгә бирмәкче булалар икән. Шуңа эскәтерләр, намазлыклар, тагы әллә нәрсәләр кирәк буласы икән. Илле тәңкә акча калдырып киткән. Менә язуы.

Сиражетдин *(халыкка карап)*. Ишкән икән! Мине чынлап та Мәскәүгә бара дип белә торганнардыр. Ярар, вакытым булса, алып кайтсам кайтырмын тагы.

Гөлҗиһан. Аннан соң шуны да әйтермен дигән идем. Барган көе шуннан бер-ике генә чиккән постау эскәтер белән ишек чаршавы өчен яхшы плүш алып кайтсаң, бик һәйбәт булыр иде. Гыймран хаҗи Газизәгә бик һәйбәт, бик киң алтын беләзекләр алып кайткан икән. Минем беләзекләрем күп; шунда бер барган көенчә яхшырак бер брушка да алып кайт!

Сиражетдин. Вакыт тисә, алып кайтырмын. *(Нәгыймә керә.)* Исәнме, Нәгыймә абыстай? Син монда идеңмени?

Нәгыймә. Әйе, улым, монда. Күрешеп калыйм дидем.

Сиражетдин *(кесәсеннән бер көмеш акча чыгарып биреп)*. Яхшы, Нәгыймә абыстай. Хәер-фатихада булыгыз инде.

Нәгыймә. Хуш, улым, хуш. Исән-сау йөреп кайт. *(Сиражетдин чыгып китә, Гөлҗиһан озата чыга.)*

Пәрдә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге зал. Ак эскәтерләр ябылган өстәлләр хәзерләнгән.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Нәгыймә ялгыз.

Нәгыймә *(ишектән чирекле шешә күтәреп кереп)*. Йөзе кара, бер дә күбекләнми. Мин кайнаткан тамырны бай хатыннары бик яраталар: «Синең кулың бик шифалы, эчеп җибәргәч тә, бөтен тамырларга китә, тәмам изелдереп йоклата»,— диләр. Трахтир сырасын күбрәк салсаң, аның өстенә актан да бераз тамызсаң, йоклату гына түгел, җырлатыр да ул.

ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан белән «Туганым».

Гөлҗиһан *(«Туганым» белән ишектән кереп).* «Туганым», зинһар инде син булыша күр. Шунда рәтләп, кунакларны карап утырта күр. Гарифә кодагый түбәнгә кала күрмәсен. Бик үпкәчән, бик гаепчән кеше. Аның бу ягына хаҗи хатыны Мәликәне утыртырсың. Икесе бергә килсәләр, бөтен шәһәрдәге кешене элеп алалар да селкеп салалар. Шуның өчен бер дә аларның теленә керәсем килми.

«Туганым». Ярар, ярар.

Гөлҗиһан. Әнимай Ибрае, Самавар Кәрим, Кылтын Гарәфи, Чатан Хафиз хатыны шикелле бер төрлерәк кешеләрне теге як табынга утыртырсың. Әллә кем түгел әле.

«Туганым». Фатыйма тудык кайда утырыр?

Гөлҗиһан. Мин аны чакырмадым. Теле бик озын.

ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, «Туганым».

«Туганым». Харап булдык! Оятлы булдык! Кунаклар килер вакыт җиткән, безнең аш артыннан утыртырга бламажи[1] да хәзерләнмәгән.

Гөлҗиһан. Ә, ни дисең? Ай Алла, туганым! Ул нинди сүз? Харап булдык! *(Чыгып китәләр. Зал бераз буш тора.)*

ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Хәмди ялгыз.

Хәмди. И билләһи, кызык соң тегендә. Абыстай тетә тегендә безне тиргәп. Аш артыннан утыртырга бламажи пешерелмәгән, ди. Аның өчен без гаеплемени? Йөрмәссең түшеңне киереп. Үзенең кулыннан бер эш килми, кешене тиргәгән була. *(Чыгып китә.)*

БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гарифә белән Мәликә.

Гарифә *(Мәликә белән ишектән кереп, түргә утырып).* Син ишеттеңме? Әллә нәрсә «бламажи» дигән сүзләрен генә ишетеп калдым. Йә бламажилары оемагандыр әле.

---

[1] *Бламажи* — сөт, какао, җиләк-җимеш, желатин кушып пешерә торган ашамлык.

Мәликә. Бламажилары дигәннән исемә төште, беркөннәрне мин чүпче Әхмәтләргә ашка барган идем, үрдәк бөккәннәре бер дә пешмәгән иде.

Гарифә. Андый була ул, беркөнне мин читекче Таҗиларга чәйгә барган идем. Кабарткан паштитлары менә нәкъ такта шикелле булган.

Мәликә. Читекче Таҗи дигәннән исемә төште әле, аларның бер шадра кызлары бар иде, ишеткәнең бармы, чибәр торалар микән?

Гарифә. Каенанасының сүзен бер дә тыңламый, диләр.

Мәликә. Каенанасының сүзен бер дә тыңламый, дигәннән исемә төште әле, син ишетмәдеңме, тегүче Әхмәдулла хатынын аерган дигәннәр иде, чын сүз микән?

Гарифә. Чын булырга кирәк. Кибеткә чыкканда күргән идем, кулына кәрзинкә күтәреп, бәрәңге алып йөридер иде.

Мәликә. Бәрәңге димәктән, безнең дә кәбестә тозлыйсы бар иде әле, алдырырга һич тә җитешә алганым юк. *(Чыгып китәләр.)*

АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Җамали, Гөлҗиһан, Камали.

Җамали *(ишектән кереп, әрле-бирле йөгергәләп, ишекләр саен барып)*. Килен! Килен!

Гөлҗиһан *(ишектән кереп)*. Нәрсә, абзый, ни бар?

Җамали. Сираҗетдин... Сираҗетдинны... Талаганнар!..

Гөлҗиһан *(урындыкка егылып)*. Аһ! Харап булдык! Читек балтыры!

Җамали. Әйе, әйе, читек балтыры... Менә телеграм... Сираҗетдинның читек балтырыннан акчасын алганнар!

Гөлҗиһан. Аһ!.. Кырык тугыз мең!

Җамали. Читек балтырында кырык тугыз меңме?

Гөлҗиһан. Үзем, үзем күрдем. Бишәр йөзлек иде.

Камали *(ишектән кереп)*. Абый, абый!

Җамали. Сираҗиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын талап алганнар, ди.

Камали. Кайда?

Җамали. Пуезда. Үзе... үзе... килен, акылдан шашкан, ди. Бүлнискә җибәргәннәр, ди.

Камали. Алай булгач, аны аннан алып кайтырга кирәк. Бүген үк китәргә кирәк. Әйдә, китик. Килен, хуш, сау бул. Без Сираҗины алып кайтабыз. *(Чыгалар.)*

ЖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, «Туганым», Хәмди, Нәгыймә, Гарифә һәм Мәликә.

Гөлҗиһан. Инде ни эшлим? Мәҗлес! Бламажи! Кунаклар! Хәмди! Мәрфуга! Гайниҗамал! Мөхәммәтҗан! Барыгыз, бар! *(«Туганым», Хәмди, Нәгыймә, Гарифә һәм Мәликә керәләр.)*

Һәммәсе бердән. Нихәл, ни булды? Нәрсә бар?

Гөлҗиһан. Барыгыз, бар! Йөгерегез. Кунакларга әйтегез! Килмәсеннәр! Мәҗлес бетте! Бөлдек, харап булдык! А, харап булдык, Сираҗиның читек балтырыннан кырык тугыз мең сум акчасын урлаганнар. Ух! Үләм! Бетәм! *(Егыла, Нәгыймәдән башкасы Гөлҗиһан янына җыелалар.)*

Пәрдә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук зал. Залда күп үзгәреш юк. Өстәлләр җыелган.

БЕРЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Җамали, Камали, Сираҗетдин һәм Гөлҗиһан. Җамали белән Камали Сираҗетдинны җитәкләп килеп керәләр.

Җамали. Менә шунда гына утыртыйк! *(Сираҗетдинны бер эскәмиягә утырталар. Сираҗетдин, дивана кеше төсле, тирә-ягына ялт-йолт карап утыра. Ишектән Гөлҗиһан килеп керә.)* Килен, мин сезгә ничә мәртәбә әйттем, Сираҗетдинны яхшы саклагыз, өйдән чыгып китмәсен дип. Ул бит үзен бер дә белешми. Әле менә хәзер, трамвай дип белеп, утын төягән вагоннар өстенә менеп утырган да киткән. Хәмидуллалар җитәкләп китерделәр.

Гөлҗиһан. Абзый, мин ни эшләтим соң инде аны, аны бит бер дә җиңеп булмый. Бәреп җибәрә дә чыга да китә.

Сираҗетдин *(урыныннан сикереп тора да почмакта өстәл өстендә торган граммофон янына барып бора башлый. Бер колагына кулын куеп)*. Палисә, палисейский! Палисейский! Каравыл! Талыйлар!

Камали. Чү, энем, чү, монда бер кеше дә юк, бер кеше дә!

Сираҗетдин *(читек балтырларын тотып карап)*. Таладылар, таладылар!

Җамали. Менә, агай, эш! Моны ни эшләтергә инде?



Камали. Самашушныйга менгерсәк ничек булыр икән? Төнлә белән ялангач көенә чыгып китеп, белешмичә әллә кайларга китеп, суга барып төшүе ихтимал.

Сираҗетдин *(халыкка таба карап, үзалдына).* Төшәр, төшәр, суга төшәргә мин җүләрмени? Болар инде мине чын-чыннан җүләр дип беләләр.

Җамали. Менә инде Мәскәү давиренныйлары гына килеп килешеп китсеннәр, аннан соң самашушныйга менгерсәк менгерербез.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Тотарсыз капчыгыгызны! Алар килеп киткәч, ничек йөрергә икәнлеген мин үзем дә бик яхшы белермен.

Камали. Алар соң әле ни диләр?

Җамали. Бернәрсә дә әйтмиләр, кибеттәге кенәгәләрне карадылар. «Сезнең бу кенәгәләрегезне чурт үзе килсә дә аңламас»,— диләр.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Аны шул алар төшенсен дип язмыйлар.

Камали. Соң тагы нәрсә диделәр?

Җамали. Бүген без аны барып карыйк әле, үзебез белән доктор да алып барырбыз, ул аның гакылдан шашканмы, юкмы икәнлеген карар, диделәр.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Ә менә монысы гына бераз күңелгә ятып бетмәде. Әгәр дә ул минем җүләр түгел икәнлекне

белсә, эш харап. Тукта әле. Алар килгәнче, җүләрлекне ныклап күрсәтергә өйрәнә торырга кирәк. *(Аякларын бөкләп, өстәл өстенә менеп утыра.)*

Җамали. Әйе, докторга күрсәтербез, ди. Әгәр дә доктор авыру дип әйтсә, бераз скитке ясап булса да килешербез, диләр. Кибеттәге малларны да бер кат карап чыктылар. Малы бик аз калган икән, диләр.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Бер дә хафаланмагыз, акча ерак түгел, кладавайда гына. Ачкычы менә монда, кесәдә генә.

Гөлҗиһан. Соң инде, абзый, без шулай бер тиенсез бөлеп калырбыз микәнни? И Ходаем! Бар икән күрәселәребез! *(Елый.)* Күңелле генә аш уздырам дип йөргәндә, бөтен эшләр чуалды да китте.

Камали. Килен, анысы бик зур эш түгел. Сираҗетдин терелсә, бар да булыр әле.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Эшне бетергәч, ничек фарсит итәргә кирәклеген Сираҗетдинның үзе дә бик яхшы белер әле. *(Өстәл өстеннән сикереп төшеп, кулына лампа алып, ишеккә таба бара башлый.)* Ахмак нәрсәләр, йөзе каралар, кладавай ишеген ачык калдырганнар. Талыйлар! Әнә йозагынватканнар! *(Ишектән чыгып китә. Аның белән бергә Җамали белән Камали да чыгып китәләр.)*

ИКЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан ялгыз.

Гөлҗиһан. И Раббым, и Раббым, тәмам харап булдык! Нинди генә матур иттереп аш уздырам дип торганда гына харап булдык. Итче дә бүген ит бирмичә керткән. Аласыз да аласыз, акча бирүне белмисез. Асрауларның да берсенә дә бер сүз әйтер хәл юк, хәзер үзеңнән дә битәр биш өлеш артык итеп кычкырырга торалар. *(Ишектән Нәгыймә карчык килеп керә.)*

ӨЧЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, Нәгыймә.

Нәгыймә. Исәнме, кызым Гөлҗиһан, исәнме? Исән-сау гына торасыңмы? Хафалана торгансыңдыр, ахры, ябыгып киткәнсең.

Гөлҗиһан. И Нәгыймә абыстай. Ничек итеп хафаланмаска кирәк? Ичмасам, акчасын алдырмый гына кайткан булса, тагын да бер хәл иде.

Нәгыймә. Әле менә беркөн теге, беләсең ич Хәмди Мәфтухасын, шуның Әсма атлы бер кызы бар. Шул кыз урамнан узып бара икән. Сираҗетдин шуның каршысына барган да: «Син кем кызы, бик матур кыз икәнсең, мин сине үземә кече хатынлыкка алам»,— дип, юлыннан туктаткан. Анасы тагын, җүләр нәрсә, шул сүзгә ышана калган: «Бай кеше бит, сораса, ни эшләп бирмәскә, бирәм»,— ди.

Гөлҗиһан. Сираҗины башларына чәйнәп яксыннар, җүләр белән тормасам миңа ир бетмәгән! Ачуымны китерсәләр, иртәгә үк аерылып китәрмен. Тәмам туеп беттем инде. *(Ишектән Җамали, Камали, Сираҗетдин, Закир һәм Мөхәммәтҗан килеп керәләр. Сираҗетдинны урындыкка утырталар.)*

ДҮРТЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан, Нәгыймә, Җамали, Камали, Сираҗетдин, Закир һәм Мөхәммәтҗан.

Җамали. Закир, Мөхәммәтҗан, сез шунда Сираҗетдинны яхшы гына каравыллап утырыгыз. Әйдә, Камали, без кибеткә төшик. Анда теге давиренныйлар безне көтеп тора торганнардыр. Аларны монда алып килербез. Гарәфигә дә әйтергә кирәк, ул да килсен, ул аның юлда ничек таланганын күргән кеше, бәлки файдасы тияр. *(Чыгып китәләр.)*

Гөлҗиһан. Әнә инде, Нәгыймә абыстай, аның хәле шул инде. Менә инде көне буе шуны саклап утыр. Әгәр гомер буе шул җүләрлегендә булса, аның белән ничек торырсың?

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Тормассың, тормассың бер дә. Тизрәк эшем генә бетсен, мин аннан ары сине типкәләп, ишегемнән чыгарып җибәрермен.

Нәгыймә. Ичмасам, байлыгы бар вакытта шулай булган булса бер хәл иде. Байлыгы бар дип чыдап торыр идең. Әле менә теге җүләр Йосыф хатыны акча белән калды да нинди чибәр яшь кешегә барды.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Күрәсезме, карчык нинди яхшы киңәшләр бирә! Калдырдылар, ди, сезгә акча, капчыгыгызны тотмыйсызмы?!

Закир *(үзалдына)*. Итәрсең аны җүләр, үз файдасына килгәндә ул бер дә җүләр түгел! Беркөнне миңа алмаштырырга дип егерме биш тәңкәлек акча биргән иде, шул вакытта мин, бераз батырып калыйм әле дип, бер өчлекне кесәгә яшергән идем, хәзер сизде. «Кая акча? Талыйлар!» — дип, каравыл кычкыра башлады.

Мөхәммәтҗан *(үзалдына)*. Акчасы булгач, баргандыр шул, акчасы булса, абыстайны алудан мин дә качмас идем. Мин дә бит бик чибәр егет. Абыстай карт кеше түгел, акчасы булгач, аның белән торырга мөмкин. Матур булмаса да, акчасы булгач, ярап торыр иде.

Гөлҗиһан. Нәгыймә абыстай, зинһар, акрынрак сөйли күр. Үзе ул дивана булса да, сөйләгән сүзне бик тиз ишетә. Әйдә теге якка чыгып, бераз сөйләшеп утырыйк. *(Чыгып китәләр.)*

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Минем бу җүләр булып кылануның бик күп файдасы булды, мине җүләр дип фараз кылып, һәммәсе дә үзләренең серләрен яшермичә сөйлиләр. Хатынның да, кибетчеләрнең дә, кучерларның да — һәммәсенең серләре мәгълүм булды. Тизрәк эшләрем генә бетсен, аннан ары мин сезнең барыгызны да ничек итеп өреп чыгарырга белермен. Инде теге мәскәүләр тиз килеп җитәрләр. Әгәр доктор чын-чыннан да җүләр дип шаһитлык бирсә, эшне озакка сузмаслар, тиз килешерләр. Докторы нинди кеше икән? Аңар бер биш йөзлекне сузмый туры килмәс. Эшнең башы шунда. *(Ишектән Мәскәү доверенныйлары керә башлыйлар.)* Уф! Килеп тә җиттеләр. Ничек тә булса серне сиздермәскә кирәк. *(Доверенныйлардан дүрт кеше, доктор, Җамали, Камали һәм Гарәфи килеп керәләр.)*

БИШЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Әүвәлгеләр, дүрт доверенный, доктор, Җамали, Гарәфи һәм Сираҗетдин.

Җамали *(доверенныйларга)*. Пажалти, пажалти, менә моннан утырыгыз.

Василий Дмитриевич. Тукта әле, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, әүвәле Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович белән күрешергә кирәк. *(Сираҗетдин янына килә.)* Здравствуйте, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович!

Сираҗетдин *(алдына гына карап утырган урыныннан сискәнеп, сикереп торып)*. Каравыл! Талыйлар! *(Ишеккә таба бара башлый.)*

Василий Дмитриевич *(куркып, артка чигенеп утыра)*. Кызганыч бичара, куркыныч.

Икенче доверенный. Бөтенләй төсләре дә үзгәргән.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Үзгәрерсең, уен түгел ул, кырык тугыз мең тәңкә диләр аны! *(Сикереп, өстәл өстенә менеп утыра.)*

Бер доверенный. Карагыз әле, тагы әллә ни эшли.

Камали. Юк, зарар юк, ул һаман шулай.

Доверенный. Ах, бичара.

Василий Дмитриевич. Ну, менә хәзер барыбыз да җыелган чак. Сез тагын бер сөйләгез әле, вакыйга ничек-ничек булган?

Җамали. Ул безгә сөйләнеп йөргән иде: «Мин фәләнчә көн Мәскәүгә барам»,— дип. Китте дә барды. Ул акчасын үз янында алып киткән икән, минем аннан да хәбәрем булмады. Соңыннан, «Сираҗетдин таланды» дип, менә Гарәфидән телеграм килгәч, киленнән ишеттем, «кырык тугыз мең» диде.

Василий Дмитриевич. Киленегез аны кайдан белгән? Үзе әйткәнме?

Җамали. Юк, үзе әйтмәгән. Ул чыгар алдыннан, аягын чишенеп, кәгазь акчаларын балтырына чорнап, аягын киенгән.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Анысы дөрес, кәгазьләрне балтырына чорнап киенгән.

Василий Дмитриевич. Киленегез мондамы? Аннан да сорап карасак, ничек булыр?

Җамали. Бар әле, Мөхәммәтҗан, абыстаңны монда чакыр, хәзер генә чыгып керсен әле. *(Гөлҗиһан керә.)*

АЛТЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Башкалар һәм Гөлҗиһан.

Василий Дмитриевич. Менә нәрсә, абыстай: сез Сираҗетдин Гыйлаҗетдиновның үзе белән акча алып киткәнен белдегезме?

Гөлҗиһан. Белдем.

Василий Дмитриевич. Ул аны кайсы кесәсенә салып алып китте?

Гөлҗиһан. Бер кесәсенә дә салмады. Иң әүвәл менә шушы төшкә утырды да аякларын чишенде. Аннан соң кырык тугыз мең тәңкә акчасын дүрткә бүлде дә, аякларының як-якларына, балтырларына куйды да киенде.

Василий Дмитриевич. Ул акчаларны ул кайдан алып чолгады?

Гөлҗиһан. Сумкадан алып чолгады.

Василий Дмитриевин. Ярый, абыстай, рәхмәт. Башка сорый торган сүз юк. *(Гөлҗиһан чыгып китә.)*

ЖИДЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһаннан башкалар.

Василий Дмитриевич. Гарәфи әфәнде, эшнең ничек булганын сөйләп бирегез әле...

Гарәфи. Без аның белән бер вакзалдан кузгалып киттек. Юлда бик яхшы бардык. Соңыннан Мәскәүгә барып җитәргә берничә станса калгач... Сираҗетдин: «Мин тышка чыгып керим әле»,— дип, тышка чыгып китте. Төн караңгы иде. Ул чыгып бераз торгач, поезд бер стансада туктады, аннан да кузгалып китте. Шуннан соң мин, тынычсызланып, Сираҗетдинны эзләргә чыктым. Бәдрәфне барып төртеп карадым, бәдрәф бикле иде. Бәдрәф янында бер-ике кеше көтеп торалар. Шул вакытта бер кандуктыр узып барадыр иде, аңа жалуба бирделәр. Кандуктыр: «Стансада торганда, икенче кандуктыр бикләп куйгандыр аны»,— дип ачып керде. Бервакытны ачып керсәк... ни күзебез белән күрик, Сираҗетдинның башыннан бүрек, кәләпүшләре төшкән. Аякларын салдырганнар.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Анысын үзем салдым.

Гарәфи. Казакиларын, камзулларын чишкәннәр...

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Аларын да үзем чиштем.

Гарәфи. Бернәрсә белмичә һушы китеп ята...

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Әйе, белмәмешкә салынып яттым.

Гарәфи. Моны күргәч тә минем йөрәкләрем «гөп!» итеп китте, кандуктыр да: «Кенәзне талаганнар!..» — диде.

Сираҗетдин *(сикереп торып)*. Каравыл! Тотыгыз! Тот! *(Ишеккә таба йөгерә. Сираҗетдинны барып тоталар.)* Каравыл! Талыйлар!

Җамали, Камали, Гарәфи һәм башкалар *(бер авыздан)*. Җибәрмәгез, җибәрмә! Сираҗи, Сираҗи, бернәрсә юк, утыр! Утыртыгыз! *(Урындыкка китереп утырталар.)*

Доверенныйлар. Доктор, доктор әфәнде, ярдәм итегез, карагыз. *(Доктор килә.)*

Доктор. Бераз гына торып хәл алсын әле, сез, зинһар, бераз читкәрәк китеп торыгыз, яңадан күзен ачып җибәреп сездән курыкмасын. *(Читкә китәләр. Доктор бераз торып.)* Менә инде хәзер тамырларын карап карыйк. *(Сираҗетдинның асылынып торган кулын кулына ала. Шул арада Сираҗетдин бик кечкенә итеп бөкләнгән биш йөзлекне докторның кулына кыстыра. Доктор, биш йөзлеккә күзен төшереп,*

үзалдына). Һа, алай икән, эш сизелде, бик шәп акылдан шашкан икән. Ярый, миңа барыбер. *(Кесәсеннән сәгать алган булып, биш йөзлекне кесәсенә тыга. Тамырын тотып бераз караганнан соң.)* Эш бу яктан бик өметле түгел, тамыр бик еш тибә. *(Күкрәкләрен тыңлый.)* Монда да хәл бик яхшы түгел. Йә әле, башкача тәҗрибә кылып карыйк. *(Кесәсеннән бернәрсә алып, кулларына, битләренә төртеп карап.)* Дөрес. *(Доверенныйларга әйләнеп карап.)* Әфәнделәр, гакылына бик зур хәләл килгән. Әгәр дә бик зур, хәтта гадәттән тыш бер вакыйга булып, шул вакыйганы күргәндә кинәттән гакылына килмәсә, дәва белән генә терелтергә зур өмит күренми. Мин сезгә бер дару язып бирермен. Шул даруны эчерткәч, ул тынычсызлануыннан бераз тукталыр.

СИГЕЗЕНЧЕ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһан һәм башкалар.

Гөлҗиһан *(ишектән елап кереп).* Доктор әфәнде, мин нихәл итәрмен, кая барырмын?

Доктор. Белмәссең, бәлки Ходадан вәгъдә җитсә, терелеп тә китәр.

Җамали. Хода безгә дә шулай ярдәм бирсә иде.

Василий Дмитриевич. Доктор әфәнде, алайса сез Сираҗетдин әфәнденең акылына зарар килү хак дисез?

Доктор. Аңа һичбер шик-шөбһә юк.

Василий Дмитриевич *(доверенныйларга карап).* Алай булгач, әфәнделәр, безгә эшкә керешергә вакыт. Сез ни дисез?

Доверенныйлар. Без дә шуны уйлап торадыр идек, без дә шул фаразда. *(Гөлҗиһан чыгып китә.)*

ТУГЫЗЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Гөлҗиһаннан башкалар.

Василий Дмитриевич. Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, доктор әфәнде әйтә, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович акылга килерлек түгел, ди. Шулай булгач, инде ул моннан соң сату итә алмас. Кибеттәге бар малын, йортларын сатарга кирәк тә, шуның белән бурычларын түләргә кирәк.

Сираҗетдин *(үзалдына).* Ай-яй, начар сүз әйтте.

Җамали *(аптырап китеп).* Ул ни дигән сүз? Ничә еллардан бирле бер тиен калдырмый түләп килгән фирманы шулай итеп тар-мар итмәкче буласызмы?

Василий Дмитриевич. Ә соң сез ни эшләмәкче буласыз?

Җамали. Менә сезнең белән килешсәк, агай-эне, икебездән беребезне апикун итеп куярбыз да, әүвәлчегә сату итә бирербез.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Менә монысы яхшы сүз.

Василий Дмитриевич. Соң сез күпме бирмәкче буласыз? Илле процент бирәсезме?

Җамали. Ул ни дигән сүз? Аның йорты залук, кибетендә малы юк, акчасы урланган. Аның кибетендәге бар малын сатып бетерсәгез дә, ун прасинттан артык җыя алмыйсыз.

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Монысы өчен абыйга рәхмәт.

Василий Дмитриевич. Соң күпме бирмәкче буласыз?

Җамали. Күпме дип, ун прасинт бирербез. Аны да инде тик, барган көенә фирманың эше туктамасын дип кенә бирәбез.

Василий Дмитриевич. Алай бик аз. *(Доверенныйларга карап.)* Әйдәгез әле, монда килегез. *(Бер читкә китәләр.)* Ну, сез ни дисез? *(Үзара шыпыртлап бераз киңәшәләр. Янәдән килеп утырып.)* Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, менә нәрсә, унбиш процент бирерсез.

Җамали. Ихтыярыгыз, без артык бирә алмыйбыз.

Василий Дмитриевич. Алай булса, менә нәрсә: ун процентның һәммәсен дә иртәгә биреп бетерергә кулыгыздан подписка бирәсезме?

Җамали *(Камалига карап)*. Камали, синдә иртәгә алты мең тәңкәләп акча булырмы? Калган яртысын мин табам.

Камали. Яхшы, ярар, булыр.

Василий Дмитриевич. Ну, доверенныйлар, сез дә ризамы?

Доверенныйлар. Риза, риза!

Василий Дмитриевич. Алай булса, мин актны язам. *(Яза.)* Менә сезгә үзебезнең йөз егерме мең сум алачагыбыз бәрабәренә унике мең сум алырга риза булганлыгыбызга распискалар. Рәхим итеп, һәммәгез дә шуңа кул куегыз! *(Куялар.)* Яхшы, инде алай булса, менә, менә монысы сезгә. Ә менә монысы безгә. Яхшы, хәерле сәгатькә булсын. *(Кул бирешәләр.)* Ну, Җамалетдин Гыйлаҗетдинович, инде эш бетергәнлекнең сые сездән.

Җамали. Әйдәгез, рәхим итегез, барабыз. *(Чыга башлыйлар.)*

Сираҗетдин *(үзалдына)*. Ух, эш пеште! Бер көн эчендә йөз дә сигез мең тәңкә файда!

Доктор. Әфәнделәр, сезгә бер сүзем бар. Әгәр дә минем сүземне тотсагыз, хәзерге көндә ике кешегә сез бик зур файда китерә аласыз. Бердән, сез авыруны терелтә аласыз, икенчедән, миңа бик зур шөһрәт була.

Доверенныйлар. Ничек итеп?

Доктор. Бая мин сезгә сөйләгән идем бит, гадәттән тыш бер эш булса, диваналарның терелүе ихтимал дип. Минем башыма бер фикер килде. Сезнең кайсыгызда булса да дүрт данә бишәр йөз сумлык акчалар бардыр бит?

Доверенный. Бар, миндә дә бар.

Җамали белән Камали. Миндә дә бар.

Сираҗетдин *(үзалдына шатланып)*. Аңладым, аңладым, бу доктор түгел икән, шайтан икән! Яңадан бер биш йөзлекне тамызмый туры килмәс.

Доктор. Булса, китерегез монда акчаларыгызны. *(Бирәләр.)* Хәзер миңа калын-калын итеп дүрткә бүлеп төргән чуар кәгазьләр бирегез. *(Кәгазьләрне китереп бирәләр.)* Менә аларны шушылай итеп төрик. *(Төрәләр.)* Хуш, сез, әфәнделәр, менә бу почмакка килеп, бер дә дәшми-тынмый гына торыгыз. *(Тегеләр почмакка китәләр. Доктор, тышкы ягыннан бишәр йөзлек акча белән төргән кәгазьләрне икешәр-икешәр ике кулына тотып, аларны югары күтәреп, акрынлап, аяк очлары белән генә басып, Сираҗетдинның артына килә. Соңра кинәттән, аяк тибеп, бик каты аваз белән: «Сираҗетдин!» — дип кычкыра. Сираҗетдин, сискәнеп, аяк өстенә баса. Акчаларга карап тора. Соңра көлеп җибәреп: «Акчам! Акчам!» — дип, кулларын суза.)*

Доктор *(акчаны биреп)*. Мә, ал акчаларыңны! Монда кырык тугыз мең тәңкә! Акчаң табылды! *(Сираҗетдин, акчаларны алып, контора өстәленә йөгерә. Өстәл эченә салып бикләп, ачкычны ала.)*

Доктор *(халыкка карап)*. Ну, каналия, нинди оста эшли, артист кына буласы бар! *(Сираҗетдин янына бара. Бер кулы белән Җамалига ишарә кыла. Җамали килә.)* Сираҗетдин әфәнде, бу кем? Бу абзаң, күрешегез.

Сираҗетдин *(Җамалига карап)*. Абый!

Җамали. Исәнме, энем! Исән кайттыңмы?

Камали. Исәнме, энем?

Сираҗетдин. Исәнме.

Доктор. Хатынын чакырыгыз!

Җ а м а л и. Исән-сау кайттыңмы, энем?

С и р а җ е т д и н. Ә?

Д о к т о р. Менә болар — агаларың, таныйсыңмы?

С и р а җ е т д и н. Таныйм.

Д о к т о р. Танысаң күреш. *(Сираҗетдин күрешә. Гөлҗиһан керә.)*

УНЫНЧЫ МӘҖЛЕС

Г ө л җ и һ а н һәм б а ш к а л а р.

Д о к т о р. Менә монысы кем?

С и р а җ е т д и н. Гөлҗиһан!

Д о к т о р. Күрешегез. *(Күрешәләр.)* Йә, инде утырыгыз. *(Дүртесе дә утыралар.)* Йә, менә инде тыңлап торыгыз, Сираҗетдин Гыйләҗетдинович! Әнә сезнең кырык тугыз мең тәңкә акчагыз, сез ул акчаны Мәскәү юлында югалттыгыз.

С и р а җ е т д и н *(сикереп торып)*. Ә?

Д о к т о р. Утыр, утыр, менә инде хәзер ул акчалар табылды.

С и р а җ е т д и н. Сез кем?

Д о к т о р. Мин — доктор.

С и р а җ е т д и н. Хуш?

Д о к т о р. Хәзер инде син терелдең.

С и р а җ е т д и н. Мин авырмадым!

Д о к т о р. Ярый, авырмасаң. *(Халыкка карап.)* Авырмаганлыгың бик мәгълүм. *(Сираҗетдинга.)* Ярый, хуш инде! Мин китәм.

С и р а җ е т д и н *(урыныннан торып)*. Ярый, хуш! Ә болар кемнәр? Ә, Василий Дмитриевич, уһуу, исәнме? Миңа ник әйтмисез, исәнме? Һа, сез дә исәнме? Акчага дип килдегезме? Менә хәзер сезгә акча бирәм. *(Өстәл астын барып ача башлый. Доверенныйлар шаркылдап көлеп җибәрәләр.)*

В а с и л и й Д м и т р и е в и ч. Юк, Сираҗетдин Гыйлаҗетдинович, кирәк түгел. Бирерсез әле. Әйдә, без сине сыйларга алып барабыз. Шунда сөйләшербез.

С и р а җ е т д и н. Ярар, барам, бар чыга торыгыз. Кая, Гөлҗиһан, бүрек белән яңа киемнәрне китер. Аңладым, аңладым. Сезгә тагын биш йөз. Мин хәзер чыгам. *(Доктор чыга.)* Ә менә монда икән җилән. *(Киенә.)* Эш пеште! Бер минут эчендә йөз дә сигез мең сум файда! Хатынны җибәрәм, яшь хатын алам, йорт салам, афтамабил алам! Типтерәм дөньясында! *(Чыгып китә.)*

Г ө л җ и һ а н *(ишектән сөйләнеп керә).* Бүрекләрең бу яктадыр, ахры. Ай Алла, чыгып та киткән, күрми дә калдым. Үзе дә терелде! Байлыгыбыз да үзебезгә калды. Кунакка барам, кунак чакырам, мәҗлес уздырам! Янсын дошманнарның йөрәге!

Пәрдә

1911 ел

Сораулар һәм биремнәр

1. Сатирик әсәрләрдәге конфликт үзенчәлеген исегезгә төшерегез.

2. Сатирик әсәрләргә хас конфликтны «Банкрот» комедиясендә табыгыз.

3. Сираҗетдин — хәйләкәр, димәк, акыллы гына сәүдәгәр. Шуңа күрә әсәрдә җиңүче булып кала да. Сираҗетдинның акылына бәя бирегез.

4. Шул ук вакытта ул — буш бер кеше дә. Сираҗетдинның бушлыгы нидән гыйбарәт?

5. Сираҗетдин сыйфатларын бергә җыеп сөйләгез.

6. Типик персонаж дип нинди персонажларга әйтәләр? Исегезгә төшерегез.

7. Сираҗетдинда типик геройларга хас сыйфатлар бармы?

8. Комедиядә Сираҗетдинга охшаган башка персонажларны табыгыз. Кайсы яклары белән охшаулары турында сөйләгез.

9. Персонажлары аша Г. Камал җәмгыятьнең үзе мөһим дип санаган бер чиренә бәя бирә. Әдипне борчыган шул чирне атап әйтегез.

10. Гөлҗиһанга автор биргән сыйфатларны санап чыгыгыз һәм бу персонажга үзегезнең бәягезне бирегез.

Йомгак

Галиәсгар Камалны да татар милләтенең артталыгы, наданлыгы бик борчый. Шәһәр кешесе һәм үзе дә сәүдә эше белән шөгыльләнгән кеше буларак, ул илдәге җанлануны бик тиз күреп ала. Татарлар арасында да җирдән аерылган һөнәрчеләр күбәя, яңа заводлар, фабрикалар ачыла. Сәүдә эшләре бик тиз җәелеп китә. Сәүдәгәрләр, төрле эшкуарлар, алар тирәсендә йөрүче кущтаннар саны артканнан-арта бара. Кинәт баеп китүчеләр, бөлүчеләр күбәя. Татарларның шул рәвешле капитализм мөнәсәбәтләренә керүе яңа иҗтимагый төркемнәр тудыра. Әмма мондый җанлану әдипне бер дә шатландырмый. Әрсез сәүдәгәрләрнең, күбәйгәннән-күбәя барган түрәләрнең башбаштаклыкларын әдип үз күзе белән күреп тора. Яңарыш

көткән нәтиҗәне бирми. Әдәплелек, шәфкатьлелек, гаделлек, горурлык кебек рухи байлыкның мал байлыгына буйсына баруы аны тәмам хәсрәткә сала.

Әдип бу чирдән котылу юлларын эзли. Милләт башына төшкән бу яманлыкның сәбәбе гаилә эчендә дигән нәтиҗәгә килә. «Бәхетсез егет» исемле беренче әсәрендә шул хакта әйтә. Баштагы әсәрләрендә әле ул юлдан язган кешеләрне кызгана. Бу әсәрләрендә әдип әхлаксызлыкның сәбәбен гаилә башлыкларының наданлыгында күрә. Мәгърифәт кешеләрнең дөньяга карашын үзгәртер, әхлаклы итәр дип уйлый. «Бәхетсез егет» пьесасында шундый үрнәк бер гаиләне дә тасвирлый.

Әмма тиздән әдип мәгърифәтчелек карашының кимчелеген күрә башлый. Сезгә таныш «Беренче театр» һәм «Бүләк өчен» комедияләрендә дә әле ул надан гаилә башлыклары турында яза. Ләкин бу әсәрләрендә наданлык сыйфаты кешеләрнең башка сыйфатларын алыштырып килми. Башка кире сыйфатлар рәтеннән генә санала. Милләтнең төп чирен әдип вак җанлы кешеләрнең югары дәрәҗәгә дәгъва кылуларында күрә.

Әдипнең дөньяга карашы еллар үтү белән тагын да киңәя төшә. «Безнең шәһәрнең серләре» һәм «Банкрот» комедияләрендә Галиәсгар Камал гаилә эчендәге кимчелекләр чигеннән чыгып китә. Шәһәрдәге абруйлы байларны да, зыялыларны да, шәһәр белән идарә итүчеләрне дә вак җанлы, ләкин дәрәҗәгә дәгъва кылучылар итеп сурәтли. Бу әсәрләрдә алар берсе дә надан түгелләр.

Тормышның бозыклыкка таба үзгәрүенә сәбәпне әдип җәмгыятьнең үзендә, яшәп килүче системада күрә. Вак җанлы, буш, ләкин дәрәҗәгә дәгъва кылучы персонажлар әдипнең барлык әсәрләрендә дә бар. Димәк, Галиәсгар Камал бу кимчелекне җәмгыятьнең иң аянычлы типик кимчелеге итеп исәпли. Ләкин уртак сыйфатларын персонажлар һәр әсәрдә төрлечә күрсәтәләр. Эчке бушлык белән тышкы җитдилек каршылыгы — сатирага хас каршылык. Шулай булуын Галиәсгар Камал бик тиз сизеп ала. Һәм соңга таба фәкать сатирик комедияләр генә яза. Комедияләрендә әдип бу каршылыкны конфликт дәрәҗәсенә җиткереп күпертә, көлке тудырырлык чаралар таба.

Мирхәйдәр Фәйзи (1891—1928)

Мирхәйдәр Фәйзи 1891 елның 31 октябрендә Оренбург губернасы Орск өязе Күкшел авылында туа. Бу авыл миллионер Хөсәеновларның утары санала. Әдипнең әтисе Мостафа шунда управляющий булып эшли. Димәк, булачак драматург укымышлы һәм һәр нәрсәсе җитешле гаиләдә тәрбияләнгән. Бераздан Мостафа Орск шәһәренә күчеп килә һәм шунда йорт төзеп яши башлый.

Кечкенә Мирхәйдәр авылда чакта ук абыстайлардан сабак ала. Шәһәргә күчкәч, ике ел Орск мәдрәсәсендә укый. 1905 елда иң алдынгы мәдрәсәләрнең берсе саналган Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсендә белем ала. Кечкенәдән сәламәтлеккә туймаган Мирхәйдәр ике елдан укуын ташларга мәҗбүр була һәм Күкшел авылына кайтып китә. Монда ул кулына төшкән китаплар укып белемен күтәрә.

Башта шигырьләр яза. 1912, 1913 елларда шигырьләрдән генә торган ике китап та бастыра. Шул ук елларда Орскидагы драмтүгәрәк өчен «Яшьләр алдатмыйлар» исемле беренче пьесасын иҗат итә. 1913 елда «Кызганыч» һәм «Тәкъдирнең шаяруы» исемле ике пьеса яза. Пьесаларының икесен дә яшьләр мәхәббәтенә багышлый. Әдип гомеренең соңгы көненә кадәр иҗат итә, ләкин драматург буларак «Галиябану» драмасын язгач кына дан казана. Бу — театр сәхнәсендә иң күп куелган әсәрләрнең берсе.

ГАЛИЯБАНУ

Драма дүрт пәрдәдә, биш картинада

ВАКЫЙГАНЫҢ КЕШЕЛӘРЕ:

Бәдри — хәлле генә кеше. Беренче вә дүртенче пәрдәләрдә — чалбарсыз, читек, камзул һәм такыядан[1]; икенчедә бүрек, чалбар, казаки кия. 50 дә.

Галимәбану — хатыны. Гади авыл киемендә. 40 та.

Галиябану — кызлары. Беренче, икенче, дүртенче пәрдәләрдә — гади киемдә; өченчедә — аягына яңа читек-кәвеш, өстенә яңа күлмәк киеп, чулпылар таккан, яулык белән шәл ябынган була. Бик матур кыз. 17 дә.

Садретдин — уллары. 8 дә.

Хәлил — яшьләй ата-анасыннан аерылган. Урта хәлле матур егет. 21 дә.

Исмәгыйль — күп җир биләүче бай егет. Аягында — америкаң итек, өстендә — һәйбәт тужурка, башында — эшләпә. 25 тә.

Бәдига — яучы булу белән аты чыккан карчык. 65 тә.

Рәхмәтулла, Сибгать, Хәмзә, Шәмсетдин, Биктимер — 18—23 ләр арасындагы авыл егетләре.

Гөлми, Рабига, Хәерниса, Сәгыйдә — киенгән, ясанган, 16—18 ләр арасындагы авыл кызлары.

Гыймади — Бәдринең ялчысы.

Хатын — 40 та.

Көтүче — сәләмәрәк киенгән, башында иске эшләпә, яланаяк. 16 да.

Старшина.

Вакыйга Оренбург ягы авылларының берсендә.

---

[1] *Такыя* — бизәкләнгән баш киеме.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Уң якта — бер ишек, түрдә тыкрыкка караган — бер, сул якта бакчага караган ике тәрәзә. Бәдринең ишегалды як өе. Кич.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Пәрдә күтәрелгәндә урамнан «Галиябану» көенә гармун белән җырлап, сызгырып, куллар чабып үткән тавыш ишетелә. Галиябану, чигеп яткан эше кулында көенчә, өстәл янында тыңлап утыра.

Җыр

Бакчада гөлләр ал икән,
Гөлдә былбыл бар икән;
Кашы кара, буе зифа,
Галиябану, сылуым иркәм,
Кемгә насыйп яр икән?

Галиябану. Ай шушы көй, өзә бит минем үзәгемне. Беркөн кайдан, күкрәгемнең кайсы җиреннән алып кына җырладым икән соң мин бу көйне? Инде менә үз исемемне кушып җырлый башладылар. Мин аны үземнең сөйгәнем өчен генә җырлаган идем.

Ерактан гына егетләрнең җырлап киткәннәре ишетелә. Шулвакыт Садрый бакча як тәрәзәдән башын тыга.

Садрый. Апа, Фәрханә апа сине монда гына чыксын әле ди; баскычта. *(Китә.)*

Галиябану. Ярый. Җиләккә барырга дидер инде. *(Чыгып китә.)*

Күп тормый. Бәдри, тагы соңрак Галимә керәләр.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бәдри, Галимә.

Бәдри. Ишеттеңме, хатын?

Галимә. Ишетмәгән кайда. Бигрәк безгә төбәп җырлаган кебек инде. Әллә бөтенләй Галиябануга атап чыгарганнар?

Бәдри. Әле ничек кенә дип җибәрәләр. «Кашың кыйгач, битең кояш» ди бит. *(Куанып көлә.)* Инде егетләр Бәдриеңә бер чакрымнан сәлам бирә башладылар. *(Шәбәеп.)* Шундый бер кыз үстереп биргәч, ни... Ә... ни әйткәндәй, хатын, син абайладыңмы? Мин бу җырлап үткән кешене Исмәгыйль түгел микән диебрәк калдым.

Галимә. Ай-һай, булмас ла. Ул безнең тирәдә чуалыр микән?

Бәдри. Белмәссең, чәчләре чәчкә бәйләнгән булса, Галиябану белән дуслашып йөрүләре дә мөмкин шул.

Галимә. Бик кенә матур эш булыр иде дә бит, белмим шул. Ходай шундый рәхмәтен багышлаган булса, дүрт кул белән бирер идек инде. Үзе черегән бай, үзе баш...

Бәдри. Аннан да һәйбәт урынны күтәргә дә ярамый.

Галимә. Галиябану миннән башкага булачак түгел, дип әйтә икән Исмәгыйль дип, беркөн Гайни сөйләп торган булган иде аны.

Бәдри. Тукта, без, хатын, Садрыйны җибәреп карыйк, шул төркем эчендә Исмәгыйль бармы, юкмы, белеп кайтсын.

Галимә чыга.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бәдри ялгыз.

Бәдри. Ходай кушып башланган гына булсачы. Егет менә дигән. Үзе бай, үзе хуҗа. Дөньяны дер селкетеп тора. Шәйхи бай да аннан соң безнең белән сакланыбрак сөйләшер иде. Фатыйхның да авызы томаланыр иде. Ай, Галиябану да йоклап тормаган гына булса... Тукта, бер-бер ишарәсен табып булмасмы? *(Як-ягына каранып кына, өстәл өсләрен актара. Чиккән кулъяулыгын табып алып, шатланып.)*

Галимә керә.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бәдри, Галимә.

Бәдри. Хатын, хатын, тиз, монда кил әле. Эш пешә. Сөенче! Башланган. Менә Исмәгыйльгә бүләккә эшләп куйган.

Галимә. Тизрәк урынына куй инде! Үзе сизмәсен тагын.

Бәдри. Тукта әле. Тагын берәр нәрсә табып булмасмы? *(Яулыгын урынына куя да эзләнә.)* Менә, бу ни? Хат бит. *(Ача.)* Егетләр хаты. Мә әле, син маташтыра алмассыңмы?

Галимә. Кит аннан, мин язу танымыйм бит.

Бәдри. Танымыйм дип, моны укымый калырга ярамый инде. Танымасаң да укы! Көндез булса, сиңа әйтеп тә тормас идем. Беләсең бит кич күземнең язу укый алмаганын.

Галимә. Ай Аллам, белмәгәч, ничек итеп укыр, ди, икән.

Бәдри. Мин өйрәтеп торырмын. Мә, шуннан иң ахыргы сүзен генә кара! Башкасы кирәкми дә.

Г а л и м ә *(алып карап)*. Монда бер «әлеп» бар, атасы!

Б ә д р и. Ә-ә-ә, таяк кебекме? Әнә инде шуның янында бер тырма теше кебеге дә юкмы?

Г а л и м ә. Андый юк. Таяктан соң чалгы кебек кәкрәебрәк киткән нәрсә бар.

Б ә д р и. Анысы ни булды тагы?.. Хуш, тагы, тагы?.. Шул чалгы янында саплы чукмар кебек нәрсә юкмы?

Г а л и м ә. Чукмар кебек түгел. Балык аулый торган җәтмә кебегрәк бернәрсә бар.

Б ә д р и. Әһә, әһә, инде бер табагач кебеге да бармы?

Г а л и м ә. Бар... *(Куана китеп.)* Азагында ләм, атасы, ләм!

Б ә д р и. Ләм? Кармак кебекме?

Г а л и м ә. Әйе, әйе, анысын мин үзем дә таныйм.

Б ә д р и *(бик куанып)*. Исмәгыйль инде, Исмәгыйль. Аллага шөкер, Аллага шөкер! Менә син, бөтен эшне пешереп куйган Галиябану... *(Хатын куя.)* И Ходаем, һәр икесенә тигез мәхәббәт бир! Әйтәм шул бик тилмереп җырлыйдыр иде. «Галиябану, гомерлек яр булсана!» ди бит. Тикмәгә генә түгел икән ул. *(Куанып көлеп куя.)*

Г а л и м ә. Ходай күктән көткәнне җирдән бирде.

С а д р ы й керә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Б ә д р и, Г а л и м ә, С а д р ы й.

С а д р ы й. Әти, Ногман абый анда юк.

Б ә д р и. Алар нишләп утыра соң анда?

С а д р ы й. Хәлил абый гармун уйный. Сибгать абый бии. Кызык.

Б ә д р и. Өч-дүрт кеше ни кызык табып утыралар икән?

С а д р ы й. Анда күп кешеләр. Вәли абый, Төхби, Хәмзә, Йосыфлар да бар.

Б ә д р и. Сиңа бер сүз әйтмәделәр дәме?

С а д р ы й. Исмай әйтә, апаең чакырдымы әллә, ди.

Б ә д р и *(куанып китеп)*. Исмәгыйльме?

Галимә Бәдригә төртә.

С а д р ы й. Әйе, миңа: «Нихәл, кайниш?» — дигән була.

Г а л и м ә. Кара син хәерсезне.

Б ә д р и. Син нәрсә дидең соң аңа?

С а д р ы й. Сыртыңа ишкән каеш, дип йөгереп киттем. Йокым килә инде. *(Чыгып китә.)*

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бәдри, Галимә.

Бәдри *(кулларын уып, бик куанып)*. Йә, күрдеңме, карчык? Менә син, эш пеште бит, ә? Егет тә сөя, кыз да сөя. Туй итәсе генә калды. Һем, каениш дип әйтә, ди, ә?.. Миңа бабай ди инде ул, сиңа әби ди. *(Куанып көлеп җибәреп.)* Яман түгел бит, хатын, ә? Нибуч, әби булырсың. Туй! Туй! Иртәгә үк калага китәргә кирәк. Бер егерме-утыз потлап бодай салып, иртәрәк китим...

Бу вакыт йомшак кына сызгырган тавыш ишетелә.
Картлар бер-берсенә карашалар.

Бәдри. Тиз-тиз, хатын! Килде, килде...

Галимә. Исмәгыйль, Исмәгыйль!

Бәдри *(ишектән чыкканда әйләнеп)*. Төкле аягың белән, кияү!

Чыгалар. Күп тормый, Галиябану, кереп, ишекне элә.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галиябану ялгыз.

Галиябану. Бөтен авыл йоклап беткән, боларга ни калгандыр төн сакларга! Хәлил килеп сызгырмагае дип куркып беттем. Хәер, Исмәгыйль белән сүзгә килгән булсалар, кайтып та киткәндер. Ул Исмәгыйль дә бер җан көеге булды миңа. Әтиләргә сүз сала гына күрмәсен инде. *(Исенә төшереп.)* У, шуның хатын ертып ташлыйм әле. Әтиләр-мазар күрер йә. *(Ертып ташлап.)* Хатлары белән, сәламнәре белән, җырлары белән тәмам теңкәгә тиде инде. Ходай башымны шул кансызга насыйп итмәсен! Унөч яшемнән алып йөрәгемә кереп утырган Хәлилем бар чагында, аның кызыксыз байлыгына бер дә исем китми...

Шул вакытта тагы әче сызгыру.

Ай, Хәлилме икән? *(Лампаны сүндерә дә, пәрдәне күтәреп, тәрәзәне ача.)* Чыгыйм микән, чыкмыйм микән? Бүген чыкмыйм булмаса. Әни сизсә яхшы түгел.

Шулвакыт матур тавыш белән сузып кына «Галиябану» көенә җырлаган тавыш ишетелә.

Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә;
Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым иркәм,
Чыкмый сызгырган җиргә.

Галиябану *(тәрәзә янына килеп җырлый).*
Йөгереп төштем су буена,
Суда кошлар йөзә дип;
Чыкмыйсың дип үпкәләмә,
Җаныем, бәгърем, сылуым иркәм,
Куркам кеше сизәр дип.

Хәлил. Тәрәзә төбем каты бал,
Ашыйсың килсә ватып ал.
Сөюләрең чыннан булса,
Тәрәзәдән тартып ал.

Галиябану шәле белән капланыбрак кулын бирә. Хәлил бүлмәгә керә, кулында гармун.

Читән аша төшкән чакта
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Шулкадәрле сагындым.

Синең тирәдә козгыннар очканы беленмиме? Исмәгыйль арага керә бит.

Галиябану. Мин мәңге аңа барачак түгелмен. Әтиләр кыстап йөдәтә башласалар, син миңа ярдәм итәрсең бит, Хәлил?

Хәлил. Теләсәң, мин иртәгә үк яучы җибәрәм.

Галиябану. Яхшылык белән бирмәсәләр, минябышып чыгам.

Хәлил *(аякка басып, кулын сузып).* Вәгъдәме? Мин иртәгә яучы җибәрәм.

Галиябану. Иртәгә үк җибәр! Исмәгыйль кысылганчы, бер хәл булсын.

Хәлил. Рәхмәт. Хуш, җаным. Мин тыныч күңел белән китәм.

Галиябану *(күрешеп).* Юлыңа ак җәймә!

Хәлил гармун уйнап китә. Сузып кына әтәч кычкыра.

Пәрдә төшә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бәдринең урам як өе. Сәкедә **Галимә** каба белән җеп эрләп утыра. Капчыклар тотып, **Бәдри** керә.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галимә, Бәдри.

Бәдри. Хатын, менә бу капчыкларны ямыйсы бар икән. Шимбә базарына барганда кирәк булыр. *(Галимәнең алдына китереп ташлый.)* Ай хатын, теге яулык нишләгән? Очкандыр инде ул күптән. Инде икеләнеп торасы юк. Бодайны салып, тизрәк калага китәргә кирәк. Галиябану төс белән дә авылда бер иде, акыл белән дә өстен булып чыкты. Менә дигән егет сайлый белде.

Галимә. Бай, төскә дә ярыйсы гына, артык бозыклыгы да ишетелми.

Бәдри. Бозыклыгы дип, андый гына гаеп хан кызында да була. Кесәң калын булса, йөрәкнең чуарлыгы күренми ул. Алтын күзнең җавын ала, диләр бит... Галиябану ул үзен алтын-көмешкә чумдырыр. Безгә дә бу турында... *(Як-ягына каранып.)* Әйе, үзең беләсең инде... Шулай инде... Әй, ансын карарбыз әле... Мин юкта, хатын, яучы-мазар килсә, мин кайткач җавап бирербез дисәң дә, ризалыгыбызны сиздереп куй!

Икесе дә чыгалар. **Галиябану** каршы очрый.

Галиябану. Әни, этигә ике генә бармак тамбур җебе алырга кушсам, орышыр микән?

Галимә. Нигә орышсын, орышмас. Тагы башка йомышларың булса да әйт... Сатингамы, бер затлырак нәрсәгә чиктерсәкме дип торам әле мин.

Галиябану *(куркып)*. Нигә ул?

Галимә. Атаң да әйтә, бердәнбер кызыбызны кеше арасында күркәм булырдай итеп хәзерли алсак, ди. Яшең дә җитмәде түгел; Ходай бәхетеңне бирсен инде. Атаң әйтә, ялгыз бер кызыбыз, без аның теләгенә каршы килеп йөрмәбез инде, үзе дигәнен эшләрбез, ди.

Галиябану *(үз-үзенә)*. Мөгаен, болар белгәннәр икән. Теләгемә каршы килмәүләрен белдерергә тырыша бит. Шулай булса, нинди бәхетле булыр идем.

Галимә. Синең теләгең — безнең теләк инде ул.

Галиябану *(үз-үзенә куанып)*. Ах, шатлыгымнан шашам инде, әйтми чыдый алмыйм. *(Анасына.)* Рәхмәт, әни, сиңа да,

этигә дә... *(Читкә карап.)* Ничек кенә белдертим? Урыны килгәндә әйтеп каласы иде. *(Анасына).* Минем... теләгемә каршы килмәсәгез, бәхетле булыр идем... *(Әйтә алмый туктый.)* Минем киенү-ясанудан башка бер теләгем бар... Тик әйтергә генә оялам... Үзегез дә беләсездер инде...

Галимә. Кыскасы гына, кызым, без синең ниятеңне белдек. Ходай ак тормышлар бирсен инде. *(Чыга башлый.)* Атаң көтә, чәйгә чык инде.

Галиябану. Мин эти киткәч чыгам.

Галимә чыга.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Галиябану ялгыз.

Галиябану *(куанып, сикергәләп).* И, мин нинди бәхетле, нинди бәхетле! Әтиләрне күндереп булмас дип куркадыр идем. Хәзер Хәлилнең солдатка алынмавын гына теләргә калды. Хәер, китсә кайтыр әле. Аныкы булып калсам, биш ел көтәргә дә риза.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галиябану, Бәдига.

Галиябану *(каршы йөгереп барып).* Әби, миңа яучыга килдеңме әллә?

Бәдига. Әйе, әйе, кызым, синең башыңны ашарга килдем.

Галиябану. Хәлилдән килгән булсаң, ашый бир.

Бәдига. Хәлилдән, Хәлилдән. *(Утырып.)* Сине башкага әрәм итәмме соң. Әниеңнәр ничек, күнәр җайлары бармы?

Галиябану. Күнә, күнә.

Бәдига. Ай җитез! Ул якны да ныгытып өлгергән.

Галиябану. Шулай итми ни аны! Мин әнине җибәрим. Әти киткәнче сөйләшеп калыгыз. *(Чыга.)*

СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бәдига ялгыз.

Бәдига. Менә кыз дисәң кыз, чәчрәп тора. Хәлил дә йокламаган: бөтен тирә-юнь егетләре күз тотып торган кызның күңелен бәйләп өлгергән. Дөньяны селкетеп торган Исмәгыйль сөйләнеп калды...

Галимә керә.

ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бәдига, Галимә.

Галимә. Кунак бар икән, абайламый да калдым. Сау йөрисеңме?

Бәдига. Шөкер Аллага. Мин сезгә зур гына бер йомыш белән килгән идем. Мин сезнең кызыгыз Галиябануга яучы булып килгән идем. Үзегез дә белгәнсездер...

Бәдринең арба белән чыгып барган тавышы ишетелә.

Галимә *(сикереп торып, тәрәзәгә йөгерә.)* Тукта әле! Атасы! Тиз генә өйгә кереп чык әле.

Билләрен буып киенгән Бәдри керә.

УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Бәдига, Галимә, Бәдри.

Бәдри *(ачык йөз белән).* Ә, исәнме, Бәдига абыстай, сау гына йөрисеңме?

Бәдига. Юлыңны бүлдердем. Мин сезгә бер хәерле эш белән килгән идем.

Галимә. Галиябануга яучы булып килгән Бәдига абыстай...

Бәдига. Яшьләрнең бер-берсенә вәгъдәләре дә бар икән. Инде эш сездән генә калып тора.

Бәдри *(куанып).* Ай, Бәдига абыстай, син дә корыга гына йөрмисең. Ишеткәч үк, безне кызыбыздан аерырга йөрми микән дип, эчем жу итеп киткән иде. Уйга килгән алга килә, ди, шул. *(Көлә.)*

Бәдига. Бер-берсенә тиң булмаганнарны яучылап йөрмим мин. Менә Галиябануны да тәвәккәлләгез, моннан да артык аңа тиң килгән урын булмас инде. Хан кызын димләсәң дә оят китермәслек егет.

Галимә. Әйе, егеткә сүз әйтерлек түгел.

Бәдри. Сузып та, назланып та торырга вакытым тар. Без кызыбызның теләгенә каршы килмибез. Үзләре табышкан, үзләре вәгъдә куешкан. Шулай булгач, Ходай бәхетләрен бирсен диюдән башка сүзебез юк.

Бәдига. Әле Галиябану бик бәхетле кыз икән, менә дигән егеткә бара. Киявегез дә һәркемнең ышанычын казанган. Бик һәйбәт егет, авылда бер дип әйтерлек.

Бәдри белән Галимә куанычларыннан урыннарында утырып чыдый алмыйлар.

Инде, алайса, юлыңнан туктатмыйм. Бар, мин дә кайтып егетне куандырыйм.

Бәдри *(торып).* Шулай Аллага тапшырабыз инде. Вәгъдә. Икенче килүеңдә, алайса, сый хәзерләп каршы алырбыз.

Чыгалар.

УНБЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Галиябану ялгыз.

Галиябану *(йөгереп кереп).* Бирделәр, рәхмәт төшкереләре! Менә хәзер мин Хәлилнеке... Утырдыңмы, Исмәгыйль!.. Шулай була ул. *(Тәрәзәгә барып.)* Әнә эти дә китте. Хәерле юл, эти, рәхмәт төшкере! Исән йөреп, сау кайт, эти җаным! Кадерлем! Акыллым!.. Мин кияүгә ярәшелгән кыз, әни янына чыгарга да оялам инде.

Пәрдә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Су буенда таллар янында бер күренеш. Сәхнәнең бер ягында кызлар, бер ягында егетләр утырышканнар. Пәрдә ачылганда, кара-каршы җырлашу бара.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Егетләр, кызлар.

Гали. Бу Исмәгыйль кайда бүген, бер дә күренми?

Рәхмәт. Аның сыерчыгы очкан, ди.

Шаулап көләләр.

Хәлил. Ай-яй, усал син, Рәхмәт!

Рәхмәт. Кешенең сыерчыгын очырган син усал әле.

Сәгыйдә. Сыерчыкны козгыннан коткарган карчыга ул. Сез Хәлилне карчыгага тиңләп зурладыгыз. Галиябануны сыерчыкка тиңләп хурладыгыз.

Гали. Аны Рәхмәт беркөн үк сандугач дип атады.

Хәмзә. Йә Хәлил, әйт азаныңны. Галиябануыңа сандугач дип исем кушабыз.

Рәхмәт. Моннан соң без аңа, «сылуым иркәм» дип, бик иркенләп әйтә алмабыз инде.

Көләләр. Хәлил «Галиябану» көен уйный. Хәмзә белән Рәхмәт парлап җырлыйлар. Шәми кайсы җирләрдә сызгырып кушылгалап ала.

Су буенда гөлләр үскән,
Кызлар йөргән төштер бу;
Сөеп алу, сөеп бару,—
Галиябану, сандугачым,
Илдә булган эштер бу.

Галиябану. Тау чаклы рәхмәт.

Хәмзә. Яхшы сүзең өчен — бәхетең канатлы булсын.

Хәлил. Әйдәгез, кузгалмыйбызмы?

Бар да аякка басалар, егетләр төркеме алга чыга.

Гали. Туйны кайчан итәбез, Хәлил?

Хәмзә. Башкасын белмим, Исмәгыйльнең борынына чирттең соң.

Хәлил. Куаныч зур инде. Исмәгыйль каныгыр тик.

Сибгать. Чөябез без аны. Моңарчы котырганы да җитәр.

Хәмзә. Ну, малай, кайда басканын белмәс үзе дә.

Гали. Кара аны, Хәлил, туйда сыйны мул яса!

Хәлил. Аннан эш калмый.

Сыерлар мөгрәгән, бозаулар кычкырган, кәҗәләр бакырган тавышлар ишетелә.

Биктимер. Әйдәгез, кызлар, калмагыз, бүкәй тияр.

Хәлил «Нужа» көен уйный. Хәмзә җырлый. Сызгыру, кул чабу, төрле кыйланышлар. Ду күчереп кузгалып китәләр.

Өй түрендә гөлләр үскән,
Сабакларын кем кискән?
Бер дә уйнамый, бер дә көлми
Бу дөньяда кем үскән?

Тавыш югала. Көтү кайткан вакыттагы тавышлар. Кулына чыбык тоткан бер хатын керә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хатын ялгыз.

Хатын *(җәһәтләп килеп кереп)*. Нәгъләт суккыры, өйгә туры кайтмый теңкәмә тия бит. Һәр көн шуның артыннан йөри-йөри эт булып бетәм... Көтүчесе дә, чәнчелгере, малларын бер юньләп карамый. Маллары кайсы анда, кайсы монда тарала да бетә... *(Читкә карап кычкырып.)* Дуңгыз малай, малларыңны юньләп карамыйсың да, кешегә никадәр мәшәкать ясыйсың.

Көтүче малай керә.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хатын, көтүче.

Көтүче *(ваемсыз гына)*. Сезнең азгын сыерларыгызны мин нишләтим аны? Әле дә аларның артыннан аз чапмыйм мин.

Хатын. Сине шуның өчен дә яллаганнар бит. Кайда минем сыерым? Син нәгъләтне кураең белән яңаклыйсы гына бар. Курай уйнап утырып, малларын таратып бетерә... *(Чыгып китә. Аның артыннан малай китә.)*

Күп тормый, тал арасыннан Исмәгыйль килеп чыга.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль ялгыз.

Исмәгыйль *(урталыкта туктап)*. Неужели бу хәбәр чын булыр?.. Чын булса страм, валлаһи! Минеке дип ышанып торган кызыңны икенче берәү кулыңнан тартып алсын, имеш. Алучысы кем тагын? Синең кулыңа су салырга ярамаслык бер малай гына бит... Юк, мин моңа ышанмыйм. Мин барында ничек аңа бирергә кыйсыннар. Теләмәгән вакытта да миннән куркырга тиеш алар. Галиябануны алам дип йөрүем бөтен тирәгә җәелде. Юк, моңарчы бөтен тирәне селкетеп тордым. Моннан соң да миннән куркырга тиешләр. *(Кызукызу йөреп алып.)* Ник мин болай йоклап йөрдем? Ник күптән аталарына хәбәр бирмәдем? Мин шул үземнән башкага бирергә базмасларына ышандым. Юк, Галиябануның миннән башкага баруын уйларга да ярамый. Бу була торган эш түгел. Хәлилнең дә башы ике түгел, белә торып минем арага керергә... *(Читкә карап.)* Әнә Галиябану үзе килә... Нишләргә?.. *(Тиз генә тал арасына баса.)*

Көянтә-чиләк күтәргән Галиябану сәхнәдән үтә башлый.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль, Галиябану.

Исмәгыйль *(чыгып)*. Юлыңа гөлләр үссен, Галиябану.

Галиябану *(борылып, Исмәгыйльне күргәч чыраен бозып)*. Рәхмәт! *(Китмәкче була.)*

Исмәгыйль. Ник ул кадәр ашыгыч?

Галиябану. Кеше очраган саен туктый башласаң, көне буе йөрерсең.

Исмәгыйль *(омтылып, каты вә куркытырлык итеп)*. Галиябану!

Галиябану, туктап, җирәнеп, Исмәгыйльгә карый.

Исмәгыйль. Сезнең тирәдә козгыннар йөри, диләр. Расмы әллә шул сүз?

Галиябану. Рас иде дә, котылдым инде.

Исмәгыйль *(куанып).* Теләмәдеңмени?

Галиябану. Теләмәдем.

Исмәгыйль *(бик куанып).* Хәлилнеме?

Галиябану. Юк, Исмәгыйльне.

Исмәгыйльне яшен суккан кебек була. Галиябану китә башлый.

Исмәгыйль *(тиз генә барып ябышып).* Галиябану! Син минеке булырга тиеш... Син минеке бул!

Галиябану. Мәңге булмам!

Исмәгыйль. Кара, моның ахыры яхшы булмас!

Галиябану. Минем берәүгә дә начарлык эшләгәнем юк. Шунлыктан миңа берәү дә зыян итәргә батырчылык итә алмас.

Исмәгыйль *(ялыныбрак).* Галиябану, җаным! Мине шул Хәлилдән ким күрәсеңмени? Үз бәхетеңне киртәләмә. Минем кемлегемне беләсеңме? Минем исемем ишетелгәндә бөтен тирә халкы тетрәп торалар. Минем бөтен авыл халкын бармагымда уйнатырга кулымнан килә. Минем күңелемне егып, башкага китүнең ахыры бик яхшы булмавын уйлап кара.

Галиябану. Зинһар, Исмәгыйль абый, мине җәберләмә, мин Хәлилне сөям. Сиңа һич мәйлем юк. Юкка минем юлымны бума!

Исмәгыйль. Яхшылык белән күнмәсәң, нишләргә белермен.

Галиябану. Ходайдан курык азрак.

Исмәгыйль. Ачу килгән вакытта Ходай истән чыга. Аннан да аң бул!

Галиябану. Хәтта минем синең белән сөйләшәсем дә килми! *(Китмәкче була.)*

Исмәгыйль *(бик ачу белән).* Мин сиңа китмәскә кушам!

Галиябану. Миндә синең эшең юк.

Исмәгыйль, тиз генә барып, Галиябануның башыннан шәлен тартып ала. Көянтә-чиләкләре шалтырап җиргә төшә.

Исмәгыйль *(мыскыл итеп).* Бар кит, ник китмисең?

Галиябану *(көянтә-чиләкләрен алып).* Исмәгыйль абый, йөдәтмә мине юкка. Барыбер файда юк... Бир шәлемне...

Исмәгыйль *(каршысында ялынып торган Галиябануны мыскыллап, шәл тоткан кулын бөеренә таянып, «Галиябану» көенә җырлый).*

Җәйгә чыксаң, җилләр өчен,
Җәй келәткә урыныңны;
Миннән артык яр тапмассың,
Бик күтәрмә борыныңны.

Бар, әнә теге чүплек башындагы өйдә сине килен итеп көтеп торалар, ди.

Галиябану. Миңа шул да ярый. Анда синең эшең булмасын!

Исмәгыйль. Йә, бар, ник китмисең? Түбәсез өйгә шәлсез килен дә ярый...

Шулвакыт Хәлил, йөгереп кереп, Исмәгыйль белән Галиябану арасына баса.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль, Галиябану, Хәлил.

Хәлил *(Исмәгыйльнең кулыннан шәлне йолкып алып).* Без аны синнән сорамабыз. Анда ни эшең бар, бәдбәхет, кара елан! Син безнең арага кермәкче буласыңмыни?!

Галиябану *(Хәлилнең кочагына атылып).* Җаным, бәгърем, коткар мине!

Хәлил. Тыныч бул, Галиябану, аның белән сөйләшә белермен. *(Исмәгыйльгә.)* Исмәгыйль! Бел шуны: башың ике булса, кер безнең арага! *(Галиябануны алып чыгып китә.)*

Исмәгыйль *(бик ачу белән карап калып).* Әгәр шушы Хәлилнең кулыннан Галиябануны тартып ала алмасам, Исмәгыйль исеме миңа хәрам булсын! *(Нык-нык басып чыгып китә.)*

Читтә көтүче малайның курайда бер моңлы көйне уйнаганы ишетелә. Дүрт-биш минуттан Хәлил белән Галиябану керәләр. Галиябану су җилкәләгән.

ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәлил, Галиябану.

Галиябану *(суны җиргә куеп).* Җаным, мин ул Исмәгыйль эшне чуалтыр дип куркам.

Хәлил *(юатып).* Бөтен авыл безнең якта. Ялгыз Исмәгыйль әллә кая бара алмас.

Галиябану. Безнең эти — бик аумалы кеше ул. Шунлыктан күңелем бик шикләнә башлады. Исмәгыйль, мөгаен, этиләрне айнытыр. Исмәгыйльгә сатылмагайлары дип куркам. Зинһар, бер юлын тап!

Хәлил. Алайса, менә нәрсә, Галиябану. Әтиләрең айнысалар һәм изалый торган булсалар, шул ук төнне Көмшәр авылына качарбыз да никах укытырбыз.

Галиябану. Алар бит мине бикләп куярлар.

Хәлил. Син аларның айныганын сизгәч тә, алар яклы бул, мин Хәлилне ташладым, диярсең. Шуннан сине бикләмәсләр. Авыл тынгач, мин синең тәрәзәңә барырмын да, Көмшәргә сызарбыз.

Галиябану. Ярый, мин күнәм. Синеке булып калыр өчен, тау тишеп чыгарга да ризамын.

Читтә гармун тавышы ишетелә башлый.

Алар кемнәр?.. Исмәгыйль түгелме?

Хәлил. Шулар.

Галиябану *(борчулы)*. Ходаем, мыскыл итеп җырларга тотынырлар инде. Анда никадәр халык җыелган.

Гармунга кушылып, «Галиябану» көенә җырлый башлыйлар.

Җәйнең ямьле көннәрендә
Асыл кошлар кычкыра;
Әллә нинди җебегән авыз
Егет саен кочтыра.

Галиябану *(кычкырып)*. Ах, ялган! Ялган! *(Егыла башлаганда, Хәлил тотып кала.)*

Пәрдә

ДҮРТЕНЧЕ ПӘРДӘ

Бәдри, Галимә.

Бәдри. Иртәгә иртүк Бәдига абыстай килеп тә җитәр. Туйлыгына күпме, мәһәрне күпме сорыйбыз? Бер әләктерсәң, шушы туй арасында әләктереп каласың аны.

Галимә. Без сорарбыз. Ә ул тагын да күбрәк бирергә уйлап торган булса. Шуның өчен дә үз иркенә генә куйыйк дим мин.

Бәдри *(башын кашып, уйланып)*. Әгәр ул туйлыгына, мәһәренә нибарысы ике йөз сум гына биреп куйса?

Галимә. Ник, шул җитмимени?

Б ә д р и *(ачуланып).* И чүпрәк баш, чүпрәк баш. Соң Исмәгыйль кебек бер байга кыз бир дә, имеш, ике йөз белән генә эш бетер.

Г а л и м ә. Алай бик акыллы булгач, киңәшмәсләр аны. Миңа димәгәе өч йөз сум сора.

Б ә д р и. Өч йөз?.. Менә мин, алайса, мең тәңкә сорыйм... Ишетәсеңме? Мең!

Г а л и м ә. Илаһи, ал гына, мин бер дә күпсенмим... Алай зурдан сорый белгәч, әзерли дә бел инде.

Б ә д р и *(йомшап).* Тегеннән чиртүен генә чиртим, менә дигән итеп туй ясарбыз. Ике мичкә бал эчетербез... Сиңа тагы бер кәшимир шәл алырбыз. Бер настоящий американ кәвеш алырбыз. Шуны киеп, кодагыйлар янында җирне җимерттереп йөрерсең. *(Абайлап.)* Шундый ай яктысында нигә ут яндырып утырасың? Сүндер! Әле бит мең сум кулга кермәгән.

Г а л и м ә *(сүндерә).* Әле ай яңа гына күтәрелде бит...

Б ә д р и. Чү әле, чү! *(Агачлар арасыннан сузыла-сузыла карап.)* Исмәгыйль. Тиз, тиз, хатын! Китик, Галиябануга килә...

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Б ә д р и, Г а л и м ә, И с м ә г ы й л ь.

И с м ә г ы й л ь. Ни хәл, Галимә җиңги, эшләр гөрлиме?

Г а л и м ә. Аллага шөкер, бик һәйбәт әле.

И с м ә г ы й л ь *(ачуын тыярга тырышып, мыскыл иткән сымак).* Сез бик шат, Бәдри абзый! Куанычыгыз эчегезгә сыймагандай күренә.

Б ә д р и. Һи-һи-һи... Куанычыбыз эчебезгә генә түгел, дөньяга да сыя алмый. *(Галимә белән ишарәләр ясашып.)* Без сиңа комачауласак китик...

И с м ә г ы й л ь. Мин таракан булдым ахры сезгә.

Б ә д р и. Юк, юк. Алла сакласын!

И с м ә г ы й л ь *(сабырлыгын җуеп).* Рияланма юкка, Бәдри абзый! Бары да беленде инде.

Б ә д р и. Ничек, ничек? Нәрсә беленде? Ни булды?

И с м ә г ы й л ь *(бик ачу белән).* Син тиле, син аңгыра!

Б ә д р и. Исмәгыйль...

И с м ә г ы й л ь *(аяк тибеп кычкыра.)* Молчать!

Бәдри дер-дер килә.

И с м ә г ы й л ь *(гайрәт белән).* Мине танымый йөрисез икән әле. Менә танырсыз, минем белән шаярасыгыз килгән

икән... Постой! Мине Исмәгыйль диләр. Мин сезнең кадерле киявегез Хәлил кебекләрнең унавын бер бармакта биетәмен, беләсезме?

Бәдри } (икесе бергә). Хәлил кияү? Ул ни дигән сүз
Галимә } тагын?

Исмәгыйль. Улмы? Галиябануны Хәлилгә ярәшкәнсез дигән сүз.

Галимә. Язмаганны, кем әйтә.

Бәдри. Менә тагын кирәк булса. Юк, юк! Кызыбыз да син дип үлеп тора.

Исмәгыйль *(кычкырып)*. Алдама!

Галимә. Соң, вәгъдә билгесе итеп үзеңә чиккән яулык та бирде ләбаса.

Исмәгыйль. Чиккән яулык?.. Алайса, ул яулык Хәлилдә. Йә, тагы да әйтә торганыгыз бармы?

Бәдри. Ах, Исмәгыйль... Алайса, без ялгышканбыз... Без син дип белдек. Бу ни дигән эш?.. Юк, юк, болай ярамый. *(Гайрәт белән.)* Бар, хатын, алып чык кызны монда! Мин кызымны андый урам көчекләренә тоттырып җибәрермен дип үстермәдем.

Галимә йөгереп чыга.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бәдри, Исмәгыйль.

Исмәгыйль. Ул якны үзең кара, Бәдри абзый, мин китәм. Бәлки, әйләнеп килермен. Тик шуны яхшы бел: Галиябану ниприменно миңа булырга тиешле! Мин, үземнең исемемне әллә нинди малайлардан таптатмас өчен, һәртөрле юлга керергә әзер. Әгәр Галиябануны Хәлилдән айнытып, иртәгүк миңа никах укытып бирә алсаң, туйлык мәһәрләрдән башка үзеңә мең сум!

Бәдри *(соңгы сүзнең дәһшәтеннән аптырап, ни әйтергә белми калып)*. Э... е... е... ме-ме-мең тәңкә?!

Исмәгыйль. Эшлисең бит, Бәдри абзый, шуны?

Бәдри *(күзләре дүрт булып)*. Булды, кыз синеке! *(Кулын бирә.)*

Исмәгыйль. Кара, сүзеңдә нык тор! Аларның вәгъдәләре бик нык. Син шуны җимерергә тиешле. Булдыра алмасаң, икегезгә дә яхшы булмас! *(Китә.)*

Бәдри *(күзләрен ялкынландырып)*. Мең тәңкә...

Галиябану белән Галимә керәләр.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Бәдри, Галимә, Галиябану.

Бәдри. Әле монда, кызым, булачак кияү дә бар иде. Шуңа күрә сине дә чакырткан идем.

Галиябану. Нинди кияү?

Бәдри. Үзеңнең булачак киявең, Исмәгыйль.

Галиябану *(куркып китеп, белешмичә)*. Исмәгыйль? Ул нинди кияү булсын? Бу нинди сүз тагын? Бер бирдегез бит инде.

Бәдри. Кемгә?

Галиябану. Хәлилгә.

Бәдри. Юк, без сине Хәлилгә биргәнебез юк. Исмәгыйльгә дип бирдек. Менә сиңа шул: син Исмәгыйльгә барырга тиеш!

Галиябану. Бәдига абыстайга да вәгъдә куеп җибәрдегез бит.

Галимә. Тәрәзәгә килеп йөргән кешене Исмәгыйль дип белгәнгә, Бәдига абыстай яучы булып килдем дигәч тә, Исмәгыйль җибәргәнлегендә шик итмәдек.

Галиябану. Мин аңа бармыйм... *(Исенә килеп, үз-үзенә.)* Ах, яңлыштым... Инде нишлим?..

Бәдри *(кычкырып)*. Барырсың!

Галиябану. Мин аңар барырга мәңге риза түгел. Мин Хәлилнеке! *(Елап.)* Әти җаным, кыстама мине...

Бәдри *(кычкырып)*. Әти, барам, диген!

Галиябану елый.

Галиябану. Булмый!

Бәдри *(өстенә барып)*. Булмыймы? Булмыймы?

Галиябану. Булмый, дим...

Бәдри, бик ачуланып, гайрәт белән селтәп җибәрә. Галиябану атылып барып төшә.

Галимә. Юньләп...

Бәдри. Тик тор, сиңа да кирәкме әллә?!

Галиябану *(торып, бер агачка сөялеп үз-үзенә)*. Инде нишлим? Әти хәзер җанымны алырга тора... Болай итеп кенә булмый икән... Әгәр Хәлил кушканча эшләсәм?.. Ул килми калса, бүген, иртәгә үк Исмәгыйльгә никах укытып куйсалар нишләрмен?..

Б ә д р и. Йә, кызым, күп уйланма! Инде акылга килмәдеңме?

Г а л и я б а н у *(үз-үзенә).* Күнәм инде, моннан башка чара юк. *(Атасынарак бер-ике атлап.)* Инде... Ихтыярыгыз... Мин шуннан артык каршы тора алмыйм. Сез алай риза булмый торган булгач, карышудан файда чыкмас. Сез минем өчен кайсы яхшы буласын артыграк беләсездер.

Г а л и м ә. Менә рәхмәт, кызым! Күптән шулай гына әйткән булсаң.

Б ә д р и *(тынычланып).* Без бит синең бәхетең өчен тырышабыз... Ярый әле, соң булса да, акылга килдең. Исмәгыйльгә барырга риза булдың бит инде? Әнә Исмәгыйль үзе килә. Елаганыңны белдермә! Кара, уйлап сөйлә!..

И с м ә г ы й л ь керә.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Б ә д р и, Г а л и м ә, Г а л и я б а н у, И с м ә г ы й л ь.

И с м ә г ы й л ь. Исәнме, Галиябану!

Галиябану баш ия. Эндәшми.

Б ә д р и *(ачык чырай белән).* Насыйп булса, иртәгә никах укытырбыз инде, кияү. *(Галиябану сискәнеп китә.)* Бала бит әле, ялгышкан гына. Төшендереп биргәч, бик куанып риза булды.

И с м ә г ы й л ь *(куанып).* Эш булдымыни?

Г а л и м ә. Синең кебек егет булганда бик куанып инде.

И с м ә г ы й л ь *(иркәләп кенә).* Шулаймыни, Галиябану туташ?

Галиябану эндәшми.

Б ә д р и. Ул ояла инде.

И с м ә г ы й л ь. Алайса, кулыңны гына бир!

Г а л и я б а н у *(кулын биреп).* Җаның тыныч булсын!

И с м ә г ы й л ь. Менә рәхмәт.

Картлар куанышалар.

И с м ә г ы й л ь. Ярый, бүгенгә мин киттем. Калганы иртәгә. Хушыгыз!

Пәрдә

ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Беренче картинадагы күренеш. Төн уртасы. Ай нурлары коя. Тынлык. Акрын гына Исмәгыйль керә.

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль ялгыз.

Исмәгыйль. Йоклыйлар. Тик мин генә йоклый алмыйм. Ник килдем мин монда? Мине монда көнчелек китерә. Көнләү генә дә түгел, курку китерә... Хәлилдән сакларга кирәк. Төнлә килеп, Галияне тагы айнытып йөрмәсен... *(Бик горурлык белән.)* И Хәлил, көчле белән көрәшмиләр аны! Имеш, аны Галиябану сөя. Инде менә сөеп карасын. Мин аны ничек тота белермен! Әгәр юньгә килми икән, миңа нәрсә? Соңыннан ник миңа димәгәе чәнчелми... Миңа намус кыйбат. Миңа исемне җуймау кыйбат... Миңа Исмәгыйль отылды дигән сүзне ишетмәү кыйбат. Йоклыймы икән үзе? *(Акрын гына барып, тәрәзәдән карап килә.)* Йоклый, ахры... Урынына йөзтүбән яткан. Елый-елый йоклап киткәндер. Әйдә ела! Кичә бик шәп идең әле. Ерак бара алмадың шикелле... *(Чыбыклар чытырдаган тавыш ишетеп.)* Бу ни?.. Берәү килә, ахры... Хәлилдер... Мөгаен, шул булыр, кем килсен бүтән?.. *(Карап.)* Хәлил. Ярый кил! Мин сиңа кемлегемне танытыйм. *(Кесәсеннән револьверын алып.)* Күп шаяра башласаң, мин сине моның белән дә сыйлый белермен! *(Агачларга ышыклана.)*

Акрын гына басып, як-ягына карана-карана, сакланып кына Хәлил килеп керә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль, Хәлил, Галиябану.

Хәлил *(сәхнә уртасына туктап)*. Ни хәлләр бар икән бу йортта? Эшләр башкача әйләнгән булып, саклап торып харап итә күрмәсеннәр. *(Галиябану тәрәзәсенә барып, сузылып карый, сакланып кына тәрәзәне чиртә. Тагы чиртә, тәрәзә ачыла.)*

Галиябану. Хәлил, килдеңме?

Хәлил. Йә, эшләр ничек?

Галиябану. И җаным, мине Исмәгыйльгә барырга көндерер өчен күрсәтмәгәнне калдырмадылар.

Хәлил. Мин әйткәнчә эшләмәдеңмени?

Галиябану. Монда башта ук зур ялгышлык булган. Әтиләр мине Исмәгыйльгә бирдек дип белгәннәр. Риза булган булып, эшне чак юнәттем.

Хәлил. Мин атлар, кешеләр алып килдем. Куралар артында гына тора. Китик, алайса, тиз!

Исмәгыйль, револьверын тотып, атылып чыкмакчы була. Тагы тыела. Галиябану тәрәзәдән төшә, Хәлил күтәреп ала.

Исмәгыйль *(чыдый алмый, эсләренә атыла язып)*. Бетерәм!

Галиябану. Бик куркам. Кешеләр килеп тотсалар, ни хәл итәрбез? Хәерле генә булсын инде!

Хәлил. Йә, киттек...

Галиябануны биленнән тоткан көе йөгереп китә башлыйлар. Исмәгыйль, револьверлы кулын кесәсенә тыгып, тып итеп алларына килеп баса. Болар кире чигенәләр.

Галиябану *(бик куркып)*. Ах!

Исмәгыйль *(бик каты ачу белән)*. Җибәр Галиябануны!

Хәлил. Ник җибәрим мин аны!.. *(Китмәкче була.)*

Исмәгыйль *(револьверын төзәп)*. Кузгалма! Бир яхшылык белән Галиябануны!.. Йә Галиябануны бирәсең, йә җаныңны!

Хәлил *(бик аптырап)*. Уйла, зинһар, Исмәгыйль. Мине үтергән белән барыбер Галиябануны ала алмыйсың бит...

Исмәгыйль. Анда синең эшең булмасын! Син менә үз хәлеңне тикшер. Ташлыйсыңмы яхшылык белән юкмы?

Галиябану. Зинһар, Исмәгыйль абый, безне җәберләмә!

Исмәгыйль. Сез минем алдымда калтырап торырга тиеш икәнне генә беләм. Һәм менә шуны күзем белән күреп торам. *(Револьверын Хәлилнең маңгаена китереп.)* Менә Исмәгыйльнең кулы бу җирдән вәгъдәләрегезнең көле күккә очканнан соң гына алыныр...

Галиябану *(хәлдән таеп)*. Атма! Атма!

Исмәгыйль. Кит Хәлилнең яныннан. Ташла аны! *(Хәлил белән Галиябану, нишләргә белми, аптырашып торалар.)* *(Исмәгыйль сул кулы белән Галиябануның кулына ябыша: Галиябану тартыла; көч белән тартып алып, Хәлилгә.)* Инде Галиябану миндә. Син үзеңнең язмышыңны билгелә! Йә туры гына чыгып кит, йә дөнья белән исәнләш! Бер минут срок сиңа...

Хәлил кинәт Исмәгыйльнең өстенә очып куна. Исмәгыйль атарга өлгерә алмый кала. Револьверы җиргә төшә. Икәү алыша башлыйлар. Ахыр Исмәгыйль, Хәлилне җиргә егып, өстенә атлана. Ләкин Хәлил җирдәге револьверны алып өлгерә дә яткан җиреннән өстендәге Исмәгыйльгә төзи.

Исмәгыйль *(кире чигенә биреп)*. Шаярма дим минем белән!

Хәлил. Тор! Атам!

Исмәгыйль. Уйнама дим! *(Акрын гына тора.)*

Хәлил *(револьверын төзәгән килеш торып)*. Менә инде хәзер син минем кулда. Инде мин синең язмыш белән уйныйм. Бездән каласыңмы? Юкмы?

Галиябану *(Хәлилгә килеп ябышып)*. Ай, үзеңне харап итәсең. Атма, зинһар! Атма дим, Хәлил! Ташла җиргә аны! Ташла, зинһар, ташла!

Исмәгыйль. Йә, күрсәт егетлегеңне.

Хәлил. Синең кебек этне атарга хурланам. *(Револьверны җиргә бәрә.)*

Исмәгыйль револьверга ташлана.

Ал, иманың булмаса, шул җиргә ташланган алтатарны!

Исмәгыйль. Кит, сөйләнмә! Тыясыңмы телеңне? Китәсеңме яхшы чакта?

Галиябану. Имансыз ук икәнсең!

Исмәгыйль. Китәсеңме дим?

Хәлил, ике бармагын кабып, әче итеп сызгыра.

Исмәгыйль *(револьверын төзәп)*. Стоп! Ә, син шулаймыни?!

Галиябану *(кулын сузып, Исмәгыйльгә каршы йөгереп)*. Зинһар, Исмәгыйль абый!.. *(Аягына егылып.)* Кызган!

Хәлил. Ялынма ул эткә!

Исмәгыйль *(ачуыннан буылып)*. Ә, этме?!

Хәлил. Эт син! *(Кесәсеннән пәке чыгарып, Исмәгыйльгә һөҗүм итә.)*

Исмәгыйль. Мә, алайса! *(Атып җибәрә.)*

Хәлил чалкан килеп төшә.

Галиябану *(сикереп торып, әче тавыш белән кычкыра)*. Ах!

Хәлилнең шаһитлары Сибгать белән Хәмзә йөгереп киләләр.

ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Исмәгыйль, Хәлил, Галиябану, Сибгать, Хәмзә.

Хәмзә. Ни булды, ни булды?

Хәлилне карыйлар. Хәлил газаплана. Исмәгыйль шашып кала. Качарга да, качмаска да белми. Галиябану Хәлилгә ташлана.

Сибгать *(каты тавыш белән кычкыра).* Килегез! Кеше үтерделәр!

Исмәгыйль. Ник кычкырасың! Ул үзен үзе атты.

Галиябану *(күтәрелеп).* Хәлилне Исмәгыйль атты.

Исмәгыйль. Алдама!

Сибгать. Син аткансың, бәдбәхет!

Хәмзә *(читкә карап).* Бар,бар, Ибрай абзый, кире йөгер! Старшинаны чакырыгыз! Үтереш!

Өй яктан күлмәк-ыштаннан гына Бәдри, эчке киемнәрдән Галимә, аларның артыннан Гыймади йөгереп чыгалар.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәлил, Хәмзә, Сибгать, Галимә, Исмәгыйль, Галиябану, Бәдри, Гыймади.

Бәдри. Бу ни эш? Бу кайсыгыздан?

Галиябану *(елап).* Хәлил, җаным, үләсеңмени?

Хәмзә. Менә Хәлилне атканнар.

Бәдри *(Исмәгыйльне абайлап, үз-үзенә).* Ай, эшне бозган, ахры.

Йөгерә-йөгерә старшина һәм ике кеше керәләр.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шулар ук һәм старшина, кешеләр.

Старшина. Нишләдегез? Ни булды, үтерешме?

Галиябану. Исмәгыйль атты. Тотыгыз атучыны!

Соңгы килгәннәр, гаҗәпләнеп, Исмәгыйльгә карыйлар.

Исмәгыйль. Мин атмадым. Миңа бәйләнмәгез!

Старшина *(Хәлил янында яткан пәкене табып алып).* Бу нинди пәке?

Исмәгыйль. Ул... пәке... Хәлил мине атмакчы булды да, мин үземне саклар өчен пәке алдым.

Галиябану *(кычкырып).* Ялган!

Бәдри *(Галиябануга).* Тор, Галиябану, аннан! Сиңа алай утыру ярамый.

Галиябану. Зинһар, ичмасам, соң сулуларында...

Бәдри *(ачуланыбрак)*. Шаулама күп!

Старшина. Әйе, аны алып керсәгез дә ярый.

Хәмзә. Ник алып керергә? Бу эштә иң кирәкле кеше бит ул, алып китмәгез!

Старшина *(Исмәгыйльгә)*. Ничек соң ул элек сине атмакчы булып, соңыннан үзе атылды?

Исмәгыйль. Мин сезгә үзе атылды дип әйтәм бит, нигә аны төпчеп сорыйсыз. Мин үтергән дияргә сметь итәсезме әллә?

Бер кеше. Исмәгыйль нигә алай эшләсен, әйе...

Старшина. Булуын булмас... да...

Галиябану. Аз гына Ходайдан куркыгыз, белә торып бер ерткычны яклыйсыз!

Бәдри. Тик тор дим!

Галиябану *(тайпылып, тырышып-тырышып)*. Мине Исмәгыйльгә көчләп бирмәкче булдылар. Мин мәңге аңа булачак түгел. Үземне суга атып булса да, аңа бирелмәм! Мин Хәлилне генә сөям. Ул минем өчен үзен харап итте. Миңа биргән вәгъдәсен ул актык чиккә кадәр саклагач, мин дә аның хакын мәңге саклармын! *(Галимәдән ычкынып, Исмәгыйльнең алдына ук басып.)* Әйт менә, мин үтермәдем, дип, минем күземә карап, аны син үтердең! Син бит!

Исмәгыйль җавапсыз, Галиябануның күзенә карап торып, калтырап китә.

Галиябану. Инде танмакчы буласыңмы? Аны син аттың! Син үтердең!

Исмәгыйль *(ирегеп җуеп)*. Әйе, мин үтердем.

Һәммә кешедә үзгәреш.

Бәдри. Ах, Исмәгыйль, бик зур хаталык.

Галимә. Өметсез үк икәнсең! Без сиңа бердәнбер алма кебек кызыбызны бирергә йөрибез тагы, син, алайса, кеше үтерүче икәнсең!

Исмәгыйль Мин үтердем, мин аттым. Ачуымнан белешми аттым. Мин аны куркытмакчы гына булган идем, ул пәкесен чыгаргач, белешми атып җибәрдем.

Старшина *(бераз аптырап нишләргә белми торгач, кыймыйчарак)*. Алайса, без сине кулга алырга тиешлебез.

Сибгать.Үзе өстенә алып торганда, якламакчы буласызмы әллә?

Хәмзә. Тотыгыз атучыны!

Хәлил. Уф!.. Үләм.

Исмәгыйль. Мин, бу эшне эшләвемә үкенеп, гаебемне муеныма алам. Судның туры хөкеменә бирелә м.

Старшина *(кешеләргә)*. Әйдәгез, без гаепләне алып китик!

Кешеләр Исмәгыйльне тоталар.

(Калучыларга.) Сез Хәлилне карагыз. *(Пәке белән револьверны ала.)* Өлгерсәм килеп җитәрмен, килә алмасам, өенә илтә торырсыз. Әйдәгез!

Китәләр.

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Хәлил, Галиябану, Бәдри, Галимә, Гыймади, Сибгать, Хәмзә.

Хәлил. Үләм... *(Газаплана.)*

Галиябану *(елап)*. Хәлил, китәсең бит...

Хәлил. Галия... бану... *(Кулын суза.)* Кил... Үләм...

Галиябану *(Хәлилнең башын кочагына алып, елап)*. Шулай ук аерылабызмыни?!

Хәлил *(өзеп-өзеп кенә)*. Инде үлсәм дә... үкенмим, Галиябану, сылуым... иркәм, җан... бирәмен... куе...ның...да... *(Үлә.)*

Галиябану. Үлде. *(Елый.)*

Галимә *(елап)*. И Ходаем, изге җаннардан ит!

Сибгать *(кулының тамырын тотып карап)*. И дускай, үлдең бит!

Хәмзә. Хуш, иптәш, мәңгегә!

Бәдри. Алып китәргә кирәк инде. Гыймади, бар, син тизрәк ат җик!

Гыймади китә. Хәлилне сузып салалар.

Галиябану *(Хәлилнең янына тезләнеп)*. Хуш, җаным. Күңелемнең иң тирән җиреннән, каршымда син бар вакытта гына килеп чыга алган, син «Галиябану» дип атаган көй минем бердәнбер юанычым булып калды. Моннан соң бу көйне сине сагынып җырлармын. Синең төсең итеп тотармын... Хәлил! Бу көйне синең өчен генә җырлый алган идем. Менә шуны җеназаң өстендә синең исемеңә мәңгелек бүләк итеп багышлыйм... *(Бу вакыт ерактан скрипкада «Галиябану» көен уйнаган тавыш ишетелә. Һәммәсе дә тын гына тәэссорат белән тыңлап торалар. Бераздан Галиябану бик моңлы итеп кушылып җырлап китә.)*

Пьесаның эчтәлеге

Драманың эчтәлеге конфликттагы якларны өйрәнеп табыла. Сюжет сызыкларының берсендә конфликт Бәдри белән Галимәнең ялгышына нигезләнә. Алар кызлары белән конфликтка керәләр — Галиябануны, ирексезләп, яратмаган кешесенә кияүгә бирмәкче булалар. Сюжет сызыгының икенчесендә Исмәгыйль Галиябану һәм Хәлил белән конфликтка керә. Конфликт сәбәпләрен эзлибез. Бәдри белән Галимә ни өчен кызларының бәхетенә каршы төшәләр?

Бәдри авылда хәлле хуҗалардан санала. Үзсүзле. Каршы әйткәнне яратмый. Хатыны белән киңәшкән сыман итсә дә, барыбер үзенчә эшли. Ачуын тыя алмыйча, кызына сугып җибәрүдән дә тартынмый. Әмма Исмәгыйль янында бөтенләй башкага әйләнә. Тавышын үзгәртә, бутала, ялагайлана. Бәдри холкындагы бу сыйфатларда укучылар каршылык күрергә мөмкиннәр. Аңлатып китик. Бәдринең үз-үзен тотышында бернинди дә каршылык юк. Башкалардан өстенлеген күрсәтергә яратучы кеше һәрвакыт үзеннән көчлерәк, яки дәрәҗәлерәк кеше алдында җебеп кала, ялагайлана.

Бәдри акча дигәндә бернәрсә белән дә исәпләшми. Кызының бәхетен ул мең сумга бик шатланып сата. Әйткәннәрдән мондый нәтиҗә чыгарабыз. Бәдри — үзе турында гына кайгырта, үзе өчен генә яши торган, намусын әллә кайчан югалткан бер кеше. Ягъни рухи яктан буш кеше. Бәдринең бер генә нияте бар — кызын сатып булса да баю. Ә баю аңа дошманнарыннан үч алу өчен, мактану өчен кирәк. Бу әсәрдә без кабат зур дәрәҗәгә дәгъва кылган буш кеше белән очрашабыз. Мондый типлар сатирик әсәрләр материалы дигән идек. Мирхәйдәр Фәйзи Бәдрине көлке персонаж итеп сурәтли дә. Әмма әдип сатирик әсәр язмаган. Бәдри кебек дәрәҗәгә омтылучы бушкуыкларның башкалар өчен күпме бәхетсезлек китерүен тасвирлаган.

Галимәнең күңелендә кешелек чаткылары калган әле. Ул вакыты белән кызын кызгана, артык комсызланмый да. Бирнәгә ике йөз сум бирүгә дә риза була. Әмма акча дигәндә, аның да кешелек сыйфатлары бик тиз юкка чыга. Ул да, акчалы булып, яхшы күлмәкләр кию, авыл халкын шаккатыру турында хыяллана. Галимә — иренең сыңары. Аның үз фикере бөтенләй юк.

Исмәгыйльнең мин-минлеге чиктән ашкан. Үзенең башкалардан өстенлеге турында ул теләсә кайда, теләсә кемгә зур бер

канәгатьлек белән сөйли. Үзен һичкем тел-теш тидерергә хакы булмаган, ни теләсә шуны эшләргә тиешле бер кеше дип уйлый, бу ышанычын тартынмыйча әйтә. Ни өчен Исмәгыйль үзенең башкалардан өстенлегенә шулкадәр ышанган соң? Ул — авылда иң бай, хуҗа кеше. Акчага теләсә нәрсәне, теләсә кемне сатып алып булуына инанган бай. Шуңа күрә авылның иң матур кызын да, старшинаны да сатып ала алуына аз гына да шикләнми. Исмәгыйльне акча күплеге кешелексез иткән. Бу фикер белән килешик тә әсәрнең үзенә мөрәҗәгать итик. Әгәр дә башкалар акчага сатылмый торган булсалар, бай алдында тәлинкә тотуны хурлык дип исәпләсәләр, Исмәгыйль акча белән теләсә нинди максатка ирешергә мөмкин дип уйламас иде һәм бу кадәр тәкәбберләнмәс тә иде. Исмәгыйль,— яшь булса да, дөнья күргән кеше. Ул үзен күрү белән билен бөгеп каршы алучы, теле тотлыга-тотлыга сәламләүче һәм акчага кызын гына түгел, хатынын да, үзен дә сатарга торучы Бәдриләрне дә, старшина кебек байлык алдында калтырап торучы түрәләрне дә күп күргән. Сатлык җаннарның, ялагайларның күплеге Исмәгыйльне ничек бар, шулай тәрбияләгән. Мин-минлек, тәкәбберлек аның холкына әйләнгән. Өстәвенә Исмәгыйль — ялганчы да. Ул, күрә торып, Хәлил үзен үзе атып үтерде, ди. Димәк, Исмәгыйль моңа кадәр дә күп мәртәбәләр ялган сөйләгән. Кешеләр, аның ялганына ышанмасалар да, ышанган булып кыланалар. Бәдри дә, старшина белән килгән кешеләр дә аның ялганына ышанырга торалар. Ялганчы, тәкәббер, башкаларны санга сукмыйча, үзен генә кайгыртып йөрүчеләргә буш кеше диләр. Шулай итеп, Исмәгыйль дә башкалардан өстен булырга тырышучы буш кеше булып чыга.

Исмәгыйльнең дә, Бәдринең дә, Галимәнең дә эчке конфликтлары юк. Алар, ни эшләсәләр дә, үзләрен хаклы дип уйлыйлар. Өчесе дә — рухи яктан ярлы кешеләр. Өчесе дә дәрәҗәгә дәгъва кылалар.

Сорау һәм биремнәр

1. Бәдринең кызы ихтыярына каршы төшүе акча өчен генә булмавын исбат итегез.

2. Исмәгыйльнең Галиябануга өйләнергә ниятләве аны яраткан өчен булмавын исбат итегез.

3. Исмәгыйль белән Бәдри — сезгә таныш типлар. Андый типларны нинди әсәрләрдә очраткан идегез?

Нәтиҗә ясыйк. Үзләрен генә кайгырткан, дәрәҗә артыннан куучы кешеләр башкалар теләген исәпкә алмыйлар. Татар әдипләре шундый типларның асылын ачуны җәмгыять өчен әһәмиятле чара дип уйлыйлар. Җәмгыятьнең чире шундый типларның күп булуында дигән фикердә торалар.

4. Соңгы нәтиҗәне ничек исбат итәр идегез?

Конфликтларның икенче ягы — Галиябану.

Галиябану — чынлап торып ярата алучы кыз. Ул Хәлилне генә ярата. Үзенең шундый матур, көчле хисе өчен башкалар алдында кыенсына да. Ләкин мәхәббәтен берәүдән дә яшерми. Аны бөтен авыл яшьләре матур дип мактый. Галиябануның чын матурлыгы исә тышкы кыяфәтендә генә түгел, җаны-тәне белән ярата белүендә, мәхәббәтенә тугрылыгында, батырлыгында.

Галиябану — тыйнак, оялчан кыз. Ул әти-әнисеннән дә, авыл кешеләреннән дә ояла. Әмма үзенең мәхәббәте өчен көрәшкәндә, берәүдән дә куркып тормый. Ул — горур кыз. Аны Исмәгыйльнең дәрәҗәсе дә, байлыгы да кызыксындырмый. Кияү булырга дәгъва кылып йөрүче байның кемлеген ул бик яхшы белә. Хәлилнең иске йортында, ләкин яраткан кешесе белән гомер кичерүне барыннан да өстен күрә.

Дәреслек вариантында су буендагы яшьләр уены күренеше төшереп калдырылды. Авыл егетләренең шаянлыгы, дуслыгы күбрәк шул күренештә ачыла. Егетләр һәм кызлар бер-берсенә карата шәфкатьлеләр, игелеклеләр. Алар Галиябану белән Хәлилне авылның иң матур һәм иң уңган кызы һәм егете дип таныйлар. Ләкин алардан аз гына да көнләшмиләр. Киресенчә, икесенә дә бәхет телиләр, дусларының кавышуына чын күңелдән шатланалар. Дусларына теләсә кайчан ярдәмгә килергә торалар. Исмәгыйльне старшина яклап маташканда да, авыл егетләре аяк терәп старшинага каршы төшәләр. Исмәгыйльдән дә, старшинаның үзеннән дә шүрләп калмыйлар.

Хәлил белән Галиябану авыл егетләренә һәм кызларына табигый шәфкатьлелекләре, гадилекләре һәм беркатлы булулары белән охшаганнар. Алар — ирекле табигать балалары. Бәдриләр, Исмәгыйльләр, Галимәләр кебек үзләрен өстен итеп күрсәтергә тырышмыйлар. Тормышның матурлыгын, милләтнең элеккедән сакланып калган рухи байлыгын Мирхәйдәр Фәйзи авыл егетләрендә күрә.

Сыер югалу вакыйгасы пьеса сюжеты белән бөтенләй бәйләнмәгән. Шуңа күрә бу күренешнең кирәге юк кебек. Әмма Мирхәйдәр Фәйзи әсәренең барлык басмаларында да бу эпизодны үз урынында калдыра бирә. Нигә шулай итә?

Без әсәр сюжетыннан читтә торган вакыйгаларның башка вакыйгаларга бәя бирүче метафора булуын беләбез.

5. Үзегезне сынагыз. Өченче пәрдәнең икенче күренеше башындагы конфликтның мәгънәсе ни булырга мөмкин?

Йомгак

XX йөз башы әдәбиятының үзенчәлеген табыйк. Моның өчен аны бөтен бер күренеш итеп күзаллыйк. Шулай итсәк, аерым язучылар иҗаты шул бөтеннең өлешләре булачак. Бөтеннең үзенчәлеге өлешләре арасындагы бәйләнештә табылуын сез инде беләсез.

Бәйләнеш, беренче чиратта, өлешләрнең уртак якларында табыла. Шулай итеп, язучы иҗатларының уртак якларын эзлик. Уртак сыйфатларны бу чорда язган Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Шәриф Камал, Сәгыйть Рәмиев, Шәехзадә Бабич, Нәҗип Думави, Садри Җәләл иҗатларыннан да таба алабыз. Алар белән сез 7—8 нче сыйныфларда танышкан идегез.

Бу чорда иҗат иткән әдипләр иҗатындагы **уртак идея** — кешеләрне бәхетле итү. Кешене ничек бәхетле итәргә? Әдипләр икеләнүсез: шәхес милләтне тәрәккый итү (чәчәк аттыру) юлы белән генә бәхетле була ала дип җавап бирделәр. Шуңа күрә бу чорда иҗат ителгән әсәрләрнең **уртак темасы** милләтне үстерү булды.

Шәхес бәхетен милләт язмышы белән бәйләп карау XX йөз башы әдәбиятының бер үзенчәлеге дия алабыз.

Аерым шәхесне бәхетле итү өчен, милләтне икътисади (экономик) һәм мәдәни яктан үстерергә кирәк. Ә менә милләтне ничек үстерергә? Әдипләр әсәрләрендә кат-кат күтәрелгән **проблема** шуннан гыйбарәт.

1905 елгы революциядән соң татарлар арасында милли хәрәкәтләр башлана. Милләт эчендәге сыйныфларны үзара сугыштыру юлын алга сөргән эсерлар һәм большевиклар партияләре барлыкка килә. Бу партия вәкилләре азатлыкны көрәш белән яулау нәтиҗәсендә генә милләтне үстерергә мөмкин дип уйлыйлар. Сыйнфый көрәш идеясе әдәбиятка да

килеп кирә. Мәсәлән, драматург Гафур Коләхмәтов пьесаларының («Ике фикер», «Яшь гомер») идеясе революцион көрәшкә чакырудан гыйбарәт.

Үз вакытында Сәгыйть Рәмиев тә, Гаяз Исхакый да, хәтта сабыр холыклы Фатих Әмирхан да милләтне революция генә бәхетле итә ала дигән фикердә торалар. Әмма соңрак бу ниятләреннән кире кайталар.

Әдипләр яхшылыкны милләтнең борынгыдан килгән әхлакый ныклыгы саклануда күрделәр. Халыкка игелек күрсәтүче, аңа риясыз хезмәт итүче, милләтне үстерүдә көчен кызганмаган кешеләрне мактадылар. Намусларын югалткан, икейөзле, үз эченә бикләнгән, милләтнең мескен хәленә битараф калып, ярдәмгә мохтаҗ кешеләрне күрмәүчеләрне яманлык дип бәяләделәр. Кешеләрнең үз мәнфәгатен генә кайгыртуларын милләтнең фаҗигасе итеп кабул иттеләр. Бу фаҗига язучыларның үзләренә күчте һәм иҗатларының эчтәлеген тәшкил итте.

Милләтнең барлык кимчелекләрен бергә җыеп, язучылар «йоклау» дип атадылар. Халыкны йокысыннан уяту өчен көчләрен дә, сәламәтлекләрен дә кызганмадылар.

Габдулла Тукай «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» исемле мәкаләсендә: «Без ул милләткә әдәбият гөлсулары сибик, газета веерлары илә йомшак җил истерик һәм авызына берләшү сулары салыйк; хәтта рәсемнәр илә милләтнең үз сурәтен үзенә күрсәтик; тәмам күзе ачылсын»,— дип яза.

Шагыйрь сүзләрен тагын бер тапкыр игътибар белән укып чыксак, анда өч нәрсә турында әйтелүен күрербез: 1) милләтне мәгърифәт белән назлап; 2) берләшү даруы белән уятып; 3) үз кыяфәтен үзенә күрсәтеп оялтырга мөмкин, ди Габдулла Тукай. Кешеләрне мәгърифәт ярдәмендә әхлаклы итү карашы XX йөзгә алдагы чор әдәбиятыннан күчкән караш дия алабыз. Хәзер Тукай әйткән ысулларның калган икесенә тукталыйк.

Иттифакъ (берләшү) сүзенә әдипләр мөһим әхлакый эчтәлек салалар. Габдулла Тукай «Иттифакъ хакында» шигырендә берләшүнең үзе күз алдында торткан эчтәлеген: «Ваз кичик мин-минлектән; Көчле-көчсез тиңлектән файда алыйк, бәдәвам; Бетсен, кадалсын икейөзлелек; Бүлик без бер алманы бишь кисәккә; Бер-беребезгә ут атмыйк, бер-беребездән качмыйк»,— ди.

Берләшү темасының Тукай күрсәткән эчтәлеген әдипләр әле бер яктан, әле икенче яктан ачалар. Кешеләрне бер-

берсеннән аерган, дошманлаштырган якларын: мин-минлекләрен, шәфкатьсезлекләрен, игелексезлекләрен, усаллыкларын гарьләнерлек кыяфәттә сурәтләп, үзләренә күрсәтәләр.

Галимҗан Ибраһимов әсәрләрен искә төшерик. «Көтүчеләр», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карт ялчы», «Карак мулла» хикәяләрендә үз эчләренә йомылган, кешеләрдән читләшеп, үзләре уйлап чыгарган хыял дөньясында яшәүче типларны күрдек.

Фатих Әмирхан «Нәҗип», «Ул үксез бала шул!», «Корбан», «Сәмигулла абзый», «Габделбасыйр гыйшкы» хикәяләрендә көнчелек, мактану, иркәләнү, тәкәбберләнү кебек, кешеләрне кешедән аера торган сыйфатлар турында яза.

Шәриф Камал да берләшүнең үзе яхшы белгән, үзгә ягын сурәтли. «Буранда», «Сукбай», «Әүвәл-әүвәл заманда» хикәяләрендә, «Акчарлаклар» повестенда туганнарын, илләрен ташлап киткән читтәге кешеләрне үз илләренә кайтырга чакыра. Газизә авызыннан «Акчарлаклар»дагы Сафа белән Солдатка: «Илдә аналарыгыз зарыгып көтә торганнардыр... Кайтып, аларны кинәндерегез, ичмасам»,— дип, ә Гарифка: «Авылыңа кайт, Гариф абзый, авылыңа кайт, яме?! Туганнарың көтәләр булыр»,— дип үгет бирдерә.

Нәҗип Думави, Сәгыйть Рәмиев, Дәрдемәнд — һәркайсы халыкның рухи ныклыгы какшавына борчылалар.

Гаяз Исхакый, буржуаз мөнәсәбәтләр урнашу сәбәпле, милләтнең беркадәр җанлануына сөенә. Ләкин бу җанлануның халык күңелендә сакланган әхлак нигезләрен какшатуын да күреп ала. Вак җанлы, әмма зурга дәгъва кылучы кешеләрнең күбәйгәннән-күбәя баруына борчыла һәм, татар әдәбиятында беренчеләрдән булып, милләтнең шул яман йөзен бөтен ямьсезлеге белән үзенә күрсәтергә керешә. «Кияү», «Җәмгыять» әсәрләрендә шундый типларның төрле иҗтимагый төркемнәрен тасвирлый.

Тәкәбберлек, көчлеләр алдында тәлинкә тоту, дәрәҗә артыннан куу сыйфатларының йә көлкегә, йә фаҗигагә әйләнеп, кешеләрне бер-берсеннән читләштерүне Габдулла Тукай, Идрис Багданов, Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи дә фаш итә.

Халыкны берләштерү юлы белән торгынлыктан кузгату татарларның үз ихтыярына бәйле булганга, әдипләр, беренче чиратта, игътибарларын шуңа юнәлтәләр. Әмма халыкны уяту гына аны бәхетле иттем дигән сүз түгел әле. Дәүләте, хөкүмәте булмаган милләт феодаль кануннарга буйсынып

яшәүдән баш тарткан очракта да буйсынган колония булып калачак.

Ирексез халык бәхетле була алмый. Татар укымышлылары бу хакыйкатьне яхшы белгәннәр. Шуңа күрә берләшүнең дәвамы ирек алу дигән фикердә торганнар.

Гаделлекне иманнары итеп санаган язучылар рус халкын чит итмиләр. Киресенчә, бөек рус мәдәниятен, телен өйрәнергә чакыралар. Милләткә ирекне патша хөкүмәтеннән таләп итәләр. Габдулла Тукай:

Без сугышта юлбарыстан көчлебез,
Без тынычта аттан артык эшлибез.
Шул халыкныңмы хокукка хаккы юк? —
Хаклыбыз уртак ватанда шактый ук! —

дип сорый да үзе үк җавап та бирә. Ә «Китмибез!» шигырендә:

Иң бөек максат безем: хөр мәмләкәт — хөр Русия! —

дип, бөтен рус иленә ирек даулый.

Милләтне уятуның ике баскычын Сәгыйть Рәмиев «Юк, үлмим! Торам әле!» мәкаләсендә язган: «Менә, Алла теләсә, татарлар да кеше булырлар, татарларның да күңелләренә рәхмәт салыныр, нур керер, татарларның күзләрендә дә мәхәббәт йолдызлары ялтыраганын күрәчәк көнемез булыр... Шушындаен саф көмеш кебек ак өмидләремнең ахыры тигезлек, дуслык, мәхәббәт булачак...» — дигән.

Галимҗан Ибраһимов та милләттәге бозыклыкны тормышның үзеннән күрә: «Бозыклыкка «нә татарлык, нә руслык гаепле — ул тормышның хәзергәчә капитал вә милеккә корылган булуыннан килгән бер һәлакәттер»,— дип яза.

Бу чорда татар халкы, әлбәттә, язучылар тәнкыйтьләгән дәрәҗәдә бозык түгел иде. Әдипләр халыкның икътисади һәм мәдәни үсешен ата-бабалардан мирас булып калган рухи байлыгын саклаган хәлдә генә күз алдына китерделәр. Шуңа күрә әхлак кагыйдәләрен бозучыларга, иске тәртипләргә ябышып ятучыларга каршы рәхимсез көрәш ачтылар. Татар милләте шулкадәр аяусыз тәнкыйтькә фәкать шушы чорда гына дучар була.

Бу тәнкыйть татар милләтенең үзаңы үсүе, үзенә читтән торып бәя бирү дәрәҗәсенә җитүе иде.

Иманы нык булган милләт кенә үзен үзе шулай рәхимсез рәвештә тәнкыйтьли ала.

Бу чорда иҗат иткән әдипләрнең киләчәктә көтелгән **иң зур теләкләре, ахыр максатлары алга киткән, ирекле, бәхетле милләт иде.** Шуңа күрә бу теләкне һәм максатны чорга хас идеал дибез.

Идеалга якын торган яки хезмәт иткән кешеләр матурлык буларак макталды. Әдипләр милләтнең үзен үзе күтәрә алу көченә ышаналар. Борынгы бабайларның куәтле мөстәкыйль дәүләт булып яшәүләрен шуңа дәлил итеп исәплиләр. Борынгыларның көчен, куәтен, дәртен җае туры килгән саен искә алалар.

Габдулла Тукай «Шүрәле» әкиятендә зур, чиксез урман матурлыгын язганда кинәт чигенеш ясый һәм, кылт итеп искә төшәдер карт бабайларның исемнәре, дәүләтләре, батырлыклары. Нигә соң без болай яшибез дип көрсенеп куя.

Галимҗан Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» исемле хезмәтендә Сәгыйть Рәмиевне ирекле шәхесне һәммәсеннән өстен итеп күрсәтүе өчен мактый. Аның иреккә омтылу сыйфатын борынгы бабайлардан килгән күркәм сыйфат дип бәяли: «Буңардан борынгы татар каны, татар куәте исе килә, ул куәт, ул йөрәклелек бездә бөтенләй бетмәгәнлеге күрелә»,— ди.

Кеше матурлыгын да әдипләр беренче чиратта милләткә хезмәт итү дәрәҗәсенә карап бәялиләр. Үзләрендә милләтне кузгатырлык эчке көч туплаган кешеләр турында язалар. «Хөрмәтле Хөсәен ядкяре» шигырендә Габдулла Тукай Хөсәен Ямашевны «көч белән бергә гүзәллекне җыйган диңгез кебек» дип бәяли. «Ул көрәште һәм явыз эшкә җәза бирде көлеп», ди. Ләкин алай да игътибарны рухи матурлыкка юнәлтә: «Көчле, көчсез, ярлы, бай булды һаман да бер аңар» дип — гаделлеге, «Үтте тормыш пычрагын гәүһәр кебек вөҗдан белән» дип — намусы, «Буш куыклар атмагач» дип, табигыйлеге турында сөйли.

Бу чорда **табигыйлек,** гомумән, матурлыкның бик мөһим сыйфаты булып санала.

Табигать — туган җир табигате булганга, туган авыл — туган урын булганга, хәтта ярлы, ямьсез булса да, үзенең табигыйлеге белән матур. Фатих Әмирханның Хәяты, Садри Җәләлнең Фәридәсе табигатьнең үзе кебек табигыйлекләре белән чибәрләр. Татар язучылары, кызлар матурлыгын күкләргә чөеп мактасалар да, тешләренең кыеклыгын өстәп булса да, аның гап-гади бер кыз булуын кисәтеп китүне кирәк табалар.

Ә ямьсезлекне әдипләр милләтнең үсүенә каршы торучыларда, икейөзлелектә, байлар алдында тәлинкә тотуда күрәләр.

Бу чорга хас фәлсәфәнең, идеалның, матурлыкның милләт җирлегендә барлыкка килүе чынбарлыкны үз агышында һәм каршылыгында тасвирлауга ярдәм итте. Язучылар шулай иттеләр дә. Хәтта хыялында йөрткән ирек дөньясы турында язарга яраткан Сәгыйть Рәмиев белән тормышны фәлсәфәсе калыбына сыйдырырга тырышкан Дәрдемәнд тә җирдә нык басып тордылар. Ә хыялый дөньяларын һәм фәлсәфәләрен тормыш ямьсезлеге уяткан авыр тойгыларыннан качу, юану өчен тудырдылар.

Шуңа күрә бу чордагы татар язучылары р е а л и з м методы белән иҗат иткәннәр дибез. Татар әдәбиятының реализм методына күчүе аның зур казанышы булды.

Мәдәниятләре нык алга киткән дәүләтләрдә, бигрәк тә рус дәүләтендә, реализм күптән үз кагыйдәләрен булдырып, алымнарын табып куйган иде инде. Татар язучылары реализм методы туплаган сәнгать алымнарын беренче чиратта рус әдипләреннән өйрәнделәр. Татар язучыларының аеруча ратып кулланган алымы метафора булуын күрдек.

Әсәр эчтәлеген вакыйгаларның, сүзләрнең үзара бәйләнешенә салу XX йөз башы әдәбиятының стиль үзенчәлеге дия алабыз.

Тормышның эченә, кеше күңеленең түренә үтәргә омтылу бу чор әдәбиятының күңел ихатасын (мәйданын) җирне, күкне, бөтен галәмне сыйдырырлык дәрәҗәдә киңәйтте. Вакыт тәртипкә китерелде һәм әсәр эчтәлегенең табигый бер өлешенә әйләнде.

Чорлар бәйләнеше

Ф ә л с ә ф ә

Яман сыйфатларга каршы көрәшеп, тәрбия ярдәме белән кешеләрне татулыкта яшәтү сез өйрәнгән чорларның барысы өчен дә уртак максат булды. Яманлык һәм яхшылык төрле чорларда төрлечә аңлатылса да, аларның төп эчтәлеге үзгәрмәде. Яманлык һаман әхлаксызлык белән тиңләштерелде.

XX йөз башы әдәбияты берләшү идеясен күтәреп чыга. Ләкин берләшүгә дә әхлак эчтәлеген сала. Милләтнең баенярлысын, көчлесен-көчсезен тигез хокуклы кешеләр итеп карарга, дуслашырга чакыра.

Күрәсез, татар әдәбияты үзенең үсешендә борынгыдан килгән фәлсәфәсен алыштырмый. Киңәйтә, тирәнәйтә, тормыш таләпләренә туры китереп конкретлаштыра гына бара.

Метод

Татар әдәбиятының борынгы чорындагы эчтәлеге бик гомуми (абстракт) әхлакый кагыйдәләрнең мөһимлеген исбат итүдән гыйбарәт.Сюжет вакыйгалары исә максатка буйсындырып уйлап чыгарыла. Соңга таба әдипләрнең тормыш белән кызыксынулары артканнан-арта бара. Алдагы чорларда язучылар тормышны ныклап өйрәнергә керешәләр. XX йөз башында иҗат иткән әдипләр инде әхлак кагыйдәләрен кешеләрнең табигый асыллары дип исәплиләр. Һәм тормыш вакыйгаларына әхлак кагыйдәләреннән чыгып бәя бирәләр. Кешеләрнең эчке дөньясы реаль тормыш вакыйгалары кебек үк иҗат объектына әйләнә. Шуңа күрә татар әдәбияты XX йөз башында реализм методын үзләштерде, дибез.

Стиль

Борынгы әдипләр әсәрләренең төзелешләре охшаш вакыйгаларга корылуын күрдек. Әсәрләрнең мондый төзелеше (структурасы) билгеле бер хакыйкатьне тәэсирле һәм ышандырырлык итеп исбатлау өчен иң уңышлы алым иде.

«Идегәй» дастаны да гомуми эчтәлекләре кабатланып килүче вакыйгалардан тора. Әмма дастан авторлары аларны үзара бик тыгыз итеп бәйләп куйганнар. Вакыйгаларның эзлекле агышына корылган сюжет беренче мәртәбә «Идегәй» дастанында иҗат ителде.

Лирик герой татар әдәбиятына Утыз Имәни иҗат иткән чорда килеп керде. Ул әле һаман кешеләрне яман эшләрдән сакланырга, яхшылыкка өйрәтте. Ләкин, сак кына булса да, үзе турында да сүз кушты. Лирик герой хисе әле үзенең яман эшләре өчен борчылудан уза алмады. Ләкин, соңгарак калып булса да, аерым кеше шәхесе сәнгать объекты буларак әдәбиятка килеп керде һәм әдәбиятның түренә таба юл алды.

Камил лирик шигырьне беренче мәртәбә Габделҗәббар Кандалый иҗат итте. Шәхес хисен сәнгать матурлыгы дәрәҗәсенә күтәргән беренче әдип ул булды. Утыз Имәни үзенең әсәрләрендә үзен үзе тәнкыйтьләде, ә Габделҗәббар Кандалый исә үз кимчелекләреннән үзе көлү югарылыгына иреште. Татар әдәбиятына юморны беренче мәртәбә ул алып килде.

Кандалый иҗатында беренче мәртәбә әсәрләрнең традицион төзелешенә җитди үзгәреш керде. Яман эшкә җәзаны автор үзе бирде. Юмор җәза югарылыгына күтәрелде.

Хәтта кеше хисләрен табигать күренешләре аша ачу алымын да иң элек Кандалый кулланды. Соңрак татар әдипләренең аеруча яраткан алымы — метафора — «Сәхипҗамалга» поэмасыннан башланды дисәк ялгышмабыз.

Әдәбият тормыш эченә тирәнрәк кергән саен, яңа темалар, проблемалар туа. Катлаулы кичерешләр, фикерләр тасвирлауның яңа алымнарына мохтаҗ булалар. XX йөз башында татар әдәбияты «язучы — укучы» диалогына күчә. Вакыйгалар кабатлануы бу чорда да татар әдипләренең яраткан алымнарының берсе булып кала. Ләкин кабатлау хәзер кат-кат әйтеп исбат итү вазифаларын югалта. Бу алым да метафора, чагыштыру, өлешләр арасындагы бәйләнеш, әсәрнең фокусы кебек бер үк дәрәҗәдәге диалог теле булып китә. Язучылар әсәр сюжетындагы вакыйгаларны функция бәйләнеше белән ялгарга өйрәнеп җитәләр. Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Галиәсгар Камал, Дәрдемәнд һ. б. татар әдәбиятын бөтендөнья әдәбияты югарылыгына күтәрделәр.

Шул рәвешле, татар әдәбияты үзеннән күп алга киткән башка халык әдәбиятларын уңышлы гына куып барганда, 1917 елгы Февраль һәм Октябрь революцияләре була. Шул вакыйгалардан соң әдәбиятның яңа чоры башлана.

Габделҗәббар Кандалый

БУ ХӘСРӘТЛӘР БЕТӘР МИКӘН

Таң алдыннан ки йилләрдин,
Киләдер илгә илләрдин;
— Хәбәр көтәм туганнардин,—
Диеп сорыйм ки алардин.

— Әя йил, сән каян истең?
Ничә сахра үтә кичтең?
Туганымны кайда күрдең? —
Диеп сорыйм ки алардин.

— Әя йил, исмәгел бик тиз,
Минем хәлем илтеп йиткез,
Вә ләкин һич туктап калма,
Әманәттер ки безләрдин.

— Әя кош, сән күрмәдеңме?
Фәлән җирдән килмәдеңме?
Туганымны күрмәдеңме? —
Диеп сорыйм ки анлардин.

— Әя кош, сән бармы балаң,
Атаң берлән тагын анаң?
Якын итеп йөрисеңме,
Аерылдыңмы ки анлардин?

— Әя агач, яшең күпме?
Түгелгән йимешең күкме?
Миндәгедәй сагышың күпме? —
Диеп сорыйм ки анлардин.

— Ничә йимешләрең үсте?
Ничә яфракларың төште?
Ботакларың кемнәр кисте? —
Диеп сорыйм ки анлардин.

Яфраклар яшь гомер икән;
Ботаклары бала икән,
Аерылу бер бәла икән,
Бәгырь өзгән туганнардин.

Агачлардин нә чыкмагай?
Сачаклардин нә булмагай?
Бу дәрдемә дәва тапмый,—
Диеп кайттым ки алардин.

Языйм микән, йитәр микән?
Шушы кайгы бетәр микән?
Шушы кайгы, шушы хәсрәт
Күңелләрдин китәр микән?

Габдулла Тукай

МИЛЛИ МОҢНАР

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә, матур милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле,—
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Өзлеп-өзлеп кенә әйтеп бирә
Татар күңлениләр сизгәнен;
Мискин булып торган өч йөз елда
Тәкъдир безне ничек изгәнен.

Күпме михнәт чиккән безнең халык,
Күпме күз яшьләре түгелгән;
Милли хисләр белән ялкынланып,
Сызлып-сызлып чыга күңленнән.

Хәйран булып, җырны тыңлап тордым,
Ташлап түбән дөнья уйларын;
Күз алдымда күргән төсле булдым
Болгар һәм Агыйдел буйларын.

Түзәлмәдем, бардым җырлаучыга,
Дидем: «Кардәш, бу көй нинди көй?»
Җавабында милләттәшем миңа:
«Бу көй була,— диде, — Әллүки!»

ӘХЛАКСЫЗЛЫК

Бик югартын күз салырга башладык әхлакка без,
Кер күңелдә күплегеннән бармыйбыз ак якка без.

Тик хәзер, йөз сумны урлап килгүче угъры кеби,
Күз салабыз чын сүз әйтердән элек як-якка без.

Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.

КӨЗГЕ ҖИЛЛӘР

Яктырак йолдыз янадыр, төн кара булган саен;
Ядыма[1] Тәңрем төшә, бәхтем кара булган саен.

(Русчадан)

Көзге төн. Мин йоклый алмыйм. Өй түрендә җил җылый;
Җил җыламый, ач үлемнең куркусыннан ил җылый.

— Иң сөекле эшче әүладым[2] быел ач калды, — дип,
Изге, шәфкатьле анабыз — мәрхәмәтле җир җылый.

Куйса монда корткалар, төшкән тешен алтын белән,
Бер телем икмәк дип, анда назлы нечкә бил җылый!

Бер сынык юктан гына үлгән таза ирләр күреп,
Җан алырга кызганудан анда Газраил җылый.

Көлсә монда тук вә ихлассыз халык тәкбирләре[3],
Һәр ишеткән җан җыларлык — андагы тәкбир җылый.

Көзге төн, ямьсез, караңгы... Өй түрендә җил җылый,
Җил — хәбәр ул: ач үлемнең куркусыннан ил җылый!

---

[1] *Ядыма* — хәтеремә.

[2] *Әүладым* — балаларым.

[3] *Тәкбирләре* — «Аллаһе әкбәр» дип Алланы олылау (тәрҗемәсе: Алла — иң бөек зат).

Фатих Әмирхан

ГАБДЕЛБАСЫЙР ГЫЙШКЫ

1

Мәдрәсә күршесендәге йортны сатып алган яңа байның бик матур кызы барлыгын ишетү Габделбасыйр шәкерткә әллә ничек бик зур бер тәэсир калдырды.

Габделбасыйр бу байларның яңа сатып алган өйләренә күчеп килүләрен әллә нинди бер сабырсызлык белән көтте, көннәр, төннәр, атналар, хәтта айлар көтте. Беркөнне, иртә торып тәһарәткә чыкканда, ул моңар кадәр тып-тыныч була торган күрше ишегалдында әллә нинди бер хәрәкәт сизенде дә койма ярыгына барды. Габделбасыйр, шактый вакытлар ярыктан карап торып, өйгә инде ике хадимә[1] хатын килгән икәнен дә белде һәм ни өчендер бу хатыннарның берсен — яшьрәген Рәүф бай кызына хезмәт итә торган хадимә булыр дип уйлады. Ташыла торган әйберләр арасында ул бер сары калайлы сандыкны, «матур кыз» сандыгы булырга кирәк дип, күңеленә утыртып куйды.

«Бу сары калайлы сандыкның эче тулы йон һәм асыл күлмәкләрдер, бу күлмәкләрнең кайсысы ука чачаклыдыр; «матур кыз», кунакка барганда, ул күлмәкләрнең әле берсен, әле икенчесен кия торгандыр»,— дип уйланып, Габделбасыйр сандык кертелгән ишектән күзләрен алды да, теләр-теләмәс кенә ярык яныннан кузгалып, тәһарәт алырга китте.

Габделбасыйр тәһарәтен бик озаклап, бик пөхтәләп алды, битләрен, муеннарын өчәр кат сабынлап юды.

«Матур кыз» бу көн күчеп килсә дә, күрә калса...»,— диди уйлый-уйлый юынды. Кайтканда, тагы койма ярыгы тугрысына туктап, Рәүф бай ишегалдын карап торды. Габделбасыйр озакламый «матур кыз» килер инде дип ышанды һәм кыз килеп кергәндә үзенең бу ярыктан карап торганлыгын күрсәтәсе килмәде: Алла сакласын, ул моның ярыктан карап торуын теге асрауны карап тору дип аңлар да кәефсезләнер...

Габделбасыйр кесәсендә тугры килгән зәңгәр матур язу кәгазе кисәгенең бер ягын, Рәүф байлар ишегалдына күренерлек итеп, ярыкка кыстырып куйды да мәдрәсәгә кайтты.

---

[1] *Хадимә* — хезмәтче хатын-кыз.

Кереп чәй янына утыргач, Габделбасыйр үзендә оялу катыш бер кәефлелек сизде: теге «матур кыз» килеп җиткәндер һәм ярыкка кыстырып куелган зәңгәр кәгазьгә игътибар иткәндер, ул бәхетле зәңгәр кәгазь «матур кыз»ның ай кук йөзен, зифа буен күргәндер шикелле иде.

Чәйдән соң Габделбасыйр, сөлгесен муенына чолгап, базарга чыкканда гына кия торган купшы бишмәтен купшы һәм эре генә итеп иңбашына салып, тәһарәткә чыгу сылтавы белән тагы мәдрәсәдән чыгып китте, тагы теге ярык янына килде. Теге зәңгәр кәгазьне мәдрәсәдән хәзерләп алып чыккан кызыл кәгазе белән алмаштырды. «Инде «теге кыз» килгәндер, килмәгән булса да, хәзер килер... Ишегалдына чыкса, баягы зәңгәр кәгазь урынында хәзер инде кызыл кәгазьне күрер... Кызыл кәгазь бит ул зәңгәр шикелле түгел, күзгә бигрәк бәрелеп тора...» — ди-ди уйланып, Габделбасыйр тәһарәтханәгә китте.

Хәзер аңар дәрескә керергә кирәк иде. Шәкертләр һәм мөдәррис бик дикъкатьләп «кеше зиһенендә әйбер образының тууы» белән «кеше зиһенендә туган образ» арасындагы аерманы тикшерделәр. Габделбасыйр, бу дәресханәне башыннан чыгарып, Рәүф бай кызын уйларга тотынды.

«Матур кыз» түп-түгәрәк ап-ак йөзледер, чем-кара кашлыдыр, кап-кара күзледер, бик озын кара чәчледер, түгәрәк симез гәүдәледер, шоп-шома итеп таралган чәченә калфагын кәкрәйтеп киеп куя торгандыр, аягында ефәк белән каелган үкчәле читектер, өстендә зәңгәр асыл күлмәктер...» — ди-ди уйланып, Габделбасыйр үз зиһенендә үзе матур дип уйлый торган бер сурәтне ясап куйды да шуны карап кәефләнде, шуңар мәхәббәт итеп рәхәтләнде. Зиһененнән ул бу сурәткә «җаным!» дип кенә эндәшә, ул сурәт тә аңар «җаным, Габделбасыйр» диярлек төсле итеп карый иде.

«Матур кыз»ның бармаклары — кыска-кыска гына, симез генә бармаклардыр; куллары кечкенә генә, симез генәләр дә, иреннәре кып-кызыллардыр, борыны кечерәк, ләкин бераз гына очлырактыр, һәр бармагында икешәр алтын йөзектер»,— дип уйлап, ул «матур кыз»ның хәзергә кадәр әле томанлырак күренеп торган сурәтен ачыграк итеп күрә башлаган шикелле булды. «Матур кыз»ның шул күп йөзекләреннән берсен үзенә бирәчәгенә ышанды.

— Мә, җаным, сиңа бүләк!

— Бик зур рәхмәт, җаным, былбылым, менә синең үзеңә дә бүләк!

Дәрес тәмам булып, шәкертләр китапларын япканда гына, Габделбасыйр бу уйлануыннан уянып китте.

Өйләдән соң базарга чыгарга уйлагач, Габделбасыйр бик тырышып купшыланды: «эре» бишмәтне өч-дүрт мәртәбә щеткалап чыкты, берәүдән каракүл бүрек алып торды, чыгып китәр алдыннан дүрт-биш мәртәбә көзгегә карады.

Габделбасыйрның йөзе матурлык белән аерырлык түгел иде: төссез генә сары күзләр, саргылт кашлар, тәбәнәгрәк кенә борын, шактый ерынкы гына авыз, таррак кына маңлай — ике башыннан кысып сытылып, озынчалыгы вә түгәрәклеге бетерелгән шикелле дүрт почмаклырак йөз өстенә тезелгәннәр иде. Габделбасыйр үзенең бу йөзен матур дип атый алмаса да, бик мәхәббәтле дип ышана һәм аның «матур кыз»га охшаячак икәненә шикләнми иде.

Габделбасыйр Рәүф бай йорты буйлап китте. Йортның урамга карап тора торган биш тәрәзәсеннән әүвәлге тәрәзәне үткәндә, Габделбасыйр шулкадәр каушады ки, күтәрелеп, аңар карый алмады.

«Ул» беренче тәрәзә янында булгандыр, ак пәрдәнең бер читен ачып карап калгандыр», дип уйлап, Габделбасыйр шул тәрәзәгә карый алмаганы өчен, эченнән үз-үзен шелтәләде. Бу кадәр җир китеп, урамның икенче ягына чыкканда, ул, артына борылып, шул беренче тәрәзәне карады. Ара еракка күрә ул тәрәзә инде аермачык күренми иде; алай да Габделбасыйрга ул пәрдәнең бер чите аз гына ачылып тора шикелле күренде.

Йөри торган җиреннән мәдрәсәгә кайтырга дип борылгач, Габделбасыйр адымнарын җәһәтләтте: «матур кыз», һаман тәрәзә янында утырып, инде зарыга башлагандыр, моның тизрәк кайтмаганына үпкәли башлагандыр шикелле тоела иде.

Кич җитте; мәдрәсә, ахшам чәеннән бушанып, уку тавышы белән гөрли башлады. Габделбасыйр да китабын ачып куйган иде, күзләр сары кәгазьле һинди китап[1] эчендәге бернәрсәгә дә игътибар итәргә теләмәделәр. Бервакыт сары кәгазь өстендә «матур кыз»ның ишегалдына чыгу хәбәре язылган шикелле тоелды. Габделбасыйр сикереп урыныннан торды да, муенына сөлгесен чолгап, ашыгып чыгып китте. Габделбасыйр койма ярыгы янына килергә ашыкты: ярыкта кызыл кәгазь юк иде.

[1] *Һинди китап* — Һиндстанда басылган китап.

2

Көннәр үттеләр, Габделбасыйрның «матур кыз»га булган мәхәббәте кимемәде генә түгел, киресенчә, арта гына барды. Ул бик еш урамга чыга, ләкин һәр чыкканда Рәүф байлар капкасы ягына каранып торып кына керә.

Бер атна үтеп китте. Габделбасыйр «матур кыз»ның йөзен түгел, сынын да күрә алмады.

Ләкин бу эш аның мәхәббәтенә зарар китерми иде. Купшы бишмәт, һәр төнне «матур кыз»га әйләнеп, Габделбасыйрның кочагына керә, үзенең телсезлеге белән аңар әллә нинди матур сүзләр, гыйшык сүзләре сөйли, «матур кыз» исеменнән әллә нинди вәгъдәләр бирә иде. Кызыл кәгазь дә һәр кичтә теге койма ярыгына куела, иртә торганчы каядыр китә, җуяла иде. Бу кызыл кәгазьнең шул серле җуялышы Габделбасыйрга әллә нинди өмидләр генә дә түгел, хәтта бөтен бер тереклек бирә, купшы бишмәт һәр төнне Габделбасыйрга:

— Кызыл кәгазеңне алдым, хат язганыңны көтәм,— дип аңлата иде.

Габделбасыйр койма ярыгына кыстырылачак кызыл кәгазенә хат сымак бернәрсә язарга да карар бирде. Һәм күп икеләнеп торганнан соң: «Син җанымга сәлам хат. Моны алганлыгыңнан бер хәбәрнамә яз»,— дип язып, кәгазен ярыкка кыстырырга чыгып китте.

Берәр минут карап, яңа бернәрсә дә күрмәгәч, Габделбасыйр инде ярык яныннан китәргә уйлаган гына иде, ишегалдындагы зур кыңгырау шалтырап куйды. Дворникның олуг капкаларны ачуы, аннан хатынмы-кызмы ике кеше утырган чаналы атның керүе күренде. Теге хатынмы-кызмы парадный ишегалдына туктаган аттан төшеп, өйгә кереп тә киттеләр. Фәкать аларның берсенең икенчесенә: «Диләфрүз, итәгемә бастың!»— дигән сүзе Габделбасыйрның колагын кәефле чыңгыратып калдырды.

— «Матур кыз» Диләфрүз исемле икән, аның тавышы шулай мәхәббәтле чыңгырдак икән!

Габделбасыйр, кызыл кәгазьгә язган сәлам хатын ярыкка кыстырып, урынына кайтты. Мәдрәсә һәр кичтәге шикелле гөрли, халык дөньяда бернәрсә дә булмаган шикелле, гади хәрәкәт итә, гади укый, гади сөйләшә, гади көлешә. Бу кешеләрнең дөньяда бернәрсә дә булмаган шикелле, көндәге эшләре белән шөгыльләнеп утырулары аңламаслык дәрәҗәдә гариб һәм мәгънәсез иде.

Бу көн төнлә купшы бишмәт инде, «матур кыз» гына түгел, бәлки Диләфрүзгә әйләнде.

3

Икенче көнне Габделбасыйр өчен кайгылы бер вакыйга булып китте: Рәүф бай, балта остасы китертеп, коймадагы теге ярыкны каплатып куйды, ул гына да түгел әле, мәдрәсәнең мөдәррисенә:

— Шәкертләрең минем асрау кызларым белән шаярырга тели башлаганнар, тәкъсир, аларны ул эштән тыярга кирәк иде!— дип зарланган. Габделбасыйрның койма ярыгына кыстырылган кичәге хаты кучер кулына төшеп, ул аны асрау кызга язылган хат дип уйлап, Рәүф байга биргән вә бөтен бу вакыйга да шуннан чыккан иде.

Койма ярыгының каплануы Габделбасыйрга шундый бер кайгы булды ки, ул моның өчен тәһарәтханә бүлмәләренең берсенә бикләнеп, күз яшьләре белән җылап та алды.

Төн җитте, мәдрәсә дә тынды, тирә-як йокыга чумды, ләкин Габделбасыйр йоклый алмады:

— Диләфрүзем, җаным, синең атаң теге койма ярыгын бикләтте бит ул, синең мине сөя башлаганыңны күреп көнләште. Бер фәкыйрь шәкерткә матур кызын күпсенде. Диләфрүзем, җаным, синең кулыңнан минем хатымны алдылармыни? Син, бичаракаем, миңа ничек итеп хат бирергә дә белми торгансыңдыр инде?!

Боларны хыялына китереп, Габделбасыйр шулкадәр рәхәтләнде ки, хәзер аңар койма ярыгының бикләтелүе зур бер бәхет шикелле тоела башлады.

Ята торгач, бу хыяллар Габделбасыйрга бөтенләй дөреслек шикелле булып киттеләр.

4

Әхмәтнең табигатендә, табигатеннән дә бигрәк коңгырт, бераз моңаебрак карый торган күзләрендә гаҗәеп бер хасият[1], бер гипноз бар иде. Аңар дустлары да, дуст булмыйча коры таныш булган кешеләр дә үзләренең сер дип уйлаган нәрсәләрен сөйлиләр, ул шул серләрне бер мөкатдәс нәрсәне саклаган шикелле итеп саклый, берәүгә дә сөйләми иде.

---

[1] *Хасият* — үзенчәлек, сыйфат.

Өйлә намазыннан кайтып ашлар ашагач та, Әхмәт белән Габделбасыйр базарга чыгып киттеләр.

Габделбасыйр бераз җавапсыз барганнан соң:

— Их, иптәш, минем нихәлдә икәнемне белсәң иде...— дип, сүзен башлап китте.

— Мин гыйшык тотам бит, иптәш... Бер кыз белән сөешәмез, ләкин аның ата-анасы бер дә миңа бирер төсле түгел...

Габделбасыйр сөйләгән нәрсәләренә сөйләгән минутында үзе дә ышанып тора, шул нәрсәләрне хис итеп уздыра иде.— Менә инде Рәүф байлар күчкәннән бирле аның кызы Диләфрүз белән гыйшык тотышамыз, иптәш. Ул да саргаеп, кибеп бетте; мин дә, менә үзең күрәсең, көннән-көн саргаям, кибәм... Моңар хәтле без һәр көнне төнлә, теге ярык аркылы күрешеп, сөйләшә торган идек. Хәзер инде ярыкны бикләттеләр. Минем исемемне әйттереп, мәдрәсәдән кудыртмакчы булганнар, тик кыз нишләсә — эшләгән, минем исемемне әйтмәгән. Менә кичә төнлә күрешә алмадык, бары ул бичаракай миңа кечкенә бер хат кына бирдертә алды. «Инде нишләрмен, гыйшкымнан үлмәсәм ярар иде»,— дип язган. Их, иптәш, белмисең генә сөю хәленең авырлыгын. Рәүф бай: «Үлсәм үләрмен, ул шәкертеңә бирмәм мин сине»,— дип әйтә, ди...

Габделбасыйр бу минутта зур бер кайгыга батты.

— Беркөнне, бичаракаем, муеныма асылынды да җылый, җылый да җылый. «Ходай безне кавыштырмаса нишләрмен дип җылыйм»,— ди...

Моны ишеткәч Әхмәт, иптәшен бүлдереп:

— Соң сез аның белән шулай кочаклашырлык ук җирдә дә күрештеңезмени? Койма ярыгы аркылы гына күрешәмез дигән идең түгелме? — диде.

Габделбасыйрның эче «жу» итеп китте, бер минутка гына сөйли торган сүзләренең ялган икәнен үзе дә хис итте. Әхмәтнең сөаленә ул ике-өч минуттан соң гына җавап бирде:

— Әйтсәм әйтим инде, син кеше серен кешегә чәчә торган адәм түгел... Әйе шул, иптәш. Беркөн төнлә мин койма аркылы алар ишегалдына төштем...

Хыял бу вакыйганы җентекләп тасвир итәргә иренмәде:

— И иптәш, белсәң иде ул вакытта нинди хозур булганны... Диләфрүз эчке күлмәктән генә, башында мамык шәл...

Әхмәт бу кышның төнендә эчке күлмәктән генә тышка чыккан кызны чын-чынлап кызганды. Баштарак иптәшенең сүзендә арттыру булырга кирәк дип уйлабрак барса да, соңга

таба ул аңар тәмамән ышанды: Габделбасыйрның күзләре вә бөтен йөзе бу вакыйгаларны сөйләгәндә чын гыйшык, чын бәхет, чын кайгы күрсәтәләр иде. Әхмәт:

— Бу көн хат-фәлән керттерсә, миңа да укыт әле,— диде.

Габделбасыйр укытырга вәгъдә бирде.

Бу көн кич, шәкертләр ястү намазына киткәч, Габделбасыйр, бер аулак урын табып, иптәшенә күрсәтер өчен, Диләфрүздән үзенә килергә тиешле хатны язарга тотынды. Кызлар язуына охшатыр өчен, каләмне сул кулына тотып, язарга тотынды:

«Сезки гыйззәтлү, җанымның җаны, бәгыремнең бәгыре Габделбасыйрга чук-чук сәламнәрем торыр. Вә бәгъдә безнең тарафтан хәл-әхвәл сорашсагыз, син җанымның хәер-фатихасы бәрәкәсендә ләһелхәмдер. Вә бәгъдә әмре Алладыр. Бәгъдә, җаным, син баягынак ят кеше белән идең, шуңар күрә күренә алмадык. Йөрәк бәгырьләрем өзелеп калды син җанымны күргәч. Иртәгә үзеңә мәгълүм йирдә, мәгълүм сәгатьтә күрешермез. Зинһар өчен, чыкмый калма. Сөйлисе сүзләрем бик күп. Мәгълүмегез Диләфрүз».

Язып бетергәч, Габделбасыйр хатка ислемай сөртте дә конверт эченә салып, ябыштырып куйды.

Халык ятып, мәдрәсә тынгач кына, Габделбасыйр бу хатны Әхмәткә күрсәтте.

Габделбасыйр белән Әхмәт озак вакытлар серләшеп утырдылар. Бу эч бушату аңар әллә нинди бер бәхет биргән, Әхмәтнең аның сүзләренә ышануы шул бәхетне ныгыткан, хыялыйлык дәрәҗәсеннән уздырган шикелле иткән иде.

5

Габделбасыйр Әхмәткә һәр көнне инде Диләфрүз хакында нәрсә дә булса сөйли торган булып китте. Өч көннән өч көнгә үзенә Диләфрүздән итеп хат яза да шуны Әхмәткә укыта вә аннан соң ул хатларны, чынлап ук бер гыйшык вәсикасы (документы) булган шикелле итеп кадер вә хөрмәтләп җыя, вә саклый бара иде.

Атналар үттеләр. Габделбасыйр инде серне үзенең шәкерттәшләреннән вә дустларыннан дүрт-биш кешегә дә сөйләп ташлады. Яңа бер кешегә сер ачкан саен, аның хыялы куәтләнә бара, уйнаклый. Бу «роман»нан Габделбасыйр вакыт-вакыт бәхетле була, әмма вакыт-вакыт тирән бер бәхетсезлеккә төшә иде ки, гакыл үткенәеп, хыял зәгыйфьләнеп, бөтен бу

«роман»ның чын түгел икәнен ап-ачык аңлаган вакытлар да була иде. Мондый вакытлар бик еш булмыйлар, ләкин булган вакытларында бик ачы буладыр иде.

Кышның ахыр көннәре якынлаштылар.

Көннәрнең берсендә Габделбасыйр вә аның белән бергә Әхмәт тә капка төбенә чыктылар. Боларның чыгып җитүе булды, Рәүф байларның олуг капкалары да салмак кына шыгырдап ачылып китте.

Капкадан чыккан тәңкәчуар атка җигелгән җиңел вә матур санкидә берсе — чапанлы, берсе мамык шәлле ике хатын утырганнар иде. Бу хатыннарның кемнәр икәнен күрергә мөмкин булмаса да, гәүдә торышларына карап, берсенең шактый яшьле хатын вә икенчесенең йә яшь хатын, йә кыз кеше икәнен чамаларга мөмкин иде.

Габделбасыйр, каушап кына: «Мамык шәллесе Диләфрүз икән!» — дип уйланды да пошынды: Диләфрүз күзен дә төшермәде бит!»

Бу минутта аның рухын теге бушлык каплап алды. Үз гыйшкының хыял гына икәнен бу вакыйга мөнәсәбәте белән ул тагы бер кат сизеп вә тоеп үткәрде. Ләкин бу авыр бушлык озакка сузылмады:

— Әнә шул мамык шәллесе минем Диләфрүз инде. Капкадан чыккач та, миңа җиңел генә баш селекте.

Теге абыстайларга капка ачкан Рәүф бай дворнигы, капкасын япкач, урамга чыкты да кулындагы себеркесе белән тротуарны себергәләп, шәкертләргә таба килде. Әхмәт, Габделбасыйрга бер дә көтелмәгән рәвешчә генә:

— Бу чапанлы абыстай кем була?— дип, дворникка сөаль бирә куйды.

Дворник та, эшеннән туктап, себеркесенә таянып, болар белән сүзгә керешге:

— Ул безнең бикә була инде: байның хатыны. Ә тегесе — безнең байның кызы Газизәбану була...

Бу сүздән Габделбасыйрның башы томан белән тулган шикелле булды. Әхмәт Габделбасыйрга бәян[1] көткән күзләрен текәде. Бу караштан бераз аптырап калган Габделбасыйр да, сүз табылганчы, бер-ике мәртәбә тамак кырып куйды да бераз тотлыгыбрак сүзгә керешге:

---

[1] *Бәян* — ачыклык.

— Сер бөтенләй-бөтенләй ачылды инде, иптәш. Мин әле сиңа аның чын исемен әйтмәкче түгел идем. Ул үзе дә бит хатына «Диләфрүз» дип куя. Без юри, кеше кулына төшсәнитсә дип, шулай эшлимез аны.

Бу сүз шулай әйтелеп беткәч, Габделбасыйр шактый тынычланып китте: Диләфрүзнең Газизәбану булып чыгуы бу сүздән соң әллә ничек гаҗәп тә түгел, уңайсыз да түгел шикелле иде, чынлап та ул Газизәбану бит. Габделбасыйр сер саклар өчен генә аны Диләфрүз дип сөйләп йөргән.

Габделбасыйр әүвәлдә серен сөйләгән иптәш вә шәкерттәшләреннән һәрберсенә Диләфрүзнең Диләфрүз түгел, бәлки Газизәбану икәнлеген хәбәр биреп чыкты.

Болай дип ышана башлау Габделбасыйрның Рәүф бай кызына булган гыйшкын тагы да көчәйтеп җибәргән шикелле итте.

6

Яз тәмам җитеп, пароходлар да төште. Шул вакытта инде Габделбасыйрга өенә кайтып китәргә тугры килде.

Аерылу хәленең авырлыгын Габделбасыйр иптәшенә шулкадәр итеп сөйләде, хәтта үзенең күзләренә яшьләр килде, урынына кайтып яткач, шул сөйләгән сүзләренең тәэсире белән җылап алудан да ул үз-үзен тыя алмады.

Озатырга төшкән кешеләр «сер»не белә торган кешеләр иде. Арадан берсе уйнабрак:

— Мәдрәсәдән китү уңгайсызмы әллә? — дип соравына каршы Габделбасыйр:

— Газизәбану бичаракаем ничек итсә иткән, озатырга төшәргә хәйлә тапкан. Әле шуның белән күрешеп килдем. Җылый-җылый җанымның күзләре шешенеп бетте. Мин дә чыдый алмадым, җыладым, — диде.

Пароходта уздырган төн Габделбасыйрга моңар кадәр әле бер дә булмаган өр-яңа тойгы белән килде:

«Ник мин моңа кадәр Газизәбануга, хат язып, үземнең гыйшык тотканымны белдертмәдем? Хат язар идем дә, дворникларына акча биреп, шуның аркылы тапшыртыр идем...»

Үзенең чынлап бәхетле булуы өчен шулкадәр тиеш булган бу ап-ансат эшне эшләмәгәнлеге өчен Габделбасыйр үз-үзенә шулкадәр үпкәли вә шулкадәр ачулана иде ки, бу тойгыларын үз-үзенә ничек итеп әйтеп бетерүдән гаҗиз кала иде.

Бу тойгы белән Габделбасыйрның күңелендә теге бушлык, теге мәхрүмлек тойгысы да уяна башлаган иде, ләкин ул аны тиз бастырды: мәдрәсәгә яңадан килгәч тә, Газизәбануга хат язарга үз-үзенә вәгъдә бирде. Газизәбануның кабул итүе бер дә шиксез нәрсә булган шикелле тоела иде.

7

Габделбасыйр хәлле генә бер авыл крәстияненең иң кечкенә угылы иде. Ага-энеләр арасында бер генә шәкерт булганлыктан, ул йорт эшләренә йөрми, өйгә кайткач, кунак сыманрак булып тора иде. Ул һәркөнне йә кырга чыгып йөри, йә урманга барып ята. Авылның урамнарын үтеп узып, тегермәннәрне үтеп киткәнче, Габделбасыйр бернәрсә уйламыйча килә дә, үсеп утыра торган арышлар арасына барып керү белән, Газизәбануны үзе белән итеп фараз кыла башлый:

— Газизәбану, җаным, менә сиңа безнең авыл инде бу! Менә бу нәрсәләрне арыш диләр...

Газизәбану Габделбасыйрга сылана, Габделбасыйр аны үбеп ала...

Хыял бу җиргә җиткәч, аңар бер бәхәс килгән шикелле була: ничек итеп Газизәбану Габделбасыйрлар авылына килеп чыккан?

Габделбасыйр шул бәхәскә җавап эзләгән шикелле була: Габделбасыйр күптән түгел генә Газизәбануга өйләнгән дә, яшь киленне күрсәтер өчен, авылына алып кайткан... Габделбасыйрның шулкадәр матур, шулкадәр бай кызга өйләнеп кайтуына бөтен авыл халкы шакката... Габделбасыйрлар авылының мулласының угылы Сафый мәхдүм, Габделбасыйрның Газизәбану белән кырга чыгып киткәнен күреп калып, бик көнләшә... Габделбасыйрның ата-аналары угылларының шундый бай кызга өйләнүеннән бик шат булганнар, алар киленне бик кадерләп кенә, аңар исләре китеп кенә торалар...

Хыял бу җиргә җиткәч, тормышның шигърияттсез яклары белән катышып китә башлый. Габделбасыйрның ата-аналары киленне яраталар яратуын... Әмма алар һаман ашны кара оннан пешерәләр, мунчалары да кара мунча, аталары, агалары да чабата киенеп йөриләр...Газизәбану бу эшләрне яратмый, гаеп итә...

Ләкин монда җиткәч, хыял кинәт өзелә дә, Габделбасыйр үз-үзенә:

— Ник соң мин Газизәбануга хәзергә кадәр үземнең гыйшкымны белдермәдем? — дип, бер сөаль бирә. Габделбасыйр әллә йөзенче кат инде үз-үзен чынлап ук Газизәбануга хат язмаганы өчен шелтәләргә тотына, озак шелтәләп, озак үпкәләп арыганнан соң, ул үз-үзенә сүз бирә:

— Мәдрәсәгә барган көнне үк Газизәбануга хат керттерәм...

Менә шушы хыяллар белән Габделбасыйр көннәрен вә төннәрен уздыра иде. Бу уйлар Габделбасыйрны бервакыт ялыктыра башладылар, ул үзендә үзенең «сер»ен монда да берәр кеше белән бүлешәсе килү тоя башлады.

Июльнең соңгы көннәре иде, Габделбасыйрларга икенче өяздән үзләренә якын карендәш бер шәкерт кунаклый килде. Кунак килеп җитеп әүвәлге чәй эчкәч тә, Габделбасыйр аны басуга алып чыкты.

Габделбасыйр кунагын тыгыз сафланып торучы алтын саплы башаклар арасына кысылып калган ат юлы буенча алып китте... Габделбасыйр сүз башлады:

— Минем башка бу ел бик зур сагыш төште бит әле, Галиулла иптәш... Менә инде кыш башыннан бирле яр сөям бит мин...

Габделбасыйр Галиуллага үзенең Рәүф бай кызы Газизәбануны сөйгәнлеген һәм Газизәбануның үзен сөя икәнен Әхмәткә сөйләгән тәртибе белән сөйләп китте.

Өенә кайткач, Габделбасыйр, Әхмәткә вә үзенең башка иптәшләренә күрсәтер өчен дип, Газизәбанудан иттереп язган хатларын да берәм-берәм Галиуллага укып чыкты вә аннан соң аларны, үбә-үбә, яңадан сандыгына җыеп куйды. Галиулла өенә кайтып китеп, «сер» сөйләр кеше калмагач, «чын-чынлап хат язу» уе тагы туды. Аның тизрәк мәдрәсәгә китәсе килә башлады. Ул үз-үзендә көз җиткәнне көтәрлек сабыр калмый шикелле итеп хис итә, вакыт-вакыт үзе авылда чакта мәдрәсәдә калган шәкертләрдән берәрсенең Газизәбануга хат язып куюыннан курыккан шикелле куркынып китә иде дә, бу шигъриятсез тойгыны басар өчен, «чын-чынлап хат язу» мәсьәләсен онытып торырга тырыша иде.

— Җаным, Газизәбануым, кем генә хат язса да, син аңар илтифат итмәссең бит? Сөйгән ярыңны ташламассың бит?

— Юк, җаным, юк, Габделбасыйрым минем, үлгәндә дә сине онытасым юк, җаным! Сине сагынып, саргаеп беттем инде, җаным!

8

Габделбасыйр июль уртасында ук инде авылдан китәр өчен юллар хәзерләргә тотынды. Аның атасы, әүвәл Габделбасыйрның болай иртә мәдрәсәгә китүенә каршы торса да, ахырдан риза булып җибәрде.

Башта Габделбасыйрның бу ашыгуы «Газизәбануга чын-чынлап хат язып гыйшык белдерер өчен» булса да, Габделбасыйр өеннән чыгып киткәч, хат тугрысында уйланудан бигрәк, хыялга батарга тырышты:

Җаным, Газизәбануым, син мине сагынганга күрә, менә мин нинди иртә мәдрәсәгә барам...

Шәһәргә барып җитеп, Рәүф байларның тәрәзә алларыннан үткәндә ул, бөтен нәрсәне онытып, күзләренең бөтен көчләре белән тәрәзәләргә каранды. Урта тәрәзәнең пәрдәсе күтәрелгән һәм аннан кемнеңдер, калфаклы бер кешенең карап торганы күренә иде. Габделбасыйрның бөтен тәне буенча бер эсселек йөгерде: «Газизәбану! Ул, ул! Газизәбану җаным карап тора»,— дип уйлап, Габделбасыйр шулкадәр каушады ки, тәрәзәгә каравын да дәвам итә алмады, аның күзләре үз-үзләреннән түбәнгә карадылар.

Мәдрәсәгә килгән көннең төнендә Габделбасыйр өстән-өстән генә, әллә нәрсәдән куркынып кына «чын-чынлап хат язу» мәсьәләсен уйлап карады. Ләкин бу юлда инде аңар бу эш һич мөмкин булмаган, соң дәрәҗәдә куркыныч булган эш шикелле тоелды. Ул хәзер инде үзен «чын-чынлап хат язу» мәсьәләсе белән мәшгуль булган вакытлары өчен шелтәләде: Рәүф байга сизелеп, мәдрәсәдән куылырга сәбәп булыр иде... Дворниклары Газизәбануга бирәсе урынга, аның анасына кертеп бирер иде... Газизәбануга тапшырылса да, ул, атасына биреп, мәдрәсәдән кудырттырыр иде...

Бу уйлар белән бергә Габделбасыйрның җанында теге бушлык, теге мәхрүмлек тойгысы да уянды: күңел сыкранды, мәхәббәт ачылыгыннан яшьсез җылады...

Җәй үтте, көз килде, көз үтте, кыш килде, кыш та үтте, ләкин Габделбасыйр Газизәбануга чын-чынлап хат яза алмады. Бу мәсьәләне фикергә китерү дә анда әүвәл бер куркыну, аннан соң теге күңел бушлык һәм мәхрүмлек тойгыларын уята да ачындыра гына иде. Бу ел кыш та Габделбасыйр үзенең мәгъшукасының йөзен бер генә мәртәбә булса да күрә алмады. Газизәбану ул уйлаган төсле булгандырмы яки аның хыя-

лындагы сурәткә бер дә генә охшамагандырмы — ул мәсьәлә бу ел да Габделбасыйрга беленми калды. Хода белә, Габделбасыйр аны урамда берәр җирдә, бәлки, күргәндер дә, үзенең мәгъшукасы Газизәбану икәнен танымыйча гына киткәндер, ләкин Габделбасыйр үзе аны күрмәгәнлегенә нык ышана иде.

Габделбасыйрның бу гыйшкы, үзе мәдрәсәдән чыгып, өйләнгәнчегә кадәр сузылды. Мулла булып өйләнгәч тә, әле ул мәдрәсә иптәшләре белән очрашканда, Газизәбануны хәтеренә төшереп, аның тугрысында сөйләп аладыр иде:

— Җанашым, бигрәк мәхрүм калды шул. Атасы миңа бирергә риза булмады. Минем өйләнгәнемне ишеткәч, җаным бер атна башын урыннан күтәрми җылап яткан, атасы-анасын бик каргаган, ди...

Бу сүзләрне сөйләгәндә ул әле һаман үзе шул эшләрне чынчынлап хис итеп уздырудан айный алмый иде:

— Җанашым, бик җылаган, ди!

Болай дигәч, аңар Газизәбану да, үзе дә кызганыч тоелып китә иде.

Мәҗит Гафури

ИНКЫЙЛАБ[1]

Дөньяда торсаң — күрерсең һәр көнне бер инкыйлаб,
Бер көне юаш торыр, икенче көн китәр дулап.

Дусларыңнан аерып, фирак[2] утына яндырыр;
Эшләрең чуалдырыр да су кебек болгандырыр.

Йөрмәс ул син уйлаганча — бәдбәхеттә юк сәбат[3]:
«Бу фәкыйрьне рәнҗетермен ич»,— димәс, юк анда ят[4].

Ул сине эскәнҗәгә кыскан кебек кысар, ватар,
Бервакыт тартыр үзенә, бервакыт читкә атар.

---

[1] *Инкыйлаб* — алмашыну, революция.
[2] *Фирак* — аерылышу.
[3] *Сәбат* — даимилек.
[4] *Ят* — оят.

КЫЗГАНАМ!..

Бер фәкыйрьнең бер кисәк икмәккә мохтаҗ калганын,
Кыш көнендә калтырап, җәй көннәрендә янганын,
Бар көчен сарыф итеп, үлмәс өчен тырнанганын...
Күрдисәм, мин кайгырам да чын күңелдән кызганам.

Кайвакытта бер гашыйкның күзләрендә яшь күрәм,
Ихтыярсыз тамчыланган яшьне мөкаддәс күрәм,
Шул гашыйкны яшь түгүдә үземә иптәш күрәм...
«Аh, вафасыз дөнья!»— дим дә шул гашыйкны кызганам.

Тәрбия кыйлучысы юк кечкенә ятим бала
Юлда күргән бер кешедән бер тиен сорап кала,
Калтырый, нишләргә белми, әрле-бирле кузгала...
Бу ятимнең шул авыр хәлен күрәм дә кызганам...

Бервакыт мин кырда чакта көнбатыш як саргая,
Сап-сары, кызгылт кояш та зурая, шундук бая...
Җир йөзе булды караңгы, инде якты көн кая?..
«Аh, гомер үтә!..»— димен, үткән гомерне кызганам.

Ни сәбәптәндер ялан, урманда кошлар сайраша,
Шатланам, күңлем туладыр, сандугач сайраса.
Шул вакытта әйләнәмдә барча нәрсә җанлана...
«Сез бетәсез бит!..»— димен дә мин боларны кызганам.

Шулвакыт күздән чыга тәгәрәп көмештәй яшьләрем,
Сахра, урманнар, гарибләр[1] — барчасы иптәшләрем...
Төрле уйларда үтәдер көннәрем һәм кичләрем...
Моңланам... җырлыйм... шуларның һәммәсен дә кызганам.

Сәгыйть Рәмиев

ДӨНЬЯГА

Аh, әгәр бу күңелем үткен
Сөнге йә ук булсае;
Яисә ул бер уй белән су
Яндырыр ут булсае.

Әмма соң бер эт итеп, бу
Дөньяны атар идем,
Җир-суын да яндырыр һәм
Күкләрен ватар идем!..

---

[1] *Гарибләр* — ярлылар.

Юк шул ул көч бу күңелдә,
Ул зәгыйфь, ул кечкенә,
Уйласам уй, сызлый күңлем,
Сызлый җан да эч кенә.
Бигрәк артык изде дөнья...
Калмады сабрым, бетәм,
Тик азаккы тамчы яшьнең
Җиргә тамганын көтәм.
Ул тамар бер, мин бетәрмен,
Тик шуны белсен үзе,
Бу азаккы яшь булыр бу,
Идеалымның йолдызы!..

Бу яшем, юк, җиргә сеңмәс;
Бу калыр, бу ялтырар!
Һәм, караңгы көн бетеп бер,
Мәңге якты ай туар.
Тугмый калмас, бер туар ул,
Идеалым күренер әле,
Шунда эчкән яшенә дөнья
Тончыгыр, күбенер әле!
Ник исәпсез калдырыр җан
Елгалап аккан канын?
Юк, алыр һәр тамчы канга
Дөньяның мең кат җанын!

«УЛ»

Кашлары — ай аның, яңа туган,
Йөзе — айның туган көннәре,
Керфекләре — нурлар, кич чәчелгән,
Ике күзе — шул кичнең күлләре.

Күзе аның — диңгез, гыйшык диңгезе,
Бар мәхәббәт аңа җыелган,
Аңа күк тә ае, йолдызлары
Белән төшеп сәҗдәгә егылган.

Бите — кояш, кызарып чыгып килгән,
Көлгән чагы — гүя бер сахра,
Тавышлары — чын-чын былбыл тавышы...
Аһ, үләмен, үләм шул чакта!

Шәехзадә Бабич

МАНДОЛИН

И үзәк өзгеч тавышлы, моңлы, зарлы мандолин,
Килче, моңланчы өзеп бер, мин дә тыңлап моңланыйм.

Син минем җан сердәшем, җан моңдашымсың, мандолин!
Сергә беткән, моңга беткән зарлы таушың җанга им.

Шул синең тавышың гына тик дәртемә дәрман бирә,
Шул бирә һәр нәрсәне: шул җан бирә, ул ямь бирә.

Шул миңа уй, шул миңа хис, шул миңарга аң бирә,
Шул миңа сер чишмәсеннән алтын вә мәрҗән бирә.

И минем күңелемне сафлаучы мөкатдәс мандолин,
Сине тыңлап, күзләрем саф яшькә манчып алгалыйм.

Сине тыңлап, һәммә таптан, һәммә кердән сафланам,
Сафланам да, пакьләнәм дә — Алла, Алла, Алла! дим.

И сихерле, серле, илһамлы, гаҗәеп мандолин!..
Әйдә сыздыр, әйдә өздер, сафланыйм, иманланыйм!

Сәгыйть Сүнчәләй

АВЫЛ

Аһ, туган, моңлы авыл! Китмәс күңелдән күрнешең,
Кайгы, михнәт җырлый-җырлый шаулаган моңлы кышың.
Язгы эссе көндә яуган ул сәрен[1] яңгырларың,
Ямь-яшел хәтфә кебек киң-киң уҗымлы кырларың.

Ярдагы шат чишмәнең серле агымлы уйнавы,
Ул күңлеңнең, тын гына йоклап, борынны уйлавы;
Ул бабайлардан калып килгән бәхет — урманнарың,
Ул бабайлар таптаган сукмакларың, тәхтең — тавың...

Шул җыенда — бәйгедә ул яшьләреңнең шатлыгы,
Ул, сиңайтим, кызларыңның күңеле йомшаклыгы;
Ул аларның йөзләренә балкыган ямь — җан яме,
Ул аларның язгы иркен яшь мәхәббәт бәйрәме!..

Әй авыл! Һәрбер җирең, һәрбер төшең, һәр байлыгың,
Һәр баланың тормышы, ач кошларың, һәр бар-югың,—
Барсы да күп күңлемә изге, якын кардәш булыр;
Һәммәсен сагыныр, онытмас, китсә дә читкә улың!

СӨЕНЕР ИДЕМ...

Сөенер идем,
Көләр идем,—
шат булсам,
Сөймәс идем,
Көймәс идем,—
ят булсам.

---

[1] *Сәрен* — вак.

Нур телимен,
Нур эзлимен
төнлә мин.
Ал болытны,
Ал бу утны,—
теләмим!

Алладамы,
Дөньядамы
күз нурым?
Бармы ак юл,
Бармы пакь юл —
үз юлым?..

ИЛ КАЙГЫЛЫ

Кайсы илгә барма — һәр ил
Әллә ниткән кайгылы.
Һәр кеше үксез, күңелсез,
Һәр кеше — дөнья колы.

Син сузасың кул, кулыңны
Кем дә кысмый; син — ятим.
Кайгылы ялгызлыгың тик
Әз генә һәйбәт, рәхим.

Тагы да җитте матур яз,
Тагы яз җитте, дисең.
Яз дисең дә шатланасың...
Ник? Үзең дә белмисең.

Зариф Бәшири

ДУМАГА ХИТАП

Дума, сине көттеләр,
Саргаешып беттеләр,
Чөнки синнән башка безне
Хур һәм фәкыйрь иттеләр!
«Безгә Дума булсын!»— дип,
Күп каннарны түктек без;
Залимнәрдән котылуны
Синнән өмид иттек без!
Инде син дә йоклама,
Залимнәрне яклама;
Алга куеп ерткычларны,
Эшчеләрне таптама.
Көрәш бара ил өчен,
Кан түгелә җир өчен;
Инде син дә гайрәт ит,
Кызганмастан бар көчең.

Халык әйтә:
— Гафу!— ди,
— Төрмәләрне ачу!— ди.
— Илне изгән, канын эчкән
Түрәләрне асу!— ди.
Без бар эшне күзәтеп
Торабыз синең якта,
Синнән ишарә булса
Булышырбыз шул чакта!
Ил, халыкта сәләт бар,
Залимнәргә нәләт бар;
Куркып торма ул хакта
Артта терәк бар чакта!
Үзеңне ал кулга син,
Куркак куян булма син;
Гайрәтеңне нык сакла,
Халык сиңа яр чакта!

Гаяз Исхакый

ОСТАЗБИКӘ

Сәгыйдә остазбикәдә бер дә артыклык-кимлек юк иде. Ул гади генә авыл остазбикәсе иде. Аның кияүгә чыгуы муллаларда булганча гади генә булды. Ул кыз булып үсеп килә башлагач та, төрле җирләрдән мулла, мөәзингә, мулла сыманрак булырга тырышкан байларга сорарга тотындылар. Әтисе хәзрәт, мужик халкын яратмаганга, һәммәсенә сүз кайтара килде.

Менә еракта гына булса да, яңа указ алган муллага Сәгыйдәне сорарга килделәр. Хәзрәт үзе, кияү булачак шәкертне бер мәртәбә күреп ихлас баглаганга, «киңәш итешик» дигән җавапны бирдертте вә башкода булып килгән Фәхри мөәзин артыннан ук абыстайның туган кардәшен ат җиктереп шул авылга, югалган атны эзләргә җибәрделәр... Яшь мулланың бөтен хәл-әхвәле, мәхәллә халкы, мәхәлләнең яшь муллага карашы хакында тулы мәгълүмат китерергә куштылар.

Шакир мөәзин яучы килгән авылга килеп җитте. Мәчеттән ерак түгел генә таза гына бер мужикка туктады.

Өй хуҗасы үткен генә мужик, бик тиз бу хәзрәтме, мөәзинменең ник килгәнен сизеп алып, турыдан-туры сөйләде. Шакир мөәзин аның сүзеннән яңа мулланың бик һәйбәт укымышлы, инсафлы шәкерт икәнен аңлады. Шул сүзне алып, Шакир мөәзин өйгә чапты.

Шакир мөәзиннең китергән мәгълүматы абыстай, кардәшкабиләне канәгатьләндермәсә дә, хәзрәт үзе бирү ягында булганга, киңәш мәҗлесендә килен итеп төшермәенчә, аерым тору шарты белән бирергә карар чыгарылды.

* * *

Туйлары ничек булганын Сәгыйдә, әлбәттә, бөтен ваклыкларына кадәр хәтереннән чыгармады. Кодалар килгәндә ул, кечкенә өйдә булганга, каенатасын да, каенанасын да бердән күрмәде. Ирләр чәй эчәргә утыргач кына, ярыктан беренче мәртәбә карады. Иң түргә бер таза кеше утырган.

Кулында зур гына, акайган гына мужик килененеке кебек яулык. Менә ул шул яулык белән бик кычкыртып борынын сөртте. Бу кем икән? Кара әле, мулла җизни: «Яңез, кода

хәзрәт»,— диде. Шул сөйкемсезмени? Менә сөйләргә тотынды. Теле гомердә мәдрәсә күрмәгәнме, аю уйнатучы мишәрмени, «да, да...» дип тора.

Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла!

Сәгыйдәнең күзенә яшь килергә өлгермәде, зур абыстай килеп: «Әйдә, тәһарәтең бармы? Каенанаңа күрендерергә»,— дип, җилтерәтеп алып китте. Сәгыйдә ничек күрешкәнен белмәде. Тутасының төртүеннән соң каенанасына сигез чиреклe ефәк яулык биргәнен дә, каенанасының зур ике талир тәңкә бүләк иткәнен дә рәтләп сизенмәде. Шул гадәтләр, йолалар бетеп, Сәгыйдәгә әнисе: «Утыр, кызым»,— дип, йомшак кына әйткәч, Сәгыйдә самовар артына утырып күзен күтәрде.

Түрдә киң генә битле, урта яшьле бер хатын утырган. Колакларындагы хәзерге заманның чулпысы кебек колак алкалары болай да зур колакларын басып, сәлендереп торалар. Кулларының саргайган тиреләре өстендә берсеннән-берсе киң, әллә ничәшәр беләзекләр аның кулларын сынганнан калайлаган чәйнек борыны кебек иттереп күрсәтәләр. Юанюан бармакларда төрле төстәге, алды-артлы киелгән өчәрдүртәр йөзекләр аның бармакларына кырык тартмачыдагы сатар өчен төрле төстәге, төрле буяудагы йөзекләр утырткан агач төсен биләләр.

Битенә кершән яккан. Инлек белән бит урталарын кызартып, аны буяган чиләк төбенә охшаткан, атныкы кебек зур-зур тешләрен карага буяган!..

Сәгыйдә бер мәртәбә карады: үзенең каенанасы шул булуга ышанмады. Үзенең колагы белән каенанасының тавышын ишетте. Ул Сәгыйдәнең моңынча күргән һичбер кешенең тавышына охшамаган кебек, һичбер кош-корттан да ишеткән тавышына да туры килми. Ул, чыдарга тәкате калмаганын белеп, акыртын гына торды. Ишеккә барып җиткәндә, аның ике күзеннән дә яшь куып җитте. Ул кызу-кызу баскычтан төшеп, караңгы бүлмәгә кереп, акырып-акырып еларга тотынды.

Тутасының: «Угыллары боларга охшамаган»,— диюләре, анасының: «Атаңнан курык, кунаклардан оял!» — диюе дә тәэсир итмәде.

Никях мәҗлесе дә шактый салкын үтте. Кодаларны озаткан атлар кияүне алып киләсе булганга, Сәгыйдә, иртәдән үк ап-ак балавыз кебек агарып, гомерләре бергә үтәчәк иптәшен

күтәргә тотынды. Аның күз алдында теге затсыз авыл старостасы төсле карт белән түбән очның юлаучы кертүче Гыйззәтбану кебек карчык басып торганга, аның хыялы, күптән инде шуларның икесеннән кушып, бер егет — бер кияү ясап куйды.

Менә капка ачылды. Кыйбла яктан повозкалы атлар чабып килеп керде. Повозка янына — сафланып чалма-чапаннан тора торган Сәгыйдәнең әтисе, җизнәсе янына сикереп кияү төште. Яңа гына мыек чыгып килә торган таза-яшь йөз, йөзендәге үткен генә кара күзләре, җиңел генә хәрәкәтле сабыр гына кыяфәтне Сәгыйдә бердән күрде. Шул күрү белән аның җилкәсеннән зур бер йөк төшкән кебек булды. Аның котын алган шул кодагый белән коданың сыйфатлары бердән югалды. Көн бердән матурайган кебек булды. Ул, нишләргә белмичә, якындагы тутасын кочаклап үпте.

* * *

Сәгыйдәнең кияү буләге чыгаргандагы көләчлеге, ачыклыгы тутасыннан анасына, анасыннан атасына җитеп, бөтен авылны йөреп чыкты.

Кияү китеп ике көн үткәч тә, Сәгыйдә сузып-сузып «Мөхәммәдия» укырга тотынды. Танышлыклары озайган саен, Сәгыйдәгә мулласыннан аерылу авырая барды. Ул, тәмам хикәяләрдәге кебек иттереп, мулласын сөйде, мулласына гашыйк булды. Сәгыйдә, кышкы озын төннәрдә ялгыз — кияү хәзрәтсез булуы уеннан коты очканга, бөтен юллар белән китәргә тырышты һәм дә көзге казлар суюдан элек килен булып төште дә.

Көзнең күзгә төртсәң күренмәс төннәрендә мулласы белән карабодай ташуның уңайсызлыгын да, көзнең көз буенда алтылап ике ындыр табагында ашлык сугучыларны ашатуның күңелсезлеген дә, көне-төне лыр-лыр лыгырдап йөри торган каенанасының эч пошыруының авырлыгын да ул сизмәде.

Үз бүлмәләренә кереп, үзләре генә калгач, хәзрәте Габделвахид белән ялгыз гына калгач, ул бөтен аруларны, тиргәүләрне — һәммәсен оныта торган булды. Шул бәхет, шул тынычлыктан иртәгәге мәшәкатьләргә, иртәгәге тынычсызлыкларга хәл-көч җыя торган булды.

* * *

Бәлки, Сәгыйдә гомергә дә килен булып калыр иде, хезмәтчеләр ашата торган, сарыклар карый торган, сыерлар сава торган, карт белән карчыкның комганнарыннан җылы суны бушатмый тота торган асрау да булып калыр иде. Асрау булганын да сизенмәгән булыр иде. Ләкин тормышта бик күп эшләр уйламаганча чыккан кебек, бу юлы да көтелмәгән эш хәятны борып җибәрде.

Беркөнне Сәгыйдә капканы ябып килә торган атасын күргәч катып калды.

Карт хәзрәт: «Исәнме, кызым! Исәнме?» — дип дәшсә дә, күзен кызыннан ала алмады.

Карт хәзрәтне үзенең сөекле кызын өстендә дублы мужик туны, кулында ярты аршинлы бияләйле, башында ирләрдән калган мескен бүрекле, аягында тула оек өстенә юкәдән үреп ясаган башмаклы иттереп күрү хәйран калдырды. Ул, күзеннән яшьләр тәгәрәгәнгә, бер сүз дә эндәшә алмады.

Мулла Вахид икендесез кайта алмады. Ул да каенатай хәзрәткә чабатадан, билдә алъяпма булган кыяфәттә очрап оялды.

Ястүдән соң карт хәзрәт, авылның игътибарлырак картларын чакыртып: «Җәмәгать! Минем сезгә йомышым бар иде,— дип, сүзгә керешге.— Мин, кызымны мулла Вахидка биргәндә, анасы да, кардәш-кабиләмез дә, авыллары кара, укыган, хезмәт итәчәк остазбикәгә мохтаҗлар, дин өйрәтер, намаз-ниязга алыштырыр, дип уйлаган идек. Мулла Вахидка бер сүз юк. Гыйлеме бар. Ир вазифасын белә... Ләкин, җәмәгать! Мин кызымны монда Рәхим мулланың сарык абзарын тазартырга бирмәдем. Сез дә муллагызны аты белән әвен сугарга дип алмагансыз?.. Монда безнең кода хәзрәттә гаеп»,— дигәч, мужиклар бердән «шулай, шулай» дип сөйләшергә тотындылар.

Озын сүздән соң мәхәллә картларына хәзрәт: «Җәмәгать! Менә ничек булса да мәчет тирәсендә муллага бер йорт алырга кирәк»,— диде. Картлар мәчет күршесендәге шактый зур җирле Шәмсетдиннең йортын сатып алырга булдылар.

Хәйретдин хәзрәт үз күзе белән кызы, киявенең үз башларына тора башлаганын күрер өчен, иң дөресе, үзе бетереп китмәсә, очлый алмаслар дип куркып, үзе өйне яктыртты. Үзе кушып идәннәрен юдыртты.

Икенче көнне үзе үк иртәнге намазында: «Җәмәгать! Кыз балаларыгызны укытасыгыз килсә, яңа остазбикәгә китерегез! Иншалла, белгәне кадәр намаз-нияз үгрәтер»,— диде.

Дүшәмбе көнне авылның төрле очыннан табак-табак оннар, икмәкләр, итләр күтәреп килгән кыз балаларны күреп, Хәйретдин хәзрәт тынычлап өенә кайтып китте.

* * *

Яңа өйдә, яңа җирдә яшь мулла белән яшь остазбикәнең тормышлары бөтенләй башка төс алды.

Хәзрәт өйгә кергәнче, сыерның азыгы барын-юклыгын күздән кичерә. Өйдә аны һәр көнне бертөсле ачык Сәгыйдә каршы ала. Балалар белән маташып тамагы карлыгып беткән булса да, аны Вахид һәрвакыт кайнаган самовар янында көтә торган, яна торган мич алдында табасын кыздыра торган итеп таба. Вахид һәр көнне өенә: «Әссәламегаләйкем!» — дип керә, һәр көнне Сәгыйдә озтазбикә:«Вәгаләйкем әссәлам, исәнме, хәзрәт, бик арымадыңмы? Әнә, хәзрәт, җылы су бардыр, битеңбашыңны ю, мәдрәсәдә тузанланып беткәнсең, мин берәр таба гына пәрәмәч пешереп алыйм,— дип каршы ала.

Вахид хәзрәт чәйне ясагач та, Сәгыйдә остазбикә йә пәрәмәч, йә коймак, йә сумса күтәреп килеп утыра.

Көннең көнендә тормыш шулай бара.

Абыстай хәзрәттән башка бер эш эшләми, берни капмый.

Яшь мулла белән яшь остазбикә бөтен көчләре белән мәхәлләгә хезмәт итәләр. Мәхәллә дә бөтен ихлас белән, муллалар мохтаҗлык күрмәсен дип, гошерне, фитырны, гүр сәдакасын ташый гына бирәләр.

Өч-дүрт ел эчендә Вахид мулла тирә-юньдә игътибарлы муллага әверелә; Сәгыйдә остазбикә, атаклы остазбикә булып, бөтен авыл хатынының киңәшчесе, мәслихәтчесе, гакыл бирүчесе, дин-диният өйрәтүчесе була.

Сәгыйдә остазбикә белән Вахид мулла көн үткәнен, гомер узганын сизмәенчә дә рәхәтләнеп, берсен берсе олугълап, кадерләп, берсе өчен икенчесе үләргә хәзер булып, сөенешеп гомерне үткәрәләр.

Өстән генә сөйләгәндә: «Ник баламыз юк икән!»— дигән сүз әйтелсә дә, ул да эч күңелдән кайнап чыгып әйтелми, ул да онытыла, аның юклыгы да бер-берсенең барлыгы белән ябыла.

* * *

Капка дөбердәгән кебек булгач, Сәгыйдә, сабак кызларыннан фонарь күтәртеп, йортка чыкты: «Хәзрәт! Синме?.. Хәзрәт!»— диде. Күктәге фәрештәләр дә, җирдәге җанварлар да аның эндәшүенә җавап кайтармады.

Иртәгә, йә аннарыга кайтам дип киткән кешегә дүрт көн булды, һаман юк!

Кайдан собраниесе шул юк кәгазьне тикшерергә җибәрде! Кайдан көзге айларда белмәгән-нитмәгән авылга китеп барды!

Төне нинди? Аты, килеп, күпер астына төшеп батып үлсә... Үлсә?!

Шул сүз аның бөтен тәнен-җанын өшетеп җибәрде.

«Ул үлсә?.. Минем кемем кала?!»

«Әй бер угылым булса иде!..»— дип җибәрде.

Шул сүз аның бөтен йөрәгенә кереп утырды, аңарда моңарчы һичбер булмаган бер куәт белән: балалы буласы килү — үзенең угылын күрәсе килү дәртен тудырды.

Шул дәрт шулкадәрле куәтле булды, ул «Хәзрәт үлсә?» дигән сөальне дә оныттырды.

Таң алдында былчыранып-юешләнеп, суга манчылган кебек булып хәзрәт кайткач, беренче сөаль бердән бетсә дә, икенче сөаль куәтләнә генә барды.

Мулла хатыннарыннан сорап, элгәре әллә нинди догалар укырга тотынды. Коръән чыгарга күрше авыл остазбикәсенә җиде бөтен тәңкәсен җибәрде.

Ул, гөнаһ булса да дип, имчеләргә күренде.

Алла бирмәде дә бирмәде.

* * *

Бала сагыну белән өметсезлектән туган хис Сәгыйдәнең йөзендә әллә нинди бер кайгылы сызык сызды. Аның табигате йомшарды, изрәде. Бөтен кызларга «ай гакыллым, кызым» дип дәшә торган булды. Кош-кортларга, мал-туарга да сөюле атлар кушты.

Бер-бер кардәш-кабилә кунакка килсә, ул бөтен гомерен шуларның баласы артыннан йөрергә сарыф итте.

Элгәре Вахид хәзрәт Сәгыйдәнең шул сагышына каршы читтәрәк торган кебек күренсә дә, бик тиздән ул да үзенең күңелендәге балага сагынуны шуңарга кушты. Шәһәргә бардымы, Вахид хәзрәт, Сәгыйдәнең авыл тулган балаларына дип, базардан бүләкләр ташый башлады.

Шул уй һәм дә уртак сагыш боларны тагы якынлатты, берсенә берсенең кыйммәтен тагы зурайтты.

Икәүләп Хуҗалар өстенә барып корбан чалдылар, икәүләп барып, Мулла-морад бабайның чишмәсеннән алып кайткан су белән тәһарәтләнеп Коръән чыктылар. Җиде көн руза да тоттылар...

Шул тынычсызлык боларда балага мәхәббәтне, дәртне тагы арттырса да, үзләрен арытты, ялыктырды. Менә беркөнне Сәгыйдәнең бер тутасы кияве, балалары белән килеп төште. Сәгыйдә кунакларның үзләреннән битәр балаларын кадерләде.

Мулла җизнәләре дә, зурракларының кулларыннан тотып, ындырга алып барды; алар белән үзе уйнарга да утырды. Хосусән дүрт яшьлек Әхмәт исемле бер бала аларның икесенең дә бөтен дикъкатьләрен тартты. Күп балалы баҗа белән тута Әхмәтне калдырырга, өйрәнсә, үзләренә дә бирергә булдылар һәм Әхмәтне калдырып та киттеләр.

Сәгыйдә остазбикә Әхмәткә хәзер үк әллә ничә күлмәкыштан текте.

Мулла җизнәсе, шәһәргә барып, аңарга әллә никадәр уенчыклар өстенә читек-кәвеш, ялган сәгать тә алып кайтты.

Аны бергә яткырдылар, бергә йөрттеләр, бергә сөйделәр. Ләкин Әхмәт, әллә нигә, көннән-көн күңелсезләнде, ул тик торганда еларга тотынды.

Бала көн акырды, төн акырды. Ахырдан тәмам авырырга тотынды.

Сәгыйдә белән Вахид хәзрәт, кеше баласын үтерәмез, дип котлары очты. Вахид хәзрәт, төнлә белән ат җигеп, исән вакытта Әхмәтне илтә китте. Сәгыйдә Әхмәттән калган уенчыклар, әйберләр, ваткан чынаяклар янында бик озак утырып елады.

Хәзрәтләрнең бала алырга теләүләре әллә кайдан чыгып өлгергәнгә, төрле җирдән балалар әйтә башладылар. Беркөнне бер хатын матур гына кара кашлы, биш-алты яшьлек бер малай тотып китерде. «Ирем авырды дип хат алдым. Балаларымыз, Аллага шөкер, җитәрлек. Шул угылымызны тәрбиягә алсаңыз ла. Үзе гакыллы, үзе үткен. Теләсәңез, бөтенләй сезгә бирермен,— диде.

Хәзрәт тә, Сәгыйдә остазбикә дә малайны бик ягымлы тапкач калдырырга булдылар. Малай бик тиз өйгә ияләште.

Бала көннән-көн матураеп, үсеп килгәндә, көннән-көн боларның мәхәббәтләрен җәлеп итә барганда, абыстайның бер

йөзеге югалды. Бераздан тагы беләзеге югалгач, күрше килене Маһруйдан шикләнә башладылар. Тагы бераздан соң хәзрәтнең кесәсеннән акчасы югалды.

Берникадәрдән соң күрше хатыны абыстайга, акыртын гына иттереп, угыллары кибеткә йомырка илткәнен сөйләде.

Икесе дә, Вагыйзны шул гадәттән биздерер өчен, кыш буе тырыштылар, тырмаштылар. Ләкин көн үткән саен ул гадәт аңарда шәбәя барды.

Икенче елны теге хатынга, кайтуы белән, Вагыйзны кире бирделәр.

Вагыйз киткәч, хәзрәт белән остазбикәнең тормышы тагы буш булып калды.

* * *

Сәгыйдә уянып китте.

Вакытның кай чак икәнен белмәгәнгә, ул намазлыкка утырып, Ясиннан башлап белгән бөтен Коръәннәрен укыды.

Кул күтәреп дога кыла башлаганда, аның башына бердән: «Хатынның үгие бармы?»— дигән фикер төште.

«Чыннан да, хәзрәткә бер хатын алып бирсәм?.. Аның баласы бит хәзрәт баласы була. Хәзрәт баласы бит минем балам...»— дип уйлады һәм шулай җиңел генә була кебек тә тоелды.

Ләкин, дога кылып бетереп, тагы башын мендәргә куйгач та, уй башкаланды.

«Хәзрәткә хатын алып бирү?.. Икемезнең арамызга әллә нинди ят, сөйкемсез бер хатын кереп басармы?..»

Ул салкын су сипкән кебек булып китте.

«Юк! Мәңгегә булачак түгел!»— диде.

* * *

Иртә белән чәйгә утыргач та, тагы шул уй, башка төшеп, Сәгыйдәне куркытып җибәрде.

Вахид мулланы намазга озаткач, аның акыртын атлап урам буйлап китеп баруын караганда да теге фикердән котыла алмады.

«Чын да, шулай ук үземә көндәш алып бирсәм?..»

Көндәш?..

Әнә туганым абыйстайның көндәше бар иде. Ашына керосин тамыза торган, түшәге астына үлгән мәче баласы сала торган кебекме?

Юк, юк! Мәңгегә юк!..

Ник алай?.. Менә карт җиңгинең дә көндәше бар иде бит. Чибәр җиңги үлгәч, карт җиңги нинди елаган иде.

Шундый булса?

Ул тагы шундый көндәшле әллә ничә хатыннарны искә төшерде. Шуларның кырык төрле җәфаларын, җәзаларын күзеннән кичерде.

«Көндәш» дигән сүз, Сәгыйдәнең саф уйларында юыла-юыла, ачысын бетерә төште; ул аны ул кадәр куркытмый башлады.

Әйе, көндәш алып бирсә?

Уй шуннан узмадымы, шунда туктадымы? Ләкин ул үсте, ныгыды, беректе. Бик озак эзләгән авыруына дару тапкан кеше кебек, Сәгыйдә тынычланып, рәхәтләнеп китте. Яраклы кызларны эзләргә дә тотынды.

Авылларындагы үзендә сабак укыган уртача гына бер мужикның кызын яучыларга дигән карарга килде.

Менә ул, Сәгыйдә, үзе яучы булып бара. «Мин бит, Зөлфия абыстай, Галимәне бик яхшы бер урынга сорарга килдем»,— ди.

Кызны бирергә разый булалар... Менә туй. Менә кияү алырга килделәр, ди...

Хәзрәт, Сәгыйдәнең хәзрәте, кияү булып барачакмы?

Теге елны Сәгыйдәгә кияү булып килгән хәзрәтме?..

Аның күңелендә Галимәгә каршы иксез-чиксез дошманлык туды.

Үзенең шулай мыскыл ителүеннән, хәзрәтеннән мыскыл ителүеннән янды, көенде.

Аның күзеннән елгалап яшь агарга тотынды.

Фикерләре рәткә килә башлагач, ул:

— Юк, юк, мәңгегә юк... Хәзрәт минеке, хәзрәт минеке... Бирмим! — дип кычкырды.

Балага мәхәббәт, хәзрәтне бәхетле итәргә теләү аның күңелендә көндәш ачысыннан көчлерәк чыкты. Ул акрын гына шул уйга өйрәнә килде.

Шул эштә иптәш-ярдәмче итеп, ул тагы китап — Коръәнгә керешге, ул тагы намаз-ниязга чумды.

Иске китаплардан изге хатыннарның тәрҗемәи хәлләрен эзләп, аннан рухына азык алды.

Әюп пәйгамбәр хатыны 18 ел авыру иренең яраларын-җәрәхәтләрен юып торган. Ахырда ирен ашатыр өчен бернәрсә булмаганга, матур толымын кисеп сатып, азык китергән...

Әллә нинди бер әүлиянең изге хатыны, иренең язу өстәлендә язуы бетүдән элек шәме беткәч, ирен эштән аермас өчен, зур толымын кискән дә, шуны майга чумырып, шәм иттереп яндырган...

Көн үтте, ай үтте.

Сәгыйдә үзенең күңелен шул авырлыкларга өйрәтә килде.

Вакыт үткән саен, көндәшнең ачысы кимемәсә дә, Сәгыйдәнең ачыга чыдавы арта барды.

Аның күңеле ныгый килеп, ахырдан ул, үзенең шул корбанны итә алырлык көч җыйганны хис итеп, хәзрәткә мәсьәләне чиште.

Хәзрәт ашыга-ашыга җомгага хәзерләнә иде.

Сәгыйдә чапанны биргәч тә:

— Менә, хәзрәт, баламыз булса, җомгадан кайтуыңа балаң каршы чыгып торыр иде. Әллә, хәзрәт, сине өйләндерикме?..— диде.

Шул сүз хәзрәткә шулкадәр ят тоелды, аның мәгънәсенә ирешә алмады. Тиз-тиз мәчеткә ашыкканнан-ашыкты.

* * *

Вахид хәзрәтнең чәй ясап тора торган Сәгыйдәгә күзе төште. Берни дә юк... Һаман иске самоварлар, иске хуш исле чәй исе, иске җиһазлар...

Һәммәсе иске... Сәгыйдә дә иске Сәгыйдә... Ләкин... Аның күзенә сыек кына әллә ни сөртелгән...

Әйе, сөртелгән!..

Моңлык, кайгылык сөрмәсе тартылган...

Маңгаенда да яңа бер сызык бар...

Яңа...

Вахид аны күргәне юк иде...

Әйе, аның бөтен йөзендә әйткәннән чигенмәү язылган...

Бу элгәре юк иде...

Әллә Вахид күрмәде генәме икән?..

Эчендә әллә нинди эчне пошырып тора торган ят нәрсә, 12 ел дәвамында бер мәртәбә дә күрмәгән, хис итмәгән ят нәрсәне тойды, сизенде. Аның күзләре Сәгыйдәнең күзләренә очрашты. Ул күзләр биниһайә[1] тирән, төпсез кебек күренде.

---

[1] *Биниһайә* — чиксез.

Вахид теге ятлыкны биргән нәрсә, моның тыныч күңеленә теге үги дошман фикерне суккан нәрсә шул күзләр икәнен бердән хис итте.

Сәгыйдә, йомшак кына көлеп:

— Хәзрәт, синең әллә ник кәефең юк...— диде.

Вахид хәзрәт ачуланган тавыш белән:

— Юкны сөйлисең! — дип җавап кайтарды.

Сәгыйдә, йөзенә тагы көләчлек кушып, баягы күзенә тагы әллә нинди көч кушып:

— Хәзрәт, юкны сөйләмим. Унике ел бергә торамыз... Әлхәмделиллаһ, көнемез иркен... Дәүләтебез мул... Ләкин, хәзрәт, боларга хуҗа кем? Без шуларга хуҗа таба алмадык... Мин, хәзрәт, сиңа бала бирә алмадым... Хәзрәт, әле өмет бетмәгән... Хәзрәт, сиңа өйләнергә кирәк!.. Пәйгамбәрләр дә өйләнгән... Шуның өчен, хәзрәт, менә мин сине өйләндерергә кирәк дигән уйга килдем... Сиңа яучы булмакчы булдым. Кызын да таптым. Үзе инсафлы. Үзе тәрбияле. Үзе укыган. Үзе чибәр. Фәхри абзый кызы Галимә... Миңа, хәзрәт, рөхсәт бир! Мин Зөлфия абыстайга яучы булып барыйм...

Сүзнең ахырын әйтеп бетерә алмады, Вахид хәзрәт сикереп торды. Ямьсез тавыш белән:

— Ахмак, тик тор! — диде.

Шул сүзләрне ул Сәгыйдәгә гомерендә беренче мәртәбә әйтсә дә, шулкадәр куәтле чыкты: ул үз тавышыннан үзе куркып китте. Сәгыйдә һаман көләч йөзе белән, керфекләреннән батырлык чыгып тора торган күз белән Вахидның күзен каршы алды.

Вахид, аның күзендә әллә никадәр мәхәббәт, шәфкать кушылган көч күреп, шуңарга ачуы чыдый алмаганны сизеп, ишекне бик каты ябып чыгып китте.

Сәгыйдә, хәзрәтнең балага мәхәббәтен тагы арттырыр өчен, авылның бөтен матур балаларын, әле берсен, әле берсен алып килеп сөя башлады.

Бер мәртәбә ул бүлмәдә чигеш чигеп тора торган Галимәне күрсәтер өчен: «Хәзрәткәем, бүлмәдән комганыңны үзең ал! Сыерым моңаеп тора»,— дип, Галимә өстенә кертте.

Ләкин шул күрүләр, очрашулар вакытлы гына булса да, нә хәзрәтнең күңелендә вәсвәсә тудырды, нә гаилә тормышын үзгәртү хакында бер уй башка сукты.

Ул һаман элгәреге ышаныч белән — «Сәгыйдәдән башка хатын юк» фикере белән яшәде дә яшәде.

* * *

Беркөнне хәзрәт әллә нишләп суык тидереп кайтты. Икенче көнне намазга чыга алмады.

Дүртенче, бишенче көннәрне хәзрәт ятактан тормады. Алтынчы, җиденче көннәрне хәзрәт каената хәзрәтне алдырды, күрше авылдан берничә мулланы чакыртып, васыять язарга кушты. Фидиясен әйтте. Бурычлары чыкса, түләргә сумма күрсәтте.

Шуннан калган йортын-җирен, мал-туарын — бөтен дәүләтен Сәгыйдәгә яздырды.

Картларның берсе:

— Хәзрәт! Авылымызны яктырткан идең, мәчетемез, мәдрәсәмезгә нур керткән идең, безне калдырып китәсең? Михрабыңны[1] кемгә калдырасың? — диде.

Вахид хәзрәтнең авыру башында шул уй тагы чуалчык булып басты.

«Михрабыңны кемгә калдырасың?..»

Шул михрабта менә йөз дә унбер ел бер нәселнең балалары имам булып килделәр.

Инде ул буын өзелә!.. Вахидның баласы юк...

Вахидның: «Әнкәңне тыңла, әнкәңә итагать ит!» — дип васыять әйтеп калдырырга да угылы юк...

Шәт, Сәгыйдә теге көнне хаклы иде...

Ул, озын иттереп, зәгыйфь күзендәге бөтен көчен җыеп, Сәгыйдәгә карады.

«Бу хатын бөтен барлыгын миңа бирде. Минем тормышымны оҗмах ясады... Хәзер менә үләм, моңар ни калдырам?.. Моны кемнең каравына тапшырам?..

Теге вакытта аның сүзен тыңлаган булсам, бәлки, аның хәзер бер угылы булыр иде...»

Менә әллә ни булды... Вахидта үзенең угылын күрәсе килү теләге туды.

* * *

Озын сырхаудан озынлап терелгәндә хәзрәтнең уйларга вакыты бик күп булып, шул очсыз уйдан бер нәтиҗә чыгардымы, алар яңадан бер мәртәбә сөйләмәенчә дә шул фикердә Сәгыйдә белән бер сүзгә килделәр.

Шуны да сүз белән түгел, тойгы белән, әллә ничек, күзгә-күз карашу белән аңлаштылар.

---

[1] *Михраб* — мәчеттә намаз уку урыны.

Кич буе алар икәүләп бөтен туй яракларын санап чыктылар.

Шул эшләрен һәммәсен угылларын өйләндерә торган карт белән карчык кебек шат эшләделәр.

Шул ук туй кәефе белән Сәгыйдә Зөлфия абыстайга яучы булып та барды.

Никях көне җиткәч, шул ук кәеф белән хәзрәтне үзе мунчага кертте, үзе яңа күлмәкләр кидертте.

Үзе хәзрәтнең сакалын, мыегын төзәтте.

Атка утыргач та хәзрәтнең: «Хуш, Сәгыйдә!» — диюенә каршы тагы ук шул шатлыклы, көләч йөз белән: «Хуш, хәзрәт, хуш, сау бул!» — диде.

Ул кияү озатуны карарга килгән әллә никадәр балага да, туй төсе булсын дип, бүләкләр бирергә онытмады.

Ястүдән соң, гади көндәге шикелле, урын салды.

Түшәкне кабартты, ястыкны күпертте, япмаларны пөхтәләп япты.

Ләкин, ни өчендер, ул шул урынга якын килә алмады...

Ул унике елда беренче мәртәбә шул урыннан суыклык хис итте.

Бердән бөтен йөрәген салкын тимер белән каерып алган кебек булды. Ике күздән мөлдерәп ага торган күз яшьләрен туктата алмавын, кайгыга сабырсызлык булмасын дип, Аллага ялварырга, ялынырга башлады.

* * *

Икенче көнне иртүк кияү чәенә Сәгыйдәне алырга килгән атка утырып баргач, калтырабрак каршы чыккан Зөлфия абыстайга да ул һаман элгәреге кебек көләч йөз белән: «Исәнме?» — диде.

Хәзрәт бикәчли торган өйнең ишегенә җиткәч кенә, бердән, алдында упкын ачылган кешедә була торган кебек кот очу аны биләде. Сәгыйдә тагын көчен җыйды.

Аның күзләре Галимәнекенә очрарга өлгермәде: Галимә, иелеп, башын бөкте, йөзен яшерде.

Хәзрәт туп-туры иттереп Сәгыйдәгә карарга батырчылык кылмаса да, Сәгыйдә һаман шул көләч йөз, һаман шул хәтфә тавыш белән: «Исәнме, хәзрәт?» — дигәч, ул акыртын гына күзен күтәрде.

Сәгыйдә, кара сыманрак күлмәк киеп, кара өстендә ак бизәкле яулык бәйләгән.

Йөзе балавыздан ясаган кебек ап-ак.

Күзләре ут кебек яна, аларның төпләре тәмам беткән — упкынга әйләнгәннәр.

Маңгаена әллә нинди бер зурлык чыккан.

Бакышы — падишаһлар бакышы...

Йөреше — баһадирлар йөреше.

Ул алга атлаган саен, шундагы кешеләрне, өйне, бөтен тирәюньне вакландыра бара.

Ул якынайган саен зурая, үсә бара.

Вахид бердән сикереп торды.

Кояшка караганда күзнең чагылуыннан курыккан кебек, оялып кына Сәгыйдәгә таба карады...

Аның падишаһ кебек бөеклегенә сыгыныр өчен, тиз-тиз каршы барып, күңеленнән аның алдына тезләнде.

Үзе кызарып, үзенең кечкенәлегенә кызарып:

— Исәнме, Сәгыйдә?— дип, калтырый-калтырый гына, күрешергә кул сузды.

Сәгыйдәнең суык кулын алгач, йөрәгенә зур салкын агым кереп китеп, тагы аны өшетте, дерелдәтте.

Сәгыйдә Галимә белән күрешкәндә дә көләчлеген югалтмады.

Ул чәй янында хәзрәт белән бик матур сөйләгән кебек, Галимә белән дә бик йомшак, бик шәфкатьле кыланды.

Сәгыйдә чыгып киткәч тә, хәзрәт бик озак Сәгыйдәнең соңгы сыйфатын, сынын күз алдыннан җибәрә алмады. Шуның алдында иелгән башын күтәрә алмады.

Падишаһ кебек олугъ, фәрештә кебек шәфкатьле көндәшкә каршы Галимәне дә дошманлык, көндәшлек хисе били алмады.

Аның дошманлыгы Сәгыйдәнең йомшаклыгына, аның балага йомшаклыгы кебек шәфкатенә бәрелеп эреп киткән кебек булды.

Хәзрәт, бикәчләүне бетереп, Галимәне өйгә төшергәч тә, шул хис — Сәгыйдәнең олугълыгы хисе кимемәде.

Галимә, мулла хатыны булып китеп, мәҗлесләргә йөри башлагач та, бөтен эшләр, бөтен хәрәкәтләрнең Сәгыйдәгә ияргәнлеге бетмәде.

Шунысы гаҗәп: Галимә аналыкка чыгып бала тудыргач та, хәзрәткә дә, Галимәгә дә чын ана Сәгыйдә булып урнашты.

Ул гына да түгел, балалар, үсә башлагач, беренче сүзне әйткәндә дә иң беренче «әннә, әннә» дигәнне Сәгыйдәгә эндәште.

Зурая башлагач та бөтен балалар, чын әни — Сәгыйдә дип ышанып, Галимәгә бик озакка кадәр «әни» дияргә базмадылар.

Балалар күбәйде.

Бала тәрбиясе, бала мәшәкате хәзрәтнең дә, Сәгыйдәнең дә бөтен тормышын тутырды.

Алланың биргән бер елында Галимә абыстай йә бер кыз, йә бер угыл багышлап торса да, хәзрәт үз кулы белән метрикә дәфтәренә исемен «атасы Вахид, анасы Галимә» дип язып торса да, ул үзен үзе һаман бер хатынлы иттереп хис итте; бер хатынлы иттереп уйлады.

Галимә һәрвакыт бергә булса да, хәзрәткә дә, Сәгыйдәгә дә матур балалар багышласа да, әллә ничек, ул хәзрәткә хатын булып, бала анасы булып күренмәде.

Ул шунда җарияме, кәнизәкме?.. Әллә нәрсә генәме булды да калды.

1914—1915 ел

Давыд Гобәйди

ТАҢ АЛДЫ

Әтрафны[1] караңгы зольмәт басса,
Йолдызлар да берсе артыннан берсе качса,
Капласа болыннарны куе томан,
Күк читендә әкрен генә ак ай батса,
Курыкма, дус! Ач күзең: таң алды бу!—
Бары шуның өчен генә караңгы бу!
Кузгалса елан, кәлтә хәшәрәте,
Чебен, кортның калмаса хәсарәте[2],
Аһ орса Җир шары, кайгысыннан,
Курыкма: бу — таң алды бәшарәте[3]!
Кара төн кара шәлен бөкләп япса,
Үлекләрдәй, тыныч кына йоклап ятса,
Сирәк-мирәк өреп, этәчләр дә
Мәгънәсен шигырьләрен күпләп сатса,
Бу йокы — таң йокысы. Караңгы бу.
Бары шуңа — кайгырма: таң алды бу!

---

[1] *Әтраф* — тирә-як.
[2] *Хәсарәт* — чикләү.
[3] *Бәшарәт* — сөенче.

ТОРМЫШ ХӘБӘРЛӘРЕ

Сорадым бервакыт җилдән: «Аманмы?
Ничек кайтарыйм, әйтче, яшь заманны?»
Җавабында диде җил: «Йөр очып син,
Минем кебек төтендәй һәм кучеп син».
Чабып киттем, көнем кичкә авышкан,
Күрәм: диңгез үкермәгә ябышкан.
Дидем: «Дускай, олуглык кайда, әйтче?»
Диде: «Миндәй үкер, бакыр, тавышлан».
Сорадым мин күреп нурлы кояшны,
Түгеп алдында күздән канлы яшьне:
«Ничек кызылланыйм ал төсле кандай,
Ничек һәм нурланыйм ал, моңлы таңдай?»
Көтәм, көтәм — җавап юк һич кояштан,
Фәкать ишетте җан: «Ян! Ян! Тоташ ян!»

Заһидә Бурнашева

ЯЛКЫНЛЫ ЙӨРӘКТӘН

Туктамас күңлем очудан, яшь йөрәк ярсыр әле,
Изге, ак нурлар сибеп, йолдызларым балкыр әле.
Сафланыр кәгъбәм[1] санәмнәрдән[2], ачар идеал йөзен,
Балкытыр назлы, сихерле, пакь фәрештәм ал йөзен.
Тик илаһи дәрт күкрәкне яндырсын гына,
Изге илһамына тәңрем кальбеме яксын гына.

СӘБАТ[3]

Төшмә, рухым, сүнмә, и күкрәктәге ут чаткысы!
Сүнде, дип, күктә өмит йолдызларыңның яктысы.
Курыкма, юк, сүнмәс алар, бу күкрәгең тик бер болыт
Каплаган, йолдызларның төшмәсен, дип, яктысы.
Бел: үтәр бу тау-болытлар, яктырып тормыш юлың,
Алдагы көннең берендә елмаер нур яктысы.
Кой, чылатсын битләремне күз яшем... Ул да бетәр,
Яңгыр артыннан үсәр күкрәктә гөлнең аллысы.
Булмасын күңелдә «кер», тик андагы шәм сүнмәсен,
Шиңмәсен күкрәктәге «дәрт»нең яшел яфраклары.

---

[1] *Кәгъбәм* — кыйблам.
[2] *Санәмнәрдән* — гыйбадәт кылыр өчен ясалган сурәтләрдән.
[3] *Сәбат* — чигенмәү.

Шәриф Камал

ХАҖИ ӘФӘНДЕ ӨЙЛӘНӘ

КОМЕДИЯ

3 пәрдәдә, 4 картинада

КАТНАШУЧЫЛАР:

Юнус хаҗи.
Галимә — аның хатыны.
Камилә — мөгаллимә.
Нәгыймә — Камиләнең тутасы.
Җәлал — артист.
Габделхак — шагыйрь.
Хөснетдин — маклер.
Шакир.
Хәйретдин — малай.
Мөгаллим.
Нәсимә — яучы.
Артистлар.

БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

БЕРЕНЧЕ КАРТИНА

Җәлал квартирасы. Җәлал мандолина уйнап утыра. Нәсимә карчык керә.

Нәсимә. Исәнме, балакаем. Исән-сау гына торасыңмы?

Җәлал. Ә, Нәсимә әби. Әйдә, ни йомыш? Хаҗи нишли?

Нәсимә. Минем сүзне тыңла. Син Камиләгә ныгытып әйтсәң, ул синең сүзеңә күнәр. Усалмы, яхшымы, син аның абзасы. Ата урынына калган кеше ләбаса. Ул чагында синең Камилә сеңлең, дөбер-шатыр губернатор хатыны шикелле, ялтыравыклы тарантасларда тузаннар туздырып йөрер. Син дә хәзерге шикелле адәм көлкесе кәмитшик булып йөрү урынына, хаҗи әфәнденең берәр магазинында зур приказщик булырсың.

Җәлал. Ә син өр-яңа ефәк чапан бөркәнеп, вак-вак атлап, чыж-чыж...

Нәсимә. Әйе, бик дөрес әйтәсең. Әйтеп бетермәдең әле. Каюлы читек, резин галуш киеп, шылт-шылт... Тик, зинһар өчен әйтәм, эшне тизләтергә кирәк. Хаҗи әфәнде бик ашыктыра.

Тышта эт өргән тавыш. Хаҗи аптырап килеп керә.

Хаҗи. Әссәламегаләйкем! Сау-исән генә торасызмы? Әһле бәйтегез[1], кавем-кабиләгез, ыруг-кардәшләрегез исән генә торалармы?

Җәлал. Бик исәннәр хәзергә, хаҗи әфәнде. Ыруг-кардәш, кавем-кабилә, һәммәсе сау, сәламәтләр.

Хаҗи. Бәрәкалла, бәрәкалла. Исәнлек кирәк, исән булган яхшы.

Нәсимәгә башы белән ымлап куя. Нәсимә урыныннан тора.

Нәсимә. Ярый, хушыгыз инде алайса, мин китеп торыйм.

Җәлал. Килгәли тор. Онытып куйма.

Нәсимә. Ярый, ярый, боерган булса, иншалла, килермен. Килми ни...

Хаҗи. Ярар, ярар. Шулай итәрсең, фаразан.

Нәсимә. Бер эшне башладыммы, башкарып чыкмый туктый торган гадәтем юк, хәтта...

Хаҗи. Җитәр инде, фаразан, күп сөйләп торма.

Нәсимә. Хаҗи әфәнде бер изге эшне миңа тапшырган икән...

Хаҗи. Фу, сине эттәгенәсе!..

Нәсимә. Ярар, ярар... Бетте, хуш иттек. *(Чыга.)*

Хаҗи. Менә шул була инде Нух пәйгамбәр каргасы. Бертуктаусыз каргылдый да тора, әкият! Ә үзенең һич рәте юк. Шуңа күрә, тукта, мин әйтәм, бу хәерсездән эш чыкмас, үзем генә барып, эшне яхшылап аңлатыйм әле. Җәлалетдин гакыллы егет, аңлар ул мине, дим, фаразан! Мин эш кешесе, минем вакытым кадерле. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам яхшы эшне ашыктырырга кушкан.

Җәлал. Пәйгамбәр ашыктырырга кушкан кушуын да бит, хаҗи әфәнде, әнә сеңелнең бер дә ашыгасы килми. Хаҗи әфәнденең хатыны бар, фәлән-төгән дигән була.

Хаҗи. Булды, алайса. Бәрәкалла, машалла, барып чыкты дигән сүз.

Җәлал. Ничек?

Хаҗи. Авыру ич ул!

Җәлал. Кем авыру?

Хаҗи. Минем хатын, Галимә абыстаң, ягъни мәсәлән. Озакламый үлә инде, фаразан.

---

[1] *Әһле бәйт* — өйдәге кешеләр, ягъни гаилә.

Җ ә л а л. Нинди авыру икән ул, хаҗи әфәнде?

Х а җ и. Шул инде, әҗәл зәхмәте[1], фаразан. Менә алай булса, мин сиңа үземнең хәлемне сөйлим... Мин Кәгъбәтуллада[2] хаҗ кылган вакытта бер хикмәтле төш күрдем. Төшемдә Мөхәммәт Галәйһиссәлам миңа болай диде: «Әгәр дә, ул әйтә, бер ысул җәдид мөгаллимәсен хәләл җефетлеккә алмасаң, нихәтле генә гыйбадәт, нихәтле генә хаҗлар кылып йөрсәң дә, барыбер иманың зәгыйфь, урының җәһәннәм булыр»,— ди. Аңлыйсыңмы?

Җ ә л а л. Аңлыйм, аңлыйм. Чынлап та, эшегез хәтәр икән, хаҗи әфәнде.

Х а җ и. Хәтәр шул, Җәлалетдин энем. *(Күзләрен сөртә.)* Бар ышанычым синдә генә. Кыз-хатын — ул туганнар сүзенә караучан халык, син ныгытып әйтсәң, иншалла, күнәр ул.

Җ ә л а л. Эш алай булганда, бик ныгытып әйтәм инде мин аңар. «Син, сеңел, хаҗи әфәнденең иманын ныгытырга ярдәм итә күр инде. Югыйсә аның иманы чак-чак эләгеп кенә тора»,— диярмен.

Х а җ и. Шулай әйтә күр инде, зинһар, энекәем. Аннан соң менә нәрсә: әгәр без аның белән бер-беребезгә охшап китсәк, фаразан, яратышсак, тотам да ярты дәүләтемне аның исеменә яздырам.

Җ ә л а л. Анысы күбрәк булмасмы, хаҗи әфәнде? Аның чиреге дә җитеп торыр, минемчә. Бәлки, сез миңа бурычка бераз биреп торырсыз?

Х а җ и. Ә ул икенче мәсьәлә. Әмма яшь бикәчкә ярты дәүләтемне яздырам, Алла боерган булса. Ә сиңа бурыч биреп тору, бәлки, мәслихәт булыр, аны уйлашырбыз. Тик сиңа кәмит уйнап йөрүне ташларга кирәк булыр, фаразан. Мин сине үземнең бер магазинга приказщик итеп куярмын, Аллаһ боерган булса. Ул чагында бурыч бирүнең кирәге дә булмас, фаразан.

Җ ә л а л. Ярар, уйлашырбыз.

Х а җ и. Мин әйткәннәрне оныта күрмә инде, җаным. Галимәнең авыру икәнен, тиздән үләчәген, төш күргәнлегемне, ярты дәүләтемне яздыру турында — һәммәсен бәйнә-бәйнә колагына тукыштыр, яме. Хуш, җаным, хуш, энекәем. *(Чыга.)*

К а м и л ә белән Г а б д е л х а к керә.

---

[1] *Әҗәл зәхмәте* — үлем авыруы.

[2] *Кәгъбәтулла* — Мәккә шәһәрендә гыйбадәт йорты.

Җ ә л а л . Нәсимә әби тагы килгән иде, аның артыннан ук Юнус хаҗи үзе дә килеп җитте. Эш җитди төскә кереп бара. Сеңел, синең алдыңда хәзер ике юл тора: берсе — пар ат җигелгән ялтыравык коляскага утырып, карт хаҗи белән китәргә. Плюс аның ярты дәүләте. Икенчесе — тәпи-тәпи генә атлап, яшь шагыйрь белән җәяү китәргә. Плюс түшләрегезгә эләктереп куйган сирень чәчәкләре. Башка бер әйбер дә юк. Менә сайла инде. Ярар, минем роль укыйсым бар. *(Бүлмәгә кереп китә.)*

К а м и л ә . Габделхак әфәнде, гафуыгызны үтенәм. Минем иртәгә дәрескә хәзерләнәсем бар. Икенче вакыт иркенләп утырырбыз. Яме? *(Икенче бүлмәгә керә.)*

Пәрдә

ИКЕНЧЕ КАРТИНА

Пәрдә ачылганда, К а м и л ә укып утыра.

Г а б д е л х а к (*кереп*). Рөхсәттер дип уйлыйм. (*Кулын үбә.)*

К а м и л ә. Әһи, сез бүген әллә нишләп киткәнсез, шагыйрь әфәнде. Тфү, тфү, күз тия күрмәсен.

Г а б д е л х а к. Камилә туташ миңа шулай караса, мин үземә күз тиюне бик зур бәхеттән санар идем.

К а м и л ә. Бер яшь шагыйрь шулхәтле купшы булсын да, аңар сөеп карый алма, имеш. Мин сезнең шигырьләрегезне яратып укыйм.

Г а б д е л х а к. Камилә туташ, башкалар теләсә ни әйтсеннәр, минем өчен барыбер, тик бер генә кеше мине шатландыра һәм шулай ук хәсрәтләндерә ала.

К а м и л ә. Менә ничек. Габделхак әфәнде, сез утырып торыгыз, мин хәзер чыгам. *(Бүлмәгә керә.)*

Г а б д е л х а к. Ничек кенә итеп моңар эч серемне ачыйм? Юк инде, бу юлы да калдырырга ярамый. Гыйшык тотасың икән, нык бул, егет!

К а м и л ә керә.

Камилә туташ, сез мине кызганыгыз, аяк астыгызда туфрак булыйм. Мин сезнең илаһи матурлыгыгызга җанымны бирергә әзер. (*Тезләнә.)*

Х ө с н е т д и н, Ш а к и р, Н ә г ы й м ә, Җ ә л а л көлешеп килеп керәләр.

Җ ә л а л. Билләhи, кызык итәбез. Ә, шагыйрь әфәнде дә монда икән. Исәнме, иптәш?

К а м и л ә. Кергән чакта нәрсә дөнья кубарып шаулаша идегез?

Җ ә л а л. Эндәшмә, сеңел, хаҗины кызык итәбез. Кабахәт нәрсә, hич бит шул фиргавеннән котылыр хәл юк, иптәш. Тәмам гакылдан шашкан.

Г а б д е л х а к. Эзең булмасын бу тирәдә дип, нишләп өзеп кенә әйтмисең? Син аңардан файдаланырга уйлыйсың бугай, Җәлал?

Җ ә л а л. Исәп юк түгел иде түгелен. Ләкин Юнус хаҗидан файда, шайтаннан иман — икесе бер чамадыр, ахрысы. Бурычка дигән булып азрак кылын тартып караган идем, бер дә кымшанмый, ләгънәт!

Г а б д е л х а к. Димәк, мәсьәлә мин уйлаганча булып чыга, ярар. *(Чыга.)*

К а м и л ә. Йә, әйтегез инде, шул кабахәтне өстерәлдереп йөртеп, нишләмәкче буласыз?

Х ө с н е т д и н. Хаҗиның үз хатынын үзенә бирмәкче булалар. Әй, егетләр, эшегез пешмәс бит, ышанмыйм, булдыра алмассыз бит, әмма да кәмит булыр иде соң булдыра алсагыз.

К а м и л ә. Юк, юк, абзый, зинhар дип әйтәм, алай шаярырга ярамый. Кирәкми, мин андый эшләрдән куркам, абый. Әнкәй дә бу эшкә hич риза булмас.

Х ө с н е т д и н. Түтинең риза булуы монда кирәкми, безгә генә чакырып алырбыз, сизми дә калыр. Ул барыбер хаҗига күренеп йөрми бит.

Г а б д е л х а к керә. Ишек кагалар.

Т ы ш т а н. Керергә рөхсәтме?

Җ ә л а л. Рөхсәт, рөхсәт, хаҗи әфәнде, хуш киләсез.

Х а җ и. Әссәламегаләйкем!

Х ө с н е т д и н. Вәгаләйкемәссәлам! Хаҗи әфәнде, әйдә рәхим итегез.

Х а җ и. Син соң кем буласың? Болай күргән кешегә дә охшатам үзеңне.

Х ө с н е т д и н. Минем исемем, хаҗи әфәнде, Хөснетдин, әткәм мәрхүм Мөхетдин, фамилиябез Гайнетдиновлар дип йөртәләр.

Х а җ и. Гайнетдиновлар? Әй, алай икән, яңа фирмадыр шул, бер дә колагыма чалынган юк төсле.

Х ө с н е т д и н. Булмас шул, хаҗи әфәнде, безнең фирма түгел... болай... ваграк кәсеп.

Х а җ и. Фирма булмагач, нәрсәгә соң Гайнетдиновлар дип торган буласың? Гайнетдинов кына дисәңче!

Җ ә л а л. Монысы шунда безнең кардәш тиешле кеше, хаҗи әфәнде.

Х а җ и. Ата-аналары бармы соң, фаразан?

Җ ә л а л. Әйт инде... Бар, хаҗи әфәнде, атасы да бар, анасы да бар.

Х а җ и. Атаң үзе зур дәүләтле кешеме соң, энем?

Г а б д е л х а к. Юк, ул дәүләтле кеше түгел, тегүче.

Х а җ и. Шулай булгач, нәрсәгә соң, җаным, бик ул хәтле господаларча кыланган буласың?

Г а б д е л х а к. Анысы инде минем эш, бабай.

Х а җ и. Ә... ә... шулаймы?.. Хи-хи-хи... Мин тегеләй генә әйтәм, энем, чынга ала күрмә тагын. Яшьләр фырт кыланырга яраталар. Минем үз приказщикларымның берсе казаки астыннан, менә *(Габделхакның жилеткасын тотып күрсәтеп)* шундый кечкенә пальто да киеп алган, әкият.

Г а б д е л х а к. Пальто түгел ул, хаҗи әфәнде, аңар жилет диләр.

Х а җ и. Урыс киеме булгач, барыбер лә инде ул, энем, пальто дибез без аңар, мөселманча исеме шулай аның. Юкны боргалап маташкан буласың. Инде бу егетне кем дип белик?

Җ ә л а л. Һәммәсе дә үзебезнең якын кешеләр, чит кеше берәү дә юк. Кайсы кияү, кайсы туган, кайсы тегеләй-болай — бар да үз кешеләр.

Х а җ и. Шулай булгач инде — әлеге серне алар да беләләр булыр бит?

Җ ә л а л. Беләләр, хаҗи әфәнде, алар белән дә мәслихәтләшеп алган идек.

Х а җ и. Хуш, җаным, хуш.

Җ ә л а л. Әлбәттә, арада кирегә кагучылар да булды. Картрак имеш, фәлән имеш, төгән имеш... Беләсең бит бу заманда...

Х а җ и. Мине карт диләрме? Сөбханалла, мине карт диләрме?.. Кара син аларны, әле менә кырык биштән узганыма унунбиш ел бармы, юкмы — алар карт диләр.

Җ ә л а л. Тик менә, хаҗи әфәнде, бер ягы бераз уңайсызрак булып тора: сеңелнең никяхка яше җитми.

Х а җ и. Ә... ә... шулаймыни? Нихәл итәбез соң инде?

Җ а л а л. Әгәр сез риза булсагыз, бер чара бар барын. Әнкәй әйтә: әгәр Хаҗи әфәнде риза булса, ди, хәзергә үзебезнең хәлфәдән генә алдым-бирдем ясатып алыйк, ди. Яше тулгач, ди, хәзрәтләр чакыртып, һәйбәтләп туй ясап, форменный никях укытырбыз, ди.

Х а җ и. Мәгъкуль, җаным, бик мәгъкуль, бәрәкалла, машалла, фаразан.

Х ө с н е т д и н. Әйе, әйе, нәрсә чит кешеләр чакырып туй ясарга, үзара гына эшне бетерәбез, вәссәлам.

Х а җ и. Бик яхшы, бик яхшы. Хуш, инде ничек соң, энем, мелла Җәлалетдин? Син бит инде, әлбәттә, ягъни мәсәлән, йорт башы, фаразан, мәһәрне ничегрәк куябыз инде, ху-уш-ш?

Җ ә л а л. Анысы инде, хаҗи әфәнде, үз ихтыярыгызда.

Х а җ и. Хуш, менә алай булса, үз белүемчә биш йөз сум билгелим.

Җ ә л а л. Бик җиткән, үзебез дә шулайрак чамалаган идек, хаҗи әфәнде.

Х а җ и. Шулай, җаннарым, шулай. Ягез, бер дога кылыйк. Ярый, Хода хәерле кылсын. Әйе, хуш... Инде, энем, алдым-бирдем эше ничегрәк соң? Фаразан, кайсы көнгә диебрәк тәгаен итәбез инде?

Җ ә л а л. Әгәр, хаҗи әфәнде, сез риза булсагыз, шушы киләсе якшәмбегә булсын иде.

Х а җ и. Бик мәслихәт, бик мәгъкуль, хи-хи-хи... Киләсе якшәмбе сәгать тугызда, бик хуп, бик мәгъкуль. Ягез, алайса, дога кылыйк та, миңа риза бирерсез, җаннарым... Хушыгыз алайса, җаннарым!

Х а җ и чыга.

Г а б д е л х а к. Мин бу эшкә протест белдерәм, Җәлал. Хаҗиның биш йөз сум акчасына кызыгып, син үзеңнең туган сеңлеңне сатасың! Позор! *(Чыга. Көләләр.)*

Пәрдә

ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Юнус хаҗи квартирасы. Х а җ и үзе генә.

Х а җ и. Хи-хи-хи... Якшәмбе көн сәгать тугызда, диген, ә? Хи-хи-хи...

Г а л и м ә *(керә)*. Ашыккан җитми, боерган җитә, диләр, әнә сиңа самовар.

Хәйретдин самовар алып керә, өстәлгә куям дигәндә, аягы сөртенеп, чак-чак кына ычкындырмый кала.

Хаҗи. Акрын, кабак баш, күзләрең чыкканмыни? Карап йөрмисең!

Хәйретдин чыга.

Күрәсем дә килми шул шайтанны. Нәрсә дип шул уңмаганны яклап маташа торгансыңдыр.

Галимә. Уңганнары безгә ярамыйлар. Үзеңне үзең тота белсәң, кеше төсле нәфесеңә хуҗа була алсаң, андыйлар да торыр иде. Чыдамнан чыгып бит икесен куып чыгардым, берсе, син аптыраткач, үзе тормады, чыгып китте.

Хаҗи. Нахак[1], Галимә, нахак. Җаным шикелле якын күрә торган хәлал хатыным була торып, әллә нинди асраулларга күз тотарга мәҗнүн[2] дип белдеңме?

Галимә. Сөйләмә инде, зинһар. Соң бит үз күзем белән күргән эш ләбаса. Наташаны кочаклап маташа идең бит.

Хаҗи. Ә... теге зур битле марҗа кызын әйтәсең икән син... Ул инде, Галимә, дөресен әйткәндә, шайтан вәсвәсәсе[3] белән булган эш. Ул чагында теге бәдбәхет иблис мәлгунь коткысына дучар булган идем, бәдбәхет, ул аздырды, йөзе кара нәрсә, юкса, менә Хода хәзер, Галимә, һич тә инде гаебем юк минем ул турыда.

Галимә. Ә теге Маруся белән нәрсә иде?

Хаҗи. Кем? Әлеге юан марҗаны әйтәсеңме? Куй инде шул кабахәтне, аңар мин үзем дә шаккатам. Әллә нишләп кенә Ходаның хикмәте күңелемне вәсвәсәләндерде. Юкса, Аллага шөкер, үземнең һич-һич гаебем юк. Тузан хәтле дә күңелемдә усаллык юк, фаразан, хи-хи-хи...

Галимә. Мәрфуганы онытыңмыни?

Хаҗи. Син дә инде, Галимә, кайдан гына казып чыгарасың... Хаталык белән андый эшләр була инде ул, фаразан.

Галимә. Җитмеш яшькә җитеп, инсафка килмисең. Элекке вакытларыңны хәтерләргә кирәк иде сиңа. Син бит йолкыш шәкерт кисәге, кибетче малай идең, мин синең баеңның кызы идем. Әткәйләрнең риза булмавына карамыйча, мин сиңа кияүгә чыктым. Син бит ул чагында хәтта минем кәвешемне

---

[1] *Нахак* — ялган.
[2] *Мәҗнүн* — тиле.
[3] *Вәсвәсә* — күңелгә салынган коткы.

үбәргә риза идең. Бервакыт әткәй мәрхүм безгә кибет ачып бирде. Шулай итеп, син дә бай булдың, соңыннан хаҗи да булдың. Ә мин инде синең каршыңда кирәксез, юләр мәхлук булдым. *(Елый.)*

Галимә чыгып китә.

Хаҗи. Менә әкият, кырык ел элек синең каршыңда фәрештә идем, имеш... Кырык ел элек фәрештә булгансың да бит, хәзер инде шайтан булгансың, фаразан. Бик җәнҗаллы нәрсә, хәерсез. Әлеге эшне тәмамлаганчы сизә күрмәсен тагы.

Хәйретдин самоварны алып керә. Галимә керә.

Галимә. Хәйретдингә нинди йомыш бар иде?

Хаҗи. Мәзингә кереп чыксын димәкче идем — чәчне алдырасы бар иде дим.

Галимә. Әле беркөн генә кырдырган идең түгелме соң?

Хаҗи. Әллә нәрсәсенә кычытып тора. Вакыты җиткәндер, ахрысы. Йә, мин ашыгам. *(Чыга.)*

Галимә. Мәзингә барып кайт! Хаҗи абзаңның чәчен алырга кереп чыксын дип әйттеләр диген.

Хәйретдин чыга. Нәгыймә керә.

Нәгыймә. Исәнмесез!

Галимә. Аллага шөкер, менә өстәл янына рәхим итегез! Мин сезне күргән кешегә дә охшатам.

Нәгыймә. Минем ирем Шакир исемле кеше. Садыйк байларда конторда хезмәт итә. Үз исемем — Нәгыймә.

Галимә. Хуш, нәрсә йомыш?

Нәгыймә. Өйдә кеше юкмы? Хаҗи әфәнде була күрмәсен.

Галимә. Юк, юк. Ул күптән түгел генә чыгып киткән иде.

Нәгыймә. Бәлки, үзегез дә ишеткәнсездер? Ул бит өйләнмәкче булып йөри.

Галимә. Әй, ләгънәт төшкән нәрсә! Мәлгунь! Кемне, кем дигәнне алмакчы була?

Нәгыймә. Миңа сеңел тиешле мөгаллимәне.

Галимә. Хуш, сеңлегез барырга риза буламы соң?

Нәгыймә. Риза булса, без мәслихәт күрсәк — сезгә хәбәр биреп тә тормас идек. Яучыдан бер эш тә чыкмагач, инде хәзер үзе йөри башлады. Мин ысул җәдид мөгаллимәсенә өйләнмәсәм, күңелем тынычланмаячак, иманым зәгыйфь булачак,

Тәгалә изге төш аркылы миңа моны белдерде, дип әйтә икән. Аптырагач, инде абыем әйтә: барып абыстайга сөйлә, ди. Ичмасам, нык кына мәсхәрәләп оятлы итик, ди, үзен. Сез риза булсагыз... Без аны, яшь кәләш янына китереп керткән булып, сезнең янга кертергә уйладык. Әгәр абыстай иренең борынына чиертергә теләсә, бүген кич белән сәгать тугызларда безгә рәхим итсен, ди.

Галимә. Каһәр сукканны бер кызык итәсе иде итүен... Чит кешеләр буласы түгелдер бит?

Нәгыймә. Юк. Чит кешеләр буласы түгел. Бар да үз кешеләребез генә булачак.

Галимә. Ярый алайса, бер кызык итик каһәр сукканны, бераз күңелем тынычланыр иде, ичмасам.

Нәгыймә. Ярый, хәзергә миңа рөхсәт бирегез инде. Мин кайтыйм.

Галимә. Хуш, исән бул.

Нәгыймә китә. Галимә озата чыга. Хаҗи белән Хөснетдин керәләр.

Хөснетдин. Сез мине танымыйсыз бугай, хаҗи әфәнде? Мин Камилә туташның әнкәсенең туганы, әлеге беркөнге Хөснетдин булам.

Хаҗи. Аны кергәч тә шулай әйтәләр. Уз, утыр, сөйлә, нәрсәләр бар соң? Камиләкәйнең кәефләре ничек, фаразан?

Хөснетдин. Аңар ни, кәефләре әйбәт. Хаҗи әфәндегә гашыйк-мәгъшук сәламен җитештер дигән булды.

Хаҗи. Бәрәкалла, машалла, гашыйк-мәгъшук сәламе диген, ә? Бәрәкалла, афәрин!

Хөснетдин. Тик менә үземдә рәт чамалырак, хаҗи әфәнде. Акча ягыннан кысылды да китте кеше. Эш болай, хаҗи әфәнде: бервакыт, әнә сез теге тимер күк айгырны алган чагында, миңа егерме биш сум маклерский бирергә вәгъдә иткән идегез. Әмма ләкин шуны бирмәдегез.

Хаҗи. Ничек булды икән соң ул, фаразан?

Хөснетдин. Сез миңа егерме биш сум урынына өч сум бирмәкче булган идегез, мин алмадым.

Хаҗи. Менә анысын хата эшләгәнсең, аласың калган.

Хөснетдин. Соңыннан өч сумны да алырга риза булган идем, әмма ул чагында инде сез өч сумны да бирмәдегез.

Хаҗи. Ә анысы минем хата булган, фаразан. Мин аны хәзер бирәм.

Хөснетдин. Мин, хаҗи әфәнде, сезгә зур ышаныч белән килдем. Инде ул кеше, кияү дә буласы булгач, хаҗи әфәнде вәгъдә иткән егерме биш сумын бирер, бәлки, бераз арттыра төшәр дип бик өметләндем.

Хаҗи. Өметләнгәнсең өметләнүен, ләкин өч сумнан артык бирә алмыйм, Хөснетдин әфәнде. Үз кеше булгач, сез мине дә чак кына кызганыгыз, фаразан. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә хәзрәтләре шәфкатьле, мәрхәмәтле бәндәләрне ярата, әйе.

Хөснетдин. Анысы шулайдыр. Әмма ләкин миңа акча кирәк. Мин өч сумны алмыйм. Чыгыша алмыйм мин аның белән. Миңа илле сум кирәк.

Хаҗи. Ничек илле сум? Саташтыңмы әллә син? Тәүбә диген. Ни өчен соң ул? Ни өчен кирәклеген әйтеп бир, Ходайның тинтәк бәндәсе.

Хөснетдин. Маклерский егерме биш сум. Булдымы? Шушы егерме биш сумны ике ел бирми йөрткән өчен, процент унбиш сум. Сеңелкәштән гашыйк-мәгъшук сәламе китергән өчен ун сум. Шулай итеп, барлыгы төп-төгәл илле сум булып чыга.

Хаҗи. Син мине нишләтмәкче буласың, ягъни мәсәлән?

Хөснетдин. Мин сезне бернәрсә дә эшләтергә уйламыйм, хаҗи әфәнде. Тик бары минем Камилә сеңелне кәләшлеккә алу уйларыгызны бөтенләй башыгыздан чыгарыгыз дим, ул чагында.

Хаҗи. Без бит ул турыда сүзне бетердек инде. Мин биш йөз сум мәһәр бирергә дә вәгъдә кылдым, фаразан.

Хөснетдин. Сезнең вәгъдәгез тавык төчкерегенә дә тормый бит. Бүтән кешеләрне сез кырык тапкыр алдарга мөмкин, ләкин мин үзем дә маклер, шартласагыз да мине бер тапкырдан ары алдый алмассыз.

Хаҗи. Чамадан тыш күп сорыйсың бит, җаным. Менә нәрсә алай булса: егерме биш сум бирәм.

Хөснетдин. Булмый. Вакытым юк. Ат базарына кичегәм. *(Чыга.)*

Хаҗи. Уф, мәлгунь, жулик, шарлатан. *(Тәрәзәдән тыгыла.)* Хөснетдин, Хөснетдин әфәнде! Кайт әле. Бирәм, бирәм диләр сиңа. Уф, нишләргә инде.

Хөснетдин *(керә)*. Булдымы?

Хаҗи. Менә сиңа кырык сум, артык, зинһар өчен дип әйтәм, сорама.

Хөснетдин. Их, ярар инде, алайса, каян килеп китмәгән! Хуш иттек. *(Чыга.)*

Хаҗи. Хуш, җаным, Хөснетдин әфәнде!.. Кабахәт, хулиган, Ходайның ләгънәте төшкере! Галимә, Галимә дим! Кая дөмеккәнсең?

Галимә *(керә).* Нәрсә бар? Нигә җикеренәсең?

Хаҗи. Җикеренерсең синең белән! *(Читекләрен сала.)* Монда бит өч бармак кына түгел, алты бармак сыярлык тишек. Шуны да карап бирмәгәнсең. Кая, чыгар әнә теге Мәкәрҗәдән алып кайткан лакирувный читекләрне. Нәрсә купшы киенден, берәр җиргә барасыңмы әллә?

Галимә. Туганым абыстайларга барып кайтыйм дигән идем.

Хаҗи. Бар, бар, хәлләрен белеп кайт. Икенде-ахшамнан соң Фәйзерахманнарга керергә эшем бар. Чәйгә мине көтмәсәң дә ярый. Тиз кайта алмамдыр, фаразан.

Галимә. Ярый, мин киттем, алайса. Әнә читекләрең дә шунда.

Хаҗи. Тугыз сәгатьтә диген, ә? *(Сәгатькә карый.)* Сәгать ярым вакыт бар икән әле, хуш.

Нәсимә керә.

Нәсимә. Исәнме, хаҗи әфәнде. Шатлык, бәхет эчендә яшь кәләш белән бергә-бергә гомер итегез.

Хаҗи. Шулай итик. Хуш, ни эш бетереп йөрисең, фаразан.

Нәсимә. Минем эш шул инде: дәртле күңелләргә дәрман табу. Кая, бераз хезмәт хакы кирәк иде бит.

Хаҗи. Туйдан соң, Нәсимә, туйдан соң, фаразан.

Нәсимә. Туй бүләге ул икенче, хаҗи әфәнде. Миңа хәзер бераз акча биреп торыгыз. Яучылый йөргән өчен.

Хаҗи. Кара, кара, әкият! Мин үзем яучыладым лабаса, Хода бәндәсе.

Нәсимә. Ә минем ун тапкыр баруымны санамыйсыңмы? Шуның өстенә биш тапкыр сүгеп сөрделәр. Маэмайлары ике тапкыр чапан чабуымны өзеп алды, бер тапкыр сыйрагымны тешләде. Шуларны исәпкә алмыйсыңмы?

Хаҗи *(счет сала).* Ун тапкыр бардым дисеңме? Унар тиеннән — бер сум булды. Биш тапкыр сүгеп сөрделәр дисеңме? Бишәр тиеннән — егерме биш тиен.

Нәсимә. Ай-яй!..

Хаҗи. Маэмайлары ике тапкыр чапан чабуыңны өзеп алды дисеңме? Анысына Галимәдән ямаулык сорап алырсың.

Нәсимә. Хи-хи-хи, нинди юмарт!

Хаҗи. Сыйрагыңны маэмай бер генә тапкыр тешләде дисең. Анысын да счетка салмыйм. Галимәдән агач мае алып сөртерсең. Димәк, барлыгы сиңа бер сум егерме биш тиен акча тия.

Нәсимә. Бер сум егерме биш тиен! Мине хәерче дип беләсеңме әллә? Оятсыз! Үзеңә булсын, жулик! *(Акчаны атып бәрә дә чыга.)*

Хаҗи. Нух пәйгамбәр каргасы! Алла боерса, иртәгә үк килеп шушы бер сум егерме биш тиен көмешне инәлеп-ялынып сорарсың. Әмма ләкин хаҗи әфәнде сиңа аларны биреп тормас инде! *(Акчаларны җыя.)*

Хәйретдин *(керә)*. Тегендә сезне бер кеше сорый. Кунакка алырга килдем, ди.

Хаҗи. Ә-ә-ә, Шакир әфәнде булырга кирәк. Булды бу! Кая син, яшь кәләш, җанкисәгем, киттем яныңа...

Пәрдә

ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге күренеш. Камилә гитара чирткәләштерә. Габделхак аның янында утыра.

Габделхак. Камилә туташ, дөресен әйтегез, байлык сезне ни дәрәҗәдә кызыксындыра? Байлык кешеләрне боза дигәнегез хәтеремдә.

Камилә. Аерым кулларда булган һәм аерым кешеләрнең генә теләкләрен үтәүгә хезмәт итә торган байлыкка мин хәзер дә шулай карыйм.

Габделхак. Беркөн сезнең кадерле абзагыз Җәлал сезне җилтерәтеп ялтыравыклы коляскага утыртып җибәрергә кереште.

Камилә. Әйдә, ул мәсьәләне калдырып торыйк.

Габделхак. Чәчәкләр кыйммәт түгел. Ләкин әгәр ул чәчәкләр җәмгыять тарафыннан шагыйрьнең бөек иҗатларына бәя бирү символы булсалар, ул чагында хаҗиның ярты дәүләте генә түгел, бәлки мең хаҗиның бөтен дәүләтләрен миллион кабат тапкырлаганда да ул чәчәкләр бәһасына җитәчәк

түгел. Миңа менә шундый чәчәкләр кирәк һәм мин аларга ия булачакмын.

Х ө с н е т д и н керә.

Х ө с н е т д и н. Шакир килмәдеме? Фу эттәгенәсе!

Г а б д е л х а к. Бай кеше белән туганлашасыгыз килә бугай?

Х ө с н е т д и н. Шулай шул. Дөньясы шундый.

Н ә г ы й м ә, Г а л и м ә керә.

Әйдә, әйдә, абыстайны әнә бүлмәгә керт, Нәгыймә.

Г а б д е л х а к. Камилә туташ, мин китим. Монда утыру минем өчен авыр һәм сезгә дә уңайсызлыйм.

К а м и л ә. Китмәгез. Сез миңа уңайсызламыйсыз. Утырыгыз, мин хәзер киләм. *(Чыга.)*

Җ ә л а л иптәшләре белән керә.

Җ ә л а л. Шагыйрь, исәнме?

Г а б д е л х а к. Бер шигырь язарга уйлап утырам.

Җ ә л а л. Нәрсә турында?

Г а б д е л х а к. Үземнең газап һәм шатлык катыш иң нечкә тойгыларымны ачып салырга уйлыйм.

М ө г а л л и м керә.

М ө г а л л и м. Әссәламегаләйкем, кодалар.

Җ ә л а л. Вәгаләйкемәссәлам! Кара әле, Иделгарский, син чалма-чапан алып киләсең калган. Кияүнең күңеле тәмам канәгатьләнсен иде инде.

М ө г а л л и м. На фчәки случай менә чалма алып килгән идем. Чалма булгач, казаки белән дә ярар.

Х ө с н е т д и н. Чапан кирәк, чапан. Иделгарский, кара әле, үзебезнең теге чапан ярамасмы соң?

Җ ә л а л. Ярар, ярар, шуны гына киярсең.

Г а б д е л х а к. Хаҗига нихәтле тәлинкә тоталар. Позор! *(Чыга.)*

1 н ч е а р т и с т. Нәрсәгә кәҗәләнә ул?

Җ ә л а л. Эшне аңламый ул! Камиләне чынлап та Юнус хаҗига кияүгә чыга дип уйлый.

А р т и с т л а р. Шулаймыни, ха-ха-ха!..

Җ ә л а л. Әйдә, башлагыз, иптәшләр.

Мөгаллимне киендерәләр, мыек ябыштыралар, музыка белән Х а җ и н ы каршы алалар.

Хаҗи. Әссәламегаләйкем. Иһи-һи!.. Думбыра чиертеп утырасыз, егетләр.

Җәлал. Рәхим итегез, хаҗи әфәнде.

Хаҗи. Бәрәкалла, машалла. Кавем-кабилә, ыруг-кардәшләрегез хәтсез генә икән, Җәлалетдин әфәнде. Ягез, утырышып, бер дога кылыйк. Бер-беребезгә догада булыйк, фаразан, пәйгамбәребез шулай итәргә кушкан.

Җәлал. Думбыра мәсьәләсе ничегрәк, хаҗи әфәнде?

Хаҗи. Бәгъзе бер риваятьләргә караганда, кяферләр белән сугыш заманнарында пәйгамбәребез Мөхәммәт Мостафа думбыра кагарга фәрман бирә торган булган. Никях мәҗлесләре, думбыра чирту, әлбәттә, күркәм һәм саваплы фигыльләрдән булса кирәк, әйе.

Хөснетдин. Алай булгач, егетләр, хаҗи әфәнде белән Камилә сеңелнең никях мәҗлесләре хөрмәтенә әйбәтләп чиерттереп җибәрегез булмаса.

Бию, бераздан соң мөгаллим керә.

Мөгаллим. Әссәламегаләйкем, хаҗи әфәнде. Исәнлек-саулыкмы?

Хаҗи. Вәгаләйкемәссәлам. Үзең исән-саумы, хәлфә?

Мөгаллим. Ярар алайса, бер фатиха бирик, җәмәгателмөслимин!

Дога кылалар.

Тагын киләсе кешеләрең юкмы? Ул чагында хәзер без эшкә керешик.

Җәлал. Элек чәй эчмибезме соң?

Мөгаллим. Юк, элек эшне тәмамлыйк.

Хаҗи. Башла, хәлфә әфәнде, хәерле сәгатьтә булсын, әйе.

Мөгаллим. Кыз тарафыннан вәли[1] вәкил үзең булырсың, Җәлалетдин әфәнде.

Хөснетдин. Кияү тарафыннан мине язып куй, хәлфә.

Хаҗи. Рәхмәт, бәрәкалла. Хөснетдин әфәнде, мин синең теге маклерскийдан тагын биш сумын бирермен, Аллаһ боерса.

Мөгаллим. Инде тулы исемнәрегез һәм әткәләрегезнең исемнәре кирәк.

Җәлал. Җәлалетдин Мифтахетдин улы.

---

[1] *Вәли* — яклаучы.

Х а җ и. Мөхәммәт Юнус Мөхәммәтрәхим углы, первый гилди купец, әйе.

М ө г а л л и м. Инде сез, шаһитлар, кызның ризалыгын барып сорагыз.

Җ ә л а л. Кыз риза инде, хәлфә әфәнде.

М ө г а л л и м. Юк, алай түгел, Җәлалетдин әфәнде. Шәригатьнең кушуын җиренә җиткерергә кирәк.

Х ө с н е т д и н. Әйдә, киттек, кияү.

Х ө с н е т д и н белән Ш а к и р чыга.

Х а җ и. Машалла, афәрин, хәлфә әфәнде, бик дөрес әйтәсең. Шәригать боерыгы буенча гамәл итәргә кирәк, ягъни мәсәлән.

Х ө с н е т д и н белән Ш а к и р керә.

Х ө с н е т д и н. Камилә Мифтахетдин кызы чын ихлас күңелдән хаҗи әфәндегә хәләл җефетлеккә чыгарга риза. Шуны сезгә җиткерергә кушты.

Х а җ и. Хи-хи-хи... Бәрәкалла, машалла... Мин электән үк, фаразан, шулай дип уйлаган идем.

М ө г а л л и м. Ул чагында дәвам итәбез. Мәһәрне ничек билгеләдегез?

Х а җ и. Анысын язмаганда да ярый, минемчә. Әйдә ике йөз сум яз инде, алайса.

М ө г а л л и м. Бирелгәнме инде ул?

Х а җ и. Юк, биреләчәк, алдагы көндә. Ягъни мәсәлән, сәүдәләр уңышлы барса, әйе.

Х ө с н е т д и н. Тукта әле, тукта, башта сөйләшкән чагында биш йөз сум дигән идегез түгелме соң, хаҗи әфәнде?

Х а җ и. Шулай дигән идем диюен, мелла Хөснетдин, ләкин зрә күпкә китә ул чагында. Сез мине дә азрак кызганыгыз, туганнар. Кысмагыз инде, Ходай Тәгалә хәзрәтләре аның өчен сезгә башка җирдән бирер.

Җ ә л а л. Ярар, хаҗи әфәнде, ике йөз сум җитәр. Ләкин бер йөз сумын хәзер бирсәгез яхшы булыр иде. Чөнки сеңелгә әйбәтрәк кием-салым юнәтмәкче идек.

Х а җ и. Ә, анысын мин үзем юнәтермен, Алла боерса. Ул яктан сез бер дә хафаланмагыз, фаразан.

Х ө с н е т д и н. Бер илле сум гына булса да кирәк иде, минемчә.

Х а җ и. Ярар, утыз сум биреп торам, алайса.

Мөгаллим. Ярар, төп эшкә керешик. Син, кем Җәлалетдин Мифтахетдин улы, үзеңнең туган сеңлең Камилә Мифтахетдин кызын Мөхәммәт Юнус Мөхәммәтрәхим улына хәләл җефетлеккә вәли вәкил булып бирдеңме?

Җәлал. Бирдем.

Мөгаллим. Син кем, Мөхәммәт Юнус Мөхәммәтрәхим улы, первый гилди купец, Камилә Мифтахетдин кызын хәләл җефетлеккә алдыңмы?

Хаҗи. Алдым.

Мөгаллим. Әлхәмделиллаһ, әлхәмделиллаһ... *(Никях хөтбәсе укый.)* Хода хәерле кылсын.

Хөснетдин. Хаҗи әфәндегә бәхетле тыныч гомер телибез.

Хаҗи. Рәхмәт, рәхмәт җаннарым, яхшы сүзегезгә. Мә ал, хәлфә, бераз садака бирим әле.

Җәлал. Мин дә бераз садака бирим, хәлфә әфәнде. Кая әле, кияү, минем өчен биреп кенә тор әле, вак акча калмаган икән.

Хаҗи. Ярар, үзем генә биреп торыйм, алайса, күпме кирәк?

Җәлал. Күпме дип инде... Бир әйдә бер биш сум, булмаса.

Хаҗи. Ярар, ярар, менә бер сум. Үзең бирерсең, ал!

Хөснетдин. Мин дә бераз бирәсе иде дә... Бер дә вак акчам калмаган икән...

Хаҗи. Ярар, хәерле булсын, алайса, вагың булгач бирерсең инде.

Җәлал. Җәмәгать, чәй өстәле әнә теге бүлмәгә хәзерләнгән, әйдәгез, анда рәхим итегез.

Хаҗи. Бәрәкалла, машалла, мин дә чыгып торыймы, Җәлалетдин әфәнде?

Җәлал. Әйдәгез, хаҗи әфәнде, өстәл хәзер булгач та хәбәр бирерләр.

Хаҗи. Хуш, бик әйбәт, бик мәгъкуль. Хәбәр бирерләр диген, ә? Бәрәкалла, бәрәкалла.

Чыгалар. **Нәгыймә** самовар кертә. **Камилә** өстәл әзерли. **Галимә** кызлар кыяфәтендә өстәл янына килеп утыра.

Галимә. Әмма каһәр сукканга бирермен кирәген. Менә күрегез дә торыгыз, Аллаһе теләсә!

Нәгыймә. Йә, булды бугай. Камилә, син бүлмәгә чык инде. Мин барып хәбәр бирәм.

Н ә г ы й м ә белән К а м и л ә чыга, Г а б д е л х а к керә.

Г а б д е л х а к. Фәрештәм! Ярлы бер шагыйрьнең саф мәхәббәтен сез дөнья байлыгына корбан итәсез. Шулай да мин сезгә үпкәләмимм. Юк, юк, мин сезне үлгәнчегә хәтле сөячәкмен. Пар ат җигелгән ялтыравыклы колясаларда утырып үткән чакларда мин сезнең юлыгызга сирень чәчәкләре сибәрмен, бәгърем, фәрештәм! Шуның өчен мин сездән үземнең янган йөрәгем белән үтенәм, бер генә тапкыр ичмасам минем маңгаемнан үбегез, бәгърем!

Г а л и м ә. Бик сөчек телле егет икәнсең. Ярый инде алайса, хәтерең калмасын... Бер үбим үзеңне. *(Үпмәкче була. Габделхак кача.)* Башына тай типкән төсле бәрелеп чыгып китте, юләр! Нишләп килми инде, карт тәре?

Ишектән Х а җ и күренә.

Н ә г ы й м ә. Әйдә, рәхим итегез, хаҗи әфәнде. Сеңелкәш белән танышыгыз. Мин сезгә комачауламыйм.

Х а җ и. Ярар, ярар, сез чыксагыз да ярый, кайнигәч. Бәрәкалла, машалла! Нурлы йөзем, оҗмах кошым, хи-хи-хи! Исәнме, җанкәем. Йә әле, күрешик... Менә бирегәрәк утырыгыз ла, җанкисәгем...

Г а л и м ә. Юк, юк, җаным, ярамый, мин әлегә оялам шул, җаным.

Х а җ и. Ярар, ярар, җанкәем, синеңчә булсын, хи-хи-хи... Ярар, иялешә төшкәч алайса, җанкәем. Думбыра чиерттерә беләсеңме әллә, җанкәем? Хи-хи-хи...

Г а л и м ә. Беләдер идем шул азрак.

Х а җ и. Менә, фаразан, минем яраткан бер көем бар. Фаразан, булдырасыңмы икән? Менә фаразан:

Чөн адәм җәннәттә керди,
Юҗа дәүләтләрә ирди,
Каму илекләри күрди,
Идәрди шөкер илә ихлас.

Әйе, иблис, ләгыйньнең атабыз Адәм галәйһиссәламне, фаразан, җәннәттән чыгаруын сөйли. Мөхәммәдиянең иң кәттә җире, фаразан, белерсеңме икән?

Г а л и м ә. Беләдер идем, әгәр онытмаган булсам.

Х а җ и. Бәрәкалла, әгәр моны белсәң, фаразан, башка көйләреңнең кирәге юк.

Г а л и м ә. Өлкән хатынызгыз думбыра чиерттерә белмидер, ахрысы?

Х а җ и. Өлкән хатыным... Хи-хи-хи... Куй инде, җаным, шул мәче башлы ябалакны! Кеше төсле итеп ашый беләме диген, ичмасам! Сыер шикелле итеп күши бит ул.

Г а л и м ә. Тешләре юкмыни соң?

Х а җ и. Теш юк инде, теш каян килсен!

Г а л и м ә. Шулай да сез аны яратасыз дип ишеткән идем.

Х а җ и. Кем? Минме? Хи-хи-хи... Галимәнеме? Менә инде монысы, җанкәем, чеп-чи ялган. Алдаганнар, җанкәем, сине. Мин аның нәрсәсен яратыйм?.. Әкият, соң ул Галимә — хатынмыни?.. Тфү... Мин ул хатынны күрәсем генә дә килми, кабахәтне, фаразан. Җирәнәм үзеннән хәтта!

Г а л и м ә. Син күптәнме миңа гыйшык тотасың?

Х а җ и. Хи-хи-хи... Мин, былтырдан бирле, җанкәем, ашым аш түгел, суым су түгел, фаразан, сиңа гыйшык тотып йөрим. Тап беренче күрүемдә үк, фаразан.

Г а л и м ә. Әйтсәм әйтим инде, алай булгач, мин дә сиңа гыйшык тота башладым, җанкәем... Әйе...

Х а җ и. Синме, җанкәем? Нишләп соң әлегә кадәр әйтми торасың? Менә син әкият, Алланың хикмәте диген, ә?.. Хи-хи-хи... Йә әле, җанкәем, алай булгач, бер кочаклашып алыйк.

Г а л и м ә. Ярый, кочаклашып алыйк, алайса...

Х а җ и. Сөбханалла, лә хәүлә вә лә куәтә, илла билла.

Г а л и м ә *(хаҗины яңаклый)*. Саташып беттең, каһәр суккыры! Оятсыз! Җир бит!

Башкалар килеп керәләр.

Җ ә л а л. Менә хаҗи әфәндене өйләндердек!

Көләләр.

Пәрдә

ЭЧТӘЛЕК

Кереш 3

Борынгы чор татар әдәбияты

Әдәбият тарихын өйрәнү принциплары 5
Тел 5
Мифлар 6
Халык авыз иҗаты әсәрләре 9
Дин 11
Бөек Болгар дәүләте 14
Кол Гали 17
Йосыф кыйссасы 18
Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастаны 57
Сәйф Сараи иҗаты 58

XIV—XV гасырларда иҗат ителгән әсәрләр

Тарихи шартлар. Мәдәни мохит 60
Идегәй 61
Җик Мәргән 115

Урта гасыр татар әдәбияты (XVII—XVIII гасырлар)

Мәүла Колый 123
Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари 126

XIX гасыр татар әдәбияты

Муса Акъегет 132
Каюм Насыйри 145
Габделҗәббар Кандалый 149
Мәкәрҗә бәете 157
Идрис Багданов 165

XX йөз башы татар әдәбияты

Габдулла Тукай 200
Гаяз Исхакый 238
Дәрдемәнд 278
Галиәсгар Камал 294
Мирхәйдәр Фәйзи 315
Йомгак 344
Мөстәкыйль рәвештә анализ ясау өчен әдәбият 352

Учебное издание

Яхин Альберт Гатинович

ЛИТЕРАТУРА

Учебник по татарской литературе для 9 класса
татарской средней общеобразовательной школы

Издание третье

Казань. Издательство «Магариф». 2007

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

Яхин Альберт Гатинович

ӘДӘБИЯТ

Татар урта гомуми белем бирү мәктәбенең
9 нчы сыйныфы өчен дәреслек

Өченче басма

Редакторы *З. М. Гыйниятова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы
һәм компьютерда биткә салучысы *Л. Г. Зиргизова*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчесе *Э. Ф. Нурмөхәммәтова*
Корректорлары *А. М. Закирова, Г. Р. Ногманова, А. А. Дәүләтова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 04.09.2007.
Форматы $60 \times 90^1/_{16}$. Офсет кәгазе. «Школьная» гарнитурасы.
Офсет басма. Басма табагы 25,5 + форз. 0,39.
Нәшер-хисап табагы 25,5 + форз. 0,25.
Тиражы 5200 д. Заказ С-1131.

«Мәгариф» нәшрияты. 420059. Казан, Оренбург тракты, 20 а.
Тел./факс (843) 277-52-88, 277-52-62.
E-mail: magarif@mail.ru

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы» ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.

Рационализм
Реализм
Мәгърифәтчелек
ШАЛКАН АЛУ ТЕХНОЛОГИЯСЕ